ISSN 0206–4189

казан утлары

4.2004

Нәни Апуш. *Хажимурат Казаков (1914-1984) рәсеме.*

Казан утлары
Qazan utları

2004

4

(978)

ИӘШТЫРУЧЫЛАРЫ:

Татарстан хөкүмәте,
Татарстан Язучылар берлеге,
редакциянең хезмәт коллективы

БАШ МӨХӘРРИР
Равил Фәйзуллин

ИДАРӘ:

Харрас Әюпов
Зилә Вәлиева
Мөдәррис Вәлиев
Фоат Галимуллин
Тәлгат Галиуллин
Миркасыйм Госманов
Алмаз Гыймадиев
(җаваплы сәркатип)
Флүс Латыйфи
(баш мөхәррир урынбасары)
Мирза Мәхмүтов
Туфан Миңнуллин
Хатыйп Миңнегулов
Гәрәй Рәхим
Факил Сафин
Ренат Харис
Зиннур Хисняр
Розалина Шаһиева

Мөхәррирләр: **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Көримов, Марс Шабаев.**

Гамәли хезмәткәрләр: **Радик Вәлиев, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
Исәп-хисап бүлеге: **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркатип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 92-93-16.
Факс — (8432) 43-56-12.
E-mail: kazanutlari@telebit.ru.

Казан утлары

ӘДӘБИ-НӘФИС һӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

ШИГЪРИЯТ һӘМ ҖӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Роберт МИҢНУЛЛИН. Чордашларыма. Шигырьләр. 5
Фоат САДРИЕВ. Бәхетсезләр бәхете. Роман. 12
Фәрит ГАБДЕРӘХИМ. Әйтим әле ярып турыдан. Шигырьләр. 96
Марат КӘБИРОВ. Хикәяләр. 100
Фәйрүзә ИСМӘГЫЙЛЕВА. Яшәү дигән якты алан. Шигырьләр. 112

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Ленар ШӘЕХОВ. Җанда — бер чәчәк... Шигырьләр. 114

ПУБЛИЦИСТИКА

Мирза МӘХМҮТОВ. Мәгълүмати көрәштә мәдәнилек 116

ДИСКУССИЯ: "БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ".

Әхмәт РӘШИТ. Зурдан күбләп сойләшкәндә. 132

ФӘН

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. Гаяз Исхакыйның мөселман көнчыгышына сәяхәте. 140
Гаяз ИСХАКЫЙ. Ислам мәмләкәтләрендә. 146
Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. 154

КИТАП КҮЗӘТҮ

Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ. Иҗат офыклары. 160
Факил ӘМӘК. Кеше, идея һәм әдәбият. 164

Коръән татар телендә. 168

САМАТ ШАКИРНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Камил КӘРИМОВ. Боз кичү. 174

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

Вәсимә ХӘЙРУЛЛИНА. Шигырьләр. 177

ЮМОР-САТИРА

Тәлгать НӘҖМИЕВ. Саба хикмәтләре. 179

Берлекнең яңа әгъзалары. 183
"Казан утлары" архивыннан. 184
Хатлардан юллар. 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. 188

В ЭТОМ НОМЕРЕ:

Журнал выходит один раз в месяц

«Проза и поэзия»: роман Ф. САДРИЕВА «Счатье несчастных» (продолжение трилогии); рассказы М. КАБИРОВА; стихи Р. МИННУЛЛИНА, Ф. ГАБДРАХИМА, Ф. ИСМАГИЛОВОЙ.
«Творчество молодых»: стихи Л. ШАЕХОВА.
«Публицистика»: статья М. МАХМУТОВА «Культура в информационной войне».
«Дискуссия»: «Герой нашего времени»: статья А. РАШИТА об актуальных проблемах современной поэзии.
«Наука»: Х. МИННЕГУЛОВ. «Путешествие Г. Исхаки в мусульманский Восток»; Г. ИСХАКИ. «В исламских странах»; А. ТИМЕРГАЛИН. «Словарь нации».
«Книжное обозрение»: А. ЗАКИРЗЯНОВ. «Горизонты творчества»; Ф. АМАК. «Человек, идея и литература».
Коран на татарском языке.
«Юбилеи»: статья К. КАРИМОВА к 80-летию С. Шакира.
«Мир малышей»: стихи В. ХАЙРУЛЛИНОЙ.
«Юмор-сатира»: Т. НАЗМИЕВ. "Забавные истории".
Новые члены Союза писателей.
Из фотоархива журнала.
Строки из писем.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Первые цветы»—фотоэтюд Н. ИСМАГИЛОВА; поэтесса Э. МУКМИНОВА.

IN THIS ISSUE:

The magazin edits monthly

«Prose and poetry»: Novel by F.SADRIEV «Happiness of unfortunates» (continuation of trilogy); Stories by M. KABIROV; Verses by R. MINNULLIN, F. GABDRAHIM, F. ISMAGILOVA.
«Creativity of the young»: verses by L. SHAEKH.
«Publicism»: article by M. MAHMUTOV «Culture in information war».
«Discussion»: «Hero of our time»: article by A. RASHIT about actual problems of modern poetry.
«Science»: H. MINNEGULOV. «G. Ishaki's Travel to the Muslim East»; G. ISKHAKI. «In Islamic countries; A. TIMERGALIN. «Dictionary of the nation».
«Book's review: A. ZAKIRZYANOV. «Horizons of creativity»; F. AMAK. «Person, idea and literature».
Al Quran in Tatar language.
«Anniversaries»: article by K. KARIMOV to S. Shakir's 80-anniversary «Crossing on ice».
«World of kids»: V. HAJRULLINA'S verses.
«Humor-satire»: T. NAZMIEV. «Amusing stories».
New members of the Union of writers.
From photo archive of the magazine.
Lines from letters.
Diary of public—cultural life.
On our covers: «First flowers N.ISMAGILOV'S photo etude»; Poetess E. MUKMINOVA.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмахана гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция жавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә жыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 19.03.2004 ел. Офсет кәгазь. Кәгазь форматы 70X108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8014. Заказ Э—174
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында терkәлгән. Терkәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2004 ел.

Роберт Миңнуллин

Чордашларыма

Мин яшимен сезнең арагызда,
Мин яшимен сезнең белән бергә.
Барып була сезнең белән яуга,
Кереп була сезнең белән гүргә.

Мин сагынып искә алачакмын
Сезнең белән үткән елларымны.
Мин тагын бер тапкыр үтәр идем
Сезнең белән үткән юлларымны.

Мин дә төшеп калганнардан түгел,
Мин шулай ук әллә кем дә түгел.
Сездән артык җирем булмаса да
Мин, әлбәттә, сездән ким дә түгел.

Белеп яшим мин үз дәрәҗәмне,
Яхшы беләм мин үз урынымны.
Мин юкка да борын салындырмыйм
Һәм күтәрмим юкка борынымны.

Егетлекләр эшләштерсәм дә мин,
Беркемгә дә этлек эшләмәдем.
Беркемгә дә өреп калганым юк,
Беркемне дә юкка тешләмәдем.

Ә үземә өрүчеләр булды,
Мин аларга юри әндәшмәдем.
Миннән талантлылар, батырлар бар—
Мин алардан бер дә көнләшмәдем.

Роберт МИҢНУЛЛИН (1948) — *шагыйрь, публицист, җәмәгать эшлеклесе. Күпсанлы китаплар (балалар өчен шигырьләр, лирика, әдәби һәм иҗтимагый публицистика) авторы. Республиканың Г. Тукай һәм М. Җәлил премияләре, халыкара Г. Х. Андерсен исемендәге Почетлы Диплом лауреаты. Казанда яши.*

Кичерсез мине, кирәк чакта
Сезнең төсле әгәр булалмасам,
Кешеләргә сез эшләгән кадәр
Игелекләр әгәр кылалмасам.

Сезнең белән мин ярышмыйм—сезне
Тырышсаң да узып булмас иде...
Ә шулай да сезнең үзегезгә
Миннән башка кызык булмас иде.

Мин, әлбәттә, сезнең кебек түгел—
Үзгәралмыйм, үзем аңласам да.
Сезнең янда мин чәчкә дә түгел,
Күгәрчен үк була алмасам да.

Курыкмагыз, мин таракан булып
Беркайчан да төшмәм ашыгызга.
Киртә булып ятмам юлыгызга,
Кайгы булып килмәм башыгызга.

Сезгә күбрәк шатлык китерермен,
Мин тоз салмам сезнең ярагызга...
Рәхмәтле мин сезнең һәммәгезгә
Алган өчен мине арагызга.

Мин яратам сезне, чордашларым!
Сез кадерле миңа барыгыз да!
Шуңа күрә дә мин сезнең белән,
Шуңа да мин сезнең яныгызда!

Синең чәчләр әле кара иде

Фәрит Мөхәммәтшинга

Синең чәчләр әле кара иде,
Күңелләрдә дәрман бар иде.
Татарстан Дәүләт Советының
Заллары да безгә тар иде.

Эшләдек без кулдан килгәнен дә,
Килмәгәннәрен дә эшләдек.
Кулдан килмәсә, без тешләшмәдек,
Иреннәрне генә тешләдек.

Кайнар заманның да, Казанның да
Син эченә кереп кайнадың,
Мәскәүнең дә көен көйләдең син,
Казанның да җаен җайладың.

Ә без исә янәшәндә булдык,
Синең белән бергә атладык.
Акладыкмы халык ышанычын?—
Миңа калса, әйе, акладык.

Тик артыгын эшли алмас иде
Кем булса да безнең урында.
Ә чәчләргә чаллар төшкән икән,
Ансы гына аның ерунда!

Чыгармаслар җырлар без яшәгән,
Без эшләгән чорлар турында.
Безнең дәвер үзе җыр шикелле...
Без һәммәбез — тарих кулында.

Болай гына тормас дөньялары,
Килми калмас башка патшалар.
Кайтмый калмас безгә мөстәкыйльлек —
Ансын инде эшләр башкалар.

Тормыш дәвам итәр моннан соң да,
Безнең картаюга карамас...
Ул дәверләр генә кире кайтмас,
Синең чәчләр генә каралмас.

Еникины да озаттык...

Еникины да озаттык...
Дөньялар бушап калды.
Кояшлы көннәребез дә
Төннәргә охшап калды.

Еникины да озаттык...
Ә нинди көчле иде!
Арабыздан бик тиз генә
Ул китмәс төсле иде.

Еникины да озаттык...
Күңелсез, моңсу, читен.
Китеп алып китте кебек
Күңелләрнең бер читен.

Көтелмәгән югалтуга
Дөнья шул бай икән ул.
Еникины да озаттык...
Дөнья шулай икән ул.

Менә шундый ил инде!

Кычкырасың — ишетмиләр...
Чукраклар иле.

Күрсәтәсең — юк, күрмиләр...
Сукырлар иле.

Сорыйсың — җавап бирмиләр...
Телсезләр иле.

Сыныйсың — дога белмиләр...
Динсезләр иле.

Исерекләр һәм угърылар,
Юләрләр иле...

Башкалар күптән гарьләнеп
Үләрләр иде.

Корыч та бирешәдер...

Зәки Зәйнуллинга

Зәки абзый больницада...
Йөрәген тотып ята.
Дарулар йотып ята ул,
Кайсысын тотып ата.

Авыртадыр...
Авыртканга
Йөрәген учлап ята.
Йөрәген учлап ятса да
Каләмен очлап ята.

Ә бит мәйдан тота иде,
Бил бирмәс егет иде,
Гомергә дә бирешмәс һәм
Авырмас кебек иде.

Йөрәге дә тимер иде,
Чыныккан корыч иде.
Һәрбер сүзе өзә торган —
Тутыкмас кылыч иде.

Мин ярый инде...
Мин — шагыйрь,
Миндә гадәти йөрәк.
Шагыйрь йөрәге авыртса,
Антырамаска кирәк.

Минем кебекләргә әле
Чирләү дә килешәдер.
Ә Зәки абзый...
Күрәсең,
Корыч та бирешәдер.

Кая югалдыгыз, татарларым?!

2002 елгы җанисәптән соң
юкка чыккан 200 меңнән артык
Башкортстан татарына мәрсия

Кая булдыгыз сез, татарларым?
Әллә сезне утка тыктылармы?
Әллә инде суга салдылармы,
Йә булмаса, тупка тоттылармы?

Кая югалдыгыз, татарларым? —
Кичә генә әле бар идегез,
Бар идегез, татар идегез бит,
Татарларыбызга пар идегез!

Кая булдыгыз сез, татарларым? —
Хөкемнәргә сезне тарттылармы?
Астылармы сезне, аттылармы?
Төрмәләргә әллә яптылармы?

Килмешәкләр диеп сөрделәрме,
Башка юлын әллә таптылармы?
Әллә инде башка бер халыкка
Коллар итеп сезне саттылармы?

Әллә инде үз-үзегезне сез
Җиңел генә шулай саттыгызмы?
Әби-бабайларның әманәтен
Чүплекләргә тотып аттыгызмы?

Әллә инде милләтегезне сез
Бер яртыга сатып эчтегезме?
Нәрсә булды сезгә, милләттәшләр? —
Шушы көнгә килеп төштегезме?

Ә башкалар әнә үрчи тора, —
Татарларны әллә печтеләрме?
Ник дәшмисез, нигә эндәшмисез —
Телегезне әллә кистеләрме?..

Мин беркемне гаепләмим монда,
Мин бит бары авыр сулыйм гына.
"Кая югалдыгыз, татарлар?" — дип
Мин бит сездән бары сорыйм гына...

Кая булдыгыз сез, татарларым?
Сез кайларга китеп югалдыгыз?
Канлы гасырлардан исән чыгып,
Ничек кенә болай булалдыгыз?

Ишетелә кебек ераклардан
Зарларыгыз сезнең, аһларыгыз...
Яу кырында ничек сирәгәйсә,
Сирәгәя шулай сафларыгыз.

"Каравыл!" дип бөтен дөньясына
Нигә әле оран салмадыгыз?
Ниләр эшләр менә киләчәктә
Бу афәттән исән калганыгыз?..

Ниләр булды сезгә, татарларым? —
Ни дисәң дә сезгә сүз юк инде.
Җиңел булсын авыр туфрагыгыз! —
Татар өчен хәзер сез юк инде...

Яңа гасырлардан әзләр әле
Ұлларыгыз сезне, оныгыгыз!..
Йә, хушыгыз! Йә, бер дога кылыйк!
Җәннәтләрдә булсын урыныгыз!

Биләр

Биләрдә уйный көзге җил,
Зыңлый көзге көйләр.
Тирә-юньне әлек монда
Биләгәндер Биләр...

Монда болгар батырлары
Алышкандыр биллəр.
Тамашаны карагандыр
Падишаһлар, биләр.

Булгандыр алар акыллы,
Йә булгандыр юләр...
Кайнагандыр монда тормыш,
Кайнагандыр Биләр!

Ташка калган таш калалар,
Җырга калган илләр...
Булмагандыр да шикелле
Бөек шәһре Биләр.

Татарны тарих иләгә
Тагын күпме иләр?
Илəнгән дә, игәлгән дә,
Имгәнгән дә Биләр...

Борынгы чал җиллəр генә
Уйный синдә, Биләр...
Көтә безне нинди җиллəр,
Дәшә безне ниләр,
Биләр?..

Татар

Татар белән изгән Рәсәй,
Татар белән баскан.
Татардан башка булалмый, —
Татар баштан ашкан!

Татар күчмә кошлар кебек —
Ул туктаусыз күчә.
Утлар-сулар кичә татар,
Шахталарга төшә.

Тату булып яши белә
Татар барсы белән:
Үрчетә чит миллəтлəрне
Татар башы белән!

Күпме милләт карап тора
Татар күзе белән,
Күпме милләт балкып тора
Татар йөзе белән!

Күпме милләт яшәп ята
Татар каны белән,
Үзе — үзбәк, урыс, башкорт...
Татар — җаны белән.

Татарларны ұлчи алмый
Бернинди дә бизмән...
Татар белән баскан Рәсәй,
Татар белән изгән!

***

С.Г.га

Очты да китте бер Күңел...
Ул инде безнеке түгел.

Ул шул инде читләрнеке...

Ирек сөйгән ул Күңелне
Читлекләргә бикләрлекме?

Очкан күге — чит илләрдә,
Йөзгән күле — чит җирләрдә...

Кайчакларда очып кына
Иленә дә килеп китә —

Җилпенгәндә, канат җиле
Күңелләргә тиеп китә...

Алмаз улыма

Син һаман да миңа бала әле,
Син дип йөрәк һаман яна әле!..

Мин тырыштым күлдан килгән кадәр,
Мин өйрәттем сине... белгән кадәр!

Тик барсын да эшләп калалмадым,
Бу тормышның җаен табалмадым...

Мин дигәнчә генә булмады шул,
Юлларым да кайчак уңмады шул...

Минем белән тормыш вакланмады,
Өметләрнең күбе акланмады...

Шатлыгыма күпләр шатланмады,
Тик намусым, шөкер, тапланмады...

Без мәңгелек түгел беребез дә.
Бер китәрбез без дә... йөрербез дә.

Бөтен дөнья сиңа кала инде.
Дөнья авыр... Үзең кара инде!

Котылу юк сездән!

Сездәй хатын-кызлар бездә генә,
Сездәй хатын-кызлар беркайда юк.

Сезне яратабыз, әмма ләкин
Сезне яратудан бер файда юк.

Сезнең үткен, ут, мут карашыгыз
Телебезне безнең бәйләндерә.

Йөрәкләребезне җилкендерә,
Башыбызны безнең әйләндерә.

Әйләндерсә генә ярар иде,
Югалттыра кайчак башыбызны.

Оныттыра бөтен дөньябызны,
Оныттыра ашар ашыбызны.

Рәхмәт инде — безне аздырасыз,
Аздырасыз безне, туздырасыз.

Күзебезне безнең кыздырасыз,
Акылларыбыздан яздырасыз.

Нилектәндер, безнең җаннарыбыз
Сезнең чибәрлектән эреп китә.

Төп-төз генә барган җиребездән
Кыек юлга алып кереп китә.

Һәм чирләргә безне сабыштыра —
Безне, гүя, пәри алыштыра.

Сезнең хакка күпме утлар кичтек,
Башка яратмам дип антлар эчтек.

Сүзебездә ләкин торалмадык,
Сездән башка берни кыралмадык.

Сез, ахрысы, пәри затыннандыр,
Сез иблискә, ахры, сатылгандыр...

Ничек итсәгез дә итегез лә,
Чукынып тына китегез лә...

Без картайган саен сез матуррак,
Без бөкрәйгән саен сез турырак.

Сез һаман да матур, чибәр, гүзәл,
Бу йөрәкләр, белмим, күпме түзәр?!.

Котылу юк сездән үлгәндә дә,
Сезсез булмас, ахры, гүрләрдә дә.

Рәхмәт инде — газап чиктердегез,
Кирәк чакта гашыйк иттердегез,

Бик кыланып тормадыгыз алай —
Кочтырдыгыз һәм дә үптердегез.

Кирәк чакта юлдан яздырдыгыз,
Чама белеп кенә аздырдыгыз...

Рәхмәт сезгә, инде азып туйгач,
Шушы шигыремне яздырдыгыз.

Фоат Садриев

БӘХЕТСЕЗЛӘР БӘХЕТЕ

РОМАН*

Беренче кисәк

1

Яктырып бетеп килгәндә, Ирек, аяк очларына гына басып, купедан чыгып китте. Туалетка кереп юынгычка борылуга, каршыдагы көзгегә күзе төште һәм ул бер мәлгә өнсез калды: аның чәчләре яртылаш агарган иде! Кимендә биш елга картайган, ябыгып, агарып калган йөзенә ул танымагандай карап торды да, аңардан качарга теләгәндәй, күзләрен чытырдатып йомды. Шул килеш шактый вакыт торды...

Юынганнан соң, тамбурга чыгып, уттай янган маңгаен тәрәзәнең салкын пыяласына терәде. Яфракларын койган, ботакларын күнелсез тырпайтып утыручы агачлар, беренче кырпактан соң чокыр-чакырларда эремичә калган ак карлы урыннар, электр-телефон баганалары артка йөгерә. Бәхетсез жир өстеннән поезд чаба. Поездмы, әллә Иректән язмышымы? Ул кача, коточкыч үлем авызыннан ычкынып кача. Әле кайчан гына күнеленең иң изге, иң мөкатдәс урынында саклаган татлы хыяллары белән Мәскәүгә ашкынган иде. Менә хәзер, әлегә хыялларын мәңгегә ташлап, Мәскәүдән качып бара. Каранғы авыр уйлар шушы поезд белән бергә гүя аны дөрләп янган жәһәннәм утының уртасына сөйриләр...

Казанда көн жилле, күк йөзен күргашындай авыр кара болытлар томалаган, вакыт-вакыт ырашкы сибәли иде. АН—2 самолеты, көчле давылга эләккән корабтай, юл буе чайкалып, кинәт төшеп китеп, бер күтәрелеп очты. Болынкырга житкәч, Иректе, танышлар очрамаса гына ярар иде, дигән уй биләде. Казаннан шушы аэропортка кайтып төшкәч, ул һәрвакыт иксез-чиксез шатлык хисләре кичерә иде. Бүген, киресенчә,

*Роман беркадәр кыскартулар белән басыла. Трилогиянең беренче кисәге 2001 елның 4—6 саннарында дөнья күрде.

Фоат САДРИЕВ (1941) – *язучы, "Таң жиле" романы, "Шаһзаманов эше", "Авыш бәсү икмәге" кебек повесть, хикәяләр, "Их сез, егетләр!..", "Ач төрәзән...", "Кондырлы кодачасы" һ. б. пьесалар авторы. Мәслимдә яши.*

башын пальто якасы эченә яшереп, кызу-кызу адымнар белән Болынкырга читтәнрәк керде, күзгә бәрелмәскә тырышып, таррак тыкрыклардан урый-урый, үзләреннең турына житте. Сөембикә коймаларны, капканы зәп-зәнгәр итеп буяган, веранда да ачык-сары булып балкый иде. Ишек алдына кергәч тә, ул бөтен ихатаның ялт итеп жыештырылганлыгына сокланып торды.

Ачыкчы урынында иде. Ул өйгә кереп ботинкаларын салды да ашыкмыйча гына бөтен жирне карап чыкты. Өйдә элекке вакыттагы сыман ыргытып ташланган кием-салым да, юылмаган савыт-саба да күренми, барысы да тәртиптә, чиста һәм пөхтә иде. Ирек газ плитәсе өстендә торган кәстрүлне ачып карады, итле аш та пешереп куелган икән. Айгөл нишләп мәктәптән кайтмады икән, дип уйлап куйды ул тальтосын сала-сала. Бүтен юньләп ашаганы булмаса да, нишләптер аның бер нәрсә дә кабасы килмәде. Чемоданын ачып, күчтәнәчләрен өстәлгә бушатты, кызына дигән әйберләрне сервантка куйды. Аның күнелендә дә, башында да, ашказанында да бушлык иде. Диванда бераз хәрәкәтсез утырганнан соң, Сөембикәгә шылтыратты.

—Әйе,—дигән таныш тавыш ишетелде трубкадан.

—Исәнме, Сөембикә.

Сөембикә кычкырып жибәрде:

—Ирек?! Син каян?!

—Өйдән,—диде Ирек.

—Ничек кайтып життен?

—Әйбәт кенә. Айгөл нишләп өйдә түгел?

—Ул минем янымда. Өске катта дәресләрен әзерләп утыра. Мин Казаннан шылтыратканнарын көтеп утыра идем. Сөйләшкәч тә кайтып житәрбез. Анда аш бар.

—Тизрәк кайтыгыз,—дип Ирек трубканы куйды.

Абыйсы эшендә юк иде, өенә шылтыратты. Трубканы Алмаз алды.

—Бишлеләргә укыйсыңмы?—диде Ирек исәнләшкәч.

—Бишлеләр бик елгыр шул.—Алмаз кых-кых килеп көлеп куйды.—Аларны тотуы авыр.

—Кара аны, сынатма син. Өйдә тагын кем бар?

—Үзем генә,—диде Алмаз.—Әни мәктәптә, бүген педсовет утырышы, диде.

—Ярар, әти-әниеннәргә Ирек абый Мәскәүдән кайткан, диярсен.

Телефон аша әзләп, Әхнафне дә туры китерә алмады, кайтканын Фәһимәгә генә житкерде. Аннары бакчага чыкты. Анда бөтен яфраклар жыеп яндырылган, агач төпләре казылган иде. Миләш агачының эре кызыл төлгәшләренә ул кызыгып карап торды, авызыннан сулар килеп, берничә миләш өзеп капты. Миләш шактый балланган иде. Шулчак капкадан кереп килүче Сөембикә белән Айгөлне күрде. Кызы сумкасын аяк астына атып бәрде дә, ике колачын жәеп, ана йөгереп килде. Ирек кызын кочаклап алды, күкрәгенә кысып, салкын битләреннән үпте, аның иннәренә ун күлын салган килеш, сулы белән Сөембикәне кочып алды, икесен дә каты итеп кысты һәм аларны ни дәрәжәдә сагынганлыгын шунда гына төшенде.

Өйгә кергәч, Айгөлгә алып кайткан әйберләрен бирде. Кызы сөенеп туймады, фломастерын алып, рәсем ясарга да кереште. Ирек кухня ягына чыкты. Сөембикә газ плитәсен кабызып маташа иде. Ул аны инбашларыннан тотып үзенә таба борды һәм иреннәреннән озак итеп үпте. Алар кара-каршы баскан хәлдә бер-берсенә сынап карап тордылар. Сөембикә бармаклары белән иренен чәчләрен сыпырды һәм аларның агаруына гажәпләнеп баш чайкады. Син ана игътибар итмә, дигандәй, Ирек күл селтәде дә Айгөл янына чыкты, өстәлгә таянып, кызының тырышатырмаша рәсем ясаганын карап торды.

—Кызым, мәктәптә рәхәтме соң?

—Рәхә-әт,—дип сузды Айгөл һәм, карандашын ташлап, тагын әтисен кочып алды.

Аннары китап-дәфтәрләрен алып килде. Дәфтәрләрне ачып, үзенең язганнарын озак итеп ана аңлата-аңлата сөйләгәндә, Ирек кызының

сиздермичә генә үсеп барганлыгын аңлады.

—Әнкәйләр ни хәлләрдә ята?—дип сорады Ирек ашарга утыргач.

—Исән-саулар. Айгөл белән ял саен кайтып киләбез. Бәрәңгеләрен дә алыштык.

—Әйе, мин дә бәрәңге чүпләштем,—дип сүзгә кушылды кызы.

Ирек аның чәчләреннән сыпырып куйды.

—Әти эшли башлады, авыл Советы председателе итте ләр. Халык сораган. Өйгә телефон да керттеләр. Шылтыратасыңмы?

—Бүгенгә шылтыратмам инде. Борчылып көтеп торырлар. Иртәгә абый белән кайтып килербез әле.

Алар шулай хәл-әхвәл сораша-сораша ашап-эчтеләр. Ирек Сөембикәнең елмаюының гадәти түгеллеген, йөзендә элекке нурның кимүен ачык күрде. Моның сәбәпләрен аңларга да була, ләкин аңа калса, бүген, Ирек кайткан көнне, ул кояштай балкып торырга тиеш иде кебек. Ашап туйгач, Сөембикә мунча ягып кайтты. Шулчак ишек кыңгыравы шылтырады. Сөембикә йөгереп барып ачуга, Әхнәф белән Фәһимә килеп керде. Ирекккә алар кочаклашып күрешерләр кебек иде. Ләкин Әхнәф:

—Хәерле кич! Исән-имин кайтып житүең белән!—дип кенә ике кулын сузды.

Кулларын кысышкан хәлдә бер-берсенә шактый вакыт карап тордылар. Табын янына утыргач, Ирек рюмкаларга аракы салды, алар Әхнәф белән эчеп куйдылар, Сөембикә бер йотты, Фәһимә исә авызына якын да китермәде. Кунаклар, табыннан гына кузгалдык, дип аш салдырмадылар, Иректән вәзгләп Мәскәү хәлләрен сораштырдылар. Сөйләшеп утыра торгач, бәлеш тә пешеп чыкты. Аны өстәлгә утыртып кискәч, Ирек тагын рюмкаларын тутырды. Инде эчәбез генә дигәндә, Фәһимә Әхнәфнең кулыннан рюмкасын тартып алды да читкә куйды.

—Фәһимә, син нишлисең, алай ярамый бит инде,—диде Сөембикә.

—Аның нормасы үтәлгән, бүтенгә житәр,—диде Фәһимә көлеп.

Янадан кысташмадылар, бәлешне мактый-мактый ашадылар. Ирек күрешүдән алып бәлешнең төбенә төшкәнгә кадәр бер нәрсәгә гажәпсенеп утырды: әйтерсең ләә Әхнәф белән Фәһимәне алыштырып куйганнар иде. Сөйләшүләре сак, күз карашлары, нәрсәдәндер курыккандай, әрле-бирле бәргәләнә, элеккечә дәртләнеп, бер-берләрен бүлдерә-бүлдерә эчкерсез сөйләшүләр беткән иде. Кунаклар, сәгатькә якын утыргач, китеп бардылар.

—Юынып кайт инде,—диде Сөембикә, Иреккә киемнәрен сузып.

—Ә син?

—Айгөл уянса, куркыр. Арканны ышкып кайтырмын.

Ирек мунчаны чыннан да сагынган иде. Ул барып чишенү белән пар салды һәм ләүкәнең түренә үк менеп утырды. Сөембикә килгәч, аның корсак турындагы кып-кызыл озын жәйне күреп, кычкырып жибәрде:

—Ни булды сина?!

—Кич парк аша кайтканда, хулиганнар һөҗүм итте... Операция ясадылар. Мин әле больницадан чыктым гына,—диде Ирек.

Сөембикә аның юеш тәнен кочаклап алды:

—И, жаныкаем, шушы гына житмәгән иде. Чәчләреңнишләп агарган дисәм, сәбәпләре булган икән шул.

Мунчадан соң урынга яткач, Сөембикә бөтенләй көтмәгән-уйламаган яңалык әйтте:

—Йөкле мин, Ирек...

Бу сүзләрне ишетүгә, Ирек аны күкрәгенә кысты, озак итеп кайнар иреннәреннән үпте.

—Бусында малай алып кайт, яме?

Сөембикә бер сүз дә дәшмәде...

2

Икенче көнне Мәлс карангы төшкәндә генә килде. Алар кочаклашып күрештеләр, Сөембикә өйгә керергә кыстаса да, абыйсы ашыгам дип баш

тартты. Күчтәнәчләр салынган сумкасын алып, Ирек машинага чыгып утырды һәм алар Баллы Төбәккә кузгалдылар.

Алар өйгә кергәндә, әниләре өстәл жыештырып маташа иде. Ирекне күргәч, аның кулындагы сөлгесе идәнгә төшеп китте. Аркасын ястыкка терәп утырган әтиләре дә сикереп торды. Гөлҗамал елый-елый Ирекнең чәчләреннән, ике кулы белән янаклары сыпырды, үзе туктаусыз:

—И, улыкаем, исән генә йөреп кайттыңмы, шулкадәр сагындым. Кайчан кайттың? Ябыгып киткәнсең, әллә чирләдеңме, Ходаем?—дип бер-бер артлы сораулар бирә башлады.

—Әнисе, барысын да берьюлы өймә әле,—диде Хәйри, аны инбашыннан йомшак кына якка этеп.—Син өстәл әзерлә, аннары күпме еласаң да, сүз әйтмибез.

Мәлс белән Ирек өстәл янына утырганда, әниләре аш бүлеп куйган иде инде.

—Сәламәтлекләрегез ничек соң, бер көе генә ятасызмы?—диде Ирек, әле әнисенә, әле әтисенә карап.

Хәйри кеткелдән көлеп куйды:

—Таш кебек, улым. Менә авыл Советын житәкләргә кодаладылар. Сәламәтлегә начар кеше шундый эшкә алынамыни? Әниең кызлар кебек инде ул.

—И-и, картлач! Көлмә инде, көлмә,—диде Гөлҗамал, ана яратып карап.

Ашны ашагач, Ирек кинәт маңгаена сугып куйды:

—Күчтәнәчләрне онытканмын бит,—диде ул сумкасын алып килеп.

Гөлҗамал әфлисун, лимон, өрек ише жиләк-жимешләрне юып өсталга куйды, төзләп утырган самавырдан чәй ясады. Берара ниндидер тынлык урнашты һәм әтиләре Ирекнең күзенә туп-туры карап:

—Син нишләп кайтасы иттең соң әле?—диде.

Ирек өчен бу коточкыч сорау иде. Ул бүген иртәдән бирле шушы сорауның биреләсен көтеп борчылды.

—Райком чакырып кайтарды.

Өй эчендә зур дивар сәгатенең теке-теке йөргәне ишетелеп тора башлады.

—Башлык агымга каршы йөзмәскә иден. Хәзер ни була инде?

Ирек дәшмәде, Мәлс жинел генә итеп:

—Ни булсын инде, бюрода тикшерерләр дә шелтә чәпәрләр,—диде.

Хәйри имән бармагы белән шыкы-шыкы өсталне тәйде:

—Сез мине юләргә санамагыз. Мин барысын да сизеп торам. Моның бөтен хурлыгы мина.—Шулай диде дә Хәйри, чынаяк утыртылган тәлинкәне кулына алды. Аның кулы калтырый, чынаяк белән тәлинкә чыкы-чыкы бер-берсенә бәрелә иде.—Ишетәсеңме, улым?—диде ул Иреккә карап.

—Ишетәм...

—Ишетсән, моны мина үзеннән бүләген дип сана, яме.

Ирек башын аска иде, Гөлҗамал алар янына килеп:

—Ярар инде, әтисе, кайтып кермәс борын баланың йөрәгенә яра ясама,—диде.

—Ә минем йөрәктәге яраны кем ясаган? Шушы балалар түгелмени?

Аның карашына түзә алмыйча, Гөлҗамал тагын кече якка кереп китте.

—Ярар, әти, баш ярылып, күз чыкмаган, барысы да үз урынына утырыр әле,—диде Мәлс.

—Рәхмәт тынычландыруың өчен.—Хәйри алдындагы чынаягын кискен генә читкә алып куйды.—Нишләп шундый акыллы итеп үстердек икән без сине?

—Сез генә түгел.

—Тагын кем соң?

—Менә син агымга каршы йөзмәскә кирәк иде, дисең.—Мәлс, кесәсеннән тарак чыгарып, уч төбен сыпырып-сыпырып куйды.—Тарак белән йонны кирегә сыпырсаң, аның төбендәге бөтен борчалары, көяләре, бозык урыннары күренә. Мин гомер буе агымга каршы бардым. Акылны шул кертмәде микән, әти.

Ул елмаеп Хәйригә карады. Ләкин әтисе аның шаяртуын кабул итмәде.

—Тормыш агымына карышып, сез пычагымны да кыра алмыйсыз! Ул инде үз көенә салынган, аның ярлары ярылган. Син аңа иркенләп агарга юл ач, күренгән киртәләрне алып ат.

—Юк инде, әти, мин партия кушты дип, синең сыман күземне йомып, райком ягыннан искән һәрбер җилгә баш иеп тора алмыйм.

Хәйринең күзләре түгәрәкләнеп китте, ул йодрыгы белән өстәлгә сукты.

—Әле син минем турыда әнә нинди уйда йөрисең икән! Әгәр тискәре булмасаң, син әллә кайчан район белән генә түгел, республика белән житәкчелек итә идең.

—Нигә кирәк минем шулай югары күтәрелү?

—Мина кирәкми, халыкка кирәк!—Хәйри үрелеп чынаягын алды һәм авызын чопырдата-чопырдата чәен эчеп куйды.—Күрмисеңмени ничек бозылганнарын?! Кайберләре акылларын югалтып бара...

—Синең дә күзең ачыла башлаган икән, әти. Хәерлегә булсын...

—Син мине кимсетеп сөйләшмә, малай актыгы!

Аларның арасына тагын Гөлҗамал килеп керде:

—Мәлс улым, әрепләшмә инде шуның белән. Ник үртисең, холкын беләсең бит.

—Син арага кермә, әнисе, ялгыш эләгеп куюы бар.

Мәлс ике кулын өскә күтәрде:

—Ярый инде, бетте, әти, бетте. Гафу ит. Күзгалыйк без.

Гөлҗамал тагын алар янына килеп житте:

—И-и, күргән кебекләр дә булмадым. Китәсез дәмени, балалар? Ирек әллә нишләп китте.

—Ярар, абый, мин, булмаса, бүген күнып кына китәрмен инде,—диде ул. Аннары:—Авыл урамнарын әйләнеп кайтыйм әле, сез ятыгыз, ишекне үзем ачып керермен,—дип өстәде.

Урамда машина янына килеп житкәч, Хәйри сагыш тулы тавыш белән:

—И, балалар, кичерегез инде...—диде. Кулын Мәлсның иңбашына салды.—Гел сиңа эләгә инде, улым...

Мәлс акрын гына көлеп куйды:

—Шулай эләктергәләп торырга син булсаң иде әле, әти...

—Рәхмәт, улым, аңлагач...

—Шуннан соң бераз акыл керә бит.

Алар өчесе дә тыенкы гына көлеп куйдылар. Мәлс машинасын кабызды, Ирек аның янына кереп утырды.

—Мине ак балчык юкыры янында калдырырсың,—диде ул абыйсына. Өч-дүрт минуттан алар тау башында иде инде. Икесе дә төшеп, аста электр утлары белән жемелдәп яткан авылга карап тордылар.

—Син аны һаман оныта алмыйсың бугай.

—Кемне?—диде Ирек.

—Кемне икәнен үзең беләсең. Карангы октябрь төнендә нормаль кеше урам әйләнеп йөрми инде.

—Ни әйтергә дә белмим, абый,—диде Ирек авыр сулап.—Ул искә төшсә, йөрәкне үтмәс пычак белән ярып жибәргән кебек. Әллә язмыш дигән нәрсә чыннан да хак микән дип тә уйлап куям.

—Син, энекәш, ялгышларын кемнәргәдер аударырга тырышучылар фалсәфәсен башыннан чыгарып ташла. Әнә күккә кара—иксез-чиксез галәм, күпме йолдызлар, бөтенесе хәрәкәттә, бөтенесе жемелди, галәм туктаусыз әйләнә, аның үртасында бер генә зат—кеше генә бар. Язмыш та син, тәкъдир дә син, иблис тә, фәрештә дә син үзең.

—Минем көч калмады бугай, абый...

—Ахмак!—дип кычкырып жибәрде Мәлс һәм аны иңбашларыннан тотып жилтерәтеп куйды.—Шундый сүз әйтергә ничек оялмыйсың?! Тормыш ин элек үз-үзең белән көрәшү ул. Син моны китап сүзе дип карама, менә мин

көн саен тан тишегеннән шул көрәшкә ташланам. Йөрәгем ярылганчы, сонгы мускулымның жегәре беткәнче озын көн буе тырышам. Кирәк булса—сугышам, кирәк булса—качам, кирәк булса—алдыйм, кирәк булса ялагайланам, ә чигенмим, икенче көнне тагын тотынам. Кайчакта көн саен, кайчакта икe-өч көнгә бер мәртәбә үләм. Иртән тагын терелеп, әүвәл тезләнәм, аннан тагын аягыма басам. Күзен кан капларан үгез кебек, бернигә карамыйча, тагын шул эшкә тотынам, һәркөн шулай, айлар-еллар буе шулай. Бер көне генә дә—олы бер сугыш.

—Ә кочне каян аласың соң?

—Мина күпме халык карап торганны күр син. Балалардан алып карт-корыга кадәр. Меңнәрчә баш терлек, көн дә акырып, миннән фураж, печән, силос, салам даулый. Меңнәрчә гектар жирләр, туфрагымны эшкәрт, орлык чәч, ашлама керт, жыеп ал, дип ah ора.

Абыйсы киткәч, Ирек, авыр уйларына батып, шактый гына басып торды. Аннары кызы-кызу адымнар белән таудан төшеп китте. Чишмә тыкрыгын узып, югары очка борылды, аяклары ирексездән Sahит Фәхруллиннын капкасы турына алып килде. Алты почмаклы өйнең барлык тәрәзәләреннән якты нур бөркелә иде. Ирек, бер генә минутка туктаып, ул тәрәзәләргә корылган пәрдәләр аша Зәнфирәне күрергә теләгәндәй, текәлеп карап торды. Ләкин өйдә бернинди хәрәкәт сизелмәде. Аның йөрәге күкрәгеннән чыгардай булып типте. Барысы да якты, барысы да жылы көннәр, барысы да чәчәкле, кояшка, йолдызларга төрелгән көннәр, ап-ак карлар, серле томаннар белән өретелгән, кайнар хисләр белән чигелгән, гөнаһсыз уйлар белән балкыган көннәр ераста, бик ераста калган иде инде...

3

Баллы Төбәктән кайтып өч көн узуга, иртүк телефон шылтырады. Райком инструкторы Хисмәтуллин:

—Сез бүген сәгать икегә райком бюросына чакырыласыз, персональ эшегез каралачак,—диде.

Бераздан Ирек, әниләренен хәлен белергә телән, Баллы Төбәккә шылтыраткан иде, Зәнфирәнен әнисе үлгәнлеген, аны бүген уйненрече яртыда жирлиселәрен белде. Шундук авылга ычкынды. Ул кайтып житкәндә, мәетне алып чыгып, ишек алдындагы пар урындык өстенә куйганнар иде. Ирек шунда әтисе белән сүзсез генә күл биреп күреште. Кайгы мәрәсимен Хәйри ачты, Тәзкирәнен гомере бүе намус белән эшләвен, сәламәтлеген дә халык дип, колхоз дип тырышу юлында югалтуын сөйләде. Ул тагын ниләр әйткәндер, тагын кемнәр чыгыш ясагандыр—Ирек ишетмәде дә, күрмәде дә. Аның күзләре Зәнфирәдә генә иде. Күп елаудан кызарып, шешенеп беткән Зәнфирә кулъяулыгы белән туктаусыз күзләрен сөртә, әнисенен женазасы өстенә авып төшәрдәй булып чайкалып куя. Аны бер ягыннан Sahит, икенче ягыннан малае тоткан.

Менә мәетне кабыкка салып, акрын гына урамга алып чыктылар. Зиратка житеп, хатын-кызлар тышкы якта калды. Ирек, капканы атлап кергач, бөтен гәүдәсе белән артына борылды һәм шунда Зәнфирә белән аларнын күзләре очрашты. Әгәр Зәнфирә карашын аска төшермәсә, Ирек күпме басып торган булыр иде—ул моны әйтә алмый. "Күрде, минем кайгысын уртаклашырга кайтканны күрде!"—дип куанды ул эченнән генә. Бу минутларда анын өчен, ә кем белә, бәлкем Зәнфирә өчен дә шушыннан да зуррак, шушыннан да мәгъналерәк нәрсә булмагандыр...

***

...Бюро нәкъ сәгать икедә башланды. Аның ничегрәк узасын инде мен мәртәбә кичергән булса да, Ирек дермантин белән тышланган ике катлы ишекне ачып кергәндә, тәненен эсселе-суыклы булып китүен тойды. Арсланов гадәттәгечә түрдә утыра, инструкторлар стена яныннан урын

алганнар. Хасбулатова, блокнот-ручкасын тотып, түрдәрәк утыра иде. Ирек бюро членнары арасында Вафинның юклыгын абайлады. Арсланов алдындагы кәгазьләрдән кинәт башын күтәреп:

—Ну, с приездом, дезертир!—диде.

Ирекнең әз генә кагылсан да кашлырга торган күнеле ярсып китте.

—Әгәр мыскыллырга уйласагыз, мин хәзер үк чыгып китәчәкмен,—диде ул, һәрбер сүзенә басым ясап.

—Карагыз әле,—диде Арсланов кинаяле елмаеп.—Ирек Хәйриевич Мәскәүдә күпме генә булды, ә ничек үсеп кайткан. Йә, сөйләгез, Сабитов, ни өчен сез, райком бюросы карарын игнорировать итеп, эшегезне беркемгә дә тапшырмыйча, Мәскәүгә китеп бардыгыз?

—Мин сезгә үземнең китү мотивларымны инде ул вакытта ук кат-кат аңлатсам да, тагын бер мәртәбә кабатлыйм: миңа укырга кирәк иде.

—Алай иркенләп йөрергә сезнең урынгыз ат абзары түгел бит,—диде Шәвәлиев.—Без барыбыз да партия Уставына буйсынабыз. Ә сез аны аяк астына салып таптадыгыз.

—Партия Уставы, һәр коммунистны халык өчен кайсы өлкәдә күбрәк файда китерә ала, шунда куюны хуплый. Мин беркайчан да үземне профсоюз булырга әзерләмәдем һәм мин ул эшне булдыра да алмыйм. Мин үземне ижат кешесе дип саныйм. Ә безнең райком...

—Булды!—диде Арсланов аны бүлдереп.—Без Сабитовның уйларын аңладык. Кемнәрдә нинди тәкъдимнәр бар?

Иң элек Шәвәлиев торып басты:

—Редактор вакытында ук Сабитов беркемне дә санга сукмады. Шуның аркасында газетада нинди генә материаллар чыкмады, нинди генә шаушулар купмады. Мәскәүгә командировкага чакыралар, дип мине алдап, укырга кереп кайтты. Бюро утырышы аның бу адымын ике мәртәбә гаепләп, үзенең катый сүзен әйтте. Шуңа да карамастан, Сабитов Мәскәүгә качты һәм менә без аны кире кайтарттык. Аның өчен бюро да, партия уставы да юк. Дөресрәге, Сабитов партиягә түгел, партия Сабитовка хезмәт итәргә тиеш. Ә мондый хәл була алмый. Бүгенге бюро утырышы, минем фикеремчә, бер генә төрле карар кабул итә ала: Сабитовны партия сафларыннан чыгарырга!

Ул урынына утыргач, башын як-якка боргалады, менә мин сезгә әйттемме дигәндәй, бюро членнарына күз уйнаткалап алды.

—Тагын кем чыгыш ясарга тели?—диде Арсланов.

Акрын гына Нәҗмиев күтәрелде.

—Минемчә, монда озак сөйләп торыр нәрсә юк. Сабитовка карата тәрбия чараларының барысы да кулланылды. Безнең белән бер сафта йөреп тә, үзенең дөньяга карашы буенча ул беркайчан да чын коммунист булмаган. Мин Зофәр Шәриповичның фикеренә кушылам.

—Гайса Батталович, сезнең фикерегез?—диде Арсланов.

—Бер качкан малны күпме генә ярсан да, көтүгә ияләштереп булмый,—диде Батталов.—Мин Сабитовны партиягә алганда үк йөрәгемнең бер почмагында аңа ышанмау яткандыгын сизгән идем. Йөрәгем алдамаган икән. Синнән коммунист чыкмады, Ирек Хәйриевич. Кит син безнең сафлардан. Үзең өчен дә, безнең өчен дә шуннан да әйбәте булмас.

—Башка фикерләр бармы?

Шунда Гаскәров сүз сорады.

—Үз гомеремдә мина бик күп кешеләр белән эшләргә туры килде.—Ул, сүзеннән туктап, Иреккә карап торды.—Тормыш безне Ирек Хәйриевич белән дә чәкештергәләп алды. Мин аны "вәжданлы кеше", дияр идем. Минемчә, аңа учет карточкасына язып, шелтә белдерү житкәндер. Гаебен юсын өчен берәр эш тәкъдим итәргә кирәк.

—Тагын фикерләр барма?—диде Арсланов.

Бюро членнары дәшмәделәр.

—Мин Гаскәровның фикерен хуплыйм!—диде Арсланов ниндидер куанычлы тавыш белән.—Без сезгә, Сабитов, "Завод"ка председатель булып

китәргә тәкъдим итәбез. Әйбәт кенә эшләсәгез, мы будем квиты.

Беренченең көтелмәгән бу тәкъдименнән соң булмаделәр тын да алмыйча Иреккә төбәлделәр. Аларның карашында тантана да, астыртын көлү дә, мыскыллау да, кызгану да, хәтта курку да бар иде. "Завод"—районның ин ерак почмагында, урман эченда өч рус авылын берләштерүче колхоз иде. Анда революциягә кадәр бакыр заводы эшләгән, шуңа күрә урманы да завод урманы дип йөртелә. Халкы баш күтәрми эчә, ялкау, вакыты белән кырларда, фермаларда эшләргә кеше булмаудан җәфа чигәләр. Гаепле, яисә үзләренә ошамаган житәкчеләрне райком һәрвакыт шул колхозга сөрә һәм ул, бик тиз арада андагы урыслар белән сугышып, үзе дә эчкечегә сабышып, кешелеген югалткач, шул ук райкомга кайтып егыла иде...

—Дәшмәү—ризалык билгесе,—диде Арсланов һәм, башын артка ташлап, өстән аска таба Иреккә карады.

Ирек теләмәсә дә елмаерга тырышты:

—Бу хурлыклы элмәккә башымны тыкмыйм инде мин. Рәхмәт тәкъдимегез өчен.

Арсланов инбашларын жыерып куйды. Бүлмә тып-тын калды.

—Ул чакта тавышка куям: партия уставын күп мәртәбәләр тупас бозганы өчен Ирек Сабитовны КПСС сафларыннан чыгарырга, дигән бюро членнарының тавыш бирүен сорыйм.

Бюро әгъзалары барысы да кул күтәрделәр.

—Төшерегез. Бертавыштан. Партбилетыгызны биргез,—диде Арсланов.

Ирек, кулларының калтыранган сиздермәскә тырышып, күкрәк кесәсеннән партбилетын чыгарды. Аны шундук Нәжмиев эләктереп алды һәм Арслановка илтеп бирде. Аның партбилетын актарып-актарып карагач, ул:

—Эш бетте, Сабитов, сау булыгыз,—диде.

4

Башка елларны октябрь бәйрәме көнен Мәлс зур шатлык хисләре белән каршы ала, һәр бригадада, һәр фермада терлекчеләр белән тантаналы жыелышлар үздыра, аш табыннары әзерләтә, үзе дә рәхәтләнеп ял итә иде. Быелгы бәйрәм ана шатлык китермәде. Беренче ноябрьдән дәүләткә тапшырабыз дип торган өч йөз башка якын мөгезле эре терлек һәм дунгызның юлы киселде: Яңа елга кадәр районнан дәүләткә мал жибәрү туктатылды. Бу—һалакәт белән бер иде. Шушы кадәр терлекне ике ай буе ашату өчен бер "Биектау" совхозының гына түгел, янадан ике-өч хуҗалык фуражын кушсан да житмәячәк иде. Димәк, симертелгән бу маллар ябыгып сөякке калачак, кырылачак, ничә айлар буе түккән хезмәт, ашаткан азыклар юкка чыгачак. Менә ни өчен Октябрь бәйрәменең икенче көнендә үк Мәлс үзе артыннан Газ-51 машинасын иярткән Чаллыга юл тотты. Ул инде Чаллы юлын ике атна таптый. Башта шәһәр комитетының беренче секретарена барып керде. Алар институтта бергә укыганнар иде. Әсфән ачык йөз белән каршылады, хәтта арткы булмәсенә алып кереп, чәй дә эчердe. Әмма фураж теләнеп килгәнлеген белгәч, чыраен сытты. Алар да өлкә комитеты басымы астында ашлыкларын дәүләткә тапшырып бетерә язганнар, авызларын ачсалар, үпкәләре күренеп тора икән. Шулай да, он комбинаты директорына шылтыратып, ул Мәлска унбиш тонна фураж жибәрергә боерды. Моннан соң Мәлска аның янына тагын ике мәртәбә керергә туры килде. Әсфән, үз районы фонды хисабына жибәрергә кушып, язу биргәндә:

—Янадан күземә күренмә инде, Мәлс,—диде.—Анла: мин сина мөмкин булмаганны эшләдем.

Мәлс рәхмәт әйтеп чыгып китте. Менә бүген тагын Чаллыга бара. Сүз дә юк, ул инде Әсфән янына керә алмый. Моңа кадәр бирелгән фуражларны алганда, комбинат директорына да, башкаларына да өз-мөз күчтәнәчләр

алып килгәләгән иде. Моны ул кабат теләнеп киләчәген белеп, алдан уйлап эшләде. Сәгать жиде тулганда, комбинат директоры бүлмәсендә иде инде. Директор һәрвакыттагыча затлы костюм-чалбардан, ап-ак күлмәктән, кара галстуктан иде. Аның шома йөзе, нечкә бармаклары, сыгылмалы төз гәүдәсе нишләптер он комбинаты өчен әрәм кебек иде.

—Тыңлыйм сезне,—диде директор, калын күзлеге аша илтифатсыз гына карап.

—Фураж бетте,—диде Мәлс.—Бөтен өмет сездә.

—Сез бит инде бик күп алдыгыз,—диде директор, алдындагы кәгазьләргә күз төшергәләп.—Әле үзебезнең район хуҗалыкларының да сезнең кадәр алганнары юк.

—Мина бит бер көндә дүрт тонна фураж кирәк. Совхозда дунгызларның ачтан чинавына түзеп торырлык түгел.

—Нишләтсәгез дә бирә алмыйм. Шәһәрнең кошчылык фермасыннан килгән машиналарны да борып кайтардым.

—Ләкин сез бит разнарядка буенча безгә алтмыш тоннага якын фураж тиеш.

Директор Мәлснның бу сүзләренә авызын кыйшайтып, күлындагы кәгазьләрен селкеп кенә куйды.

—Разнарядка, разнарядка!—диде ул мыскыллаган тавыш белән.—Барысы да шуны сөйли. Онытыгыз сез аны. Канададан бодай көтәбез. Хак булса, килгән диләр. Әле карантин сроты егерме көн. Хушыгыз.

—Һич югы бер көнлек бирегез—дүрт тонна.

—Әлдә сез әйткәнне аңламадыгыз? Тавыклар ачка үлә.

—Ә безнең дунгызлар кырыла. Ичмасам машина буш кайтмасын инде. Совхозда күренергә оят бит.

—Бүлмәне бушатыгыз!

Мәлс аның каршына үк барып утырды.

—Беркая да чыкмыйм. Зинһар дип әйтәм, мин бурычлы булып калмам.

Директор, кәгазь кисәге алып, тиз генә язып күлын куйды да Мәлска сузды:

—Менә ике тонна.

—Кирәкми, алмыйм,—диде Мәлс.

—Нишләп?

—Кайтканчы машина әрәсеннән очып бетә ул. Әйтәм ич, бер көнгә дүрт тонна кирәк мина.

Директор торып басты.

—Может, кырык тонна кирәктер?

Мәлс та сикереп торды:

—Бир разнарядка буенча караланны! Знайт не знаю!

—Нинди кеше син, ә? Оят дигән әйбер бармы синдә?—Директорнын ачудан чырае кызарып бүртенде.

—Бездә нинди оят булсын?!—Мәлс та кызып китте.—Юлда төшеп калган инде ул. Сезнең сыман полировкаланган бүлмәләрдә генә утырмыйбыз без. Әгәр син авыл тормышының ни икәнен белсәң, алай сөйләшмәс иден.

—Минем әти белән әни авылда яши.

—Яшәсә, кайтып печән чабып йөрмисендер әле. Кулларың андыйга охшамаган.

—Мин милиция чакыртам.

—Берничә кешелек наряд чакыр. Әгәр берәү генә килсә, мин аның белән сугышачакмын.

—Кара әле, нинди намуссыз кеше син?!

—Менә син ул намуссыз кеше! Вот намуссыз син!

Директор өстәлдәге телефоннарның берсен алды:

—Алло, Зарифуллин, кер әле мина. Менә хәзер лейтенант керә. Сугышып карарсың аның белән,—диде ул.

Мәлс түя аның сүзләрен ишетмәде дә:

—Кара әле, Локман Баязитович, әтиләрегезгә печән-мазар алтергә кирәк түгелме? Бер дигән урман печәне, борыныгызга бөтереп тыкмалы.

—Кирәкми, берни дә кирәкми, чыгып кына кит!

Ул арада ишектә сары мыеклы, кып-кызыл чырайлы милиция лейтенанты пәйда булды. Шкаф биеклеге бу әзмәверне күргәч, Мәлс шикләнеп тә куйды.

—Кара әле, Зарифуллин... ни... кичәге тикшерүнең протоколларын миңа кертерсез әле.

Әзмәвер чыгып китте. Директор яңадан язды.

—Менә өч тонна, олак!—диде ул.

Мәлс язуны рәхмәт әйтеп алды да:

—Локман Баязитович, тагын берне өстә инде. Хет тәүлеклек булсын,—диде ялварулы тавыш белән.

Директор тамак төбе белән кычкырып жибәрде:

—Олак! Йә... бусын да бирдермим!

Мәлс ишеккә таба чигенде.

—Тагын кайчанрак килим соң?

—Син мине үртисенме?!

Ул арада ишектән күн куртка кигән бер кеше кычкыра-кычкыра килеп керде:

—Мин сезнең өстән обкомга барам, сез тавыкларны кырып бетерәсез!

Мәлс калганын тынлап тормады, чыгып ычкынды. Аннары ул накладнойлар бирә торган Наташа исемле хатын янына керде. Сумкага салынган ун кило балны тотып, шоферы һәм мәктәпнең художнигы Ханов ишек төбендә калдылар. Мәлс Наташаны үтеп киткән бәйрәмнәр белән котлады, шоколад сузды һәм, ишекне ачып, шоферны чакырды.

—Наташа,—диде ул пышылдап кына.—Менә бу сумкада сезгә күчтәнәч бар иде.

—Башны бетерәсез!—диде Наташа.

—Бетмәс, без аны өегезгә илтербез.

Мәлс ана директорның язуын сузды.

—Наташа, жаным, бәгырем, чибәрем, зинһар ике тонна өстәп яз инде.

—Сез нәрсә?!—диде Наташа, тыны беткән кеше кебек башын чайкый-чайкый.—Кул куйганда күрәчәк бит ул аны.

—Күрмәячәк,—диде Мәлс.—Ханов, кер әле.

Художник аның кырында иде инде. Мәлс Наташадан бер бит кәгазь сорап алды.

—Яле, Ханов, Локман Баязитовичның имзасын куеп күрсәт әле.

Ханов "ә" дигәнче анын боерыгын үтәде. Имзаны карагач, Наташаның зәп-зәңгәр сөрмә тарткан күзләре тәлинкә кадәр булдылар. Ул, бер сүз дә әйтә алмыйча, аптырап карап торды.

—Сездән берничек тә котылмак юк икән...

Наташа накладнойны биш тоннага язды, Ханов кул куйды һәм алар, рәхмәт әйтеп, бүлмәдән чыгып киттеләр. Әле ун килограмм ит белән бер банка бал калган, алары склад мөдирен "майларга" кирәк иде...

* * *

Бүген ябалак-ябалак жепшек кар яуды, бөтен дөнья яктырып китте. Шәвәлиевнең әллә кар яуганнан, әллә башка сәбәпле, кәефе күтәренке иде. Сөята кичке алты тулганда, өстәлләрне жыештырып, кайтып китәргә әзерләнгәндә, телефон шылтырады.

—Исәнмесез, Зөфәр Шәрипович.

—О-о, исәнме, Сөембикә!—диде ул иректән елмаеп.—Син дә исән икәнсең, ә?

—Бәлкем бүген очрашырбыз? Күптән сөйләшеп утырган юк ич.

—Мин каршы түгел,—диде Шәвалиев.—Кайда соң?

—Сезнең кабинетта инде.

—Әле бит монда кешеләр китеп бетмәгән.

—Хәзергә минем дә вакытым юк. Сигезләр тулганда килсәм?

—Ярый, килештек.

Шәвәлиев өенә авыз эченнән генә җырлый-җырлый кайтты. Яхшылап ашагач, бераз ял иткәч, хатынына:

—Обкомга информация язасы бар,—дип чыгып китте.

Сигез туларга ун минутларда аның бүлмәсенә Сөембикә килеп керде.

—Арткы ишектән үттеңме?

—Билгеле инде,—диде Сөембикә.—Сезнең бит урам якта дежурныегыз утыра.

Шәвәлиев аның пальтоларын салдырып шифоньерга элде һәм кочакламакчы булды.

—Соңрак, соңрак,—диде Сөембикә читкә тайпылып.

Шәвәлиев аны култыклап, азык-төлек куелган өстәл янына алып килеп утыртты. Ике стаканга яртыдан күбрәк итеп аракы салды.

—Очрашу өчен,—диде ул һәм үзенекен соңгы тамчысына кадәр эчеп куйды.

Сөембикә стаканны авызына якын да китермәде.

—Нишләп инде алай?

—Бераздан, бераздан...

—Йәле, сөйлә, нинди яңалыкларың бар?—Шәвәлиев зур итеп кабып колбаса чәйнәде.

—Партиядән куылган ир белән яшәп ятам, яңалык шул.

Зөфәр Шәрипович аңа сагаеп карады, ләкин Сөембикәнең йөзендә үпкәләү-ачулану билгеләре юк иде.

—Ирек кайткач, мин Арслановка керергә җыенганда, сез туктаттыгыз. Кереп йөрмә, без инде килешендек, каты шелтә генә булачак, дидегез.

—Әйе. Әмма ирен бюрода үзен әллә кем итеп куйды. Миңзаһит Усманович кара яңды. Безнең аңа каршы сөйли алмаганны син яхшы беләсең. Ә син артык беторенмә. Иҗат кешесе барысын да кичерергә, тормыш каршылыкларын жинәргә өйрәнергә тиеш. Юкса ул бармак суырып яза башлый. Газаплы кичерешләр дә язучы өчен файдага гына.

—Файдагамы?

—Ьичшиксез!—диде Шәвәлиев дәртләнеп.—Менә син безнең мәчене генә кара. Аны өйдә ит-колбаса биреп сыйлыйлар. Ул йокыдан башка әйберне белми. Тычканны хәзер танымый да торгандыр инде. Синең язучыңа да уяныргә кирәк иде.

—Икебезнең дуслык өчен!

Ул эчә генә башлауга, Сөембикә үзенең аракысын аның чыраена сипте һәм ике кулы белән этеп жибәрде. Шәвәлиев урындыгы-ние белән төрселдәп идәнгә ауды.

—Кабәхәт жан!—дип кычкырды Сөембикә.—Синең кебекләрне ничек жир күтәрә?!

Мәрәлән торып маташкан Шәвәлиевне ул тагын төртеп жибәрде һәм өстәлнс шешәләре-колбасалары белән бергә аның өстенә аударды. Аяк асты ватылган шешә-стакан ватыклары белән тулды.

—Сөембикә, син нишлисең?! Акылыңа кил!—дип тамак төбе белән кырылдады Шәвәлиев, һаман идәннән күтәрелә алмыйча.

Сөембикә аягындагы бер итеген салды да шуның белән Шәвәлиевкә кизәнеп-кизәнеп бәрә башлады. Тегесе сакланып ике кулы белән чыраен каплады. Сөембикә елый-елый соңгы мәртәбә бәрде дә пальтосын алып чыгып йөгерде. Ул баскычтан төшә-төшә киенде, сәдәфләрен эләктерде һәм, арткы ишектән чыгып, китапханәгә йөгерде. Китапханәне ачып кереп, хәлсезләнеп урындыкка утырды һәм кычкырып еларга тотынды. Башта ул бернн дә уйламады, ярсып елады гына. Күз яшьләре кибеп, ярсуы кими башлагач, тып-тын китапханәнең эчен янгыратып кычкырып жибәрде:

—Барсына үзем гаепле, барысына да үзем! Мин анардан да кабәхәтрәк!

***

Әллә Сөембикә сугудан, әллә пыяла ватыгы тиюдән, Шәвәлиевнең маңгаеннан бераз өстәрәк башы яраланган һәм аннан кан ага иде. Ул, калтырана-калтырана, кульяулыгы белән шул ярасын тоткан хәлдә, идәнгә "Правда" газетасы жәеп, пыяла ватыкларын шуңа жыярга кереште. Шәвәлиевнең куллары-аяклары гына түгел, һәр сөяге, һәр шәмәе калтырый иде. Кинәт ул бүлмә ишеге ачылганны ишетте һәм артына борылып карады. Ишектә, ике кулын кесәсенә тыгып, Арсланов басып тора иде...

Вакыт уза. Ике-өч көнгә бер мәртәбә Ирек авылга кайта, маллар астындагы тиресне чыгара, абзар-куradагы сынган-купкан урыннарны рәтләштерә, әнисе белән озаклап сөйләшеп утыра. Ә менә әтисенең йөзе дә кырысланды, сүзләре дә салкынайды. Ирекнең, көн саен сиздерми генә, кайнар кисәү тыгып куйгандай, йөрәге яна. Аның йөрәген яндырган нәрсә— яза башлаган китабы. Язу өстәле яныннан ул, кырын тына карап аяк очларына басып үткәндәй, жәһәт кенә үтеп китә, Мәскәүдә очныпдәртләнеп йөргән чакларын сагына.

...Әнисе аның бөтен эчке халәтен үтәли күреп йөргән икән. Беркөн төштән соң әтисе эшкә киткәч, Ирек ихатага чыгарга кузгалганда, әнисе йомшак кына:

—Улым, сиңа сүзем бар иде,—дип аны тукталты.—Мәскәүдән кайтканнан бирле эчендә ут синең. Без белмәгән бүтән сәбәп юктыр бит?

—Бар шул, әнкәй,—диде Ирек авыр сулап.—Яза алмыйм мин. Ә аннан башка мина яшәүнең кызыгы юк.

—Язар әйбер таба алмыйсыңмыни?

—Яза башлаган китабым бар минем. Шуны дәвам итә алмыйм.

—Ни турыда соң ул?

—Ул...—Ирек әнисен борчымастайрак сүзләр эзләде, әмма таба алмады.— Ул... ни... мин яңачарак Корһән язмакчы булам...

Әнисенең авызы нидер әйтергә телән ачылган килеш калды, күзләре киерелеп, әллә нинди куркыныч рәвеш алдылар, ул кулларын йодрыклап күкрәгенә кысты.

—Кабатла әле: ни диден?!

—Корһән...

Әнисе йодрыкланган кулларын өскә күтәрде дә, кинәт атылып Ирек каршына килде. Аның йөзе танымаслык булып чалшайган, башы, бөтен гәүдәсе дер-дер калтырый иде.

—Ба-ha-ар, ба-а-ар!—дип хырылдык тавыш белән сүзды ул.—Хәзер үк күземнән югал!

—Әнкәй, туктале...

Ләкин әнисе ана бер генә сүз әйтергә дә юл куймады, ул аны ишетмәде дә.

—Чыгып кит өйдән! Башка кайтып аяк басасың булма!—диде ул, кайнар күз яшьләрен коеп.—Йә Аллам! Күпме гонаһ! Бу бит жир күтәрә алмаслык гонаһ! Дәһриләр уртасында берүзем ялгызым калдым. Төннәр буе саташуларым юкка булмаган, Ходай кисәткән, синең балаң олы гонаһлы, дип кисәтә килгән...

Әнисе елый-елый догалар укырга кереште, Иреккә шикләнеп карый-карый, иске китапларын чиста ашъяулыкка төреп, өйдән алып чыгып китте. Әнисен бу кадәр хафага салырмын, дип ул һич тә уйламаган иде. Чарасызлыктан ни кылырга белмичә, тораташ катты да калды. Озаклаган әнисе китапларын каядыр яшерен килеп керде.

—Бар, өемдә әзен булмасын!—диде ул, ишеккә кулы белән күрсәтеп.

—Әнкәй, туктале...—Ирек әнисен йомшартырлык сүзләр эзләде.— Корһән түгел бит ул... Шуны яңарту гына...

—Корһәнне яңартып булмый! Ул хакта уйлау да гонаһ!—Бу әнисенең тавышы түгел, бу акырып, инрәп елау иде.—Корһән—изге китап! Аллаһе Тәгалә тарафыннан индерелгән! Ул берәү генә! Ул мәңгелек! Син

сөйләгәненне аңлыйсыңмы, аңгыра баш?!—Әнисе күкшелләнеп чыккан иреннәрен кыймылдата-кыймылдата ниндидер дога да укыгач, тирләгән йөзен Иректең йөзенә тери язып якынайды да сулышына буылып пышылдады:—Хәзер үк ул ниятеннән кайт! Бөтенебезгә дә олы афәт килүен теләмәсән, ниятеннән кайт, бөтенләй оныт аны!

—Ярый, әнкәй, аңладым...

—Ю-у-у-ук!—дип сузды әнисе башын чайкап.—Шушы минутта үк әйт: кабат ул хакта үйлап та карамам, диген. Хәзер үк әйт, тәүбә ит!

Әнисенә ул-бу булмагае, дип Иректең коты очты. Шуна күрә башын аска иеп, аның һәр сүзен жөпләп торды:

—Бетте, әнкәй. Ул хакта беркайчан да уйлап та карамам. Шушы минуттан оныттым.

Ләкин әнисе тынычлана алмады.

—Йә, Аллам, бу бит берничек тә юып бетерә торган гөнаһ түгел. Шундый дәһри уйга килергә кирәк бит!.. Болай гына калмый бу. Әллә ниләр булуы бар...—Әнисе почмакка борылып бик озак торгач, кинәт борылды да коточкыч зур булып ачылган шомлы күзләрен Иреккә тибәде.—Син кем икәненне беләсеңме?! Мин әйтергә дә куркам... Аңа каршы ният кылу бит бу... Тәүбә, тәүбә, тәүбә, әйтмәгәнем булсын!

Ирек ишек алдында эшләп йөргәндә дә яныннан китмәде әнисе. Аның тирән уйда, хәсрәттә икәнлеге бөтен кыяфәтенә чыккан иде. Ул Иректе төрлечә үгетләде, иманга, тәүбәгә чакырды, ялварды, үтенде, кыркытты...

Кичкә таба Болынкырга кайтып китергә әзерләнгәч, әнисе ана, берничә кисәккә бөкләп, ак кәтүк жебе белән чорналган кәгазь тоттырды.

—Бу "Аятел-Көрси", улым. Гел күкрәк кесәңдә йөрсен. Ул сине күп бәла-казалардан саклар,—диде. Аннары шыпырт кына өстәп куйды:—Әгәр тегеләр язган әйберләреңне бүген үк яндыр. Яндырырсыңмы?

—Яндырырмын, әнкәй...

Бу вакыйганы Ирек яңадан берничә көн кабат-кабат хәтереннән үткәрде һәм яза башлаган китабына тотына алмавының сәбәбен тәмам аңлап бетерде. "Яңа Коръән"! Исеме генә дә ни тора бит. Никадәр беркатлы, никадәр хыялый, никадәр романтик булган ул. Менләгән язучылар, философлар алынса да, яңа Коръән ижат итү кулларыннан килмәслек эшне ул берүзе башкарам, дип йөрде. Искә төшерергә дә оят. Язам дисең икән, халык тормышына риясыз күз белән кара, аны өйрән, хыял канатларына күтәр, бәгыреңне телгәләгән уй-тойгыларыңны ак кәгазь битләрен көйдерелек итеп яз да яз.

Ирек кулъязмасын яндырмакчы булып кулына алды да берәм-берәм аның битләрен актарырга тотынды. Укый башлагач, кызык кына икән үзе болай.

...Бер-бер артлы ачыла барган кулъязма битләре аны безнең галактиканың Н. планетасына алып китте. Бу серле планетада яшәүче бер метр-метр ярым озынлыктагы затлар гәүдә төзелешләре белән жир кешеләреннән аерылмыйлар. Әмма аларның төннәре алсу, чәчләре, сакал-мыекларе, каш-керфекләре көмеш төсле жемелдән тора. Аларның ирехатыны барысы да актан киенгәннәр, берсендә дә баш киеме юк. Көмеш мыеклы, көмеш сакаллы галактика башлыгы житәкчелегендә бүген жир планетасының язмышы тикшерелә. Жирдә ниндидер бацилла таралды, дип чыгыш ясый берсе. Ин элек ул югары катлауларга үтеп кереп, алар гына авырый башлаган иде. Хәзер өермә кебек бөтен планета халкын бөтереп алды, ди. Бу коточкыч рухи чирне туктату өчен жирнең төрле кыйтгаларына лептон ракеталары жибәрелде, анда яшәүчеләр белән даими контактта торып, төрле сеанслар уздырыла. Әмма аларның рухында бернинди дә янарыш булмады. Безнең фикеребезчә, бердәнбер котылу юлы кешенең үзендә. Кешенең үзенең эчке галәменә үтеп керү шарт... Ин кызганычы шунда, алар безнең тарафтан салынган гигант сәләтләреннең барлыгын да белмичә үлеп китәләр. Бирелгән гомерләреннән яртысын да яши алмыйча үләләр. Галактика башлыгы үз вәкилләрен жир кешеләренә көткару өчен

соңгы сәфәргә жибәрә. Әмма адәм балалары һич кенә дә акылларына килергә уйламыйлар...

Әнисенә сүз бирсә дә, Ирек кулъязмасын яндыра алмады. Гади кәгазь генә түгел иде шул ул. Янадан тотынмаска ант итеп, кулъязмасын газетага төрде дә верандага ук чыгарып куйды. Икенче көнне үк аның тормышында бөтенләй көтелмәгән хәлләр башланды...

***

Төштән соң сәгать икеләрдә ишек кынгыравы шылтырады. Ирек яланөс килеш кенә оялдына чыкты. Каршысында Шәвәлиевнең хатыны Нажия басып тора иде.

—Мөмкинме?—диде Нажия, гаепле кеше кебек ана кыяр-кыймас карап.

—Рәхим итегез...

Нажия акрын гына адымнар белән өйгә керде. Ирек аның пальтосын, бүреген элгәч, залга чыктылар.

Нажия бик озаклап аның күзләренә карап торды. Аның карашыннан Ирек бернидә дә аңлый алмады. Ниһаять, ул сүз башлады:

—Сез икенче секретарь булмәсендә булган сугышны иштегезме?

—Нинди сугыш?—диде Ирек аптырап.

Аның аптыраулы карашыннан Нажия, күрәсен, барысын да аңлады һәм болай диде:

—Алайса анысы кирәкми,—диде Нажия.—Мин бер нәрсә әйтергә килдем: сезне бәхетсез итүемдә мин үземне гаепле саныйм.

Ирек өчен бу чын мәгънәсендә табышмак иде. Болынкырда ничә еллар яшәп, күпме мәртәбәләр аптекага даруга кереп, аның бер генә мәртәбә дә Нажия белән сөйләшкәне булмады.

—Зинһар өчен аңлатыгыз: сез ни турында сөйлисез?—диде ул, аптырашлы күз карашын ана төбәп.

Нажиянең мөлдерәп аккан яшьләре, ирен читләреннән тәгәрәп, тез өстенә куйган ап-ак кулларына тамалар иде.

—Ирек! Зөфәр белән Сөембикә күптән чуалалар бит...

Ирекнең башына китереп сукkандай булды. Нажиянең әйткәннәрен ул аңлады да, аңламады да бугай.

—Мин бит аларның чуалуын сизеп йөрдем. Туктату өчен ни үзем бернә кыла алмадым, ни сезне кисәтмәдем... Мин аны саклыйм, дидем. Абруйны, гаилә тынычлыгын саклыйм, дидем...

Нажия тавышсыз гына елый иде. Ирек аның күз яшьләренең аккануын, кулъяулыгы белән корытырга тырышканын битараф кына күзәтте. Аның нәрсәседер жимерелгән, уе югалган иде.

—Сез мине тыңлый аласызмы? Мин үземнең гаебемне сөйләргә телим.

—Сөйләгез,—диде Ирек.—Ләкин мин сезне берничек тә гаепле итеп саный алмыйм...

—Аныcы сезнең эш... Безнең Зөфәр белән бер мәртәбә зур тавыш чыкты. Сезнең аркада. Сезне укырга жибәрмичә интектергән вакытта...

—Кызык...

—Халык шаулады. Мин түзә алмыйча әйттем: сез аны район халкы каршында жәзалыйсыз, ә үзегез палачка әйләндегез, дидем. Ул атылып-бәрелеп мина ташланды... Ул тарткалаш бик озак барды.—Нажия әллә ничек, сабыйларча кызганыч елмаеп куйды да сүзен дәвам итте:—Тормыш үтте. Кайчак зерә кызганыч, үкенечле булып китә. Мин бит ана киявгә табынып чыккан идем. Тора башлагач, бик акрынлап кына кем икәнен аңлый башладым. Бөтен яшәү рәвешем түзүгә, сабыр итүгә кайтты да калды... Яратмаганга түзү, жан жылысы булмаганга түзү, ялганга түзү... Тормышны халык язмышын хәл итүче кеше белән бәйләдем, дигән өмет жимерелде...

Нажия башын аска иде һәм тынып калды.

—Сез мина ни әйтергә теләдегез соң?—диде Ирек.

—Аңламадыгызмыни?

—Аңладым кебек. Ләкин бу минем башыма керә алмый.

—Мин шушыннан артыгын әйтә алмыйм.

Ирек Нажиянең ничек киенеп чыгып киткәнен күрми дә калды... Аның йөрәгендәге әллә кайчан төзәлеп беткән яраслы кабат ачылды һәм, тәнендәге һәрбер күзәнәкне авырттырып, сулык-сулык тибәргә кереште. Нажия әйткән нәрсәнең булуы мөмкин түгел иде. Ул бит инде Сөембикәне бер мәртәбә гафу итте. Ул чакта да Ирек үзе өчен хурлыклы адымны ясады, үз-үзен аяк астына салып таптады. Ә инде аны Шәвәлиев белән бергә күз алдына китерү дөньядагы иң зур кабәхәтлеккә тиң иде. Юк, Нажия ялгышадыр. Монда нәрсәдер туры килеп бетми. Шул чак Иректән хәтеренә Мәскәүдә Рашат белән очрашуы күз алдына килде. Ул бит аңа шушы үк нәрсәне сиздерде, ачык аңларлык итеп әйтте һәм, Ирекне кызганып, сүзен кире алган булып кыланды. Рашат белерлек булгач, димәк, нидер бар, һәм бу халык арасында йөри. Бәлкем күпләр аңа инде төртеп тә күрсәтәләрдер, артыннан көлеп калалардыр.

Менә тәрәзәдән Сөембикә белән Айгөлнең кайтканы күренде. Иректе ниндидер курку биләп алды. Ул ашыга-кабалана бүрегең, сырмасын, киез итекләрен киеп, агач бакчасына чыкты. Сөембикә белән очрашудан, Нажия сөйләгәннәр турында сүз кузгатудан курка иде ул. Алар кереп киткәндә, көрәк тотып, агач төпләренә кар өйгән булып калды. Ләкин бу эшләү түгел, бернинди мәгънәсез хәрәкәтләну, сөйләшүдән качу гына иде. Менә Сөембикә аны ашарга чакырды. Ирек, аякларын көч-хәл белән сөйрәп атлап, өйгә керде.

—Әти, мин бүген "биш"ле алдым,—диде Айгөл, аның белән үзенен шатлыгын уртаклашырга теләп.

Аның белән һәрвакыт озаклап сөйләшә торган Ирек:

—Әйбәт булган, кызым,—диюдән узмады.

Айгөл үпкәләп, өстәл яныннан китеп барды. Итле бәрәңге бик тәмле булса да, Ирек аны һава йоткандай гына йоттый. Ул, йөзен күтәреп, вакыт-вакыт Сөембикәгә карап алды. Анардан баягы сөйләшүне раслый торган ниндидер билгеләр эзләде, әмма таба алмады.

—Ни булды сина?—диде Сөембикә аптырап.

Ул аның өстәл янына килеп утыргач та йөзенен ничектер кырыс, ямьсез, газаплы икәнлеген күргән иде. Ирек авыз эченнән мыгырдап җавап кайтарды:

—Ни булсын, берни дә булмады...

—Әллә нинди син. Танымыйм.

Ирек, ашавыннан туктап, аңа төбәлде:

—Синең мина берәр әйбер әйтәсең юкмы?—аның иреннәре жинелчә калтырый иде.

—Эчкәнсең дисәм, син айнык, тик ни сөйләвеңне генә анлап булмый.

—Аңлашылмыймы?—диде Ирек, сүзенә әллә нинди астыртын мәгънә салып.—Синең мин белмәгән, ләкин мина сөйләргә тиешле сүзләрең бар кебек...

Сөембикә кызып китте:

—Ирек, мин эштә дә житәрлек талкынып кайтам, ә син табышмак әйтеп утырасың.

—Синең тормышында мин белмәгән нәрсәләр бар, күңелем шулай тоя.

Аның бу сүзләре Сөембикәне сискәндереп жибәрделәр. Йөзеннән ниндидер куркуга охшаган шәүлә чагылып үткәндәй булды.

—Нәрсә инде бу?! Ни кирәк сина?

—Сине күбрәк беләсем килә...

—Ашамасан, бар чыгып тор. Мина өстәлне жыештырырга кирәк.

Ирек, аның шул сүзләрен генә көткәндәй, җәһәт кенә торып, залга чыкты, телевизорны куштыы. Ләкин аның күзләре экранда хәрәкәтләнүче әйберләрне күрсә дә, ул әйберләрнен ни үзләре, ни мәгънәләре башына барып житмәде. Сөембикә берни дә әйтмәгәч, ул бераз жиңеләеп китте.

Ул баштук анын ни турында сораганын аңламавын теләде, аңларга сурәттә, кире кагуын теләде. Чөнки Ирек, әлеге нәрсә расланса, тормышына коточкыч афәт киләсен аңлады. Аның ул афәтне күтәрәрлек көче юк иде. Әлеге нәрсә расланмаган сурәттә генә барысы да искечә калачак иде. Ләкин әле аның расланмавын исбатларга кирәк.

Ул, телевизорны сүндереп, кухня ягына атлады. Сөембикәнен һаман шалтыр-шолтыр савыт-саба җыештыруын күреп, кире борылды.

Сөембикә аның төпченүеннән үзен ин куркыткан нәрсәнен күзгала башлавын сизенде. Ни өчен ул кайтып керү белән анардан нидер әйттерергә тели? Шәвәлиевне куйнавы белән берничек тә төзәтеп булмаслык ялгышлык эшләнгәнен Сөембикә аңлаган иде инде. Әллә Ирекка шул килеп житкәнме? Ул мең төрле эш тапты, кухнядан чыгарга курыкты. Бик соң гына йоклы булмәсендә урын җәйде һәм эчке күлмәктән генә залга керде. Ирек һаман телевизор карап утыра иде. Сөембикә йомшак кына итеп аның инбашына кулын салды.

—Йокларга вакыт...

Ирек хатынының кулын читкә селтәп җибәрде һәм ачулы пышылдап:

—Кагылма мина!—диде.

Сөембикәнең шиге юкка чыкты...

6

Ноябрь-декабрь айлары, сугыштагы олы штурманы хәтерләтеп, барлык халыкны кылбырдак китерүче кайнар көннәр тудырды. Бөтен эшнен тыгылган бер чорында "Биектау" совхозында республика семинары үздыруны китереп керттеләр. Авыл халкының тормыш-көнкүрешен яхшыртуга багышланган бу семинарга унаты районнан ике йөзләп кеше җыелды. Аның белән Министрлар Советы председателенең беренче урынбасары үзе житәкчелек итте. Совхозда күрсәтер әйберләр бар иде. Наратбаш элек-электән сугыш чукмарлары, караклар авылы дип йөртелсә дә, Мәлс Сабитов халык күненләнә ачкыч тапты. Хуҗалык елдан-ел алдынгылар рәтенә күтәрелде. Биредә халыкка хезмәт күрсәтү өчен төзелгән махсус бригада ин зур яңалык иде. Аның турында сөйләүне Арсланов баштук Әнәс Нәбиуллинга йөкләде. Әнәс—аның бертуган абыйсының малае, биредә эшчеләр комитеты председателе. Аны Чабаксар партия—совет мәктәбендә укытып чыгарсалар да, артык эш майтара алмады. Чаллыда әтисе яныңда ике мәртәбә әйләнеп, аерылып, шактый гына салыгра өйрәнеп, инде аларның жаңына төшкәннән сон, абыйсы күз яшьләре белән ялынгач, Арсланов аны бирегә китерткән иде. Ана семинарда чыгыш ясарга күшуы нәкъ менә Әнәсне республика һәм күрше район житәкчеләренә күрсәтү максаты белән эшләнгән иде. Ләкин ул халык алдына чыгу белән, Арсланов кып-кызыл булды. Чөнки Әнәснен күзләре майланып тора, чырае тимгел-тимгел булып кызарган, махмырдан икәнлеге һәркемгә ачык иде. Дөрес, сөйләвен ул начар сөйләмәде, аны бик игътибар белән тыңладылар, чөнки хезмәт күрсәтү бригадасының үзе мактап бетергесез иде. Бу кешеләр халыкка печән-салам ташыйлар, көзен булган ашлыкны китереп бирәләр. Шушы ук бригада кешеләрә тегермән тарта, утын кайтара, такта яра, таз баллоннары тарата. Кешеләр үзләренә кирәкле эшләрне алдан ук бригадирның журналына яздырып кына күялар икән.

Семинарда катнашучыларны авыл кешеләренең үз хуҗалыкларында бернинди мәшәкатьсез бәрәңге үстерүе хәйран калдырды. Барлык бакчаларны совхоз сөрдерә. Йорт хуҗалары бакча башына капчык белән күзәнәкләрен чыгарып күялар да бәрәңге арасына кереп тә карамыйлар. Совхоз техника белән утырта, рәт арасын эшкәртә, күмә, агуын сиптерә, көз көне бәрәңгесен алып бирә.

Совхоз үзәгендәге культура йортына кайткач, Арсланов яңа сортлар белән эшләү тәжрибәсенә дә кин туктальп узды.

—Совхоз директоры Украинага гел барып тора,—диде ул.—Анда борчакның атасы академик Шевченко эшли. Хәзер "Биектау"да шуннан

алып кайтылган "Неосыпающийся", "Труженик" кебек сортлар шактый гектарларда игелә. Сабитов Мәскәү селекционеры Неттевичның да якын дустына әверелгән. Ул чыгарган бодай, арпа, солы сортлары совхоз жирләрендә күкрәп үсә. Республика галимнәре чыгарган яңа сортлар иң элек "Биектау" басуларында районлаштырыла.

Соңыннан авыл хуҗалыгы министры үзә эчкәндә Сабитовның орден-медальләргә тәкъдим ителүе-ителмәве белән кызыксынды. Тискәре җавап ишеткәч, ул Арслановны, мондый кадрларны онытырга ярамый, дип кисәтте.

Семинардан соң икенче көн ул бик күтәренке күңел белән йөрде. Минзаһит Усманович үзенең райкомның беренче секретаре булып эшли башлаган чордагы халәтенә кайтканын сизде. Кешеләр белән күпме генә бәрәшмә, күпме генә тарткалашма, тулаем алганда, алар берсе дә сиННән түбән түгел бит, дип уйлады ул. Житәкчеләр арасында Мәлс Сабитов югыйсә иң жайсысы, иң тешләге. Ә бит төптән уйлап карасаң, совхозны ул житәкләрәндә никадәр эш башкарылган! Эшли башлаган чорында Арслановның уйлары саф, кешеләре, житәкче кадрларга ул яратыбрак карый, каты бәрелүдән, аларның хәтерен калдырудан курка иде. Ә хәзер дөртләп кабына, кайчакларда ни әйткәнен дә белми. Шушы ук нәрсәләр гаиләгә дә күчте. Ничек болай булды соң бу? Үзен фәрештә дип уйламаса да, яхшы кешегә санады бит ул. Вакыт-вакыт аның көч-куәте ташкын булып ургый. Берәрсе каршылык күрсәтсә, тыңламаса, ул нишләгәнен белештерми, әлеге көч каршысындагы киртәне жимерми торып тынмый...

Бүген ул өлкә комитетының оештыру булегендәге дустына шылтыратып, Шәвәлиевне башка районга күчерү мәсьәләсенең торышы белән кызыксынды. "Тиздән, тиздән",—дип җавап бирде ана дусты. Бүлмәсендә кыйналынуынын икенче көнендә Шәвәлиев елый-елый гафу үтенде. "Бер таныш хатыным кулгән иде, исереп өстәлне аударды",—диде.

—Ул хатын кем иде соң?

—Ул безнең районныкы түгел.

—Алдашмыйсызмы?

—Честное партийное,—диде Шәвәлиев, күзен дә йоммыйча.

—Сез, Зөфәр Шәриповнч, партия намусы белән авыз чайкарга өйрәнеп беткәнсез икән.

Шәвәлиев ана куркынып карады.

—Йә, дөресен әйтегез: кем иде ул хатын?

—Мин бит инде әйттем.

—Яхшы түгел. Сезгә беркайчан да таянып булмый икән. Сезнең янда Сабитова булды.

—Юк, юк, юк!—диде Шәвәлиев аягүрә басып.—Сез ничек шундый яла яга аласыз?!

—Әллә мине очраклы килде, дип уйлыйсызмы? Мина бит шылтыратып әйтеләр, хәрмәтле Зөфәр Шәриповнч.

—Алар бутаганнар, ул түгел иде.

—Мин инде аның белән чуалганыгызны күптән сизеп, күреп йөрим. Әгәр мин сорагач, аның кем икәнлеген яшермәгән булсагыз, сезне әле һаман да ун кулым итеп тотар идем.

—Гафу итегез, зинһар, гафу итегез. Мин шул кадәр каушадым...

—Хәзер соң инде. Бер уйласаң, кызык бит, ә? Кечкенә генә әйбер: дөреслек. Шуны әйтү-әйтмәүгә карап, кеше дигәнең ачыла да куя.

Шул көннән башлап, алар юньләп сөйләшмәделәр, ниндидер мәсьәлә буенча мөрәжәгать итәргә туры килсә, эшлекле берничә сүз ташлау белән чикләнделәр.

Инструкторның унай жавабын ишеткәч, аның кәефе күтәрелде. Шулчак кабул итү бүлмәсендә утыручы секретарь кыз керде.

—Минзаһит Усманович, "Биектау"дан сезгә делегация килгән.

—Нинди делегация?—диде ул аптырап.

—Белмим, алты кеше. Эш буенча килдек, диләр.

—Керсеннәр,—диде Арсланов.

Ул аларны ишек янына барып ук каршы алды, һәрберсе белән кул биреп исәнләште.

—Утырыгыз,—диде, урындыкларга күрсәтеп.

Керүчеләр урыннарга теләр-теләмәс кенә урнаштылар. Арслановның борынына фермага гына хас әчкелтем-төчкелтем исләр килеп бәрелде. Аларның терлекчеләр икәнлегенә әлегә исләр ачык дәлил иде. Кыяфәтләре дә шуны сөйли. Киемнәре үтүк-мазар күрмәгән, кайсы свитердан, кайсы костюмнан, араларында урта яшьләрдәге ике хатын-кыз да бар.

—Ягез, тыныйм сезне,—диде Арсланов, керүчеләрнең һәрбersенең жентекләп карап чыккач.

Шулчак алар берьюлы күтәрелделәр дә, кулларын кесәләренә тыгып, аның өстәленә таба атладылар. Арсланов сикереп торып артка чигенә башлады. Кырыс карашлы, житди йөзле бу кешеләр аны нидер эшләтергә киләләр иде. Ул авызын ачып сүз әйтәкәнче, өстәл өстенә шап-шап партия билетлары килеп төшә башлады. Билетларын атып бетергәч, ишеккә юнәлделәр.

—Туктагыз әле,—дип кычкырды Арсланов.—Нәрсә булды? Бу нинди хәл? Аңлатыгыз!

Керүчеләр теләр-теләмәс кенә туктадылар.

—Утырыгыз әле, утыр.—Арсланов аларны берәм-берәм үз куллары белән урындыкларга утыртып чыкты.—Йә, сөйләгез, ни булды?

Араларында илле яшьләрдәге бер ир кеше бар иде. Ул торып басты. Янаклары эчкә баткан, яиге алга чыккан бу кешенең карашы аяктан егарлык ачулы иде.

—Без менә барыбыз да үгезләр симертәбез. Семинарда карап киттегез бит,—диде әлегә кеше.—Малларны октябрь азагында ук дәүләткә тапшырырга тиеш идек. Ничә айлар буе, алны-ялны белмичә тырышып, шәп итеп симерттек. Елкылдап тораләр иде. Хет сыртларында пәке үткенлә. Симерүе житкән малны шул көе саклау өчен күпме ашатырга кирәклегең сез беләсездер. Бер ай эчендә безнең терлекләр ярты авырлыкларын ташладылар.—Шулай дип, бу куркыныч ир төкереген йотты да кинәт кычкырып жибәрде:

—Ник саттырмыйсын син аларны?!—Ул яргаланган, бака кабыгы төсле тырнакларын күбеп беткән көрәктәй кулларын кинәт Арсановка таба сузды:

—Кара менә бу кулларга!—Ул ике бармагы белән авыз читен каерып, сарганең, череп беткән тешләрен күрсәтте:

—Күрәсеңме боларны? Туганнан бирле шул фермада без. Ә син безнең хезмәтне юкка чыгарып ятучы корткыч икәнсен!

—Туктагыз әле, сез дөрес аңламыйсыз,—дип аны бүләргә тырышты Арсланов.

—Дөрес аңлыйм!—диде әлегә кеше.

Бу вакытта аның янына тагы ике хатын-кыз да торып басты.

—Кирәкми партбилетыгыз,—дип елап жибәрде хатыннарның берсе.—Ничә елдар буе бездән жыйган взнос акчаларына үзенә кием-салым алып ки. Тьфу, оятсыз син!

Алар дәррәү күтәрелделәр дә, дөбер-дөбер атлап, бүлмәдән чыгып киттеләр.

Арсланов лырык итеп урындыгына утырды һәм, ике кулы белән янагына таянып, хәрәкәтсез калды. Бу нәрсәне белә ул. Семинарга әзерләнгәндә, тавыш-гауга чыга күрмәсен дип, фураж кайтарып котыльган иде. Болынкырда райкомга партия билетлары китереп ташлаганнар икән, дигән хәбәр өлкә комитетына барып житсә, ул иртәгә бу урында утырмаячак. Минзәнит Усманович, ник икәнен дә белмичә, партия билетларын актара башлады. Аларның дүртесен ул үзе биргән булып чыкты. Кызганычка каршы, ул әлегә коммунистларны әйле-шәйле дә хәтерләмәде. Ниһаять, аның күнеленда бер сорау бөтерелә башлады: бу хәтәр эшкә терлекчеләр үзләре алынганмы, әллә берәрсе котыртканмы? "Биектау"да мона этәрердәй бер генә кеше бар: ул—Мәлс Сабитов. Этәргәнме-юкмы, һәрхәлдә терлекләрне сатарга рөхсәт иттермәуне бу кешеләргә ул житкергән—бусы бәхәссез.

Симертелгән малны тапшырмауның коточкыч нәрсә икәнлеген Арсланов үзе дә бик аңлый, ләкин тормыш шундый итеп китереп куйса, кайчакларда ярый торган гамәлләрә караганда ярамый торганнарын күбрәк эшләргә туры килә. Инде районның бәйлегы ит планы үтәлгән. Аны тагын да арттырыбрак жибәрсән, әйтик, йөз егерме процентка үтәсән, алдагы елда ул шуннан кимителмәячәк кенә түгел, йөз утыз процент күләмендә биреләчәк. Гыйнвар аеннан үк өлкә комитетыннан да, министрлыктан да беренче квартал планын үтәргә тыкырдата башлагач, син нишләргә тиеш буласын? Хәзергесе көндә район хуҗалыкларында бүген үк тапшырырлык югары көрлектәге дуңгызлар, үгезләр барын Арсланов бик яхшы белә. Аларның гел кирәксезгә күпме азык ашавын, дистәләрчә-йөзләрчә кешеләрнең хезмәтен юкка суыруын, йөз меңнәрчә сум зыян китерүен дә белә. Ләкин башка чара юк. Әгәр быел бу терлекләрне тапшырып, сина рәхмәт әйтсәләр, алдагы ел планыңны элеккечә калдырсалар, әлбәттә, Арсланов моңа сөенә-сөенә барыр иде. Ин хәтәре—моның бөтен республика, ил буенча шулай эшләнүенә. Үзәк Комитетта яисә Министрлар Советында берәр акыллы баш табылып, күпме байлыкның, күпме кеше хезмәтенең жилгә очканлыгын хисаплап караса, ул акылыннан шашар иде. Беркем дә моны хисапларга теләми, акылдан язучы да юк, гомер бye шулай дәвам итә.

Кинәт аның башына тагын бер фикер килде: әгәр бу эшнс Шәвәлиев оештырса? Моның да булу ихтималы бар ич. Арсланов барысын да әйтеп ташлавы белән ялгышты ахрысы. Хәзер аның ниңди ниятләр белән ниләр кылып йөргәнен каян белəсен? Шулай да мәсьәләнең асылын аңлау өчен беренче чиратта эшнс "Биектау"ның үзеннән башларга кирәк. Ул секретарь кызга Сабитовны, партком Нуриевны һәм профком Нәбиуллинны ашыгыч чакыртырга кушты.

Күрәсең, бүгенге көн аның семинардан соңгы икс төүлек тыныч кына йөрүеннән үч алу өчен туган көн иде. Өйлә турына кадәр туктаусыз халык агылды. Арсланов "Биектау"лар юкмы, дип гел сорап торды, ләкин аларның берсе дә килмәде. Сабитов белән Нәбиуллин фураж юлларга чыгып киткәннәр, Нуриев район үзәгенә күргәзмә материаллар өчен кирәк-ярак эзләп йөри, диде секретарь. Төштән соң ВЛКСМ райкомының беренче секретаре Рәфгать Хажиев килеп керде.

—Минзаһит Усманович, безнең бер проблема килеп чыкты бит әле,— дип сүз башлады ул.

—Проблемалар чыгарга тиеш,—диде Арсланов.—Без аларны чишәргә тиеш. Шулай итмәгәндә, ниңди тормыш була инде ул.

—Эльза чыгыш ясаудан баш тарта.

Арслановның йөрәге чәнчеп куйды. Фермаларда-кырларда эшче куллар күзгә күренеп кимегәч, урта мәктәп бетерүче яшьләрне класслары белән авылда калдыра башлаганнар иде. Узган ел Арсланов үзенең кызы Эльзаны, мең төрле вәгъдәләр белән кызыктырып, колхозда калырга үгетләде. Икенче елны ук институтка китәрсең, диде, укырга керүенне үзем гарантиялим, дип ышандырды. Беренче секретарьның үз кызы калырга теләк белдергәч, башкалар аңа иярми ништәсен? Эльза язалаштты һәм ул чыннан да көтелгән нәтиҗәне бирде. Иртәгә Эльза чыгарылыш классы укучылары җыелышында авылда калырга өндәп чыгыш ясарга тиеш иде.

—Ярый, бусын мин сиңнән, Хажиев, комсомол порученисе итеп үз өстемә алам,—диде Арсланов елмаеп.

Хажиев чыгып киткәч, ишектән Нуриев тәрәрәп килеп керде. Аркылысыбуе бер, озынлыгы метр ярым чамасы, түгәрәк чырайлы, түп-түгәрәк соры күзле, куркудан күзләрен һәрвакыт челт-челт йомып торучы бу кеше туганнан бирле шул Наратбашта әле авыл Советы председателе, әле партком секретаре булып эшли иде. Уч төпләре тирләп чыккан кечкенә кайнар кулы белән Арслановның кулын кысканнан соң, ул читтәге урындыкка барып утырды. Чалбар кесәсеннән кулъяулык алып, ашыга-кабалана битләрен сөртте.

—Син ник чакырганны беләсеңме?
—Юк, иптәш Арсланов.
—Кил әле минем янга.
—Киләм, иптәш Арсланов.—Нуриев, авызын кулъяулыгы белән тоткан килеш, аякларын шудыра-шудыра атлап, аның каршына килде.
Минзәһит Усмановичның борынына аракы катыш канәфер исе бәрелде.
—Син эчкәнсең бит.
—Эчтем, иптәш Арсланов,—диде Нуриев баш селкетеп.—Төнлә кодалар килгән иде. Шуна күрә төшкә кадәр сезнең янга килүдән качып йөрдем.
—Бер өйрәнгән гадәтне ташлый алмыйсың син.
—Ташлый алмыйм, иптәш Арсланов.—Ул мангаеннан атылып чыккан борчак-борчак тирләрен сөртеп алды.—Ташларга тырышам, ташлый алмыйм, иптәш Арсланов.
—Пенсиягә ике ел калдымы әле сина?
—Ел ярым, иптәш Арсланов.
—Да-а, әйбәт түгел бит.
—Әйбәт түгел, иптәш Арсланов, үзем дә беләм.
—Партком секретаре эчеп йөргәч, башкалар нишләргә тиеш була инде?
—Сез нәрсә, иптәш Арсланов?! Эш вакытында эчеп йөрсәм, мине ин элек Мәлс Хәйриевич сугып үтерә...
—Ярый әле ул бар,—диде Арсланов аның белән килешкәндәй һәм партбилетларын сузды.—Менә моны син оештырдынмы?
Нуриев партбилетларны дерелдек кулларына алды, берәм-берәм ачып карый башлады, яртысы идәнгә коелды. Ух-вах килеп, чүгәләп алып, аларның һәрбересен карап чыкты. Кесәсеннән валидол алып авызына капты.
—Мин бернн дә белмим,—диде ул калтыранган тавыш белән.—Мин шушы эшкә барамны курыкмыйча? Алла сакласын, иптәш Арсланов!
—Сине алла сакламас, сакласак, без сакларбыз.
—Зинһар саклагыз инде, иптәш Арсланов,—диде зиһене тәмам чуалган секретарь, ни әйтергә дә белмичә.
—Ә кем оештырырга мөмкин моны?
—Белмим, иптәш Арсланов.
—Син коммунистларын белән юньләп эшләсәң, моңдый хәл булмас иде. Бар, билетларны алып кайтып өләш үзләренә.
—Мин булдыра алмыйм, иптәш Арсланов... Алар миннән алмаячак.
Арсланов дөпелдәтеп йодрыгы белән өстәлгә сукты:
—Миңа үз коммунистларына баш була алмаган партком секретаре кирәкми! Йә алып кайтып өләшәсең, яисә...
Нуриев акрын тына борылып, чаштыр-чоштыр атлап ишеккә юнәлде. Ләкин ишеккә барып житкәч, маңгаена китереп сукканда, ул кискен борылды да кабаланып Минзәһит Усмановичның каршына килде һәм билетларны өстәлгә ташлады.
—Теләсә нәрсә эшләтегез, иптәш Арсланов...—аның иреннәре, борын эфраклары калтырый иде.—Мин булдыра алмыйм!.. Алар мина бөркөн әйткәннәр иде: әгәр терлекләрне саттырмасагыз, партбилетларны райкомга илтеп ыргытабыз, дип...
—Нишләп безне кисәтмәдең?
—Кисәттем. Семинарга әзерләнгән чакта иптәш Шәвәлиевкә әйттем.
—Соң шуннан?
—Ул кычкырып көлде генә.
Арсланов башын игән килеш шактый сүзсез утырды.
—Ул көлде генәме, берәр сүз дә әйттеме?
Нуриев, күзләрен кысып, шактый озак вакыт уйланып торды һәм авыр сулап:
—Көлде генә,—дип тукталып калды. Аннары бүлмәдә башка беше юк микән дигандәй, як-ягына каранып алды.—Кеше ышанмаслык сүзне чын булса да сөйләмә, адәм көлкесенә калырсың, диде. Әйе, хәтеремә төште, иптәш Арсланов, шулай дигән икән ул.

—Хәзер мин Шәвәлиевне чакырып кертәм.

Минзаһит Усманович әлеге сүзләрне әйтеп тә бетерә алмады, ысылдап килгән ата каз кебек, Нуриев аңа таба ике күлын жилпи башлады.

—Юк, юк, иптәш Арсланов, чакыра күрмәгез. Кем белә, бутала да торганмындыр мин. Әйтте микән соң әле ул аны? Әйтмәгән сыман да тия ул, иптәш Арсланов.

—Кара әле, Нуриев, сиңа кайчан да булса ышанырга-таянырга буламы соң?—дип сорады ул, маңгаен ачулы жыерып.

—Була, иптәш Арсланов, була.

—Кайчан?

—Мин үлгәч, иптәш Арсланов.

Минзаһит Усманович тыела алмыйча көлеп жибәрде. Ул озак итеп, күзеннән яшь чыкканчы көлде. Күльяулыгы белән яшьләрен сөртеп, башын күтәрсә, аптыраштa калды: Нуриевның күзеннән мөлдерәп яшь ага иде.

—Бусын ничек аңларга соң инде?

—Эх, иптәш Арсланов!..—Нуриев күз яшьләрен дә сөртмичә сөйләп китте:—Тормыш мине шундый итеп кыйнады, минем бер исән сөягем дә калмады. Бөтен фажига минем белем алырга мөмкинлегем булмауда. Әллә ничә анадан, әллә ничә атадан жыелган тугыз бала әби белән бабай күл астында үстек без. Шул балаларны туйдырыйм, дип ниләр генә күрмәдем. Колхоз ашлыгын урлаганда, әллә ничә мәртәбә тотып, үтергәнче кыйнадылар. Урламасаң, бабай чыбыркы белән яра иде. Аннары бабай чыбыркысын партия чыбыркысы алыштырды. Ни кушсалар, шуна йөгердем. Шуна гына аптырыйм, минем күнелемдә беркемгә дә рәнҗү булмады. Әйтерсең, мин бу дөньяга шуның өчен яратылган... Мина, кая кусалар, нинди эш кушсалар да, барыбер. Бабай чыбыркысының эзләре хәзер дә сыртымда ярылып ята. Партия чыбыркысыныкы йөрәктә... Өйләнгәч, совхоз кечкенә булса да фатир бирде. Менә шунда яшәп ятабыз хатын белән. Бәхетсезлегемә каршы, ул да чирләшкә булып чыкты. Беренче группа аның. Балаларыбыз булмады. Бала урынына көн саен кайтам да аракы шешәсе белән песине сөям.

Арсланов тамак төбен нидер яндыруын тойды. Йомшавын күрсәтмәс өчен ашыга-кабалана, тавышын мөмкин кадәр ачулы итәргә тырышып:

—Ярар, олы башын белән жебеп торма,—диде.—Сөйли китсән, беркемнең дә капчыгы буш түгел.

—Гафу итегез, иптәш Арсланов. Мин теләмәгән идем, әллә ничек килеп чыкты бит...

—Ярый, кайт, разберись: кем башлаган бу эшне, кем котыртқан аларны?

—Тыныштырып карармын, иптәш Арсланов.

Кич эштән кайтып өстәл янына утыргач, Минзаһит:

—Эльза кайттымы?—дип сорады.

—Бүлмәсендә китап укый,—дип жавап бирде Хәят.

Минзаһит кызын чакырып кертмәкче булган иде дә, тагын ул уеннан кире кайтты. Юньләп кенә ашыйм әле, дип уйлады ул. Ләкин барыбер тынычлап ашарга туры килмәде. Ишектә кыңгырау тавышы ишетелде. Хәят йөгереп барып ачуга, анда Әнәс тавышы ишетелде. Аның Хәят белән күрешкәне, үзен райкомга чакырганнарын, соңрап кайтуы сәбәпле өлгермәвен, тагын нәрсәләрдер әйтеп аклануын Минзаһит кайнар бәлеш чәйни-чәйни, яратмыйча тыңлап утырды. Кычкырып сөйләшүенә караганда, ул ару гына жибәргән иде. Әнәс кухняга килеп керде. Абыйсының бу малаен үтә дә әрсез, үтә дә тиктормас, килгән саен нәрсәне дә булса ватканы өчен Минзаһит бала чактан ук яратмады. Шуның өстенә Әнәс үтә дә ялганчы иде. Пелөшләнә башлаган кечкенә башындагы сирәк сары чәчләрен күлы белән сыпыргач, ул үтә нык кычкырып:

—Исәнме, Минзаһит абый!—диде.

Шушы бәләкәй генә юка гәүдәдән, нечкә генә иреннәр арасыннан шул кадәр тавышның чыгуына ышанып та бетәрлек түгел иде. Минзаһит урынннан торды, аларга күл бирепе күрештеләр. Әнәс, утыр дигәнне дә

көтмичә. Хәятнең урынына барып утырды. Хәят ана икенче урындыкка күрсәтте һәм алдына бәлеш бүлеп куйды. Хатынының рюмка тотып килүен күргәч, Минзаһит ана ачулы караш ташлады. Хәят, кире борылып, бокалга шифалы су салып куйды.

—Йә, ни хәлләр бар, энекәш?—диде Минзаһит теш арасыннан.

—Эш белән йөреп, килеп житешә алмадым, гафу ит, абый.

—Ә лыкынырга өлгергәнсең. Совхоз "Москвич"ының рулендәме?

—Жәяү йөри алмыйм ла инде мин,—диде Әнәс, үпкәләгән кебегрәк итеп.

—Аша әле, Әнәс, бәлешне суытма,—диде Хәят, сүзне икенчегә борып булмасмы, дигән өмет белән.

Ул арада Эльза кереп сервантка сөялде. Анын урыс биялә кадәр халатыннан күкрәкләренең яртысы күренеп тора, астан ботлары шулай ук ачык иде.

—Әзрәк кешечәрәк киенеп булмыймыни?—диде Минзаһит, кызына ачулы караш ташлап.

—Ә нәрсә булган?—диде Эльза, шәрә ботларын сыпырып куеп.

—Чит кеше бар бит, кызым.

—Нишләп инде, әни, Әнәс абый чит кеше булсын?

—Эльза,—диде Арсланов кискен генә.—Бар әле чыгып тор. Безнең бик житди сүзебез бар.

—Семья бюросымыни?—Эльза мыскыллап көлеп жибәрде.—Не завидую мин сина, Әнәс абый.

—Ничего, чират сина да житәр, әзерләнә тор,—диде Арсланов, ана таба кул селтәп.

Эльза күнядан ишекне каты ябып чыгып китте.

—Син мине позорить иткәненне аңлыйсынмы,—дип башлады Минзаһит.—Семинарда чыгыш ясадың, чыраена карамалы түгел. Бүген килгәнсең, шыр исерек. Партком секретарегыз исерек. Нәрсә, сез анда әллә эчеп кенә ятасызмы?

—Нишләп эчеп ятыйк, шулай туры килде инде, абый. Гафу...—Сүзен әйтеп бетергәнче, аны бик каты очкылык тота башлады. Ул бокалдагы суын да эчеп карады, әмма моның файдасы тимәде.

—Йә, сөйлә, киләчәккә планнар нинди инде синең?

—Эшләргә...

—Эшләү булыр микән соң? Хәят, син ничек уйлыйсың?

—Сина, Әнәс, үзенне кулга алырга вакыт,—диде Хәят.

—Мин нишләгән соң әле?—Әнәс оятсыз күзләре белән аларга карап торды.

—Без барыбыз да авылда яшибез,—дип дәвам итте Хәят.—Һәр адымыбызны кеше карап тора. Ә синекен, беренче секретарның энесе булараҡ, бигрәк тә игътибар белән күзәтәләр. Эчәргә яратасың, хатын-кызларны да чит куймыйсың, дигән хәбәрләр йөри.

—Менә соңгысы дөрес түгел инде,—диде Әнәс, очкылык тота-тота.

—Син башта ирен читендәге помаданы сөрт, аннары сөйләшерсең,—диде Минзаһит.

Әнәс тиз генә кулъяулыгы белән ироннәрен сөртеп алды, әмма йөзенә әз генә дә кызыллык билгесе чыкмады.

—Ә-ә, бухгалтериягә кергәч, кемдер шунда шаяртып үпкән иде...

—Ярый, син ул әкиятеңне кайткач хатыныңа сөйләрсең. Мин сине кисәтеп куям: әгәр үзгәрмәсәң, районда сина эш булмаячак, аңладыңмы?

—Аң... аңладым...—диде Әнәс, очкылыгыннан туктый алмыйча, һәм урынынан торды.

Ишектән чыкканда, Минзаһит ана:

—Совхозыгызда ЧП бар, шуның сәбәпләрен ачыкларга кирәк,—диде.

Ашаунын тәме калмаган иде инде. Минзаһит кабаланып бәлешен капкалап бетерде дә, чәйне соңрак эчәрбез, дип залга чыгып китте.

—Эльза, кил әле,—дип дәште ул кызына.

Үзенең бүлмәсеннән, башын горур тотып, Эльза залга чыкты. Ул аяк йөзләренә кадәр төшеп торган халат киеп өлгергән. Чибәр иде аның кызы. Нәкъ әнисенекс төсле ап-ак түгәрәк йөз, чем-кара чәчләр, шундый ук куе кашлар, озын керфекләр, шомырттай күзләр. Гәүдәсе дә артык юан да түгел, артык нечкә дә түгел. Буе да тап-таман, билләре дә өзелеп тора. Эльза диванның икенче башына утырды.

—Әти, бүген бюрода нинди мәсьәлә карала?—диде ул, киная белән елмаеп.

Минзаһитның хәтере калды. Кызының җае чыккан саен чәнчеп алуы аны кайчак рәнжетә, күп вакытта ачуын кабарта иде. Ул якынрак килеп утырды.

—Кызым, нишләп син укучылар алдында чыгыш ясаудан баш тарттың? Сәбәп нәрсәдә?

—Әти, син аны яхшы беләсең. Мин үзебезнең класс белән бергәләп колхозга эшкә дип калдым. Фермада өч ай йөрмәдем, райкомолга урнаштырдың. Хәзер сез мине институтка керергә әйдисез. Минем шул балаларга, авылда калыгыз, менә мин калдым, дияргә хакым бар микән?

—Син бит беркөн риза идең.

—Әни белән киңәшкәч, кире уйладым.

—Менә хәзер аңлашылды. Хәят, чык әле бирегә!

Хатыны кулына сөлтесен тоткан килеш залга керде.

—Син нәрсә баланың башын бутап ятасың?

—Бу очракта син ялгышасың,—диде Хәят.—Ин элек син минем хакта уйлап кара. Эльза чыгыш ясаганда ук мина бармак белән төртеп күрсәтәчәкләр бит. Әнә Татарстанның атказанган укытучысы Хәят Арсланова былтыр үз баласын колхозда эшләргә дип алып калды, райкомолга урнаштырды, хәзер башкаларны авылда калырга үгетләтә, диячәкләр. Үзенне дә уйла. Эльза институтка кергәч, ин элгәре бөтен Болынкыр, сонрак бөтен район шул хакта шаулаячак. Халыкның телендә без икебез—синең белән мин булачакбыз. Дөрес түгелмени?

Ул сөйләгән саен Арсановның башы аска иелә барды. Хатынының фикерен юкка чыгарырлык аның бер генә юньле дәлиле дә юк иде.

—Бер уйлаганда, сез хаклы.—Ул чигәсен кулы белән кышкып торды. Нидер чәнчи, пычак белән кискән кебек чигәдән түбәгә бәрә иде.—Нәрсә төкъдим итәсез соң?

—Беткәнмени урта мәктәп бетереп колхозда эшләп йөрүче кызлар? Шулар сөйләсен.

Хәятнең бу сүзләре белән килешүдән башка чара калмады.

—Минем сезгә әйтәсе бер сүзем бар,—диде Эльза.—Институтка бармамдыр мин...

—Нәрсә-ә-ә?!—дип жикерде Минзаһит.—Син изденьяться итәргә уйладынмы бездән?!

—Мин институт бетергәннән дөньяда нәрсә үзгәрәчәк?

—Үзгәртегез. Сез бит яшьләр.

—Сез инде аны үзгәрмәслек итеп коргансыз.

—Кем ул без?

—Коммунистлар.

—Син чамалап сөйлә, кызый!—дип Минзаһит аның борын төбендә йодрыгын селкеде.—Мин синең ипи шүрлегенә дә менеп төшәргә күп сорамам.

—Менә, менә!—диде Эльза, әтисенең йодрыгына бармагын төбәп.—Сезнең бөтен аргумент шул инде.

Ул кызу-кызу атлап, үз бүлмәсенә кереп китте. Хәят белән Минзаһит аптырашып, бер-берсенә карашып калдылар. Хәят сөлгесен диванга ташлады да йокы бүлмәсенә кереп китте. Аның ингалятор өрдергәне ишетелде. Минзаһит диванга ятты да кырык төрле уйнын ин кирәкләсен эзләргә тотынды. Алар барысы да бикле читлектән ычкынган жәнлекләр кебек төрле якка чабышалар, аларны куып тотарга, кире шул читлеккә

кертергә кирәк иде. Аның күз алдында ин кичектергесез булып, алты коммунист, алты партия билеты калды. Бу аның өстендә бомба кебек асылынып торган ин хәтәр нәрсә иде. Билетларны иртүк үл коммунистларга ризалыклары белән алырлык итеп кайтарып бирергә, бу тавышны басарга кирәк. Моны эшләүнең юлы бер генә: алар сименткән маллярын иртәгә үк тапшыртырга рөхсәт итәргә. Бу инде Мәлс Сабитовның Минзаһитны үз алдында тезләндерүе булып чыга. Ләкин башка юл юк.

Иртән эшкә килгәндә, кабул итү бүлмәсендә Мәлс Сабитов аны көтеп утыра иде инде. Арсланов күл биреп күреште дә, әйдә, дип аны үзе белән бергә алып кереп китте.

—Семинар яхшы узды. Барысын да әйбәт оештыргансыз,—диде ул, Мәлс Сабитовның йөзеннән нинди генә тантана билгеләре эзләп. Әмма ару-талчыгу төсмерләреннән, рәнҗүгә охшаган чалымнардан башка берни күрмәде.—Ә менә кичәгесен тагы да шәбрәк оештыргансын. Алай кирәкми иде, Мәлс Хәйриевич.

Үзенең бу сүзләреннән соң Сабитов гажәпләнер микән, дип ул ана текәлде. Ләкин директорның бер генә керфеге дә селкенмәде.

—Без инде барысын да ачыкладык,—диде Арсланов аны эләктерү максаты белән.

—Мин бу хакта ишеттем,—диде Сабитов.—Бөтен совхоз шаулый. Ә минем катнашым юк.

—Ант итегез.

—Кичерегез, минем беркайчан да беркемгә дә ант иткәнем юк. Хәер, бер мәртәбә иткәнмен икән: армиядә присяга вакытында.

Шулчак партия өлкә комитетыннан шылтыратып, Арсановка иртәгә үк терлекчелек буенча киңәшмәгә килеп житәргә куштылар. Аның болай да куркып беткән йөрәге ярсып тибәргә кереште. Ул кабаланып Гаскәровка шылтыратты.

—Сәет Мөбәрәкович, сез инде "Биектау"ның откормдагы маллары белән критически хәл икәнен беләсез. Давай, без аларга семинарны яхшы итеп оештырганнары өчен бер яхшылык эшлик әле. Бүген үк терлекләрен тапшыра башласыннар. Комбинат белән дә сөйләштек. "Сельхозтехника" аша күпме кирәк, шул кадәр транспорт бирдерегез. Сабитов хәзер сезнең янга керер.

Мәлс аягүрә басты.

—Рәхмәт, Минзаһит Усманович. Бу яхшылыгыгызны мәңге онытмам,—дип бүлмәдән чыкты.

Арсланов кичкырын Наратбашка китте. Ит комбинатына терлек озату башланган иде инде. Ул Нуриевтан коммунистларны комплексның кызыл почмагына жыйдырды.

—Сез хаклы булгансыз, райком үзенең хатасын төзәтте,—диде Арсланов, эчкерсез елмайган кыяфәтка кереп һәм папкасыннан алып партбилетларны өстәлгә куйды.—Ике мәртәбә билет алу бәхете теләсә кайсы коммунистка тәтеми,—диде ул, һаман да баягы елмаюын сакларга тырышып. Һәрберсенә күлын кысып билетларны биреп чыккач, сүзен йомгаклап куйды:—Кайчакта мондый бәрелешләр дә кирәктер. Мин конфликтны беткән дип саныйм. Сезнең башка әйтәсе сүзләрегез юкмы?

—Юк, юк,—диештеләр терлекчеләр, урыннарыннан торып.

—Ә шулай да мин сезгә киләчәктә болай дәррәү күтәрелмәскә киңәш итәр идем. Үзегезне борчыган мәсьәләләр булса, турыдан-туры минә килегез. Райкомның ишекләре һәрвакыт ачык бит.

Аның бу сүзләреннән соң терлекчеләр, бер-берсенә карашып, серле генә елмаештылар да ишектән чыгып киттеләр. Арсановның машинасы янында әнәс көтеп тора иде. Ул чип-чиста итеп кырынган, ак күлмәк, кара галстуктан, кышкы ботинкаларын көзгедәй елтыратып чистартылган.

—Менә бит бүген син егет кебек,—диде Арсланов, аның белән күл биреп күрешкәч.—Нишләп бу терлекчеләрнең восстаниегә әзерләнүе турында хәбәр итмәден?

—Мин берни дә сизмәдем.

—Киләчәктә сизәргә кирәк. Син биредә профком гына түгел. Үтәр еллар, син райкомга килерсең, балкем минем урында да калырсың. Әле абыенның обкомда дуслары шактый. Халык өчен көченне кызганма, кешеләр сине яратсыннар. Күрәсеңме, Сабитов ничек ныклы басып йөри.

—Ярый, тырышырмын,—диде Әнәс баш селкеп.

—Сина дигән йортны төзиләр.

—Төзиләр.

Арсланов канәгатләнеп кайтып китте.

7

Эш сәгате бетүгә, Сөембикәнең йөрәге калтырана башлый, китапханәдән өйләренә кайтып җиткәнче, ниндидер авыр томан эченнән атлый. Кайтуга Ирек аңа тагын кинаяле сораулар белән ябырыла. Ул Ирекнең ни теләгәнен бик яхшы аңлый, ләкин үзендә ачыктан-ачык сөйләп бирергә көч тапмый. Бүген ул озын көн буе шушы хакта уйлады һәм, китапханә ишеткән киклән, эштән кайтып киткәндә, ныклы карарга килде: сөйләп бирергә! Аның яулап алган бәхете шушының белән төгәлләнәчәк.

Ул кайтып кергәндә, өй аллары шыр ачык, өстәлдә башланган ярты утыра, савытта суынып беткән аш, ипи, суган кисәкләре тора иде. Ирек үзе диванда йоклап ята. Алар Айгөл белән тавыш-тынсыз гына чишенделәр.

—Әллә әти эчкән?—дип сорады кызы, яшьле күзләре белән әнисенә төбәлеп.

—Борчылма, кызым,—дип аның коңгырт чәчләрен сыпырды Сөембикә.—Әтинең янына кунак килгән. Мин ашарга әзерләгәнче, син дәресләренне карый тор.

Күрәсең, аларның кайтканын ишетеп, Ирек кухняга чыкты. Тавыш-тынсыз, су багыннан алып, бер чүмеч суны голт-голт эчеп бетерде. Аннан соң ярты белән рюмкасын алды да йокы бүлмәсенә кереп китте. Ашарга чакыргач, ул эндәшмәде, кухняга чыкмады. Айгөлнең дәресләрен әзерләшеп, бераз телевизор карап, аны йокларга яткыргач, Сөембикә суыткычны чистарта башлады. Шулчак, Ирек кухняга чыгып, өстәл янына утырды һәм, бер сүз дәшмичә, Сөембикәгә карап тора башлады. Аның карашы астында эшләү шулкадәр кыен иде, Сөембикә туктап калды.

—Йә, ниишлисең инде, Ирек?! Ник шулай карап торасың?—диде өзгәләнеп.—Ник мине болай газаплыйсың?!

Ирек мыек астыннан гына көлеп куйгандай итте.

—Кем кемне газаплыйдыр. Мин бит сизеп-белеп торам: синең миннән башка яшерен тормышың бар. Син барысын да сөйләячәксең.

Сөембикә, эшеннән бүленеп, хәрәкәтсез калды. "Әйт!—дип боерды ул үз-үзенә.—Барысын сөйлә дә котыл!" Ләкин эчендәге ниндидер көчле нәрсә мона ирек бирмәде.

—Миннән берни дә сорама,—диде ул зәгыйфь тавыш белән.—Әгәр минем хакта нидер уйлыйсың икән, уйлый бир—мин риза.

—Әгәр әшәке уйласам?

—Әшәке уйласаң да. Күпме булдыра аласың, шул кадәрле өй.

Ирек йокы бүлмәсеннән яртысын алып чыкты, бер рюмка тутырып аракы эчте, ләкин берни дә капмады.

—Димәк, нинди әшәкелекне өйсәм дә, син күтәрергә риза?—Сөембикә дәшмәде.—Алайса мин хаклы икәнмен...

—Теләсән ни уйла...—Сөембикә үксүен көч-хәл белән генә тыеп тора иде.—Безнең бәхетле чагыбыз кайчан да булса бетәчәген мин белдем... Менә ул көн килде...

Сөембикә яланөс, яланбаш, яланаяк килеш елап чыгып йөгерде. Ирек аның керүен шактый көтте, тагын аракы эчте. Ашыйсы килүдән түгел, ипи сындырып алып, авызында әвәли башлады. Ул аны чәйнәмичә әвәләде дә әвәләде, ахырда ипи жебеп таралды, ул аны йотарга мәҗбүр булды. Шул

вакыт ул күз кабакларының авырайганын тойды, өстәлгә терсәкләрен күеп, ике кулына ияген салды да күзләрен йомды. Ул йоклырга тырышты, әмма йоклый алмады. Вакытның узганы сизелми, ул шушы газаплы, бәгырьне өзә торган урында туктап калган да ни алга, ни артка хәрәкәтләнмичә тора бирә. Ирек күзләрен ачты, каршыдагы сәгатькә карагач, хатынының чыгып киткәненә егерме минутлап вакыт узганлыгын чамалады. Ул кинәт сикереп торды һәм, үзе дә киенмәгән килеш, ишек алдына ташланды. Сөембикә беркайда да күренми иде. Ирек мунчага йөгерде, анда атылып барып керде һәм караңгы мунча эчендә ишек алдыннан төшкән яктылыкта Сөембикәнең утырып торганын күрде. Күрәсең, ул елаудан яна туктаган, тавышын чыгармаска тырышып, сирәк-сирәк кенә үксеп ала иде.

—Нишләп утырасың монда?

—Тәк утырам...

Ирек аның суынып беткән, бала йоннары кабарган беләкләреннән тотты да урынныннан торгызды һәм аркасыннан йомшак кына итеп ишеккә таба этте. Алар шулай өйгә кайтып керделәр.

—Утыр әле, Сөембикә,—диде Ирек.

Алар өстәлнең икесе ике башына утырдылар.

—Син мине исерек дип уйлама, мин бүген көне буе эчтем. Тик исереп булмый. Аңлыйсыңмы син минем ни әйткәнне? Утка су сипкәч, ул да сүнә. Ә минем эчемдә утка бензин сипкән кебек. Син туп-туры әйт: яратмыйсыңмы син мине?

—Мин сине яратам,—диде Сөембикә һәр сүзенә басым ясап.—Мәңге яратачакмын. Тик без беркайчан да үзара тигез булмадык. Мин күтәрелергә тырыштым... күтәрелермен дигән идем, булмады... Елан үз койрыгын нишләп тешлидер—белмим... Мин тормыш пычрагыннан чистага туктаусыз чыгарга омтылдым... авылдан башлап... Бөтен күңелем изгелек теләсә дә, янымда гел әшәке бәндәләр бөтереледе... Ә мин сина Аллаһы Тәгалә урынына табындым.

Сөембикәнең тавышы акрынайганнан-акрыная барды да бөтенләй тынып калды. Аның сулыш алуы бөтен өйгә ишетелә, ярым шәрә күкрәге бер күтәрелә, бер төшә, әрнүдән түгәрәкләнгән яшьле күзләренә күрку катыш ялвару тулган... Ул хатынын кызганырга теләде, ләкин булдыра алмады. "Чәчләре кай арада тузган соң анын?"—дип уйлады ул Сөембикәне кызганасы урында. Хатыны аның каршында зур тузганак чәчәре төсле хәрәкәтсез утыра бирде. Иреккә ул зәңгәрсу томан эчендә кебек күренде. Әз генә өрсәң дә, аның тузыган чәчләре, төрле якка чәчелеп, очып китәрләр кебек иде. "Мин рәхимсез, аны кызгана да алмыйм",—дип уйлады ул эченнән. Ләкин үзен бу мөмкин булмаган нәрсәгә мәҗбүр итә алмады, кинаяле тавыш белән:

—Табынуын өчен рәхмәт,—диде.—Тик шунысы бар: үзең табынган Алланың дошманы белән якын мөнәсәбәткә кермиләр.

—Сине котыртканнар!

Сөембикә чәчрәп торып чыгып китмәкче булды, әмма Ирек аның юлына аркылы төште.

—Әйт: Шәвәлиев белән сезнең арада ни булды?!

—Мин аны кыйнадым.

—Ничек райком секретарена кул күтәрә алдын?

—Синең ачуны алдым.

—Алдашасың! Син аның белән булгансың. Син хыянәтче!

Иреккә йөзе куркыныч иде. Сөембикә почмакка ук чигенде. Инде барыр җир калмаган, әйтеп бирергә кирәк иде. Ләкин теле ана буйсынмады.

—Ярый, шулай уйла,—диде ул, өзек-өзек сулыш алып.—Тик мин сина хыянәт итмәдем.

—"Шулай уйла" түгел, шулай!—дип кычкырды Ирек.

Бөтен бите дөрләп янган хәлдә Сөембикә почмакка таба борылды һәм мең газап белән күкрәгеннән коточкыч сүзне этеп чыгарды:

—Әйе...

Ирекнең күнелендәге соңгы ышаныч җимерелеп төште. Ул Сөембикә янына ничек барып житкәнен дә, аны ниченнән эләктереп, ничек идәнгә барып салганын да сизми калды. Бөтенесе бер мизгел эчендә булды. Сөембикәне ярсып типкәләгәндә генә ул аңына килде һәм шашынып туктап калды.

Сөембикә куллары белән идәнгә таянырга, башын күтәргә азапланган хәлдә канлы иреннәрен сыпырды, кайнар битләреннән үпте.—Кичә күр... мин моңа барырга тиеш түгел идем...

Сөембикә акрын гына күзләрен ачты.

—Ә мин кичерүеңне сорамыйм...—Сөембикәнең зәгыйфь тавышы әллә үксүдән, әллә авыртудан туктап-туктап алды.—Их, алар!.. Аңлатырлык сүзләр юк... Минем тормышымда бары син генә булдың. Язуынны теләдем... Яза алырлык эшең булсын дидем... Сиңа бәйләнүләреннән курыктым...

Сөембикә күзләрен йомды. Ирек, нишләргә белмичә, аның һәр сүзеннән көеп утырды. Хәзер аның хатынына булган ачуы юкка чыккан, әмма нишләптер ул аны кызганмый иде. Бары тик, имгәтмәемме, берәр җирен сындырмадыммы икән, дип хафаланудан башы гына чатнады.

—Сөембикә, авырткан җирләреңә юкмы?

—Бер җирем дә авыртмый,—диде ул пышылдап. Аның йомылган керфек араларында яшь тамчылары елтырый иде.—Йөрәгемнең әрнүе, син кыйнагач, кимегәндәй булды. Матур яшәгән идек без, әйеме?

—Әйе, матур...—диде Ирек, аның сүзләренә ияреп.

Әмма Сөембикәнең үткән заманда сөйләве аны куркытып җибәрде.

—Мин бая "әйе" дидем. Газап утыннан куркып кычкыру гына иде ул. "Әйе" түгел, юк! Мәнге юк! Тик син мине аңлый алмыйсың инде... Беркем дә аңлый алмый... Нык буталдым... Мин бер котылган читлеккә кабат кермәячәкмен... Читлек түгел, үткен тырнаклар... Әшәке тырнаклар...

Сөембикәнең күзләре йомык, әмма керфекләре туктаусыз дерелди, юка тире аша күз алмаларының сикереп чыгарга теләгәндәй йогерешкәне сизелә иде. Кинәт ул ыңгырашып куйды, күзләрен ачты, куркынган карашын Иреккә төбәгән хәлдә, янбашын аз гына кыймшатып, кулын аска тыкты һәм кабаланып тартып алды: аның бармакларыннан кан тамып тора иде. Ирек күнел болгаткыч җылы кан исеннән чак кына укшып җибәрмәде.

—Сөембикә!—дип илерде ул, коты очып.

Ләкин хатыны дәшмәде. Ул калтырана-калтырана телефонга барып ябышты һәм ашыгыч ярдәм чакырды...

Больницаның дежур врачы куркырлык берни дә юк, тынычлап ял итегез, дип Ирекне кайтарып жибәрде. Сөембикәнең баласы төшүен ул көнне Иректән яшергән булып чыкты врач...

Сөембикә авырганда, больницага Ирек Айгөл белән бергәләп барып йөрде. Унөченче көнне ул терелеп чыкты. Тагын гадәти көннәр башланды. Сөембикә хәзер бик сирәк кенә, саран гына елмая, елмаюыннан ниндидер сабыйларча оялчанлык бөркелә, күзләрендә тынкы җылылык, тавышында буйсынучанлык сизелеп тора. Ул элеккечә өйдәге барлык эшләрне эшли, ашарга әзерли, бергә утырып ашыйлар-эчәләр, аерым йоклыйлар. Араларында күренмәс дивар калыккан һәм алар икесе дә уртак тормышның беткәнлеген аңлаганнар иде инде. Өйдә кычкырып сөйләшкән, бергәләп көлешкән тавышлар тынды. Алар, аквариумдагы балыклар кебек, тып-тын яшәүгә күчтеләр. Ләкин бу кычкырышып яшәүдән газаплырак иде...

Бер якшәмбедә төштән соң Сөембикә, чемодан алып, үзенең әйберләрен тутыра башлады. Аның яныннан берничә мәртәбә узып киткәч, Ирек сорау бирде:

—Син нишлисең?

—Китәм,—диде Сөембикә бер сүз белән.—Болай яшәп булмый бит инде.

—Кая китмәкче буласың?

—Кичә бер илгыз карчык белән сөйләшеп каяттым. Әе зур гына, акчамазар сорамыйм, үземе тәрбия кылсаң, шул житә, ди.

Ирек, аның чемоданындагы әйберләрен алып, шифоньерга ыргытты.

—Айгөл белән сез калыгыз, мин китәм.

Аның бу сүзләреннән Сөембикә дерт итеп сискәнеп куйды. Күзләрен мөлдерәтеп, сорауны карашын Иректә төбәде.

—Ник гажәпләнәсең?—диде Ирек.

Әйе, нигә гажәпләнә соң әле Сөембикә? Кемдер китәргә тиеш бит. Ләкин аны куркытканга нәрсә Ирекнең китүе түгел, кая китүе иде. Ул инде әллә ничә көннәр монын шулай буласын белеп йөрде һәм үз гомерендә беренче мәртәбә элек бар дип тә белмәгән Ходайга эченнән туктаусыз ялварды: "Зинһар Болынкырда гына калдыр! Аның янәшәдә икәнлеген тоярга гына мөмкинлек бир! Аның тәүдәсен читтән генә булса да, күреп кенә калырга булса да мөмкинлек бир!" Сөембикәнең бөтен курыкканы Ирекнең Казанга китүе иде. Алай булган очракта ул инде аны беркайчан да кермәячәк, Ирек шунда калачак...

—Гажәпләнмим. Рәхмәт игелегең өчен. Тик кая китәсен?

—Башта авылга кайтам әле... Аннан күз күрер...

—Айгөлгә ни дибез соң?

—Командировкага китәм, диярмен. Айгөлне генә алдап булыр ул... Минем кием-салымнар калып торсын. Язу-сызуларымны гына алырмын да... Чемоданга тутырып куйсаң яңа.

Шул якшәмбедә алар икесе дә аерылу сәгате сукканын бөтен рәхимсезлеге белән аңладылар. Сөембикә йокы бүлмәсендә, Ирек диванга яткан килеш, төнне керфек тә какмыйча уздырдылар. Әгәр икесенең үйлаган үйларын бергә җыйсаң, олы бер әрнүле дингез булыр иде. Ирекнең хәтеренә кешеләрнең өч төрлегә бүленүе турындагы кайчандыр укыган хыяллй фәлсәфә килде. Имеш ирләр күктән, хатын-кызлар жирдән яралган. Болары беренче ике төркемле тәшкил итә. Күктән яралган ирләр гомер буе азгын Дон-Жуаннар, алар хатын-кызга тирән мәхәббәт тота алмыйлар. Максатлары—мөмкин кадәр хатын-кызны үзләренә буйсындыру. Жирдән яратылган хатын-кызлар гомерләре буе дәртләнеп ирләрне аздыру, аларны үз ятьмәләренә төшерү белән мәшгульләр. Өченче төркем кешеләр айдан яралганнар һәм алар ике женеселе булганнар. Дүрт куллы, дүрт аяклы, ике башлы бу кешеләр ашыккан чакларында имеш тә тәгәрмәч кебек тәгәрәп йөргәннәр. Болай яшәүнең унайсызлыгын күреп, күк Алласы аларны урталай—ир һәм хатын-кыз өлешенә бүлгән. Болар гомер буе үзләренең икенче яртыларын эзлиләр һәм тапкач, мәңге бер-берсенә тугры калалар. "Бүгенге тормыштагы кешеләр кайсы төркемгә керә икән?"—дип уйлады Ирек. Айдан яралганнары калмаган ахрысы. Тормышны, күрәсең, жирдән яратылган хатын-кызлар, күктән яратылган ирләр тутырган. Ирек Сөембикәнен кайбер вакытларда тора салып, бернинди сәбәпсез өйдә тавыш чыгарганнарын, савыт-сабаларны атып бәрүләрен, Ирек белән Айгөлгә жикерүләрен күз алдыннан үткәрде. Димәк, ул көннәр аның хыянәт көннәре булган. Ә Ирек шыр тиле булып, берни аңламыйча яши биргән...

8

Ирек авылга кайтканда ала торган зур зәңгәр рюкзакка кулъязмаларын тутырды, майка-күлмәкләр салды. Айгөл әле торып юынып кына маташа иде. "Мин киттем",—диде ул акрын гына Сөембикәгә. Сөембикә, күзләрен мөлдерәтеп, ана хәрәкәтсез карап торды, ләкин авыз ачып берни дә әйтә алмады. Аның сүзләрен ишетеп, кызы юынган жиреннән башын борды:

—Кая киттең, әтием?—диде ул, битендәге суларын сыпырып төшереп.

Ирек нәкъ шушыннан курыккан иде дә инде. Ул, рюкзагын куеп, кызы

янына килде, аның ябык инбашларыннан тотып, колак яфрагыннан, юеш битеннән үпте.

—Мин, кызым, командировкага китәм, әниеңне тынла, яме,—диде.

—Син озак торасыңмы соң?

—Озаграк торылыр шул, ә син борчылма, мин кайтып киткәләргә тырышырмын.

Ирек, дымланган күзләрен Сөембикәгә күрсәтмәс өчен, ашыга-кабалана өйдән чыгып китте. Нинди матур көн! Инде бер атна тамчылар тамды, түбәләрдән боз сөңгеләре сузылган, бөреләр бүртә. Март ае өр-яңа киемнәргә киенгән, хушбуйлар сибенгән уңәҗде яшьлек кыз кебек, бала чактан ук таныш изгеләре бөрки, җылы җилләре дөньяны муеннарны иркәли.

Баллы Төбәккә кайтып җитеп, урамнан атлаганда, Ирек үзенең жилкәсенә әйтеп бетергесез зур авырлык басуын тойды. Бу авырлык түгел, нинди генә тере җан иясе кебек, аның бөтен йөрәгенә тырнакларын батыра, кайнар сулышы белән ике бит очын өттереп яндыра. Ана очраган, исәнләшеп киткән кешеләр барысы да бу җанварны күралардан, нигә бу хәшәрәтне безнең авылга алып кайта икән, диярләрдән кебек тоела. Аны сытардай булып басучы бу җанвар—ул коточкыч зур ялган. Әтиләре янына Ирекнең беркайчан да ялган белән кайтканы юк иде. Менә бүген туры киләчәк. Һәм ул ялганны сиздермичә өй эчендә асарга, һәркөн туйдырырга, шул ук вакыттә әтисе белән әнисенә күрсәтмәскә дә кирәк булачак.

Ул кайтып кергәндә, әтисе дә, әнисе дә өйдә иде.

—Ни хәлләрдә ятасыз?—диде Хәйри, чәй эчәргә утыргач.

Ирекне куркыткан сорауларның бу әлегә ин беренчесе, ин битарафы иде.

—Әйбәт кенә, Сөембикә эштә, Айгөл мәктәпкә йөри.

—Ә үзең?—диде Хәйри.

Ирек үзенең жилкәләренә баскан ялганның тырнак батыруын сизеп куйгандай булды.

—Мин ни... сезнең янга кайтып әзрәк язу белән утырырмын, дигән идем.

—Болынкырда утырып булмыймы?

—Кеше күп килә, бүләләр. Күнел монда тартты...

Аны хуплап, әнисе:

—Бик рәхмәт, улым,—диде.—Без бит сезне сагынып торабыз. Мәлс абыеңны кайчакта айлар буе күрә алган юк. Син булгач, менә өйләребез яктырып китте.

Чәйләгәч, әтисе эшкә китеп барды. Ирек ул көнне кичкә кадәр ихатада мәш килде. Икенче көнне, яза торган кәгазьләрен таратып, өстәл янына утырды. Әнисе, күрәсең, ана комачауларга теләмәде:

—Мин, улым, Гыйзедиаса абыстайларга барып кайтам әле. Хәер бирәсем бар иде,—дип өйдән чыгып китте.

Ялгызы калгач, Ирек күпме генә тырышса да, бер генә хәреф тә куя алмады. Әйтерсең лә миенең барлык күзәнәкләре катып калган иде. Язгы карны ашаган горләвек суыдай, күнелне ермачлаучы сагыш елгасына түзәрлек түгел. Кинәт ул катгый карарга килеп, медпунктның телефон номерын җыйды.

—Әйе, тыңлыйм,—бу Зәнфирә тавышы иде.

—Исәнме, Зәнфирә,—диде Ирек, куанычыннан кабаланып.

—Исән-ме,—анын шулай сүзне урталай сындырып әйтүеннән Ирекне таныганлыгы анлашылды.

—Мин берничә көнгә кайттым әле. Сина бер сүз әйтәсем бар иде.—Ирек туктап калды, Зәнфирә дәшмәде, анын сулыш алганы гына ишетелде.—Мине син ишетәсеңме?

—Ишетәм.

—Бүген кич теге өянке төбенә килә алмыйсыңмы?

—Ничәдә?—диде Зәнфирә.

—Мина барыбер, син үз вакытынны чамала...

—Ярый алайса... Нәкъ алтыда,—Зәнфирә трубканы куйды.

Ирек көне буе тагын ихатада дәртләнеп эшләде. Мал өендәге бер метрдан артык калынлыкка житкән тиресне чыгарып өйде. Кичке ашны ашагач, һава сулап кайтам әле, дип чыгып китте. Ул барып житкәндә, Зәнфирә өянке төбендә иде инде. Анда бер генә әз дә төшмәгән, тездән карга батабата, Ирек аның янына килде.

—Рәхмәт килүең өчен,—диде Зәнфирәнең калтыранган салкын кулларын кысып.—Бик туңгансың, әллә күптән килгән иденме?

—Юк, әле яңа гына. Әллә нишләп туңам.

—Кулларың калтырый шул.

—Мин ашыгам, Ирек.

—Аңлыйм,—диде Ирек.—Беләсеңме, Зәнфирә,—ул тәненең кызыша башлавын тойды.—Сөембикә белән барып чыкмады безнең тормыш...

—Балалар үсеп житкәндә, ул турыда ниндидер сүз булырга мөмкин, Ирек? Хәзер инде барысы да яшьлектә калды. Әйтер сүзең шушы гына булса, мин киттем.

—Зинһар ашыкма. Әйтер сүзем әле бетмәде. Без аерылыштык.

Зәнфирә кычкырып жибәрде:

—Аерылыштыгыз?!

—Бу хакта жир йөзендә әлегә син генә беләсең. Мин хәтта әтиләргә дә әйтергә куркам.

—Бик начар эшләгәнсез бит, Ирек. Ул яшәмәслек хатын түгел, минемчә. Берәр нәрсә булдымыни?

Дөресен әйтсә, ул, ир кеше буларак, юкка чыгар кебек тоелды. Зәнфирә каршында аның элекке Ирек булып каласы килде.

—Берни дә булмады. Баштан ук барып чыкмады безнең тормыш.

—Ә ник син моны мина әйтергә уйладың әле?

—Белмим... Нишләптер сина әйтәсем килде. Менә күнелемә жинел булып китте. Мин синнән берни дә сорамыйм, кызгануынны да теләмим. Тынлавың өчен рәхмәт.

—Сина Алла ярдәм бирсен, сау бул.—Зәнфирә салкын иреннәрен Иркнең иреннәренә тигерде дә кар яра-яра китеп барды. Аның бу хәрәкәте Иркне исертеп жибәрде. Ул сыры белән оянкенең юан кәүсәсенә сөялде. "Зәнфирә минем иреннәремә кагылды, аның күнеле һаман да минеке белән бергә",—дип куанды ул эченнән.

***

Зәнфирә ашыга-кабалана чишенде, Заһитка күренмәскә тырышып, кече якка чыкты. Әле теге эшкә, әле бу эшкә тотынып карады, ләкин күнелендә әллә нинди өермә күптеләп, кулыннан эше коелды.

Зәнфирә ана мәктәптә укыганда ничек директор итеп караган булса, өйләнешкәч тә "Заһит абый" дип дәште. Ул эшкә чыгып китәндә, Зәнфирәне ике битеннән үпте, кич кайтканда, үбеп каршы алды, өс-башын чишендереште, пальтосын, шәлен элеп куйды, хәл-әхвәлләрен сорашты, өстәл янына чакырып, үзе пешергән ниндидер тәмле ризык белән сыйлады. Мәктәптән сонарыбрак кайтса, гафу үтенде, эш күп булды, диде, бүген сине каршылый алмадым, диде. Һәркөн ятар алдыннан Зәнфирәнең аякларын жылы су белән юды, буыннарына массаж ясады. Зәнфирә моңа күнегә алмыйча, бик озак изаланды, мин синең аякларыңны юарга тиеш, диде. Әмма Заһит аның бу ниятен юкка чыгарды.

—Хатын-кызның ир-ат аягын юуы—атавизм калдыгы, ирләр хатын-кызга мөмкин булган хөрмәтнең барысын да күрсәтергә тиешләр,—диде ул.

Тора-бара моңа Зәнфирә күнекте. Иренең сәер яклары торган саен күбәйде.

Өйләнешеп яши башлаганда, беркөнне Зәнфирә өстәл әзерләде, аш бүлде.

Шулчак Заһит кашыгын әйләндерә-әйләндерә карарга кереште.

—Әллә берәр нәрсә тигәнме?

—Икенчене бир әле, аллә ничек елтыравы житми.

Зәнфирә икенче кашык китерде, әмма ул янадан савыт-саба юганда һәрвакыт шуны хәтеренә төшерде, кат-кат юды, кат-кат сөртте...

Бервакыт Зәнфирә кибеттән ярма, пряннек, шикәр ише әйберләр алып кайтып өстәлгә бушатты.

—Кибетчеләрнең төгәл эшләвенә ышанасыңмы син?—диде ана шулчак Заһит.

—Ышанам.

—Әйдә, юри генә тикшереп карыйк әле.

Алар алынган һәр әйберне үлчәү аша үткәргәч, Зәнфирәнең исе-акылы китте: алган әйберләрнең һәркайсы шактый ким булып чыкты.

—Сатучы шулай бозыла,—диде Заһит.—Әле бит ул нибары егерме яшьтә. Берсен дә бер генә граммга да артык үлчәмәгән. Ә акчаны шактый артык каерган. Бөтен авыл шушыңа ирек куйгач, киләчәктә анардан кем чыгар? Ул бит әле балаларын да шуна өйрәтәчәк.

Шушы вакыйгадан соң Заһит ана үзенең гомер буе тутырып барган дәфтәрләрен күрсәтте: анда алынган, сатылган һәр әйбер, көненә күпме акча тотылган, күпме акча кергән—һәммәсе графалап, җентекләп язып барылган иде. Хатынының гажәпләнеп баш чайкавын күргәч, ул болай диде:

—Әйе, син аңлый алмыйсың... Авылда беренче булып мин машина алдым, мин үз көчем белән авылда бер итеп шушы йортны төзедем. Мәктәпне салганда, төзүчеләр миңа ничәмә-ничә меннәр тәкъдим итмәделәр... Тагын шушындый өй салырлык акча чәлдереп була иде. Ә мин аларны, жирәнеп, бүлмәмнән куып чыгардым. Минем төп баю чыганагым: бернине дә, хәтта ипи валчыгын да әрәм итмәү.

Аның көндәлек керем-чыгымнарны, алынган әйберләрне, ватылган савыт-сабаны, ертылган, ташланган кием-салымны язып-хисаплап баруы тора-бара Зәнфирәне шаккатырмый башлады. Ул үзе дә һәр тиенгә сак карарга, акчаның кая китеп, нәрсәгә тотылганын, каян кергәнен исәплә рә өйрәнде. Заһит хуҗалыкта бер генә нәрсәне дә әрәм итмәде, ул чүп үләннәрен дә яндырмады, аларны өеп, ашламага әверелдерде.

Кеше гомере алтыннан кадерлерәк, дияргә ярата Заһит. Вакыт исәплә буенча аның аерым дәфтәре бар. Бер тәүлек сиксән алты мең дүрт йөз секундка тин. Иртән жиздә чәй эчеп утырганда, ул акрын гына: "Менә бүген яшисе гомеребезнең егерме алты мең секундын ашап бетердек",—ди. Әлеге секундларның файдаланылышына һәркөн нәтижә чыгара. Казаннан аллә ничә китап кайтартты, шуларны укып, тирене эшкәртергә, иләргә, теләгән төскә манарга өйрәнде. Үзе үк шул тиреләрдән бүрек, тун текте, хәтта бозау тиресеннән күн эшләде. Аның теккән киемнәрен Заһит эшләгән дип беркем дә уйламый, "каян сатып алдыгыз, күпме тора?" дип кызыксыналар. Кием-салымны, туза башлау белән, үзе ремонтлап куя.

Мәктәптә Заһит бер генә балага да кычкырмады. Әгәр кемнендер тәртип бозганын белсә, күрсә, моның ярамый торган нәрсә икәнлеген ул шундый итеп аңлатты, бала янадан тәртип бозмады. Башка мәктәпләрнең стеналары тырналып, күпшаклап бетсә, аның мәктәбенеке төзеп тапшырганда ничек булса, шулай саклана. Бер бала стенага сызгач, ул бөтен мәктәпне жыеп, аны олы итеп тикшерү оештырды, бу тикшерүгә укытучыларын гына түгел, ата-аналарны да чакырды. Аны киная белән "Бер сызык жыелышы", дип атасалар да, жыелыш үз эшен эшләде. Моңдый хурлыкка калганчы, ярамаган эшне эшләмәү мең мәртәбә әйбәтрәк иде.

Заһитның гомере буе бер табчы да аптека даруы эчкәне юк. Ул барлык төр үләннәрне белә, кирәк булса, үзен дә, Зәнфирәләрне дә дәвалый. Ул көн саен кич йөз грамм үзе ясаган чия шәрабен эчә. Андыз суы аның өстәлендә тора, ул аны, китапларда язганнан аермалы буларак, арыш суы белән әзерли. Зәнфирә үзе дә үләннәр белән эш итәргә, кайсын нинди

чирдән кулланырга икәнен тәмам өйрәнеп житте.

Һәр алган әйберне, юкка чыкканын тиенен тиенгә язып барса да, Заһитның бер ягы Зәнфирәне хәйран калдыра: аның беркайчан да "бу әйбергә ник шушы кадәр акча тоттың, йә булмаса ник бу савытны ваттың?" дип үпкә сүзе әйткане юк. Ләкин андый нәрсәләрнең язып куелачагын белгәнгә күрә, Зәнфирә әйбер алырга ниятләсә, башында бик тиз генә хисаплау үткәрә торганга әверелде: кирәкме бу, юкмы; алыргамы моны, әллә бераз кичектерергәме; кыйммәтме бу, очсызмы... Иренең хаклы икәнен дә белә, ләкин икенче яклап караганда, синең белән һәрвакыт ниндидер көч идарә иткән кебек: туктаусыз һәр әйберне бизмәнгә саласың, үлчисең, борчылып хисап кыласың.

Бүген нишләптер Зәнфирәнең ничә елдар буе урнашкан шушы тәртипне жимерәсе килеп китте. Күнелен басар өчен, ул, ишек алдына чыгып, койма буендагы карны бакча эченә ярсый-ярсый атарга тотынды...

Ирек кар ярып тыкрык башына чыкты да, инде шактый чираргә өлгергән төрләвек эзләрен челтәр-челтәр ватып, өйләренә атлады.

Аның кайтуына оч көн дигәндә, партия-хуҗалык активы жыелышыннан әтисе яңа хәбәр алып кайтты:

—Шәвәлиевне кайсыдыр районга күчергәннәр. Аның урынына кемне куйганнарын беләсеңме?

—Кемне?—диде Ирек кызыксынып.

—Әхнәф Шәрифуллинны.

Бусы Ирек өчен көтелмәгән куанычлы яңалык иде. Арсланов курыкмыйча бу адымны ничек ясады икән? Һәрхәлдә Әхнәф өчен шатланырга кирәк. Бүгенге житәкчеләр арасында аның кебек гадел, туры күзле, тынгысыз кешене табу авыр бит әле.

Биш көн вакыт үтеп китте, шимбә житте һәм ул зур гауга китереп чыгарды. Өйлә вакытында әтисе сәгатькә карады да:

—Бәй, нишләп килен кайтмады соң әле?—дип сорап куйды.

—Белмим,—диде Ирек ишетелер-ишетелмәс тавыш белән, аның башы аска иелде.

—Ничек инде белмисең? Хәзер бер атна бездә, телефоннан сөйләшкәнегезне дә ишеткәнем юк. Бу нинди хәл?

Ирек астан гына бер әтисенә, бер әнисенә карады. Аларның икесенең дә йөзләре борчулы, карашлары сорау белән ана төбәлгән иде. Инбашларына тырнакларын батырып баскан ялганны бүтән күтәреп торып булмаячак иде.

—Без... бергә тора алмабыз инде...

—Нәрсә?!—әтисе, әллә ялгыш ишеттемме, дигәндәй Иреккә иелде.

—Сөембикә белән арылыштык без...

Хәйри белән Гөлжамал аптырашып бер-берсенә карадылар. Әнисе лышык-лышык еларгә кереште, алъяпкыч итәге белән йөзен каплады.

—Син ни сөйләгәненне беләсеңме?!—диде Хәйри тетрәнеп.

—Соң, әти, мин юкка кайтып егылмаган бит инде монда...

—Ә син егылма, бас! Шушы вакыттан егылгач, нәрсә була ул. Рәхсәтем юк аеры-чөерге килергә!

—Рәхсәттән узган инде ул...

—Партиядән куылып хурлыкка калдыруын житмәгән, мине хәзер гүргә кертергә уйлыйсыңмыни?!—Хәйри шкаф янына китте һәм калакка салып дару эчеп жибәрде.

—Абыең беләме бу хакта?—дип сорады Хәйри, телефон трубкасына үрелеп.

—Абыйны ник бутыйсың инде монда, әти?

Хәйри, катышып торма әле монда, дигәндәй, кул селтәде дә телефоннан номер жыйды.

—Улым, синме? Менә нәрсә: Сөембикәне ал да хәзер кайтып жит әле. Кайткач сөйләшербез.—Ул, трубканы куйгач, Иреккә ачулы карашын төбәде:—Эш юк, дип эчеп йөрмисеңдер бит?

Иренең утырган урындыгы шыгырдап куйды. Ул, кулъяулыгын

чыгарып, тирләгән маңгаен сөрткәндәй итте, тамак кырып:

—Эчүнең монда катнашы юк,—диде.

—Мин бер нәрсәне аңламадым.—Хәйри ишек төбеннән әйләнеп, Ирек каршына килде.—Син ништләп кистереп кенә "эчмим" дип әйтмисең?

—Алдашасым килми,—диде Ирек, авыз эченнән мыгырдап.—Тормыш бит, дуслар килгәләп тора, анысын да тотарга туры килә.

Шул вакыт аны әнисе якларга кереште:

—И-и, әтисе, берни белмичә баланы битәрләмә әле. Талашканнардыр, әйткәләшкәннәрдер дә инде. Яшь чакта үзебезнең дә булмадымыни?

—Әйбәт тәрбиялисең малаенны, рәхмәт!—диде Хәйри, ана бармак янап.—Күбрәк якла син аны. Күбрәк эчәр, күбрәк бозыклыклар кылыр. Ата-ана яклаганда, барысын да эшләп була.

Хәйри ачуланып өйдән чыгып китте. Ирек урыныннан кузгалмыйча, күтәрелеп әнисенә кararга да куркып утыра бирде. Гөлҗамал аның ике битеннән сыпырып башын турайтты, күзләреңә туп-туры карады.

—Улым, үземә генә әйт, ни булды соң? Бик әйбәт тора идегез бит.

—Әйбәт тормый идек, әнкәй.—Ирек авыр сулап куйды. Ул, әллә дөресен әйтимме, дип тә уйлады, ләкин эчке тавыш аны, кирәкми, ялгышасын, дип кисәтте.—Тыштан гына иде... Сезне борчыйсым килмәде.

"Теге гөнаһы өчен Аллаһе Тәгалә безгә җәза жибәргән", дип уйлады Гөлҗамал. Ул як-ягына шикләнүле караш ташлап алды да Иректең колагына:

—Улым, теге язуларыңны яндырган идеңме?—дип пышылдады.

Ирек, биектән сикерергә әзерләнгән кешедәй, тын алудан туктап калды, аннары "әйе" дигән төстә баш селкеде.

Әтисенең өй алдыннан кергән тавышын ишетеп, Ирек тиз генә сырма белән бүрек киде, авыр сөйләшүдән качу өчен абзар эченә кереп китте һәм иске тораклың тиресен сәнәк белән кубарып ыргытырга кереште.

Менә капка төбенә машина килеп туктады һәм Мәлс, Сөембикә, Айгөлнең очәүләп кереп килгәннәре күренде. Бу күренешкә, әлекке вакыт булса, Ирек шатланып туймас иде. Ә хәзер аның аркасын салкын энәләр авырттырып чәнчергә керештеләр. Сәнәген кадап, ул алар каршына чыкты. Кызы, атылып килеп, аны кочаклап алды, йомшак җылы битен әтисенекенә тигереп иркәләнде.

—Кайттыңмы, кызым?—дип пышылдады ул әллә нинди зәгыйфь тавыш белән.

—Син нигә өйгә кайтмадың, әтием?—диде кызы, кашларын җыерып.

—Ин әүвәл әбиең белән бабаңны күрим, дидем...

Исәнлек-саулык сорашкач, Гөлҗамал белән Сөембикә табын әзерли башлады. Айгөл, әле әбисенә, әле бабасына барып, мәктәп хәлләре турында тәтелдәде. Өстәл янына тезелешеп утыргач, тавыш-тынсызы гына ашарга керештеләр. Берничә мәртәбә Иректең карашы Сөембикәнеке белән очрашты. Хатынының күзләре салкын һәм битараф булуына Ирек хәйран калды. Беркем дә сүз башламады, моның сәбәбе, әлбәттә, Айгөл иде. Әтисе урыныннан торып, тамак кыргалап, кече яклардан урап килде, әнисенең аркасына кагылып куйды. Гөлҗамал үзе дә хәлне аңлап утыра иде. Ул Айгөлне күкрәгенә кысып:

—Ипташ кызым Нәсимә сине бик сагынган иде, аны күрәсең киләме соң?—дигән булды.

Оныгы кайту белән, өйдә әз генә торгач та, Нәсимәләргә йөгерә иде. Әбисенең сүзләрен ишетүгә, аның күзләре очкынланып китте.

—Керәм, әбием,—диде ул, пальтосына үрелеп.

Гөлҗамал үтә күренмәле пакетка Мәслар күчтәнәченнән берничә алма, апельсин, конфет салды да Айгөлгә тоттырды.

—Бар, кызым, иркенләп уйна,—дип оныгын озатты.

Өй эче тып-тын булып калды. Абыйсы, әти безне ник чакырдын, дип сорамады, күрәсең, Сөембикә аерлышканнарын әйткән. Сүзне гадәттәгечә әтиләре башлады:

—Менә, балалар, сезне үстердек, кеше иттек. Ә бүген тормышыбыз убылып төшкәндәй булды. Сөйләп бир, килен, нәрсә житмәде сезгә?

—Ирек әйткәндер бит.—Сөембикәнең йөзе бурлаттай кып-кызыл булды.—Мин тагын нәрсә әсти алыйм?

—Ул бернидә әйтмәде,—диде Хәйри каты тавыш белән.—Сез яшьләрне аңлап буламыни?

—Без бергә тора алмыйбыз,—диде Ирек.—Бер-беребезгә комачаулыйбыз.

—Туктале, энекәш,—дип сүзгә кушылды Мәлс.—Ни соң ул бер-беренә комачаулау? Әти әйткәндәй, бернидә аңлап булмый бит.

—Ул аңлатсын әнә,—диде Ирек, хатынына ымлап.

—Сина энекәш комачаулыймыни, килен?

Мәлсның бу сүзләренә Сөембикә баш чайкап җавап бирде.

—Ул мина комачауламый, мин аңа комачаулыйм.

Хәйри, кинәт сикереп торып, арлы-бирле йөренергә кереште:

—Комачаулый-комачауламый!—дип мыскыллап сүзды ул.—Ни дигән сүз инде бу?

—Комачаулау... ул мина язарга ирек бирми, дигән сүз, әти.

—Ә-ә-ә,—дип ачулы тавыш белән сүзды Хәйри.—Кулыннан ручканны тотып алып бәрәмени?!

—Көн саен кайта да тавыш чыгара—шул житмәгәнмени?

Аны яклау өчен Ирекнең дөреслекне яшерүен аңлагач, Сөембикә рәхмәт йөзеннән кызылап сөйләп китте:

—Әйе, ул хак әйтә. Әллә нәрсә булды мина. Эштән кайтып керү белән женем котыра, теләмәсәм дә, тавыш чыгарам. Хәтта китереп сугасым килә.

—Монда мәсьәлә ачык кебек,—диде Мәлс.—Сине аның өйдә эшсез ятуы котырта. Шулаймы?

—Юк, юк,—диде Сөембикә кабаланып.—Мин аның язуын телим. Аны эшкә мин үзем кертмәдем,—дип алдашты ул.—Ә үзем комачаулыйм. Барысына да мин гаепле.

Бер мәлгә бөтенесе тынып калдылар. Сөембикәнең, күрәсең, түземе бетте, ул лышык-лышык еларга кереште, кулъяулыгы белән күзләрен сөртте. Биатасының бездай салкын тавышы аны елаудан туктатты:

—Алайса йөргән кешең бар инде, килен. Син шулай дип туп-туры әйт.

—Юк, юк, әти,—дип өзгәләнде Сөембикә.—Беркемем дә юк минем. Мин аның белән яши алмыйм. Ул да минем һәр адымыма бәйләнеп тора.

—Вәйт син, агай,—дип кулларын як-якка җәйде аптыраудан гажиз булган Хәйри.—Мин аеры-чөерс килерлек бернинди дә сәбәп күрмим. Йә сез яшерәсез, йә мин—юлэр.

—Кызым,—дип йомшак тавыш белән сүз башлады Гөлжамал.—Мин үз малаемны яклага теләмим, әтисенә охшап, баш бирмәс яклары күп аның. Ни генә булса да, хатын-кыз сабыр итәргә тиеш. Карагыз инде Айгөлне? Ул сабыйның йөрәгенә кан савачак бит. Ятим балага урамнан үтеп барган эт тә ырлый.

—Мин аны ким-хур итмәм,—диде Сөембикә үксүеннән тыелып.—Тик, үтенеч сорыйм, үгетләмәгез. Бүген генә килеп чыккан хәл түгел бу. Һәммәсенә мин гаепле.

Ирек хатынының йөзенә карап алды, ни әйтергә белмичә шактый вакыт дәшми торганнан соң:

—Гаеп икебездә дә,—диде.—Әти... әни... Мәлс абый... Газапламагыз безне...

Алар барысы да башларын аска иеп тынып калдылар. Бу тынлыкны Сөембикә белән Гөлжамалның тыелып-тыелып елавы гына боза иде. Шулчак ишектән Айгөл белән күрше кызы Нәсимә елмаеп-көлеп килеп керде. Алар ике сабыйның уйнаганын күзәтгеләр, ара-тирә шаярткалап сорау биргәндәй иттеләр. Тик бу утыру ин якын кешеләрен югалткан туганнарның мәсәте янында утыруны хәтерләтә иде.

Берҡадәр вакыттан соң Мәлс кайтырга әзерләнә башлады. Ул киенгәч, ана ияреп Ирек тә чыкты. Абыйсы пышылдап сорап куйды:

—Әлек берни дә әйткәнең юк иде. Начар яшәдегезмени?

—Сорама инде, абый...

Ул арада Хәйри дә килеп чыкты.

—Үгетлә син аны,—диде ул, Мәлсәга ачулы эндәшеп.—Мин сине күзле бүкән сыман карап утырырга чакырмадым.

—Кеше тормышына кысылганчы, үзеңнекен көйлисе бар әле.

Хәйри аның бу сүзләренә дәртләп кабынды:

—Әле һаман көйсезмени?!

—Савыт-саба шылтырамый тормый инде ул...

—Ә нигә аны шылтыратасың?—диде Хәйри.—Чәлпәрәмә китереп ват та ташла. Сез дә аерылышыгыз, әниең белән безгә рәхәт булыр!

—Ярый, кызма инде, әти,—диде Мәлс, ишектән чыгып килүче Сөембикә белән әнисенә ымлап.—Вакыт төзәтер әле. Өметне өзмик.

Алар җыйнаулашып капка төбенә чыктылар. Машинага утыруша башлауга, Айгөл тагын әтисе янына йөгереп килде:

—Әти, әйдә, син минем янга утыр,—диде ул, аны кулыннан тарткалап. Иректән күкрәге тәнчешеп күйды.

—Кызым, ни бит әле, минем бераз эшләрем бар. Мин соңрак кайтырмын...

Айгөлнең чырае бозылды, ул шыңшырга кереште. Сөембикә аны сүзсез генә машинага утыртты һәм "Нива" кузгалып китте. Ирек абына-сөртенә абзарга атлады һәм сәнәгенә ябышты.

9

Баллы Төбәктә Ирек тагын бер атна яшәде. Бу бер атна аның өчен җиде көн генә түгел, сөйләп бетерә алмаслык кичерешләре белән җиде ай кебек тоелды. Әтисе бөтенләй сөйләшмәс булды, ул аны тиргәмәде дә, ләкин һәр күз карашы, уфылдап сулыш алуы "ник син безгә бу газапларны алып килдең?" дип кисәтеп тора иде. Төннәрен алар өчесе дә юньләп йоклямадылар. Әле әнисе, әле әтисе уфтанып, ыңгырашып, яткан урынында борсаланды. Ирек үзе дә мең төрле уй эчендә, язмышы тарафыннан ниндидер билгесез дөньяга очыртылгандай, йөрәген тотып ятты. Иртән әтисе эшкә киткәч, үжәтләнеп повестена тотынды. Башы тәмам арыгач, ишек алдына чыгып китә дә язгы көнгә хәйран калып карап тора. Кар шикәрләнде, учка алсаң, аннан су тамып тора. Ә койма буендагылары күзләрне чагылдырып жемелдәүгә жыелган суларның, аккан гөрләвекләрнең мәрхәмәтле кояш нурлары астында көмештәй ялтыравы күшыла. Алма, чия, күгәнә бөреләре күзгә күренеп бүртте, карлыганнар яшел яфрак чыгара башлады, агачларның әчкелт-тәмле исләре борыннарны кытыклый. Ул арада өйдә йомыркада утыручы каз каңгылдап килеп чыга, аны ата каз, кыйгак-кыйгак килеп, башын, муенын сузып каршы ала, туктаусыз ка-ка-ка килеп сөйләшәләр, куанышалар. Бу вакытларда ата каз яныннан үтеп тә китеп булмый, ул ысылдап өскә ташлана, канатлары белән кыйный, тиздән чыгачак бәбиләренең әнисен шулай саклый.

Нинаять, Ирек повестен төгәлләде, аны Әхмәткә жибәрергә карар кылды.

***

Гаскәров, Ирекне аягүрә каршылап, үзенең өстәле янына алып килде.

—Мәлс Хәйриевич сезне авылда дигән иде.

—Әйе, бераз картлар янында булдым.

Алар икесе дә тынып калдылар. Ирек йомышын әйтергә кыймады, Гаскәров аның ник кергәнен чамалый алмады.

—Сәет Мөбәрәкович, мин сезгә бик авыр мәсьәлә белән кергән идем.

Гаскәров ирен чите белән генә елмайгандай итеп күйды.

—Менә ничә ел эшлим инде, бер генә жинел мәсьәлә белән керүчеләрне дә очратканым булмады. Тыңлыйм сезне.

Ирек кулы белән чәчләреп сыпырып куйды, карашын аска төшерде.

—Мина яшәргә иске-москы булса да берәр почмак табып булмас иде микән?

Гаскәровның кысык күзләре түгәрәкләнеп киттеләр. Ул кискен генә гәүдәсен турайтты, башын урындыгының артына таба ташлады.

—Ирек Хәйриевич, мин сезне дөрес аңладыммы?

—Дөрес.

—Ә ничек соң...—Гаскәров сүзен дәвам итә алмый туктап калды.

—Без аерылыштык...

Гаскәров кинәт урыныннан торды, читтәге өстәлдән алып су эчте һәм тәрәзә каршына килеп басты.

—Мин сезнең икегезне дә дуамал кешегә санамыйм,—диде ул, кулындагы стаканын әвеш-тәвеш китереп.—Димәк, мәсьәлә житди. Сораштырып күнелегезне яраларга теләмим. Адәм балалары акыллырак, белемлерәк булган саен бер-берсен авыррак аңлыйлар. Моны сезне гаепләп әйтүем түгел. Барыбыз да шулай. Сез минем белән килешәсезме?

—Килешәм,—диде Ирек һәм акрын гына торып басты.

—Кызганыч...—Гаскәров бүлмә буйлап әрле-бирле йөргәргә кереште.—Тагын шунысы кызганыч: әзер квартирам булса да, сезгә бирә алмас идем. Аңлыйсызмы?

Ирек дәшмәде.

—Аңлыйсыз, бик яхшы аңлыйсыз. Ләкин ихлас күнелдән әйтәм, бүген бернинди почмак та юк.

—Борчуым өчен гафу итегез,—диде Ирек һәм акрын гына чыгып китте.

Бинаның беренче катына төшеп житкәндә, секретарь хатынның "Сабитов!" дип эндәшкән тавышы ишетелде. Ирек башын күтәреп өскә карады.

—Сәет Мөбәрәкович сезне чакыра.

Ирек баскычтан күтәрелеп кабул итү бүлмәсенә кергәндә, Гаскәров ана каршы чыгып килә иде. Ул аны белә генә элә кте реп бүлмәсенә алып керде.

—Ирек Хәйриевич, башка бер уй килде бит әле. Минем апам Казанда абыйларда яшәп ята. Аның кечкенә йорты бар. Риза булсагыз, шуны биреп тора алам.

—Рәхмәт,—диде Ирек.—Минем сайланырлык рәтем юк.

—Ул чакта болай итик: өйнең ачкычын төштән соң алып килермен. Кич алтынчы яртыларда мина сугылыгыз.

Нәкъ сөйләшкәнчә эшләделәр дә. Гаскәров, УАЗигының руленә үзе утырып, Иркене әлеге өйгә алып китте. Ул Болынкырның буена төшә торган аулак бер тыкрыктагы кечкенә агач өй булып чыкты. Аның турына килеп туктагач, Ирек бер нәрсәгә гажәпләнде: капка төбе яхшылап көрәлгән, ишек алдыннан да керерлек юл салынган иде.

—Шофердан чистарттырдым,—диде Гаскәров, аның гажәпләнүен күреп.

Алты почмаклы, кызыл калай түбәле бу йорт әле яшәмәслек түгел иде. Янәшәсендә алма, шомырт, милеш агачлары үсеп утырган кечкенә бакчасы, җиргә сеңгән булса да мунчасы, утын сарае, тагын берничә корылма күренә. Баскычлары сап-сары итеп юылган, буялмаган тактадан булып, ишеге зур йозак белән бикләнгән иде. Гаскәров йозакны келтерәтеп ачты, һәм алар эчкә үздылар. Өй тыштан салкынрак иде, ләкин ул үзенең чисталыгы, похтәлеге белән Иркенең күнеленә хуш килде. Сул яктагы зур моржа ап-ак итеп агартылган, аралыкта юынгычы, моржа алдында ике комфоркалы газ плитәсе бар. Зур бүлмаган өстәлгә киндер ашъяулык җәелгән, аның өстендә җиз самавыр утыра. Кече яктагы шкафта кәстрүл, чәйнек, чыныяк, савыт-саба, илдәгә ике су багы, электр плитәсе күзгә ташланды. Ястык-мендәрләр белән җыештырылган ике караватның берсе түр якка, икенчесе ишек янына куелган.

—Түтәйнең йорты менә шушы,—диде ул.—Савыт-сабасын тотыгыз, урын-җирен дә файдаланыгыз. Житмәгәнен алып килерсез. Суны инде ул

колонкадан алып керә иде. Җәйгә кайтса, тагын күз күрер.

Иректең күзенә яшь тыгылды. Үзенә беркем дә булмаган бу кешегә аның әллә нинди жылы сүзләр әйтәсе килде. Гаскәров, тәжрибәле житәкче буларак, аның кичерешләрен тулаем аңлады һәм инбашына кулы белән жиңелчә генә кагылып алды.

—Тыныч кына яшәгез... Язмыш шулай күшкан икән, яшәгез.

—Мин бурычлы булып калмам,—диде Ирек, көч-хәл белән телен әйләндереп.

—Сез түгел, мин бурычлы сезнең алда.

—Ничек?

Гаскәров башын тәрәзәгә таба борды. Кичке шәфәкъ нурларында аның йөзе кызыл ут кебек яна, шул ук вакытта калын жыерчыклары, тирән ерганаклар кебек, ул кызыллыкны телгәлиләр иде.

—Әллә сез мине бик рәхәтләнеп утыра дисезме ул урында?—диде ул бик озак дәшми торганнан соң.

—Житәкче урынның нинди икәнен беләм инде мин.

Гаскәров кырыс чыраен ялт итеп аңа борды. Моңа кадәр сын кебек хәрәкәтсез иреннәре, саллы ияге ничектер күркыныч булып калтыранып китте.

—Әгәр йөрәгем күшканча яши алсам, сезне партиядән чыгару өчен күл күтәреп утырыр идемме әллә?!

Иректең аны тизрәк тыныч ландырасы килде:

—Аның урынына мин хәзер ирекле кош.

—Хикмәт сездә генә булса! Көн саен, гомер буе бит...—Гаскәров тыны кысылгандай туктап калды. Чыннан да аның авыр итеп сулыш алганы ишетелә иде.—Йөрәк ничек түзәдер, белмим.

—Шулай яшәү кемнәргәдер ошый ләбаса.

—Безнең бөтен фажига шунда... Ошамаса, үзгәртерләр иде...

Гаскәров күл селтәде дә, хуш та димәде, исән дә димәде, ишектән чыгып китте. Ирек ашыгып аның артыннан атлады. Гаскәров машинага утырган:

—Зинһар языгыз,—диде.—Мин шул кадәр телим язуыгызны. Өметем зур сезгә...

—Рәхмәт.

Машина күзгалып китеп барды. Ирек инде шактый асылынырга өлгергән иске капканы күтәреп ябып ишек алдына керде, авыр адымнар белән өйгә үтте һәм салкын урындыкка утырды. Гомер юлы менә шушында килеп элгәшер дип кем уйлаган? Күнеле сулык-сулык килеп өрнедә. Ул башын тәрәзәгә борды һәм күз алмаларын авырттырырлык кызыллыктан керфекләрен кысарга мәжбүр булды. Мунча түбәсендә кояшның түбәтәй кадәр генә өлеше ут булып яна иде. Ул бөтен дөньяны кып-кызыл иткән, күк гөмбәзен, бакчадагы агачларның кәүсәләрен кызыл нәкыш белән өреткән. Күзен бу кызыллыктан яшерү өчен Ирек башын сулга борды һәм сискәнеп китте: тәрәзә рамнарының моржага төшкән шәүләсе кара рәшәткә төсле иде. Шунда Иректең үзенең дә шәүләсе күренә. Ул әлеге рамнардан качмакчы булып күзгалырга итә, әмма кыймшана алмый, әйтерсең лә шушы урынга кадакланган. Ул хәйран калып шактый утырды. Менә кояш түбә артына төшеп юк булды, күк йөзе пешкән чөгендер төсенә кереп күгәрде. Бөтен дөнья шушындый шыксыз төстә, үлгәндәй катып калды. Ник бер жил исеп, агач ботагын селкетсен, ник бер кош очып үтсен, ник бер тавыш ишетелсен. Ирек акрын гына урыныннан торды—мичкә ягарга кирәк иде. Ул утын алып керде, моржаны ачты, коры әрдәнәләрдән каен тузлары алып, мичнең уртасына өйде, тик күпме эзләсә дә, шырпы тапмады. Өйнең биклән, киветкә юл тотты. Кибеттән шырпы, ипи, бер кисәк май, бер кап шикәр, тез сатып алды. Аның бу оч кибетенә кереп, әлеге әйберләрне алуын күреп, сатучының йөзенә гажәпләнү галәмәтләре чыкты.

Ирек кайту белән мичкә ягып жибәрде. Каен утыны дөрләп кабынып киткәч, өйдә ялкын шәүләләре уйный башлады. Ул ут каршына утырды һәм мич астында нәрсәнендер хәрәкәтләнгәнен күрде. Ана күзен елтыратып

бер тычкан карап тора иде. Ул әз генә селкенүгә, тычкан юкка чыкты. Ирек, ипи сындырып алып, идән уртасына ваклап куйды, тычканнын килеп шул ипине ашавын теләде. Ләкин тычкан кабат күренмәде. Бераздан ялкын мичне тулысынча биләп алды, арага эләккән усак утыны шарт-шорт ата, имән белән каен бер көйгә дөрли башлады. Мичтә күмерләр төшә башлауга, Ирек, утны яндырып, аралыктагы пешкәкне тапты һәм ишек алдындагы коедан су кертеп казанга салды. Идәндәге ипи кисәкләре юкка чыккан иде. Ирек куанып куйды, "дуслашырбыз әле без синең белән",—диде елмаеп. Казанны тутыргач, тагын мич каршына утырды, кисәүагач белән күмерләрне казан астына тартты.

Төнне Ирек ике аягын урындыкка күтәреп куеп утырган хәлдә ярым йокымсырап үткәрде.

Өйнең идәне салкын иде. Ул Мәлсәка барып хәлне аңлатқач, ике егет белән ком төяп кайттылар һәм, сайгакларны ачып, нигезләрне ком белән төйделәр. Кичкә Мәлс үзе ит, бәрәңге ише азык-төлекләр төяп килеп житте.

—Бу ой тормаслык түгел,—диде ул.—Эш мәсьәләсендә ниишләрсең микән соң?

—Хәзергә язам әле, абый.

—Ярый, анысын үзең беләсең.

Атна-ун көн Ирек өйне караштырып-юыштырып үткәрде. Өстәл лампасы алып кайтып куйды; язасы әйберләрен барлады. Өстәл артына көненә әллә ничә мәртәбә утырып караса да, бер генә жөмлә дә яза алмады, Сөембикә күз алдыннан китмәде. Аның эндәшкән тавышын ишетеп, ул ялт итеп борылып карады, янәшәсенә килеп басканын сизде, аның сулышын, исен тойды. Бер көнне кич түзә алмыйча уң алар янына китте. Ишек эчтән бикле иде. Шалтыраткычка басуга, Сөембикәнең "Кем бар?" дигәне ишетелде.

—Мин әле бу,—диде Ирек йөрәге дөп-дөп типкән хәлдә.

Сөембикә сүзсез генә ишекне ачты һәм эчкә узды. Ирекнең күзләре Сөембикәнең шәрә балтырларына, гәүдәсен кысып торган халат итәкләренә төште. Тупсадан узуга, Айгөл аның муенына ташланды. Кызының колак яфракларына иреннәрен тигерепе нәрсәдер пышылдавы, аның кайнар сулышын тою Ирекнең хәлен алды, ул кызын иркәләде дә иркәләде.

—Әти, син нишләп кайтмыйсын?—диде Айгөл, аның күзләреннән жавап эзләп.

—Минем эшем шундый, кызым. Әлегә кайтырга ярамый.

—Син ул эшне ташла да өйгә кайт,—диде Айгөл.—Без сине сагындык, әйеме, әнием?

Сөембикә кызының соравын жавапсыз калдырды.

—Әйдә, өлләрене сал,—диде ул.

Ирек ничектер кыенсынып кына чишенде. Айгөлгә алып килгән күчтәнәчләрен бирде. Аннары кызы белән олы якка чыкты. Ул дәрес әзерләп утыра икән. Дәфтәрләрен, көндәлеген карады. Көндәлектәге бер "өч"лене төртеп күрсәтеп:

—Ә бу нәрсә?—диде Ирек.

Айгөл алдагы ике теше төшкән авызын күтәреп көлеп жибәрде:

—Чирле "өч"ле ул.

—Татар теленнән син "өч"ле алырга тиеш түгел бит, кызым.

—Яңадан алмам, әтием.

Айгөл авызының тешсез жиреннән телен чыгарып күрсәтте. Аннары алар "очты-очты"лы уйнадылар. Сабый тәгәри-тәгәри көлде.

—Очты-очты, "өч"деләр очты!—диюгә, ул ике куллап көндәлеген өскә чәеп жибәрде, китап-дәфтәрләрен чөйде һәм, уенны ташлап, әтисе тирәсендә әйләнә-әйләнә йөгерә, мәтәлчек ата башлады... Ул арада аларны Сөембикә чәй эчәргә чакырды. Ул төмле итеп бавыр кыздырган иде. Бик нык ашыйсы килсә дә, ач икән дип уйламасын өчен, Ирек тылын кына ашады. Айгөл туктаусыз тәтелдәде, ә алар бер-берсеннән карашларын туктаусыз яшерделәр.

Ашагач-чәйләгәч, Ирек кайтырга әзерләнде. Айгөл, башта шыңшып, этисенең кулына ябышты, муенын кочаклады, аннары елый ук башлады. Ирек тизрәк киенде.

—Мин, кызым, яңадан килермен әле синең янына,—диде ул чыгып киткәндә.

Хуш димәде, сау бул димәде, башын игән килеш, кызу-кызу ишек алдына чыкты һәм урамга атылды...

10

Кызык инде бу тормыш: язны да, җәйне дә, көзне дә ничек килер дип куркып көтәсең—жылысы булырмы, янгыры булырмы, игеннәр өчен уңай килерме? Курку белән бергә өмете дә яңәшә йөри. Быел Миңзаһит Усмановичның өметләре акланып кебек: язгы сулар мул ташыды, ләйсән янгырлар да вакытында явып узды, кыр эшләрен дә әйбәт кенә башкарып чыктылар. Басуларда ямь-яшел игеннәр күтәрелде, болыннарда печән дулкынланып утыра. Инде менә өч атна барлык хуҗалыклар печән әзерләү белән мәшгуль. Бүген дә Миңзаһит Усманович, иртүк чыгып китеп, бөтен районны урады. Һәркайда тупланып эшләп яталар, ямь-яшел эскертләрәге карап, күңел куана. Ул соңгы хуҗалыкка барып төшкәндә, механизаторлар ашаганнан соң ял итеп утыралар иде. Кемнәрдер тәмәке тарта, яшь-жилкенчәк шаярыша, өлкәнрәкләре күләгәдә ятып тора, ә бер урынга жыелышканнар да утырып таяк тартышалар. Миңзаһитны күргәч, алар туктап, сикерешеп тордылар.

—Кузгалмагыз, кузгалмагыз,—диде ул елмаеп.—Әйдә карыйк әле, кем көчлерәк икән?

Беренче секретарьдан мондый сүз ишеткәч, егетләр дәртләнеп киттеләр. Ахырда базык гәүдәле, бүтәкә кебек тыгыз тәнле механизатор жиңүче булып калды. Ул утырган жиреннән күзләрен хәйләкәр елтыратып:

—Миңзаһит Усманович, әйдә утырыгыз,—диде.

Бөтенесе дә бердәм көлеп жибәрделәр.

—Синең беренчене жиңәсең килә инде.

—Парин, юри булса да жинел.

—Сезнең бик көчле кеше дилəр бит, Миңзаһит Усманович. Авырлыгыз да бер центнер тына бардыр.

Ул көлә-көлә әлеге егет каршына утырды. Алар таякны тотуга, "бер-ике-өч" дип кемдер команда бирде. Егет чыннан да каты иде. Миңзаһит жаны чыгардай булып тартышты. Алар икесе дә кызарынып бүртенделәр, ахырда бер якка аудылар, торып кабат тотындылар.

—Жәмәгать, чыннан да көчле икән безнең секретарь!

—Миңзаһит Усманович, бер талпынсагыз, була бит! Әйләндереп салыгыз әле шул бүтәкә тәрене!

—Жинелсән, уныш бәйрәмендә бүләк бирәм, диегез сез ана. Әйбер дисән, чукына ул.

Механизаторлар туктаусыз көлештеләр, әллә юри, әллә чынлап, һаман ана көч-күәт бирделәр. Миңзаһит кинәт биленең уртасында черт итеп нәрсәнендер купканын тойды һәм каты авырту өттереп алды. Ул таякны жибәрде.

—Кая инде безгә, картларга,—диде ул кул селтәп.

—Ничья, ничья!

—Молодец, Миңзаһит Усманович! Бүтәкәнең уылдыгы чыга язды!

Бөтенесе дә шаулатып кул чаптылар.

—Нигә көндә төгәллисез?—дип сорады Миңзаһит.

—Бер атнага барыр әле,—диде аның белән таяк тартышкан егет.

Миңзаһит "юк" дигән мәгънәдә башын чайкап куйды.

—Бер атна булмый, егетләр. Барометр угы түбән төшә: ике-өч көннән янгырлар башланырга мөмкин. Таяк тартышкан кебек тартышырга кирәк. Өч көндә төгәллибезме?

—Сез әйткәч, эшләрбез,—диештеләр механизаторлар.

Минзәһит машинасына утырып Болынкырга юл алды. Һәр сикертмәдә биле сыкрап-сыкрап куйды. "Бәйт карт дурак!" дип каргады ул үзен. "Картаеп акыл кермәгән нәрсә, ник кирәк иде инде бу мина? Кайчаннан бирле бернинди заярдка ясаган юк, юньләп физик эш эшләмә, тот та таяк тартышырга утыр. Ярый үзып китсә. Аның бит бил белән бернивә мәртәбә больницада да ятып чыккан бар иде инде. "Гомер буе шушылай,—дип каргавын дәвам итте ул үз-үзен.—Беркайчан да алдын-артын уйлап бетерә алмадым..."

Машинасын райком гаражына куеп чыкканда, аның каршысына райкомолның беренче секретаре Рифгать Хажиев килеп басты.

—Бу вакытта нишләп йөрисең?—диде Арсланов ана күл бирепе.

—Мин дә колхозлардан кайттым гына әле,—диде Хажиев.

—Ничек соң?

—Эскертлиләр. Ни бит әле, Минзәһит Усманович... Бүген Эльза гариза бирде.

—Нинди гариза?

—Эштән китәм, ди. Иртәгәдән расчет сорый.

Арсланов бер минут чамасы сүз әйтә алмыйча, әле уңга, әле сулга карап алды һәм иреннәрен кыскан хәлдә кызу-кызу китеп барды. Өйгә кайтып кергәндә, аның көне буе очынып йөргән күнеле кургаштай авырайган иде. Костюм-чалбарларын алыштырып, юынып өстәл янына килгәндә, Хәят кайнар өчпочмаклар китереп куйды.

—Эльза кая?—диде Минзәһит.

—Үзенең бүлмәсендә. Без ашаган идек инде.

Пешәләнә-пешәләнә бер өчпочмак ашагач, Минзәһит авызын салфетка белән сөртте дә:

—Эльзаны чакыр әле,—диде.

Үзе залдагы диванга чыгып утырды. Бераздан Эльза белән Хәят аның янына керделәр. Кызы читкә китеп, пианинога таянды. Минзәһит урынынан торып, акрын гына аның янына барды һәм диванга алып килеп, үзе янына утыртты.

—Кызым, нишләп кәефең юк?—диде ул, барысын да аңларга теләп аның күзләренә төбәлгән килеш.

Эльзаның сөрмәле керфекләре дерелдәп куйдылар, ул карашын читкә яшерде.

—Әллә әйтте?—диде ул пышылдап.

—Син нишләргә жыенасың?

Эльза куркып әнисенә карап куйды, тагын керфекләрен аска төшерде, ишетелер-ишетелмәс кенә итеп:

—Китәм,—диде.

—Кая?

—Кая да ярый, Болынкырда гына булмасын.

Хәятнең йөзенә аптырау галәмәтләре чыкты һәм ул өзгәләнеп алар янына килде:

—Нишләп әле без бернидә белмибез? Ни булды?

—Үземчә яшәп карыйсым килә.

—Сәбәп шулмыни?—диде Минзәһит.

—Әйтсәм, рәнжерсез дип куркам. Янадан сөйләшербез әле.—Ул урынынан торып бүлмәсенә таба атлады, ләкин Хәят аның каршына килеп басты.

—Юк, хәзер,—ул авызына ингалятор белән даруын өрде.—Институтка керер вакытың житкәндә...

—Китү бит укырга комачауламый, әни.

Хәят идәнгә шапылдатып тибеп куйды һәм елардай тавыш белән кычкырып жибәрде:

—Хәзер үк әйтеп бирәсең! Абыең башы-аягы белән югалды. Безгә аның кайгысы да житкән иде. Әйт, нинди сәбәп бар?

Эльза, әнисенең бу кыланмышыннан куркып, акрын гына артка чикте дә ярым пышылдап:

—Аның сәбәбе—сез,—диде.

—Без?!—диде Хәят елардай булып.—Без сина начарлык кылдыкмыни?

—Яхшылык кына,—диде Эльза киная белән.—Бүтәнәрдән аерып.

—Йә-йә, шуннан?—диде Минзәһит, күзләрен кысып бетереп.

—Их, әти! Син бит кешеләрнең үзенә ничек караганын белмисең...

—Без әлегә синең турыда сөйләшә идек бугай,—дип куйды Минзәһит.

—Мин синең аркада китәм.

—Әйдә, аңлатып бир...

—Син бит, әти, ин бәхетсез кеше...

—Күпме дәрәҗәдә бәхетле, никадәр бәхетсез икәнемне мин үзем бик яхшы беләм.

—Белмисең! Сине бит беркем дә яратмый.

—Бу сүзләрең белән әтиеңне ничек рәнжеткәненне аңлыйсыңмы син?

—Мин баштук кисәттем: төпченмәскә кирәк иде.

—Күпме яшәп, таләпчән житәкчеләрне яратканнарын хәтерләмим әле мин,—диде Хәят.

—Әнисе, тукта,—диде Минзәһит, кинәт урынныннан торып. Аннары бик акрын, төшенке тавыш белән дәвам итте:—Эльза хаклы. Кызым, минем бер генә төтенечем бар: игътибар белән тыңла зинһар. Мин туктаусыз әйләнеп торучы, бер-берсенә керешкән мең төрле шестерня эчендә әвәләнәм, изеләм...—Минзәһит, авыр сулыш алып, башын игән хәлдә туктап калды.—Күкрәк киереп, көр тавыш белән сөйләшкәч тә, әллә син мине эчтән шулай дип беләсеңме? Минем куян кебек калтырап торган чакларым күбрәк тә түгел микән әле?.. Үкереп елыйсым килсә дә, кешеләр алдында минем еларга да хакым юк.

Ул акрын гына атлап Эльза каршына килде, идәнгә тезләнде. Биле авыртудан ыңгырашып куйды. Аннары башын югары күтәреп, аның күзләренә төбәлде һәм кайнар итеп пышылдады:—Китмә син, ярдәм ит миңа, үтенеч сорыйм!

Эльзаның ике күзе яшь белән тулды. Ул да әтисе каршына тезләнде һәм аның битләренә, танырга теләгәндәй, бармак очларын тигереп алды, колакларын сыпырды.

—Әти, мин ничек ярдәм итим соң сина?—диде ул, елаудан көчкә тыелып.

—Янәшәмдә генә бул!—диде Минзәһит шактый нык тавыш белән.—Ялгышларымны күрсәтеп тор. Әйдә, яңача яши башлыйк. Мин үзгәрергә сүз бирәм, мин үзгәрәчәкмен... Якынайт кешеләргә... Мин бит үзем дә сизәм... Тирә-юнемне ялагайлар басты...

Алар шактый вакыт шул хәлдә бер-берсенең күзләренә карашып тордылар.

—Ярый, мин гаризамны кире алам.

—Рәхмәт, кызым.

Эльза бүлмәсенә кереп китте. Минзәһит диванга барып утырды, ул, йөзен ике кулы белән каплап, терсәкләре белән тезенә таянган хәлдә хәрәкәтсез калды. Хәятнең акрын гына атлап үзе янына килгәнен ишетте, инбашларына аның йомшак кулларының кагылуын тоюга, күзләреннән кайнар яшь бәреп чыкты...

11

Ул көнне Мәлс Нәфисәгә иртүк әйтеп куйды: кичкә мунча як, ашарга әзерлә, Ирекне алып кайтам, дидә. Алар кич карангы төшкәндә генә кайттылар. Нәфисә кайнар бәлеш китереп куйды. Мәлс, кече якка чыгып, аңа акча сузды: "Үткән айның хезмәт хакы",—диде ул пышылдап кына. Акчаларга күз салгач, Нәфисәнең чырае бозылды:

—Бөтенесе шушымыни?!

—Тс-с-с! Яңадан аңлатырмын...

Хатыны кайнар бәлеш куйгач, алар ашарга утырдылар. Берничә минуттан киенеп-ясанган Нәфисә кече якка чыкты.

—Син кая?—диде Мәлс.

—Мәктәпкә. Иртәгәге расписаниене үзгәртәсем бар.

—Беркая да бармыйсың,—диде Мәлс.—Иртән барырсың.

—Юк, мина хәзер кирәк,—диде Нәфисә, ишеккә таба атлап.

—Ярый, бар, тик кайтуына ишек бикле булыр.

Нәфисә берничә генә секундка икеләнеп торды да кулындагы китап-дәфтәрләрен кием чишенә торган урындагы тумбочка өстенә шапылдатып ыргытты һәм кызулап бүлмәсенә кереп китте. Кабат чыкканда, аның ике күзе мөлдерәп яшь белән тулган иде инде.

—Менә, Ирек, кара абыеңны,—диде ул ярым елап.—Чын тиран. Йортта барысы өчен дә мин жавап бирәм, бөтен хуҗалык минем өстә. Ә ул ничек тели, шулай командалык итә.

Мәлс көлемсерәп куйды:

—Йә, йә, карчык, тынычлан. Әйдә безнең белән утыр әле.—Мәлс аны кочаклап алып килеп каршыларына утыртты, тәлинкәгә бәлеш салды.

—Ашыйсым килми,—диде Нәфисә, лышык-лышык борынын тартып.

—Кызганыч,—диде Мәлс.—Бәлеш искиткеч тәмле. Ничек түзәсеңдер, карчык, белмим.

—Ул бит мине менә шушылай кыланып жанымны ашый,—диде Нәфисә, һаман Иреккә зарланып.—Алмазның ничек үскәнен белмәдең, шулаймы?—диде ул, Мәлска туп-туры карап.

—Дөрес,—диде Мәлс тыныч кына.

—Малай егет булып житте. Аның кайда йөргәнен белми. Наилә6ез абыйсы артыннан куып бара. Анын ничек үскәнен дә син белмәдең.

—Дөрес,—диде Мәлс.

—Аларны мин тәрбияләдем. Күпме йокысыз төннәр үткәрдем. Хәзер дә үзем баш, үзем түш. Шулай түгелме?

—Шулай,—диде Мәлс.—Барысын да син эшләдең, карчык. Син аларны гына түгел, мине дә тәрбиялисең. Синең түземлелегең алдында мин баш иям.

Нәфисә чәчрәп урынныкан торды.

—Менә тагын мыскыл итә башлады.

—Нишләп мыскыл итим?!—Мәлс бераз уйланып торды.—Тормыш шундый булгач, нишлик соң инде?

—Тормыш андый түгел,—диде Нәфисә тавышын күтәреп.—Без гомер буе аерым. Агроном чакта басуда иден. Директор булгач, бөтен жирдә. Син өйдә йоклап кына чыгасың. Ә бу тормышның барлык сөремен мин йотам... Ялгыз кисәү...

—Жә инде, карчык, энекәшне ышандыруын бар бит,—диде Мәлс йомшак кына.

—Ышандырасы юк, күрсен безнең ничек яшәгәнне.

Мәлс та, Ирек тә инде ашаудан туктаганнар иде, Нәфисә әрле-бирле әле кече якка, әле залга атлап, йөренеп торды, туктаусыз борынын тартты. Мәлс кашыгы белән берничә мәртәбә табага шакы-шокы сугып алды.

—Син чыннан да хаклыдыр да... Тик ничек әйтсәм, анларсын микән...—Мәлс күзләрен йомып, уйланып алды.—Ятьмә белән балык сөзгәнне синең күргәнең бар ич. Берәү яр буйлап сайдан сойри, икенчесе ятьмәне тирәннән көймә белән тарта. Без дә шулайрак. Ятьмә бит уртак, карчык. Балыгы да...

Нәфисә чәрелдәп кычкырып жибәрде:

—Балык?! Кая ул балык?!—Ул кулындагы акчаларны идәнгә чәчеп жибәрде.

Мәлс торып басты:

—Нәфисә! Хәзер үк жыеп ал акчаларны!—диде ул тавышын күтәреп.

Нәфисә акчаларны тиз генә элэктерде дә бүлмәсенә кереп китте. Бүлмә тып-тын калды. Тынлыкны Ирек бозды:

—Мин сине юлда алдадым бит, абый. Пьеса төгәлләдем, повестем бетү алдында, дип.—Ул, Мәлсның күзләренә кәрәргә кыенсынып, башын читкә борды.—Бәрсе дә төгәлләнмәгән. Яза алмыйм мин. Жанымны әллә нәрсә актара.

—Әллә Сөембикәне оныта алмыйсынмы?

—Яшермим, анысы да бар.

—Кире аның янына кайтырга уйламыйсынмы сон?

Ирек "юк" дигән мәгънәдә баш чайкады.

—Мин нинди ярдәм күрсәтә алам?

—Синең күрсәткән ярдәмең бик җиткән инде. Мин елгадагы йомычка кебек. Дулкын кая кага, агым кая алып бара, агам да агам, бөтереләм, каядыр килеп бүләм, тагын кузгалам. Бер генә тотыныр жир дә юк...

Алар урыннарыннан торып мунчага киттеләр. Мәлс себеркеләрне пешергәч, аны мунчада калдырды, озаклап, ашыкмыйча генә, кайтуына мәтрүшкәле чәй пешереп торам, диде.

Ул кайтканда, Нәфисә үз бүлмәсендә иде әле. Мәлс анда үтте, хатынының урын җәймичә, чишенмичә генә бөкләнеп, кечкенә генә булып караватта ятуын күрде, акрын гына аның янына барып таянды.

—Их, карчык,—диде ул.—Минем бит кайтып жан тыныч лыгы таба торган бердәнбер кешем син. Хикмәт бит төче сүзләр сөйләүдә генә түгел. Көнетөне бергә булуда гына да түгел. Элек-электән күпме ир, күпме хатын аерым яшәгән, берсе Россиядә, икенчесе Америкада, башка илләрдә. Үзләрен бер тән, бер жан итеп тойганнар. Елга ике-өч мәртәбә дә очраша алмаганнары булган.

Нәфисә кинәт кенә ана таба борылды.

—Димәк, берни дә үзгәрмәячәк?—диде ул әллә нинди өзгәләнүле тавыш белән.

—Их, Нәфисәкәем!.. Көн саен сина күпме саулык-сихәтлек теләгәнемне белсәң син!—Ул пышылдауга күчте:—Учак янына бит син кирәк... Синнән генә бөтен жылы...

Нәфисә ана ышанырга да, ышанмаска да белмичә, гаҗәпләнеп карап торды...

***

Арсланов Бөгелмәдән котырып кайтты. Ул анда зур гына төзелеш житәкчесенең юбилеена барган иде. Культура бүлеге мөдире Халиковны кат-кат кисәтте: бик яхшы бер жыр булэк итәсез, диде. Арслановның котлау сүзен кайнар алкышлар белән каршыладылар. Әмма бүлэк ителəсе жырны башкарырга чыккан баянчы белән жырчы хатын аны жир тишегенә кереп китәрдәй иттеләр. Баянчы салмыш иде, ул, тиешле тонны ала алмыйча, теге хатынны туйганчы чинатты. Күнел бүлсын өчен генә берничә кеше чәпе-чепе күл чабып алды. Арслановның ашавы ашау, эчүе эчү бүлмады. Житмәсә, үзенең коллегалары, ана астыртын кинаяле караш ташлап, мыскыллы елмайдылар. Халиковның аны яндыруы беренче генә мәртәбә түгел иде инде. Гомумән, пенсия яшенә житеп килүче бу кеше инде бүгенге культура талəпләреннән нык артта калуы, зəвыксызлыгы өстенә гаять жавапсыз да иде. Юбилейның икенче көнендә сəгать кичке дүртkə Арсланов Сөембикәне үз бүлмəсенə чакырды. Сөембикə зəнгəр костюмнан, дулкынланган сары чəчлəрен инбашларына таратып куйган хəлдə, төз-нафис гəүдəсен тыйнак кына уйнатып керде һəм аның каршына килеп туктап калды. Минзаһит Усманович торып ана таба атлады. Сөембикəдəн бөркелгəн төмле хушбуй исеннəн Минзаһитның башы əйлəнеп китте. Ул түзмəде, бармак очлары белəн аның иягенə кагылды. Ләкин Сөембикə елмаймады, артка чигенде. Аның ике битенə кып-кызыл булып үт капты, күзлəре очкынланды, иреннəре калтырап куйды. Минзаһит моны аермачык күрде. Ул кабат ана таба атларга базмады, тамак кырып куйды да кабат урынына кайтты.

—Утыр, Сөембикә,—диде ул ягымлы гына.—Ни хәлләр бар?

—Рәхмәт, бер килеш.

Минзәһит Усманович кулларын угалап куйды, өстәленнән нидер эзләгәндәй, карашын аска төшерде һәм акрын гына сүз башлады:

—Эльза укырга киткәч, өйдә икәү генә калдык. Әллә вакыт күбәйде, әллә үйланырга мөмкинлек туды: мин бик сәер хәл кичерәм.—Ул башын күтәрде һәм Сөембикәнең күзләренә туп-туры карады.—Ышанасынмыюкмы, һәркөн син күз алдыма киләсең.

Сөембикә акрын гына урыныннан торды.

—Вакытыгызны әрәм итмәгез, Минзәһит Усманович,—диде ул.

—Нәрсәгә?

—Очрашуга көйләгәнегезне сизеп торам. Очрашулар бетте.

Минзәһит Усманович башын чайкады да аның күзләренә төбәлде.

—Нибары өч мәртәбә очраштык. Аларның һәр мизгелен мин хәзер хәтеремнән уздырам. Мин күп хатын-кызлар белән аралаштым, әмма...—Ул беразга тынып калды, өстәлендәге кәгазьләрне бер яктан икенче якка алып куйды, ияген сыпыргалады.—Ни әйтсәм дә, ышанмассың... Беләсеңме, Сөембикә, мин нәрсә турында уйлыйм: әгәр безнең очрашу мәнгелекнең үзе тарафыннан боерылган булса?

Сөембикә ана сәерсенеп карады.

—Мин сезне аңламыйм.

—Аңларсың әле. Минем өчен син тәүге һәм соңгы хатын-кыз булмадың микән...

Бу сүзләр ярым аңлаешлы, ярым аңлаешсыз булуларына карамастан, Сөембикәнең бөтен гәүдәсен үт төрткән кебек кызыштырдылар, битләренең кайнарланып яңуын ул аермачык тойды. Сүз бик зур нәрсә хакында бара иде... Ә Минзәһит Усманович серле сүзләрен дәвам итте:

—Мине башка беркем дә кызыксындырмый.—Ул ике кулын кесәсенә тыгып тәрәзә каршысына басты, аның мәһабәт гәүдәсенә Сөембикә аптырап карап торды.

Вакыт шактый сузылгач, ул урыныннан торды:

—Мина китәргә мөмкинме, Минзәһит Усманович?

Арсланов ана жавап бирмәде, тәрәзәгә караган килеш әллә Сөембикәгә, әллә үз-үзенә сагышлы сүзләрен тезде:

—Быелгы көз нишләптер жанны суыра. Бу сары яфраклар яшьрәк вакытта мине елмайталар иде, ә алар хәзер сары күргаш кебек авырлар, салкыннар. Алар мыскыллап кычкыралар. Шушы кадәр тыныч сарылыкның бөтен тирә-юньне тутырып кычкыра алуын берәр китаптан укысам, мин ул язучыны ахмак дип сүтәр идем. Ә менә хәзер мин кичергәннәрне дөрес итеп аңлый алырлык берәр язучы табып булыр микән? Мин ана "Кычкыра торган сарылык" дигән әсәр яздырып идем. Элекке хисләрнең картаюымы бу, әллә алар үлеп, урыннарын картайган-бетәшкән тойгылар биләдеме?—Ул акрын тына борылып, тагын Сөембикә янына килде, аның йөзенә сокланып карап торды.

Сөембикә артка чигенде:

—Мин китим әле...

—Син китмә әле,—диде ул, әллә ничек итеп.

Минзәһит Усманович урынына барып утырды һәм аның күзләрендәге, йөзендәге жылылык һәм сагыш шундук юкка да чыкты. Ул һәрвакыттагыча кыядай мәгърур, корычтай нык Арслановка әверелде.

—Мин сина культура бүлеген житәкләүне йөкләргә жыенам,—диде ул ныклы тавыш белән.

—Сез нәрсә?!—Сөембикә, очып китәргә теләгәндәй, алга талпынып куйды.—Минем кулдан килә торган эшме шул?

—Сөембикә, дулкынланмый гына тыңла әле. Без сина барлык ярдәмне дә күрсәтербез. Халиковтан зарланып кергәннәренне хәтереңә төшер. Теләсә нинди томанага буйсынганчы, һәммәсен дә үзең житәкләячәксең. Күл астында машинаң, шоферың була.

—Юк, юк,—диде Сөембикә аны бүлдереп.—Мин ялгыз хатын. Минем кызым бар. Мин көне-төне чаба алмыйм.

—Чапмассың. Синең бит инспекторын бар, башка работникларың да житәрлек.

—Минем белемем дә юк.

—Ничек юк? Син культура институтыныңөченче курсын тәмамлагансың.

—Аны ташлаганыма биш былтыр инде.

—Укуынны восстановить итүне мин үз өстемә алам,—диде Арсланов.

—Туктагыз әле, Минҗәһит Усманович. Мин бит әле рәзалык бирмәдем.

—Әгәр дә акылың булса, бирерсең. Иртәгә жавабынны көтәм. Хуш, Сөембикә.

Сөембикә аның бүлмәсеннән ни үле, ни тере халдә чыкты. Башы тәмам катып, өенә кайтты, ашарга әзерләде, Айгөлнең дәресләрен карадылар. Аны йоклаткач, ныклап торып уйларга кереште. Бу эш бик зур да, шул ук вакытта кызыктыргычта иде. Аның культура өлкәсендәэче пошып йөргән нәрсәләр гаять күп, әгәр әз генә ялкын өстәсәң, кешеләрне кызгатсаң, район тормышына жылылык өреп, аны нурлап булыр кебек иде. Ул күпме генә әйләнгәләп ятса да, башы мең төрле уйдан катып, аныкына карарга килә алмады.

Иртән башы чатнап уянып китте. Әле яктырылып кына килә иде. Ул жылы киемнәр киеп, агач бакчасына чыкты. Көелган яфракларны кыштырдатып, бакчаның түренә үк атлады һәм кечкенә эскәмиягә утырды. Күк йөзен күнелсез, соры болытлар каплаган. Кинәт иртәнге салкын һаваны ярып, каяндыр карга өере күтәрелде. Өер шул кадәр зур, анда каргалар шул кадәр күп, ул туктаусыз кыймылдап, хәрәкәтләнеп торучы һәм очып баручы кара челтәрне хәтерләтә иде. Каргалар канатлары, койрыклары белән иртәнге салкын һаваны ышылдатып ярып, кинәт аска төшеләр, тораташ өер булып, әкрен өстенһән шуышып узалар да, тагын борылып киләләр, тагын өскә күтәрелеп ерагаялар. Аларның шаукылдаулары, чыкы-чыкы чыйкылдап, бер якынаеп, бер ерагаеп, бөтен һаваны шыбырлап тора, гүя бөтен күк йөзе, каралты-кура шул тавышлардан калтырый. Кара челтәр төсле каргә иле, әллә ничек кенә кыйгачлап борылып, әле аска төшә, әле өскә күтәрелә, әле аерыла, әле кушыла, әле әйләнеп бөтерелеп йөри, койрык булып сөйрәлә, өзелә, тагын башына кушыла, тарала һәм жыела...

Сөембикә күзләрен йомды, анын уйларының рәте-чираты юк иде. Ин элек ул бер нәрсәгә аптырады: ни сәбәпле ул Арслановка ачулана алмады? Иреккенә язмышын жимерүче ул бит. Ник бер сүз дә әйтмәде? Әйтү түгел, аңарда әйтү теләге дә булмады. Нишләп алай? Бюродан соңгы көннәрдә ул Арслановны да, башкаларны да автомат белән кырып чыгарга әзер иде бит югыйсә. Аны тагын бер нәрсә хафага салды: ни сәбәпле ул Арсланов каршында торганда уттай кызышты, бит очларына, иреннәренә ялкын үрләде? Әллә ул аның сәер хисләрен йөрәге белән кабул иттеме? Әллә аның кайнар иркәләүләре тәнендә кабат уянды мы? Нәрсә булды соң? Туйдан соң Ирек гафу иткач, ул бит үз-үзенә мең мәртәбә антлар биргән иде: янадан мәнге андый юлга басмаска, гомеренең азагына кадәр Иреккә тугры булырга, аның табанының туфрагын яларга. Ә антында тора алмады. Теге вакытта Арсланов белән беренче очрашасы төнне аш әзерләүче кызларны Шәвәлиев керде дә эчерде, керде дә эчерде. Аның кулында әллә коньяк, әллә башка нәрсә— нинди сергьлт эчемлек иде. Баш тартканнарын көчләп эчерде, аннары алар исерештеләр. Сөембикә, барысы киткәч, берүзе калганга кайгырмады да. Ул чакта анын тәне дә, жаны да үзеневе түгел иде инде. Минзәһит Усманович аны шашып иркәләргә кереште, ул аның аяк бармакларыннан алып төненең һәрбер ноктасын кат-кат үпте, кайнар иреннәре белән пешерде. Сөембикә башта карышмакчы булып карады, аннары хәлсезләнеп биреште... Аның иркәләүләрен Сөембикә айныгач, кат-кат тәүбә иткәч, үзен-үзе каргаганда да оныта алмады. Яңадан күп вакытлар узгач, Арсланов шылтыраткач, аның сүзләреннән ул кабат исерде. Күнеле теләмәсә дә, акылы карышса да, аяклары аны ул чакырган урынга алып бардылар...

Ул күзләрен ачты. Каргалар кара күч булып, бер урынга жыелып,

агачларга, каралты-кура түбәләренә, коймa башларына килеп кундылар. Кунгач, коточкыч итеп бер шаулашып алдылар да тын гына шакы-шокы, чәлдер-чөлдер килеп, озын юл алдыннан дога укыгандай, эндәшешеп утырдылар. Кинәт, тагын дәррәү күтәрелеп, һаваны айкый башладылар. Алар ышылдап, шыбыршып үткәндә, күршедән үрдәкләр бакылдап, казлар каңгылдап тавыш бирде. Иртәнге йокыны бүлдегез, дигәндәй, кайдадыр ялкау тына эт өреп куйды. Каргалар китәргә әзерләнәдер, шуна алгысыйдыр. Ә үйлар? Аларның китәр урыны юк, алар һаман шул бер башта бөтереләләр, кара үкенеч булып, йөрәкне талкыйлар, кара үкенеч булып, бәгырьне телгәлиләр. Әйе, үкенечнең дә кап-карасы. Әлекке Сөембикә юк инде. Чын Сөембикә әллә кайда—еллар артында калган. Икенчесе—буталучы Сөембикә. Ул әле яңәшәдә бәргәләнеп-бөтереләп йөри. Менә хәзер өченче Сөембикә аякка басып маташа. Бусы әле бөтенләй булмаган, яши генә башлый торган Сөембикә. Ә Ирек белән кайсысы гомер иткән сон? Кайсы Сөембикә яраткан аны? Кайсысы анын тормышын жимергән? Ул, башын күтәреп, инде яфраклары коелып бетә язган ярым шәрә алма ботакларына карады. Ботак араларыннан ашыга-ашыга кургашындай авыр болытлар агыла. Ин биек ботак очларында, жилләргә дә бирешмичә, икс-өч алма калтыраның утыра, ара-тирә сары яфраклар өзелеп төшә. Жирдә ярым черек алмалар ауный: кайсыларын корт төшеп харап иткән, кайсы үзеннән-үзе черегән. Борынгы аларның өчкелтем исе килеп керә дә, күнелдәге төшенке уйларны тагын да көчәйтеп жибәрә. Тиздән беренче кар күренер, бу сары яфраклар, черек алмалар кар астында калырлар. Алар язга кадәр онытылырлар, берәүнең дә күзенә бәрелмәслəр, уйларына да кермәсләр...

12

Кечкенә тыкрыктагы кечкенә генә өйдә нич уйламаганда Ирекнең үз жәмгыяте барлыкка килде. Әйе, бу жир йөзендә ул кечкенә бер жәмгыять иде. Жир шары үзе бер жәмгыять, ил халкы үзе бер жәмгыять. Болынкырда яшәүчеләр—үзләре бер жәмгыять, ә менә Ирекнең үзенең жәмгыяте туды. Бу яңа ел алдыннан булды. Аның яңына элек-электән Бәкер исемле кеше кереп йөри иде. Ул типографиядә гомер бакыена хәреф языучы булып эшләде, шигырьләр, кечкенә хикәяләр, фельетоннар яза, язганнарын Ирекккә күрсәтә, уңышлы дип табылганнарын газетада бастыралар. Бәкернең бөтен яшәвенең куанычы шунда иде. Берәр шигырь басылган көнне ул типография хатыннарына өйдән нәрсә дә булса пешерергә алып килә, рәте булса, берике кызыл ярты ала, аларны бәйрәм иттерә, күнел ача. Бәкер гомер буе өйләнмәгән, сукыр әбисе белән ялгызы яши. Бер яшьтә анын әнисе улган, әтисе ташлап чыгып киткән. Уртача тәүдәлe, бик юаш кыяфәтле бу кешенең түп-түгәрәк башы, муенсыз-нисез генә, тәүдәсенә утыртылган. Ап-ак битләре шешмәкләнеп тора, колаклары кечкенә, яшькелт күзләре тычканныкыдай күренер-күренмәс елтырыйлар, ун күз кабагы һәрвакыт асылыныбрак тора. Керфек төпләре кып-кызыл. Шома битендә төк әсәре юк, бары тик борын төбендә генә бернича аксыл йон мыек сыман тырпаеп тора. Кашлары да, сирәк керфекләре дә, беркайчан да озын булып үсмәүче чәчләре дә аксыл тостә. Бәкернең тавышы кәжә тавышын хәтерләтә, бик нечкә һәм кызганыч. Аның өстендәге бөтен кием үзе тарафыннан тегелгән. Башында куян бүрек, остендә үзе теккән кыска тун. Ул тунның төсен берничек тә аермалы түгел. Аякларында олтанлы иске, ак киез итек. Итекләрнең берсе кайчандыр баш турыннан көйгән булган. Бәкер кәжә асрый, куян тота. Кәҗәне үзе тәрбияли, үзе сава. Мамыгыннан шәл, бияләй бәйләп сата. Аның һәр жөмләсе "Алла бабай кушкан", "Алла бабайга рәхмәт әйтегез" дигән сүзләр белән башлана. "Алла бабай кәҗәне безнен ише фәкыйрьләр өчен яраткан", дип зур канәгатьләнү белән сөйли. Бәкер ихатасында алма, чия, карлыган үстерә, күпләп яшелчә әзерли.

Бәкер үзенең язмаларына үзе пешергән берәр нәрсә дә ияртә, акчасы булганда, аракысын да онытмый. Пешерү дигәннән, бәлешмe ул, бәрәңге

тәкәсеме, чәкчәк дисенме—һәммәсен дә Бәкер теленне йотарлык итә. Ул әле бик оста балыкчы да. "Алла бабай бүген елгага төшәргә куша", дип кармагын тотып китсә, бер-ике табалык балык эләктереп кайтасын көт тә тор. Кайсы төше белән сизәдер, бәлки балык сизәдер, балык эләгәсе көнне ул алдан ук белеп тора, булмаслык икән, елга-күл ягына әйләнеп тә карамый.

Бер көнне кич Бәкер озын гәүдәле, кап-кара чырайлы, тавык күкәе кадәрле күзләре бүлтәеп торучы бер кешене изәртеп керде.

—Бу безнең туган тиешле кеше. Шигырьләр яза, синең белән сөйләшәсе килә иде.

Озын адәм гырылдык тавыш белән тамак кырып куйды.

—Узыгыз,—диде Ирек.

—Миргазяз,—диде әлеге кеше, эре озын тешләрен күрсәтеп, һәм көрәктәй кулы белән Иректең кулын кысты.

Аның кулында ямаулы арыш капчыгына салынган ниндидер әйбер дә бар иде. Ул аны тупса янында калдырды. Бу кеше өстәл янына утыргач, ой эче баләкәйләнгән кебек булып китте. Ирек аны кызыксынып, ныклап күзәтергә кереште. Миргаязның күзәтле ияге алга чыгып тора, иреннәре негрныкы кебек калын, зур борыны очлаеп аска сузылган. Бөтен битен, муенын күе кара төк каплаган. Хәтта колак эчләреннән дә берничә бөртек йон тырпаеп тора иде. Шактый чаларган чәчләре әле куе. Уң янагында һәм аскы иреннәндә тирән яра эзе күренә. Инбашлары текә, озын муенының һәр сенере белеңеп-күренеп тора. Алгы ягында йодрык кадәр төене бар. Ул төен сөйләшкәндә-йотканда тире астында хәтәр булып шуышып йөри. Зур күлларының кайсыдыр бармаклары тырнаксыз, кайсының беренче буыны бөтенләй юк. Аның өстендә озын кара җәйге пальто, пальтоның ни төсле икәнен белмәле түгел: тузан сенеп, жил, янгыр, кар тәэсирендә ул ниндидер көлсу төскә кергән. Әре сәдәфләрен Миргаяз нечкә бакыр чыбык белән тегеп куйган. Аягында ботинкага охшаган иске нәрсә, бәйли торган бавы да, каптыргычы да юк. Миргаяз аларны галош кебек кенә тупса янында салып калдырды. Ирек өстәлгә пешкән бөрәнге куйды, соңгы тозлы кыярны кисте, ипи турады. Миргаяз капчыгыннан бер ярты аракы чыгарды. Стаканнарга салып берәрне тотканнан соң, Ирек:

—Күптән язасызмы?—дип сорады.

—Күптән инде,—диде Миргаяз калын тавыш белән.

Аннары сүзсез генә торып ишеккә таба китте, капчыгыннан зур, калын дәфтәр алып килде. Ул дәфтәр майланып, каралып беткән, почмаклары шомарган һәм анардан дөньядагы барлык исләр дә килә иде. Ирек дәфтәрне актаргалап карады, аның яртысыннан күбесе шигырь язып тутырылган. Миргаяз тары ярмасы кебек вак хәрефләр белән бик матур яза икән.

—Вакытыгыз булганда, укып карарсыз әле,—диде ул.

Ирек дәфтәрне үзенең кулъязмалары янына алып куйды. Бер яртыны бетереп, икенчесен башлагач, Бәкер:

—Әйдә, Миргаяз, бер сыздырып жибәр әле,—диде.

Миргаяз зур кара күзләре белән Иреккә төбәлде.

—Хужа ни әйтер бит?

—Гармун уйный ул,—дип ачыклык кертте Бәкер.

—Ә-ә-ә,—дип сузды Ирек.—Әйдә, уйнагыз.

Миргаяз арыш капчыгыннан көрән төстәге кечкенә тальян гармунын алып куйды. Унике телле бу гармунны тартып жибәрүгә, Иректең йөрәге төшеп киткәндәй булды. Тальян телләреннән чыккан моңны аңлатып та, сөйләп тә бетерерлек түгел иде. Миргаяз авыл көен уйнады. Бу моң аларның яшьләгеннән ишетелә, аларның яшьлек тавышы иде. Бу моңнар гомернең үткәнен, инде киргә юл юклыкны күңелгә телеп-телеп сөндерәләр иде. Күрәсең, алар өчесе дә шушы бер ук тойгыларны кичерделәр, Миргаязның күзләре йомылды, аның бары тик моң көенә гәүдәсе генә чайкалды. Бәкернең күзләреннән яшь ага, ул аларны туктаусыз күл сырты белән сөртә иде...

Ирек Миргаязның теге дәфтәрен өч көн буе укыды. Шигырьнең нәрсә икәнен белмәсә дә, аның искиткеч талантлы кеше икәнлеген чамаларга

мөмкин иде. Миргаязның язмаларында хыял җитмәс метафоралар, эпитетлар, чагыштырулар, сискәндерерлек кыю фикерләр энҗе бөртекләредәй сибелеп ята. Кызганычка каршы, аларның берсен дә матбугатка тәкъдим итәрлек түгел, чөнки аларны шигырь итеп язарга кирәк иде.

Икенче очрашуда шуларның һәммәсен дә ул Миргаязга сөйләп күрсәтте, шигырьнең нәрсә икәнен аңлатырга тырышты. Ул Ирекка үпкәләмәде, әйткәннәрен кабул итте, "Миннән шагыйрь чыкмас, тик мин язуымнан туктый да алмыйм", диде. Бәкер белән Миргаяз ике-өч көн саен аның янына килә торган булып киттеләр. Дусларының килүен Ирек бәйрәм көткән кебек көтте. Алар әледән-әле бәхәсләшеп, үртәшеп алалар. Бәкер махмырдан калтыраның керсә, Миргаяз аны үртәргә керешә:

—Алла бабаң бирмәдемени?

—Алла бабайга тел тигермә!—ди нечкә тавыш белән Бәкер, үзенең очкындай күзләре белән аңа тишәрдәй булып карап.

Миргаяз үртәвен дәвам итә:

—Алла бабаң сынау өчен яраткан, дисең бит. Нигә ул сине махмыр белән интектереп сыный?

—Аның гаебе юк,—дип аклана Бәкер.—Гаеп минем үземдә. Ахыр заманга якыныябыз. Китапта: наданлык артыр, гыйлемлек бетәр, эчүчелек белән бозыклык тормышны басар, дигән. Әби әйтә, ирләр кырылып бетеп, илле хатын-кызга бер генә ир-ат калыр, ди.

—Шуннан?

—Шуннан дөнья бетәчәк, кыямәт көне киләчәк.

Алар яшәешнең әллә нинди эчке катламнарына кереп китәләр, борчыган уртак нәрсәләрдә фикерләренең туры килүен күреп, җаннарына тынычлык табалар.

Менә бүгенге бәхәстә Миргаяз озын кулларын җил тегермәне канатлары кебек болгап, болай диде:

—Бездә беркайчан да генийлар, бөек фикер ияләре була алмый. Сез барыгыз да иелеп беткәнсез. Сыртыгызда йөгереп йөриләр. Сез бит яшәмисез, йоклыйсыз. Юри генә урамга чыгып кара син: берәр тавыш ишетерсеңме? Су астындагы кебек тып-тын. Әллә мин юкка гармун кычкыртаммы?—Ул йөзен Ирекка борды.—Минем белән килешәсеңме, Ирек Сабитов?

Ирек бераз сүзсез торды. Аларның үзенә җавап көтеп төбәлгән күзләренә карап-карап алды.

—Әйе, тыштан караганда, тормыш тыныч кына ага кебек,—диде ул.—Ләкин ул астан да, өстән дә әйләнә-тирәсеннән бигырдап кайнап тора, кешеләрне үз эченә рәхимсез суыра. Үткән заманнарның көточыкч афәтләре хәзер юк. Әмма алар кешеләрнең йөрәгенә, эчке дөньясына күчте. Аны мең төрле гаделсезлек борчый, әмма адәм баласы алар белән көрәшә алмый.

Шуны гына көткәндәй, Бәкер элеп алды:

—Во! Күрдеңме? Менә бит хикмәт нәрсәдә!

—Нишләп соң ул көрәшә алмый?—дип күпты Миргаяз.—Моңа кеше үзе гаепле. Ул яшәргә тырышучы ит кисәге генә. Ул бик бәләкәйләнде, гәүдәсе белән түгел, рухы белән бәләкәйләнде. Ник дисәң, бәхәсләшергә дә, фикер күтәрелеп оча алмый. Әгәр минем күлымда булса, мин бөтен җир шарына: "Башкаларга игелек кыл!" дигән өндәмә ташлар идем. Ә хәзер бөтен кешелек бер көймәгә тезелгән, һәр төркем, көймәнең бер тактасын кубарып алып, шуңа утырып йөзмәкче. Шулай эшләгәндә, исән калам, дип уйлыйлар.

Очы-кырые булмаган бу бәхәс бик соң төгәлләнде.

13

Вакыт дигәнең ничек тиз чаба: Ирекнең бу йортка күчкәненә дә елдан артык вакыт узды. Ул моннан өч көн элек кичен, күтәнәчләр алып, Айгөл

янына барды. Кассадан алган акчасыннан бераз Сөембикәгә дә өлеш чыгарды. Аларның яшәвеннән күпмедер көнләшеп кайтты, кызы белән уйнады, көндәлекләрен, дәфтәрләрен карады, бергә утырып ашадылар. Ләкин йөрәкнең яңуы басылмады. Культура бүлеге мөдире булып алгач, Сөембикә институтта укуын башлаган, курс эше эшләп утыра иде. Аның тормышта нык басып һаман югарыга атлавына Ирек куана алмады. Төнлә төшләреңә кереп, аның белән саташулар, аны юксынулар инде үткән, алар кабатланса да, көттереп килгән яңгыр кебек, бик сирәк кенә булалар һәм тиз үзалар. Ул үзенең капкасы турына җитүгә туктап калды: кичкырын Ык суы арта башлап, яр белән тигезләшеп калган иде. Шул арада су жәелеп, ярты бакчага кадәр кергән булып чыкты. Димәк, Ыкка Идел типкән. Ирек бик озак, баскан урынныннан кыймышмыйча, күктәге йолдызларга, аларның судагы шәүләләренә хәйран калып карап торды. Апрель аеның җылытылган май кебек йомшак, хуш исле тыныч бер киче иде бу.

Аннары кинәт кызулап кайтып өенә керде. Утны яндырды да, яза башларан пьесасын өстәлгә таратып ташлап эшкә утырды. Ләкин каләме ана буйсынмады. Ирек авыр йөк тартып тауга менүче, ак күбеккә баткан ат хәлендә иде. Мәктәптә укыганда бер кышны район чаңгы ярышына әзерләнгәндә, физкультура укытучысы Хафиз абыйлары һәр көн тренировка ясагыз, дип аларны ген кисәтеп торды. Ирек ялкауланып, бер генә көн дә чаңгыга басмады. Ә ярышта адәм хурына калып кайтты. Уныбиш минут баруга, аның тыны кысылды, аяклары җәле бетте. Хәзер ул үзенең нәкъ шундый хәлдә калганлыгын аңлады. Әгәр син бүгенге мөмкинлегеңне эшкә жикмәсәң, ул мөмкинлек иртәгә кимиячәк, иртәгесен шул кимегән мөмкинлегеңне дә файдаланмасаң, ул берсекөнгә икеләтә кимиячәк. Һәр көн язган чакта аның ручкасы көгазь өстеннән дулаган ат кебек чаба иде, фикерләре бер-берсен куып узышалар, аларны язып өлгерең, житешеп булмый иде. Шул чакта Ирек үзен-үзе йөгәнләде, олы максатын һаман киләчәккә чигерә барды. Мин вак-төяк белән мавыкмаячакмын, мин язам икән, ул инде менә дигән булырга тиеш, диде. Ул, түбәсе болытларга тиеп торган таш кыяга күтәрелеп, кешеләрне яшәргә өйрәтмәкче иде. Ләкин ул кече, мөмкинлекләре барында кыяга менәргә омтылмый ясамады. Чөнки ана кыяның очы кирәк иде. Ул кыяның уртасына канәгать түгел иде. Шушының аркасында ул үзе башлаган юлның яртысына да житмичә туктап калганлыгын аңлады. Ләкин шулай булса да, торып басарга, баса алмаса, үрмәләп булса да, тырмашырга, алга барырга кирәк иде...

Ирек капканы эчке яктан терәтте, ишекнен дә келәсен элде һәм берничә минутка күзләрен йомып, уйланып утырды. "Тагын ике мәртәбә алсам, кассадагы акчам да бетә,—диде ул үз-үзенә.—Мин хәзер упкын читендә. Яза алсам да, яза алмасам да язарга кирәк."

Ул, беркая чыкмыйча, беркемне кертмичә, өч көн язып утырды. Өч көн жәфаланунын нәтиҗәсе булды: ул пьесаның ике күренешен төгәлли алды. Көчәнеп, үзен мәжбүр итеп эшләүдән булса кирәк, икенче көнне башы сулкылдап авыртырга тотынды. Ул хәлен жинеләйтергә ниятлән аракы эчте. Хәле жинеләйде, әмма гел өстән торырга кирәк иде. Ирек дипломатын эләктерепен кабат кибеткә юл тотты.

Су әле чигенмәгән, көн һаман да матур, кояш баеп, кичке шәфәкъ очсыз-кырыйсыз булып жәелгән суның өстен ал төскә манган. Ыкның арьягындагы кызыл балчыклары күренеп торган тау тезмәләре энгер-менгер пәрдәсе артында ниндидер тылсымлы серлелек белән шәйләнәләр иде. Ирек тыкрыктан чыгып олы урамга борылуга, аның артыннан ниндидер машина килеп туктады һәм кычкыртып куйды. Әйләнеп караса—руль артында Әхнәф. Ирек ишекне ачты.

—Әйдә, утыр,—диде Әхнәф.

Алар күл биреп күрештеләр.

—Ни хәлләр бар?—диде Әхнәф.—Кереп чыгарга да вакыт юк. Син үпкәләп тә ятасыңдыр инде.

—Нишләп үпкәлим? Райком секретареның вакыты юклыгын мин аңламыйммыни?

—Анысы хак,—диде Әхнәф.—Соңгы вакытта басудан кайтып кергән юк. Берүзәмә сигез хужалык. Менә хәзер капкалап алам да тагын чыгып китәм. Райкомга кергән дә юк. Ижат эшләреңә барамы соң?

—Бер пьеса белән азапланып ятам шунда...

Әхнәф, аны почмактагы кибеткә төшереп калдырганнан соң, бераз машинасының ишеген ачып барды. Аракы-махмыр исеннән тын алырлык түгел иде. Ул ни уйларга да белмәде. Икенче көнне Мәлс белән очрашкач, Әхнәф Ирекне нинди хәлдә очратуын сөйләгәч:

—Нишлибез? Әрәм була бит,—диде.

—Бердәнбер котылу чарасы—аны эшкә урнаштыру,—диде Мәлс.

***

Апрель азакларында йорт хужасы булган карчыкны паралич суккан, дигән хәбәр килде. Беркөнне Гаскәров кагылып, Ирекка бакчасына ни тели, шуны утыртырга кушты. Туганнары белән сөйләшергә сүз бирде һәм, теләсәгез, кыйммәт булмаган бәягә өйне саттырырга тырышырмын, диде.

Май башында беркөнне кич Миргазя белән Бәкер килде. Алар өчәүләп бакчаның шактый өлешен казыдылар. Бәкер тәмле итеп уха пешерде. Алар ул кичне бәйрәм иттеләр. Бик кәефле генә тәп корып утырганда, Мәлс абыйсы килеп керде. Исәнлек-саулык сорашкач, Ирекне, биш кенә минутка дип, ишек алдына алып чыгып китте.

—Ну, хәлләр ничек, энекәш?—диде Мәлс.

—Күреп торасың инде, абый...

—Болар кемнәр соң?

—Берсе типографиядә эшли, күптән. Икенчесе Урта Азия якларыннан кайткан. Икесе дә язалар. Бүген менә бакча казып кердек тә...

Мәлс, авыр сулап, бакча каршыннан әйләнеп килде. Ирекка текәлеп карап торды һәм әллә нинди кызганыч тавыш белән:

—Энекәш, тормышның соңгы чигенә төшеп житәсең бит. Чамалыйсыңмы?—диде.

—Чамалыйм, абый...

—Сина эшли башларга вакыт. Бер бик шәп урын таптым мин сиңа.

—Нинди урын?—диде Ирек зур кызыксыну белән.

—Исполкомга тәнге дежур. Ике көнгә бер барасы. Акчасы да ярыйсы гына. Яз да утыр рәхәтләнеп.

Ирек үзе дә инде күптән шундыйрак эш табарга хыялланып йөри иде.

—Мин моңа биш куллап риза, абый,—диде ул, шатлыгын яшерә алмыйча.

—Син иртәгә иртүк Гаскәровка бар. Ләкин махмыр ислөренне бетереп бар.

Ул абыйсын машинасына кадәр озата килде. Руль артына утыргач, Мәлс:

—Ә мондый әтрәгәләмнәрдән читләшергә тырыш. Елганын култыгына бөтен чүп-чар, әшәке күбек жыела. Син алардан берни дә ала алмыйсың. Әгәр дә алыйм дисәң, үкертеп эшлән йөрүче сәламәт кешеләр белән аралашырга кирәк.

Ирек икенче көнне иртән сәгать унда Гаскәров янында иде инде. Ул ике сүз белән эшнең нидән гыйбарәт икәнен аңлатты, гариза яздырып, анын почмагына "эшкә алырга", дип имзасын куйды. Дүрт көннән ул термоска кайнар чәен ясап, пешкән йомыркасын, май ягылган бер телем ипиен алып, район Советы башкарма комитеты бинасына тәнге дежурга китте.

14

УАЗик асфальт юлдан Болынкырга таба элдерә. Шәвалиев әледән-әле спидометрга күз төшерә, тизлекне туксаннан арттырмый да, киметми дә. Әле сөрелгән, әле урып саламы эскертләнгән жирләр ике яклап артка йогерә,

каракучкыл булып күтәрелеп утыручы күкуруз басулары, чөгендер кишәрлекләре күзгә чалынып кала. Быелгы җәй дә Ләбәлиев өчен менә шушы артта калган басулардай сизелмичә үтте дә китте. Иртә яздан басу юлларында чаба башлаган иде, уракны төгәлләгәнче кайтып кермәде диярлек. Аерым көннәрдә тузан киемнәргә генә түтәл, колакларга, авыз эчләренә кадәр тулып, теш араларында шытырдый башлады. Ул эшли торган районның жирләре көлсу тупраклы, коры, Болынкырыкы белән чагыштырганда, ярлырак та иде. Шулай да халык тырыш, үз эшенә бирелгән, игенен дә үстерәләр, маллардан да тиешле продукцияне алалар.

Зөфәр Шәриповичның бүген борчулы уйлар белән кайта. Әле ул Нажияне үзе янына күчерергә бик атлыгып тормый иде. Теге атнада булган бер хәл аның ботен планнарын жимерде. Чит жирдә хатын-кыз белән чуалырга, исем чыгарырга ярамаганлыгын ул яхшы аңлый иде. Шуна күрә яшеренпоспырын гына күрше районга сукмак салды. Андагы коллегасы ярдәме белән бер бик чибәр хатынга ияләште. Инде башкасы белән чуалмам, дип үзенә сүз дә бирепкуйган иде. Әмма ул иблис токымнарыннан котылып буламы соң? Алар синең бер күз карашыңны, барлык теләкләренне, күңеленнең иң нечкә, ин тирән почмагында яткан уйларыңны аңлап алалар да үзләре үк аяк астында бутала башлыйлар. Шулай итеп "Сельхозтехника" берләшмәсенең баш бухгалтеры белән дуслашып өлгерде. Ул—доньяның бер чибәре иде. Алар Зөфәрнен мең мәртәбә уйлап эшләнгән планы нигезендә, дошман тылындагы разведчиклар кебек, барлык төр конспирация чараларын кулланып кына очрашгтылар. Шул хатын үткән атнаның чәршәмбесендә кичке сигездә өенә килде дә керде.

—Нишләп өйгә килден?! Башны бетерәсең бит!—дип ачуланды аны Зөфәр.

Ә теге, очрашасым килде, ди, житмәсә, кочакламакчы була. Зөфәр аны ишек тобеннән дә уздырмыйча куып чыгарды, эзен булмасын, диде. Житмәсә, аның кергәнен дә, чыкканын да күрше хатыны күреп калган.

Зөфәр Шәриповичйортына әле яңкорма эшләтеп ята иде. Теләсә, атнаун көндә эшне төгәлли ала иде. Ләкин Нажияне алып килмәс өчен ул аны юри сүзды. Ә хәзер аны алып килүдән башка чара калмады. Абруйны пычратырга ярамый иде. Ул аны бик авырлык белән яулады. Көнне-төнне онытып чапты, кайбер көннәрне районны тулаем урап чыкты. Үзенен турыдан-туры вазыйфасына кергән идеология эше белән генә түгел, хужалык эшләренен дә эченә керде. Колхоз председательләре, совхоз директорлары, белгечләр белән бергә басуларда да, фермаларда да мәш килеп эш оештырышты. Аннары халык арасында шундый сүз таралды: имеш тә беренче секретарьны өлкә комитетына эшкә алмакчы булалар; әгәр бу дөрескә чыкса, Зөфәр Шәриповичка үзен аның урынына ин лаек кеше итеп күрсәтергә кирәк иде. Яшерен өмет булып, шушы тойгы аны көнетөне куалады. Бу яктан караганда да, Нажияне алып килергә вакыт иде.

Зөфәр Шәриповичкарангы төшкәндә генә кайтып житте. Нажия аның кайтуына шатланууын артык сиздермәде. Быел беренче малайларын институтка кертәннәр иде, ул хәзер Казанда, инде бер айлап белем ала. Икенчесе мәктәптә укый, борынына ис керә торган чагы Нажия ипташкә эниесен дә алып килде, өчәүләп яшәп яталар. Әбисе аның кайтуына бик канәгать иде. Киләсе атнада ял көнне әйберләрне төяп күченергә кирәк булачагын ишеткәч, ул тагын да шатланды.

—Күптән кирәк иде, балалар. Аерым яшәү, кайсы яклап карасаң да, әйбәт нәрсә түгел ул. Семья бик аздан гына какшап китә ул,—диде.

Ашап-эчкәннән соң, әбисе кече булмәгә керепкитте, Нажия үз булмәләренә урын жәйде. Менә алар чишенеп, урыннарына яттылар. Зөфәр ниндидер бер эчке дулкынлану белән, әллә инде ул хатынын чыннан да сагынган иде, аның күкрәкләре өстенә күлын салды. Нажия көрт чаккандай сикереп торып утырды.

—Нәрсә булды?—диде Зөфәр пышылдап.

—Зинһар кагылма,—диде Нажия әллә нинди ят тавыш белән.

—Ничек инде кагылма?

—Шулай...

Зөфәр аптырап сикереп торды һәм утны яндырды. Ул, өйгә кайтып, бусаганы атлап керү белән, өйдә ниндидер үзгәреш барын сизгән иде. Менә хәзер аңлады: ул үзгәреш өйдә булмаган, хатынында икән.

—Туктале, бу ни була соң бу?—диде Зөфәр, хатынының күзләренә төбәлеп.

—Мин сина шуны гына әйтә алам, Зөфәр: мин күчмәячәкмен.

—Күчмәячәксен?!—диде Зөфәр, кашын-күзен жимереп.—Бу ни дигән сүз?!

Нажия, утырган килеш башын кыйгайтып, иренененә бер чите белән ничектер сәер итеп елмайды. Әз генә тешләре күренеп алды, ә күзләрендә ниндидер аңлашсыз очкыннар уйнады. Нажия шул сәер елмаюлы иреннәре арасыннан дүрт кенә сүз сыгып чыгарды:

—Ә син үзең уйлап кара...

Зөфәр нишләргә дә белмәде. Ул көлеп куйгандай итте, кинәт кенә кочаклап, аны түшәккә аударды.

—Әйдә, фәлсәфә сатмыйк әле,—дип пышылдады ул аның колагына иреннәрен тигереп.

—Зөфәр, кит,—диде Нажия каты итеп.—Мин хәзер кычкырам. Әни белән малай алдында оятка калмыйк...

Нажиянең сүзләре Зөфәрнең бугазына үткен пычак белән сызган кебек итте; ул ничек сикереп торганын сизми дә калды һәм сүзсез генә хатынына төбәлде. Ниһаять, ул аның елмаюыннан теге үзгәрешнең мәгънәсен аңлады: бу мәгънә башка сыярлык түгел иде. Ләкин ул хатынның йөзендә, иреннәрендә, күз карашында, әйткән сүзләрендә ярылып ята иде. Зөфәр Нажиянең инде үзенеке түгеллеген аңлады! Ни өчен соң әле ул Зөфәргә ят кешегә әверелгән? Әле теге кайтканында гына Зөфәр бу әйберне сизмәгән иде бит. Хәер, ул бит кайту белән мендәренә ауды да иртән таң атканчы чыгып та китте. Зөфәр моннан тыш хатынының йөзеннән һәм әлеге елмаюдан тагын бер хәтәр нәрсәне аңлады: Нажия остә, ә ул—Зөфәр түбәндә иде. Бу шулай ук, кире каккысыз хакыйкать булып, Зөфәрнең йөрәгенә кереп утырды. "Мин аста, ул югарыда!—дип ярсып типте аның һәр күзәнәге.—Ә нишләп мин аста? Моны бит Нажия шулай билгели. Нәрсәдән чыгып Зөфәрне түбән төшерә ул? Ни өчен ул югарыда кала?"

—Минем күрүемчә, син ике арага кытай дивары корып куйгансың. Ә мин тегендә, син килүгә дип, өйгә янкорма төзеп ятам. Нишләп соң без икебез ике әйбер төзегәнбез?

—Мин берни дә төземәдем, Зөфәр. Ә кытай стенасына килгәндә, аны бит син монда чакта ук үз кулларың белән салдың.

—Андый стена төзегәч, нишләп соң бергә булдык?

—Анысы инде минем гаептер.—Нажия дерелдәп куйды, аның тәнендә бала йоннары кабарган иде.

Зөфәр аңа кофтасын сузды, ләкин Нажия аны алмады, чәйдәге шәлне элэктерен, инбашларына салды.

—Ике бала... Синең абруең... Эш урының сина бик кадерле иде.

—Ул урын миңа хәзер дә кадерле. Әйт, ни булды?

—Алайса әйтәм. Мин бит барысын да белеп тордым. Син, без өйләнешеп бер атна үткәч тә, үзең элек йөргән хатының янында төн юнып кайттың.

—Нажия!—дип кычкырып жибәрде Зөфәр.—Син ни сөйлисең?!

—Тәпчәгән булып кыланма. Әгәр син ачыктан-ачык сөйләшүдән куркасың икән, шушының белән төгәллибез.

—Юк, мин бит әле...

—Мин әйткәнне кире кагасыңмы?—диде Нажия, аңа тишәрдәй караш ташлап.—Кире кагарга уйлыйсыңмы?

Зөфәр: "юк" дигән мәгънәдә баш чайкады.

—Менә бусы ирләрчә. Әле гел үк төшеп калмагансың икән. Аннары инде синең сөярҗәләрең стройга тезеп демонстрациягә алып чыгарлык булды.

—Нажия, син инде бигрәк...

—Мин туктыйм.

—Ник соң син дөшмәдең? Ник вакытында кисәтмәдең?

—Кисәтсәм, туктар идеңме?—Нажия сәер генә көлеп куйды.—Мөхәммәд пәйгамбәр нәрсә дигән? Тауны күчереп була, ә кешенең характерын үзгәртеп булмый, дигән. Берни дә үзгәрмәячәк иде. Син тегендә киткәч тә ул эшеңне ташлый алмадың.

Зөфәр нәрсәдер әйтергә авызын ача башлаган иде, Нажия аңа "тукта" дигән мәгънәдә кул селтәде.

—Акланырга азапланма. Бу сүзләремнән, мең адвокат килеп, сине якларга маташса да, ми кире кайтмаячакмын. Йоклык, иртүк китәсең бар.

—Мондый хәлдә ничек йоклап булсын?—диде Зөфәр.—Рәхмәт, яхшы каршы алуың өчен.

Ул тиз генә киенде дә, ишек алдына чыгып, машинасын кабызды һәм үзе эшли торган районга китеп барды...

Икенче кисәк

I

Ирек төнге каравылда торганда, бер кичне Вафин килеп керде. Аның киемнәре элеккечә пөхтә, ап-ак күлмәгенә кара галстук таккан, чалбары яхшылап үтүкләнгән, туфлилары ялтырап тора. Ләкин күзләре битарафланганнар, чырае көл төсенә кергән, янган яралары кызарган, чәчләре ап-ак булып агарган, гәүдәсе авыру кешеneке кебек бетешкән, калтырабрак та тора иде. Алар бик озак сөйләшеп утырдылар. Ирек анын ике мәртәбә Дан ордены белән бүләкләнгәнлеген беренче мәртәбә ишетте.

—Берлинга якынлашканда, Өченче дәрәҗәсенә дә тәкъдим иткәннәр иде,—диде Вафин тыныч кына.—Каядыр югалды ахрысы. Моның хәзер бернинди әһәмияте юк инде. Хәзер бер нәрсәнең дә әһәмияте калмады...

Кайтып китәргә җыенгач, ул Иреккә бик озак карап торды. Нидер әйтергә теләгәнлеге йөзенә чыккан иде.

—Ирек туган,—дип сүз башлады ул.—Мин бер әйбер язып ятам. Бетергәч, алып килсәм, карап чыга алырсызмы икән?

—Алып килегез, Лотфулла Габдрахманович, укырбыз, фикерләшербез. Берничә көннән, Вафин зур гына конверт калдырып китте.

Ирек, конвертны ертып, эченнән шактый калын язманы алды. Беренче битенә күз төшерү белән ул барысын да аңлады: "В Центральный Комитет Коммунистической партии Советского Союза". Вафин, һәр хәрефен аерып-аерып язып, тип-тигез юлларга тезгән иде. Шулай да аның элеккеге матур язуы шактый бозылган, кулының вакыт-вакыт калтырап китүе сизелеп тора. Аның язганнарын Ирек тын да алмыйча укырга кереште:

"Коммунист өчен халык мәнфәгатьләрен кайгырту бурычы анын канына, жанына салынган булырга тиеш. Минем бу хатымны әнә шул бурычтан чыгып язылган жан авазы итеп кабул итсәгез иде.

Фикерләремә бүталчык булса, гафу итәрсез, ләкин сез мине барыбер аңларсыз, дип уйлыйм. Мин үземнең жанымны чәнечкеле тимер чыбык эчендә хис итәм. Нишләп алай, сәбәп нәрсәдә? Бәлкем бу—Сталин заманнарыннан килүче кайтаваznың чагылышыдыр? Бәлкем безгә бу ата-бабаларыбызның каны белән бирелгәндер. Безгә шулай да булсын, ә менә хәзер власть башында торучыларның жаннарына аларның ата-бабалары шуны салдымы икән? Юктыр. Димәк, Сталинны гаеплә рга ярамый. Хикмәт безнең үзебездә. Дөресрәге, кешене изүче, сындыручы системада. Дистәләрчә еллар без ялганга ышандык. Политбюрода, Үзәк Комитетта, хөкүмәттә утыручылар да юләр түгелдер. Алар да барысын да күрделәр һәм дөшмәделәр. Һәр көн телевизор, радио, матбугат үзгәртеп корулар алдында торган киртәләрне, каршылыкларны юкка чыгарырга чакыра. Генераль ный секретарь Горбачев та шуңа чакыра. Мин—коммунист,

шушыларны ишетеп, үземне жинаятьче кебек хис итәм. Мин ул киртәләрне күрәм, әмма аларны алу өчен көрәшергә кыймыйм. Ни өчен? Үз урыным өчен куркаммы? Юк. Мин инде пенсиядә. Мин бер нәрсә дә үзгәрмәячәген, әүземнен юләргә калачагымны белеп торам. Тормыш әзер схема буенча бара. Өлкә комитеты, райком аппараты сызган схема буенча. Ана карыш торырлык коч булмагач, бары тик бер генә аваз салып була: "Безнен жаннарыбызны коткарыгыз!"

Кесәсендә партбилет йөртүчеләрнен күпчелеге өлкә комитетына, райкомга күнелендә бернинди дә ихтирам да, ышаныч та сакламый. Ә күпме райком секретаре, кесәсендә партия билеты йөртен тә, халыкка каршы гамәлләр кыла. Алар шулкадәр котычыкы жинаятьнән эшлиләр ки, күптән инде урыннары иркен кабинетларда түгел, ә төрмәләрдә булырга тиеш. Моннан ничек котылырга? Шушы сорауга жавап бирмәкче булып, мин кулыма каләм алдым. Әгәр бүгенгенең астын өскә әйләндерерлек чаралар күрелмәсә (Мин партиянен эш стилен күздә тотам.), илдәге үзгәртеп коруларга бернинди ышанычым да калмаячак. Бу чараларның ин көчлесе— Дөреслек. Партия һәм ил тормышындагы барлык житешсезлекләрне күз алдына чыгарырга, яшермәскә кирәк. Дөреслекне сөйләү канун итеп куелырга тиеш. Кем дөреслекне кыса, аны жинаять жаваплылыгына кадәр тартырга. Әйтелгән дөреслек өчен эзәрлекләү түгел, ә дәртләндерә торган шартлар тудырылырга тиеш. Әйдәгез, "кеше фәлән-фәлән дөреслек әйтте", дип күрсәтә торган ниндидер символик билгеләр кабул итик. Бәлкем ул дөреслек орденыдыр? Дөреслекне әйткән өчен кеше оялмасын, ә бәлки жәмгыять алдында дан казансын.

Ялган, икейөзлеләнү шулкадәр озак еллар дәвам итте, хәзер инде халык та хакыйкатькә бөтенләй диярлек битарафланды. Безнен жәмгыятьтә дөреслек исеме астында алдау хакимлек итә. Ул югарыдан түбәнгә, түбәннән югарыга хәрәкәтләнә. Шулай яшәдек, шулай яшибез. Бүген үзгәртеп кору торган саен киң колач ала, тирәнәя, дип ышандырыргa тырышалар. Ә кайда соң ул? Ни экономикада, ни социаль сферада, ни идеологиядә өлкәсендә үзгәртеп корулар сизелми, ә туктаусыз алга барбызы, дибез. Тимер пресс һаман кысылган халдә, режим ничек булды, шулай кала бирә.

Барлык товарларның бәясе күтәрелгәндә, хакыйкать бөтенлай бәһасен югалтты. Аны беркем дә теләми, ул беркемгә кирәкми. Үзгәртеп кору башлангач, регионнар, шәһәрләр, районнар буенча араҗыта коры закон кертгеләр. Ә дөреслеккә коры закон бөтен ил буенча инде алдә кайчан кертелгән иде. Бүген жирдә дөреслек турында сөйлиләр, аны үтмәс товар кебек тәкъдим итәләр, тик анарның беркем дә файдаланмый. Чөнки файдалану отышлы түгел, хәтта аның азагы хәвефле, бәла-казалар китерүчән. Дөреслек исеме астында тарихны кабат язу башланды. Барлык үлгән юлбашчылар туйганчы типкәләнә. Элек һәр съезд һәм пленум, конференция тарихи булган, хәзер: "Алар тарихи булмаган икән", дип чан сугабыз. Элек халык дошманы итеп ингылан ителүчеләрне герой дибез. Бу күпме барыр? Минемчә, жанлы тормышны әзер схемага тутыру туктагач, дөреслеккә тулы ирек бирелгәч, ил башына яңа житәкче килгән саен тарихны кабат язуга чик куелачак.

Сугышта фашистның муенын сындырып кайткан батыр коммунистлар бүген башларын иделәр. Чөнки беренче секретарь, томана булса да, аларнын барысыннан да көчлерәк. Чөнки аның урыны үз эшен эшли. Партия житәкчеләреи халык ашый торган гомуми табынга ничек утыртырга? Моны берничә партия яшәгәндә, алар арасында фикер көрәше жәелгәндә генә эшләп була. Жәмгыятьтә аяусыз тәнкыйтьгә барырга тиеш.

Гажәеп феномен туды: хәзер халык бернигә дә ышанмый, чөнки һәр жирдә ялган. Хәтта дәүләт отчетлары да дөреслектән ерак тора. Партиянен кулында коточкыч абсолют власть. Аның өчен бернинди закон да юк. Ул теләсә кемне, теләсә кайчан эшеннән ала, КГБ, милиция, прокуратура органнары аша жинаять жаваплылыгына тарта. Халык өстендә ул кылыч кебек асылынып тора. Партиянен болай булуы киләчәктә коточкыч

нәтижәләргә китерәчәк, чөнки аның башында гадел, әхлаклы кешеләр бетеп бара. Шушы эш стиле дәвам иткәндә, партия житәкчелеге әхлак ягыннан бозык, шәхси мәнфәгатьләре күзләрен томалаган, байлыкка омтылучы пигмейлар кулына калачак. Бүген исә партия билеты һәм устав белән богаланган коллар моңа каршы берни дә куя алмый. Әлеге пигмейлар халыкны акыртып талаячак. Безнең ил өчен беркайчан да күрелмәгән оятсызлар дәвере, кешелексезлек дәвере киләчәк.

Мин институт аудиторияләреннән унтугыз яшемдә үз теләгем белән немец фашистларына каршы сугышка киттем. Танк эченда янып, тылга озатырга теләгәч тә, мин фронтта калдым. Немецларның жиде танкын яндырдым, әллә ничә мәртәбә кул сугышларында катнаштым, снайпер булып, өч дистәдән артык фашистны теге дөньяга аткардым. Европаны кичеп, Берлинга барып життем.

Сугыштан кайткач, көнне төнгә ялгап, илне торгызыйм, кешеләр сугыш яраларын онытсыннар, әйбәтрәк яшәсеннәр, дип дәртләнеп эшләдем. Минем күз алдымда законга буйсынмаучы катлау барлыкка килә башлавын күргәч, халык контроле комитетына куюларын сорап, үзем гариза яздым. Ул чакта мин әлеге начар тенденцияне туктата алырмын, дип ихлас күңелдән ышана идем. Без, бу хәлләр вакытлы күренештер, житәкчеләр үзгәргәч, тормышлар да үзгәрер, законны таптап йөрүчеләр бетәр, дигән өмет белән яшәдек. Без ялгышкан булып чыктык. Берни дә үзгәрмәде. Киресенчә, әлеге тискәре күренешләр яшәешне торган саен кинрәк колачлый барды. Партия житәкчелегенең һәр баскычы карьеристлар оясына әверелде. Күз яшьләрем белән кисәтәм: партия тормышындагы бу аяныч күренешләргә ашыгыч рәвештә чик куелмаса, ил, халык өчен коточкыч куркыныч көннәр көтелә. Безнең һәм безгә кадәрге буыннарның ялаган казанышлары чәлпәрәмә киләчәк. Чаң сугыгыз һәм үзгәртегез! Моны бары тик сез генә эшли аласыз. Әгәр эшләмәсәгез, тарих сезне мәңге гафу итмәс.

Коммунистлар партиясенә мәңге тугрылыклы Л. Г. Вафин."

Икенче көнне эштән кайтышлый үк Ирек хатны Вафинга кертен бирде һәм, ике данәдә машинкада бастырып, берсен Үзәк Комитетка, икенчесен "Правда" газетасына юлларга кушты.

2

Арслановның йокысы йоклы булмады. Ул, төне буе туктаусыз бастырылып, әллә нинди куркыныч төшләр күреп чыкты. Казанга киңәшмәгә чакырсалар, сатаулы төн үткәрү аның өчен инде гадәткә әверелде. Чөнки ул киңәшмә дигән әйбернең синең өчен нәрсә әзерләп куйганын бер Ходай гына белә. Юка боз катлавына кереп, аның сытылганын сизеп, чытырдаганын ишетеп алга таба атлаганда нәрсәләр кичерсән, киңәшмәгә барганда да шундый ук тойгылар сине куркыныч билгесезлеккә сөйри. Аяк астыңдагы бозына бер типсәләр, су төбенә китәсең дә барасың. Сине тартып чыгармыйлар, ә баш түбәңә басып торалар.

Ул бишенче яртыда ук райкомда иде инде. Дәүләткә ашлык тапшыруның барышына, әле кызыл, әле кара карандаш белән сыза-сыза, анализ ясарга тырышты. Терлекчелек күрсәткечләрен дә һәр тармак буенча карап чыгарга, башка сендерергә, кайберләрен язып алырга кирәк иде. Кабул итү бүлмәсендә дежур торучы инструктор кереп, аның күшуы буенча чакыртылган алты кешенең көтеп торуын әйтте.

—Ярты сәгать үтмичә, беркемне дә кертмәгез,—дип чыгарды ул инструкторны.

Районнын саннары куанырлык түгел иде. Арсланов кәгазьләрен тирләп-пешеп актарды, телефоннары да, үч иткән кебек, туктаусыз зырылдады. Менә ишек артында ниндидер кычкырышкан тавышлар ишетелде. Арсланов аптырап башын кәгазьләрдән күтәрде. Ишекнең тышкы каты дөпе-дөпе килде. Инструкторның: "Кермисез, кермисез!"—дигән тавышы ишетелде. Ул арада эчке ишек тә киерелеп ачылып китте һәм тупсада терәлеп торган

күршеләре Гандәлифә Чукаева пәйда булды. Аны күргәч, беренченеп йөрәге табаның төшеп китте. Чукаева башына кышын да, җәен дә салмый торган түгәрәк каракүл бүреген кигән, ап-ак чәчләре шул бүреге астыннан күркыныч булып тырпаешканнар, күмердәй янучы кара күзләренең зур булып ачылуы аның коточкыч дулкынлануы турында сөйли иде. Бүрәнәдәй төз аяклариына шулай ук кышын да, җәен дә салмый торган хром итекләрен кигән, өстендә озын сарган плащ, култык астында ниндидер катыргы тартма. Ул, ун кулындагы юан таягы белән идәнне дөпелдәтеп, Арсланов каршына килде дә зарланырга кереште:

—Бу нинди бюрократия бу, ипттәш Арсланов?! Инструкторыгыз: "Нинди мәсьәлә белән керәсез, шәхси мәсьәләме, эш мәсьәләсеме?"—дип чат ябышты, житмәсә мине—халык контроленең штаттан тыш инспекторын, гомер буе авыллярда вәкил булып йөргән кешене кертмәскә маташа.

—Кертмәскә күшкан идем шул,—дип борын астыннан гына мыгырданды Арсланов.

Ул арада Чукаева тирләгән битен жине белән сөртеп алды да ике сәдәфкә эләккән плащын ычкындырып жибәрде. Ул әллә марлядан, әллә үтә күренмәле материядән тегелгән эчке күлмәктән иде. Арсланов, аңа карамаска тырышып, башын читкә борды һәм:

—Ипттәш Чукаева... үзегезне көзгедән карагыз әле...

Чукаева, ул борылган якка килеп, таягын Арслановның борын төбендә селкеде:

—Көлмәгез миннән!—дип жикеренде ул.—Кояшың житмешкә борылгач, көзгегә карасаң да-карамасаң да юк инде ул. Үзегез тирәсендә бөтереләчүе сыйлы хатыннарыгыз карасын ул көзгегә!

Чукаева таягын идәнгә ташлады да, катырғы тартманы ачып, Арсланов алдындагы кәгазьләр өстенә биш-алты мәче баласы китереп аударды. Ак йоннары арасына күе-кызгылт сары тамга төшкән, яшел күзле мәче балалары, кәгазьләр өстендә очлы койрыкларын тырпайтып, мияулый-мияулый йогерешә дә башладылар. "Мин акылдан шашам, төнлә күргән күркыныч төшләремнең дәвамы хәзер күз алдымда галлюцинация булып гәүдәләнә ахрысы", дип уйлады Арсланов күркынып.

—Сез ниишлисез, ипттәш Чукаева?! Бу нәрсә?!—дип кычкырды ул, ике күлын мәче балалары өстендә аркылы-торкылы уйнатып.

—Минем түзәрлегем калмады,—диде Чукаева, аңа йбырылып.—Елына ничә мәртәбә мәче баласы тараттан. Сезнең мәче балалары алар.

—Сез ни сөйлисез?!—Арсланов сулышы кысылып туктап торды.—Безнең мәчебез ата.

—Ата шул. Нәкъ үзегезгә охшаган. Өй алды ярыгыннан төшә дә минем мәчене аздырып алып чыгып китә. Күрәсезме, сезнең әдрәс мәчегезнең жирән тамгалары, берничә тә кире кага алмыйсыз.

Арсланов, кулы белән тиз-тиз эләктергәләп, мәче балаларын тартмага салып, өстәленнән читкә этте. Берсе кәгазьләрен юешләп тә өлгергән иде инде.

—Юк, алай гына котыла алмассыз,—дип ажгырды Чукаева.

Ул, тартмасын аударып, мәче балаларын идәнгә жибәрде. Аннары дәшләтле карап, Арслановның каршына үк килде:

—Утыр, ипттәш Арсланов!

Колак яргыч тавыштан ул кәнәфиенә чумды.

—Мин күпме газап чигәргә тиеш, бу хәл күпме дәвам итәр?!

—Соң аны ниҗләтик соң инде?

—Печтерегез! Йә бәйдә тотыгыз!

"Үзеннең мәченә спираль куйдыр",—дип кычкырасы килде Арслановның. Бер мәче баласы, анын чалбар балагы белән трико арасына кереп, төненә тырнакларын батыра-батыра, югары үрмәли башлады.

—Мин сезнең өстән обкомга жалоба язам. Сезнең әдрәс азгыныгыздан башлыйм. Минем ак песиемне мораль яктан тарктатын күрсәтәм, аннары сезнең үзегезгә күчәм. Алимент түләп тә котыла алмассыз!

Арслановның башы шаулый башлады. Әгәр Чукаеваның аның өстеннән язган шикаятьләрен бергә тупласаң, зур бер папка булыр иде. Арслановлар күчеп килгән елны ук, ул "әтәчемне тозлы ит ашатып үтерделәр", дип бөтен тирә-юньне сасытты. Чыннан да аның күркә кадәр кызыл әтәче, койма өстеннән очып кереп, су түгә торган урынга ташланган тозлы ит ашап, Арслановлар ишек алдында үлгән иде. Хәят белән алар Чукаевага өч әтәч биреп тә котыла алмадылар. Чукаева гомер буе орлыкчылык инспекциясендә эшләде. Анарда районның барлык информациясе дә тупланган, ул аны теләсә кайда сөйләп, халыкка житкереп бара иде. Ул беркемнән дә күрку дигән нәрсәне белми, кибетләрдә, ашханәләрдә, балалар бакчаларында, мәктәпләрдә туктаусыз нотык тота, дәһи Ленин күрсәтмәләрен Арслановлар аяк астына салып таптадылар, дип сөйләп йөри; кечкенә генә кимчелегенне дә олы итеп күпертә, синнән халык дошманы ясый, ялгышып бер сүз катсаң, бәгырене чүкый башлый. Кайчаклада Арсланов, хатыны йә кызы белән ял көнне машинада берәр жирдән кайтып туктаса, ул, аның каршына чыгып, тагын бармак яный: "Дәүләт бензины белән чабасыз! Районда ничә начальник—барыгыз да шулай. Ничек оят түгел?"—дип сукыр чебен кебек күзенә керә. Районда, әлбәттә, жалоба язучылар ул гына түгел, алар күзенә күренмәскә, синнән качарга тырышалар, ә бу, үтмәс балта белән юнып ясалган гәүдәсен, таяк тыккан төсле туптуры жилкәләрен сикертә-сикертә, юан таягын шыкылдата-шыкылдата, синең каршыңа дәһшәтле атлап килә. Ул урамнан да кешечә генә йөрми: үртадан киерелеп бара, ике аягын юлның ике читенә аерып басып атлый. Машинаң белән килсәң, ни бер ягыннан, ни икенче ягыннан үтеп тә китә алмыйсың, туктап көтәргә туры килә. Башка жалоба язучылар синнән качарга тырышса, ул ин элек "Жалоба язам", дип әллә ничә мәртәбә сине үрти, шомландыра, бәгыреңә төшә. Аннары жалобаны яздым, жибәрдем, дип жаһынны ашый. Әгәр дә тикшерү килсә, тантана итеп, "Эйттемме мин сиңа! Менә хәзер шәһәреңне бөрәлсен синең!" дип тагын йөрәгеңне чукый. Кайда халык бар, шунда "Мин жалоба яздым", дип мактана, тикшерергә килделәр, дип горурлана. Берәр чара күрелсә, "Шәһәрләрен бөрдемме!" дип тантана итә. Аның белән күрше булып тору Арсланов өчен үзе зур фажига иде. Бер елны ул Батталовка "Суыткыч бушабрак китте бит әле", дип шылтыратканда иде. Мондый очракларда икенче көнне үк колхоздан ит китерәләр, ләкин бусында андый нәрсә булмады. Бер дүрт-биш көннән соң Батталов белән очрашкач, Арсланов ана үпкә сүзе белдерде:

—Син ни сөйлисең, Минзаһит Усманович?—диде Батталов гажәпләнеп.— Икенче көнне үк склад мөдире ин зур сарык түшкәсен полиэтиленга төреп сезгә жибәрүе турында хәбәр итте.

Мәсьәләне ачыклый башлагач, шофер егетнең, адресны бутап, түшкәне Чукаеваның болдырына куеп китүе мәгълүм булды. Ит турында әйтү түгел, алай-болай Чукаева сүз кузгатса, ни дип аклану турында баш ватты Арсланов. Берәр айлап үткәч, район газетасында бер кечкенә генә мәкалә чыкты. Анда картлар йортында тәрбияләнүче бер әби Чукаеваның аларга утыз килограммлы сарык түшкәсе алып килеп тапшыруы, хәер өләүче турында язган, ана барлык тәрбияләнүчеләр исеменнән рәхмәт әйткән иде...

Мәче баласы, үрмәли торгач, анын тезеннән югарыга үк менеп житте. Арсланов торып аягын селкетте, кулы белән мәче баласын сыпырып төшерергә теләп, чалбар балагы аша аска шудырырга маташты. Әмма ул тырнакларын тәненә батыруга, кулын корт чакчандай кире алды. Чукаева ана һаман ниндидер сүзләр белән яный иде. Арсланов аны гомере буе аңлый алмады. Жәй көне ул чикләвек жыеп, стаканлап сатып утыра. Урамда ыргытылган бер генә буш шешәне дә калдырмый, аны, күрәсезме, дигәндәй кулына тотып кайта. Үзе кычкырып эчкечеләрне сүгә: "Бай хәерчеләр, шешәләрсн атып бәрәләр, имеш. Әле ачка интегәсе көннәрегез алда!— Кемнәрдер очраса, ул аларга сөйли, әгәр кеше юк икән, берүзе авызыннан уг чәчеп бара.—Ул жир шары төмам тилерде. Туп типкән өчен миллиардлар түгеләр, үзышып машина ваткан өчен миллиардлар, бер-берен бияләй киеп

кыйнаган өчен миллиардлар сарыф ителә. Ә күпме халык ачтан кырыла. Моннан да зуррак ахмаклыкның булуы мөмкин түгел.” Чукаева ишек алдында, бакчасында йөз төрле чәчәк үстерә, алар арасында кар яуганчы уттай янып утыручылары бар. Ул аларны иркәли, аларга табына, битләренә тигерә. Ә кешеләргә “үлгәннәрнең жаны чәчәкләрдә”, ди. Чукаева барлык акчасын картлар йортына, ятим балаларга, гарипләргә бирә, дилләр. Ул әле бүген дә урта мәктәптә звонок бирүче булып эшли. Аны күргәч, балалар аяк очларына гына басып йөриләр. Кырыс, беркемгә дә ташлама ясамаучы, усал Чукаева аларны надзиратель кебек тәртиптә тота, мәктәп директорының шаярып әйтүенчә, Чукаева булганда, ана тәрбия завучы кирәк тә түгел.

Арсланов ирексездән ынгырашып куйды: мәче баласы бот төбенә үк күтәрелеп, ин авырта торган жиренә тырнагын батыргач, аның түземе калмады:

—Бер генә минутка, ипташ Чукаева,—диде дә үзенең түр яктагы ял итү бүлмәсенә кабаланып атлады. Бүлмәгә керү белән, чалбар каешларын-изүләрен ычкындырып, мәче баласын элә-төртүгә, артында шартлап ишек ачылып китте. Ул бур кеше сыман башын артка борды һәм, ярым чүгәләп, таягын ана таба төзәгән Чукаеваны күрде.

—Мал иясен таныган!—дип хихылдады Чукаева.

Арсланов бер кулына чалбарын, икенче кулына мәче баласын тоткан килеш тораташ катты.

—Йбагысы ишекне!—дип кычкырды ул кызарынып-бүртенеп.

Чукаева көлүен дәвам итте, Арсланов мәчене ана таба ыргытты да ишекне япты, әмма борыс белән ишек арасында Чукаеваның таягы кысылып калды.

—Ха-ха-ха! Халык күзеннән бернине дә яшерә алмыйсын!—Чукаева таягын тартып алып ишекне япты.

Арсланов, кыйнап кыерсытылган бала кебек мышкылдый-мышкылдый, кабаланып чалбар изүен, каешын элә-төрде һәм бүлмәсенә чыкты. Чукаева киткән, бөтен жирдә мәче балалары йөри, ишек төбендә дежур инструктор басып тора иде.

—Тизрәк тартмага тутырыгыз боларны! Минем шоферга гаражга чыгарыгыз. Теләсә нишләтсен,—диде ул, күлларын чатый-ботый бутап, үзе кабаланып тагын ял бүлмәсенә керде, суыткычтан алып, бер стакан шифалы су эчте һәм ни уйларга, ни кылырга белмичә аптырап торды.

Бераз хәл алганнан соң, ул бүлмәсенә чыкты, селекторга басып, инструкторга:

—Сабитов керсен,—диде.

Мәлс салмак адымнар белән бүлмәгә керде, алар күл биреп күрешеләр.

—Утыр, Сабитов,—диде Арсланов.

Мәлс стена буендагы урындыкка барып утырды.

—Юк, син анда утырма әле, менә минем каршыдагы урындыкка күч.

Мәлс, эченнән гаҗәпләнсә дә, тыштан берни дә сиздермичә, аның каршысына утырды. Арсланов, күзләрен дә йоммыйча, туп-туры аның йөзенә текәлде. Беренченең чыраеннан берни дә укырлык түгел иде. Аның хәрәкәтсез күзләре каршында болай утыру Мәлсны туйдырды. Ул түземсезләнеп урындыгын шудырып куйды һәм тамак кырды.

—Ник чакырганны беләсенме, Сабитов?

—Юк.

—Минем менә шушылай озак итеп синең күзләреңә карыйсым килде.

—Нәрсә күрдегез соң?—диде Мәлс, көчәнеп елмаерга тырышып.

—Берни дә күрмәдем. Син тәмам әйбәт кеше маскасы киярга өйрәнеп беткәнсең.

Мәлснын йөзе житдиләнеп китте.

—Маскадан талаучылар, бандитлар, шамакайлар гына йөри.

—Кара нинди нечкә икәнсең син!—дип куйды Арсланов.—Әйдә, алайса конкрет сөйләшик. Син рабочком председателенә дип салынган йортның элеккесенә бер механизаторны керттең, мина биргән вагъдәнне бозды.

—Анда минем гаебем юк,—диде Мәлс.—Нәбиуллин үзе үк сезгә

аңлатырга тиеш иде.

Арсланов шапылдатып учы белән өстәлгә сукты:

—Кисәтеп куям: мин мондый әйберләрне кичермим. Күп нәрсәләрне гафу итеп була: эчүчелекне, караклыкны, ялкаулыкны, сина хас кирелекне, әмма ялганны мин кичерә алмыйм. Ни өчен икәнен әйтимме?—Арсланов, сүзеннән туктап, аңа карап торды, ләкин Мәлс авыз ачып берни дә дәшмәде.—Минем үземнең алдаганым юк.

Арсланов аның йөзендә ниндидер кинаяле елмаю билгеләре чамалады.

—Син минем сүзләр белән килешмисең ахрысы?

—Мин берни дә әйтмәдем шикелле...

Арсланов урыныннан торып кулларын чалбар кесәсенә тыкты.

—Мин тагын менә нәрсә хакында уйлыйм,—диде ул карашын аска төбәгән хәлдә, гәүдә авырлыгын әле аяк башына, әле үкчәсенә күчерә-күчерә селкенгәләп.—Син үч аласың ахрысы.

Бу сүзләрне ишетүгә, Мәлс та урыннынан сикереп торды.

—Хөрмәтле Миңзаһит Усманович!—диде ул рәнҗүле тавыш белән.—Беренче секретарь булсагыз да, хыялыгызда тудырган нәрбер нәрсәне кешегә беркетеп куярга ярамыйдыр.

—Ну-ну-ну!—диде Арсланов күкрәген киереп.—Мондый гына кыланулары мин күп күргән. Әгәр үч булса, бусы инде ялганнан да яманрак. Сина китәргә мөмкин.

Мәлс кызулап чыгып китте. Арсланов сәгатенә күз төшерде һәм китапка язмый торган сүзләр белән авыз эченнән генә карганып алды. Юлга чыгарга вакыт житкән, ул инде кабат беркемне дә кабул итә алмый иде.

***

Мәлс та, машинага утыргач, нәкъ Арсланов кебек үк карганып алды. Аның баш миендә һаман бер сүз бөтерелде: үч, үч, үч! Арсланов бу үе белән нык ялгыша иде. Әгәр Ирек өчен анардан үч алырга ниятләгән булса, Мәлс бик күп нәрсәләр таба алыр иде. Бәлки үч алырга да кирәктер. Ләкин анарда андый теләк хәтта Иректе партиядән чыгарган чорда да тумады. Нәбиуллинга квартира бирмәүдә Мәлснең тырышлыгы зур булды, чөнки бу кеше аны алырга лаек түгел иде. Эшли баштавыныңберенче көненнән үк ул үзен бик һавалы тотты. Ниндидер житди эшкә килгәндә, аның буш куык икәнлеге күренде. Моңа җитәкчеләр генә түгел, халык та бик тиз төшенде. Шуның өстенә Нәбиуллин берничә семьяны чак кына таркатмыйча калды. Аның эшчеләр комитеты председателе итеп кем аркасында куелуы да һәркемгә мәгълүм иде. Җитәкчеләр шул сәбәп аркасында аның белән бик кыен хәлдә калганда да конфликтка кермәскә тырыштылар, әгәр халык эчтән көлеп, тыштан дәшмәде, аның сүзенә буйсынган булып кыланды. Эшчеләр комитеты рәисе булып йөргән бу кешенең тагын бер хәтәр ягы бар иде: ул бөтен нәрсәне Арслановка көнесәгате белән житкереп тора. Колхоз-совхоз житәкчеләре белән бер утырганда, аның хакында Мәлс шаярып: "Ул безнең беренче номерлы шпион", дип ычкындырган иде. Бу кушамат Нәбиуллинга ябышты да куйды. "Үрнәк" рәисе Өлфәт Жәмиловка шул ук Мәлс тарафыннан бүләк ителгән "икенче номерлы шпион" дигән кушамат белән канәгатьләнергә туры килде.

Кайсы яклап уйласаң да, Нәбиуллинны яна өйгә кертеп булмый иде. Арслановның әледән-әле аңа квартира бирүне исенә төшерепторуына Мәлс тыштан "ярар, шулай эшлибез", дисә дә, эченнән ничек итеп халык алдында бу хурлыкны адымны ясамау турында баш тарты. Беренче йортны алдынгы механизатор, атказанган колхозчы Кадыйровка бирү артык катлаулы булмады. Ә инде әле генә төзелеп беткәне белән шактый шөгыльләнергә туры килде. Мәлс директорлар, профсоюз комитетындагы һәр кеше белән кат-кат әллә ничә мәртәбә сөйләште. Арслановтан курку аларны иркесез рәвештә Нәбиуллин файдасына сөйләргә мәҗбүрли иде. Эшчеләр комитеты белән директорлар берләштерелгән утырышында әлеге йортны кемгә бирү

мәсьәләсе сәгать ярым тикшерелде. Анда Мәлс үзе генә дә сигез мәртәбә чыгыш ясады. Кемнәрдер битараф калып котылырга теләде. Утырыш көнне биш-алты кеше чиргә сабышты. Аларын жилтерәтеп өйләреннән алып килделәр. Ахырда күпчелек тавыш белән йорт сыер савучы Габидуллина Нәзирәгә бирелде. Мәлс шул көнне тәнге уникедә, урамда аяк тавышлары басылгач, кача-поса Габидуллиналарга китте, тәрәзә чиертен, аларны йокысыннан уятып керде.

—Бернигә карамыйча, таң аткач ук яна йорткa күчәсез. Тавыш-гауга зурга китәргә мөмкин,—диде ул аларны кисәтеп.—Мона бәйле кешеләр берни алдында да чигенүне белмиләр.

—Безгә бер-бер хәл булмасмы соң?—дип калтыранып тора бирде Нәзирә.

—Берни дә булмаячак. Йорт законлы рәвештә сезгә тиеш. Икегез дә гомер буе совхозда сәламәтлегегезне югалттыгыз. Мин сезгә орден да, медаль дә вәгъдә итә алмыйм. Эшләгән эшегезгә бөтен рәхмәтем шушы булыр.

Ул тагын, күләгә урыннардан иелә-бөгелә аяк очларына тына басып, өенә кайтып китте. Икенче көнне Габидуллиннар яна өйгә күчкәннәр иде инде.

3

Кайтасы машиналар кайтып бетеп, башкарма комитет бинасында беркем дә калмады. Ирек ике сәгатьләп язып утырды. Инде эшләп булмаячак иде. Ул телефоннан район кулланучылар жәмгыяте рәисе Ивановның өенә шылтыратты:

—Николай Кузьмич, мин дипломны язып бетергән идем.

—Уже...—дип гажәпләнде Иванов.—Кайда соң ул?

—Мин дежурда. Әгәр алып китәм дисәгез, мин аны алып килдем.

—Әлбәттә, әлбәттә! Ун минуттан мин сезнең янығызда булам.

Ирек өстәлләрне җыештырып куйды, өч айга якын дежурга килгән саен эшләп төгәлләгән дипломны кулына алып, актарып-актарып карады. Аның читтән торып укучыларга контроль эшләр язарга булышкаларга, гаризалар, югары оешмаларга хатлар язып биргәне күп булды, әмма бу диплом беренчесе иде. Баштарак бик күпләр, Арслановка ачулыдыр дип, ана беренче өстеннән жалоба язарга кодалап, яисә язган жалобаларын төзәтеп бирүне сорап килүчеләр күп булды. Ирек аларның берсен дә кабул итмәде, мондый нәрсәгә аның кулы бармый, күңеле тартмый иде. Моннан өч ай элек дежурда чакта ана Иванов шылтыратты:

—Кызым университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый иде. Быел дипломын яклый алмады. Шуны бераз төзәткәләп бирә алмас идегезме икән?—диде ялварулы тавыш белән.

—Әгәр кулымнан килсә, ярдәм итәрмен,—диде Ирек.

Диплом эшен укыгач, Ирек аны янабаштан язарга туры килчәген аңлады. Теманы ачарга тиешле фактик материал артыгы белән тупланган, әмма ул тиешенчә анализлап, эзлекле концепциягә салынмаган иде. Берничә көн уйланып йөргәч, ул эшкә тотынды.

Иванов буш күл белән килмәячәк. Ирек үз-үзенә нәфрәтләнә, әмма берни дә кыла алмый. Кешеләрдән акча кабул итмәгәч, ана килүчеләр барысы да яртыкалдырып кителәр. Тормыш тәгәрмәче туктаусыз әйләнде. Ирек үзе исә аракыга эшли торган машина моторы кебек бер җырлап, бер сүнәм, бер үләм, дип эшли бирде. Ивановның килеп керүе аның бу уйларын шунда ук юкка чыгарды. Ул диплом эшен кат-кат актарды, "Шушы кадәр әйберне ничек язып була?"—дип тел шартлатты. Аннары өстәлгә колбаса, кыяр, помидор, ипи чыгарып куйды, затлы коньяк утыртты. Ике рюмка алырга да онытмаган иде. Иванов рюмкаларга коньяк салды һәм:

—Мин сезнең бу ярдәмегезне мәңге онытмам, Ирек Хәйриевич,—диде. Бераз сөйләшеп утыргач, Иванов кайтырга кузгалды һәм өстәлгә конверт куйды.

—Аз дип үпкәләмәгез... Рәхмәт йөзеннән генә...

Ирек ни конвертка үрелергә белмәде, ни сүз әйтә алмады. Иванов киткәч, конверттан өч йөз сум акча алды. Беркемнән бер тиен акча алмаган Ирек өчен бу коточкыч хәл иде. Ул ни шатланырга, ни кайгырырга белмәде. Бу—кемнәндер кәсәсенә кереп урлаган әйбер кебегрәк иде.

Сәгать иртәнге өчләрдә, башын өстәлгә салып өз генә ял итим, дигән иде—ничек йоклап киткәнен дә сизмәгән, хәтта ишеген дә бикләмәгән булып чыкты. Кемдер төрткәләүгә, ул авырлык белән күзләрен ачты һәм, каршысында басып торган Гаскәровны күргәч, чайкалып аягүрә басты. Ярый әле өстәлен җыештырып куйган, шешәсен дипломатына салган иде.

—Исәнмесез, Сәет Мөбәрәкович!—диде ул, телен көч-хәл белән әйләндереп.

Сәгать әле дүрт тулып кына киткән, райбашкарма рәисенең бу вакытта килүе сәеррәк иде.

—Исәнлеккә мин исән,—диде Гаскәров.—Тик менә сез генә...

—Гафу итегез, шулай килеп чыкты...

—Шулай килеп чыкмады, Ирек Хәйриевич. Кызганычка каршы, шулай бара. Дәшмәгәч тә, мин бит сукыр түгел. Сигналлар да килеп тора. Сез нинди упкынга юл алганыгызны белөсезме? Агуланган тәнне җан ташлап китә. Әгәр минем сүзләремә ышанмасагыз, тирә-юнегезгә күз салыгыз. Аракы аркасында ирләр чалгы белән чапкандай кырыла.

Ул, икенче катка күтәрелә торган баскычка җиткәч, артына борылып:

—Бүген мин сезне күрмәдем,—диде.—Зинһар тизрәк кайтып китегез...

Инде ул ничә мәртәбә "ялдан бер дә капмыйм", дип ант бирде. Әмма аракы күрү белән, "бүген генә, әз генә", дигән үй аның антын юкка чыгарды. "Мондый хәл күпме дәвам итәргә мөмкин сон?—дип уйлады ул.—Әгәр аракы эчүдән чирләгән вакытларны хисаплый башласаң, ул ничә үлемнән калды икән?" Тәннең һәр сөягенә кадәр калтырап, аяк-куллар өеп, йөрәк менә туктыйм-менә туктыйм дип типкәндә, якты дөнья сурәтен югалтып күз алдында калтырап торганда, әҗәлнең тизрәк килүен теләгән чаклары да аз булмады аның.

Ирек өстәлгә иелгән башын куллары белән кысып тоткан хәлдә шул хәсрәтле уйларын уйлады. Күпме уйласаң да, нәтиҗә бер: котылырга кирәк иде. Йә син аракыдан, йә тормыш синнән котыла. Арада берни дә юк, икесеңнең берсен сайларга кала. "Бетте!"—дигән кискен нәтиҗәгә килде ул.—Шушы минуттан ташлыйм!

***

Киңәшмә озак бармады. Үзәк Комитет кушуы буенча, дип һәр районга планнан тыш ашлык саты заданиесе житкерелде. Арсланов та, башкалар да беренче секретарьның аны хуплап алмаганлыгын яхшы аңладылар. Элекке еллардагы кебек, заданиене үтәү бөтен кискенлеге белән куелмады, куркыту сүзләре булмады. Димәк, аны үтәмичә дә калырга мөмкин булып чыга. Арсланов төнге унберенчедә өенә кайтып керде дә чәй эчкәнче үк Нәжмиевкә шылтыратты. Иртәнге сигезгә хуҗалык житәкчеләрен җыярга куштты. Киңәшмәне ул да йомшак кына, тавыш күтәрмичә генә үздырды. Булган икмәкне ычкындырасы килми иде. Планнарны, заданиеләрне үтәп, кыш көне фуражга интегеп, сызгырып йөрүләрнең азабын Миңзаһит Усмановичның яхшы белә. Эшнең нидә икәнлеген, әлбәттә, житәкчеләр дә яхшы аңладылар. Мәлс та шул көнне төштән соң дирекция каршына килеп туктаган ике КамАЗ машинасына икмәк төятмәде. Аның Чаллыдан кирпеч алып кайтасы бар иде. Урып-җыю эшләренә командировкага жибәрелгән машиналарны бүтән максатларда файдаланмаска, дигән күрсәтмә булса да, житәкчеләр аларны, хуҗалык ихтыяҗларыннан чыгып, җайлап-җайлап кына үз эшләренә боралар иде. Чаллыдан килгән ул шоферлар Мәлснының тәкъдименә биш куллап ризалаштылар.

Мәлс икенче көнне үк агрономнарны, алты хатынны, күл ураклары, чалгылар белән коралландырып, яна сортлар үстерелә торган вак

кишәрлекләргә алып китте. Һәр кишәрлекнә бер генә башакны да әрәм итмичә урырга, көлтә итеп бәйләргә, сортының исемен язып куярга кирәклеген аңлатты. Ул үзе дә яна сорт бодайны урып, көлтәләргә бәйли барды. Әледән-әле, кишәрлектән кишәрлеккә йөреп, башкалар эшен тикшерде. Көн шулкадәр матур, жилсез, август кояшы, башаклар тизрәк пешсен, дигәндәй алтын нурларын муй итеп коя. Бодай басуы читендәге каеннар дулкын-дулкын рәшә уртасыннан авыл буасына таба акрын гына йогеряләр төсле. Камыл төпләренда "Тиз-тиз-тиз!" дип чикерткәләр сайрый, уракны ашыктырырга куша. Зәнгәр күк йөзендәге өем-өем болытлар да, әллә шул чикерткәләр тавышын тыңлап, әллә халыкның эшләвен карап, бара торган юлларыннан туктап калганнар төсле. Шушыларның бөтенесенә икмәк исе, туфрак исе, камыл төпләрендә үскән күзлут, күкчәчәк, кыргый тары исе, кояш нурлары аша ингән кайнар ширбәт белән бергә катнашып, күнелдә берничек тә аңлатып бирә алмый торган куаныч уята. Бу мизгелләрдә синнән дә бәхетле кеше юк, дөньянын ин могжизалы, ин серле урыны шушындадыр кебек.

Мәлс машина тавышына башын күтәрде һәм аның шатлыклы уйлары шунда ук юкка чыкты: кишәрлек кырына Арсланов "Волга"сы килеп туктаган иде. Ул, рульдән төшеп, ураксылар янына килде.

—Исәнмесез, Алла ярдәм бирсен!—дип дәште һәм ирләр белән кул биреп күрешеп чыкты.

Хатын-кызлар янына барып, берничә шаян сүз әйтте, аларны мактады, аннары Мәлс янына килде һәм чыраен бозып кискен генә:

—Давай-ка, дорогой, ындыр табагына!—диде.

Аның машинасына ияреп, арттан чыккан тузанын иснәмәскә тырышып, тизлеген шактый киметеп, Мәлс күнелсез уйларына чумды. Беренче секретарь юньлелек белән килмәгән иде, әлбәттә. Алар инде быелгы ураста бер мәртәбә якага-яка килгәннәр иде. Казанның басымы астында райком барлык хуҗалыкларда да игенчәрне аеры уруны талән итте. Яңгырлар әледән-әле куркытып торганда, бу хәтәр нәрсә иде. Мәлс бодайны турыга урдырды. Моны белгән Арсланов, ут чыккандай, совхозга килеп төште. Мәлсны, райком линиясенә каршы килөсен, дип пыр туздырды, әллә нинди сүзләр белән тетмәсен тетте, "Бер генә центнер икмәк яндырсаң да, төрмәгә утыртам",—дип янады. Мәлснын үзе исаткан ашлык киптерү жайланмасы тәүлек буе эшләп тора иде. Урылган икмәкне тиешенчә жилгәрепп, чистартып, киптереп, дәүләткә сатып баруларын Арсланов үз күзләре белән күрсә дә, тузынудан туктамады, бик каты янап китте. Менә бүген, менә хәзер шуларның бөтенесен чыгарырга килгән булырга тиеш беренче. Алар ындыр табагына кайтып туктадылар. Жилгәргечләр дә, ашлык чистартқыч машиналар да, киптергеч агрегат та гөрләп эшли иде.

—Син нишләп кичә икмәк чыгармадын?—диде Арсланов, күзләрен ачулы ялтыратып.

—Мин чыгарырдай ипиемне чыгарып бетердем инде, Миңзаһит Усманович.

Арсланов дөртләп кабынды:

—Әллә син киңәшмәдән берни дә аңламадың?! Үзәк Комитет заданиесе турында сүз бара.

—Шулай икәнен беләм. Мин бит инде чәчүлек орлык белән сортлы ашлыкка кагыла алмыйм.

Арсланов, кызу-кызу атлап, ындыр табагының түбәле өлешендә тау кебек өелеп торган чиста бодай көшеленә килде. Ул иелеп бер уч бодай алды, аны жентекләп карады да учында сикертә-сикертә:

—Ә бу нәрсә?!—диде.

—Бусы фуражка.

—Әле урак бетмәгән,—диде Арсланов.—Фуражлык кына чыгар. Иртәгә сина мин колонна жибәрәм, менә шушы бодаенны төйисен.

—Миңзаһит Усманович!—диде Мәлс ялварулы тавыш белән.—Мин дәүләт планын бер ярым мәртәбәгә үтәдем. Үтәмәүчеләр шактый бит.

Сатсыннар. Ел саен безнең фуражга дигән ашлыкны алып бетерәсез дә, аннары бөтен җәфасы миңа кала.

—Фураж бик кирәк булгач, ник син безнең күрсәтмәне бозды?

—Нәрсә бозды мин?—диде Мәлс, аңа аптыраулы караш ташлап.

—Чиста парны йөз гектарда гына калдырырга кушылдымы сиңа?

Мәлс ярсып китте:

—Мин бит агроном кеше, Минзәһит Усманович,—диде ул акланып.—Жиргә ял кирәген беләм.—Ул, ике кулын Арслановка таба сузып, бармакларын кызу-кызу хәрәкәтләндерергә кереште.—Мина жирдә казынырга рөхсәт итегез инде, мин бит бүтән берни дә сорамыйм.

Арсланов аның кулларын кискен генә хәрәкәт белән читкә кагып жибәрде.

—Син монда спектакль куеп маташма әле, Сабитов! Иртәгә бу бодайны төятәсең! Әгәр төятмәсәң, партбилетың белән хушлашырсың!

"Биектау"дан кайтканда, инде төш вакыты житкән иде. Арсланов, райкомга кереп тормастан, машинасы белән өйләренә кайтты. Капка төбенә туктап, машина ишегеи ачуга, аның каршына ак мәчесен кулына тоткан Чукаева килеп басты.

—Песиемнең имиләре шешкән, китер балаларын!—диде ул елак тавыш белән.

Арслановның аны сугып егасы килде.

—Мин кәян белим аларны?!—диде ул ачуына тыгылып.

—Син аларны нишләп белмәскә тиеш ди?! Нигә аларны аталары янына алып кайтмадың?

Арсланов кулын селтәп өйгә кереп китмәкче булды, әмма Чукаева тотам да калмыйча аңа ярде.

—Ярый,—диде Арсланов, сүзләрен теш арасыннан сыгып чыгарып.—Хәзер шоферга шылтыратам. Әгәр үтергән булмаса, китереп бирер.

—Үтерәп карасын, "Чаян"га язармын,—дип Чукаева тузына-тузына капкасыннан кереп китте.

Хәят иренең капка төбендә Чукаева белән сөйләшеп торуын күрүгә хафага төште. Хәзер өйдә жәнжал чыгачак. Бүген ул универмагтан челтәр алып чыгучыларны очратты да шактый озын чиратның койрыгына барып басты. Һәм алдарак торучы хатыннарның сөйләшүен ишетеп колакларын сагайтты.

—Арслановның тач үзен язган,—диде нечкә тавышлысы.

—Без эштә жыелышып укыдык, көлә-көлә эчләребез катты,—диде тотлыккан кебегрәк сөйләшүчесе.—Оста да инде Ирек Сабитов.

—Кайда басылган соң ул?—дип сорады өченчесе.

—"Чаян" журналының соңгы санында.

—Ирем яныңа больницага барган идем, анда да палатадан палатага йөртеп укыйлар,—дип өстәде берсе.

Ул ике бите үт булып янган хәлдә очып кайткандай кайтты. Бер танышыннан журналны табып китертте, "Түрәев нотыгы" дигән сатирик хикәяне үт капкандай укып чыкты. Зур гына өсшма житәкчесе үз кешеләрен кыздырып чыгыш ясый. Орчык буе гәүдәле, камыт сыйраклы Түрәевнең тышкы кыяфәте дә, хәрәкәтләре дә Минзәһитка бөтенләй туры килми. Әмма ярым татарча, ярым урысча нотыгының һәр жөмләсе, һәр сүзе аның авызыннан өзеп алынган төсле. Моны беркем белән дә бүтән булмый, бу суеп каплаган Минзәһит үзе иде!

Ире ашап-эчеп залдагы диванга ял итәргә яткач, Хәят йомшак адымнар белән генә аның янына чыкты һәм журналның теге битен ачып аңа сузды.

—Укып кара әле менә моны...

—Нәрсә?!—диде Минзәһит ачулы нечкә тавыш белән.—Минем "Правда" газетасын кулыма алырга вакытым юк, ә син миңа "Чаян" сузасың.

—Зинһар карап чык, бөтен Болынкыр шуна чат ябышкан...

Минзәһитның күнеле ниндидер начар нәрсә сизенде. Ул "Чаян"ны жирәнгеч кыяфәт белән укырга кереште, укыган саен йөзе чытыла, кызарып

бүртенә барды, борын тишекләре кинәйде, иреннәре калтыранды. Ахырда журналны хатынына атып бәрде.

—Ну и сволочь бу Сабитов!—Ул, күзләрен ачулы уйнатып, әрле-бирле йөрергә кереште.—Тик ятмый соббака!

Хәят кече якка чыкмакчы булып ике-өч адым атларга өлгермәде, иренен ачулы тавышыннан туктап калды.

—Ник дәшмисең?! Син дә аның яклымы?!

—Дөресен әйтсәм, бөтен ачуынны миннән алачаксың ич син,—диде Хәят, ана күркүлы караш ташлап.

—Әйт дөресен! Аю түгел, ашамам.

—Син, Минзәһит, баштагы чорларда бер дә ике телне бутап сөйләшми иден.

—Йә, шуннан?

—Хәзергечә сөйләвең ул кешеләрне дә, үзеңне дә хөрмәт итмәү була.

Шул вакыт почмакта чикерткә сайрый башлады. Минзәһит дөп-дөп басып йөргән жиреннән туктап калды.

—Бусы тагын каян килеп чыккан?!—диде ул тәмам ярсып.

—Әле ишетелгәне юк иде бит...

—Шайтан белсен нәрсә?! Бөтен яктан һөҗүм итәсез. Сабитовка кадәр дөмбәсләп ята.

—Син анысына шаккатма, Минзәһит. Ин хәтәре—халыкның аны хуплавында, ана кушылуында.

—Аларга һәрвакыт кемнедер чәйнәргә кирәк.

—Ялгышасың. Татар телен югары мөнбәрләрдән мыскыллагач, син инде милләтнең үзен дә санга сукмыйсың, дигән сүз.

Минзәһит хатынына карчыгадай ташланды:

—Мин... мин нәрсә... синенчә, милләткә каршы кеше булып чыгаммыни?!—диде ул сулышына буылып.

Хәят акрын гына кухняга таба чигенде:

—Анысын үзең уйла инде...

—Аңлашылды! Минем турыда синең бер генә яхшы үең да юклыгын мин белә идем инде. Ачыктан-ачык әйтүең өчен рәхмәт!

Шулчак чикерткә сузып-сузып, дәртләнеп сайрарга тотынды, ана икенчесе кушылды. Чыгырыннан чыккан Минзәһит хатынының кулыннан "Чаян"ны тартып алып, шатыр-шотыр ертырга кереште.

—Китапханәнеке бит ул!—Хәят өзгәләнеп аңа үрелде.—Арсланов жыеп юк итә, диячәкләр.

—Дисеннәр! Бәдрәфенә куйган дисеннәр!—Ул ерткаланган журналны чикерткәләр сайраган почмакка томырды.—Сез минем бөтен тынычлыгымны алдыгыз! Әле Чукаева, әле "Чаян", әле чикерткә!

Ул дулап чыгып китте. Хәят журнал ертыкларын жыеп бетерергә дә өлгермәде, Минзәһит кабат килеп керде, ярсып аның каршына килде.

—Ничә еллар буе икмәк үстереп, итен-сөтен житештереп, төзелешләр алып барып, мин татар халкына каршы эшләгәнмен икән!—Ул бармагын Хәятнең борын төбендә уйнатты.—Не получится!

Хәяткә дә ниндидер көч инде.

—Икмәкнең дә, ит-сөтләрнең дә милләте юк,—диде ул тыныч кына.

—Аңлашылды! Син Сабитовтан да хуҗе икәнсең!

Минзәһит русчасын, татарчасын кушып сүгенә-сүгенә чыгып китте...

4

Беренче күзгалу белән, Мәлс ындыр табагы мөдире Әшрәфжановны күлтыклап, читкәрәк алып китте.

—Назыйм агай, Арсланов фуражга дигән бодайны дәүләткә жибәрергә куша. Ниишлибез?

Назыйм Әшрәфжанов, гомере буе механизатор булып эшләп, пенсиягә чыккан, барлык тамырлары белән жиргә береккән кеше иде. Ул озак кына

башын кашып торды. Аннары карт игенченең йөзенә сизелер-сизелмәс кенә елмаю җәелде:

—Кайчандыр бер фокус күрсәткән бар иде минем.

—Нинди фокус?

—Арпа белән бодайны бергә кушкан идем. Тәйи алмадылар.

Мәлс кычкырып көлеп жибәрде һәм шунда ук күзләрен очкынландырып:

—Әйдә шулай итик!—диде.—Арсланов ике телне кушып болгата бит әле.

Төштән соң тәвәккәлләделәр. Мәлс үзе дә гел шунда кайнашты. Кичке жидегә кадәр тырышсалар да, төгәлли алмадылар. Төнге смена өеттырырга туры килде. Иртәнгә фуражка дигән бодайның урыны ялтырап тора иде инде.

Сәгать тугыз тулганда, ындыр табагына ике КамАЗ ияртеп, район эчке эшләр бүлеге начальнигы Хасбулатов килеп туктады.

—Кайдан төйибез?—диде ул, исәнлек-саулык та сорашмастан.

Кара күчкыл йөзле, тар маңгайлы бу кешене жене сейми иде Назыймнын. Шулай да ул сабырлык сакларга тырышып:

—Без аны кичә складка салып куйдык бит инде, иптәш Хасбулатов,—диде.

Хасбулатов тупас итеп тәне белән бергә умырып, аның кулбашыннан эләктереп алды.

—Әйдә, күрсәт әле фуражынны!

Әшрәфжанов озын гәүдәсен читкә тартты, Хасбулатовның күбенгән мичкәдәй гәүдәсе чайкалып китте, бармаклары ындыр табагы мөдиренең кулбашыннан ычкынды.

—Сез, иптәш Хасбулатов, милиция начальнигы дигәч тә, бик умырмагыз әле,—диде ул, жыерчыклар белән тулы йөзенә ачу билгеләре чыгарып.— Син милициягә начальник булсан, мин туганнан бирле шушы жирнең начальнигы. Егет чагында да мин беркемгә дә умырып тоттырмадым. Тотканнарның авызын жимердем.

—Кара, кара, син үзенә күрә түгел икән,—диде Хасбулатов, ана астан өскә карап.

—Мин "үзенә күрә" дигән сүзне дә кабул итмим. Үземә күрә мин патша.

Әшрәфжанов эре адымнар белән складка юнәлде, Хасбулатов, кыска тәпиләрен кызу-кызу хәрәкәтләндереп, ана иярде. Әшрәфжанов, берни дәшмичә, аны кичә тутырылган ашлык янына алып килде. Хасбулатов, кара төк баскан кыска бармаклы кулын көшелгә батырып, аны берничә мәртәбә актарып чыгарды. Аннары авызын ачып, Әшрәфжановның йөзенә төбәлде.

—Мин синнән бодай сорыйм. Бу бит арпа.

—Әллә арпаны бодайдан аера алмыйсыңмы? Монда арпа гына түгел, бодай да бар.

—Ә нишләп алай ул?

—Фуражка без шулай икесен бергә салабыз. Малларга ашатырга әйбәт була.

—Тә-ә-әк!—дип сүзды Хасбулатов, нидер аңлый башлап. Аның ияренәре ачу белән кысылды.—Бу бит синең эш...

Әшрәфжанов бер сүз дәшми китеп барды. Кулына себерке алып, ындыр табагының иң аргы почмагындагы көшелнең өстендәге чүп-чарларны себергәли башлады. Хасбулатов атылып аның янына килде.

—Син минем белән шаярма, картлач!

Әшрәфжанов аның ботинка өстен тырмап узды да себеркене ачу белән болгап атты. Аннары бала башы кадәр йодрыгын Хасбулатовның борын төбендә уйнатып алды.

—Син, үскәнкәем, башта кеше белән сөйләшергә өйрән! Атаң кебек кешегә оялмыйча картлач дип жикереп ятасың. Мин синең кебек коммунист. Менә шушындагы бөтен байлык өчен жавап бирәм.

—Ярар, ярар, назланып торыр чак түгел. Каян төятәсең?

—Миндә төятерлек ашлык юк.

—Әнә теге нәрсә ул?—диде Хасбулатов, уң яктагы чип-чиста, озын булып сузылган бодай көшеленә күрсәтеп.

—Ул чәчүлек орлык, кагылырга ярамый анысына.

—Семена табарга үзем булышырмын. Ашыгыч задание бу.

Хасбулатов шулай диде дә көтеп торган КамАЗлар янына йөгерде. Ул арада машиналарның берсе гөрелдәп көшел янына килеп тә туктады. Әшрәфжанов ындыр табагында механик булып эшләүче Фәниска:

—Бер бөртек тә ашлык төятмисез, кешеләргә әйт, мин директорны алып киләм,—диде дә мотоциклы белән тырылдап авылга очты.

Мәлс ике сүздән хәлне аңлады. Өч минут үтүгә, ул инде Хасбулатовның каршына килеп баскан иде. Аның белән юри тавышын күтәреп, олылыклап күреште:

—О-о-о, исәнмесез, Мөстәкыйм Вәлиевич! Сезнең дә безнең хужалыкка килеп чыгар көннәрегез бар икән! Әйдәгез, кайнар чәй белән сыйлыйм үзегезне,—дигән булды ул, көчәнә-көчәнә төчеләнеп. Аның бу сүзләреннән Хасбулатовның йөзе караткычкыл төскә керде. Хәтта кечкенә колакларына кадәр бурлаттай бүртенделәр.

—Син, Мәлс Хәйриевич, бик опасный уен башлагансың,—диде ул тыны кысылып.—Алай гына котылырмын, дип уйлама. Семенанны төйибез.

Мәлснын йөзендәге ялган елмаю сыпырып алгандай юкка чыкты.

—Ничек итеп?

—Ничекме?! Кирәк булса, көч кулланып.

—Алай булса, мина сакланырга кала. Машинадагы ике көпшәле мылтыкны алыйм әле мин.

—Нәрсә, нәрсә?!—диде Хасбулатов, күзләрен алартып.

—Мин ни әйткәнне сез бик яхшы ишеттегез.

Хасбулатов йөгереп диярлек Мәлснын "Нива"сына барды. Ишеген ачып, анда яткан ике көпшәле ау мылтыгын тартып чыгарды.

—Син нәрсә?! Мина һөҗүм итмәкче буласыңмы?

—Минем сезгә һөҗүм итәргә жыенганын юк. Ә мылтыкны үзем белән йөртәм.

Хасбулатов мылтыкны ачу белән Мәлска тоттырды.

—Аңлашылды-ы-ы,—дип сузды ул.—Димәк, төятмисен?!

—Сынар бөртек тә юк.

Хасбулатов КамАЗ шоферына кайтып китәргә кушты да машинасының ишеген, тәрәзәләре коелып төшәрлек дәрәҗәдә шартлатып ябып, кузгалып китте. Ул кузгалганда, машинаның арт тәгәрмәчләре коры жирдә зырылдап әйләнеп торды. Мәлс белән Әшрәфжановның өстенә тузан бөртекләре генә сибелеп калды.

—Назыйм ага, булган ипиләрнең складка кертәсен тизрәк кертергә кирәк. Моның сугышы йә төштән соң, йә иртәгә иртән башланачак.

Хасбулатов кайтышлый ук райкомга туктап беренчегә керде. Ул сөйләгәннәрне Арсланов бүлдермичә генә тыңлады. Аның өсталгә йодрык суга-суга жикерүен көткән Хасбулатовка бу бик сәер тоелды. Барысын да сөйләп бетергәннән соң, Арсланов аның алдына өч-дүрт бит көгазь ыргытты.

—Эшнең ничек булганлыгын кыска гына аңлатып, минем исемгә язып бир. Директорның мылтык тотып ындыр табагына килүен, ашлык төягән очракта корал куллану белән янавын басым ясап күрсәт.

Хасбулатов урыныннан торды:

—Ярты сәгатьтән китерермен.

—Юк!—Арсланов кискен һәм ачулы тавыш белән имән бармагын өстәлгә төртте:—Менә шушында, хәзер үк!

Шулай диде дә бүлмәсеннән чыгып та китте. Хасбулатов башын кырын салып иелгән хәлдә көкре-бөкре хәрефләр белән язарга кереште. Бу вакытта Арсланов Нәҗмиев янына кереп хәлне аңлатты һәм Сабитовның персональ эшен әзерләргә кушты. Төп мотив—дәүләт заданиесен үтәүне саботировать итү булырга тиеш, дип кисәтте ул оештыру бүлеге мөдирен. Аннары бүлмәсенә кереп, Хасбулатовның информациясен укый башлады:

"КПСС райкомының беренче секретаре иптәш М. У. Арысланова.

20 августа сезнең боерыгыгыз буенча мин "Биектау" совхозыннан дәүләткә ашлык чыгартырга тиеш идем. Әмма анда баруга, төясе бодайны складка ташып, арпа белән кушканнар иде. Ындыр табагы мәдирe Ашрәпжанов һәм совхоз дирикторы Сабитов бер грамм да икмәк сатмаячакларын шундагы эшчеләр алдында деманастратив төстә белдерделәр. Ашлыкны төятмәс өчен һәм мине утлы корал белән куркыту максатында, совхоз дирикторы Сабитов ике көпшәле ау мылтыгы алып килгән. Әгәр ашлык төяү папыткасы булса, ул шул корал белән безгә каршы басачагын белдерде. Үтелләү, аңлатулар камунист Сабитовка тәссир итмәде. Ындыр табагында ашлык бик күп булса да, гасударыстьнный бензинне бушка яндырып, уборочный машиналар кабат район үзәгенә кайтырга мәҗбүр булдылар. Сабитовның бернинди рамкаларга сыймый торган мондый паступкысы партия уставы буенча каты җәзага тартылырга тиеш. Начальник РОВД: Хасбулатов."

Арсланов, аның һәр хатасына килеп төртелгән саен, бу бәләкәй кара адәмгә өстәлдәге телефоннарны, селектор аппаратларын, ручка-карандашларны берәм-берәм ыргытасы, туйганчы дөмбәслисе, идәнгә егып салып, өстенә менеп кат-кат сикерәсе килде.

—Бар, Хасбулатов,—диде ул акрын гына елаган кеше тавышы белән.—Эчке эшләр бүлегенә кайт.

Хасбулатов ашыгыч чыгып китте.

Ни аяныч, бу уйлаганнарның берсен дә эшләп булмый иде. Хәтта Хасбулатовка "Синең Казанда йонлы кулың бар, шуның басымы астында куйганга тына тешемне кысып түзәм",—дип тә әйтеп булмый иде. Чөнки әлеге йонлы кулның бугазыннан эләктереп алып буып ташлау ихтималы бар иде.

***

Төшлектә көнчыгыштан каракучкыл булып янгыр болыты күтәрелде. Шул яктан салкынча җил исә башлады, җил көчәйгәннән-көчәйде. Якынлашып килүче болытлардан дәһшәтле күкрәү ишетелде, яшен чаткылары җиргә тәбә сузылып-сузылып алды. Кишәрлекләрдән игеннәрне урып бетерә алмаганнар иде—Мәлс аның өчен бер борчылды. Ындыр табагында түбә астына кереп бетмәгән көшелләр бар иде—аның өчен ике борчылды. Ничек кирәк алай сөрепп, чәчелеп ята торган көзге бодай басуында эшнең буленәсен уйлап өч борчылды. Ул өенә кайтып, көндезге ашны ашап бетерүгә, кара болытлар килеп житеп, дөбер-шатыр яшен ата-ата, дулый-дулый янгыр яваргә кереште. Эре янгыр тамчыларының калай түбәгә төшүләре аермачык ишетелеп торды, бераздан ул хәвефле шыбырдауга әйләнде. Урамда, койма башларында бармак башы кадәр аксыл бөз кисәкләре сикергәли башладылар. Мәлс янгыр астында йөгереп урамга чыкты да, машинасын кабызып, дирекциягә китте. Барып кереп утырырга өлгермәде, көточкыч давыл күтәрелеп, кемнәрнендер түбәләреннән шиферларына кадәр кубарып атты. Аннары җил тынды, бер көйгә акрын гына янгыр сибәләп тора башлады, күктәге кара болытлардан бүлмә эче кинче энгер-меңгер вакытны хәтерләтеп калды. Киназ ишек ачылып китте һәм аннан Нәжмиев белән Нуриев, култыгына калын папкасын кыстырган Хисмәтуллин күренде. Салкын гына күрешеп, алар Мәлснын каршындагы озын өстәленә икс ягына кара-каршы килеп утырдылар.

—Сезне бюрога әзерлибез, Мәлс Хәйриевич,—диде Нәжмиев, имән бармагына көмеш чылбыр белән кигерелгән машина ачкычын әйләндерә-әйләндерә.—Ни өчен дәүләт заданиесен үтәүдән баш тартуыгыз турында аңлатма языгыз. Эчке эшләр бүлеге начальнигы каршында мылтык белән булган инцидентны да калдырмагыз.

—Чебеннән фил ясамагыз инде, Кәрәм Нәжмиевич!—Мәлснын йөзенә әллә аптырау, әллә көләргә маташу билгеләре чыккан иде.

—Сабитов!—Нәжмиев кулын йодрыклап, бармак буыннарының бөкләнгән турында агарып торучы сөякле жире белән өстәл полировкасына шакы-шакы сукты.—Минем берәр вакыт ике мәртәбә сөйләшкәнем бармы? Әйттем—үтисез.—Аннары ул башын Хисмәтуллинга борды һәм коры тына итеп:—Башлагыз!—диде һәм Нуриев белән бүлмәдән чыгып китте.

Хисмәтуллин тышындагы шома кабыгы күпшаклап, уйдык-уйдык киндере чыккан папкасын ачып жибәрде һәм өстәлне партия уставы, программасы, ниндидер райком карарлары, тагын әллә нинди кәгазьләр белән тутырып ташлады. Ул ин әлек, итек чолгавыннан чак кына кыскарак бер кәгазь алып, Мәлснын алдына салды. Анда житмеш өч сорау язылган иде.

—Бухгалтерия аппараты хәзер үк, бөтен эшен ташлап, шушы сораган әйберләрне әзерләсен,—диде Хисмәтуллин боерулы тавыш белән.—Аңлатмагызны язганчы әйтегез әле: мылтык корулы идеме?

Хисмәтуллинның күзләре аны тишәрдәй булып чекрәеп калдылар. Арслановның бу эшне ниндирәк яссылыкка күчерергә теләгәнен ул яхшы аңлап алды. Хисмәтуллин үз башы белән мондый сорауны берничек тә бирә алмый. Димәк, мылтык төп корал булырга һәм атарга тиеш. Әгәр алар шуны тели икән, нигә дип әле ул каршы килеп маташырга тиеш?

—Әлбәттә, корулы иде. Аерып языгыз: патроннарга аңдый-мондый ядрә генә түгел, бүре ядрәсе тутырган идем.

Хисмәтуллинның йөзенә канәгатьлек билгеләре чыкты, хәтта бит очлары кызарып китте. Дулкынланудан борынын тарта-тарта, Мәлс әйткәннәрне ул алдындагы калын дәфтәргә теркәп куйды.

Ул арада ишектә тагын Нәжмиев күренде. Аларның бер-бер артлы биргән сорауларыннан Мәлснын, торган саен гайрәте чигә барып, ахырда котырып ачуы чыкты. Ул инде бер әйберне аерымачык аңлады: бюрода аның персональ эше каралачак. Үзенең бүлмәсендә Нәжмиевнең лөззәтләнеп әрле-бирле йөрүен, берсеннән-берсе хәтәррәк, тозакка китереп каптыра торган сорауларын бирүен ул хәйран калып күзәтте. Нәжмиев машинасында алар ындыр табагында да, серүчеләр янында да, складларга, жайләүләрдә, төзелеш объектларында да булдылар. Нәжмиевнең бер генә нәрсә—кимчелек эзләве һәр хәрәкәтендә, һәр сүзендә ачык ярылып ята иде. Мәлсны тәмам эт итеп йөртеп, мең төрле сорау белән жанын ашап, дирекциягә кайтарып атканда, инде кояш баеган иде. Хисмәтуллин бухгалтерия работникларынын да берсен дә кайтарып жибәрмәген бүлып чыкты. Алар һаман нидер чүтлыйлар, ниндидер информация бирәләр. Нәжмиев, Мәлснын аңлатмасын укып чыккач, янабаштан яздырды, үзе теләгәнчә, төрлечә боргалады. Ул каранғы төшкәч кенә алар күлыннан көч-хәл белән ычкынды. Өйгә кайтып кергәндә йөрәге чәнчешә, куллары калтырый иде. Нәфисә аны танымады.

—Мәлс, ни булды сина?!—диде ул, анын каршысына йөгереп килеп.

—Житте!—дип кычкырды Мәлс, диванга авып.—Бер кабар урынын да калмады, гариза язам!

Нәфисә аның каршысына тезләнде, йомшак жылы куллары белән ике битеннән сыпырып:

—Мәлс, әйдә ашап алыйк әле,—диде.

—Китер мина кәгазь белән ручка! Әйттемме мин сина гариза язам, дип. Менә син дә теләгенә ирешәсен, рәхәтләнеп өйдә генә ятарбыз.

Нәфисә йөгерә-йөгерә аның алдына кәгазь белән ручка китереп куйды. Ул, иренеп шатыр-шотыр язганын тыңлый-тыңлый, рюмка төбенә валокордин тамызды, бер калак чамасы камырлык төнәтмәсе, аз гына жылы су өстәде һәм аның каршына килде. Мәлс гаризасын язып бетергән иде.

—Мә, эчеп куй әле шушыны,—диде Нәфисә, ягымлы тына дәшеп.

Мәлс даруны голт итеп эчеп куйды.

—Менә рәхмәт!—диде Нәфисә һәм өстәл әзерли башлады.

Ул мондый вакытта иренә эндәшмәү хәерлерәк икәнен белә иде инде. Шуңа күрә аның тынычланамы-юкмы икәнлеген күз чите белән генә күзәтә-

күзәтә, өстәлгә яшелчә салаты, жиләк-жимешләр, бәрәңге белән кыздырылган ит, тәмләткечләр ташыды. Шактый вакыт узгач, Мәлс костюмын, галстугын салып куйды, трикодан гына калып, жиннәрен сызганып, тышта юынып керде. Сүзсез генә өстәл янына утырып ашарга кереште. Эченең буш икәнен тойса да, чәйнәгән ризыгының тәмен сизмәде. Ашаганнан соң ул, йоклы булмәсенә кереп, урынга ятты. Нәфисә иренең артыннан керде дә, янына утырып, кайнар маңгаена учын куйды. Мәлсның күзләре дымлы иде.

—Чынлап та эштән китәргә ниятләдеңмени?—диде Нәфисә, үзенең бармак битләре белән сизелер-сизелмәс кенә аның иреннәренә кагылып узды.

—Әйе.

—Берәр нәрсә булдымыни?

—Эх, карчык!—ул хатынының беләгенә күлын сузды.—Берәр нәрсә булмаган көн бармы соң ул? Мин шулкадәр арыдым.

—Мин моны сизәм, Мәлс.

Мәлс кинәт сикереп торып утырды һәм Нәфисәгә таба ике күлын сузды:

—Ник минем шушы күлларым белән икмәк үстерергә хакым юк?! Ник минем үз башымны эшләтеп хуҗалык итәргә хакым юк?! Жавап бирә аласыңмы?

—Син бит инде бу сорауга жавапны мең мәртәбә үзең бирдең.

—Хак әйтәсең—шулай шул.

—Ярый, син ял ит. Өстәлне жыештырыйм әле.

—Карчык,—дип пышылдады Мәлс.—Зинһар янымда гына утырып тор әле. Утырып тора аласыңмы?

—И карткаем!..

Нәфисә аның ике күлы белән муеныннан кочаклап алды, битләрен битенә ышкыды, иреннәреннән, яшьле күзләреннән кат-кат үпте. Үзе күкрәгеннән күтәрелгән кайнар һәм тозлы ялкынны тамак төбен яндыра-яндыра туктаусыз йоттыы...

Мәлс аны күтәреп трильяж каршына алып килде. Икесе дә көзгедән бер-берсенә елмаерга тырыштылар.

—Арыдык без. Сине дә арыттым, карчык.

Аннары ул Нәфисәне идәнгә бастырды.

—Авыл халкы кайный, бөтенесенең телендә бер сүз. Берәр машина булса да жибәреп булмый идемени соң? Бүгазлары тыгылсын иде.

—Юк, Нәфисә, жибәрергә ярамый иде.

—Бюро кайчан булса да...—Нәфисә бераз тынып торды.—Мин синең янәшәңдә булырмын.

—Рәхмәт.—Мәлснын тавышы бөтенләй ишетелмәде диярлек.—Шулай тоярмын. Син янымда чакта миңа шундый рәхәт...

5

Иртән алтынчы яртыда Мәлсның эш бүлмәсенә Нәжмиев шылтыратты:

—Нуриев сезне күрмәдеме әле?—дип сорады ул.

—Юк.

—Хәзер килеп керер ул. Сәгать унда райком бюросына киләсез. Ана кадәр персональ эшегезне партком утырышы карар. Аңладыгызмы?

—Аңладым,—диде Мәлс.

Партком членнары сигезенче яртыга жыелып беткән иде инде. Нуриевны иртәдән бирле эт урынына житәкләп бүлмәдән-бүлмәгә йөрткән Хисмәтуллин, ниһаять, аны өстәл артында үзен генә калдырып, партком членнары янына утырды. Нуриев бик озаклап алдындагы кәгазьләрне чаштыр-чоштыр актарды, калтыранган күллары белән әле бер якка, әле икенче якка алып куйды. Ниһаять, ул башын күтәреп:

—Партком утырышын ачык дип белдерәм,—диде.—Көн тәртибендә бер генә мәсьәлә.—Ул туктап тамак кырды, хатын-кыз яулыгы кадәр

кулъяулыгын чыгарып, шыңгырдатып борынын сеңгерде, сирәгәйгән чәчләрен тарады, бу эшләрне эшләгәндә, бер генә секундка да күзләрен кулына тоткан кәгазеннән аермады.—Тә-ә-ә-әк... бер генә мәсьәлә... Совхоз директоры Мәлс Хәйриевич Сабитовның дәүләткә ашлык сатуны тоткарлавы... аннары хулиганлык гамәле кылырга азапланую. Кем дә кем...

—Сабиржан Закирович!—дип аның сүзен Хисмәтуллин кисәтүле тавыш белән бүлде.—Әллә синең йокың туеп җитмәдеме? Кая партия стиле?! Ул нинди азаплану? Дәүләткә ашлык тапшыруны тоткарлавы һәм,—Хисмәтуллин һәр сүзенә басым ясап дәвам итте:—шул максатта хулиганлык кылуы турында.

—Әйе... шулай...—дип куйды Нуриев, һаман да кәгазеннән күзен ала алмыйча.

—Кабатлагыз!—диде Хисмәтуллин.

Нуриев кәгазенә караган кылеш дәвам итте:

—Совхоз директоры Сабитовның дәүләткә ашлык тапшыруны тоткарлавы һәм шул максатларда тәртипсезлек...—ул кәгазеннән аерылып, күзлек өстеннән күрка-күрка гына Хисмәтуллинга башын борды. Аның кисәтүле, ачулы карашын күргәч, тиз генә кәгазьгә төртелде:—хулиганлык гамәле кылуы турында персональ эше көн тәртибенә куела. Кем дә кем шушы көн тәртибен раслыйбыз, ди, тавыш бирүегезне сорыйм.

Партком членнары барысы да гаепле кешеләр кебек башларын аска иеп утыралар, беркем дә күл күтәрергә ашыкмый иде. Шул чак Назыйм Әшрәфжановның озын гәүдәсе калыкты.

—Мин бу көн тәртибенә риза түгел.

—Нишләп?—диде Хисмәтуллин ачулы тавыш белән.

—Мин бит шунда идем,—дип дәвам итте Әшрәфжанов.—Директор анда бернинди хулиганлык та эшләмәде.

Хисмәтуллин торып басты.

—Сәгать унда Сабитовның персональ эше райком бюросында каралачак. Хәзер көн тәртибен кабул итәргә кирәк. Конкрет тәкъдимегез бармы?

—Бездән башка сез хәл итеп куйгач, нинди тәкъдим әйтәсен ди? Ярар, барыбер сезненчә булыр, әмма хулиганлык дигән әлешен алып атарга кирәк.

—Әшрәфжанов керткән төзәтмә белән көн тәртибен кабул итәбез диючеләр, күл күтәрегез,—диде Нуриев.

Унбер партком членының жиденең унаһ тавыш бирде, өчесе битараф калды, Әшрәфжанов каршы күл күтәрде. Нуриев бутала-бутала, каушый-каушый эшнең асылын аңлатып чыкканнан соң, партком членнарының үз фикерләрен әйтүен сорады. Башлар аска иелгән, күтәрелеп караучы юк иде. Партком бүлмәсендә шылт иткән тавыш та калмады.

—Мина бер генә сүз мөмкинме?—дип Мәлс урынныннан торды.

Аның артыннан ук Хисмәтуллин басты:

—Сабитов, әллә тәртипне белмисезме? Сүз сезгә соңыннан бирелә.

—Ә мин соңыннан сөйләп тормам.—Мәлс, урынына утыр, дигән төсле итеп, Хисмәтуллинга таба кулын селтәп алды.—Сез нәрсә жебеп төштегез әле, ипташлар? Корырак тотыгыз. Әнә нинди кояш, жил дә әйбәт. Барыбызны да эш көтә. Сез инде берничек тә минем халне жинеләйтә алмыйсыз. Курыкмыйча тәнкыйтләп сөйләгез. Мин ялгышымны таныйм, кызып кителгән.

—Йәгез инде, ипташлар?—диде Нуриев, яргаланган иреннәрен теле белән ялап.

Ферма мөдире Асылгәрәев тотлыга-тотлыга Мәлснын ялгышканлыгын сөйләп маташты. Тагын ике партком члены, үз-үзләре белән тарткалаша-тарткалаша, нидер әйтергә азапландылар. Нуриев күпме кыстаса да, бүтән беркем дә сөйләмәде.

Нуриев ике кулына биш-алты кәгазь тоткан кылеш:

—Иптәш Сабитовка мин учет карточкасына язып каты шелтә белдерергә тәкъдим итәм,—диде.

Партком членнары ризасызлык белдереп шаулашып куйдылар:

—Кисәтү бик житкән инде.

—Шелтә дигән сүз чыкмады бит әле монда.

—Эшләгән кешене типкәләмәскә кирәк.

—Кисәтү белән генә булмый,—диде Нуриев.—Кем дә кем минем тәкъдимгә кушыла, шул коммунистларның тавыш бирүен сорыйм.

Ул кулын күтәрде, ана ияреп, Асылгәрәев, аннары тагын берничә кеше өстәлде. Санап карагач, алты кеше тавыш биргән булып чыкты.

—Кемнәр каршы?

Дүрт кеше каршы күтәрде.

—Битарафлар?—Нуриев күзлек өстеннән Мәлсканы карады.

Мәлс акрын гына кул күтәрде.

—Димәк, күпчелек тавыш белән Сабитовка учет карточкасына язып каты шелтә белдерелә. Партком утырышы ябык.

Барысы да ашыга-кабалана бүлмәдән чыгып киттеләр.

Мәлс белән Нуриев нәкъ сәгать унда Арсланов бүлмәсенә керделәр. Барлык бюро члennары, бүлек мөдирләре, райком инструкторлары урыннарында иде. Мәлс төне буе йоклый алмаган иде, ул һәр бюро членына кызарган күзләре белән ашкрадай итеп карады. Берничә мәртәбә аның карашы Арслановныкы белән дә очрашып алды.

—Нәрсә, Мәлс Хәйриевич?—диде Арсланов, йөзенә мыскыллы елмаю чыгарып.—Йөзең бик чытылган, аякка сыер баскач, әллә авыртамы?

—Сезгә ничектер—белмим,—диде Мәлс усал итеп.—Мин үзем бирегә кәмит карарга килмәдем.

Арсланов кулына тоткан ручкасын өстәленә ташлады.

—Шулайдыр... Әгәр бюро члennарын әз генә хөрмәт итсәң, юньлерәк итеп киенеп килгән булыр идең.

Мәлс чыннан да иртән бик ашыккан иде. Партком утырышыннан соң ул комбайнчылар янында да сөйләшеп алган, шындыр табагында да булган, яна сортларны да берәм-берәм барлап чыккан иде. Шул килеш көрән свитердан, тузанлы чалбар, ялтыратылмаган туфлиләрдән кереп баскан иде ул. Арслановның сүзләре аның ачуын гына китерде. Аклану урынына ул ана төрттереп алды:

—Мин басудан гына. Әгәр сезне тузан исе куркытса, киенеп киләм.

—Сез бюрога килдегез бит.

—Туйга түгел шул,—дип куйды Мәлс, авыз эченнән генә мыгырдап.

—Житте, Сабитов!—Арсланов кулына кәгазь алды һәм күзлеген киеп сүз башлады:—Бүген бюро утырышына сабитовның персональ эше куела. Баштук әйтеп китәм: Нуриев, бу синең беспринципность, мәлжәрәвен нәтижәсе. Совхоз партком члennары чын мәгънәсендә либераллык күрсәткәннәр. Вообще-то, райком инструкторының мина сөйләве буенча, партком утырышын булмаган дип санарга мөмкин. Унбер кешенең нибары алтысы Сабитовка җәза бирү өчен тавыш биргән. Аның хулиганлык эшен бөтенләй инкарь иткәннәр. Киләчәктә безгә "Биектау" партоешмасы белән вплотную шөгыльләнергә туры киләчәк. Персональ эшнең иселе мондый: "О задержке продажи хлеба государству директором совхоза "Биектау" товарищем Сабитовым М. Х. и о его хулиганских действиях." Әйдә, секретарь парткома, доложи.

Кулына бер уч кәгазь тоткан Нуриев күзлеген рәтли-рәтли торып басты. Аның кулындагы кәгазьләре дер-дер килә иде. Ул бер кулы белән галстугын төзәткәндәй итте дә эшнен асылын аңлатырга кереште. Берничә җөмлә әйтүгә, кесәсеннән күлъяулыгын чыгарып, биткенен тирен сөртте. Ул арада күзлек пыяласы парланган иде, аны сөртергә азаплангандә, күзлеге идәнгә үк төшеп китте. Сабиржан Закирович аны алып кигәч, әле урып-жыюның, ашлык сатуның барышына анализ ясамакчы булды, әле Мәлсның машиналарны ни сәбәпле боруын аңлатмакчы булды. Ахырда хәлдән таеп, кәгазьләрен кулыннан төшереп жибәрде, ухылдый-ухылдый аларны жыйнап, актарырга кереште. Мәлсның түземе беткән иде.

—Интектермәгез инде олы кешене,—диде ул рәнҗүле тавыш белән.—Максатыгыз мин бит.

—Син монда безгә үз волянны көчләп такма әле, Сабитов. Совхозында такканын да житкән. Без барысын да бик яхшы аңлыйбыз. Әгәр ул партком членнарын син өркетеп куйган булмасаң, алар шундый гнилой либерализмга барырлар идемени?

—Мин беркемгә дә бер сүз дә әйтмәдем.

—Давай, сөйлә: ни өчен дәүләт заданиесен үтәүдән баш тарттың? Ни өчен милиция начальнигына мылтык күтәрден?

Мәлс ындыр табагында булган хәлләрне мөмкин кадәр кыска итеп сөйләп чыкты. Нәжмиев, Батталов, райкомның өченче секретаре Әхмәтҗанов аны гаепләп чыгыш ясадылар, язылган бюро карары проекты белән килешүләрен әйттеләр.

—Тагын кемнәрдә нинди фикерләр бар?—диде Арсланов, чыгыш ясамаган бюро членнарына берәм-берәм карап.

—Миндә бер генә сүз бар иде,—диде Гаскәров урынныннан торып.—Сабитовны без барыбыз да яхшы беләбез. Эшне әйбәт оештыра. Игенчелектә, терлекчелектә яналыкка омтыла, тик артык кызу, баш бирмәс, үзсүзлелек гадәтләре бар. Проектта күрсәтелгән "учет карточкасына язып шелтә бирергә", дигән карар белән мин килешәм. Ә менә аны эштән алырга кирәкми.

Гаскәровтан соң Арсланов башын Әхнәфкә таба борды:

—Әхнәф Хәсәнович, сезнең фикер нинди?

—Мин, Сәет Мөбәрәкович хаклы, дип саныйм. Без үзебез дә Сабитов кебек кызып китүдән сак булырга тиешбез.

Арсланов торып басу белән Мәлска һөҗүм башлады:

—Әгәр бүген без бөтен илдә үзгәртеп кору, җәмгыятьне демократияләштерү барганда, көпә-көндез милиция начальнигына корал күтәреп янаучы житәкчеләрне яклыйбыз икән, без кая барып чыгабыз?— Бу сүзләрнең үзләренә кагылганлыгын аңлап, гаскәров белән Шәрифуллин башларын аска иделәр.—Мондый карашта торучылар нык ялгышалар, безгә элекке психологиядән арынырга вакыт. Илне чистартыр вакыт житте. Кабат дискуссия ачунын кирәге юк, дип саныйм. Кем дә кем "Сабитовка учет карточкасына язып каты шелтә бирергә һәм аны совхоз директоры вазифаларыннан азат итүне сорарга", дигән тәкъдимгә кушыла, тавыш бирегез.

Бюро членнары барысы да күл күтәрде. Аларның йөзләре Арслановка төбәлгән булса, Шәрифуллин белән Гаскәров кенә башларын аска ирәп хәлдә утыралар иде.

—Бертавыштан.—Арсланов бераз уйланып торды да Мәлска мөрәҗәгать итте:—Мәсьәләне артык катлауландырмас өчен сина, Сабитов, үз теләгең белән эштән китәргә гариза язсан, әйбәтрәк булыр.

—Сез инде ул гаризаны языгган, дип уйлагыз.

Арслановның йөзе яктырып китте:

—Ну и хорошо. Сабитов белән Нуриевтан башкаларга китәргә мөмкин.

Бюро членнары урындыкларын шыкырдатып күчерә-күчерә торып чыгып киттеләр. Арсланов, ничек кенә тыелса да, эчендәге куанычын яшерә алмады.

—Сабитов, син мина рәхмәт әйтергә теләмисеңме?—диде ул ләззәтле елмаеп.

—Ник?

—Партбилетыңны алмаган өчен.

—Мин моңа кадәр ул мәсьәләне бюро хәл итә дип белә идем.

—Рабочкомга исемләп салдырган фин йөртын сыер савучыга бирүне кем хәл итте соң?

—Рабочком белән дирекция.

Арсланов аның каршында имән бармагын машина тәрәзәсе чистартқычы төсле хәрәкәтләндереп алды:

—Юк, Сабитов, аны бер кеше—син хәл иттең!

—Сез ничек алай дип әйтә аласыз?

—Шулай. Син телгәнне белдерден—алар хуплап кул күтәрделәр. Мин дөрес әйтәммме, иптәш партком?

Күрәсең, Нуриевның башы тәмам буталып беткән иде, ул беренченең әйткәннәрен әллә аңлап, әллә аңламыйча:

—Сез хаклы, иптәш Арсланов,—дип куйды.

—Мин хаклы булгач, партком ни карады?

Нуриев утырган урынында кыбырсып куйды, корык-корык ютәлләргә тотынды, борынын тартты һәм аклануга маташты:

—Партком катнашмады, иптәш Арсланов. Сыер савучы хатын коммунист булса да. Игезәк малайлар бит... Тупырдап торалар, иптәш Арсланов... Бала тудыру йортыннан кайтып, ике атна да тормады, эшкә дә чыкты... Батыр хатын, иптәш Арсланов.

Беренче аның сүзләрен тыңламады, үйлары башкада иде.

—Бәлкем рабочком белән директциянең карары киләчәктә үзгәреп тә куяр,—диде ул кинаяле тавыш белән.—Яңа директорның карашларын белеп булмый бит әле...

Бу сүзләрдән Мәлснның башы әйләнгән кебек булып китте. Ул үзенең беркатлылыгына хәйран калды. Бюрода бит ашлык сату заданиесен үтәргә дигән сүз дә чыкмады, аны юньләп телгә дә алмадылар. Арсланов Нәбиуллинга йорт бирмәгәннең үчен алып ята ләбаса. Шушы минутка кадәр ничек соң Мәлс бу эйберне аңлый алмаган? Аның бик нык итеп беренчегә чәнчеп сүз әйтәсе килде, әмма күпме генә тырышса да, аның жаһын көйдереп алырлык сүзләр тапмады.

Мәлс кесәсеннән гаризасын алды да аны җәеп Арслановка күрсәтте:

—Бу минем эштән китүне сорап язган гаризам. Сезнең әлеге сүзләрегезне ишеткәч, бүтенгә бюроның ни өчен үткәрелгәнен аңладым мин.—Ул гаризасын аркылы-торкылы вак кисәкләргә түйганчы ерткалады да кесәсенә салды.—Болай булгач, мин үз теләгем белән гариза язмаячакмын. Белеп торыгыз: мин көрәшәчәкмен!

Мәлс сикереп торды да ишеккә ташланды. Райкомнан ул, томан ерып атлагандай, күзенә берни дә күренмичә чыкты. Нуриев машинага кереп утырган, алар күзгалып киттеләр.

—Ну, ничек, син канәгатьме, Сабиржан Закирович?—дип куйды Мәлс битараф тавыш белән.

—Моңа беркем дә канәгать түгел.—Нуриев шунда сүзен бүлде дә куркынган күзләре белән Мәлска карап алды.—Житмәсә, баш чатный. Кичә бажайлар килгән иде...

Мәлс аңа бер сүз дә дәшмәде. Урман турына житкәч, машинаны унга борды. Яңгыр сулары жыелган чокыр-чакырлы, засламыклы юлдан эчкә керә башлагач, тәрәзә аша тулган салкынча һава аларның тәннәрен рәхәтләндереп жибәрде, сулышлары иркенәйгәндәй булды. Юл киселеп ята торган делянкага килеп чыкты. Аларның нәкъ каршында ботак өеме дөрләп яна. Ерактарак, ауган агачлар арасында, бер кеше икенче өемне салып маташа.

—Әйдә, бераз хәл алабыз,—диде Мәлс, машина ишеген ачып.

Алар, машинадан төшкәч, кулъгадә басып, берни сөйләшмичә, шактый вакыт тордылар. Инде агач яфраклыннан жәйге матур яшеллек китеп бара, алар шактый төс ташлаганнар, ара-тирә саргайган яфраклар да күренә. Әле бал кортлары, кигәвен-черкиләр тирә-юньдә безелдәп торса да, инде урмандагы элекке жанлылык сүнеп бара. Каршыдагы өемнән күтәрелгән ялкын эсселегеннән урман су эчендәге кебек дерелдәп, дулкынланып күренә. Яшел каен яфраклары кайнарлыкка түзә алмыйча жыелылып бөтерелләр, көрән төскә керәләр, аннары дөртләп янып та бетәләр. Ботаклар һәм яфраклар ничектер сызгырып, чытырдап яналар, аларның астагы кызыл күмерләргә сүлләре тамганы да ишетелә кебек. Биек итеп өелгән ботаклар һаман жиргә инә бара. Читтәрәк торучы яшь наратның тирәсендәге барлык

агачлар кисеп аударылган, ана сыеныл, ике яшь каен гына калган. Ундагысы наратка башын иеп нидер сөйли кебек, суддагысы аны култыклап читкә тарткан шикелле тоелды Мәлсха. Ул, машинадан ике помидор, башланган ярты һәм стакан алып, Нуриев янына килде. Арақыны күргәч, аның йөзе яктырып китте. Стаканны тутырып, бер помидор белән партком секретарена тоттырган, Мәлс иркәләгән кебек кенә итеп:

—Бюроны юыйк инде, Сабиржан агай,—диде.

Нуриев арақыны тын да алмыйча эчеп куйды. Помидорын капмады да, иснәмәде дә. Мәлс үзенә салган арақысын, кулында шактый тотып торганнан соң, яныл торган агачларга сипте.

—Их!.. Нигә инде?!.—дип өзгәләнде Нуриев.

—Интегеп озаклап янмасыннар. Аларнын да тәннәре авыртадыр бит. Тикшерүләр күрсәткәнчә, хәтта музыка да үсемлекләргә тәэсир итә, диләр. Синен укыганың бармы шул хакта, Сабиржан агай?

Нуриев әллә аның сүзләрен ишетмәде, әллә уйлары башкада иде—җавап бирмәде. Бик озаклап урманга карап торганнан соң, үз алдына сөйләнгәндәй әйтеп куйды:

—Без дә шушындагы агачлар кебек бит инде: кләймә суктылар—беттен. Кайчан, кем кисеп аударасы гына билгесез. Барыбер кисәчәкләр: йә утынга, йә тактага, йә бүрәнәгә...

Мәлс әллә нинди салкын көлү белән көлеп куйды:

—Хак әйтәсең, Сабиржан агай. Мин дә нәкъ шул хакта уйлап тора идем. Ничек икебез дә бер фикергә килдек микән соң әле без?

—Монда аптыраулык нәрсә юк, Мәлс Хәйриевич. Без бит бер урман агачлары...

Алар, һәркайсы үз уйларына батып, урманны күзәтә-күзәтә, андагы тавышларны тыңлый-тыңлый, шактый озак басып тордылар. Жаннары бераз урынына утыргач, Наратбашка юл тоттылар.

6

Гаскәров белән теге күнелсез очрашудан соң Ирек ун көн буе эчмәде. Өенә беркемне кертмичә, көне-төне язды. Пьесасын тулысынча төгәлләп бетерде, повестенын соңгы битләрена якынлашты. Төнге дежурдан чыгу белән ул Минзәләгә юл тотты. Төш туры житкәндә, Ирек ул борынгы шәһәрнең театр бинасында иде инде.

Пьесаны Ирек үзе укыды, коллектив аны хуплап кабул итте. Фикер алышу вакытында шактый гына тәнкыйть сүзләре дә әйтелде. Соныннан алар, режиссер һәм театр директоры белән берлектә, очәүләп фикерләштеләр.

—Әсәрегез нәкъ без яшәгән бүгенге тормышны чагылдыра,—диде режиссер.—Сәхнә законнары күзлегеннән караганда, житди кимчелекләре булса да, без аны заман проблемаларын яктырганы өчен куячакбыз.

Алар Иреккә әсәрне тозәтеп, мөмкин кадәр тизрәк машинкада бастырып китерергә куштылар. Ул канатланып, очынып кайтты. Өенә кайтып житкәндә, инде сәгать унберенче киткән иде. Капканы ачып кергәндә үк, агач бакчасында кемнәрнеңдер сөйләшкәне ишетелде. Аның каршысына Бәкер белән Миргазя килеп чыкты. Миргазя гармунын гадәттәгечә аркасына аскан, алар икесе дә ару гына булганнар иде.

—Син бүген безне унбиш кенә минутка булса да кабул итәргә тиеш, Ирек,—диде Бәкер, уң кулын өскә күтәреп селти-селти.—Менә бу кешенен бүген туган көне. Без шуны билгелэп үткәндә, сине ничек читтә калдырыйк инде.

—Котлыйм, котлыйм,—диде Ирек, Миргазянын кулын кысып.

Алар ойгә керделәр. Бәкер күз ачып йомган арада, сумкасыннан алып, өстәлне ипи, помидор, кыяр белән тутырып атты. Аннары Иректән рөхсәт сорап, рюмкаларга арақы салды.

—Ярый, Миргазя, мин сине туган көнең белән чын күнелдән котлыйм,

сәламәт булыңны телим,—диде Ирек.—Каләмеңне ташламыйча, ижат итеп, шигырьләреңне матбугатта бер-бер артлы күрергә язсын.

Ул алар белән чәкештерде дә үзенең рюмкасын өстәлгә куйды.

—Мин бу әйбер белән араны өздем, егетләр.

Күпме генә кыстасалар да ул әйткән сүзеннән чигенмәде.

Аның ниш ләптер аларга повестеннан әле кичә генә язган урыннарын укып күрсәтәсе килде. Моны әйткәч, дуслары берсүзсез риза булдылар.

Ирек укып туктагач, Миргазяз көрәктәй кулы белән аның кулын кысты:

—Әгәр бу басылса, "Түрәев нотыгы" ише генә булмас, бөтен татар дөньясында шау-шу тудырачак! Чаң суга торган мондый әсәрләр аз. Без сай йөзәбез, вак әйберләр турында язабыз.—Ул ишекле-түрле таптанып йөргән Бәкерне үзе турыннан үзын барганда эләктереп алды да:—Менә син кешелек язмышы турында уйланасыңмы?—диде.

—Нигә уйланмаска.

—Әйт, ни уйлыйсың? Ни көтә безне?

—Якын арада безне бик зур шатлык көтә,—диде Бәкер мут елмаеп.—Бүген-иртәгә безнең кәжә бәрәнләячәк.—Ул көйләп шигырь сөйли башлады:

Безнең кәжә бәрәнләгән,
Игез бәрән китергән.
Миргаязга "мә-мә-ә", диеп,
Чүмечләп сөт эчергән.

Алар шактый вакыт жырлашып утырдылар, Миргазяз гармунын алып куйды да жиһан, мәнгелек, яшәеш турында шигырь укырга кереште.

—Безгә тормышның яңа өслеген ачарга кирәк, шуның мәгънәсен табарга кирәк. Шунсыз кешелек үзен үзе һәлак итәчәк,—дип бетерде ул сүзен.—Аннары Бәкерне үртәп:—Ә син кәжә бәрәннәреңне жиһан биеклегенә күтәрәсең,—дип өстәде.

—Ә син төрмә сандугачы! Төрмә шагыйре,—диде тегесе ана жавап рәвешендә.

Миргазяның йөзендә бер генә төк тә селкенмәде. Хәтта ул Бәкергә ризасызлык та белдермәде. Ирек, гомумән, аның таш сын сыман һәрвакыт бер кыяфәттә утыруына хәйран кала иде. Гармун уйнаганда да, дулкынланганда да, кызып-кызып бәхәсләшкәндә дә, Миргазяның йөзе таштан кырып ясалган һәйкәлнеке кебек кала бирә, бик сирәк очракларда зур кара күзләреннән генә аның эчендә кайнаган давылны чамалап була. Бу юлы да ул тонык тавыш белән:

—Әйе, утырырга туры килде,—дип куйды.—Бүгенге жир шарының ничек яшәгәнен белəсең килсә, син төрмәне күреп кара. Анда берәүләр кеше каны эчә, икенче берәүләр шуларга элагайлана, аларның артын ялый, өченче берләре тизәк белән бергә аяк астында ауный. Йә, ярый, ул турыда сөйләү авыр мина. Әсәреннең дәвамын укы әле, Ирек.

—Ул башта гына бөтерелә бит әле.

—Ә ни турында булачак соң?

—Ир-ат, хатын-кыз хыянәте турында. Гаилә белән бергә әхлак та жимерелә.

Миргазяз кабаланып ана каршы төште:

—Син, Ирек, бик оста язучы да, философ та. Ә бу очракта ялгышасын: хыянәт юк ул!

—Ничек юк?—диде Ирек кычкырып жибәреп.—Безнең күз алдыбызда күпме хыянәт кылына.

—Хыянәт юк!—дип кабатлады Миргазяз.—Авыру ирләр, авыру хатыннар гына бар. Аларның чирләре эчтә, күңелләрендә. Бу чирне берәүнең дә актарып караганы юк. Моның белән шөгыльләнергә маташучылар да ин тирәнгә яшерелгән чирне түгел, ә аның тыштагы билгеләренә генә эзлиләр, шуннан карап хөкем чыгаралар.

—Ә син белəсеңме?—дип сүзгә кушылды Бәкер.

—Беләм,—диде Миргазяз тыныч кына.—Менә мин шундый чир белән

авыручы кеше. Мин хатынымнан үлеп көнләштем. Аны туйганчы кыйнадым, җәберләдем. Сандугачтай чибәр, сабан тургае кебек шат күнелле, сайрап тора торган кечкенә гәүдәле хатын иде ул. Мин аны ташлап качтым, кабат кайттым, кабат газапларга тотындым. Кабат ташладым... шул чакта билгеле булды: хатыным мина беркайчан да хыянәт итмәгән. Әйе, аның янында икенче ир бар иде. Ләкин ул хыянәт итмәгән! Мин, ялгышымны аңлап, аның алдына кайтып егылдым, тик ул мине кичермәде. Янган йөрәгемә чыдый алмыйча, туган нигезгә кайттым, мина киргә юл юк. Хәзер шушы җәзасын күрәм. Әгәр шулай булмаса, мин болай йөрмәс идем...

Ирек аның сүзенең җеп очына чыга алмады.

—Янында икенче ир бар иде, дисең ич.

—Әйе, бар иде. Ләкин хатынын мина хыянәт итмәде. Аның ялгыш адымы гына булды. Без, ирләр, хатын-кызларны гафу итәргә тиеш. Әйе, әйе! Төптән уйлап карасагыз, бу шулай.

—Бусы хак,—дип Бәкер кулларын уйнатып алды.—Безнең әби, дошманыңны да кичерергә кирәк, ди. Шул чакта гына кеше якын кеше була, ди.

—Минем инде кире анда кайтасым юк,—диде Миргазз төшенке тавыш белән.—Шулай да йокыдан торгач та беренче эш итеп хатынымнан гафу сорыйм. Һәр көнем шулай башлана.

—Алла бабайдан сорарга кирәк, дога укырга кирәк.

—Вакыты җиткәч, белмәссең—анардан да сорарга туры килер... Ялган уйлар безне янгын кебек чолгап алган. Ә утта бөтен нәрсә яна. Барлык тереклек яна, гаилә дә шунда янып бетә...

Ул, гармунын алып, "Иске кара урман"ны уйнарга кереште. Гүя жыр түгел, кара урман дөрләп яна, тормыш яна иде...

7

Мәлс Сабитов гаризасын ертып, "көрәшәчәкмен!" дип бүлмәсеннән чыгып киткәч, Арслановның күнеленә шом төште. Ул хаклыкның анарда икәнлеген тойды һәм чарасызлыктан бәргәләнде. Үзенең чиста, саф вакытларын хәтереннә төшерде. Күпме сулар аккан, күпме жилләр искән. Еллар катламы инде ул бәхетле Миңзаһитны егып, балки үтереп үктер, күмеп калдырган. Кире кайтырга иде дә, моны хәзер Сабитов белән башланган шушы матавыкта эшләп булмый. Әгәр хәзер чигенсә, ул аяк астындагы тирес өеменә әйләнәчәк. Бүтенге көндә аның каршында Сабитовлар күркыныч көч булып тора. Сыер кинәт сөзми, тора-тора сөзә. Әгәр ул Арслановның эшендәге бөтен чүп-чарын жыеп, үзенең энесенә илтеп аударып барса, анысы теләсә кая язарга мөмкин. Куласаның шундый итеп әйләнеп китүе ихтимал, Арсланов мәтәлер, Сабитовлар өскә күтәрелер. Аңа Гаскәровның бюрода Сабитовны яклап чыгуы да ошамады. Балкем алар бергәдер, очрашалардыр, ниндидер планнар кораладырлар. Гаскәров заманында бик аздан гына беренче секретарь булмый калган кеше... Ярты юлда туктап калырга һич тә ярамый иде. Бюро карарын нигез итеп алып, ул совхозда вәкилләр жыелышы уздырырга кушты. Жыелышка Арсланов, үзем барам, диде. Ләкин иртәгә жыелыш дигән көнне аның күнелен күркү биләп алды. Бу эш вулкан кебек кинәт калкып чыгар, ул вулканның кайнар лавасы Казанга үк барып житәр кебек сизенде аның күнеле. Турыдан-туры үтка кермәскә кирәк иде. Шуңа күрә кичтән ул үзенең бүлмәсенә Әхнәф Шәрифуллинны чакырды. Ана да бик үк ышанып бетми Арсланов, заманында ул аның Ирек белән аерылмас дус икәнен белә. Ирекне укырга жибәргәч теләүчеләрнең дә берсе ул булды. Арсланов Шәрифуллинны шул вакытта үзен ничек күркытканын да ачык хәтерли. Ул аның үзе астына күелган сәгатьне мина кебек торуын яхшы аңлады. Шәвәлиевне аткаргач, нәкъ менә шушы уйлардан чыгып, бер генә көнгә дә күз уңыннан ычкындырмас өчен үз янына алды.

—Минем иртәгә ашыгыч эш килеп чыкты бит әле. Чаллыга китәргә туры килә,—диде ул Шәрифуллин кергәч.—"Биектау"га вәкилләр жыелышына сезгә барырга туры килер.

Бу көтелмәгән тәкъдимнән Әхнәфнең йөзе кызарып китте. Шулай да ул каушамады, жебеп төшмәде, тыныч кына:

—Ярый, барырмын,—диде.

—Жыелышны рабочком алып барсын, дилбегәне кулдан ычкындырмагыз. Сабитов тик ята торган кеше түгел. Без монда әвеш-тәвеш килеп маташкан арада ул инде кул астындагы кешеләрен эшкәртеп чыккандыр. Яңа директор мәсьәләсен мин Казан белән хәл иткәнче кичектерегез.

Әхнәф икенче көнне иртүк "Биектау"га юнәлде. Ул юлда барганда Мәлс Сабитовны эченнән яклап барды. Кешеләрнең әлеге бюро карарын юкка чыгаруын теләде. Чөнки әлеге бюроның ни өчен үткәрелгәнлеген, Сабитовны беренченең ни өчен эштән алырга теләвен район житәкчеләре генә түгел, наратбашлылар да аңлаган иде. Гаделсезлек бит ул көчле янгын шикелле: аны беркем дә теләми, бөтен кеше дә каршы, әмма чарасызлыктан чигенергә мәжбүр.

Вәкилләр жыелышын өр-яңа кара костюм-чалбар, ап-ак күлмәк кигән, кып-кызыл галстук такаан Әнәс Нәбиуллин ачып жибәрде. Президиум сайлау, көн тәртибен раслау да тып-тыныч кына үтте. Ул аннары Мәлс Сабитовка бирелгән жәзаны аңлатты һәм райком бюросы аны эштән алырга тәкъдим итә, диде. Аны зал түзеп тыңлады, урынына утыргач та, тавыш-тын чыкмады. Аннары кинәт нәрсәдер булды. Дирижер үзенең таягын болгагач, оркестр бердәм уйнап киткән кебек, залда дәррәү тавыш-гауга күпты. Әйтерсең дә язгы ташу вакытында бер урынга жыелып, бүалеп торган бозлар әеме шатыр-дебер килеп урыныннан кузгалды.

—Кемгә кирәк булды бу кәмит?!

—Билгеле инде: Түрәвкә!

—Безне ахмакка саныйлар! Таралырга кирәк. Бетте-китте, вәссәләм!

—Кайчанга кадәр мәжбүриләп акны кара диюдән туктарлар?!

Нәбиуллин халыкны тынычландырырга азапланды:

—Туктагыз әле, иптәшләр! Тәртип белән сүз алып сөйләгез! Бу бит сезгә янгын өе түгел. Абзый, урынына утыр әле! Зинһар тынычланыгыз!

Нәбиуллинның чырае кып-кызыл булды, тамагы карлыкты.

Халыкның тынычланмавын күреп, Мәлс торып басты. Аны күргәч, зал тып-тын калды.

—Иптәшләр, болай ярамый бит. Биредә беркем дә уйнап йөрми. Үзүзегезне ничек тотуыгыздан сезнең язмышыгыз хәл ителә.

Зал күпмедер тынычланды. Эшчеләр берәмләп тә, икешәрләп тә басып сөйли башладылар. Кайберләре трибунага да чыкты. Алар ин элек Әхнәф Шәрифуллинга, шушы көн тәртибе белән жыелыш жыйган өчен, үпкә сүзләре белдерделәр. Райкомны, Арслановны сүктеләр, директорны төрле яклап мактадылар.

Шаулап аккан язгы ташу суы кебек, жыелыш халык басымы астында сәгатьтән артык барды. Аның бөтен авырлыгы Нәбиуллинга төште, ул тирләп-пешеп чыкты, халыкны үзе теләгән юнәлешкә бору өчен барлык тырышлыгын салды, әмма буйсындыра алмады. Ахырдан Сабитовны эштән алырга, дип тавышка куйгач, йөз утыз кешедән нибары сигезе күл күтәрде.

Культура йортыннан чыкканда, Әхнәф сиздерми генә Мәлснын жиненнән тартты, ул арткарак калды.

—Сине Арсланов пычагым да эшләтә алмый,—диде ул аның колагына пышылдап.—Нык тор.

Мәлснын күзләреннән ул үзенә карата рәхмәт хисләре укыды.

Райкомга кайтып, кабул итү бүлмәсенә керүгә, секретарь хатын:

—Сезне Минзәһит Усманович көтә,—диде.

—Ул Чаллыдан кайтып життеменни?

—Әйе, әле генә кайтып керде.

Беренчегә жыелышның ничек үткәнлеген сөйләп биргәч, аның чырае күмер булды.

—Полный провал!—диде ул, йодрыгы белән өстәлгә сугып.—Полнейший провал!—диде.—Ишкәнсең, Шәрифуллин, ишәк чумарын!

—Без Нәбиуллин белән кулдан килгәннең барысын да эшләдек,—диде Әхәф тыныч кына.—Сез анда халыкның ярсуын күрсәгез. Белмим, үзегез барган булсагыз да...

—Анлашылды,—диде Арсланов, иреннәрен ачулы кысып.

Икенче секретарь чыгып киткәч, ул ниндидер шатлык кичергәндәй, ярый әле үзем бармаганмын, дип уйлап куйды. Күнеле дөрес сизенгән икән. Хәзер нәрсә эшләп була соң? Ул, ияген үн кулы белән учлап, тиеш сызлаган кешедәй, бүлмә буйлап йөрергә кереште. Ишектә Нәҗмиев күренде. Арсланов бүлмә уртасында аякларын аерып туктап калды.

—Молодец, заворг, провалны шәп оештырдыгыз! Хәзер как быть?

Нәҗмиев, аның каршына килеп, кулындагы ниндидер кәгазьләргә икенче кулының аркасы белән шапылдатып сукты һәм астыртын карап болай диде:

—Без зур ялгыш җибәргәнбез.

—Нинди ялгыш?

—Сабитов депутат бит. Районныкы да, авыл Советыныкы да. Безгә юри булса да депутатларның ризалыгын алырга кирәк. Аннары совхоз коммунистларының гомуми жыелышын уздырырбыз. Шуннан соң инде, бүгенге вәкилләрне чакырмыйча, икенче вәкилләр жыярга туры килер.

Арсланов, бер сүз дә дәшмичә, аның бүртмәчләнеп торган маңгаена, кашына төшеп торган каты, кус чәчләренә, пөхтә киеменә карап торды.

—Кәрәм Нәҗмиевич, мин инде текучка кешесе. Син бит аппаратчик, кәгазь корты. Ничек син моны башта уйлап бетерә алмадың соң?

—Элегрәк ул төрлечә эшләнде. Райкомга каршы килү юк иде бит. Үзәртеп кору дигән бу нәрсә безнең күрмәгәнне күрсәтәчәк әле.

—Анысы хак.—Арслановның күнеле әллә йомшап, әллә усалланып китте.—Безне хәзер ничек сөйләшергә дә өйрәтә башладылар бит...

Беренченең зарлануы Нәҗмиевнең күнеленде шатлык тойгысы уятса да, ул аны гадәттәгечә сынап күзен кысып һәм иреченең бер читен кыйшайтып шундук эчкә яшерде, ә тыштан Арсланов көткән сүзләр белән шомартып та куйды:

—Житәкчегә таш атучы, күсәк күтәрүче генә булсын. Безнең халык шуның артына басып, һәжүмгә күчәргә генә тора.

Арсланов түземсезлеге, әлеге сүзләрне ычкындырганы өчен үкенеп куйды. Бу бит "Түрәев мин ул", дип ачыктан-ачык әйтү, шомланып йөрүен, какшавын күрсәтү иде. Шуңа күрә сүзне икенчегә борырга ашыкты:

—Ярый, исполком утырышында үзем катнашырмын,—диде. Авыл Советына кемне жибәрәбез?

—Гаскәров барсын.

—Юк, соңгы вакытларда мин ана ышанмыйм. Бездән аерылып бара бугай ул.

Нәҗмиевнең эченә жылы йөгерде:

—Мин дә шулайрак сизәм аны...

Арсланов, бераз уйланып торгач, сүзен төгәлләде:

—Әхмәтжановны жибәрик. Советлар эше буенча даими комиссия председателе бит ул.

Икенче көнне райбашкарма комитеты утырышы уздыртып, депутат Сабитовны эштән алырга рөхсәт бирү турында карар кабул итүгә ирешелде. Әмма Наратбаштан Әхмәтжанов тагын хәвефле хәбәр алып кайтты. Авыл Советы башкарма комитеты утырышында комитетның жиде члены да чыгыш ясап, каршы килгәннәр. Алар белән кабат сөйләшү өчен икенче көнне Нәҗмиев үзе, район Советының оештыру бүлеге мөдире Наратбашка китте. Ин элек авыл Советы председателе Әфләтунованы төрлечә күркытып, сындыруга ирешеләр. Аннары Әфләтунова ярдәмендә башкаларны сындыру башланды. Аларның һәрбersенә эштәге кимчелекләре, ялгыш

адымнары белән китереп кыса башлагач, йомшарга, бөгелергә мәҗбүр булдылар. Ике көннән соң уздырылган утырышта, райком карарын яклап, биш кеше үнай тавыш бирде. Партия жыелышына Арсланов үзе барды һәм ин әүвәл чыгыш ясады. Аны тын да алмыйча тыңладылар. Беренче булып фикер алышырга тәбәнәк кенә гәүдәле ир чыкты.

—Мин директорның эшендә бу кадәр күпертерлек кимчелекләр күрмим,—дип башлады ул.—Директор безнең белән яши, безнен белән ашый, яшерен эшләре юк. Сабитов барында безгә милиция дә кирәк түгел. Ир белән хатын сугышса да, төн уртасы дип тормыйча, шуна барабыз. Ул бөтенебез кебек үк чират буенча көтү көтәргә дә чыга. Без аны эшеннән алуга каршы.

Механизатор булып эшләүче коммунист үзенең чыгышын болай дип бетерде:

—Монда иптәш Арсланов олылыклап Сабитовны хулиган итеп сурәтләде. Ул бит, җәмәгать, без үстергән ашлыкны саклаган. Без дә аны саклыйк. Әгәр директорга кагылсагыз, Үзәк Комитетка делегация жибәрәбез.

Дунгыз караучы бер хатын трибунага чыгып, Арслановка борылды да елардай булып:

—Ник аласың син аны?!—дип кычкырды.—Аның бит директор бүлмәсендә утырганы да юк. Без бит ишетеп торабыз: башта хужалык житәкчеләре, берәр бәйрәм булса, машиналарына утырып, дусларына, туганнарына качалар. Ә безнең директор бәйрәмдә дә безнең белән. Ана санаторий да, курорт та кирәкми. Башта Мәлс Хәйриевич безгә жен булып күренгән иде. Ирләр кыйнарга да маташып карадылар бугай. Ә хәзер аннан да якын кеше юк. Ул килгәндә, иң артта сөйрәлгән совхоз хәзер беренче урынга менде. Бирмибез без аны сезгә!

Нуриев та, Арсланов та, берничә мәртәбә торып, сөйләшүне тәнкыйть юнәлешенә борырга тырышсалар да, бу барын чыкмады. Уннан артык коммунист чыгыш ясаганнан соң, Арслановның сүзсез ишарәсе буенча Нуриев фикер алышуларны туктатты. Жыелышны йомакчы булганнар иде дә, коммунистлар бердәм күтәрелеп:

—Үзенә ник сүз бирмисез? Әллә аның теле юкмы? Райкомда киселә кайтармагансыздыр бит?!—дип тавыш күтәрделәр.

Нуриев директорга сүз бирергә мәжбүр булды. Мәлска сөйләү кирәкми дә иде инде. Дөресрәге, аның сөйләрлек рәте юк иде: тамагына ниндидер кайнар нәрсә буалде, күзләре дымланды, аның бу халдә, йомшак булып күренәсе килмәде. Әмма сорагач, урынынан торып трибунага чыкты. Шактый вакыт сүз әйтә алмый азапланды, аның эчке халәтен залдагылар бик яхшы анладылар.

—Рәхмәт, иптәшләр...—Мәлс сүзен дәвам итә алмый торды.—Исән булсак, бергә-бергә эшлибез әле. Эшләргә язсын...

Бу жыелыштан Арсланов кыйнап ташланган кебек ватылып кайтты. Аның үзенең көчсезлегенә котырып ачуы килде. Ул шул кызудан Нәжмиевне, Әхмәтжановны, инструкторларны чакырып, йөрәге басылганчы сүктe. Башкаларны чыгарып жибәреп, Нәжмиев кенә калгач, катгый күрсәтмә бирде:

—Кәрәм Нәжмиевич, сүз Сабитов турында бармый, райкомның престижы хәл ителә. Шуна күрә Нәбиуллиннар белән киңәшеп, вәкилләр жыелышына чакырыласы кешеләрнең исемлеген төзегез, һәрберсе белән сөйләшеп чыгыгыз. Совхозда директор тарафыннан рәнжетелгән кешеләр дә бардыр бит инде.

Райком аппараты Нәжмиев житәкчелегендә тагын дүрт көн буе "Биектау"да эшләде. Вәкилләр жыелышына бу юлы Арсланов Нәжмиев белән Шәрифуллинны жибәрде. "Әгәр жыелыштан бюро карарын хуплатмасагыз, күземә дә күренмәгез!"—диде. Нәжмиев вәкилләр жыелышына ныклы ышаныч белән барды. Чөнки ул үзе генә дә алты кеше эзерләде, чыгышларын язып ук бирде. Аларның кайсы директор тарафыннан эштән куылган, кайсының акчасы киселгән, кайсы бүтәнчә

җәза алган кешеләр иде. Әмма җыелыш барышында аларның нибары икесе чыгыш ясый алды. Өченчесен мыскыллап трибуналдан ук куып төшерделәр. Моны күреп, калганнары башларын иеп, урыннарына сеңде. Ә директорны яклап сөйләүчеләр артканнан-арта бардылар. Нәбиуллин Нәҗмиев әзерләгән кешеләрнең калган өчесен исемләп трибунага чакырды. Аларның икесе сөйләүдән баш тартты, ә өченчесе—эштән куылган шофер, күп кыстый торгач, трибунага чыкты. Шадра битле, пеләш башлы, йөзе кына адәм иде бу.

—Менә ничә көннәрдән бирле директорны эштән алып атмакчы булып кылбырдык киләләр. Сәбәбе барыбызга да билгеле. Сез беткә ачу итеп, тунны утка якмакчы буласыз. Менә мин чакыргач чыктым. Мин аягы капкынга кысылган куян хәлендә: директор эчкән өчен эштән куды. Исерек көе мин аңа суктым, үтерәм, дип янадым. Әмма Сабитов мине милициягә дә тапшырмады, шау-шу да кубармады. Ә менә райкомнан килеп, әгәр ана каршы чыгыш ясамасан, жиназать эше ачтырып, судка бирәбез, дип куркыттылар. Мин ризалаштым. Аларның язган чыгышы минем кесәдә. Менә ул!—Шофер кесәсеннән Нәҗмиев әйтеп яздырган кәгазьне алып селкеде.—Төне буе йокламадым. Укый алмыйм мин бу кәгазьне. Лутчы судка биргез. Мин кызу кеше, мине "Дуамал Дәүли" дип йөртәләр. Башта Сабитовны бәреп үтерәсем килгән иде. Суынгач, уйлый-уйлый аптырадым: ничек түзде икән ул мина? Күпме араҗы эчелгән, исерек көе ничә мәртәбәләр ул мине тотып тиргәмәде... Жәзага да тартты. Шулай да мин бүген ана каршы сөйли алмыйм. Ул хаклы, мин гаепле. Сөйлисем килсә дә, сөйли алмыйм. Үзеneке төшмәсә дә, хатынының, балаларының рәнжеше төшәр.—Ул бераз тынып торды да, бөтен тәүдәсе белән президиумга борылып өстән куйды:—Аларның рәнжеше, иптәш Нәҗмиев, сезгә дә төшәр.

Инде мөмкин булганның барысы да эшләнеп беткән иде. Чигенүдән башка чара калмады. Вәкилләр жыелышы ябык дип белдерелде...

8

Нәҗмиев Чистай ягы мишәре булып, аларның нәселе авылда ин куәтле, озын гомерледәрдән санала иде. Кәрәм дә үзләренең шәжәрә агачында саргайган яфрак булып калмады. Әле аның моңа кадәр чир күргәне юк, тешләре исән-сау, егетләрдәй нык басып йөри. Ул теләсә нинди каты чикләвекне, жимеш төшләрен теше белән шарт-шорт вата. Гомер буе шатыр-шотыр итеп сенер, кимерчәк ашады. Итне яртылаш кына пешертте, каны чыгып торган ит, бавыр—аның ин яраткан ризыгы. Тавык ботларын ул тешләре белән тегермәндә тарткандай, бернинең дә калдырмыйча ваклап йота. Кулына килеп эләккән чәтрекле эшләрне, сындырасы кешеләрне дә Кәрәм кимерчәк урынына шатыр-шотыр чәйнәп кенә ташлады. Ә менә "Биектау"да күпме тырышып корган тозакның буш килеш калуы аның йөрәгенә сукты. Ул сытмаган шеш юк иде әле. Сабитов шундый шеш булып кала бирде.

Арсланов кайтып киткәч тә, ул бүлмәсендә шактый утырды. Авызына тәгам ризык та капмыйча, бер яртыны эчеп бетерә язды һәм, котырып ашыйсы килүен тойгач кына, райкомнан чыгып китте.

Ул кайтканда, хатыны Мәрзия күхняда өстәл әзерләп маташа иде. Иренең йөзен күрү белән, ул йодрыгын селкеп алды:

—Бер дә лыкынмыйча кайта алмыйсың. Әнә апаң килгән, теге якта утыра.

Бу сүзне ишетүгә, Кәрәмнең жене котырды. Аның апасы бөтен халыкка таныш Чукаева иде. Ул килсә, Кәрәм белән ике арада бара торган йөз еллык сугышның чираттагы ялкыны кабына. Кәрәмнең ачуын китереп, кайда очраса да, өйдә дә ул күл биреп күрешә. Әнә бүген дә ул аякларын белән идәнгә доп-доп басып килде дә бакадай салкын күлын биреп күрешкәндәй итте.

—Йә, коммунизм төзеп бетереп буламы? Хи-хи-хи!

Кәрәмнең аны ияк астына бәреп очырасы килде.

—Син эшләрәндә таркатып бетергәнсең бит. Әле һаман шуны рәтләп бетереп булмый,—диде ачу белән.

Мәрзия итле аш пешергән иде. Алар өчәүләп табынга утыргач, кунак хөрмәтенә ул бер ярты да чыгарды. Кәрәм, рюмкаларны тутырып, алар белән тәкәштерде, апасы белән бергәләп эчеп куйдылар. Ит артык нык пешкән, шуның өстенә ник бер кимерчәк, сенер булсын. Кәрәм авызына капкан итне, манный боткасы чәйнәгәндәй, казнасы белән бер-ике мәртәбә кыскалап йоткач, Гандәлифәнең үзенә һөҗүм башлавын көтте. Моны ул бер яклап теләмәде, икенче яклап шуны көтеп күнеле ярсыды. Ниһаять, Гандәлифә:

—"Биектау"да бик зур эш оештыргансыз, дип ишеттем,—диде, мыскыллы елмаеп.—Арслановның артын ялау рәхәтме соң?

—Әллә көнләшәсең?—диде Кәрәм кычкырып көлеп.

—Кирәге бар иде!

—Теленне сузып килсән дә, сине якын китерми шул ул.

—Ягез инде, ризыкның тәмен жибәреп утырмагыз әле,—диде Мәрзия, кашыгы белән тәлинкә читенә сугып куеп.

—Син аны гомергә якладың инде, килен. Тик бу кешене туктаусыз кыргычлап, сабынлап юып торырга кирәк.

Кәрәм, урыныннан кузгалып, өстенә плащын киде дә:

—Мин эштә булам,—дип өйдән чыгып китте.

—Бу хәлендә анда бармасаң да ярар иде инде,—диде Мәрзия һәм, аның артыннан ияреп, ишек төбенә чыкты.—Тагын бер генә грамм өстә, Арсановның өенә житәкләп алып барам. Аңладыңмы?!

—Мина синең күрсәтмәң кирәк түгел. Эшем муеннан.

—Мин аңлатып әйттем.—Мәрзиянең күз карашы үткен пычак очылай бер генә ялтырап алды.

Кәрәмнең ишекне шартлатып абуыннан болдыр түбәсендәге буяулар коелып төште. Эшенә барып, калган аракысын эчеп бетерергә уйлаган Кәрәм Нәҗмиевич хатынының үтлы карашы, кискен сүзләре тәэсирендә ул уен үзгәртергә мәҗбүр булды. Аның чыгып китүе бары тик апасы Гандәлифәне күрәсе килмәүдән генә иде. Урамнан бераз баргач, ул "Агрохимия" берләшмәсе территориясен аркылы чыкты һәм шуннан ерак түгел сазламык урында үсеп утырган зиреклекэк керде. Анда ясаган яй итү урынына утырып үз уйларына батты. Кешенең язмышын аның холкы хәл иткәнен ул күптән анлаган иде инде. Менә хәзер аны Мәрзия бәйдәге эт кебек тота, әз генә ярсып өрә башласа, шунда ук муенчагын кыса. Суеныйм дисә, чыбыркысы да кулында тына. Ә бит Кәрәм хатын-кызга баш бирер ир-егет идеме? Мондый көнгә төшәрмен, дип ул уена да китермәде. Казан янындагы бер районның райбашкарма рәисе урынбасары чакта ул беренче хатыны Гөлгенәгә өйләнде. Егет чагында ул хатын-кызлар арасында, урман кисүче агачның кайсын тели, шунысын сайлап аударган кебек йөрде. Гөлгенә искиткеч үзенчәлекле, чәчәк кебек нәфис, хыялый жан иде. Институт бетереп, әле яна гына мәктәпкә килгән бу кыз район сәхнәләрендә жырлый-бии башласа, үлгән кешенә дә жан кертә иде. Анын артыннан, әлбәттә, өере белән егетләр чапты. Әмма Кәрәм хәйләкәррәк булып чыкты. Ул Гөлгенә белән комсомолда эшләүче дустының фатирында көндезләрен очраша иде. Аның чәчәктәй нәфисленә, татар хатыннарына гына хас булганча, ир-атка сукырларча буйсынуын, тормышка соклануын, һәр нәрсәдән матурлык кына эзләвен күреп, эшне сузмыйча, Кәрәм өйләнергә тә куйды. Гөлгенә бу тормышка яраклашкан кеше түгел иде. Ул фәрештә кебек, күнеле белән йолдызлар арасында очып йөрде. Кәрәм, эченнән генә көлеп, аның янына шактый гына сәяркәләрен дә алып кайтты. Гөлгенә көнләшү, шикләну дигән нәрсәләрне бөтенләй белмәде. Ул Кәрәм юынганда сөлге тотып янында биеп торды, әз-мәз ихатада кыймылдаса, салкын әйрән, жимеш соклары белән сыйлады, мунчадан мәтрүшкә, юкә чәйләре сузып каршы алды. Кием-салымын үтүкләп, тиешле урынына

элде, командировкага китә башласа, икс-өч күлмәк, бөтен кирәк-ярагын салып, чемоданын күлына тоттырды, үбә-коча озатты, үбә-коча каршы алды, арып кайткан чакларында тас белән су алып килеп, аякларын юды, һәркөн шикәрдәй ак, үтүкләнгән жәймәле урынга яткырды. Ул шулай кыланган саен, Кәрәм азына барды. Аның пешергән ашларыннан гаеп тапты, "Ник тегелә итмәден, ник болай иттен?" дип бәйләнеп торды. Салып кайткач, сугып жибәргән чаклары да булды. Әмма Гөлгенә упкални дә, рәнжи дә белмәде. Сәяркәләреңен бөрәресен алып кайтса, хатыны күбәләк кебек очына-очына табын әзерләде, иренен күнагы итеп, аның бер алдына, бер артына төште. Кәрәмнең нишләптер мона ачуы чыга иде. Әллә инде ул сәяркәсе каршында хатынының шулай бөтерелүеннән көнләште— белмәссең. Шул үзе ияртен алып кайткан сәяркәләреннән ул Гөлгенәнен шикләнүен, көнләшүен, алар белән талашуын теләде. Әмма аның теләге кабул булмады. Бер жәйне, алар ул чакта Гөлгенә белән икс елдан артык яшәгәннәр иде инде, Кәрәм Мария исемле ялгыз хатынга азаланды. Хатынның мунчасы бик шәп иде. Йорт аулак урынды булганлыктан, Кәрәм хәтта көндезләрен дә аның янына баргалады. Сабантуйлар алдыннан Мария аны мунчага чакырды. Эш сәгате бетеп килгәндә, алар инде парлашып мунча кереләр иде. Бу хәлләрне аның кайбер сәяркәләре белеп торганнар. Берсе Гөлгенәне, кызык күрсәтәм, дип алып чыгып киткән һәм Мария йортына алып килгән. Алар келәне дә әлмәгәннәр иде. Мунча ишете ачылып китеп, Гөлгенәнең басып торганын күргәч, Кәрәм каушавыннан икс күлы белән гаурәтен капларга маташты. Гөлгенә, өнемне бу, төшемне дигәндәй, гажәпләндән зур булып ачылган күзләре белән сүзсез карап торды да йөгереп чыгып китте. Бу вакыйга көне-сәгате белән бөтен районга таралды. Кәрәм, Гөлгенәгә нинди генә әкиятләр уйлап чыгарып, нәрсәләр генә сойлаеса дә, ул аларны тыңламады. Икенче көнне иртүк туган кягына кайтып та китте. Кәрәм ана баш иеп, ничә мәртәбә баргандыр—хәтерләми. Гөлгенәне туганнары да үгетләп карады, ул бер сүз белән кисте: "Йермә, син мине белмисең, мин сине белмим". Кәрәмне аннан соң республиканың бөтенлөй икенче почмагына күчерделәр. Ул райкомның агитация һәм пропаганда бүлеге мөдире булып эшли башлады. Озакка сузмыйча, анда ул ашханә мөдире булып эшләүче инде акыл утыруткан кызга өйләнде. Аның һәрчак пөхтә киенүенә, сынар чәч бөртегенә кадәр сыланып яткан торуына мөкиббән киткән Кәрәм, өйләнешкәч, бу хатынның юбалгылыгына, шапшаклыгына хәйран калды. Юылмаган савыт-саба күхняда тау булып өелса, өйнен башка урыннары болгап катырылган кием-салым, чүпрәк-чапрак белән тулды. Өйне дә үзен кебек пөхтә тот, дип тәртипкә чакыруларның файдасы тимәгәч, кыйнап та карады, әмма кәкре кабырганы төзәтә алмады. Бердәнбер чара булып, аннан котылу калды. Ләкин корсагы борынына тия язган хатыннан ничек котылмак кирәк? Аның бәхетенә бала үле туды. Шуннан соң Кәрәм партия өлкә комитетыннан кая да булса күчерүләрен сорады. Аны Болынкырга райкомның өештыру бүлеге мөдире итеп жибәрделәр. Киткәндә хатыны Гөлгенә үзенә әйткән сүзләрне кабатлады: "Мине оныт, мин сине белмим, син мине белмисең",—диде.

Болынкырда ана өченче хатын буласы Мәрзия больницада терапевт булып эшли иде. Барган елны үк Кәрәмнен үпкәсе шеште, аның врачы Мәрзия булды. Ул искиткеч акыллы, тәртипле ярата торган кыз, терапия бүлеген житәкли иде. Биредәге тәртипкә Казаннан килгән зур врачлар да шаккатып киттеләр. Кәрәм больницадан чыгу белән Мәрзиягә тәкъдим ясады. Акыллы, тәртипле ярата торган врач дип йөргән Мәрзия, кияүгә чыккач, дилбегәне үз күлына алды. Хуҗалыктагы эшләргә дә, Кәрәмнекенә дә ул баш булды. Тормышта давыл кебек иреклә яшәргә өйрәнгән Кәрәмгә мондый нәрсә ничә тә ошамады. Алар һәркөн, нинди дә булса сәбәп чыгып, пычакка-пычак килделәр, кычкырыш-талашларда, кемнен хаклы булуына карамастан, соңгы сүзне Мәрзия әйтте. Моның шулай булуының сәбәбе дә бар иде: килеп эшли башлау белән Арсланов, Батталов, тагын бернече житәкче аерылмас компания булып өештылар. Йә туган көн, йә пленум

үткән, йә Казаннан кеше килгән—төрле сәбәпләр аркасында төрле урыннарда җыелышып, күнел ачулар бик ешаеп китте. Бервакыт үзәк авыл эшенә кунак булмәсендә сыйланып утырганда, ишек ачылып китте һәм анда Мәрзиянең ачулы йөзе күренде. Табында сүз бүленде, хәтта авызларына капкан ризыкларын чәйнәүдән туктап, барысы да аңа төбәлделәр. Мәрзия, утыручыларга берәм-берәм күз ташлап чыкканнан соң, кисәтүле тавыш белән:

—Иптәш Арсланов, әгәр тагын берәр мәртәбә мондый хәл кабатланса, мин турыдан-туры өлкә комитетының беренче секретарена чыгачакмын. Ул мине яхшы белә,—диде.

Сүзен әйтеп тә бетерде, озын өстәлнең ишек башындагы ашъуылучын эләктереп, көтөкчыч тизлек белән үзенә тартты. Табындагы шешәләр, бокалларга салынган соклар, аш, салат, котлет, шницель, балык ыыдыклары, чәнечке-калаклар, борыч-тозлар—бөтенесе шалтыр-шолтыр килеп, өстәл янында утыручыларның алларына коелды, идәнгә төшеп көл булды, түгелде.

Шушы хәлдән соң Мәрзия әлеге житәкчеләр өчен бүкәйгә әверелде. Кәрәм дә ничектер ана буйсына башлады. Шулай да алар һәр көн диярлек телгә киләләр, кызып-кызып әрепләшәләр, хатыны башлагач сүзнең төбенә тоз сипмичә, кемнең хаклы, кемнең хаксыз икәнлеген ачыкламыйча туктамый. Кәрәм юри ана каршы килә, үзенең хаксыз икәнен белсә дә, чата-кама килеп аклана, Мәрзияне гаепли.

—Син кеше түгел, иблистер, минем бөтен көчемне суырасың!—дип өзгәләнә хатыны.

"Әллә чыннан да шулай микән?"—дип тә уйлап куя Кәрәм. Эштә вакытта да кешеләр белән бәрелешкә керү, аларны үзе әйткәнгә күндерү, сындыру ана көч бирә. Максатына ирешүдән ул канәгатьләнү ала. Хатыны талаш-тарткалашлардан соң дарулар эчеп йөри, йоклый алмый газаплана. Икенче көнне ашамый-эчмичә, кәефсез хәлдә эшкә китә. Кәрәм исә, берни булмагандай, унсигез яшьлек егетләр төсле, эшенә дәртләнеп атлый.

...Зирек яфраклары селкетеп, сазламык исле җил чыкты. Нәҗмиев, башын артка ташлап, агачларга карап торды. Яфраклар шыбырдаша, ботаклар талпына, ә агачлар урынында. Үзгәртеп кору җилләренең әлегә беркемне дә аудара алганы юк. Тавышы, шыбырдавы күп, үзгәргән нәрсә күренми. Ә нигә үзгәрергә тиеш соң ул? Тормыш үзенең эзенә салынган, келтерәп бара бирсен. Нәҗмиевләр булганда, әле ул үзенең иске эзеннән дә бик әйбәт тәгәри. Ә бу үзгәртеп кору дигән нәмәстәкәй бүгенге житәкчеләрне аудару өчен чыгарылган кебек. Мәскәүнең сәясәте Кәрәм Нәҗмиевичка бик тә аңлаешлы. Ләкин аның тормышка үз аек карашы, үз сынамышлары бар. Ул сынамышларның әле беркайчан да аны ялгыштырганы юк.

Икенче көнне Арсланов белән киңәшкәннән соң, Нәҗмиев иртүк "Биектау"га юл тотты. Аның юл буе күңеле елап барды. Әллә аларга сиздермичә генә икенче төрле заман киләме? Үйлап карасаң, ышанырлык та түгел, вәкилләр жыелышында ин соңыннан чыгыш ясаган шофер Вагыйзов уен кәрте булырга тиеш иде. Аны Нәҗмиев партком бүлмәсенә керү белән дерелдәтеп бөтәреп алган иде.

—Син хәзер капкынга эләккән куян хәлендә,—диде ул ана, Сабитовка сугуын искә төшергәч.—Йә аны фаш итеп чыгыш ясыйсың, яки сина төрмә. Ничә ел икәнен әйтимме?

—Беләм,—диде Вагыйзов калтыранган тавыш белән.—Без бит директор белән килештек инде. Үткәнне нигә кузгатыргә ди.

—Кешенең үткәне гомер буе аягына чылбырлап куйган йөк кебек ияреп бара. Без аннан берничек тә котыла алмыйбыз.—Ул ана папкасыннан алып өч-дүрт кәгазь сузды.—Күрәсеңме, менә монда сезнең сугуыгызны карап торган шаһитларның аңлатмалары. Мин аларның иртәгә үк милициягә тапшырам һәм сезгә карата жиназять эше кузгатылачак. Ана кадәр партиядән чыгарачакбыз. Өч балагызга мәнге жүелмас кара тап.

Вагыйзов баскан урынында таптанды, кулларын кая куярга белмичә, бер өстәлгә таянды, бер кәсәсенә тыкты, аннары акрын гына:

—Ярый, чыгыш ясармын,—диде.

—Дөрес фикерлисең син, Вагыйзов. Капкынга эләккән куянны колагыннан тотып суялар...

Икенче куян—ветсанитар иде. Анын вакцинация ясамавы аркасында, совхозда дунгызлар кырылды. Белгеч агарынып, калтырана-калтырана чыгышын үзе язды, Нәҗмиев аның кайбер урыннарын гына көчәйтеп жибәрде. Аның әлеге ата коммунист белән ничекләр сөйләшкәнен искә дә аласы килмәде. Үз гомеренә кешеләрдә ялгышмаган Нәҗмиев бусында ничек абынды соң? Алар бит шундый ихлас күренделәр. Юк, монда һичшиксез Сабитов кулы уйнаган. Ул аларны ничек өркеткәндер, нәрсәләр вәгъдә иткәндер—анысы карангы. Әмма алар төн чыкканчы Нәҗмиевкә биргән вәгъдәләреннән кире кайтырга мәҗбүр ителгән булырга тиешләр.

Нәҗмиев совхоз дирекциясенә шундый уйлар белән килеп туктады. Ул килеп кергәндә, Мәлс бүлмәсендә утыра иде. Нәҗмиев телдән исәнләшсә дә, ана кул бирмәде, директор күрсәткән креслога да утырмады, читтәрәк торучы урындыкны сайлады.

—Йә, тантана итәбезме, Сабитов?

Мәлснын иөзеннән нур качкан иде. Монын сәбәбе—янәшә кишәрлектәге яңа икс сорт бодайның бергә кушылуы иде. Шуна күрә Нәҗмиевнын әлеге сүзләре йөрәгенә чәнчегән кебек тәэсир иттеләр.

—Сезнен бу энергиягезне эш өчен сарыф иткәндә, таулар күчереп булыр иде бит,—диде ул эченнән рәнжеп.—Инде дә тынычланмыйсызмыни?

—Бөтенесен син оештырдын,—диде Нәҗмиев ана таба борылып.—Гариханны яз да, тынычланырбыз.

—Нишләп мин гариза языйм? Әле минем күкрәп торган чагым. Менә алтмышны тутырып килүчеләргә ул хакта уйларга ярый,—дип төртгереп куйды ул Нәҗмиевка.

—Ә син бәс миенне юкка көчәндермә. Анысын аның югарыда утыручылар хәл итә. Әлегә райком теләгәннен бүлмый калганы юк. Энеңне Мәскәүдән кайтарып, партиядән чыгарып ташлаганны онытма.

—Мактанырга бик зур нәрсә тапкансыз икән. Анардан үч алдыгыз, хәзер миннән. Сез ни өчен күелган соң анда?

—Без партия линиясен алып барабыз. Мин сиңа дусларча әйтәм, Сабитов, партия эшендә зур тәжрибә тупланган карт бүре буларак әйтәм: акылына кил син, юкка тартышма, хуҗалык эшенен яртысы закон бозулар белән барганын без беләбез. Житәкче кешенең аның ике каш арасында рәшәткә тора. Аңладынмы?

—Ә мин рәшәткәдән дә курыкмыйм.

—Мин әйтәсемне әйттем,—диде Нәҗмиев урынныннан торып.—Саграк бул, Сабитов.

Нәҗмиев вәкарь белән генә атлап чыгып китте. Мәлс, тәрәзә турына барып, аның контора каршында басып торучы кешеләр белән күрешүен, елмаеп-көлеп, кайберләренең инбашларыннан кагып сөйләшүен хәйран калып карап торды.

Дәвамы киләсе санда

Фәрит Габдерәхим

ӘЙТИМ ӘЛЕ ЯРЫП ТУРЫДАН

Мин бәхетле бүген

Күңел күген яңа танышың
Болыт баскан—көне караңгы.
Үзем генә белгән юл белән
Гамәл кылдым—болыт таралды,—
Мин бәхетле бүген, бәхетле!

Сиздермәдем якыннарыма
Бәгыремне телгән ярамны.
Үтеп барган чакта урамнан
Елмаеп бер сабый карады,—
Мин бәхетле бүген, бәхетле!

Күрсәтмичә генә

Елый иде Әнкәй, күз яшьләрен
Безгә күрсәтмичә нигәдер.
Балаларда кансыз ил-дәүләткә
Нәфрәт уянмасын дигәндер.

Керә алмасам оҗмахка

Әйтсәләр дә: "Бәндәкәйләр
Хатадан хали түгел",
Нигәдер еш эчем поша,
Нигәдер сызлый күңел.

Фәрит ГАБДЕРӘХИМ (1933) – *Башкортстанда яшәүче татар шагыйре, башкорт һәм татар телләрендә дөнья күргән дистәдән артык китап авторы.*

Һаман хаталанам—димәк,
Бата барам гөнаһка.
Китәрбез: фани дөньяга
Килгәнбез тик кунакка.

Гөнаһсыз килә китәсем,
Мин генә торып калмам...
Керә алмасам оҗмахка,
Әнкәмне күрә алмам!..

Безне күралмаучыларга

Эзоп теле торып торсын әле,
Әйтим әле ярып турыдан.
Күпме ялган, күпме гайбәт сүзләр
Таратасыз татар турында.

Имеш, татар—"ышанычсыз кавем":
Сер чиштеңме—шундук әләкләр;
Төп башына бик тиз утыртачак,
Имеш, татар зерә хәйләкәр.

...Сезнекеләр, әлбәт, фәрештәләр,
Иң явызы—татар түрәсе.
Кышын кинәт яңгыр ява калса,
Кемнән булсын—бездән күрәсез.

Иртән башны төзәтергә акча
Булмаса да, татар гаепле.
Тышкы гариплек ул гаеп түгел,
Иң яманы—эчке гариплек.

Сез—бербөтен, безгә каршы бердәм,
Әйләнгәнсез бер җан, бер тәнгә.
Фараз итик әле: калмаган ди
Хәтта сыңар татар иртәгә.

Бердәмлектән сезнең җилләр исәр,
Мәхшәр кубар. Шуны белегез:
Без булмасак, бик тиз бетәчәксез,
Берегезне суеп берегез.

"Дошманыгыз" берләштерә сезне,
Рәхмәт әйтегез сез татарга.
Күралмаска түгел, кирәк аны
Күз карасы кебек сакларга!

Таллар

Каеннарны, имәннәрне
Давыл
Төбе-тамыры белән актарган.
Ай, афәрин! Таллар исән!
Таллар
Охшаганнар икән татарга...

Ташлар иде...

Җир сөргәрә вакыт тимәгәндәр:
Ил артыннан илләр яулады.
Ләх исерек килеш шул илләрнең
Мамык түшәгендә аунады.

Мантымасмы бераз, бөтәймәсме.
Шушы гадәтләрен ташласа?!
Ташлар иде... Ә шуннан соң кояш
Көнбатыштан чыга башласа?!

Оялмыйлар

Замана ычкынган чылбырдан.
Бәндәләр чыкканнар чыгырдан.
Мин-минлек. Көйдергеч карашлар.
Үтереш. Кычкырыш-талашлар.
Сандугач, бернигә карамый,
Төзәтә, яңарта оясын.
И сайрый, данлап үз оясын,
Җырларын һич тыңлап туймассың.
Бәндәләр чыкканнар чыгырдан,
Ник берсе кошчыктан оялсын...

Туу да, үлү дә

Иблис биетә заманны,
Көйли фәкать үз көен.
Туу да, үлү дә бүген
Тормый сукыр бер тиен.

Йомры баш

Бер йомры баш әйтте бүген,
Миннәндер инде көлеп:
—Бөтен халык бай булачак,
Фәкыйрьләр беткәч... үлеп.

Хәер сорап

Кызыл әләм... Кызыл сүзләр... Хәтта
Бәгырьләр дә тора кансырап.
Пьедесталдан кулын сузган Берәү—
Мал сорапмы, әллә җан сорап?!

...Төсләр бүген буталышып беткән,
Әләмнәр дә инде тузганнар.
Берәү түгел, меңнәр, хәер сорап,
Почмак саен кулын сузганнар.

Карт дәһли

Гайрәтле иде, тәвәккәл иде...
Аллагамы? Буламы соң инде,
Хакимнәргә генә башын иде,
"Тәмугъ та юк, оҗмах та юк!"—диде.

Карт дәһринең дәрт-фәрманы киткән,
Соңгы мизгел инде килеп җиткән.
Нидер сөйлә... Иренәре кипкән...
Ни сөйләсең—оҗмах өмет итә.

Килгәне юк

Күңелемдә бәйрәм, чын дусларым
Утырсалар бизәп түремне.
Дуслар килә. Тик шуларның берсе
Күптән инде, күптән күренми.

Ничә тапкыр туры килде аның
Бәгырь яраларын бәйләргә...
Елдан артык инде килгәне юк,
Тарымаган, димәк, бәлагә.

Нульләр

"Берләр" безгә "ноль" дип кенә карый,
Гарьлегеңнән ятып үлмәле.
Ә бит миллионнарның шул нульләрсез
Миллион булганнары юк әле.

Элекке

Туп тибеп уйный малайлар.
Чак-чак күшылып китмим.
Ә күшылсам — гаепмени?!
Элекке малай бит мин!

Чибәр кызлар очраганда
Чак-чак ияреп китмим.
Ә иярсәм—гаепмени?!
Элекке егет бит мин!

...Белмәдем битлек кигәнен,
Җирбиткә башым идем.
Куркам—әйтерләр шикелле:
"Ә элек кеше иде..."

Гомер көзе

Үтте язлар, үтте җәйләр,
Көз җиткән шул, көз инде.
Сандугачсыз, гөл-чәчәксез
Көзгә, җаным, түз инде.

Бакчамдагы алмаларның
Соңгылары өзелде.
Эч пошыргыч яңгыр ява,
Җанда кара көз инде.

Беркайчан да кабат килмәс,
Кабатланмас бу көзем.
Үпкәләмим мин аңарга:
Мин үзем көз, мин үзем.—
Юк бүтән әйтер сүзем!

Марат Кәбиров

ДҮРТЕНЧЕ ҮЛЧӘМ

ХИКӘЯ

—Телисеңме, хәзер айны кабызам!—диде ул, хатынын куенына ныграк кысып.

—Синме?! Айнымы?!

—Айны. Синең өчен генә!

Алар авылның каранғы урамы буйлап атлыйлар.

Ир аз гына салганрак иде.

—Менә кара,жаным!—диде ул, һәм кулларын һавага сузды.

Иренең хыялыйлыгын хатын белә иде.

Айнык чагында коры һәм салкын акыллы, эшлекле кеше булса да ире ярата белә һәм хатыны өчен бар нәрсәгә дә әзер иде. Ләкин ул айнык чагында сөю сүзләренә үтә дә саран, ялынып та аннан татлы сүзләр ишетермен димә. Гомеренә бер тапкыр да "яратам" дип әйткәне булмады. Юк инде, мондый нәзакәтлелек түгел, аның ягымлы йөзе, сөю чаткылары аз гына балкып киткән карашыннан башка берни күрмәссең. Болай итеп урам уртасында назлы кочаклап алулары турында сүз дә юк. Юк, көн булсынмы, төн булсынмы—урам уртасында ул сина мәнгегә дә хисен белдермәс.

Ә бүген...

Бүген ул салмыш иде.

Аз гына.

Аз гына авызына керсә дә ул хыялыйга әйләнә, ләкин урам уртасында түгел.

Ә бүген...

Бүген ул урам уртасында, хатынын кочаклап, юләр сатып кайта иде!..

—Нәрсә булды сиңа, жаным?

Хатын аңа ныграк елышты.

—Белмим...—диде ир, гаепле кеше сыманрак итеп.—Бүген... Әллә нинди көн...

Марат КӘБИРОВ *(1970)*—шагыйрь, прозаик. *"Онытма таңнарны", "Серләшик әле", "Күңелле табын"* исемле шигырь китаплары авторы. *"Сары йөртлар сере"* дигән повесте журналыбызның *2002* елгы *2* санында басылды. *Уфада яши.*

Хатын ана карап елмаеп куйды.
Ир дә кин елмайды.
Ул бәхетле иде.
—Телисенме, хәзер айны кабызам?!—диде ул тагын, хатынын назлы кысып.
Аның шушы сүзләреннән үк каранғы урам яктырып киткәндәй тоелды. Сирәк әйтелгән назлы сүзләрдән соң гел шулай була. Тик хатын сер бирмәде. Ул, уноч ел буе аның белән бергә яшәсә дә, үзенең саф горурлыгын югалтмаган, һәм шушы горурлыгының иренә дә нык ошавын белә иде.
—Синме? Айнымы?!—диде ул аны үчекләгәндәй.
—Айны! Синең өчен генә!
Ирнең дуамаллыгы хәрәкәтләренә үк бәреп чыкты.
Алар авылның каранғы урамы буйлап атлыйлар иде.
—Менә кара, жаным!...—диде ул һәм күлларын һавага сузды.
Аның хыялыйлыгын хатын белә иде.
Күлларын сузу белән генә бер нәрсә дә үзгәрмәячәген дә ул белә иде.
Ир бераз салган да иде. Тик ул күлларын күккә сузу белән дөнья яктырып китте. Хатын иректән һавага бакты. Болытлар арасыннан тулган ай чыгып килә иде.
—Бу синең өчен, жаным...
Хатын иренә сыенды.
Тик бу күләштерү өчен генә, ул иренең могҗизага сәләтле икәненә тамчы да ышанмый иде.
—Ә телисенме, мин синең өчен йолдызлар кабызам?—диде ир, малайларча бер ярсулык белән.
Хатын ялт итеп кенә күккә карап алды. Йолдыз әсәре күренми, тиз генә күренәчәге дә юк иде. Ул иренең кәефен төшерергә теләмәде.
—Юк, жаным... Ае да бик житкән...
Ир кинәт туктап калды.
—Ай гына житми. Ай ул ялгыз,—диде, битәрләгәндәй итеп.—Ә без икәү. Ике улыбыз бар. Аллаһы теләсә, оныкларыбыз да булыр.
Хатынның бу сүзләрдән күнеле тулып китте. Тик ул ирен, малайларча ярсулык белән кызып киткән ирен, унайсыз хәлдә калдырырга теләми иде:
—Ай ул берәү генә,—дип назлы елмайды.—Берәү генә. Мәхәббәт кебек.
Ә үзе тагын күккә карап алды. Йолдызларның сиздермичә генә болыт арасыннан чыгуын теләде. Тик йолдызлар аны аңламады.
Ир һаман үзенекен итте.
—Ай ул мәхәббәт түгел. Мәхәббәт ялгыз булмый,—диде ул, һәм хатынына каршы төшкәнлеген сизеп, өстәп куйды.—Ай мәхәббәт кебек икән, аның янында йолдызлары да балкырга тиеш. Йолдызсыз нинди мәхәббәт инде ул!
Хатын тагын күккә күз атты.
—Син бит мина яратам дип тә әйтмәдең,—диде ул сүзне икенчегә борырга теләп.—Үзем әйттем бит мин сина беренче тапкыр.
Ир аны тагын күенына кысты. Чәчләреннән генә үбеп алды.
—Яраткаңымны белмәсәң, әйтмәс идең...
Хатын үзе дә сизмәстән аның учларын кысып алды.
—Каян белергә тиеш идем соң мин аны? Синең белән?!.
Ир янә күккә карады.
Хатынның карашы да ниндидер өмет белән ана иярде.
—Сина аны йолдызлар әйтте,—диде ир, һәм күлларын һавага сузды,—кабынығыз, сөю йолдызлары!
Хатынның йөзеннән бер мизгелгә, үкенү шәүләсе узды, ләкин ул шундук гажәпләнү белән алышынды. Күктә чылап та бер-бер артлы йолдызлар кабына башлады һәм тиздән бөтен авыл якты нурга чумды.
Ир елмайды.
Хатын да елмайды. Тик аның күзләрендә гаҗәпләү очкыны сүнеп бетмәгән иде.
—Телисенме, мин аларны биетәм?—диде ир.

—Йолдызлар бии белми.

Һәм ир авыл урамын яңгыратып җыр сузып җибәрде. Хатыннын бу җырны ишеткәне юк иде.

—Кай арада өйрәндең син моны?—дип сорады ул, тик шунда ук моңга әсәрләнеп онытылды. Юк, моңга да әсәрләнмәде ул, иренең моны бик юк иде дә... Тик һавада йолдызлар бии иде. Алар үз биеклекләреннән төшеп, йортларнын кыегына тияр-тимәс булып әерелаләр, бер-берсенең нурларына күмелеп вальс әйләнәләр иде.

Йолдызлар бии иде!

Алар үзләре дә авыл урамы буйлап, йолдызларга кушылып биергә тотындылар. ...Дөнья тагы да яктырып китте.

Дөнья яктырып китте.

Әле төн уртасы гына булуга карамастан, бөтен тирә-юньдә әтәчләр уянып, сөрән салды.

Әтәч тавышына авыл картлары уянды. Киленнәр уянды.

Алар сыерларын савып, көтү куарга әзерләнделәр.

Ә урамда икәү бии иде.

—Нишләп йөрисез монда тилеләнеп! Карт юләрләр...—дип кычкырды кемдер.

Алар урам буендагы эскәмиягә барып утырдылар. Дөнья тынып калды. Йолдызлар сүнде.

Жирне тагын төн ялмады.

Ир елмайды.

—Нишләп йөрисез монда тилеләнеп! Карт юләрләр...—дип кычкырды ул, төн уртасында көтү куарга чыккан халыкка.

Кешеләр талгын гына йортларына шуды.

Урамда тынлык урнашты.

—Хәтерендәме,—диде ир,якындагы балалар бакчасына ымлап.—Без яшь чакта шунда йөри идек.

—Хәтеремдә,—диде хатын.—Без анда синең белән әбәкле уйный идек...

Иргә бу ошамады.

—Әбәкле генә уйнамый идек,—диде ул хыялга чумып,—анда мин сине беренче тапкыр үпкән идем.

—Синме? Минеме?!

—Сине!!!

Ирнең бу сүзе әллә ничек татлы булып тоелды һәм хатын иреннәрен очлайтып каршы төште:

—Бер дә хәтерләмим. Ничек итеп?!

Ир хәзер үбеп алырга тиеш иде. Тик ул үпкәләде.

—Шуны да хәтерләмәгәч инде...

Хатын тагы да назланды.

—Ә син искә төшер.

Һәм үзенең ник алай дип әйткәненә үкенеп куйды. Тик соң иде инде, ир аны назлы гына итеп бакча ягына әйдәде:

—Кереп чыгыйк әле. Яшьлек искә төшсен.

—Юк! Кермибез!

Элек аларның очрашу урыны булган балалар бакчасының, борын замандагы зират икәнлеге ачыкланып, хәзер анда төрле шомлы хәлләр булганлыгы турында сөйлиләр, шуңа күрә, бу урынны гашыйклар гына түгел, авылның алкашлары да урап үтә, ана берничек тә якын бармаска тырышалар иде.

Бу урында көндезләрен балалар уйнаса да, төннәрен өрәкләр йөри икән, алар кешеләргә зыян китерә, кемнәрнедер көчләп аракы эчертәләр, кемнәрнедер наркотик тартырга мәжбүр итәләр, ә кемнәрнедер бөтенләй кыйнап-гарипләп ташлыйлар, йә үз-үзенә кул салырга этәрәләр, дигән хәбәрләр бик күп иде. Хәтта шушы урыннан узып барышлый гына авырга калган яшь кызлар да очраштыргалый һәм алар йә ике башлы, йә сыңар аяклы балалар табып, шуларны роддомнарда калдырып китәргә мәжбүр булалар икән дип тә сөйлиләр иде...

—Кермибез!—дип кабатлады хатын.

—Курыкма.

Ирнең бу сүзе ничектер көчле булып, бөтен шик-шөһбәләрне таратырлык булып яңгырады һәм хатын ана юл куймыйча кала алмады. Шулай да ул жиңелчә калтырана иде.

—Өшисеңме әллә?—диде ир һәм хатынның ым кагуын күреп, ирен чите белән генә елмайды.—Телисеңме?..

Хатын бу шомлы урыннан тизрәк чыгып качудан башка бернәрсә дә теләми иде. Ләкин ул, бу хакта әйтеп, иренең кәефен кырудан курыкты да эндәшми калуны хуп күрде.

—Телисеңме, бу бакчаны ожмах итәм?

Хатын ана гажәпләнеп карады. Үзе нәрсә әйтергә дә белми азапланды. Ә ирнең күнеле күтәренке иде.

—Һәм яшьлеккә сине алып кайтам!

—Тиле син...—Хатын тагы нидер әйтмәкче иде, үзендә ниндидер үзгәреш тоеп туктап калды. Бер мизгелгә сулышы кысылды. Ир аны кинәт үбеп алды. Нәкъ теге вакыттагы сыман, беренче тапкыр үпкәндәге сыман итеп. Һәм хатын да нәкъ шул чакта кичергән хисләрне кичерде. Бер мизгелгә генә кайнар ирененә назына бирелде дә кинәт ычкынып, ирнең янагына тондырды. Усал итеп түгел, яратып кына, йоласын китерер өчен генә. Ә ир аның кечкенә учларын эләктереп алды да янагына кысты, бәхетле елмайды һәм хатынны кабат куенына алып үбәргә тотынды. Бу юлы назлы итеп. Күзәнәкләреннең тибрәнүен тоярлык итеп. Хатынның карышырга көче дә, теләге дә юк иде. Ул ләззәткә бирелеп күзләрен йомды.

Беренче үбешүнең дәнъяда бер нәрсә белән дә тиңләп булмаслык бәхетле мизгелләре мәнгелеккә сузылгандыр сыман тоелды. Йөрәк йә күкрәк читлегең вата да, йә үзе урталай ярыла инде—аның ярсуына чикләр юктыр сыман. Йөрәк кенәме соң, бөтен кан тамырлары, бөтен күзәнәкләр каядыр ашкына, бу бәхеткә чыдый алмыйча чәбәләнә. Әллә сөйгәненнең тәненә кушылып, бер жан, бер тән булып яшәргә телиләрме соң!..

Хатын елмаеп күзләрен ачты. Һәм гажәпләнүенә тончыгып катып калды. Үзенең кем белән үбешүен күрүдән ул кычкырып жибәрде, тик тавышы чыкмады. Куллары белән чәбәләнеп аның куеныннан котылырга теләде—буыннары тотмады.

—Курыкма,—диде таныш тавыш,—курыкма, кадерлем...

Һәм үзенә ныграк кысты. Нәзелле итеп. Гомер буе сагынырлык итеп.

—Курыкма, кадерлем,—дип кабатлады ул, елмая биребрәк.—Без яшьлеккә кайттык.

Шунда гына хатын үзендәге үзгәрешкә игътибар итте. Өстендәге ефәк күлмәгенә, аяк киеменә... Әйе, шул... Теге вакытта нәкъ шушы киемнәр белән чыккан иде бит ул сөйгәне янына. Димәк, ире генә түгел... Ул да... Ул да яшәргән!

Алар үзләренең яшьлегенә кайткан!

Кыз һәм Егет чакларына!

—Әбәк синдә...

Кыз көтмәгәндә килгән иласлек белән егетнең күкрәгенә сугып алды да торып йөгерде. Юк йөгермәде, очты ул. Сәю канатларында. Егет тә аннан калышмады, тик ул кызны шундук куып тотмады, жителәлмәгән булып кыланды, ә кыз челтерәп аккан чишмә тавышы белән аны үчекләгән булды:

—Тоталмыйсың мине! Тоталмыйсың!

Егет тизлеген арттырды да аны кочаклап алды. Бертын шулай туктала алмыйча көлешә-көлешә кочаклашып йөгерделәр дә еш-еш сулап пар каенга килеп сөялделәр. Бер-берсенең күзләренә карап тын калдылар.

Берчә, деньяны зәнгәрсу яктылыкка төреп, берчә ак болытлар арасына кереп тулы ай йөзә. Аның янында шатлык-куанычы күкрәгенә сыймаган балалардай йолдызлар биешә. Тирә-якта алма, шомырт, миләш агачлары хуш ис тарата. Иләс жилләр белән тәэсирләнеп яфраклар серләшә. Яшь үләннәр арасында бер-берсе белән үзышып чикерткәләр сайрый. Пар каен төбендә пар йөрәк тибә.

—Нәрсә уйлыйсың?
Егет дәшми.
Жавап итеп сөйгәненең учларын күкрәгенә кыса.
Тынлык.
—Йөрәгенә канат үсте мени... Ашкына ул шундый...
Егет дәшми.
Ул күзләрен кыздан ала алмый.
—Ник дәшмисең инде?..
—Сүзләр артык...
Кыз назлы елмая:
—Артык түгел... Якты сүзләр артык була алмый...
Мин яратам сине!
Мин яратам сине!
Мин яратам сине!
Егетнең тел очында тик шушы сүз генә әерелә.
Шушы сүзләр белән йөрәк тибә.
Тик ул дәшми.
Ул сөйгәнен куенына ала. Чиксез назлылык белән чәчләреннән сыйпый. Ул бәхетле.
Кыз да бәхет диңгезендә йөзә.
Һәм ул бер сүз көтә. Өзелеп көтә. Бары бер генә сүз.
Егет дәшми.
Һәм кыз тәвәккәлли:
—Мин... Яратам... Сине...
Шул сүз белән дөнья балкып китә. Бар җиһанны бәхет ялмап ала. Ай елмая. Ә йолдызлар тагы да дәртлерәк итеп, жиргә төшә язып бии башлый. Моң агыла. Чиксез сою моны...

—Рәхмәт сина, жаным!—диде хатын балалар бакчасыннан чыгып урам буйлап атлаганда,—барысы өчен дә...
Ир дәшмәде. Хатынның билендә яткан куллары назлы кысылып кына куйды. Ирененә татлы елмаю кунды.
—Ә син курыккан иден...—диде ул бераздан.
—Әллә нинди шомлы сүзләр сөйлиләр бит...
—Изге урын шомлы булмый ул. Күрәсеңме?
Хатын ул ымлаган якка карады. Балалар бакчасы өстендә генә ниндидер сихри яктылык таралган иде. Моны күрүдән күнелен рәхәтлек биләп алды.
—Мин яратам сине!—дип пышылдады ул, башын ирененә күкрәгенә салып.
Ир дәшмәде. Хатын, күзләре белән күрә алмаса да, аның сабыйларча шат елмаюын тойды. Шул елмаю сыман назлы куллар аның чәчләреннән сыйпады. Шушы елмаюга үрелеп бар дөньяга якты жыр таралды:
—Мин дә...
"Ул тагын яратам дип әйтмәде..."—дип уйлап алды хатын, якты бер моңсулык белән. Һәм елмаеп куйды. Ә жыр дәвам итте. Ул галәмнәрнең чиксез киңлеген урап кабат жиргә кайтты.
—Мин яратам сине!
—Мин дә...
Алар шушы жыр астында атладылар.
—Тиздән таң да ата,—диде ир.
Хатын ана елмаеп карады, тик шундук йөзеннән борчылу шәүләсе узды.
—Улларыбыз уянса? Курыкмаслар микән...
Һәм алар, балалар бакчасыннан кайткан ике сабый сыман, житәкләшеп өйләренә йөгерделәр.

КАНАТЛЫ КЕШЕ

ХИКӘЯ

Җәйге ямьле кичләрнең берсендә, шәһәр үзәгендәге гади генә бер йортның ишегалдында үскән бердәнбер кәрлә нарат күләгәсендә ир-егетләр сыра чөмерәләр иде. Бер подъездда озак еллар буена гомер итеп, бер-берсен яхшы белгән бу ирләр, атна азагында шулай җыелышып алалар да дөнья хәлләрен сөйләшеп, шатлык-кайгыларын, уй-хыялларын уртаклашып сыра уртлап вакыт үткәрәләр. Болар беткәнбаш ирләр түгел, һәркайсы үз өлкәсендә ниндидер дәрәҗәгә ирешкән, яшәү шартларын җайга салган, һәрберсенең тормышка гамәли карашы, күкрәк сугып "Мин!"—диярлек мөмкинлеге бар. Һәм моны алар үзләре дә белә, шуна күрә бер-берсен бик хөрмәт итәләр, вакыты белән сабыйларча ихласлыкка бирелеп, йөрәк серләрен дә ачып салалар, ул серләр нинди генә сәер булып тоелмасын, алар бер-берсе аңлый, кулыннан килгәнчә ярдәм итә. Кыскасы, болар күптәнге дуслар һәм бер-беренең язмышына битараф түгелләр.

Алар бишәү иде. Бишесе дә электән үк спорт белән шөгыльләнеп дәрәҗәләргә ирешкәннәр, кайберләре әле дә бу гамәлен ташламый, һәрвакыт формада булырга тырыша. Милиция майоры Нәжип бүген яшьләрне күл сузышына әйдәтә. Республика хастаханәсенең хирургы Шакир кыш буена чаңгыдан төшми, шахмат буенча спорт мастеры Азамат бу уенга бөтен дусларын да гашыйк итте. Әлекке авыр атлет Хөрмәт белән хәрби очучы Нуринның тына соңгы вакытта физик күнегүләр белән мавыкканы сизелми иде.

Тиздән Нури башка шәһәргә китте дә аның урынына Тәһир исемле бер адәм күчеп килде.

Юк... Дөресрәге, Нуриның фатиры берничә ай буена бикле торды. Анда керүче дә, чыгучы да булмады шикелле. Һәкъ шул көннәрдә Шакир, мул гына табын әзерләп, дусларын җыйды.

—Автомобиль фажигасенә эләккән берәүгә операция ясадым,—дип аңлатты ул моның сәбәбен.—Дөресен әйткәндә, яңадан җыйдым. Кулаяклары өзелгән, эчке органнары изелгән иде. Хатыны да, балалары да шундук һәлак булган.

—Үзенә әйттегезме соң? Гаиләсе турында...

Азаматның бу соравыннан хирургның күзләрендә газаплы очкын чагылып үтте.

—Юк,—диде ул, нокта куйгандай итеп.

—Үзенең тома ятим калганлыгын белгәч, ул сина рәнҗемәсме соң?—Монысын Хөрмәт әйтте.—Урыныннан торалмаслык гарип булып калса?! Япа-ялгыз килеш...

Хирург дәшмәде.

—Без кайчак гаеплеләрне үлем җәзасына тарттырабыз,—диде милиция майоры Нәжип, хөкем чыгаргандай итеп,—ә син аны—яшәү җәзасына...

Авыр тынлык урнашты.

Тынлык озакка сузылды. Әлеге таныш түгел кешенең язмышы турында уйланган дусларның берсе дә авыз ачып сүз әйтергә ашыкмады.

Бераздан хирург телгә килде:

—Бу хакта мин дә уйландым,—диде ул, гаеплә кеше төсләрәк,—ин кадерле кешеләрен югалтып, жаһына мәнге төзәлмәслек яра алган гарип адәмнең яшәвенә караганда үлеме хәерлерәк түгелме, дидем. Аннан соң, операция ә аллә ничшлы чыга, аллә юк бит әле. Шуларны уйлагач, мин аны үтерергә дә, дөресрәге, әҗәлгә ирек бирергә дә әзер идем.

Хирург авыр уйга чумып туктап калды.

Озак эндәшмәде.

—Ник шулай итмәдең соң?—диде Нәжип,—без сугышта өметсез яралыларны үзебез атып үтерә идек.

Һәм иптәшләренең йөзе үзгәреп китүен сизеп, акланган дәстә куйды:

—Алар моны үзләре үтенеп сорыйлар иде. Яшәү өмете юк икән, нигә кешенең гомерен сузып, газабын озайтырга?!.

Хирург дәшмәде.

Ул гомеренең бер өлешен Әфган сугышында үткәргән дустының сүзләре белән күпмедер дәрәҗәдә килешә, үзенең изгелекме, гөнаһмы эшләвен үзе дә белми иде. Һәм үлем күренындагы яралыны ни өчен яңадан терелтүен, яңадан жыюын да аңламый иде. Шул ук вакытта, ул бу гамәленең фантастик күренеш, мөмкин булмаган бер эш икәнен яхшы төшенә, һәм үзенең шушы эшкә алынуы, аны уңышлы башкарып чыгуы белән күңеленнән генә горурлана да иде.

—Ул һушына килдеме соң әле? Хәле ничек?

Азаматның бу соравыннан Шакир дертләп китте.

—Хәле ничек?..—дип кабатлады ул, әлеге сорауның авырлыгын үлчәп карагандай,—хәле ничек... Теге дөньядан кире кайтканнарның хәле ничек була?!.

Беркем дә дәшмәде.

—Сөйләшә алмый ул. Ишетми дә. Аяклары йөрми. Йөри дә алмаячак... Ә үзе исән. Фикере дөрес. Куллары яхшы хәрәкәтләнә. Түшәктә озак, бик озак ятачак әле.

Һәм хирург, күз иярмәс тизлек белән, алдындагы рюмканы киптереп куйды. Аннан соң кул сыртын белән авызын сөртеп алды. Аның чырае сытык, кашлары җимерелгән, керфек очларында ике тамчы ялтырый иде. Ул аларны сөртмәде. Чалбар кесәсеннән дүрткә бөкләнгән кәгазь кисәге тартып чыгарды да Азаматка сузды. Азамат дәфтәр биткә хәлсез куллар белән сызганланган кәкре-бөкре хәрефләргә текәлде.

—Кардиограмма кебек...—диде ул, аны барсына да күрсәтеп,—бер карасаң, чынлап та шул инде бу, кардиограмма—йөрәк тибеше.

—Йә, ходай...—дип куйды кемдер.

—Моны ул өч көн буена язды.—Шакирның тавышы һаман калтырый иде әле.—Һушына килгән саен берәр сызык өстәп куя иде. Күрәсең, гел шушы уй белән яшәгән. Ә сез ник коткардын дисез...

Барысы беравыздан кабатлады:

—Гафу ит, доктор.

—Гафу ит...—дип ирештерде хирург, жинелчә шелтә белән, һәм рюмкасын күтәреп чәкәштерергә сузды да теге кәгазьдә язылган сүзләрне укыды:

—Мин яшәргә телим!

—Мин яшәргә телим!—дип, беравыздан кабатлады табын һәм барысы да аягүрә басты.

Мин яшәргә телим!

Бу сүзләр йөрәкләрнең ин тирәненә кереп, кеше жанының яшерен көчләрен уятты да бар газапны жиңәр бер жыр булып кабат янгырады. Мин яшәргә телим!

Бу сүзләрдә кеше рухының кодрәтенә соклану да, үз бурычын гадел үтәүчегә рәхмәт хисләре дә, жинел уйлар белән ялгыш юлга төшкәннәрнең чиксез үкенече дә бар иде.

Мин яшәргә телим!

Рюмкаларны бушаткач, әлеге кәгазьне, изге бер мирас сыман кулдан кулга күчереп, яңадан карап чыктылар. Күнелләр чистарынып, яшәү дәрте артып киткәндәй булды. Аннан соң Шакир аны үзенә бирелгән ин кадерле бүләкләр саклана торган тартмага салып куйды.

—Яныма хәл белергә килүчеләр бармы сон?—дип сорады Хөрмәт.—Ялгызы тына ятмыймы?

—Юк,—Шакир янә рюмкаларга шәраб койды.—Ул бит монда күчеп кенә килгән булган. Дуслары да, туганнары да юк. Аннан соң, янына кеше кертерлек тә түгел әле.

—Әгәр ул үлеп китсә?..

Азаматның бу сүзеннән табын дертләп куйды. Әлеге таныш түгел кеше

алар өчен шул тиклем кадерлегә әверелгән иде инде, аны югалту турындагы уй үзе генә дә тирән кайгыга төшерә, йөрәкне уеп ала иде.

—Үлмәс!

Хирургның тирән ышаныч белән әйтелгән сүзе күнелләрне жылытып жибәрде. Тәрәзә артында караңгылык куера барса да дөнья яктырып киткәндәй булды.

—Ә аның исеме ничек?—дип сорады Нәжип.

Һәм аны барысы да күтәреп алды:

—Әйе, исеме ничек? Исеме...

—Тәһир,—диде хирург.

—Тәһир!—дип зур ихтирам белән кабатлады табын.—Тәһир...

—Без аны ташламаска тиеш,—диде Хөрмәт,—Тәһирга ярдәм итәргә тиешбез.

—Мин бүгеннән әзер. Ике куллап!

—Мин дә!

Күнелләрендә Тәһирга карата тирән ихтирам хисе булса да алар ничек ярдәм итәргә икәнен белмиләр иде әле. Шуна барысы да Шакирга төбәлде.

—Нәрсә эшләргә кирәген вакыты житкәч үзем әйтермен,—диде хирург. Дусларының бу теләге өчен сөенүе анын тавышына уң чыккан иде.—Әлегә барысы да Тәһирдан тора. Һәм миннән...

Тынлык урнашты.

Хирург янә рюмкага үрелде:

—Тәһир өчен!

—Тәһир өчен!—дип кабатлады табын, аягүрә басып, һәм бу сүзләрнең кайтавазы янгырады.—Яшәү өчен! Жинү өчен!

—Тәһирны якын күрүегезгә бик шатмын,—диде Шакир, рюмкаларны бушатып куйгач.—Чөнки ул безнең күршебез дә әле. Нури дустыбызның фатирын Тәһирлар гаиләсе сатып алган булган.

Мондый көтелмәгән хәбәрдән соң ни әйтергә белми катып калдылар. Тәһирның күрше булуы, ул гына да түгел, дуслары Нуриның фатирында яшәве аны күнелләргә тагы да якын итте.

—Менә шундый хәлләр...—дип куйды Шакир, иненнән авыр йөк төшкәндәй итеп...

Әлеге очрашудан соң байтак вакыт үтте. Тәһирга бер-бер артлы катлаулы операцияләр ясадылар. Яна дусларга анын янына барып йөрү әлегә рөхсәт ителмәсә дә алар читтә калырга теләмәде, кыйммәтле дарулар өчен һәрберсе кулыннан килгәнчә акча бирде. Һәм дуслар ихтирамы белән табиплар тырышлыгының нәтиҗәсе күзгә күренде—Тәһир тормышка кире кайтты. Аның колаклары кабат ишетә, күзләре янадан яхшы күрә башлады. Әлгәре хәлсез генә кыбырдаган куллары инде иркен хәрәкәтләр ясады, шул куллары ярдәмендә ул әйләнеп ятарга, ә соңрак торып утырырга да өйрәнде.

Тик ул һаман сөйләшми иде әле.

Докторның соравына ул керфекләрен сирпеп, соңрак инде баш кагып, яки кул хәрәкәтләре белән жавап бирде. Тора-бара алар арасында ым-ишарәләрдән генә торган үзенчәлекле аралашу хасил булды.

Ләкин бу телне Шакирдан башка беркем дә аңламады, шуна күрә төрле каршылыклар да килеп туды һәм хирург, үзе атна буе өйрәнгәннән соң, Тәһирга әпәләр алфавиты алып килде.

—Сина әлегә шушыны үзләштерергә туры килер,—диде ул.

Тәһир ашыкмый гына китапны актарып чыкты. Аннан соң мөлдерәмә күзләре белән хирургка текәлде. Әрнү дә, нәфрәт тә, үкенеч тә, үз хәле белән кызлегә теләмәү ачысы да тупланган бу карашлардан Шакир үзен таралып төшкәндәй хис итте. Ә Тәһир жан ачуы белән китапны атып бәрде. Бераздан ул гафу үтенгәндәй башын түбән иде. Телен чыгарып күрсәтте дә сораулы карашын Шакиргә төбәде.

—Юк, бу бары тик вакытлыча гына,—диде Шакир.

Тәһир ишаралән кәгазь белән ручка сорады һәм тиздән нәрсәдер язып Шакиргә тоттырды. Хирург үзе дә сизмәстән аны кычкырып укыды:

—Мин сөйләшергә телим!

—Мин сөйләшергә телим...—дип кабатлады ул, дуслары белән теге вакытта булган әңгәмәне искә алып.—Мин яшәргә телим.

Таһир чиксез өмет тулы карашлары белән аяусыз бораулый. Бу карашлардан берничек тә, беркая китеп тә котылып булмый, бу карашларга бары тик буйсынырга гына мөмкин иде.

—Син сөйләшәчәксең,—диде Шакир, үз-үзенә ныклы ышаныч белән. Болай дип әйтергә бернинди нигез булмаса да ул үз сүзләренең чынга ашачагына тамчы да шикләнми иде. Һәрхәлдә, әлеге мизгелдә.

—Син сөйләшәчәксең!

Таһир елмаеп куйды. Бу сабыйларча ихлас, шат һәм шул ук вакытта, үз көченә нык ышанган кешеләрчә тәкәббер дә елмаю иде. Син мине алдыйм дип уйлыйсыңмы, янәсе. Син мине юатасыңмы? Ә бит мин чынлап та сөйләшәчәкмен. Әле син мине белмисең... Мин сөйләшәчәкмен!

Икенче көнне кергәндә Таһир әпәләп телен өйрәнгән иде инде.

—Төне буе утны сүндермәде,—диде кизү торган шәфкать туташы.—Без ана сүз әйтергә кыймадык.

Таһир аны кин елмаеп каршы алды:

—Рәхмәт, доктор. Болай аралашуның да мөмкинлекләре күп икән. Рәхмәт.

Шакир дә шатлыклы елмайды.

—Без синең белән жырлашып утырачакбыз әле. Тик, аз гына көт син.

Бераздан Таһир уйчанланып калды. Һәм бармакларын уйнатырга тотынды:

—Ә ни өчен мина беркем дә килми?

—Әлегә ярамый,—Шакир күзләрен яшермәскә тырышты.

Тик Таһирга аныкъ жавап кирәк иде. Ул кабаланып ым-ишарәләр ясады һәм докторның аңламый калуын сизеп, әкеренрәк итеп тагын кабатлады:

—Алар исәнме?

—Әйе, исән-сау.

Шакир сүзнең кемнәр хакында баруын яхшы аңлый иде, әлбәттә. Ләкин ул авыруның соңгы өметен өзәргә теләмәде, "алар" дигәндә үзенең Таһирга ярдәм иткән дусларын күз алдына китерергә тырышты, шуна да жавабы бик ышанычлы чыкты.

Әмма Таһирның йөзен кара болыт каплады. Ул әрнүле нәфрәт белән докторга төбәлде. "Ай-най, егет..."—дигәндәй, башын чайкап куйды. Аннан соң бөтен тәне көзән жыергандай тартыша башлады, муен тамырлары кабарып, янаклары бүртенеп чыкты, битенә куе кызыллык йөгерде, күзләре тәгәрәп чыгардай булып түгәрәкләнде, мангай сырларыннан тир бөртекләре тәгәрәде.

—А-а-а... Ал-ллдды-ыйс-ссы-ын... Ал-дый-сың бб-ит.

Моны ишетүгә доктор, ачкан авызын ябарга да онытып, катып калды. Гажәпләнүдән аның күзләре акайды, чәчләре үрә торды.

Шул рәвешле озак вакыт үтте.

—Исән булса, ул мине күрми түзмәс иде,—диде Таһир. Сөйләшү ана зур авырлык белән бирелсә дә һәр сүзне ачык итеп әйтте.—Йә хат язар иде. Дөресен әйт, доктор. Мин түзәрмен.

Шакиргә инде сүз сөйләүнең хажәте юк, янаклары буйлап ике тасма агып төште, күксел төскә кергән иреннәре калтыранды.

—Доктор! Доктор! Шакир абый!..—дип кычкырды шәфкать туташы.

—Юк-юк, бар да тәртиптә!..—дигән тавыш ишетелде. Бу Шакирнең үз тавышы иде. Кинәт ул инендә кемнендер күлын тоеп дертләп китте. Таһирның күлы икән бит... Шакир буыннары йомшарудан аның караватына чүгәләгән икән.

—Бирешмик, доктор... Көчле булыйк, доктор...

Шакир, жине белән күз яшьләрен сөртеп, Таһирга карады.

Таһирның да күзләрендә яшь иде.

Аның бөтен гәүдәсе калтырана, ә иреннәре бары тик бер сүзне кабатлый:

—Бирешмик, доктор... Көчле булыйк, доктор...

Тиздән шприцлар тотып шәфкать туташы килеп житте...
Иртәгәсен алар бер-берсенең күзләренә карый алмадылар.
Шакир пациентның үз-үзен ничек хис итүе белән кызыксынды. Ул рәсмирәк булырга тырышты. Тәһир да бер сүз белән генә җавап бирде: "Әйбәт..."
Ләкин Шакир, үз эшенең остасы, Тәһирның шулай кинәт кенә теле ачылырга тиеш түгеллеген яхшы аңлый иде. Бу медицинада тине булмаган күренеш, моның буенча эзләнүләр алып барырга, ачышлар ясарга мөмкин. Тик әле боларның берсе дә аны кызыксындырмады, аның өчен бары тик Тәһирның аякка басуы, юк, аягына баса алмас инде—монысы бәхәссез, бары тик Тәһирның рухи бөтенлеген саклап калуы, кайгыларга бирелеп төшмәве, тормыштан өметен өзмәве мөһимрәк иде.
—Доктор, минем эчәсем килә.
Үзе дә сизмәстән Шакир аның күзләренә карады. Һәм барысын да аңлады.
Ярты сәгать үтүгә алар Тәһир яраткан "Белый аист"ның беренче рюмкасын тәкәштереп утыралар иде.
—Рәхмәт, доктор.
—Сина рәхмәт.
Эчеп куйдылар.
Коньяк тәннең бөтен күзәнәкләрен жылытып жибәрсә дә беркем бер сүз дәшмәде.
Шакир рюмкаларны тагын тутырды.
Тәһир, инендә яткан бар авырлык-газапларын күтәреп, торып утырды. Бер-берсенең күзләренә карап рюмкаларын күтәрделәр.
Тәкәштерергә суздылар.
Туктап калдылар.
Эчеп куйдылар.
Рюмкаларга таш тутырган кебек иде.
Бераз тын тордылар.
Һәркем үз уйлары белән мәшгуль, тик икесенең дә уе бер тирәдә иде.
Тагын эчтеләр.
—Синең гаиләң бармы?—диде Тәһир.
—Бер кызым, бер улым бар.
—Син бәхетле кеше.
Тынлык урнашты. Озын-озак тынлык. Хәер, тынлык микән?!.
Икесенең дә жанында давыл котыра, әгәр кешенең ихлас хисләре, үлгәннәрне терелтә, үткәннәрнең авыр фажигасен төзәтә ала икән, бу икәүнең тойгыларыннан барысы да үзгәрер, дөньяда газап-әрнүләргә бер урын да калмас, кешеләр кайгы-хәсрәтнең ни икәнен дә белми яшәрләр иде.
Кинәт Тәһирның йөзен кайгы күләгәсе каплады. Күзләре әрнү дингезенә әйләнде.
—Нигә мине үтермәдең, доктор?
Шакир уйга калды. Ул әллә нәрсәләр әйтергә, үзенең бу КЕШЕгә булган уй-хисләрен аңлатырга теләде һәм... Һәм бер сүз белән генә җавап бирде:
—Белмим.
Тагын тын калдылар.
—Доктор, аякларым йөри алачакмы?
Хирург дәшмәде.
—Димәк, юк?
Кинәт аның изүеннән алып жилтерәттеләр:
—Минем йөрисем килә, доктор. Аңлыйсыңмы? Мин йөрергә телим.—Тәһирның күзләрендә чиксез ихтыяр иде.
Ана каршы килү мөмкин түгел. Тик аның аякка басуы да ышандырмый—бу медицина кануннарына каршы килә торган гажәп бер хәл булыр иде.
—Син йөриячәксең!—диде доктор.—Син йөгереп йөриячәксең.
—Мин йөриячәкмен!—диде Тәһир, хыялый бер тантана белән—мин йөгереп йөриячәкмен.
Һәм ул кинәт аякларын идәнгә селкеп атты да торып басты. Аның

ашкынуын, аның теләген тыяр көч юк сыман иде. Ул ничәмә-ничә айлар буена хәрәкәтсез ятып, инде суына башлаган аякларында чайкалып беркавым басып торды һәм... һәм как идәнгә йөзтүбән барып төште.

Шакирнын йөрәге "жу" итеп куйды.

Таһир бермәл тынсыз ятты. Аннан соң кулларында күтәрелеп, торып утырды. Аның йөзе канга батса да иреннәрендә самими елмаю иде:

—Ярый, монысы башы гына әле,—диде ул, күзләрен очкынландырып,— монысы тәүге адым гына.

Тәүге адымнан соң икенчесе, аннан өченчесе, дүртенчесе, бишенчесе... Адымнар кабатланып кына торды. Адымнар арткан саен Таһирның йөзендә күтәрмәгән, яраланмаган бер урын калмады.

Шакирнын дуслары хәзер дәваханәгә еш йөри торган булып китте. Алар Таһир белән төрле кызыклы хәлләр турында сөйләште. Вакыт-вакыт сыра чөмерделәр, ә күбесенчә, яна күршеләреңең теләген үтәп, аның аякларын хәрәкәтләндерделәр, сәгатьләр буена, Таһирны шабыр тиргә батырып, арып егылганчы бүлмә буйлап йөрттеләр. Алар аяксызларны аякка бастыру турында төрле китаплар табып китерде, хәтта Кытайдан табип-остазлар да чакырдылар. Тик боларнын берсе дә ярдәм итмәде. Һәрхәлдә, күзгә күренерлек үзгәреш сизелмәде.

Көннәрнең берендә Таһир болай диде:

—Мин аякка баса алмам, доктор.

Шакир дәшмәде. Ул ни әйтергә дә белми иде.

—Мондый үеннардан туйдым, доктор. Минем ялгызымны калдырыгыз. Һәм яныма беркем килмәсен.

—Ярый,—дип ризалашты доктор. Аның башка чарасы юк иде.

Икенче көнне Таһир янына беркем дә килмәде.

Ул көне буе түшәмгә карап ятты. Күзләрендә чиксез моң иде.

Ә иртәгәсен хәл белергә кергәч, Шакир дертләп китте. Таһирның урынында сакал-мыекны бер ят кеше ята.

—Гафу итегез, доктор,—диде ул, Шакирнын агарынып китүен тоеп,— мин күрше палатадан, Таһир бер генә минутка коляскамны сорап торган иде... Әле булса килеп житми. Ул сезгә шушы конвертны тапшырырга кушты.

Шакир конвертны ачты.

Дәфтәр битендә бер генә жөмлә язылган иде: "Мин йөрергә телим".

Шакир озак кына сүзсез торды. Азак кул астындагыларга Таһирны эзләргә кушты. Тапмадылар.

Милиция эшкә жигелде.

Эзләделәр.

Юк.

Атна үтте.

Ай.

Юк.

Шакир да, аның дуслары да кара кайгыга батты. Кайсыдыр ягы белән әсир иткән бу кешенең шулай көтмәгәндә югалуы, бөтенләй юкка чыгуы аяныч тан да аяныч иде. Эзләмәгән жирләре калмады, аның фатир төбендә чиратлашып кизү тордылар. Әмма Таһир табылмады.

Ниһаять, Азаматның башына барып житте:

—Гаиләсе кайда жирләнгән?—диде ул бер көнне.

Нәжипнең ярдәме белән Таһирның гаиләсе кайда жирләнгәнен ачыкладылар һәм дуртесе бер булып шунда киттеләр.

—Әйе, монда коляска белән бер адәм килгән иде,—диде зиратны саклаучы карт.—Айдан артык инде чыкканы юк.

—Ник барып карамыйсыз соң?—диде Нәжип,—бәлки ул авыр хәлдәдер.

—Курыктым.

—Нәрсәсеннән?

—Ул сәер иде.

—Барыбер.

—Белмим...—Каравылчы бераз уйланып торды.—Ул бирешә торган түгел

кебек. Аның күзләре әллә нинди.

—Шулай да.

—Мин башта читтән күзәттем. Ул янәшә торган икс каберне кочаклап слады. Көне буе, төне буе... Аннан соң... Аннан соң... Белмим... Каберләр үрдәрәк бит... Ә кичә коляскасы тәгәрәп төште.

—Коляскасы?!—диделәр бар да бер тавыштан.

—Әйе. Мин курыктым. Элек тә курка идем. Беләсезме, ул нәрсә диде?! Ул болай диде: "Мин сина атлап киләчәкмен!"—диде. Шуннан бирле керфек какканым юк. Йоклап китсәм, мәетләрнең аяк тавышын ишетеп уянам.

Дуслар инде каберлек янына барырга жыенганнар иде. Тик каравылчы гына ул якка барырга теләмәде. Аны төрлечә үгетләп карадылар:

—Нинди чирләрең бар—дәваланырга ярдәм итәбез?..

—Башыңны төрмәдә черетәм...

—Юк, теләсә нишләтегез! Мин күркам.

Кинәт якында гына үлән кыштырдавы ишетелде. Барысы да тынып калды.

—Мин сина атлап килергә вәгъдә биргән идем,—диде таныш тавыш.—Мин киләм! Мин атлап киләм!

—Минем бер гаебем дә юк,—диде каравылчы, дерелдәвек тавыш белән,—зинһар мина тимә!

—Ха-ха-ха!

Хәтта Шакирның да тәне эсселе-суыклы булып китте, бала жоннары кабарып чыкты.

—Син миңнән курыкма! Мин—гади кеше! Юк, мин—гали кеше. Чөнки атлый алам. Йори, йөгерә алам. Мин—чын кеше!

—Тәһир!—диде хирург.

—Доктор!

—Тәһир...

—Доктор, рәхмәт сина!—тиздән Тәһир үзе дә күренде. Ул, бернәрсә булмагандай, аяклары нда басып тора иде.

—Рәхмәт сезгә, дусларым... Рәхмәт сезгә...

Дуслар бер-берсенә карашып алды. Алар горур иде. Бигрәк тә Шакир. Аның керфекләреннән тәгәрәгән ишь бөртекләре һәм иреннәренә күнган елмаю бу мизгелдә ничектер килешеп, бер-берсен тулыландырып тора иде.

Шуннан соң алар йөрешеп, күрешеп, хәллəр белешеп яшəр булдылар. Һəр жомга саен жыелып, кышларын берəр кафега кереп, ə жəйлəрен ишегалдында үскән бердәнбер кәрлə нарат күләгəсендə дөнья хəллəрен сөйләшеп, үй-хыялларын бүлешеп сыра чөмереп гомер үткəрəрлəр иде. Әнә шундый кичләрнең берсендə Тәһир әйтеп куйды:

—Егетләр, ə мин очарга телим!

Егетләр, иреннəренə тидергән бокалларын уртларга да онытып, катып калды.

Аның сүзләрен уенга алыргамы, əллə чынгамы?

Шакир Тәһирның күзләренə карады да гажəплəнүдəн кулындагы бокалын төшереп жибəрде.

Озак кына дəшми торды.

Башкалар да бер сүз əйтмəде.

—Син очачаксын!—диде Шакир аннан соң.—Син, мотлак, очачаксын!

Бу сүзләре бөтен кануннарга каршы килүен белсə дə, хəзер ул Тәһирга ышана, аның канатларын жилпеп шушы йортлар өстеннән үтə алуына тамчы да шикләнми иде.

Шушы сөйләшүдə соң күп вакыт узды. Тәһир башкача күзгə күренмəде. Аны фатирыннан да, эш урыныннан да, гаиләсе зиратыннан да тапмадылар.

Һəркайсы үз өлкəсендə ниндидер дəрəжəгə ирешкəн, яшəү шартларын жайга салган, һəрберсенең күкрəк сугыш "Мин!" диярлек мөмкинлеге булган гамəли карашлы асыл ирлəр бергə жыелгач, үзləре дə сизмəстəн, вакыт-вакыт һавага карап алалар да күзләрендə чиксез сагыш, сүрелмəс өмет балкып китə иде.

Фәйрүзә Исмәгыйлева

ЯШӘҮ ДИГӘН ЯКТЫ АЛАН

***

Бокалдагы затлы шәрабне
Сузарсың кулыма сак кына,
Бармак очларыңдагы наздан
Башларым әйләнә чак кына.

Иреннәрем сиңең күзләрне
Иркәләп үпкәндә сак кына,
Бәрелер дә кайнар сулышлар,
Бүлмәләр әйләнер чак кына.

Төн пәрдәсен ябып иңнәргә,
Сыенганда сиңа сак кына,
Кабатланмас татлы хисләрдән
Бу дөнья чайкалыр чак кына.

Бу сөюнең сихри вальсына
Җиребез әйләнер сак кына.
Икәү генә калып дөньяда
Онытылыйк әле чак кына.

***

Әллә ниләр булды миңа, белмим —
Син гаеплә мине, ачулан:
Синең рухың иңгән дөньямда
Көзге чәчәк булып ачылам.

Беләм, тажларымны кояр карлар,
Гөнаһлы күңелне тиргәрләр.
Ә бүтенгә рәхмәт: миңа сине —
Газаплы сөюне биргәннәр.

Алда — диңгез, соңгы сөю бу,
Сак кына чайкала җилкәннәр.
Иләсләнеп шушы халәттән,
Фәрештәләр бии җилкәмдә!

Фәйрүзә ИСМӘГЫЙЛЕВА — *шагыйрә, «Жанымда яз рәсеме» исемле китап авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Азнакай районында яши.*

Сүнәр хисләр, янар-янар да...
Бу көзләр дә бик тиз узачак.
Тик күңелдә калыр мәңгегә
Көзге чәчәк булган гүзәл чак.

Мәңгелек ишеге катында
Фәрештәләр мине аклардар.
Язык түгел ул ярату, дип,
Күкләрем каршында яклардар...

***

Көйле генә бармый шул бу тормыш:
Әбе килсә, җәбе юк аның.
Бәгырьләрне теләр мизгел бар —
Кайчагында яме юк аның.

Ярый әле җанда дога бар,
Юар өчен күздә яшьләр бар.
Юа-юа кара төсләрне,
Башкайларда ап-ак чәчләр бар.

***

Алдагысын Алла белә.
Әбием сүзләре

Язмышым рәсемен ясадым
Бай төсләрен алып хыялның.
Алдагы көннең һәр мизгелен
Иң ачык төсләргә буядым.

Куйдым да тәрәзә төбемә
Тынычлап йөрдем мин. Ә рәсем—
Чыланган яңгырга... Җил белән
Ачылып киткән дә тәрәзем.

Буяулар томанлы — кушылган,
Тапланган ап-ачык рәсемем.
...Шуннан соң ясамас булдым мин
Туачак көннәрнең рәсемен...

***

—Әбкәм, минем чибәр буласым килә!
Борыным—тегеләй, күзем—болай...
—Әй, кызым, тышкысы нигә аның,
Эчкәсенне матур итсен Ходай!

—Пычагымамыни синең "эчең"?
Аны инде, йә, эйтче, кем күрә?!
...Дәшми әбкәм. Уйларына чумган да,
Тасмалап, тузган чәчемне үрә...

...Тузган уйларны үргән икән ул—
Әбкәм сүзләре гел терәк булды.
...Эчке матурлыкларны тояр өчен
Шушы яшькә җитү кирәк булды!..

Ленар Шәехов

ҖАНДА—БЕР ЧӘЧӘК...

Мәктәптә укучы яшь иҗатчылар белән озак елларҙ эшләүче буларак, миңа шуныҫы билгеле: шиғырь язучыларның 90 процентыннан артығы — ҡыҙлар. Бигрәк тә соңғы елларҙа!

Ниһаять, Ғәмил Афзалны тыуырған Актаныш районыннан бер егет шиғриәтһеҙ ишеген ҡыуҫыз ғына шаҡыды. Тактала чыкта тыуып, Минзәлә педагогия көллиәтен тамамлаған оялчан бу егәттең шиғырҙәрен балалар матбуғатында ныҡ ҡарағанһын соң, мин аны Ҡазанға — университетҡа укырға чақырҙым. Ленар Шәехов хәҙер татар филологияһе факультетының 2 курс студенты, тел-әҙәбиәт түңәрәгенең үҙәгендә ҡайнай. Балалар өсөн шиғырҙар китабын әҙерләп, нәшриәтҡа тапшырҙы; лирик һәм сатирик шиғырҙәре әҙ матбуғатта күренә килде. Беренсе кат "Ҡазан утлары" журналына тәҡдим итеп, ышанып, Ленарға ҡыуанып, үҫеү һәм хәерле юл телим.

Илдар ЮЗЕЕВ.

***

Сине күргән саен ҙанда
Бер шиғырь бөрәлһә.
Тамҡы ғына булған шатлыҡ
Зурая, эреләһә.

Ҡилкәмһәң тау төшеп китә,
Ҡауырыйҙай ҡыңғылайам.
Ҡысыла бөтен көсөнә,
Тартыла күңел ҙәйәм.

Шул чағында кош шикелле,
Эх, бер очасы килә.
Сәю тулы яшьләремә
Нидер күшасы килә...

...Сине күргән саен ҙанда
Бер чәчәк бәреп чыға.
Гөлчәчәктәргә төренеп,
Шиғырь ияреп чыға.

Сала теле

Кала теле түгелсең син—
Сала теле,
И бүленмәс һәм сер бирмәс
Ана телем!

...Сабыйларың урыс теле
Кочағында.
Кара бөркет үҙ нотыңын
Куша монда.

Ялғыз калған Робинзондай
Бүтен хәлең.

Кая синең горурлығың
Һәм мөнбәрең?..

Кая синең күкрәк киереп
Йөргән чағың?..
Кая синең төркилегең?..
Кая чаңың?..

..."Әннә",—диеп ачылмаса
Сабый теле,
Киләчәктә кем аңлар соң,
Телем, сине?..

***

Әтиең дә, әниең дә
Зарыгып көткән.
Ябалак карга ияреп,
Төшкәнсең күктән.

Саф кыш ихлас күңеленә
Аклыгын түккән...
Ҳыял гөленә уралып
Йөрдең син күптән...

Күзләреңнән әллә инде
Йолдызлар үпкән.
Алсу битләреңә гүя
Ай нурын сөрткән.

Ак карларны уйнатучы
Тормыш-җил икән.
Күңелгә кунды ап-ак кар—
Ул кар син икән...

***

Сары сагышлар сарыды—
Саргаеп үләм, ахры...
Исемең — гамьнән йолучы
Бердәнбер сүрәм, ахры...

***

Төн саен ачып керәсең
Ак төшләремнең келәсен...

***

Син якын-тирәдә,
Мин күрше бүлмәдә.
Арада ялгызы
Йөрәгем тирбәлә.

Халәт

Интегергә килгәнмендер җиргә,
Җәфа чигәр өчен туганмындыр.
Урмандагы сары сагыш төргән
Каеннарга, бәлкем, туганмындыр...

Кайрыларым минем киртек-киртек,
Яралардан саркый сөю каны.
Беренче кар яугач, сөртеп алыр,
Суык назлар иркәләрләр аны.

Тамырымда кайгы үзе ята,
Еламсырлык куңган иңнәремә.
Башны куям, йөрәгемне ачам
Көзнең шаян моңсу җилләренә.

Күңелемдә минем әллә нәрсә,
Сары яфрак белән тулган сыман.
Урмандагы тирән уйга чумган
Гамьле каен миңа туган сыман.



Мирза Мәхмүтов

МӘГЪЛҮМАТИ КӨРӘШТӘ МӘДӘНИЛЕК

Кереш

Дөньякүләм мәгълүматилек элек бер-берсеннән аерым яшәгән халыкларны якынайтып, кешелек тарихы турындагы белемнәрне киңәйтеп җибәрде. Шул ук вакытта ул галимнәр һәм каләм ияләре кебек зыялыларда шөбһәләну-борчылу да тудырды: кешелеккә ачлык, төрле авыруларның киң таралуы, экологик, техногеник, атом-төш һәлакәтләре ише куркынычлар яный башлады. Шулар арасына хәзер халыкара террорчылык та килеп керде. Кешелек дөньясы әллә «ахырзаманга» таба атлыймы соң? Бу хәлләрдән чыгу юлы юк микәнни?

Чыгу юлын төрле мәдәниятләрнең үзара аралашуында, цивилизацияләрнең фикер алышу-сөйләшүләрендә күрәләр. Мәдәниятләрнең күптөрлелеге шартларында, бу мәсьәләләрне сәяси ысуллар аша хәл итү белән бергә, милләтләр һәм диннәр арасында сөйләшү-килешүләрнең дә зур әһәмияте булырга тиешлеге шиксез. Әмма шундый сөйләшүләр алып барырга тырышулар байтактан булса да, файдалы-нәтиҗәле килешүләргә ирешү өчен, күрәсең, әлегә тиешле шартлар өлгереп җитмәгәндер. Мәдәниятләрнең үзара аралашуы—ул икенче бер кешенең, икенче бер халыкның, икенче бер дәүләтнең мәдәнилеген белү-үзләштерү дигән сүз. Шул рәвешле без башкаларны аның тәрҗемәи хәле, әйткән фикерләре, үз-үзен тотышы аркылы өйрәнәбез.

Әмма кәнбатыш илләре, халыкара террорчылыкны сылтау итеп, башка халыклар турында тузга язмаган хәбәрләр тарата, ислам дөньясына, шәрекъ цивилизациясенә каршы мәгълүмати суғыш алып бара. Кайбер илләрдә милли сәясәт башка милләтләрнең милли хәрәкәтен тыярга, милли мәдәниятләрен кысарга юнәлтелә. «Дошман образын» булдыруның традицион сәясәте массакүләм мәгълүмат чараларында һәм мәгариф өлкәсендә һаман дәвам итә. Дөньякүләм яктан ул—мөселман кешесе, ә аерым илләрдә—йә «кавказ милләтле кеше, йә «урыс оккупанты» (Латвия), йәки «террорчы, «боевик» һәм башкалар. Дөньядагы вәзгыять хәзер менә шундыйрак.

Исламны нәрсәдә гаеплиләр соң? Сәяси явызлыкта, көнбатышка һәм христианлыкка каршы суғыш алып баруда, Европаны миграция һәм демографик шартлау, яғыни башка милләт халыкларын шунда күплән күчерү һәм үрчетү юлы белән басып алуда һәм ин мәһиме—мәдәнилеге булмауда гаеплиләр.

Татарларны нәрсәдә гаеплиләр? Сәяси үҗәтлектә (суверенитет-бәйсезлек талән итү). Россия тарихы дәреслекләрендә татарларны Рәсәйгә әхлаксызлык, явызлык, мәкерлелек кебек начарлыклар йөктыруда гаеплиләп,«урыс кешесенең тискәре сыйфатлары шуннан килә, татарлар «кыргый күчмә халык» һәм урыс мәдәниятенә бернинди әлеш тә кертмәгәннәр» диген төрле сафсаталар языла.

Әлекке катып калган фикерләрдән арынмыйча, һәр халыкның үзенчәлекле милли мәдәниятә хокукы барлыгын танымый торганда, мәдәниятләрнең үзара аралашуы-килешүе мөмкин түгеллеге көн кебек ачык. Бернинди дәлилләрсез башка мәдәниятләрне инкяр иткәндә кешеләр үзара дуслыкка һәм бер-берләре белән аралашу-аңлашуга психологик яктан әзер булмаячаклар.

Безнең бурыч—дәлилсез гаепләүләрнең нигезсезлеген һәм хаксызлыгын ачып салу, мәдәниятләрнең дөнья күләмендә һәм аерым илләр дәрәҗәсендә үзара аралашу юлларын күрсәтү булырга тиеш.

Көнбатыштагы исламофобия

Исламофобия—ул исламны дошман күрү дигән сүз.

Колониализм чорыннан ук Көнбатыш илләрендәге күп кешеләрнең аңында «башкалар» турында «өлгерәп җитмәгән халыклар", аңнары һәм мәдәниятләре бик түбән дигән фикер калган. Әлекке колонияләр һәм метрополияләр, яғыни аларны басып алган илләр арасындагы сәяси һәм икътисади каршылыклар, әгәр дә хәл ителә калса да, бары тик көч куллану алымнары—Көнбатышның империалистик сәясәтеннән риза булмаган, аның белән килешмәгәннәрне суғышлы буйсындыру, икътисади басып алу, идеологик басым ясау юлы белән генә хәл ителә.

Исламга каршы пропаганда халыкларны кимсетү-рәнҗетүнең һәртөрле формаларын файдаланучы барлык массакүләм мәгълүмат чаралары аша алып барыла. Мәсәлән, 2003 елның октябрь аенда гына да хәтта Россия телеэкраннарында ярлы илләрдәге мәселманнарның хәерче-мескен тормышларына кирәгеннән артык мәгътибар иткән ике чит ил фильмы күрсәтелде. Америка массакүләм мәгълүмат чараларында исламга каршы алып барылган пропаганданы гомумиләштерәп, америкалы Хью Фицжеральд зур мәкалә язып бастырган ("Звезда Поволжья» ("Идел буе йолдызы") журналы, NN 30-34, июль-август, 2003 ел, инглизчәдән тәрҗемә). Автор ул мәкаләсендә, көнбатышның тар карашлы обывательләрен куркытып, мәселманнар бөтен дөньяны яулап алырга, сезне бай-мул тормыштан мәхрүм итәргә омтыла, дип лаф ора. Әгәр дә «башка» халыкларга карата шовенистик мәнәсәбәт тудырырга телиселәр, расачылар гадәттә ул «башкаланың» мәдәниятен мәсхәрәләүмыскыллап сөйләүден башлыйлар. Шул ук америкалы журналист Хью Фицжеральд, мәселманнарны мәсхәрәләргә тырышып, аларның мәдәнияте бөтенләй юклыгын расламакчы була: «Төрле мәнфәгатьләре булган белемле, ирекле Көнбатыш кешесенә мәселман дөньясында яшәү үлемгә тиң,—дип яза ул. Һәм болай дәвам ите: «...каллиграфия һәм мәчетләрдән кала анда сәнгать юк; әлбәттә инде сынлы сәнгать һәм кеше сурәтен ясау катгый тыелган; әдәбият юк, асылда музыка да юк: Луи Армстронг, Бах, Моцартлар юк та юк, анда бернәрсә дә юк, җенесләрнең тигезлеге дә юк, секска ниндидер сәер, авыруларча мөнәсәбәт... юмор хисенең бөтенләй булмавы гына бар» ("Политические аспекты ислама» ("Исламның сәяси аспектлары"), инглизчәдән тәрҗемә. «Звезда Поволжья", N 32, 2003.). Көнбатыш мәдәниятенең

өстенләген Хью тарихи фактларны бозып күрсәтү яки аларны инкяр итү юлы белән исбатламакчы була. Бу мәсьәләгә кыскача тукталып үзыйк. Мәдәният киң колачлы мәгънәгә ия. Аны үткәнгә һәм хәзергегә бүлеп карарга киреәкми, ул өзлексез үсештә, буыннан-буынга күчеп килә, әгәр дә «ахырзаман» булып, дөнья бетмәсә, һәрвакыт өметле. Кайдадыр тамырлары, традицияләре булмаса, мәдәният берьяклырак юнәлештә үсә, америкалылардагы техноген мәдәният шундыйлардан. Дөнья мәдәнияте хәзер фән, телевидение, масскүләм мәгълүмат чаралары, әдәбият, сәнгать, кешеләрнең үзара аралашулары әркасында бербөтен булып карала. Фәннең, фанни фикерләрнең нигезләре Мессопотамия, Кытай, Һиндстан, Мисыр, Фарси, Грек (Юнан), Рим кебек ил-дәүләтләрнең борынгы цивилизацияләрендә үк салынган. Гарәп-мөселман цивилизациясе (VI-XVII гасырлар) шуларның варисы, дәвам итүчесе буларак үскән, тәрәккый иткән. Бик күпләр шәрекъ халыклары мәдәнияте турында аларның хәзерге халәте бүенча гына фикер йөртә, Шәрекънең кешелек цивилизациясе бишеге булганлыгын күз алдына да китерә алмый.

Әйткәнебезчә, европа тарихының «караңгы гасырлары» дип йөртелә торган чорлары да булган, ул дәвердә дин көчем сөргән, дөньяви һөнәрсә кире кагылган, чиге булмаган (V-X гасырлар). Моннан мең ел элек Кытайда халыкның егерме проценты укый-яза белгән, ә шул ук дәвердә Европада андыйлар бары тик бер-ике процент кына төшкил иткән. Бу—мәдәниятнең иң түбән тәгәрәгән чоры, бары тик монастырьларда диннең генә үсеше күренә, хәтта дөньяви византия мәдәнияте дә Европага үтеп керә алмаган.

Европа мәдәнияте кайдан башлана соң? Дини христианлыктан гына түгел, әлбәттә. Европалылар тәре походларыннан гарәп телендәге бик күп китаплар алып кайтканнар һәм аларны латинчага тәрҗемә иткәннәр. Алар арасында Аристотель, Платон һәм башка грек галимнәренең дә әсәрләре булган. Европа фәне дә гарәпләрдән, гарәп теле һәм әдәбияты аша антик язма мәдәниятне үзләштерүдән башланган. Гарәп университетларын һәм китапханәләрендә европалы сыяләлар актыккан арта барган. Гарәпләр мәдәнияте аларга укый-яза белү буенча Кытайны узып китәргә мөмкинлек биргән, ә инде XVII гасырдан—фәнни ачышлар барлыкка килгәннән соң, европалылар бик нык алга киткән, аннары исә техноген цивилизация тудырганнар. Хәзер күпләр үзләренең «альма-матеры» булган гарәп мәдәниятенә югарыдан гына карап узалар. Әмма әле борынгы римлеләр үк «наданлык—дәлил түгел» дип әйтеп калдырганнар.

Гарәп мәдәниятенең европалыларга никадәр көчле йогынты ясаганын Андалузия (Испания) мисалында күрергә мөмкин. «Саф гарәп мәдәнияте һәм гарәп теле җирле испанлылар өчен бик якын—үз була. IX гасырда исламга каршы көрәшүчеләрнең күренекле берсе кордовалы Альваро болай дип язып калдырган: «Минем диндәшләрем гарәпләрнең һәйкәсларын һәм төрле әсәрләрен яратып укыйлар, алар гарәп дин галимнәренең язганнарын, аны кире кагу өчен түгел, ә гарәпчә дөрес, матур итеп сөйләшергә өйрәнү өчен үзләштерәлар. Сәләтләре белән аерылып торган яшь христианнарның барысы да бары тик гарәп телен һәм әдәбиятын гына белә, алар зур тырышлык-теләк белән гарәп китапларын укый-өйрәнә, күп акчалар түгел, бай китапханәләр булдыра һәм һәркайда ул әдәбиятның искиткеч сокланғычлығы турында сөйләп йөри... Нинди фаҗига! Христианнар хәтта үз диннәренең телен дә оныты, хәзер сез безнең меңнәребез арасыннан үз дустыңа латинча юньле-рәтле хат язып җибәрерлек берәр кеше таба алырсызмы икән? Әгәр инде гарәпчә язарга кирәк булса, сез ул телдә бик матур итеп сөйләшә белүче бик күп кешеләрне табарсыз, сәнгать әсәре буларак гарәпләрнең үзләреннән дә уздырып шигырьләр иҗат иткәнен күрерсез...» (Е. Г. Яковлев. Искусство и мировые религии. (Дөньядагы диннәр һәм сәнгать). М. «Высшая школа", 1985. с. 204).

Испанияда гарәп теле белән латин, ә Россиядә татар һәм рус телләре берберләренә үзара йогынты ясауда бер үк закончалыклар буенча гамәлгә ашалар. Хәзер хәтта белемле татар да, үз фикерләрен туган татар телендә белдерергә авырлыксынып, рәхәтләнеп рус телендә яза.

Хью Фицжеральд: «... бары тик каллиграфия һәм мәчетләр генә...» дип яза, ә бит каллиграфия гарәп сәнгатенеке, һич тә америкалыларныкы түгел. Иерусалимдагы IX гасырның «Әл-Әкса» мәчетенең эстетик бизәлеше сәнгатьтә иң гүзәл эшләрнең берсе. Гарәпләр сәнгатендә каллиграфия (матур язу) өченче урында торган. Алдынгы карашлы галимнәр бу күренешне ничек бәялиләр соң? Америка шәрекъ белгече Ф. Розенталь: «... мәселман каллиграфиясендә дин белән сәнгатьнең бербөтен булып кушылуы чынбарлыкка әверелде",—дип яза. Француз гарәп белгече Л. Масиньон исә, гарәп шигъриятенең үзенчәлекләре турында: «Мәселманнарда шигърияткә көнбатыш шагыйрьләрендәге кебек табуны юк",—дип белдерә һәм бик гадел нәтиҗә ясый: «Шәрекъчә нәфис фикерләүне ислам дине бик тирән тоеп аңлаган һәм телдән әйтелган яки язылган сүзләр белән гамәли декоратив сәнгатьне шул фикерләүгә хезмәт итүче сәнгатьләрнең алдынгысы итеп санаган". Рус галиме И. Брагинский да: «А. Пушкин «Руслан һәм Людмила", «Бакчасарай фонтаны", «Коръәнгә тәкълид (ияру)» әсәрләренде «шәрекъчә нәфис фикерләүнең кабатланмаслыгын аңлап һәм тирән тоеп, аны европача фикерләү белән берләштерә, үзенчәлекле синтез барлыкка килә",—дип яза.

Күргәнебезчә, шәрекъ белгечләре-галимнәр мәселманнарда мәдәният юклык турында сөйләшмиләр, ә аның үзенчәлеге һәм гомумкешелек цивилизациясе өчен әһәмияте барлыгын раслыйлар. Көнбатышта тәүрат сюжетлары нигезендә сынлы сәнгать туган булса, Коръән сүрәләре йогынтысында дөньяви шәрекъ шигърияте барлыкка килгән. Европа һәм шәрекъ сәнгатьләренең бөтенлеге дә, каршылыклары да шунда чагыла. Әрүс һәм татар мәдәниятенең электән үк үзара аралашуы, аның хәзер тагын да көчләрәк тәэсире рус мәдәниятенә аерым бер төсмер биреп, ул «европача"га әверелдә һәм татар мәдәниятенең дә шуның белән синтезы нигезендә яңа үзенчәлекләрен барлыкка китерде. Рус мәдәниятендә без Рахманинов музыкасында, Пушкин шигъриятендә шәрекъ мотивларын ишетсәк, Тукай, Гамзатов шигырьләрендә, Окуджава җырларында рус мотивларын шәйлибез.

Мәдәниятнең чишмә башы кайда?

Мәдәният кешеләрне якынайта, ул, цивилизациядән аерым буларак, заман җилләренә буйсынмый, аны үткәнгә һәм бүгенгегә бүлеп булмый, ул— бербөтен. Өстәрәк мин Фицжеральдан шактый зур өзек китергән идем (янәсе, мәселманнарда сәнгать тә, әдәбият та, музыка да һ. б.—берсе дә юк). Мин аны гарәп-мәселман мәдәниятен авторның бөтенләй аңламавына, гадел түгеллегенә укучы төшенсен өчен китердем.

Хәзерге дөнья цивилизациясе нигезләренә кыйммәтле өлеш керткән никадәр күп аталты мәселман галимнәрен санап китәргә мөмкин бит! Мәсәлән, әл-Кинди (801-866) 270 хезмәт язып калдырган, алар арасында медицина һәм фармокология, философия, арифметика, логика һәм геометриягә багышланган егерме дүрт әсәр бар; ул физикага (оптикага), игътибар биргән; химия (алхимия), физик география һәм метеорология һ. б. белән кызыксынган. Аның Сократ турындагы хезмәтләрендә социаль гыйлем нигезләре чагына. Әл-Рази (865-925) энциклопедик киң белемле галим, табип һәм философ буларак танылган, ул ике йөздән артык хезмәт язып калдырган. Әл-Фараби (870-950) шәрекъ философы буларак билгеле, аны ислам дөньясының иң бөек логик фикер йөртүчесе дип атаганнар. Ул Аристотельнең «Органон» диген хезмәтенә бик тирән тәнкыйди күзәтү ясаган.

Дөнья мәдәниятенә зур өлеш керткән тагын күпме исемнәр фәнгә мәгълүм: Әбугалисина (Авиценна), әл-Кушайри, Әл-Газали (1058—1111), Әл-Шәһрестани,Ибен-Решди (Аверроис), Ибен-Гәрәби (1163—1240), Мөхәммәд Икбал (1873—1938), Хөсәен Табатабаи (1903—1981) кебек байтак урта гасыр һәм хәзерге мәселман философларын санарга була. Ибен-Решди, Әбугалисина, Әл-Фараби, Ибен-Әл-Гәрәби шикелле бик күп галимнәрнең

фәнни хезмәтләре европалыларның фәлсәфи фикерләүләренә ярдәм иткән. Европалылар танып белү теориясе, логика, математика, геометрия, Грекларга да билгеле булмаган алгебра, медицина, география, филология, астрономия, психология, этика кебек бик күп гыйлемнәрне гарәпләр аша танып белгәннәр. Гарәпләр европалыларны диңгездә йөзәргә һәм йолдызларны танып белергә өйрәткәннәр. Тарихны яраткан Карл Маркс: "Гарәпләр антик һәм хәзерге цивилизация күперне булган",—дип искәрткән. Фицжеральд ише каләм кыштырдатучылар моны белми, әмма, «наданлык дәлил түгел» дип кабатлап әйтәбез.

Ислам мәдәнияте, әлбәттә, каллиграфиядә генә түгел, ул архитектура, музыка, әдәбият, этика дөньясында да чагыла. Изге Коръән китабындагы бизәкләр, мәчет һәм аларның манарасындагы график «сырлаулар» үзенчәлекле сәнгать булып санала. Архитектуралары дөньядагы могҗизаларның берсе булып исәпләнгән, ташка индерелгән музыка дип саналган изге йөртлар һиндстандагы Таҗ Мәхәл, Испаниядәге Әлгамбра, Кәһирдәге Ибен-Тулу һәм Мөхәммәд Али мәчетләре, Иерусалимда X гасырда үк салынган Әл-Акса (Күбәттү-эс-Сәхра) мәчете—болар барысы да түзәл мәдәни байлыклар бит. Әйе, сыннарга табынуга көрәш барганлыктан, кеше сурәтен, бигрәк тә мәселманнар бары тик бөек рух дип кенә саналган Аллаһы Тәгалә сурәтен рәсем итеп ясарга ярамаган. Шулай да аталклы фарси миниатюралары, ягъни борынгы кульязмалардагы буяулы хәреф яки кечкенә рәсемнәр әллә мәселманнарның үзенчәлекле сәнгате түгелме? Шәрекъ сәнгате белгеләренә Индонезия сынлы сәнгате дә яхшы таныш.

Ислам сәнгате—рифмаланган сүзләрнең гаҗәеп тирән үтеп керә белүе көчендә. Шәрекъ шигърияте үрнәкләре европалылар өчен ияреп язу-тәкълид нигезе булды. Фирдәүсинең «Шаһнамә» поэмасын кем генә сокланып укымый, Гомәр Хәйямнең шигырьләре кемнәрне генә тыныч калдыра ала, Җәләләддин Руминың акыллы-гыйбрәтле шигърияте аның инглиз телендә дөнья күргән сигез томлык «Мәснәви"е Данте Алигьериның «Илаһи комедия"сенән ике тапкыр зуррак. Халык авыз иҗаты җәүһәрләреннән саналган «Мең дә бер кичә", «Кәлилә белән Димнә» һәм борынгы заманның тагын бик күп әсәрләре үз вакытында үк европалы укучыларга барып ирешкән. Бүгенге көндә дә бай гарәп-фарси шигърияте Көнбатышның зыялылары тарафыннан сокланып кабул ителә. Тормыш-көнкүреш, кием-салым, бизәнү әйберләре, товарлар, тукымалар һәм башкаларның күп кенә үрнәкләре шәрекъ илләреннән килеп кергән. Аларның барысын да гарәпләр, фарсилар, төркилар бик яхшы өйрәнгән иде...

Һәр халык үзенчәлекле мәдәниятқә ия. Дөнья мәдәниятенең матурлыгы да шундадыр. Әйтик, инглизләрнең үзләренә генә хас юмор хисе руслар өчен ешсына бер дә көлке түгел, русларныкы исә инглизләр өчен ят, аңлашылып бетми. Чөнки болар һәркайсы үз тормышы, үз фикерләү үзенчәлекләренә таяна. Сүз уңаеннан, Америка Кушма Штатларының да үзенчәлекле мәдәният бар, аны америкалы булмаган меңнәрчә башка милләт халыклары, төрле диннәр барлыкка китерә. Мәсәлән, Ираклы Ширин Нешат—рассам һәм кинорәжиссер, хәзерге америка сәнгатенең йолдызы, Рудольф Нуриев—татар биючесе, Шварценеггер—австралияле немец. Фәндә АКШта туып үскән галимнәр бик күп түгел, әмма имигрантлар—күчеп килүчеләр байтак...

Сүз, рациональ фикер йөртү

Борынгы кешеләр Сүзнең кешелек мәдәниятен өчен әһәмиятен яхшы аңлаганнар. Сүзнең көче Соломон патша риваятьләрендә генә югары саналмаган, ул хәзерге фәндә дә шулай бәяләнә, чөнки Сүз—ул фикерләү, ул белем, ул үз-үзеңне тота белү, ул кешенең барлык кичерешләре-хисләре. Шагыйрь В. Маяковский әйтмешли, «сүз ул кеше рухының юлбашчысы".

Гадәттә дини тәгълиматлар иррациональ фикер йөртүгә корылган була: дин белем таләп итми, ул ышану-инануны сорый. Мәселман мәдәнияте исә Сүзнең

көченә таяна, тормышка рациональ аек күз белән карауга өстенлек бирә. Коръәндә «гыйлем», «фән» дигән сүзләр җитмеш мәртәбә кабатлана, бер урында да дөньяви фән белән дин арасында аерма барлыгы күрсәтелми. Мөселман мәдәниятендә иң беренче булып язма сүз тора. Бу хакта А. Пушкиннан да остарак итеп әйтеп булмастыр, нәкъ менә ул Коръәннең төп нигезләрен ачып бирган. Сүзнең көче, ятимнәргә шәфкатьле булу турында Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһи сәламгә болай дип әйтеп калдырган (Пушкин шигъриятен бозмас өчен без аны русча китерәбез):

...не я ль язык твой одарил
Могучей властью над умами?..
Мужайся ж, презирай обман,
Стезею правды бодро следуй,
Люби сирот и мой Коран
Дрожащей твари проповедуй.

Гарәпләрнең дөньяви вокал-инструменталь музыкасы да Испания һәм Португалия музыкасына җитди йогынты ясаган. Әлбәттә, ул Фиҗеральд соклана торган көзәрге заман поп-музыкасы түгел. Көнбатыш Рим империясе үзенең затлы кешеләре, байлык һәм типтерү, көеф-сафа корып яшәүләре аркасында, бозылып беткәч, герман кабиләләре нәҗүмнәй күтәрә алмый, ул череп таркала. Мәдәният бары тик аның көнчыгыш өлешендә—Византиядә генә сакланып кала, үсештә була. Византия мәдәнияте, антик мәдәниятнең мирасчысы буларак, шулай ук мөселман (IX-X гасырларга кадәр) һәм христиан халыкларына үрнәк булып торган. Ни өчен европалылар «караңгылык гасырлары (V-X гасырлар)» чорында Византия мәдәниятен үзләштерә алмаган? Чөнки ул вакытларда европалылар, дини тәгълимат белән генә мавыгып, дөньяви мәдәниятке бөтенләй игътибар бирмәгәннәр. Хәтта соңрак та Европада чиркәү хакимияттән өстен торган. Россиядә, киресенчә, хакимият чиркәүдән өстен булган. Тегеләрдә исә һәркем чиркәүнең җәзасыннан курыкып яшәгән, шуңа күрә инквизиция котырынганнан-котырынган. Шуның өчен дә европалыларның дини һәм дөньяви әйдәп баручылары католик Европаның халык массаларын «Ходай Тәгаләнең табутын коткарырга» җиңел генә төре походына ияртә алганнар. Чынлыкта исә кешеләрне Шәрекъне талау һәм баю өмете белән бу юлга басканнар. Кораллы күпмеңләп католиклар исламны гына «дошман» итеп санамаганнар, алар христиан динендә дә «ересь", ягъни сафсата, юк-бар фикер күргән. Алар үзләреннең өченче төре походында Константинопольнең христиан храмнарын талап чыкканнар, чиркәүләрнең алтынланган әйберләрен—иконаларын, төрелерен һәм башка нәрсәләрен алып киткәннәр.

Гомумкешелек мәдәнияте буыннан-буынга күчеп килү юлы белән үскән һәм үсә. Багдадтагы «"Бәет-әл-хикмәт» ("Хикмәтләр йорты", VIII-IX гасырлар)—ул шул чордагы йөзләрчә дөньяви зыялыларның, галимнәрнең вакытлар үтеп череп бетүдән, юештән-дымнан борынгы кулъязмаларны коткару өчен тырышып эшләгән урыны. Алар дистәләрчә телләрдәге кулъязмаларны күчереп язганнар, борынгы грек, санскрит, борынгы яһүд, фарси һәм бүген инде онытылган башка бик күп телләрдән гарәп теленә тәрҗемә итеп калдырганнар. Кешелек мәдәниятенең ул байлыкларын 200-300 елдан соң европалы монахлар гарәп теленнән латинчага тәрҗемә итә башлаганнар. Шул рәвешле, мәдәният буыннан-буынга күчеп килә торган.

Фиҗеральдның ялгыш фикер йөртүе нәрсәдә?

Хакыйкать шунда: әгәр без башка бер халыкның мәдәниятен белмибез икән, ул әле бөтенләй юк дигән сүз түгел. Америкалыларның Шәрекътә һәм Европада гасырлар буе җыелып килгән традицияләре, кыйммәтле мәдәни байлыклары кебек мәдәният юк. Америкалыларның мең еллык тарихы да, ерак бабалары

күмелгән туган җирләре дә юк, бәлки, шуның өчен дә алар буй-буйлы флагларыннан башка бер нәрсе белән дә горурлана алмыйлардыр. Бәлки, шуңа күрә дә алар Европа һәм Шәрекъ кешеләренең психологик үзенчәлекләрен кабул итә алмыйлардыр...

Нәкъ менә шул сәбәпле, мәдәниятне аңлауда Фицжеральдның үй-фикерләре дә бер яклы, тар, чикләнгән. Барлык илләрнең зыялылары безнең колакка гадәти булмаган, әмма хисләнен, рәхәт кабул иткән төрек, фарси, гарәпләрнең йомшак-ягымлы музыкасын яратып тыңлый. Беркем дә бит Фицжеральдның Кәһирәдә яки Багдадта, яисә мәселман иле Малайзиянең башкаласы Куала-Лумпурның күкләргә терәлеп торган небоскребындагы йөз унынчы катында Луи Армстронг җырларын тыңлауны тыймый.

Шулай ук Аристотель, Әбугалисина (Авиценна), Әл-Фараби грек яки гарәп мәдәнияте вәкилләре генә түгел, алар бөтен кешелек дөньясыныкы. Моцарт, Бах, Бетховен һәм башка дан'илар—Европа һәм инде бигрәк тә Америка казанышы түгел, алар гомумкешелек мәдәниятенеке.

Күп кенә мәселман илләре бүген әле технологик фәннәрдә калышып килә. Ә иртәгә? Берләшкән Гарәп Әмирлекләре—ул ислам дөньясының бер читендәге алга киткән, нык тәрәккәй иткән ил. Әмир үз халкын Аллага гына ышанып ятмаска, ә тир түгел хезмәт итәргә чакыра. Һәм шулай эшлиләр дә бит! Хәзерге төзелеш технологиясен куллану, Дубаидагы дөньяда иң яхшы халыкара аэропорт, су астында зиннәтле кунакханә кору, ком түлләрендә тамчылап сугарыла торган бодай чәчү... Нефтьтән табыш алып бәю хәзер инде беренчелекне башкага бирә: Әмирлекнең бер миллион кешесенә дөньяның барлык илләреннән җыела торган биш миллион турист туры килә, аларның һәммәсе дә «Мең дә бер кичә» әкиятләреннең ничек чынга ашуын күрергә тели. Кытай белән Малайзиянең мисаллары да бик гыйбрәтле, алардагы мәдәни тамырлар гасырларга кереп киткән. Кытайларның әле безнең эрага кадәр үк төзелә башлаган 12 мең томлык энциклопедиясендә нинди мәдәни хәзинәләр сакланганын Хью Фицжеральд белеме икән? Мәселән, кытай музыкасын, кытай рәссамнәренең табигать күренешләрен тасвирлаган рәсем сәнгатен аңлый ала микән ул?

Хәтта артык күпсанлы булмаган ислам динен 920 елларда кабул иткән татар халкы да үзенең милли мәдәнияте, мең еллык бай тарихы, симфоник музыкасы, бай әдәбияты һәм башкалары белән хаклы горурлана. Безнең артистларыбыз бүген европалылар мәдәниятенә үз өлешләрен кертә. Европа татар опера һәм балет театрын алкышлый, композитор Софья Гобәйдуллина музыкасына мөкиббән китә, Лондонның король балет театрында бию'че Ирек Мөхәммәтовка соклана, Париж опера театрының бөек бию'чесе булган Рудольф Нуриевның якты истәлеген хөрмәт итә, әнисе ягыннан чыгышы белән татар Чыңгыз Айтматовның китапларын яратып укый, ә азмыни мәселманнар арасында талантлылар!

Гарәп зыялыларының югары кимәлдә мәдәни фикерли белүе америкалылар һәм европалыларныкыннан бер дә ким түгел. Алар барлык чорларда да дөнья мәдәниятене үз өлешләрен керткән һәм кертә киләләр. Әхмәд Зувейл химия өлкәсендәге ачышлары өчен Нобель бүләге алган (1999), Нәҗиб Мәхфүз—әдәбият буенча Нобель бүләге лауреаты, дөньяга танылган язучы Таха Хөсәен—Франциянең Почет легионы ордены кавалеры, Әл-Баяти әсәрләрен дөньяның үнике телендә укыйлар. Әнис Мансур иҗатына багышлап АКШта һәм Германияда ике докторлык диссертациясе язылган. Ибраһим Мәһәвваз математикада үнбиш яңа теория ачкан, АКШта аңа 2001—2002 елларда өчен «Ел кешесе» дип исем бирелгән. Фарук Әл-Баз—дөньяда танылган геолог, АКШта НАСАның элекке директоры. Али Мостафа—атом-төш физикасы өлкәсендә белгеч булган, аның турында Альберт Эйнштейн: «Без дөньяның бер бөек галимен югалттык",—дигән.

Без Төрек Җөмһүрияте мәдәниятенең күпсанлы эшлеклелә рен, аның музыкасы, әдәбияты турында сөйләп тормыйбыз: алар Европа зыялыларына болай да билгеле. Әйе, цивилизацияләр булган, була һәм үтә тора, ә мәдәният—мәңгелек.

Хатын-кызларга мөнәсәбәт

Ислам динен тагын нәрсәләрдә гаеплиләр? Хатын-кызларның хокукларын кысуда. Бу хакта дөньяны танып белү дәрәҗәләре X гасырда калган надан әфган муллалары каланчасыннан торып көкем чыгарырга һич тә ярамый. Әгәр дә мөселман гаиләләрендә хатын-кыз хокукларын бозу бар икән, ул һич тә гади америкалы, инглиз яки рус гаиләсендәгедән артык булмастыр.

"Россиядә һәр сәгать саен бер хатын-кыз ире яки сөяркәсе кулыннан һәлак була. Хатын-кызларны җәберләүләрне тикшерүләр күрсәткәнчә, 58% рус хатын-кызлары үз тормышларында бер мәртәбә булса да ир-атлар яки якыннары тарафыннан кыерсытылмый калмый икән. Шул исәптән, Россиядәге биш хатын-кызның берсе ире тарафыннан даими кыйнала килә",—дип яза «Восточный экспресс» газетасы «Любить по-русски» дигән мәкаләсендә (N49, 28 ноябрь, 2003). Матбугатта шулай ук «инглиз ата-аналар үз балаларын үтергәнче кыйныйлар, христиан диненең «якыннарыңны ярат» дигән нәсыйхәте дә нәтиҗә бирми» дигән материаллар күп китерелә.

Яхшы түгел, әлбәттә: «кеше күзендәге чүпне дә күреп, үз күзеңдәге бүрәнәне дә күрмәү» кебегрәк була инде бу.

Корьәндә хатын-кызлар, бигрәк тә аналар хакы яклана, ирләрнең хатын-кызларга, толларга һәм ятимнәргә кайгыртучан, игътибарлы булуы таләп ителә. Корьән-хатын-кызның матди хәленә ышаныч-таяныч та үтә. Монысы Румидан алып (XI гасыр) Гамзатовка хәтле (XX гасыр) шагыйрьләрнең әсәрләрендә, гомумән, мөселман әдәбиятында кин яктыртыла. Корьән күрсәтмәләрен бозган, үтәмәгән очраклар да була, әмма күпчелек мөселман илләрендә хатын-кызлар ирләр белән бертигез дәрәҗәдә югары белем ала, бер төрле үк сәяси хокукларга ия булып, иҗтимагый эшчәнлекте дә катнаша. Мөселман дөньясын ничек гаепләмәк кирәк: күп кенә илләрдә хатын-кызлар президентлар, премьер-министрлар була, Европага караганда да ешрак хәтта (Төркия, Пакистан, Шри-Ланка, Индонезия һ. б. илләр).

2003 елның октябрендә иран адвокаты Ширин Эбоди кеше хокукларын актив яклаудагы эшчәнлеге өчен тынычлык өлкәсендә Нобель бүләге лауреаты исемене ләек булды. Ул үзенең иҗтимагый эшчәнлеген Көнбатышта таныткан беренче мөселман хатын-кызы. Йөз елга беренче мәртәбә мөселман хатын-кызларыннан шундый зур бүләк алды бит. Иранда шаһ хакимлек иткәндә. Ширин судья була, хәзер—адвокат. Ике ел төрмәдә дә утырып чыккан. Эбоди белән бергә Нобель бүләген дәгъва кылучылар—Рим Папасы Павел II, Чехиянең элекке президенты Вацлав Гавел кебек дөньяга танылган 165 шәхес тә була. Нобель бүләген бируы Комитеты ни өчен мәнә Эбодины ләек дип тапкан соң? Мәдәни фикер йөртә белүе, актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен, әлбәттә.

Җенси мөнәсәбәтләр хакында

Фицжеральд мөселманнарны «женси мөнәсәбәтләргә аврыксынып карауда» гаепли. Аны нәрсә борчый соң? Бәлки, Көнбатышта хатын-кызга караш Шәрекъ илләрендәге мөселманнарныңкә хисләренә кагылганга күрә, шуңа бәйләнеп киләдер? Бәлки, Көнбатыштагы кайбер бәнделәрнең элекке советлардагы сөюздаш республикаларыннан алдап-жолдап, яхшы эш вәгъдә итеп, меңләген хатын-кызларны алып китүләре һәм аларны фахишәлеккә мәҗбүр итүләре мөселман илләрендә хупланмаганга күрә, бәйләнмәкчедер ул? Юк ла! Хью Фицжеральд мөселманнарның җенси мөнәсәбәтләргә башкача карауларын гына аңлый алмый интегә. Чөнки Көнбатышта рух культы тән культына, тәнгә табынуга алмаштырылды. Юк, һич Фицжеральдны ул борчымый, ул бары тик шәрекъ мәдәнилегенең акчага табынуга, чиксез байлыкка корылмаган, ә рухи дөньяңны баету, нәфесне тыя белү, үз-үзеңне тәрбияләүгә юнәлтелгәнлеген гена аңлый алмый. Әйе, кайбер мөселман хатын-кызлары, иске гореф-гадәтләр буенча, йөзләрен, чит-ят ирләрнең комсыз

карашларыннан яшерер өчен, пәрәнҗә белән каплыйлар. Әмма алар, Англиядәге шикелле, балаларын да үтергәнче кыйнамыйлар.

Инглизчә «сексплотейшен"—хатын-кызларны сексуаль көчләү юлы белән табыш алуга тарту—әллә Көнбатышның базар икътисады шуңа корылганмы соң? Әгәр анда акча өчен экраннарда һәм төсле журнал тышлыкларында бөтен дөньяга шәрә хатын-кызларны төшереп күрсәтәләр икән, мәселманнар әле оятларын югалтмаган, алар әле җирләрен кешегә күрсәтергә теләмиләр. Гомосексуализм—шулай ук Көнбатышның «мәдәни» казанышы бит. Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм рекламалар йогынтысына бирелеп, төркем-төркем яшьләр ирләр белән ирләрнең җенси якынлык кылуга «хокукларын» законлаштыруны таләп итә, кайбер илләрдә женесләр арасында табигый булмаган шундый мәнәсәбәтләрне законлаштырып та куялар. Мәсәлән, Норвегиядә бер ир-ат министр икенче бер ир белән «законлы» никахта яши. Әллә болар әхлакның бик түбән төшүе, бозылуы түгелме? Хәтта троглодитлар—тау куышларында яшәгән борынгы кешеләр дә үзләренең оят җирләрен яфрак белән булса да каплап йөргәннәр.

Нәрсә соң ул мәдәнилек? Шагыйрь әйтмешли, «башкалар күзендәге чүпне дә күреп, үз күзендәге бүрәнәне дә күрмәү"мө? Кабатландыкмы? Ярар. Менә тагын бер иске хакыйкатьне кабатлыйбыз: әгәр без башка халыкның мәдәниятен аңламыйбыз икән, ул мәдәният бөтенләй юк диган сүз түгел ич.

Евразия мәдәниятенең нигезендә ни–нәрсә ята?

Мәдәниятләрнең аралашуына Россиядә нәрсә комачаулый?

Мәдәният, мәдәнилек—киң төшенчәләр, аларны аңлату да бик киң була. Танылган совет тарихчысы, этнограф, академик Ю. В. Бромлей мондый аңлатма бирә: «Мәдәният, мәдәнилек—ул кешелек тарафыннан булдырылган һәм хәзер дә торышта килгән һәрнәрсә: хезмәт коралларыннан башлап йорт өченкөндәлек тормышта кирәк-яракларга кадәр, гореф-гадәтләрдән, кешенең үз-үзен тотышыннан алып фән һәм сәнгатькә, дин һәм динсезлеккә, әхлак һәм философиягә кадәр шулай". Мәдәниятнең үсеш закончалыклары турында күп язылган, шулай ук милли мәдәниятләрнең бер-берләренә үзара йогынтылары турында да күп әйтелгән, Шәрекънең Көнбатышка йогынтысы һәм, киресенчә дә булып, Евразия цивилизациясе барлыкка килү турында да күп сөйләнгән. Төрле халыкларның аңында мәдәнилекнең асылы ничек күзалланы турында, гомумилештерел, америкалы философ Ф. Роузенталь язган.

Барлык мәдәниятләрнең дә үз идеаллары булганлыгы билгеле. Алар табигать шартлары, тарихи һәи дини факторлар йогынтысында формалаша, берәр халыкның тормыштагы төрле өлкәләрдә үз-үзләрен тотышы һәм рухи байлыгының тулы бер системасы белән раслана. Нәкъ менә шул рәвешле халыкларның мәдәнияте бер-берләреннән аерылып тора да. Әйтик, борынгы грек мәдәниятендә акылга, белемгә таянганнар, акыл иясе идеал саналган. Рим мәдәниятендә исә өстенлек хокукка, законга бирелгән, гражданин идеал булган. Урта гасырлардагы христиан мәдәниятендә идеал булып изгелөр, дәрвишлар торган, өстенлек—кешенең рухи җанын коткарып калу дип исәпләнгән. Һиндстанның рухи мәдәнияте, иң югары кыйммәтләрне барлыкка китергән югары зат Брахман белән бербөтенгә әверелеп, газаплардан котылу юлын табарга омтылган. Хәзерге Көнбатыш Европа мәдәнияте исә бөтен өстенлекне матди байлыкта—акчада күрә, аның идеалы—җирдәге муллык-байлыктан күбрәк файдалану һәм шул юнәлештә туктаусыз тәрәккый итү. Монголларның күчмә мәдәнияте, тарихчы Эрентен Хара Даван әйтүенчә, «ул хәрбилөштерелгән мәдәният, аның идеалы—бөтен галәмне яулап алу". Күчмә мәдәниятне, вакытлар үтү белән, Җучи Олысында утрак тормышлы халыклар мәдәнияте кысыклап чыгара.

Мәгърифәт өлкәсендә үзара сөйләшү-диалогны үстерү өчен нәрсә кирәк? Дөреслек, социаль гаделлек кирәк, логик законнарга таяну кирәк.

Өстәрәк әйтеп үзганыбызча, мәдәниятләр диалогы ике яссылыкта—глобаль, яғъни бар дөньяны колачлаган һәм региональ, яғъни төбәкләр дәрәҗәсендә генә булып кала. Төбәкләр дәрәҗәсендә сүз тегеяки бу милләтнең үз язмышын үзе хәл итүгә, бәйсезлек-мөстәкыйльлекккә хакы барлығы, башка халыклар арасында үзенә лаек урын табуы, һәр халыкның һәм һәр кешенең хокукын хөрмәт итүе турында бара.

Әмма ләкин дөньядә идеологик көрәш, мәгълүмати тарткалаш бара, көчле илләр һәм халыклар көчсезләрне төрлечә түбәнсетәләр һәм җәберлилләр.

Мәдәниятләр диалогына дискриминация—тигезсезлек комачаулый. Аның ике төрле формасы бар—күрмәмешкә салыну, дәшми-әйтми үзү һәм тегеяки бу мәдәниятнең дәрәҗәсен төшерү яки бөтенләй мыскыл итү, аны бозып күрсәтү ысулы. Мәсәлән, югары үкү йөртлары студентларә өчен Россия Федерациясенең Мәгариф министрлыгы тәкъдим иткән культурология дәреслеген алып карыйк. Анда борынгы Мисырдан башлап барлык төр цивилизацияләргә дә урын мулдан бирелгән. Ләкин дөнья мәдәнияте дәреслегенә дәгъва кылган әлеге китапта гарәп-мөселман цивилизациясе турында бер генә сүз дә юк. 215 битлек дәреслектә кыскача һәм бик дәлилле итеп бөтен дөнья мәдәнияте тасвирланган. Ә менә мөселманнарга нибары өч юл бирелгән (аларны дәреслектәгечә, русча китерәбез): «Ряд областей знаний был обогащен в эпоху Средневековья учеными Арабского Востока и Средней Азии: Ибн-Сина, Ибн-Рошт и Бируни» һәм—бетте-китте! 640 шәхесне колачлаган иселектә исә Софокл һәм Солженицын, Тициан һәм Сологуб кына түгел, анда Добрыня, Ермак һәм Иван Носка кадәр бар. Соңгысы христиан чиркәвенда башлап җырлаучы булган. Менә шулай! Фәнда танылган күренекле шәрекъ белгечләре И. М. Фильштинский, Ф. Роузенталь, Е. Г. Яковлев һәм башкалар «гарәп-мөселман цивилизациясе"нең гомумкешелек мәдәниятендә зур урын тотканлыгы турында язалар. Бу мәдәният «гарәп-мөселман мәдәнияте» дип атала. Ни өчен дигәнде, аны гарәпләр генә түгел, ә барлык мөселман халыкларының вәкилләре тудырган, алар да нигезде гарәп телендә иҗат иткәннәр. Гарәп телеңең беренче грамматикасын фарси филологы Замаһшери язган, Әл-Бируни—үзбәк, Әл-Фараби төрки булган һ. б.

Шунысы сәер, дәреслек авторлары шулай надан булганмы, әллә кешелек цивилизациясенең иң зурларыннан булган берсен махсус дискриминацияләү өчен шулай эшләгәннәрме? Ә бәлки, АКШның ислам дөньясына каршы сәясәтен яклаганнардыр...

Бу дәреслекнең тулы мәгълүматларын русча күрсәтәбез: «Культурология. История мировой культуры. Под ред. Проф. А. Н. Марковой. М., «Культура и спорт», «ЮНИТИ», 1995».

Хөрмәтле укучылар һәм студентлар! Әгәр дә бу «дәреслекне» сезгә тәкъдим итсәләр, алмагыз, ачып та карамагыз, чөнки аңа бернинди дә ышаныч юк.

Тарихи фактларны бозып күрсәтү

Россиянең үку йөртларында Рус дәүләте тарихын укытуга иркенләбрәк тукталыйк әле. Россиядә яшь буынны патриотизм рухында тәрбияләү мәктәптән үк башлана. Ул элек-электән үзенекенә күпертен мактау һәм «читятлар» мәдәниятен—телен, тарихын, әдәбиятын, музыкасын, рәсем сәнгатен һ. б. түбәнәйтү, кечерәйтеп күрсәтү юлы белән барган һәм бара. Русьта кемнәр герой булган? Гадәттә сугышта «Россия данын яклап» батырлык кылучы шәхесләр. Ул «сугышчан геройларның» матур образлары һәм халык авыз иҗатында, һәм әдәбияттә тудырылган, чарланган. Совет хакимияте чорында хезмәт кешесенең образын күтәргәннәр, галимгә, язучыга, артистка дан җырлаганнар. Ләкин мәгариф әлкәсендә һаман да искечә рус мәдәнияте, рус теле, рус әдәбияты, рус тарихы һәм башка өстенлекләре ассызыклап мактальп килгән һәм килә. Рус булмаган халыклар—әлекке союздаш республикалар вәкилләре, россияле саналган татарлар, чувашлар, башкортлар, удмуртлар,

якутлар, кареллар, осетиннар, дагстанлылар, бурятлар һ. б.—һәммәсе руслар тарафыннан «бербөтен совет халкы» диган ялган шигарь белән йотыла-кысыла барган. Бу гамәл нигезендә милли мәктәпләрне рус телендә укытуга күчерү, милли матбугатны, милли басмаларны чикләү юлы белән эшләнеп килгән һәм килә.

Яңа «демократик» Россиядә дә шул ук хәл күзәтелә диган сүз бу. Рус булмаган халыкларның сәяси хокуклары ачыктан-ачык юкка чыгарыла, мөстәкыйльлеккә-бәйсезлеккә омтылу эзәрлекләнә. Әфганстанда үн ел буе барган мәгънәсез сугыш, көзер Чечнядә бара торган кан коеш исламга каршы пропаганда аша рус халкында мәселманнарга карата дошманлык хисе тудырып тора ("бандит", «террорист» сүзләре «чечен» сүзенә аваздашсиноним булып яңгырый көзер).

Менә шундый вәзгыять аркасында рус балалары аңында мәктәптән үк үзләреннең башка халыклардан өстенлекләрен тою хисе үсеш ала. Мисалы шул, тарих дәреслекләрендә тарихи фактлар бозып бирелә, татар халкының Русь дәүләте төзелүгә, аның мәдәниятен үстерүгә керткән өлеше кечерәйтептүбәнәйтеп күрсәтелә.

Ул дәреслекләрдә татарларның болгар чоры телгә дә алынмый. Алтын Урда чорындагы татарларны да кимсетеп карау чагыла, бу дәүләт бик түбән мәдәнияттә күчмә дәүләт булган дип бәяләнә. Алай гына да түгел, Алтын Урда рус халкына, Русь дәүләтенә бары тик тискәре йогынты гына ясаган дип раслана. Башыннан үк дөрес булмаган бу караш рус халкы аңына гасырлар буе тукып киленә, шул ялган белән яшь буын тәрбияләнә. Ә хәзер без Россия парламентындагы кайбер депутатларның «татарларны Монголиягә сөрергә кирәк» дип лаф оруларына шаккатып утырабыз!

Әмма ләкин төрки халыклар белгече Л. Н. Гумилев бәяләвенчә, нәкъ киресенчә булган бит. Ул чорда (300 еллар чамасы) әле бербөтен рус дәүләте булмаган, аерым кенәзләр үзара сугышып, бер-берләрен талап-җимереп, авылларны көл итеп, үз русларын үтереп һәм көчләп яшәп ятканнар. Әле монгол чорына кадәр үк рус җирләрендә шундый сугышлар көкем сөргән. Рус кенәзләре җир өчен шулай тарткалашканда еш кына ярдәмгә кыпчакларны яки башка күчмә халыкларны чакыра торган булганнар. Ә рус тарихчылары кыпчакларны явыз, канэчкеч халык дип сурәтләп килә. Бакса, руслар үзләре бер-берсен аяусыз кыйнаган-үтергән икән бит. Мәсәлән, «Ростов-Суздаль һәм Новгород арасында 1216 елда җир өчен барган сугышта, кыпчаклар катнашмаса да, Липица елгасы буенда бер көн эчендә 9233 рус сугышчысы һәлак була, аларны руслар үк үтерә"—бу вакыйга Мәскәүнең «Проспект» нәшрияты 2000 елда бастырып чыгарган «Россия тарихы» дәреслегендә шулай тасвирлана.

Батый яуларыннан соң да, әйтик, Тверь күп еллар буена Мәскәү белән сугыша, үзенә беренчелекне даулый. Мәскәү кенәзләре бөек Новгород шәһәрен ике тапкыр яндырып көл-күмергә калдыралар, шәһәр халкын талап-сүеп чыгалар. Татарлар исә рус кенәзләре арасында тату мөнәсәбәтләрне яклап, аларның үзара сугышларын булдырмаска тырышып торалар. Монысы татарлар өчен дә файдалы: таланган җирләрдән ясак җыеп булмый бит.

Идел Болгарының Алтын Урда составына кертелүенә беләбез, ә менә татарларның, басып алынган рус җирләре булмагач, кенәзлекләрдә түрәләре дә булмаган. Руслар Урдага вассал буларак кына буйсынып торган. Басып алынып, түрәләр кысымы астында яшәү белән вассал гына булып яшәү, ягъни үз гаскәрең, үз финансларың, үз судларың һ. б. булу арасында зур аерма бар. Рус кенәзләре Алтын Урда ханыннан кенәзлек итәр өчен ярлыклар алырга Сарай шәһәренә даими барып йөргәннәр. Алар төрле өстенлеклер һәм ташламалардан да файдаланганнар, ясакны үзләре җыю хокукы алып, күршеләренә яла яга торган булганнар. Мәсәлән, Иван III (Калита) үзе ясак җыю хокукы алганнан соң, 12 ел кенәзлек иткән чорында Урда тарафыннан аның җирләренә бер генә мәртәбә дә яу чапмаганнар. Моны тарих сөйли.

Татарларны нәрсәләрдә гаеплиләр соң?

Ни өчендер күп кенә рус авторлары үткәннәргә үзләренең бүгенге мәдәнилеге югарылыгыннан торып карыйлар. Ә бит үткән заманнарда русларның дә мәдәнилеге күрше халыкларныкыннан әлләни артык булмаган. Тарихи фактлар шул хакта сөйлиләр.

Ләкин менә тарих дәреслекләрендә татар халкының тарихын гадәтләнгәнчә бозып яктырталар. Татарларны нәрсәләрдә генә гаепләмиләр! Татар-монгол игосы, татарларның усал холкы, аларның әхлаксызлыгы турында никадәр күп сагыз чәйниләр, сафсата саталар. Дәреслек авторлары татарларның кыргый кешеләр булуы турында язалар, алар, имеш, рус кенәзлекләрен төрлечә кысрыклап килгәннәр, алар, имеш, фәлән дә төгән—кыскасы, гаепләүләрнең чиге юк. Хәтта Русь дәүләтенең Европадан артта калуын да безгә сылтыйлар. Боларның барысы бергә тарих дәреслекләреннән рус балаларын өстенә китереп аударыла, аларда хәзерге татарларга карата тискәре мөнәсәбәт тудыра. Мондый шартларда хәтта татар балаларын үзләре дә үзләренең «икенче сортлылыкларын» бик нечкә тоемлыйлар.

Шуны онытмаска кирәк, хәзерге рус мәдәнияте, үз вакытында татарлардан күп нәрсәләр алып-үзләштереп, турыдан-туры Европа йогынтысында үскән. Петр I патша заманнарыннан башлап җә немецлар, французлар, поляклардың активь катнашында төрәккый иткән. Хәзер дә ул Россиядә яшәүче бик күп халыкларның, шул исәптән татарларның һәм яһүдләрнең дә катнашы белән үсә. Рус мәдәниятенә һәр өлкәдә яһүдләр керткән биниһаә зур өлеш турында том-том аерым хезмәтләр язарга мөмкин булыр иде.

Алтын Урда татарларының мәдәнияте юк... Имеш. Урта мәктәпләр тарих дәреслекләрендә генә түгел, дөньяга күзләре ачылган студентлар өчен дә тарихи фактлар бозып күрсәтелә. Мәсәлән, профессор Г. В. Драч редакциясендә нәшер ителгән культурология дәреслегендә (Ростов-Дон, «Феникс», 2000) татар-монгол мәдәниятенә тискәре, фанни ялган бәяләмә бирелә. «Башкалар икътисадын гына үзләштереп килү чорында яшәгән әлеге халык ни рәвешле йөз еллар буена борынгы цивилизацияле халыкларны буйсындыра алган һәм изеп тора алган соң?"—дип язалар үл дәреслектә. Безнең шундый сорауларыбыз бар: Алтын Урда халкы үл чорда бары тик башкаларныкын үзләштерүче икътисадлы гына булганмени? Үл чорда кайсы халыклар тагын да борынгырак цивилизацияле булганнар икән? Алтын Урдада кемнәр мәдәнияте өстенлек иткән?

Алтын Урда тарихының чын дәресен беләсегез килсә, галим М. Г. Сәфәргалиевнең тәфсилле тикшеренүләрен алып үкыгыз (Распад Золотой Орды. На стыке континентов и цивилизаций. М., 1996).

Татарлар

Барлык сораулар да бары тик тарихи дәреслек юлы белән генә чишелергә мөмкин. Бу очракта—бигрәк тә. Кемнәр үл татарлар? Төрки кабиләләр Тын океан ярларыннан алып Әдрән диңгезгә кадәр иксез-чиксез җирләрне V-VII гасырларда биләп торган Төрки каганаты составында чәчәк ату чоры кичергәннәр. Тарих фәне шулай раслый. Төркиләрнең бер өлешe күчмә булса, икенчеләре утрак тормыш белән яшәгән, җир эшкәрткән, иген иккән.

XIII гасырда Көнчыгыш Европага ниндә халыклар, кайлардан күчеп килгән? Тарих дәреслекләрендә язганча, алар ярым кыргый күчмә кабиләләр булганмы яки борынгы мәдәниятле халыклар булганмы?

Безне шундый сорау кызыксындыра: Җучи Олысының (Алтын Урданың) мәдәни тамырлары кайда? Ул, әлбәттә, этник катнаш мәдәниятле халыкларга барып тоташа—анда татарлар, монголлар, кыпчаклар, болгарлар, угызлар һәм башкалар яшәгән бит.

Монгол чорына кадәр татарлар кем һәм нинди булган? Тарихи әдәбиятта

«татарлар» этнонимы-гыйбарәсе Алтын Урда чорында гына барлыкка килгән диген караш өстенлек итә. Ләкин татарларның монголлар белән борын-борыннан күрше булып яшәүләренә, борынгы халык икәнлекләренә төпле дәлилләр бар. Беренче мәртәбә алар «отуз татар» исеме белән Күлтәгин истәлегенә язылган язмада (732) телгә алыналар. Аннары 760 елда «токуз татар» исеме уйгур хакиме Элетмиш Билге каганга багышланган кабер ташындагы эпиграфиядә күренә. Бу хакта тарихы галим Д. Исхаков язып чыкты.

VIII гасырга караган бер чыганакта Шәркый Төркестанда татарларның дәүләтчелеге булганлыгы әйтелә, аларның уйгурлар белән бергә кыргызларга каршы сугышканнары да билгеле. Тарихчы Гардизи Иртешнең югары агымында VII гасырда кимаклар дәүләтен төзүдә татарлар да катнашканлыгын хәбәр итә (Д. Исхаков).

Шулай итеп «татарлар» этнонимы VII гасырда хасил була, ә VIII гасырда аларның үз дәүләтчелеге булганлыгы әйтелә. Соңрак бик абруйлы гарәп тарихчысы Рәшиддиннең «Җәми-әт-төварих» диген хезмәтендә татарлар турында мондый мәгълүматлар бирә: «...алар инде бик борынгы заманнардан бирле байтак кына кабиләләрнең бәйләнеш буйсындырып вә аларга хуҗа булып, шактый вакытлар үзләренең бәйләнеш, көче вә башка халыклар тарафыннан хөрмәт ителүе белән аерылып торганнар. Аларның гадәти булмаган бәйләнеш вә хөрмәтне урын тотуы сәбәпле, башка төрки ырулар да, исемнәрен әйтеп, аларга хөрмәт төрле булуга карамастан, алар исеме белән таныла вә «татар» дип йөртелә башлый» (Д. Исхаков).

Идел буйларына һәм Көнчыгыш Европага татарлар монголлар белән бергә килгәннәр. Батый хан гаскәрендә татарлар монголлардан күбрәк булган. Алтын Урданың тәп халкы кыпчак һәм татарлардан торган, бу ике халык төрки дөньяда бер үк буыннан, шуңа күрә Урдада аларның теле һәм гореф-гадәтләре, йолалары өстенлек иткән.

Батый хан армиясендә чыңгыз-монголлар командалык итсә дә, төрки телле сугышчылар монголлардан күп тапкырлар артык булган. Шул чор тарихы раславынча, монголларның үз йөзләреп югалтып төркиләшүләре бик тиз барган. Үзбәк хан хакимлек иткән вакыттан алып (1312 елдан) монгол династияләре бөтенләй юкка чыга. Алар ил белән идарә итүдән читләштерелгәннәр (Кара: Таһиров И. Р. «Татар халкының милли дәүләтчелеге хакында". Хәзерге җәмгыятьнең үсеш перспективалары. Казан, 2003).

Борынгы заманнарда татарларның мәдәнияте кытай цивилизациясе йогынтысын кичергән. Моның шулэй булуын, мәсәлән, хәзерге татар музыкасы да раслый—ул пентатоникага (биш авазлыкка) нигезләнгән. Алтын Урда да исә, кайбер авторлар язганча, болгар мәдәнияте генә түгел, ә болгар-татар мәдәнияте өстенлек иткән.

Идел Болгары

Алтын Урда җәмгыятендә, татарларның этник мәдәниятеннән тыш, мәдәни тормышта тагын кемнәр өстенлек иткән соң? Ул Идел Болгары мәдәнияте булган. Болгар иленең көньяк чикләре хәзерге Саратов (Сарытау) һәм Волгоград (Сталинград—Царицин—Сары су) шәһәрләреннән дә түбәндәрәк булган. Татар-монголлар инде мәдәни халыклы җирләргә килеп утырганнар.

Ни өчен нәкъ менә болгар мәдәнияте өстенлеккә ия булган? Чөнки аның күп гасырлык гореф-гадәтләре, мәселманлык нигезләре, социаль-икътисади үсешенең югары дәрәҗәле булуы, мәселман дөньясы (Урта Азия, Иран, гарәп халифәтләре, Төрек империясе) белән сәүдә һәм дипломатик элемтәләре, бер дәүләт теле булган.

Төркиләр һәм болгарларның мәдәнилеге хакында берничә сүз. 1230—1240 елларда татар-монголлар килгәнчегә кадәр Идел буйларында нинди халыклар яшәгән? Дон (Тын елга) һәм Идел арьяғы далаларында элек-электән үк төрки телле күпсанлы кыпчак кабиләләре күчеп йөргән, аларга күрше булып

славяннар яшәгән. Төньяк Кавказда һәм шул ук Дон буйларында төрки телле хазарлар һәм болгарлар дәүләте Бөек Болгар булган. Хазарлар әкренләп болгарларны кысрыклап чыгарганнан соң, Кубрат ханның Аспарух исемле улы үз кабиләсенең бер өлешен көнбатышка, Балкан якларына алып киткән, ул Дунай буенда Болгария дәүләтен төзи һәм аның беренче патшасы була. Кубратның икенче улы исә кабиләнең калган өлешен иярткән Идел буйлап өскәрәк күтәрелә һәм шунда Идел Болгары дәүләтен төзи. VII-XII гасырларда Идел һәм Кама (Чулман) буйларында нәкъ шул дәүләт үзенең чәчәк аты чорын кичергән. Андагы төрки телле халыкның ата-бабалары Европа белән Азиядә дә яшәгән. Мәдәниятнең иң мөһим сыйфатларыннан берсе—халыкның язуы булу. Төркиләрдә язу иртә барлыкка килгән.

1924 елны Франциядә өч меңгә якын зур булмаган ташъязмалар табылган, алар рун хәрефләренә охшаш хәрефләр белән уеп язылган булганнар. Галимнәр фикеренчә, әлегә ташъязмалар безнең эрага кадәр VI-V гасырларда үк эшләнгән булырга тиеш. Бу язмаларны Европа телләренең берсендә дә укый алмаганнар. 1992—1993 елларда гына алар, ниһаять, төркичә укылган (Эльваран, 1993, 15 бит). Төрек халык музыка белгече Халук Тарҗан Франциядәге Глозель музеенда шул ташъязмаларга игътибар итә. Аларның фотокүчермәләрен алып, борынгы язулар белгече булган төрек галиме Казым Маршанга җибәрә. Маршан язмаларның борынгы төрки телдә язылганлыгын исбатлый. Сорбонна университетында уп шул хакта доклад ясый. Язмаларны уку нәтиҗәләре турында гына сөйләп калмый, ә, табылган алфавитны латин алфавиты белән чагыштырып, аларның охшашлыгын да билгеләп үтә. Академик Мирфатих Зәкиев тә: «Төркиләрдә әле безнең эрага кадәрле үк бер төрле язу булганлыгын галимнәр дә раслый алды, аны туран язуы дип атадылар... Бик борынгы мәдәниятле этнос (халык) буларак төркиләр кешелек цивилизациясенә гаять зур өлеш керткәннәр",—дип язып чыкты.

Идел Болгары монголлар чорына кадәр нинди ил булган соң? Тарихчы Ф. Ш. Хуҗин, монгол чорына кадәрге Болгарның билгеләреле турында язганда, абруйлы-ышанычлы чыганакларга таянып болай ди: «Болгар шәһәрләре борынгы рус һәм көнбатыш Европаның шул чордагы шәһәрләреннән күпкә зуррак булган... Билгеле Болгар шәһәрләренең үнөч проценты ун гектардан да артык ныгытмалы мәйданны алып торган... Монгол чорына кадәрге Русьта исә ун гектардан артык билгеләреле булганнары өч бөтен уннан сигез генә процент тәшкил итә...»

Әгәр дә Владимир кенәзлек иткән вакытлар белән хәкем йөртсәк, рус кенәзлекләренең Идел Болгары белән шактый тыгыз элемтәдә торганлыкларын күрербез. Кенәз Андрей Боголюбскийның әнисе кыпчак, хатыны Болгар патшасы кызы булган, ул үзе болгар-татар телендә иркен сөйләшкән һәм язган. Болгар дәүләте Суздаль һәм Владимирга икмәк җибәреп торган, бу изге гамәл бигрәк тә иген уңмаган ачлык елларда эшләнгән. Иген игү ул заманнарда Русьта әллә ни алга китмәгән булган бит. Галимнәр Россиядә болгарлар төзеп калдырган корылмалар барлыгын да хәбәр итә. Мисалга, «Владимир каласына керә торган беренче төп «Алтын капка"ны XIII гасыр башында болгарлар ясаганын, ягъни шул заманда ук алар тарафыннан Русьта шундый капкалар ясау гадәте булдырылганын» әйтергә мөмкин (Ф.В. Салихова). Тарихчылар раславынча, «Византия ельяэмалары аша хәзер инде Киев каласын 630 елларда Кубрат ханның туганы Самбатос Кияби-Кий төзегәнлегә мәгълүм. «Самбат"—көйдәрә торган кояш нуры, «кий» исе төркичә «көй-көю» мәгънәләрен белдергән. Соңрак Самбат каласы Кияби—Киев—Кызыл кояш (калька сүз) дип атала башлаган. Моны украин галимнәре дә инкяр итми» (Ф. В. Салихова).

Идел Болгарында нәрсәләр эшли белгәннәр? Әлбәттә, болгарлар иген иккән, яшелчәчелек-бакчачылык белән шөгыльләнган, агач һәм таш йортлар салган, шәһәрләр күтәргән, бик яхшы сугару корылмалары корган, алтын-көмеш һәм чуен эшләнмәләр белән шәрекъ илләрен генә түгел, көнбатыш илләрне дә тәэмин итеп торган. Шуны да әйтергә кирәк, болгарлар җирне сука

белән сукаламаган, ә сабан белән сөргәннәр, кыр эшләре тәмамланганнан соң сабан бәйрәме үткәргәннәр, ягъни бүгенге сабантуй бәйрәмен, диик.

Илдә төрле һөнәр осталары күп булган—чүен кою, керамика, алтын-көмеш, савыт-саба, кием-салым, читек-көвеш һ. б. кебек әйберләр шулар кулы белән эшләнгән. Идел Болгары йөзләрчә елдар буена Көнбатыш белән көнчыгышның халыкара сәүдә үзәге булган.

Болгар каласындагы ярминкәгә Азия якларыннан—Иран, Һиндстан, Төркестан, Кытай һ. б. илләрдән; көнбатыштан рус җирләреннән, Скандинавиядән һ. б. илләрдән сәүдәгәрләр җыела торган булганнар. Соңыннан, Болгар дәүләте таркалгач, бу ярминкә Казанга күчерелгән, ә инде Казан ханлыгын руслар яулап алганнан соң, аны Түбән Новгородка күчергәннәр һәм ул аталы Мәкәрҗә ярминкәсенә (Макарьевская слобода) әйләнгән.

Болгар хәрби яктан да нык үсеш алган, монгол яулары Калька суы буенда руслар белән сугышып кайтып, Идел буйларына яу чапкач, болгарлар аларның беренче дулкынын тар-мар итеп ташлаганнар... Әмма монголларның тагын да көчлерәк икенче дулкыны Бөек Болгар дәүләтен дә ялмап йоткан, ил Алтын Урда составына аның бер төбәге булып кына кушылган, шулай да күпмедер дәрәҗәдә бәйсезлеген саклап кала алган. Урданың мәдәни һавасын нәкъ менә болгарлар билгеләгән. «Урта гасыр дөнья цивилизациясендә Идел Болгары үзенә бер аерым урын тоткан. Ул Көнчыгыш Европа халыкларының мәдәни хәзинәсенә дә күп рухи байлыклар өстәгән",—дип яза тарихчы Ф. Хуҗин.

Җучи Олысы (Алтын Урда)

Алтын Урда дәүләте буш урында күтәрелеп чыкмаган. Дәүләтнең икътисадын күчмә терлекчелек, игенчелек, һөнәрчелек, сәүдә үстергән. Урданың күп телле халкы да мәдәни яктан төрәккый иткән, әмма, илнең рәсми теле төрки-татар теле булып, Урда белән рус кенәзлекләре арасында язышу да шул телдә алып барылган, күп кенә руслар татар телен белгәннәр.

Димәк ки, Алтын Урданы кыргый күчмә кабиләләр туплланган урын дип күзаллау һич тә дөреслеккә туры килми. Ул кабиләләр үзләренә кадәрле үк мәдәниятле булган җирга килеп утырганнар, шул чордагы халыкның матди һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерерлек мәдәният булдырганнар. Шулай булмаса, бу дәүләт 250 ел яши дә алмас иде. Шул үк вакытта монгол-татарларның абруй-дәрәҗәле кешеләре күп нәрсәләрне кытайлардан, төрки халыклар булган уйгур, болгар һәм башкалардан алган, шул рәвешле Руська һәм хәтта Европага аларда моңарчы булмаган матди һәм рухи байлыкларны алып килгән. Рус чыганакларында барыннан да ешрак кыпчаклар, болгарлар, казанлылар телгә алына. Татар-монголлар килгәч, Җучи Олысы халыклары шуларның йогынтысына тарган һәм руслар барысын да «татарлар» дип атап йөртә башлаган.

Урдалыларның руслар белән үзара мөнәсәбәтләре турында бераз әйтеп үзган идек. Дәвам итик. Урданың югары катламы белән рус кенәзләре үзара бик нык аралашкан, шулай булгач, ул катлам мәдәниятенә һич тә тискәре йогынты ясый алмаган.

Әлеге дә баягы, Ростов-Донда 2000 елда басылып чыккан дәреслеккә тагын бер кат күз төшерик әле. Г. В. Драч татар-монголларга тискәре бәя биреп: «Ничек соң үзләштерү икътисады чорында яшәгән бу халык борынгы цивилизацияләре булган халыкларны йөзләрчә ел дәвамында үзенә буйсындыра алган һәм изеп торган?"—дип аһ ора.

Күрәсең, Урданың үзләштерүче генә түгел, ә җитештерүче икътисады да булган. Бик борынгы халык буларак, татарлар үз икътисадын булдырганнар. Шуның өстенә Урдага Болгар дәүләтеннән игенчелек, һөнәрчелек, сәүдә итү дә килеп өстәлгән.

Алтын Урданың дәрәҗәле кешеләре—аксөякләр гыйлемне һәм башка

файдалы шөгыльләрне кайдан алганнар? Өстәрәк татарларның этник мәдәнияте бик борынгы тамырларга барып тоташканлыгы әйтелгән иде. Урдалылар җәмгыятенә болгарлар да бик зур йогынты ясаган. Болгар (рус ельязмаларында ул «Бөек шәһәр» дип йөртелә) бөтен Идел буена уңай тәэсир итеп торган. Х гасыр башында—Алмыш хан заманы—920 елда Болгар иле ислам динен кабул иткән. Бу дин аңа, руник язудан аермалы буларак, яңа язу—гарәп алфавитын алып килгән, кулына Изге китап—Коръән тоттырган. Әллә болар Алтын Урданың мәдәниятенә саллы өлеш булып ятмаганмы? Урданың Кытай, Һиндстан, гарәп илләре белән багланышлары, Шәрекъ белән даими сәүдә әлемтәләре турында да онытмаска кирәк. Алтын Урда шагыйре Сәиф Сарае Урда аксөякләренең ел саен кыш чыгарга Мисырга күченеп торулары хакында яза.

Гарәп тарихчысы Әмин-әл Хали 1330 елда Мисыр солтаны Әл-Насирга Болгардан хат һәм бүләкләр белән илчеләр җибәрелгәнен бәян итә: «Илчеләр үз патшаларыннан ау күренешләре төшерелгән ау киеме, кондыз тиресеннән тегелгән халат, чигелгән башлык киеме, ... алтын камәр—билбау, үзләре эшләгән кылыч һәм алтын белән чигелгән солтан байрагы алып килгәннәр",—дип яза ул. Шул рәвешле, болгарлар үзләренең дөньяда нинди мәдәни һәм сәяси урын тотканлыкларын раслаганнар. Үзбәк хан монголлар Түбән Иделәгә килеп 100 ел яшәгәннән соң гына ислам динен кабул итәргә карар кылган, шәркый илләрнең һәм болгарларның көчле йогынтысын кичергән.

Яшьләрне дини мәдрәсәләрдә укыткан лыкларын да иске алырга кирәк. Әйе, Алтын Урданың үз мәгариф системасы булган, яшьләр мәдрәсәләрдә гыйлем эстәсәләр, дәрәҗәле өлкәнрәк кешеләр Шәрекънең Каһирә, Димәшекъ, Бохара, Исфахан шикелле мәдәни үзәкләрендәге университетларда укыганнар. Алар анда дини философияне дә, фәнни белемнәрне дә үзләштергәннәр. Мәдрәсәләрдәге яшьләр Коръән ятлаган, Әбүгалисина, Әл-Фараби, Ибн-Рөшти философиясен, Фирдәүси, Сәгъди, Хафиз, Хәйям һәм башка шагыйрьләрнең шигъриятен өйрәнгән. Аларга логика ("мантыйк") фәне дә укытылган. Татар шагыйрьләре әле XII гасырда ук дөньяви поэмалар иҗат иткәннәр (Кол Гали һ. б.).

Гарәп галиме Рәшиддин (1247—1318) төрки телнең монгол теленнән бик нык аерылып торганлыгын яза. Алтын Урдага сәяхәт кылган гарәп сәяхәтчесе Ибн-Батута «бу ил халкы кыпчак телендә сөйләшә» дип язып калдырган. Үзенең 1340 елда язылган «Сәүдә эше» китабында итальян Франческо Пиголотти да шуны раслый (И. Таһиров). Шул чорны өйрәнүче тарихчыбыз Миркасыйм Госманов та хан ярлыкларының кыпчак теленда язылганлыкларын әйтә, ул Сарайлы Али Мөхәммәтнең «Мөхәббәтнамә» (754 ел), «Һәһҗәл фарадис» (759 ел) әсәрләренең кыпчак теленда язылуларын күрсәтә. «Үзбәк хан, монгол телен белсә дә, кыпчакча сөйләшкән» (И. Таһиров).

Алтын Урдада һөнәрчеләр һәм зәргәр (ювелир) осталары бик затлы-зәвыклы әйберләр эшләгәннәр. Гарәпләрдән корал ясау серләрен өйрәнеп, Урда осталары Мономах бүреген һәм Александр Невскийның алтыланган сугышчан шлемын (очлымын) ясап биргәннәр. Алар эшләгән зәвыклы матур сугыш кораллары хәзергә кадәр Эрмитаж залларын бизәп тора, узган гасырның алтмышынчы елларында Ленинградның (хәзер Санкт-Петербург) рус музеенда күргәзмәгә дә куелган иделәр.

Ахыры киләсе санда.

Дискуссия: "Безнең заман герое"

Әхмәт
Рәшит

ЗУРДАН КУБЫП СӨЙЛӘШКӘНДӘ

Ул вакытта кемнәрдер мине бәлки идеалистлыкта да гаепләгәннәрдер—азмыни Жир йөзендә, башкалар сүзенә колак салмыйча, үз фикерен генә дәрес дип йөргән акыллы башлар! Мин дә үземне бердәнбер хак сүз әйткәнмендер дип дәгъва итми идем югыйсә. Шигыремдә рефрен булып кабатланган:

Шагыйрьләрдән өстен Алла гына,

—дигән фикерне, нык лы иманыма таянып, бөтен дөнья әдәбиятын күздән кичереп әйткән идем. Әйе, галимнәр әдәбият үсешендә аерым-аерым чорлар: классицизм, романтизм, реализм галәмәтләре һәм тагын әллә нинди әкәмәтләр куралар, теге яки бу ижатчыга ниндидер ярлыклар ябыштыралар, бөтенесен жәмгыятьтә өстенлек иткән карашларга яраклаштырырга тырышалар. Ләкин сүз сәнгате бер бөтен бит ул. Ул—өзлексез процесс. Ул—буыннары кайбер урыннарда ялтырап торган, икенчеләрендә исә бераз күгәрә төшкән, әмма барыбер дәвердәге, халыкларны, мәмләкәтләрне тоташтыра торган очсыз-кырыйсыз чылбыр. Башкача булуы мөмкин дә түгел. Шигъриятебезнең чишмә чыккан жирендә нәфләван булып калыккан шул ук Колгалинең рухи дөвамчылары бүген дә юкмыни?!

Әдәбиятны вакыт кысаларын белән дә, географик координатлар белән дә булгәләп булмый. Аны чорларга бәйләп карау, ниндидер гасыр тамгасы сугу җайлылык өчен бер шартлы чара гына. Заманында жан вә кан дошманнары рәсүлебез Мөхәммәтне, ул бит Алла илчесе дә, пәйгамбәр дә түгел, гади бер шагыйрь генә, дип битәрләгәннәр. Нәрсә ул, яшәешнең олуг хакыйкатьләрен аңламаган һәм әле аңларга да сәләтсез булган шактый надан тарафдарларына һәм Алланың үзеннән инган изге сүрәләргә теш-тырнагы белән генә түгел, кылычы белән каршы торучыларга: "Әйе шул, мин—шагыйрь" дип акланып торсынмыни?! Коръәннең ничәмә-ничә аятендә әйтелә бу хакта. Изге китабыбыз белән азмы-күпме таныш булган һәр кеше андагы илаһи сүзнең гаять үтемле, шаһиранә булуын инкяр итә алмастыр. Халык шагыйрь Гамил Афзалның "Минем 100 яшь тулгач язачак жырым" дигән бик гыйбрәтле бер шигыре бар:

Күз алдымда шаулап йөз ел үтте,
Тел зиначыларны үлеп бетте, —
Ялганчыга дөнья тар икән.
Күңелем һәр көн илгә бәхет көтте,
Бәхет көтеп, үй киләбен сүтте.
Эшчәннәргә бәхет бар икән,
Кичләр зәңгәр, таңнар ал икән.
Ничаклы дәһшәт дөньяга килде,
Ничаклы нәбиләр дөньядан китте, —

Мин һаман да эшлим, мин исән.
Көнгә карап көлеп йөргән өчен,
Кешеләргә шатлык биргән өчен,
Йөрәгем яшь, күңелем шук икән.
Әллә миңа үлем юк микән?

Әйе шул! Тормыш дәвам итә. Гомерләргә гомерләр ялгана. Көндәлек мәшәкатьләр дә бер заман онытыла. Ләкин, барыбер, мирас булып дөньята олыг, мәңгелек хакыйкатьләр кала.

Мин шигырьнең кайда, ничек, ни сәбәптән тууы, ижат процессының хикмәтләре хакында кат-кат уйланганым бар. Ярый, тормышта көн саен кабатланып торган вакыйгалар турында, әдәбияттан алган тәжрибәләргә таянып, бүгенге кирәкле, актуаль темага кеше укырлык берәр нәрсә әвәләп кую авыр да булмасын, ди. Шул уңайдан жиделлык мәктәптә укыган бер сабакташымның:

Безнең класс бик якты —
Алты тәрәзәсе бар;
Дүртлегә һәм бишлегә
Укылар укучылар, —

дип язганы искә төште әле менә. Әйе, бөтенесе дөрес, бөтенесе төзек; идеясенә дә, ритм-рифмасына да тел-теш тидерерлек түгел. Сабый баланы гаеплән тә булмый. Әле кайчан гына, без кичергән заманнарда гына "чын шагыйрь" исеме күтәреп йөргән, хәтта кирпеч калынлыгы китаплар чыгарган байтак абзыкайлар һәм апакайлар да шул бала дәрәҗәсендә ижат итәләр иде. Алай гынамы, хәтта мактаалар да иде.

Ә шигырь бит ул бөтенләй башка нәрсә. Ул бит бөтенләй башка дөнья! Сөеклe Такташыбызның:

Март аеның нечкә билле җиле
Сузылып ятып җиргә кар ашый, —

дигән юлларын хәтерли торгансыздыр. Математик төгәллеккә дәгъва иткән, кагыйдәләргә һәм формулаларга буйсынып яшәүче берәрсе: "Ничек инде, җилнең биле буламыни? Нечкә яки юан дип сөйләргә адәми зат түгел ич ул җил!.. Әле өстәвенә җиргә сузылып ятып салкын карны да ашый..." дип ихлас гажәпләнүе мөмкин.

Шигырь дөньясы бөтенләй башка планета шул ул! Анда кешеләр шигырь телендә сөйләшәләр. Бу үзенчәлекне һәркем аңлап та бетермидер. Коръән кадәр Коръәнне дә аңлап бетермәүчеләр бар. Ләкин... бәхетебезгә күрә, аңлаучылар да җитәрлек. Коръәннең олуг шигъриләтенә төшенгән, дөньяның төрле культураларында яшәгән бөеклəр мона битарафкала алмаганнар, аның тылсымлы юлларыннан илһам алып, үзәл әсәрләр ижат иткәннәр.

Күктән җиргә төшәм дә, "Бүгенге татар әдәбиятының кайларыннары кемнәр?" дигән сакраменталь сорауга килеп төртелəм. Соңгы егерме еллар белән чиклəнергә тиешмен икән... Ярый соң да... Ләкин минем бүгенгене борынгыдан аерырга хакым юк. Без—шул үк Колгалиләрнен, Сәйф Сараиларнын, Мөхәммәдъярларныи, Тукайларныи, Туфаннарныи дәвамчылары. Борынгыдан калган бөек мирас безгә ышанычлы таяныч ноктасы булды. Ин сөенечлесе, без халкыбыз ялагап шул рухи биеклектә кала алдык. Чигенүләр, югалтулар булуын булгандыр—анысының җитди сәбәпләре бар. Социаль гаделсезлек, милли изелү, ижтимагый үзгәрешләр кебек зилзилаләр эзсез генә үтмәгәндер. Шулай да... "Ат аунаган жирдә төк кала",—ди бит татар халкы. Күпмедер күләмдə калган алар. Калган... һәм бүгенге шигъриятебезнен тәрәкыяте өчен ундырышлы жирлек тудырган.

Егерменче гасырнын икенче яртысында әдәбият мәйданына аяк баскан ижатчыларыбызга гына игътибар итегез сез. Бүгенге шигъриятебездә ат уйнаткан, ижат мәсьәләсенда башка халыкларнын берсенә дə сынатмастай күпме талантларыбыз бар! Матбугат мәйданнарынын соңгы елларда сизелерлек дәрәҗәдə киңәеп китүе шагыйрьләр өчен дə яңа мөмкинлекләр ачты. Мәртәбәле журналларда И. Юзеев, Ш. Галиев, Роберт Әхмәтҗанов кебек өлкәннәребезнен бүген дə яшьләргə хас энергия белән бу катлаулы заманнын ин мөһим мәсьәләләренə мөрәҗәгать итүләре сөендерə. Алар, башларыннан нинди генə ижтимагый, сәяси, икътисади, мәдәни катаклизмнар узган булса да, ана сөте белəн кергән иманнарына тугры калдылар, хал-

кыбызның гасырлар буе хыялланган изге максатларын байрак итеп күтәрделәр. Әдәбиятта элек-электән бик кызыклы бер күренешне гажәпләнеп күзәтми мөмкин түгел. Элгәрләр белән соңгырак буыннар арасында үзара тәэсир итешү, ижат сферасында бер-береннең тәжрибәсенә таяну шуна күрә бик табигый чагылыш таба. Әлеге күренешне һәммәсен "остаздар", яшьрәкләрне "шәкертләр" дип кистереп әйтү хакыйкатькә бик үк туры килеп тә бетмидер. Узган гасырның алтмышынчы елларында шигъри Пегасын йөгәнләргә алынган "Равил Фәйзуллиннар буыны" дип йөртелгән яшьләр төркеме хәтта инде әдәбиятта үзенең мәртәбәле урынын биләргә өлгергән аксакалларыбыз Х. Туфан, Н. Арслан, С. Хәким ижатына да унай йогынты ясамый калмады. Бу яшьләрнең аларга күпмедер дәрәҗәдә замандаш, кордаш булган каләмдәшләренә дә тәэсире зур иде. К. Латыйп, Р. Вәлиева, Ф. Гыйззәтуллина, Б. Рәхимова, Ә. Гадел, Р. Шиһап, Н. Гамбәр, Ә. Исхаков һ. б., монарчы профессиональ дәрәҗәдә эшләп килсәләр дә, соңрак шактый җитди һәм уңай сыйфат үзгәрешләре кичерделәр.

Инде урта буынның өлкәннәр даирәсенә күчеп барган, кавырсыннары житәрлек нығыган бу "алтмышынчылар" бүген татар шигъриятенең төп таянычлары, үзләрененең эзләренә басып килүче энекәшләренә һәм сенелкәшләренә сабакълар бирерлек булып житеште. Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Мингалим, Ф. Яруллин, Г. Рәхим, Р. Гатауллин, Рәшит Әхмәтҗанов, К. Сибгатуллин (кызганычка каршы, бу икесе арабыздан да китеп бардылар инде), З. Мансуров, Л. Шагыйрҗан, И. Гыйләжев, һ.б. хәзерге ижат процессында төп көчне тәшкил иткән, шигърият арбасын төптән жигелеп тартkан шәхесләр.

Сөенечкә дин әйтик, иншалла, аларга алмашка татар шигъриятен киң жилкәләрендә күтәреп барырдай Р. Зайдулла, Г. Морат, Л. Зөлкарнәй, Л. Лерон, Р. Корбанов, һәм соңгы ун ел дәвамында М. Закир, Р. Аймәт, Ф. Жамалетдинова, Р. Рахман, Танчулпан, Л. Янсуар кебек талантлар өлгерде. Әдәбият мәйданының, шөкер, буш торганы юк әле. Кемдер китә, кемдер китә—әмма матурлыкка мохтаж тормыш барырбер дәвам итә.

Узган 2003 ел да шигъриятебезнең гүзәл бәйрәмнәренә бай, истәлекле булды. Ул бала чагыннан бабай чагына кадәр күлыннан каләмен төшермәгән, ару-талуны белмичә бөек музасына хезмәт иткән, өлкән яшьтә дә ижат учагы тоташ яныш торган Татарстанның Халык шагыйре, республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Илдар Юзеевның 70 еллык юбилее белән башланган иде. Поэзиянең төрле жанрларында, бигрәк тә аның поэма һәм җыр өлкәләрендә нәтиҗәле эшләгән, ул гына да түгел, драматургиядә дә үзенчәлекле сүзен әйтә алган, әллә ничә буын яшьләренә гыйбрәтле сабак биреп, милләттәшләребезнең ихлас мәхәббәтен казанган шагыйрь көндәлек матбугатта соңгы вакытта басылып чыккан әсәрләре белән дә үзенең ижат биеклегендә калуын тагын бер тапкыр раслады.

Әйе, әдәбият бәйрәмнәре байтак булды узган елда. Әреләре дә, ваграклары да булгандыр. Һәркемнең үз биеклеге. Кәтеп алган истәлекле даталарның берсе—ул Татарстаннын Халык шагыйре, республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Равил Фәйзуллинның түгәрәк туган көне иде. Тантаналар Казаннын Зур концерт залында гына түгел, шагыйрь туган төбәктә дә, республикабыз шәһәрләрендә һәм авылларында да, мәдәният сарайларында, китапханәләрдә һәм мәктәпләрдә дә шаулап-гөрләп үттe. Газета-журналларда, радиода һәм телевидениедә бу үзенчәлекле талантнын тормыш юлы, дәүләт һәм жәмәгать эшчәнлеге, кабатланмас ижаты турында зурдан күбрә сүз алып барылды. Равилнең үзен дә, аның шигъриятен тәкъдир итүчеләрне дә ин сөендергәне, мөгаен, беренче хәрәф таныган туган мәктәбенә һәм Балык Бистәсе урамнарынын берсенә аның исеме бирелү булгандыр. Бу инде бөтен халык тарафыннан таныну дигән сүз иде. Юбилее көннәрендә Р. Фәйзуллин әдәбият сөючеләрне өр-яна китаплары белән, ә галимнәребез аның ижатына багышланган экләнтык вә монографияләр белән куандырды.

Ул житәкләгән "Казан утлары" журналы бүген чын мәгънәсендә—әдәбиятыбыз флагманы. Мөмкинлегем һәм вакытым тар булу сәбәпле мин андагы романнарга, повестьларга, хикәяләргә, сәхнә әсәрләренә иркенләп туктала алмыйм. Бу очракта мине барыннан да бигрәк шигърият кызыксындыра. Нинди ул? Кешеләр күнелен жәлеп итә аламы? Нәрсәгә чакыра? Шактый киң карашлы, әзерлекле, белемле, денья әдәбиятының хәзерге торышыннан гына түгел, ин борынгы чорларынnан да хәбәрдар

бүгенге укучы, егерменче һәм егерме беренче гасырның үтә катлаулы һәм каршылыклы күренешләре белән бергә-бер калып, аннан чыгу юллары эзләгәндә, үзен борчыган сорауларга җавап табырга тырышкан. Юлбашчылар, сәясәтчеләр, гайрәтле гаскәр башлыклары килә дә китә. Дөньяда үзенә генә түгел, балаларына һәм оныкларына да яшисе бар бит әле! Кешелек намусы язучыларда һәрвакыт үзенең яклаучыларын күргән. Заманында бөек Шиллер: "Шагыйрь ул—бердәнбер чын кеше",—дип раслаган, шундый уй караш уртасында гуманистларына язучы хезмәтенең изгелеге турында фикер йөртергә мөмкинлек биргән. Чөнки алар сәнгатьнең иҗат кешеләренә җир шарының бер генә хакиме дә иресә алмастай көч-кодрәт бирүен аңлаган. Польшаның мәшһүр язучысы Ян Парандовский үзенең "Сүз алхимиясе" дигән атаклы хезмәтендә, бөтен дөньяның төрле-төрле чорлардагы әдәбиятын күздән кичереп: "Сүз вакыт һәм пространство өстеннән хакимлек итә. Фикер, хәрефләр әзтәмәсенә килеп эләккәндә генә, яши һәм тәэсир итә ала. Калган һәммә нәрсә дә жилгә чәч" дигән нәтиҗәгә килгән. Ул Гомер, Данте, Шекспир, А. Мицкевич, Гарриет Бичер-Стоу кебек әдипләрне короольләрдән һәм һәртөрле данлыклы ялап алучылардан өстен күргән. Сүзләрен исбатлар өчен һәркемне ышандырырлык саллы дәлилләр китергән.

Үрнәк алырдай мисаллар күп. Шөкер, бөтенесе булмаса да, әдәбиятыбызның гвардиясен тәшкил иткән, заман һәм замандашлары алдында, Такташбыз сүзләре белән әйткәндә "үзен мәсьүл" саналган язучыларыбыз күптәнге һәм бүгенге мирастан матур үрнәк алалар. Аларның күзе күпне күрә, колагы күпне ишетә.

Соңгы елларда татар әдәбиятының ориентирлары тарих ягына авышты, дисәм ялгышмамдыр. Бу нәрсә прозада да, драматургиядә дә, поэзиядә дә чагыла. Моның шулай булуы бик табигый, минемчә. Без ничәмә-ничә елдар, атасыз балалар шикелле, яшәеш карурманнарында адашып йөрдек. Баксан, куе чытырманлыклар артында, күнелләрне иркәләрлек иркенлек, гасыр офыклары арыгында данлы тарихыбыз, мәшһүр мәдрәсәләребез һәм, әлбәттә инде, безгә дөрес юл күрсәтердәй олпат затларыбыз—халык һәм дәүләт мәнфәгатьләре өчен өзгәләнүче хәнбикаләребез һәм шул фикаһгале чорларда аңа ышанычлы терәк булган иманлы шагыйрьләребез бар икән ләбаса! Ә без үзебезне кыргыйларга һәм шыр наданнарга санап йөргәнбез. Дәреслеккә сусаган әдәбият, сәнгать, фән һәм мәгърифәт дөррәү шул заманнарга ташландылар.

Егерменче гасыр башындагы зыялыларыбыз һәм бүгенге көндә, ниһаять, Халык язучысы исеменә лаек булган Нурихан Фәттах кузгатып жибәргән бу башлангычны бераз соңрак М. Хәбибуллин, Т. Миннуллин, Р. Батулла, Ф. Латыйфи кебек әдипләребез күтәреп алды. Аннан гомуми хорга шагыйрьләребез дә кушылды. Шәхсән мин үзем дә халкыбызның үзанын уяту өчен гаять әһәмияттле бу темадан читтә кала алмадым—"Сөембикә", "Колшәриф", "Мөхәммәдъяр", "Без—татарлар" дигән поэмаларым белән уртак хәзинәгә ниндидер өлеш кертергә тырыштым.

Егерме беренче гасырга аяк баскач, татар тарихына мөрәҗәгать итеп, ин уңышлы әсәр иҗат иткән шагыйрь—ул, мөгаен, Зиннур Мансуров булгандыр. Поэма жанрында үзенчәлекле сүзен әйтергә олгергән, "Хозыр галәйһес-саламне эзләү", "Балкыш яки Хәйретдин Мөжәйнең сугыш язмаларыннан юллар", "Кылдан нечкә, кылычтан үткен" әсәрләре әдәбият белгечләренең югары бәясен алган таныклан каләмдәшебез иде инде ул. Шигърияте шактый чарланган, зур тормыш тәжрибәсе туплаган, киң эрудицияле шагыйрь бу юлы безне "Ике егълау" поэмасы белән сөендерде.

Жиде икълим чиген инләп инрәү йөри,
инрәү кайта, кайта ничә ел аша.
Мәшрикъ якны тотаттырып мәгърип якка,
кара-каршы ике бикәч егълаша.

Аларның берсе—һәр милләттәшебез өчен якын вә газиз хәнбикәбез Сөембикә, икенчесе—рус эпосы "Слово о полку Игорове"дә гәүдәләнеш тапкан Ярославна. Чорлар төрле, уй-максатлар төрле. Әмма икесендә дә—аянычлы фажига. Берсе ил хәтле илен югалткан, икенчесе яу чапкан сөйгәнен сагынып өзгәләнә. З. Мансуровның бу әсәре турында матбугатта бәяләр аз булмады. Фикер ләкин уртак иде—"Ике егълау" китап сөючеләр тарафыннан да, әдәби даирә тарафыннан да татар шигъриятенең чираттагы казанышы буларак кабул ителде. Аның республиканың ин мәртәбәле булегенә—Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә тәкъдим ителү факты үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли.

Тарих—борынгы елъязмалар жыелмасы гына түгел. Аның янасы, бүгенгесе дә бар. Соңгы ун-унбиш ел дәвамында зур шагыйрьләребез биеклегенә күтәрелгән Лена Шагыйрьҗан нәкъ менә хәзерге заман вакыйгаларына мөрәҗәгать итә. "Дөнья базары яхуд яна Америка фажигасе" исемле поэма бер караганда Нью-Йорктагы Сәудә үзәген шартлату унаеннан гына язылганлыр сыман. Әмма шагыйрәнең сүз сөреше моның белән чикләнми. Ул бу фажиганең асыл сәбәпләрен эзли, тарихи экскурспар ясый, гыйбрәтле параллельләр таба. Коръән сүрәләреннән, атаклы язучылар Уолт Уитмен, Генри Лонгфелло, Теодор Драйзер, Эдгар По әсәрләреннән китерелгән өземтәләр авторның фикерләрен тагын да көчәйтеп, тулыландырып җибәрәләр.

Туктаусыз эзләнүчән, актив ижат итүче Лена Шагыйрьҗан ижатына каләмдәшләре дә битараф калмадылар, әдәбият белгечләре аның шигъри үсешенә аледән-але игътибар итәләр. Алар арасында ин салльсы, белеп-төпченеп язылганы тәнкыйтче Равил Рахманиның 2002 елда "Казан утлары" журналында (4 сан) басылган "Шагыйрәнең язмыш келәме" исемле мәкаләсе булгандыр.

Һәр ижат кешесендә башыннан кичкән, күнелен дулкынландырган, уй-тойгыларын тоташтан бимазалап торган вакыйгалар һәм тормыш күренешләре белән бәйләнгән ихтыяж—аларга карата үз мөнәсәбәтенне белдерү теләге—яши. Фәрит Гыйззәтуллина, Резеда Вәлиева, Эльмира Шәрифуллина һәм башкаларның поэма кебек катлаулы жанрда үз көчләрен сынауларын шул ижади ихтыяж белән аңлату кирәктер. Бу шагыйраләрнең өчесе дә—тормыш борылмаларында түрле хәлләр белән очрашкан, яшәешләре дәвамында бик күп гыйбрәтләр татыган, заманга, кешеләргә әйтер сүзләре булган шәхесләр. Эльмира Шәрифуллина, мәсәлән, моннан унбиш еллар элек безне "Тәмуг кисәве" дигән ихлас поэмасы белән әсир иткән иде. Заманында бу әсәр турында матбугатта язып та чыккан идем. Соңгы елларда "Казан утлары" һәм "Мирас" журналында бөек мәгърифәтчебез К. Насыйри хакында "Каюм коесы" һәм Г. Тукайга багышланган "Шагыйрь чишмәсе" поэмаларын бастырды. Бу әсәрләр дә шигырь сөючеләрдә зур кызыксыну уятты. К. Латыйп, тарих темаларына мөрәҗәгать итеп, борынгы дәүләтебез—Казан ханлыгы өчен кәһәрле чорда яшәгән Сөембикә һәм Гәүһәршад кебек шәхесләр турында язды. Ә. Гадел "Көл эченнән үсеп чыккан чәчәк" поэмасында башкалабыз Казанның үткән чорларын бүгенге белән ялгады. Х. Бадыйков "Мирас" журналында зур күләмле "Вертикаль" дигән әсәрен бастырды.

Һәрбер әдәбиятның да тарихы шигъри чишмәләрдән, шигъри дәрьялардан башлана. Шигырь дигәнһәрвакыт дә ин затлылары, ин озын гомерлеләре—поэма, эпос, кыйссадыр, мөгаен. Кайсы гына мәдәниятне алып карасаң да, аның ин хөрмәтле мөнбәрендә һиңдинең "Махабхарат"ын, юнанның бөек әсәрләрен ижат иткән сукыр Гомерен һәм... татарның Колгалиен күрербез. Шуна күрә поэзиянең бу жанры аерыча мәртәбәле. Милләттәшләребезнең поэмага яки дастанга ихтирамы элек-электән килә. Әлбәттә, еллар үтү белән ул шактый сыйфат үзгәрешләре дә кичерде. Борынгы чорларда бу зур күләмле әсәрләр ниндидер вакыйгалар һәм аларда катнашкан кәһарманнар турында тәфсилле бәян итү, ашыкмый гына хикәяләү булса, хәзер теге яки бу вакыйганың һәм шәхеснең гамәл-кыланышында нинди фәлсәфи мәгънә ятуын ачыклауга игътибар ителә—аның ачык кына сюжет сызыгы да булмый.

И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Мингалим, Рәшит Әхмәтҗан, Зөлфәт, М. Әгъләмов поэмаларындагы бу үзенчәлекләр соңгы чор тәнкыйтьчеләре дә басым ясыйлар. Ләкин бу—сюжетлы поэмалар инде тәмам гамәлдән чыкты дигән сүз түгел. Әле генә телгә алынган шагыйрьләрнең кайберләре дә, Х. Камалов, М. Шабаев кебек икәтчылар да поэма жанрының классик таләпләрен үтәргә, канунлашкан кагыйдәләренә буйсынырга тырыштылар. Утызынчы-кырыгынчы елларда ул таләпләр кагылгысыз үтәләләр иде. Соңгы чорларда публицистик башлангычның өстенлек итүе зур гомумилештерүләргә юл ачты—жанр исә мона карап ярлылланмады, киресенчә, уй-фикер ягыннан баеды гына. Темалар да артык детальләштерудән, һәр фикерне чәйнәп бирүдән арынды.

Сүз унаеннан балладаларга да тукталу кирәктер. Ул—татар шигърияте өчен бик якын, үз булган жанр. Бу өлкәдә уныллар элек тә бар иде. Хәзер дә аны И. Юзеев, Роберт Әхмәтжанов, Зөлфәт, М. Әгъләмов һәм башкалар чит итмиләр. Аларның лаеклы дәвамчыларын да күрәсе килә.

Шигъриятебезнең җыр хужалыгында эчне пошырлрлык байтак күренешләр аерыча күзгә ташлана. Югыйсә үрнәк алырдай күпме халкыбыз җырлары бар! Шагыйрьләребез генә түгел, хәтта драматурглары бәһа прозаиклары бар да инде матур көйгә салынып, телгә, кулланышка кергән яки монын-музыкасын, канат куярдай композиторын һәм башкаручысын көтеп яткан әллә никадәр шигъри әсәрләр тудырдылар. Замандашларыбыз И. Юзеев, Ш. Галиев, Ә. Баян, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Вәлиев, Р. Миннуллин, М. Галиев һ. б. сүзләрен язылган күпме җырлар дистә еллар буе сәхнә түрләреннән тошми. Алар белән рәттән сай әҗталекле, телнен-сүзнен егәрен һәм мәгънәсен, фикерләүнен мантыйкын-логикасын белмәгән, кемнәрнедер кабатлаган бер күзәнәкле шләгерләр дә әрсезләнеп мәйдан яуларга өлгерделәр. Көе, гадәттә, үзешчән музыкантныкы, шигъри тексты—очраклы, әдәбиятка ят кешенеке, башкаручысы—һәвәскәр. Һәр өчесе дә милли жирлектән, халык гасырлар дәвамында саклап килгән матур традицияләрдән аерылган. Аталы яшьләрыбызның газета-журнал битләрендә шуны искәртеп чан сугулары тикмәдән генә түгел бит. Шигъриятебез һәм музыкабыз ирешкән биеклекләрне югалту бөтен милләтебез өчен фажига булыр иде.

Әле кайчан гына социаль революцияләр ясаган, гражданнар сугышында каннар койган, ил өстенә кызыл байраклар күтәргән бәһадирлар, колхоз төзегән Мохтар картлар, СССР чикләрен саклаган Аникиннар, тырыш хезмәте өчен аэропланда очу бәхетенә ирешкән Гайжан бабайлар, һәртөрле социалистик яршыр алдынгыларны ижат кешесенең күз уңында иде. Үзгәрде дөньяр, үзгәрде! Хәзер шигъриятнен ин төп каһарманнары—тарихи шәхеслар һәм лирик "мин". Вакыйгаларның дөньяр-күләмнәре дә, жирле әһәмияткә ия булганнары да автор йөрәге, анын бәяләве, аның хөкеме аша уза. Әлбәттә, монын үнай яклары булган кебек, тискәре яклары да юк түгел. Автор яхшыны яманнан, алдынгылыкны искелектән, төрәкъкыятне катып калганлыктан аера аламы, аларга объектив була белләме—шундый сораулар да куела бит әле анын алдында. Хәлбуки... күлны күкрәккә куеп әйтик, бөтенесе дә ал да гөл түгел. Тарих мизгелләрен яктыртуда да, халкыбызның асыл сыйфатларын тасвирлауда да, гадәт-йолаларыбызны яклап сүз әйткәндә дә, мина калса, без бер якстан икенче якка күбрәк авышабыз шикелле. Идеалдагы ижатчы бернинди конъюнктураларга бирелмәүче, мостәкыйль фикерләүче, рухи яктан азат һәм бәйсез шәхес булырга тиеш. Кызганычка каршы, бүген әдәбиятка ташкын булып агылучы "яшь, таныш түгел буын" *(А. С. Пушкин билгеләмәсе)* бу хакыйкатьне житәрлек дәрәҗәдә үзләштермәгән әле. Әдәбият тарихын, әдәбият теориясен, бүгенге әдәби процессның үзенчәлекләрен белми торып, Парнас биеклекләреңә менү турында хыялланыра да мөмкин түгел. Хәзер хәреф таныган һәр кеше шигъриәт ошаган нәрсәләр әвәли ала. Ләкин һәр шигырь язучы да шагыйрь дигән сүз түгел әле. Әнә, Мөхәммәдъяр заманнарында:

Бу гыҗәиб бу кем шәһрнең эче тулуг:
Шагъыр улмыш барча кечек һәм олуг...

булган да бит, ул чордан аның "Таҳфи мәрдан"ы белән "Нуры содур"ы һәм Колшәрифнен "Кыйссаи Хөбби Хужа"сы һәм берничә шигъре генә безгә килеп житә алган. Әлбәттә, байтак рухи хәзиналәребезне илбасарлар юк иткән. Шул ук вакытта башка сәбәпләре дә булгандыр.

Мирасыбызны барлауда галимнәребез Х. Госман, Ж. Алмаз, Н. Юзиев, Х. Миннегулов, М. Госманов, М. Бакиров, Н. Хисамов, Х. Мәхмүтов, Ә. Шәрипов, Ф. Фасеев һәм башкалар бәяләп бетергесез эш башкардылар. Ул гына да түгел. Бүгенге шигърият үсешенә сизелерлек йогынты ясарлык ориентирлар күрсәтеләр, ижади киңлеккә чакырдылар.

Татар халкы—бөтен кыйтгаларга сибелгән планетакүләм олуг милләт. Республикабызда аның чирек өлеше дә яшәми—читтәгеләрнең санын-исәбен кем дә булса төгәл генә белә микән?! Арча белән Актаныш арасындагы төбәкләрдән карашыбызны Себергә, Ерак Көнчыгышка, Казакъстанга һәм Урта Азиягә, Кавказ тауларына, Оренбург һәм Астрахань далаларына күчерик әле. Аннан... тагын да еграграк якларга—чит мәмләкәтләргә... Япониядә булуым вакытында Токиода яшәүче әшмәкәр Таминдар ага Мөхит төрле илләргә таралган татарларның Бразилиядәге Амазонка суы буенда Сабан туе үткәрүләрен горурланып сөйләгән иде. Хәзер көндәлек матбугат чараларыннан, радиодан һәм телевидениедән андый бәйрәм-

нәрнең АКШта, Канадада, Төркиядә, Финляндиядә һәм хәтта ерак Австралиядә дә үздырылуын, анда хәзерге татар эшләре да жырлануын белеп-ишетеп торабыз. Чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез арасында әдәби ижат белән шөгыльләнүчеләр дә байтак. Китап-жыентык чыгарганнары да бар. Димәк, алар да безнең белән бер мәдәни мохитта гомер кичерәләр. Аралар якынайды—йөрәкләр дә бер тизлектә тибә башлады.

Мондый хатирәләргә бирелүем тикмәгә генә түгел. Әле кайчан гына ил капкалары ябылган, безнең мескен татар әдибе колхоз басуларында хезмәт алдынгыларын илһамландыручы тургайлар жырын гына тыңларга тиеш иде. Дөрес анысы, Америка кыйтасында тургайлар һәм сандугачлар гомумән яшәми. Анда Европадан күчеп килгән ижат әһелләре, кайчандыр тургайлар һәм сандугачлар турында шигырьләр яза башлагач, бер көлкегә калганнар иде инде. Татарларга, шуны белә торып, андый куркыныч янамас дип уйлыйм. Безнең илгизәр татар анда башка матурлыклар белән хозурлана алыр. Ә шулай да чит-ят илләрдә барып, илһамлы мизгелләрдә язылган әсәрләргә дә "сәяхәтче жыры", "турист мотивлары" итеп карамаска иде. Алар безнең рухи дөньябызга ниндидер яктылык өстәүче бизәкләр бит. Югыйсә, булды, гыйбрәтле сабаклар булды! Кайчандыр Роберт Әхмәтжанов Хиросима фажигаләренә багышлап "Ташбаш" балладасын язгач та, Балтика буенда үскән Сигулда усакларын жырлагач та, аны космополитлыкта гаепләүче усал телләр табылды. Р. Фәйзуллин Фәләстинәдәге һәм Әфганстандагы вакыйгаларга борчылып шигырь яки жыр яза икән—югыйсә моның өчен нигә буса куптарыргә!—анда да безнең кан вә жан кардәшләребезнең язмышы хәл ителә ләбаса! Кайбер тәнкыйтьчеләрнең башкаларга акыл өйрәтергә маташулары, әгәр ул аларның белемһәрә, талантлары һәм интеллектуаль дәрәҗәләре белән дә расланмый икән, чын ижат кешесен кимсетә, түбәнсетә генә.

Шигърият, бигрәк тә аның мәхәббәтлә, сөю-сөелүләргә кагылган, үпкәләүләрен, кавышу-аерылышу газапларын татыган мизгелләре турындагы сәхифәләре—нигездә яшьлекнең бәренче сафы хисләре. Өлкәнрәкләр өчен фәлсәфи лирикага, драмага яки эпоска тартылу хас. Бүгенге әдәби тормыштан да мисаллар күплән китерергә мөмкин булыр иде.

Кызым, сина әйтәм, киленем, син тыңла, дигәндәй, яшь каләмнәр колагына тагын шуны да кыртлән куясым килә. Шигъри казанышларыбыз нинди генә сөенечле, профессиональ язучылар сафы ничек кенә ишле булмасын, мина калса, соңгы унбиш-егерме елда "язучы" төшенчәсенең бераз кадере дә китте шикелле. Еш кына сафыбызга фокатъ тегә яки бу район нәшриятында спонсорлар ярдәмендә дәфтәр калынлыгы берме-икеме китапчык чыгара алган, әдәби хезмәткә исә пенсия яшенә житкәч кенә керешкән, язмаларны гади журналистныкыннан берни белән дә аерылып тормаган очракны кешеләр дә үҗәтләнеп килеп керә. Әдип белән әдәбиятчы, шагыйрь белән шигырь язучы бер үк түгел ләбаса! Аталы Вольтер үз заманында аларга карата "әдәбият кешеләре" дигән төшенчә кулланган иде.

Мин—деньяны шактый гизгән, дөнья халыкларының әдәбиятларын антик заманнардан бүгенгәчә өйрәнгән кеше. Шигъриятнең ин борынгы гүзәл өлгеләрен биргән Грециядә, мәсәлән, язучылар еошмасы фәкать шагыйрьләрне һәм прозаикларны тына берләштерә. Башка әдәбиятчылар тератр эшлеклеләре һәм журналистлар берлекләреңә тартылган. Миллиардтан артык халык яшәгән Һиндстанда да ижади көчләр аерым нәшриятлар, газета-журналлар каршында оештырылган һәр төрле түгәрәкләрдә аралаша. Илнең фажигале төстә һәлак булган премьер-министры Индира Ганди турында өч китап чыгарган Ума ханым Васудев шул мәгълүматны әйткәч, без—Советлар Союзыннан килгән бер төркем язучылар—бик гажәпләнгән идек. Хәзер генә менә күпмедер дәрәҗәдә аңлашыла: бер-берсенә капмакаршы идеологияләрне алга сөргән күп партияләрлек шартларында башкача булмый да торгандыр. Юк, мин моның белән ижат оешмабызны тәркатырга чакырмыйм—безне берләштергән олуг максатлар бар, безне вышанычлы таяныч итеп саныучы бөек милләтебез бар. Ә шулай да әдәби ижатка омтылучы көчләр аңа чын күнелдән хезмәт итүчеләр, үй-фикерләрен тиешле профессиональ дәрәҗәдә житкерүчеләр булсыннар иде. Үз-үзеңне алдарга кирәкми. Шигырь уты йөрәгеңдә яшьтән, ин дәртле һәм ихлас чагыннан кабынмаган икән, бөек Тукаебыз әйтмешли, "картаеп беткәч буыннар эш белү унайысы ул". Шулай дип яздым да, бер гыйбрәт-

ле очрашу искә төште. Радиода баш мөхәррир вазыйфаларын башкара идем ул вакытта. Көннәрдән бер көнне эш бүлмәмә полковник дәрәҗәсендәге хәрби кеше килеп керде. "Менә өтәвакага чыктым да, эш юктан шигырь яза башладым. Карап чыгыгыз әле шуны",–ди. Укыйм. Абзый әдәбияттан шактый мәгълүматлы күренә—рифмасы да үз урынында, ритм да төзек. Лөкин... шигырь юк. Ул абзый, очучы буларак, самолеттагы бөтен приборларның нәрсәгә кирәклеген биш бармагы кебек белә дер, әлбәттә. Һөнәре шундый. Ә нишләп ул минем ун яшемнән гомерем буе тугрылыклы булган һөнәремә шулай жинел карый? Мин бит, авиация өлкәсендә берни белмәгән килеш, аның самолеты штурвалы артына утырырга көрәчәт итмим! Шуның шикелле үзе язган һәм язганын кайдадыр (шөкер, нәшриятлар житәрлек хәзер—хәлвә акчаны гына чыгарып сал!) бастыра алган һәркемне дә язучы дип атап буламыни?!

Кайчандыр бөек Пушкин укыган Царское Село лицее кебек уку йортларында һәм мәртәбәле мәдрәсәләрдә шигырь язу серләренә дә өйрәткәннәр. Мәрхүм Нәкый ага Исәнбәт гаруз, мәкам, ритмик буыннар турында озаклап, тәфсилләп сөйли һәм һәрвакыт сүзен Г. Тукайның "Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш" поэмасындагы:

Фагыйләтән, фагыйләтән, фагыйләт,
Ну, Печән базары халкы күңле шат, —

дигән сүзләр белән йомгаклап куя иде. Әйе, әдәбият белеменең канунлашкан, гомуми кулланышка кергән үз тошенчәләре бар. Башын тулы дәһи фикерләр булса да, аларны бер калыпка салып тезмичә, йөрәк жылынмый остәмичә, туган телебезнең зур мөмкинлекләреннән файдаланмыйча укучылар күнелен биләрдәй, һәр яктан да камил әсәр ижат итү мөмкин түгел.

Өр-яңа тарих сүз осталары алдына хисапсыз күп проблемалар китереп куйды. Бу дөньякүләм глобальләшүү чорында үз-үзебезне милләт буларак саклап кала алырбызмы, ата-бабалардан калган мирас безгә тормыш ориентиры булырмы, рухи осталарыбызның аклыллы сүзенә, ижади антына тугрылыклы фидакяр кәһарманнарыбыз бармы, яшь буынның күнел түрен яулардык нинди сыйфатларга ия алар?.. Сорау, сорау, сорау... Модәррис Әгъләмов үз вакытында:

Безнең дәвам шулай яначакмы? —

дигән сорауны бөтен кискенлеге белән куйган иде. Шигырьнең, кемнәрдер шигырь генә дисәләр дә, тәэсир итү мөмкинлекләре гаять зур, тормышның төлөсә кайсы күренешен инләрдәй, аңлатырдай төрле-төрле жанрлары бар. Татар поэзиясендә борын-борыннан дастан да, мөнәҗәт тә, поэма да, баллада да, газәл дә, мәсәл дә, жыру да, бәет тә, мәдхия дә, мәрсия дә—һәммәсе бер-берсен тулыландырып, гомум бер симфония хасил итеп яшәгән. Кызганычка каршы, соңгы елларда поэзиябе бу ихтыяжны оныта бара бугай. "Ак шигырь", "Иректе шигырь" дигәннәре әдәбият мәйданында кирәгеннән артык иркенлек алды ахрысы. Нәтиҗәдә ниндидер абстракт "шигырь" төшенчәсе туды. Темалар даирәсе дә тарайды, әсәрләрнең кәһарманнары да, конкретлыкларыннан баш тартып, аморф хәлгә керде. Уйландыра һәм борчый торган күренеш бу. Инде күптән кулланыштан төшкән, бүген дә төмам аңлашылып житми торган архаик сүзләрдән, уйланып житмәгән чәчәкле-чуклы чагыштырулардан, катлаулы эмоциональ халәттә генә үтә нечкә психологик кичерешләргә бирелүчән, гадәти булмаган кәһарманнардан *(гади телгә күчереп әйтсәк, һәртөрле диваналардан)* качарга да вакыттыр. Укучы, Эзоп телен түгел, фикерләрнең ачык, аңлаешлы булуын ярата. Лөкин шул ук вакытта үтә аек акыл да канатсыз кош кебек. Монда инде "алтын урталык"ны табу ижатчының талантына бәйләнгән. Ә аны "шигырь" дигән гаять катлаулы һәм авыр фәнне тиңрәнтен үзләштермичә хәл итеп булмый.

Шигырь, бала кебек үк, үз вакыты житкәч кенә туа. Ул көндәлек тормышка да, ераткы калган үткәннәргә дә, әле хыялда гына жемелди башлаган киләчәккә дә мөнәсәбәт күренмәс жепләр белән бәйләнгән. Яшәргә сәләтле булып туармы ул, балигълыкка ирешә алырмы —анысы инде шагыйрьләр зиһененә һәрдаим сенеп торган илһам дигән, вәхи дигән кодрәтле вә илаһи көчләргә бәйле.

Хатыйп
Миңнегулов

ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ МӨСЕЛМАН КӨНЧЫГЫШЫНА СӘЯХӘТЕ

Тормышта, гәрчә бик сирәк булса да, шундый затлар очрый: аларның шәхси яшәеше, эш-гамәле, әйткән һәм язган сүзе гаиләсе, туган-тумачалары, якыннары өчен генә түгел, ә гомумән киң жәмәгатьчелек, милләтләр һәм илләр, тарих өчен билгеле бер әһәмияткә, мәгънәви яңгырашка ия була. Гаяз Исхакый да—әнә шундый инсаннарнын берсе. Аның тормышы, язганнары тереклекнең күп кенә мәсьәләләрен ачыкларга, тарихны тулырак һәм жентеклерәк күзәтларга әрдем итә, бүгенге һәм киләчәк яшәеш өчен гыйбрәтле сабак булып тора. Без, ничектер, соңгы вакытта битарафлыкка, әби-бабаларыбыз даими искәртеп килгән гафиллеккә (вәемсызлыкка) күнегеп беттек. Мондый шартларда исә Тукай, Исхакый кебек бөекләребез белән танышу, алар белән киңәш-табыш итешү гафләт йокысыннан уянырга, бүгенге хәлебезне, барыр юлыбызны төшенергә булышыр иде.

Г.Исхакый—үзенең "... Инкыйраз"ы, күпсанлы чәчмә, драма әсәрләре, публицистикасы белән татарның күнел түрендә, әдәбиятында яшьли үк мөхтәрәм урынны алган әдип. Иленнән, халкыннан аерылгач та ул үзенең милләти һәм дини иманына тугры калды. Мөһажирлектәге ижаты, эшчәнлеге—моның ачык дәлиле. Кызганыч ки, әдипнең Октябрьдән соңгы тормышы, язмалары әле һаман да бүгенге укучыга тиешенчә житкерелмәгән. А.Пушкин, Л.Толстой, А.Чехов, С.Есенин кебек әдипләрнең хәтта атнасы, көне ачыкланган тормыш һәм ижат хроникалары бар. Ә Г.Исхакый гомеренең без хәтта аерым елларын да белмибез. Мөһажирлектәге язмаларының да әле күпчелеге һаман да таралып, сибелеп ята бирә. Шундыйларның берсе—һәм милли-тарихи, һәм ижтимагый-сәяси, һәм әдәби-публицистик яктан мөһиме—"Ислам мәмләкәтләрендә" дип исемләнгән язмасы. Автор аны үзе "юл истәлекләре" дип атаган. Әмма ул үзенең эчтәлеге, төзелеше белән сәяхәтнамә (сафәрнамә) жанрына туры килә. Анын да төп үзәген сәфәр, авторның сәяхәт вакытында күргән-ишеткәннәре, тәэсирләре, уй-кичерешләре тәшкил итә.

"Ислам мәмләкәтләрендә" язмасы шактый күләмле. Ул Берлинда гарәп телендә нәшер белән нәшер ителүче "Яңа милли юл" журналының 1932 елгы 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 10, 12 һәм 1933 елгы 1, 3, 5, 7, 8-9, 10, 12 нче саннарында дөнья күргән. Аннан соңгы вакытта бу язманын башка урыннарда басылуы мина мәгълүм түгел. Безнен аерым доклад-чыгышларны, мәкалә-язмаларны исәпкә алмаганда, бу сәяхәтнамә әле фәнни әйләнешкә дә кертелмәгән.

Г.Исхакый кебек жиһанны гизгән, дөньяның төрле кыйтгаларында, күп төбәкләрендә булган, яшәгән татар адибе, белкем, гомумән татар кешесе, мөгаен, юктыр, булса да—бармак белән генә санарлыктыр. Әлбәттә, "...Инкыйраз" авторы үз ихтыяры белән генә сәяхәт кылмаган. Аны еш кына бу адымга тормыш шартлары, сәяси вазгыять мәжбүр иткән. Әмма күп кенә чыганаклар, факт-мәгълүматлар Г.Исхакыйның холкы-табигате белән гаять кызыксынучан, хәрәкәтчән булуын күрсәтеп торалар. Мина 1964-1967 елларда, Сарман якларында эшләгәндә, берничә мәртәбә Теләнче Тамак авылында булырга туры килгән иде. Биредә Октябрь инкыйлабына кадәр татарның мәгълүм сәүдәгәрләре—Хәлфиннәр яши. Аларның таш пулатлары хәзер дә исне-акылны жибәрерлек. (Мин белгәндә бу биналарда ярдәмче мәктәп эшли иде.). Февраль инкыйлабы алдыннан Г.Исхакый бернича атна Хәлфиннәрдә яшәп ала, ижат итә. Теләнче Тамактагы кайбер кешеләр шыпырт кына сөйләвенчә *(кызганыч, шул*

мәгълүматларны вакытында теркәп калдыра алмаганмын), "...Инкыйраз" авторы еш кына табигатькә чыккан, урман-тауларга, күрше авылларга йөргән, күп кенә кешеләр белән очрашкан, гаплəщкән. Финляндияләге милләттəшләребез дə Г.Исхакыйның йөргергə, сəяхəт кылырга, кешеләр белəн аралашырга яратуын кат-кат искəрткəннəр иде. Әдипнең гаять кызыксынучан табигатьле булуы анын əсəрлəрендə дə, шул исəптəн сəяхəтнамəсендə дə ярылып ята.

"Ислам мəмləкəтлəрендə" язмасының нигезен Г.Исхакыйның Мəскəлман Көнчыгышына, жəмлəдəн Фəлəстин, Мисыр, Сүрия, Иордания, Ливан һəм кайбер башка илləргə сəфəре тəшкил итə.[1] "... Инкыйраз" авторының бу төбəккə килүендə төп сəбəп—Кодеста (Иерусалимда) уздырылган Бөтендөнья мəселманнарының корылтаенда катнашу. Халыкара жəмəгатьчелектə киң яңгыраш тапкан бу житди чара 1931 елның 6-17 декабрендə 12 көн буена бара. Корылтай эшендə мəселман дөньясының күренекле əһелləре (дəүлəт эшлəкчелəре, рухания, эшмəкəрлəр, галимнəр...), төрле мəзһəб һəм фирка тарафдарлары, гаять күпсанлы журналистлар катнаша. Идел-Урал мəселманнарының вəкиле буларак, Г.Исхакый да алар арасында.[2] Сəгыйд Шамил бəк исə—кавказлылар делегаты. Бу зат—"... Инкыйраз" авторының дусты, фикердəше. Мəшһүр галим, рухани Муса Бигинен дə Кодес чараларында булуы, ватандашлары белəн аралашуы мəгълүм.

Корылтай мəселман дөньясының, илləр, халыклар арасындагы мөнəсəбəтлəрнең мөһим мəсьəлəлəрен тикшерə, житди генə карарлар кабул итə. Алар арасында исламият байлыкларын саклау һəм үстерү дə, Хижаз тимер юлын мəселманнар кулына алу да, Кодеста халыкара ислам университеты *(дарелфөнүне)* ачу да һəм башка чаралар да бар.

Корылтай Фəлəстин мөфтие Хажи Əмин Хөсəйни житəкчелегендə 25 кешелек Үзəк Башкарма комитет сайлый. Аның составына Советлар берлəге мəселманнарының вəкиле сыйфатында Г.Исхакый да кертелə. Бу юкка гына түгел. Чөнки "... Инкыйраз" авторы күренекле əдип һəм журналист кына түгел, тəжрибалe жəмəгать эшлəклəсе, сəясəтче дə. Аның проблемалы язмалары, житди чыгышлары Аурупада гына түгел, гарəп дөньясында, мəселман матбугатында да еш күренеп тора. Бу—бер. Икенчедəн, Г.Исхакый—корылтай эшендə ин актив катнашучыларның берсе. "Яңа милли юл" журналында басылган бер хəбəрдə *(1932.—№2)* моңдый юллар бар: "Ислам корылтаенда Идел-Урал вəкиле Гаяз Исхакый берлə Кафкас вəкиле Сəгыйд Шамил бəйлəрнен катышулары бик зур нəтиҗəлəр бирде. Алар корылтайда аерым бер урын тоттылар. Үзлəренең самимилыклары берлə вак-төяк мəсьəлəлəр өстендə торганнарны коралсызландырдылар. Алар большевик һəм исламның бер-беренə булган мөнəсəбəтлəрен уртага куюлары берлə корылтайның дикъкəтен жəлеп иттелəр. Кирəк корылтайда булсын, кирəк ислам матбугатында булсын бик зур хөрмəт казандылар" *(20 б.)*. Г.Исхакыйның тырышлыгы нəтиҗəсендə корылтай "Большевизмның Русия мəселманнарына жəбер-золымы хакында" махсус резолюция дə кабул итə. Ул Женевадагы "Милләтлəр жəмгыяте"нə, башка халыкара оешмаларга, дөнья матбугатына һəм ин мөһиме—мəселман илləренең житəкчелəренə ирештерелə. Корылтай көннəрен искə төшереп, Г.Исхакый бер язмасында болай ди: "Мəскəүдə Аксада *(Колестагы мəшһүр мəчет.)* мигъраж кичəсендə намаздан соң мин Русия мəселманнарының большевикларга каршы диннəрес, милләтлəрə өчен сугышта шəһид булган угыллары, кызлары өчен бер фатиха укуны үтенгəч, 10 мең мəселман күз яше эчендə фатиха укыганнарны вə мине—Русия мəселманнары угылын—мөнəҗəфə авыздан чыккан тəкбир берлə сəламлəделəр" *("Яңа милли юл" журналы.—1932.—№1)*.

Г.Исхакый Варшаудан Берлингə, аннан Италиягə юнəлə һəм биредəн пароход белəн Урта (Ак) диңгез аркылы Якын Көнчыгышка килə. Фəлəстингə ул 1931 елның

[1] Г. Исхакый. Ерак Шəрыктан Аурупага барышлый, 1919 елның декабрендə пароход белəн Сүəеш каналы аша үткəн була.

[2] Мəгълүм ки, Бөтендөнья мəселманнарының бер корылтае 1926 елда Мəккəдə була. Анда мөфти Ризаəддин Фəхреддинның Рəсəй мəселманнарының вəкиле рəвешендə катнашуы, гарəп телендə чыгыш ясавы, конгрессның вице-президенты (рəис урынбасары) итеп сайлануы билгеле. Биредə бу мəхтəрəм затны Согыд Гарəбстаны короле дə кабул итə.

30 ноябрендә аяк баса. Биредә ул корылтайда катнаша, изге-тарихи урыннарны карый; Йорданиягә дә кереп чыга. Поезд белән Каһирәгә килә. Биредә төрле очрашулар үткәрә, конференция-лекцияләр, чыгышлар ясый. Г.Исхакыйның инициативасы белән һәм аның турыдан-туры катнашында Русия мөселманнарының авыр хәле, аларга ярдәм итү турында Мисыр руханилар башлыгы—Шәйхел-Әзһәрнең ислам дөньясына мөрәҗәгате әзерләнеп таратыла. Бу унай белән Г.Исхакый үзе менә нәрсә ди: "Рамазан гаете мөнәсәбәте белән Мисырның Шәйхел-исламы бөтен ислам дөньясын большевикларга каршы тартышка чакырып, мөрәҗәгать итте. Ул большевикларның мөселманнарга күрсәткән золымнарга каршы протест итте. Бу безнең моңдагы хәрәкәтләребез җимеше иде. Без үзебезнең бу кыска вакыт эчендәге сәясәтен аңлаттык. Бүген моңда большевикларга дуст бер фикер юк. Гарәп дөньясында бүген большевик яклы булып язучы бер газит мөхәррире калмады" *("Яна милли юл"—1932—№3.—4 б.).*

Мисырдан Г.Исхакый янә Фәләстингә килә, аннан Сүриягә юнәлә. Дәмәшкъдән Бәйрутка килә һәм 1933 елның 8 мартында пароход белән Италиягә юл тота. Сәяхәтнамәсенең ахырында автор "Русия мөселманнарының эше берләә але Румага керергә мәҗбүр" булачагын искәртә. Г.Исхакый Римгә килү генә түгел, хәтта Рим папасына Русия мөселманнарының авыр хәлен бәян итткән мөрәҗәгать та тапшыра. Шунысы мөһим: югары дәрәҗәдәге бу зиярәт көчле халыкара яңгыраш ала. "Яна милли юл"ның 1932 елгы 10 нчы санында мондый бер хәбәр бар: "Папа хәзрәтләреннең рәсми гәзитенең 17 нче апрель (1932 ел) санында Русия мөселманнарының хәле хакында большевикларны тәнкыйть итеп бер озын мәкалә нәшер ителде. Бу мәкаләне бик күп италиян һәм башка милләт гәзитәләре күчереп бастылар". Бу төр мәгълүматлар Советлар Берлегенә дә иреште. "Мәскәүдә чыга торган татарча "Коммунист" гәзитендә Сәгъйдуллин дигән бер егет бу турыда бер озын мәкалә язып, Гаяз эфәндене "Ул ничек оялмыйча папага кадәр барган?"—дип ачуланды һәм ана "милләтче", "динче" дип бик каты тамга басты". "Тифлистә чыга торган "Заря Востока" гәзите бу унай берләә... Гаяз Исхакыйны "авантюрист" дип атый *(11-12 б.).*

"... Инкыйраз" авторының корылтайга, Шәрыкка сәяхәте, әдипнең үз сүзләре белән әйткәндә, өч ай эрьмга сузыла. Алтынчы дистәне ваклап барган Г.Исхакыйның шушы вакыт эчендәге сафәре, кылган эш-гамәлләре чын мәгънәсендә сокланырлык (остәвенә—әле ул берничә көн авырып та ала). Ә бит бу могтәбәр зат үз шәхесе өчен түгел, ә милләт, кин җәмәгатьчелек, инсаният мәнфәгатьләре өчен йөри, алар өчен тырыша, яна-кәя. Көндалек эшләрдән, төрле очрашу-әңгәмәләрдән, лекция-чыгышлардан тыш, Г.Исхакый сафәр вакытында шактый гына мәкаләләр яза, "Яна милли юл"да гарәп һәм гомумән дөнья матбугатында күп кенә материалларын бастыра. Аның үзе хакында да гарәп, төрек, урыс, француз, әрмән, инглиз, алман һ.б. телләрдә төрле мәгълүматлар нәшер ителеп тора. Мәсәлән, французларның католик рухы газеты "L Echo de Paris" гәзитендә (1932 —№29) Г.Исхакыйның корылтайдагы эшчәнлеге яктыртыла һәм гарәп җәмәгатьчелегенә аерым тәнкыйть фикерләре әйтелә. Бу мәкалә "гарәп дөньясында шактый шау-шуга сәбәп" була, шуна мөнәсәбәттә күп төрле язмалар дөнья күрә *("Яна милли юл"—1932—№4.—1-2 б.).* Кыскасы, бу төр факт-мәгълүматлар Г.Исхакыйның мөһаҗирлектәге эшчәнлеген әле тагын да ныграк өйрәнү мөмкинлеген ачык күрсәтеп тора.

Тарихтан узган гасырның 30 елларында ислам дөньясында һәм халыкара җәмәгатьчелектә Русия мөселманнарының хокукларын яклау хәрәкәте хакында бездә теге яки бу дәрәҗәдә мәгълүм иде. Баксан, бу эшнең башында безнең бөек милләттәшебез Г.Исхакый торган икән. Тагын шунысы да бар: халыкара җәмәгатьчелек басмы астында Мәскәү ислам диненә карата булган сәясәтен төрле юллар белән аларга тырыша. Әмма барып чыкмый. Мәгълүм ки, Кремль "СССР да ислам диненә иреклеләр, ислам диненә бер төрле дә кысу юк" дигән ялган кәгазьгә кул куйдыртып, бөтен дөнья тарату мәкаләсе белән Риза Хәзрәттән Мәскәүгә чакырта. Мөфти ... исә моның ялган кәгазьгә кул куюдан баш тартып: "Ялган сөйләү безнең динемездә юк",—дип жавап бирә һәм Кремльнең динебезгә азаплык бирүен талән итә" *(К.Казанлы. Төрк-татар халкының бөек мөфтие Риза Фәхреддин // Азат Ватан (Мюнхен).—1952.—№1.—14 б.).*

* * *

Күп кенә әдип-журналистлар кебек, Г.Исхакый да даими рәвештә дип әйтерлек күен дәфтәре аның бара, ана үзе кирәк дип тапкан эш-гамәлләрен, тәэсирләрен, факт-мәгълүматларны, мөһим детальләрне теркәп бара. "Ислам мәмләкәтләре" әсәре

дә шундый материалларга нигезләнеп туган. Аннан тыш Г.Исхакый ел кына үзе барасы жирнең (илнең, халыкның, шәһәрнең...) тарихын, үзенчәлекләрен дә алдан үк билгеле бер дәрәҗәдә өйрәнә торган була. Мәсәлән, ул 1933—1935 елларда өч елга якын Япониядә, Кытайда була. Әмма бу сәфәрга чыкканчы ук инде Г.Исхакый "Яңа милли юл" журналында "Ерак Шәрык" исемендә мәкаләләр сериясен бастыра. Кыскасы, "Ислам мәмләкәтләрендә" сәяхәтнамәсенең дә фактик нигезе шактый нык, саллы. Автор аның төгәре өлешен Мисырда яза, ә калган күпчелеге Варшавада барлыкка килә.

Әйткәнебезчә, Г. Исхакый үз язмасын "юл истәлекләре" дип атаган. Татар әдәбиятында сәяхәтнамә жанрында әсәрләр язуның озын тарихы бар. Исмәгыйль Бикмөхәммәд угълы, Гали Чокрый, Заһир Бигиев, Фатих Кәрими һәм башкаларның язмалары күпчелек татар укучыларына мәгълүм.

Сәяхәтнамәнең нинди үзенә, иң беренче чиратта, авторга, аның позициясенә, талантына, сәфәр максатына бәйле. Сәяхәт вакытында күргән, ишеткән, кичергән нәрсәләр күп була. Ә менә аларны сайлап алу, урнаштыру, бәяләү авторның күңел күзенә, эчке тоемына, рухи тәжрибәсенә, гомумән, шәхесенә бәйле. "Ислам мәмләкәтләре"ндә язмасын укыганда Г.Исхакыйның эрудициясе, тарихтан һәм сәясәттән яхшы хәбәрдарлыгы, оригиналь фикерләве, тугрылыгы, югары зәвыгы, тәнкыйди карашы ачык сизелеп тора. Очсызлы, ялган, бушэйберләргә аның мөнәсәбәте тискәре. Дәмәшкъта вакытта Г.Исхакый аталы Өмәвия мәчетенә жомга намазына бара. Әмма ул биредәге вәгазьдан канәгатьсез кала. "Хотбәсе,—ди автор,— искерепбеткән бер хотбә; хәзерге әхвал берлә һичбер мөнәсәбәте, багланышы юк". Кәһирәнең аталы милли театрындагы "Ләйлә вә Мәжнүн" спектаклендә Г.Исхакыйда ризасызлык уята. Аның фикеренчә, артистлар уйнау, күрсәтү урынына, сүз сөйләү, сөйләм белән мавыгалар. Бу исә театрның *"ибтидаилыгын" ("башлангычын", "тәжрибәсезлеген")* күрсәтә. "Мин,—ди Г.Исхакый,—Мисырның театрлары әле безнең татар театрыннан бик күп түбән икән дигән фикер берлә театрдан чыктым һәм безнең милли труппаларбезне кызганычка Мисырда нинди зур уңышлар ясый алачакларын уйлап өйгә борылдым".

Якын Көнчыгыш—яһүди, христиан, ислам диннәренең асыл Ватаны, донья мәдәниятенең мөһим бер мәркәзе. Г.Исхакыйның бу мәсьәләләргә, мәдәни-тарихи кыйммәтләргә нык игътибар итүе нәкъ әнә шуның белән дә аңлатыла. Авторның "Мәсҗеде Акса", "Әл-Әзһәр", "Кыйямә" *(Воскресение чиркәве.)* һәм башка корылмалар, изге урыннар хакындагы мәгълүматларны гаять кызыклы. Әмма шулай да Г.Исхакый тарих, борынгы истәлекләр белән бик мавыкмый. Алар автор өчен, иң беренче чиратта, бүгенгене аңлау, мөһим сәяси мәсьәләләрне төшенү, милли язмышны ачыклау өчен кирәк. Мәсәлән, Византия дәверендә үк төзелгән борынгы бер чиркәүне карағанда Г.Исхакый һәм аның юлдашларының *(шул исәптән Муса Бигинең дә)* Тула шәһәрендә коелган кыңгыравуларга күзләре төшә. Бераздан биредәге биналарның да урыс акчасына төзелүе ачыклана. "Аларда,—ди автор,—безнең халкыбызның да мангай тирләре белән эшләнгән миллионнарның әрәм булып ятуына ачындык".

Кодеста вакытта Г.Исхакый шәһәрне әйләндереп алган "ныk", "биек", "койма"га игътибар итә. Кирпечтән корылган бу ныгытманы карап өчен "ин аздан дүрт сәгать вакыт" кирәк. Аны XVI йөздә идарә иткән Госманлы солтаны Сөләйман Кануни төзеткән. "Бу кояманы кору өчен,—ди автор,—миллионнар-миллионнар акча түгелгән. Аны елдар буе ун-егермешәр мең кеше эшләткән". Бу урында Г.Исхакый бик тә мәгънәле, бик тә символик сорау куя: "Ни өчен төрекнең ин зур падишалы— мөселманлыкның көчле хәлифәсе—моны эшләткән? Ул вакытта бу көчне, бу материалны, бу акчаны төрек *(төркн)* халкының үз файдасына куя алачак бер урын юк идеме? Бар иде! Ул төрекләк өчен дә, мөселманлык өчен дә Кодестан кырык мәртәбә әһәмиятле бер урын—Идел буенда урыска каршы төрк-татар милләтенең корган Казан каласы, мөселман әммәтенең христианлыкка каршы корган Казан ханлыгы иде. Ул шул көннәрдә Иван Грозный берлә үзенең барлыгын, иреген саклар өчен канлы сугышта иде... Ул үзенең көче берлә генә урыс агымын, христианлык ташкынын туктата алмавын күргәч, үзенең мәсҗедләрендә исеменә хотбә укыла торган хәлифәсенә—Сөләйман Канунига дин исеменнән ислам байрагын сакларга ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән иде... Сөләйман: "Мин, бөтен мөселманнарның хәлифәсе, жир йөзенең солтаны, дингезләрнең патшасы... Мин андый вак, Казан кебек эшләр берлә бәкланыйммы? Минем алдымда зур эшләр тора: Кодесны зур койма белән әйләндерәсе, Крит *("атавын")* камасы, Бенаны мохасарә итәсе бар. Китегез, башны әйләндерегез йөрмәгез, мине вакслытмагыз",— дип, Казанның күз яше эчендә булган илчеләрен кире борып жибәргән иде.

Ана инде дурт йөз елга якын вакыт үтте. Сөләйман Канунинның меннәрчә-меннәрчә төрекләрнең канын түгеп, еллар буе сугыштан соң алган Крит атасы бүген Юнанстанның *(Грециянең.)* яшьы зәйтүн үстерә торган губернасы булды. Кодесның әйләнәсенә миллионнарга төшерелә башлаган. Төрк илләренең сакчысы үтерелде. Урыс ташкыны Казанны гына түгел, бөтен Идел буен басты. Себерне алды, Кырымны таптады. Төркияне Кара диңгезнең бу ягыннан куды... Төркиянең берлеген парчалардылар...”

Г.Исхакый бу сәяхәтнамәсендә һәм, гомумән, мөһаҗирлек чоры язмаларында төрки, ислам бердәмлеге тарафдары буларак чыгыш ясый, үзара аңлашу, килешү житмәүнең аянычлы нәтиҗәләргә китерүен искәртә. Бу яктан аның бабизм турындагы фикер-күзәтүләре шактый гыйбрәтле. Автор укучы алдына: “Баблар, Баһаүуллалар вә башкалар аңлап-аңламыйча ислам дошманнарына корал булмадылармы?”—дигән житди сорау куя. Бу искәртүнең шактый урынлы һәм житди икәнлеген тарих кына түгел, соңгы заман чынбарлыгы да раслап тора.

Г.Исхакый, гәрчә ул төрки, мәселман бердәмлеге тарафдары булса да, беркайчан да үзенең татарлыгын, туган Ватаның, Идел-Урал төбәген онытмады. Миллилек аның рухына, канына сеңгән, татар мәнфәгате, татар хөрлеге аның яшәү кыйбласына әверелгән. Сәфәр вакытында Г.Исхакый төрле милләт, төрле катлам, төрле дәрәҗәдәге кешеләр белән очраша, аралаша, үзенең ихтирамы, тәнкыйдын хисләрен дә бәян итә. Әмма аның өчен ин якыны—үзенең милләттәшләре, ватандашлары. Кая барса да ул, ин беренче чиратта, алар белән очрашырга, аралашырга омтыла. Кәһирәдә яшәүче Хәмзә Тәһирбәк, Фәләстиндә гомер кичерүче Габдулла Тимур, Дәмәшкътә тотланәп калган Миңлелбанат һ.б.—әнә шундыйлардан. *(Аларның кайберләре хакында Г.Исхакый “Яңа милли юл”да аерым материаллар да урнаштыра. Мәсәлән, 1932 елгы 10 нчы санда Хәмзә Тәһирбәкнең рәсеме бар.)* Сәяхәтнамә авторы үз язмасы эченда милләттәшләре турында кызыклы тасвирлар, сюжетлар бирә. Менә Бөгелмә өязеннән чыккан Миңлелбанат “абыстай”. Ул инде 38 ел читтә жирләрдә. Аның бөтен килеш-килбәтендә, өенда татарлык. “Үзе сөйли, үзе көлә, үзе жылый”. “Үз илең түгел шул, күркеңә кына торабыз”,—дип тә куя. Авторның “чәй эчүне онытмаган икәнсез, чәегез бик һәйбәт” диюенә “абыстай” “онытаммы соң, онытмадым”,—дип өзелеп жавап бирә. Шушы уңай белән Г.Исхакый бу сүзләрне яза: “38 ел буе төрек, гарәп мәдәнияте эчендә йөрланган бу абыстай(ның) ник утка янмас, суга батмас татар булып калуы мине бик тирән уйларга төшерә иде”.

Сәяхәтнамәдә милләттәшләребезнең кайда да югалып, төшеп калмавы, белеме, зирәклеге, тырышлыгы аркасында гарәп дөньясында да жаваплы эшләр башкаруына кат-кат басым ясала. Мәсәлән, Спас өязе Салман авылы хәзрәтенең улы Габдулла әүвәл Жаек-Уральскида, аннан Мисыр мәдрәсәләрендә укый. Бераздан Фәләстиндә дарелмөгаллимне *(укытучылар институтын)* төгәлли. Алга таба Лондонда югары белем ала. Хәзер Фәләстиндә укыта; спортчы, жәмәгать эшлеклесе. “Кыяфәте, тәдәге берлә,—ди Г.Исхакый,—төмамән безнең тирәнен мишәре булса да, яна тәдәге ачык Чистай шивәсе булса да, хәзерге көндә гарәп мәдрәсәләрендә гарәпчә әдәбият вә фәсахәт *(риторика)* дәреслөрен өйрәтә...” Мондый милләттәшләребезнең уңганлыгын, эшчәнлеген күрепләр, сәяхәтнамә авторы үкенеч тә белдерепләр куя һәм “Өйгә таба” повестенда һәм кайбер башка язмаларында яратып кулланган “әмә”, “әмәче” детальләрен дә телгә ала (яғъни, башка илгә, халыкка хезмәт итү). Габдулла әфәнде кебекләрнең күздә тотып, Г.Исхакый болай ди: “Безнең Идел буе егетләре кемнәргә өмәгә йөрмиләр. Үз илең булмагач, үз халкың үз ихтыярында булмагач, шулай итеп мәгъһәви чегән булып каласың, күрәсең”.

Юльяэма авторы өчен Идел-Урал, үз милләте өчен нигез, таяныч ноктасы, чагыштыруның төп объекты рәвешендә. Г.Исхакый декабрь башындагы Кодес табигатен “бездәге августа ахыры һава”сы белән тиңли. Мисыр жәмигыбында бер вәгазьче хатыннарны ямаланган нәсыйхәт сөйли. Г.Исхакый аның сүзләрен әбисе Мәхфүзә һәм әнисенең авыл хатыннарына сөйләгәннәре белән чагыштыра да кәефе төшә. Ана вәгазьче тарафыннан мәрхүм әби-әнилөренең хатираләре мыскыл ителә кебек тоела. Бер урында автор үзен “Чистай мишәре” дип тә атый.

Колониаль изелү, чукындыру сәясәте Рәсәйнең күпләрән мөселманнарын ислам дөньясына күчәргә мәжбүр иткән. “Сәяхәтнамә”дә аларның яңа язмышлары хакында дулкынландырырлык юллар бар. Мәгълүм булганча, хәзерге күп кенә гарәп илләре узган гасырның башларына кадәр Госманлы империясе составына кераләр. Милли яктан бигрәк, дини урталыкъ хисе көчле була. Бу аеруча мөһаҗир мөселманнарда нык чагыла. Гарәпләр бәйсезлек өчен көрәшкә күтәрелгәч, бирегә күчеп килгән

татарлар, чиркәсләр аеруча кыен хәлдә кала. "Дөнья сугышы вакытында гарәпләр инглизләр яклы булып, төрекләргә каршы сугыш ачкач, безнекеләр дә төрек санаулы, йортлары-жирләре таланып, маллары алынып, бик күбесе үтерелеп, калганнары... лагерьга ябылган була...",—ди бу хакта Г.Исхакый. Мәккә шәһәрендә яшәүче татарларның башлыгы булган, дингә чын күңелдән бирелгән, туры сүзле, горур табигатьле Гомәр кәрт язмышы күңелләрне тетрәндердекләр. Төрек-гарәп конфликтында динне барыннан да өстен куйганы өчен, үл мал-мөлкәтеннән мәхрүм ителә, үзе, гаиләсе төрмәгә ябыла.

Юлъязма авторы татар-Шәрык мәдәни багланышларына да игътибар итә. Аның фикеренчә, Октябрь инкыйлабына кадәр Якын Көнчыгыштагы уку йортларында (аеруча "Әл-Әзһәр"дә, Бәйрутта) күпләгән татар егетләре белем ала. Мәсәлән, Муса Биги, Петербург имамы Лотфулла Исхакый, "Галия" мәдәррисе Зияәддин Камали, Закир Кадыйри, Габдельбарый Баттал Мисырда, Нияз Максудый, Габдулла Сөләйман, Кәмал Локман һ.б. Бәйрутта укый. Шулар арасында татар денъясына Шәрык казанышларын, өлешчә Аурупа фикерләре дә керә. Үз чиратында татарлар да гарәпләргә аерым рухи кыйммәтләрне житкерәләр.

Г.Исхакыйның "юл истәлекләре"ндә тарихи-иҗтимагый, мәдәни, сәяси яктан башка төр мөһим факт-мәгълүматлар да бар. Автор Шәрыкның кайбер күренекле музейларын, билгеле шәхесләрен телгә ала, аерым гореф-гадәтләргә, милли үзенчәлекләргә дә тукталма. Мәсәлән, мисырлылар сүздә "ярлыкны-арттыруны бик яраталар". Моның сәбәбе аларның олы тарихы, зур-зур пирамидаларга ия булуы белән дә аңлатылма икән.

Якын Көнчыгыш—яһүдиләрнең дә асыл ватаны. Денъяның төрле почмакларына сибелгән бу халык узган гасырның 20-30 елларында кабат бирегә кайта башлый: йортлар сала, сәудә итә... "Сәяхәтнама"дә дә бу хакта шактый мәгълүматлар бар. Автороа ун ел эчек салына башлаган 40 мең халыклы Тель-Авив шәһәре авыл төсле генә күренә. "Ул,—ди автор,—Казанның Яңа Бистәсе төсле дә булып күренә, Бишбалта кебек тә булгалап куя". (Әгәр дә Г.Исхакый бүгенге Израильне, Тель-Авивларны күрсә, нәрсә дияр иде микән!?). Автор Сүриядә 35 мең чамасы чиркәс, 100 менгә якын әрмәни яшәгәнен искәртә. Алар төрек, гарәп телләрен белсәләр дә, үз телләрендә дә гәзитәләр чыгаралар. Бер әрмәни газета Г.Исхакыйның күп кенә чыгышларын бастырып чыгара. Бер үк дәүләт—Госманлы мәмләкәте составында яшәү нәтиҗәсендә күпләгән гарәпләр һәм башка кавемнәр дә, нигездә, төрек телен белә. Аерым гарәп дәүләтләре төзелгәч тә, әле төрек теле тормышта кин кулланыһ дәвам итә. Г.Исхакый да күбрәк шул телдә, аерым очракларда француз сөйлы, аралаша.

"...Инкыйраз" авторы гомере буе диярлек күзәтү-тикшерүләр астында яши. Сәяхәтнамадә дә бу берничә урында сизелә. Мәсәлән, пароходка утырып алдыннан да ул жентекле тикшерүгә дучар була. "Кырык төрле сөаллэр бирдә башымны катырдылар. Соңыннан үзләренең тизле *(яшерен.)* бүлмәләренә кереп бик озак тоткач кына... виза суктылар",—ди автор. Кунакханәдә яшәгәндә дә "полис"лар аның хәлен "белеп" тора.

"Ислам мәмләкәтләрендә" язмасы—төрле башлангычларны үз эченә алган яҗкәр. Анда бәян итү-хикәяләү дә, тасвир-сурәтләү дә, аналитик фикерләү дә, публицистик башланғыч та бар. Мәсәлән, Г.Исхакыйның Кәһирәдә сөйләгән лекция тексты тирән эчтәлеге белән түгел, ә форма-шәкеле ягыннан да ораторлык-публицистик стильнен күркәм бер үрнәге. Язмада табигать күренешләре дә (мәсәлән, "Уле дингез"не тасвирлау, тауларны, бакчаларны сурәтләү) бар. Текстка табигый рәвештә диалог-бәхәс тә, төрле уйланы-чигенешләр дә кереп китә. Боларның һәммәсен автор образы, аның көчле ихтыяры бербөтен итеп тота.

Корылтайның үзе хакында Г.Исхакыйның янә берничә язмасы бар. Мәгаен, шуңа күрәдер автор үз сәяхәтнамәсендә корылтайның үзенә чагыштырмача азрак урын бирә.

"Ислам мәмләкәтләрендә" язмасының тел-стилендә аерым кытырлыклар (бер үк сүзләрне кабатлау; гарәп, төрек алынмаларын күбрәк куллану, хәтта аерым юлларын шул теллардә китерү һ.б.) очрый. Бу авторның күп һәм ашыгыбрак язуы, текстның, күрәсен, кайчак редакцияләнмичә генә басылуы белән дә аңлатыла. Техник хаталар да бар.

Сәяхәтнамә татар укучысына адресланган һәм үл тел-стиле, эчтәлеге белән укучыны җәлеп итәрлек.

Тагын бер моментны искәртү зарури: "Сәяхәтнама" "Яңа милли юл"да басылган. Яңа мәгълүматлар бу журналның татар укучылары арасында гына түгел, башка төбәкләрдә дә билгеле бер дәрәҗәдә таралуын күрсәтәләр. Андагы аерым язмалар

гарәп, төрек, француз, алман, поляк, урыс телләренә дә күчереп басылган. Мәсәлән, Г.Исхакыйның "Яна милли юл"дагы (1932.—№4.—1-6 б.). "Ислам дөньясы һәм большевиклар" исемле мәкаләсе, Габдулла Тимур тарафыннан гарәпчәгә тәрҗемә ителеп, Кодеста чыга торган "Әл-җамигату-л-гарәбия"дә (дүрт санында) һәм янә берничә тәзитәдә дөнья күрә.

"Ислам мәмләкәтләрендә" юлъязмасының, бер яктан, тарихны, әлеккеге тормышны, мәдәниятне танып белү ягыннан татар өчен генә түгел, башка халыклар өчен дә әһәмияте зур. Икенче яктан, бу ядкяр—әдипнең тормышын, күпкырлы эшчәнлеген өйрәнүдә дә кыйммәтле чыганак. Аны укыганда Гаяз Исхакыйның шәхесе тагын да олылана, тулылана, җанлана төшә.

* * *

Әйткәнебезчә, "Ислам мәмләкәтләрендә" сәяхәтнамәсе гарәп графикасында әлеккеге язылыш кагыйдәләре белән басылган. Аны хәзерге язуга күчерәндә, нигездә, әлеккеге үзенчәлекләр сакланды. Аерым үзгәрешләр, кагыйдә буларак, хосусый характерда гына. Тиешле шәрех-аңлатмалар җәяләр эчендә бирелде. Аерым сүзләрнең, атамаларның язылышында, аңлатылышында кайбер төгәлсезлекләрнең китүе дә табигый. Болар өчен укучыдан алдан ук гафу үтенәбез.

Гаяз Исхакый

ИСЛАМ МӘМЛӘКӘТЛӘРЕНДӘ [1]

30 ноябрьнең (ягъни 1931 елның) иртәсендә, минем юлга чыгуымның сигезенче көнендә Яффа шәһәре күренде: матур гына, зур гына бер мәселман, гарәп шәһәре. Пароход лиманга яңәшә /тукталып/ алмады, дингез эчендә тимер (якорь) салды. Ул да булмады—бөтен тарафтан акча алыштыруны, эфлисүн сатучы, христианнарның төрләрен, яһүдиләрнең арзи (алтын) мөкаддәс ташын, мәселманнарның тәсбихен сата торган, төрле милләтнең төрле телендә дурт-биш сүз мыгырдый торган сатучылар пароходны чолгап алды. Төрле телдә кычкырыш, бакырыш китте. Пароход өсте берничә минутка чегән табуры төсен алды. Без, Яффада чыгучылар, полисәләрне (полицейскийларны) көтәргә тотындык. Бер-ике сәгать вакыт кичкәч кенә полисәләр керде. Болар барысы да инглизләр; араларында гарәп юк иде. Алар берлә бергә, бик күп иттереп, төрле яһүди әгәнтыятьләрнең каршы алучылары, әллә никадәр хаммаллар (йөк ташучылар) пароходны тутырды. Яһүдиләр үз кешеләренә әйберләрен бирделәр. Безне каршы алучы күренми иде.

Мин бер хаммалга әйберләремне тапшырып, паспорт каранырга киттем. Ләкин анда сыйныфлап караганга, мина бик озак көтәргә тугры килде. Мең бәла берлә паспортымны эшләтеп бетергәч, каек берлә гүмрүккә (таможняга) киттем. Анда чанталарның (сумкаларның) исәп-саны икәнен күреп сөенергә өлгермәдем, "карантинга!"—диделәр вә бик күп кеше көтә торган бер җиргә тыктылар. Мин безнең белән бергә килгән юлчыларның һичбер көтмичә карантинга китүләрен күрү берлә, шул хәлдән файдаланырга телән, гүмрүктәге кечкенә полисәләр берлә орыша, талаша доктор ишегенә кадәр килдем. Андагы сакчы мине жибәрми, төрле сүзләр берлә алдаштыра, башкаларны берсе артыннан берсен жибәрә генә иде. Мин тагын талашып докторның алдына килеп бастым. Монда, ни өчендер, юлчыларны доктордан каратып үткәрү дигән бер юл тотылган һәм бу да докторның исем-фамилияне, паспортны язып алу рәвешенә сугылган. Доктор нә исәнлекне сорый, нә карый. Бу полисәнең яшерен тикшерүчеме, әллә башка берәр кирәге бармы—белмәдем. Ләкин монын исәнлек-саулык берлә һичбер мөнәсәбәте юк иде.

Доктор мина күзен акайтып карады, читтән килеп торган яһүдиләрне

[1] "Яна милли юл" (Берлин).–1932.–2,3,4,5,6,7,8,10,12 нче саннар; 1933.–1,3,5,7,8-9,10,12 нче саннар.

карабында дəвам итте, алар да бер-бер артлы кереп эшлəрен бетереп чыгалар иде. Мин дə докторның алдына паспортымны тутырып: "Минем кизүем (чиратым)",—дидем. Паспортымны алды. Карашырга, маташтырырга тотынды. Миннəн элəбез үткəннəргə моны эləмəгəн иде. Мин: "Полис карады, зəхмəт итмəгез",—дидем. Нəрсəдер инглизчə мыгырдады "Франциүза сөйлим",—дидем. Авырсынып кына аллə нилəр язырга тотынды. Əллə нинди мəгьһəсез сораулар бирде. Аның мəгамəлəне авырайту юлын тотканы күренеп тора иде. Шул ара да булмады, бер чалмалы, бер фəсле ике мөселман килеп керделəр дə: "Монда Гаяз Исхакый бəк юкмы?"—дип төркчə сорадылар. Мин дə үземне таныттым. Күрештек. "Без мофти тарафыннан сезне каршы алырга чыктык. Бер сəгатьтəн бирле эзлибез. Таба алмыйбыз",—диделəр. Доктор да язганнарын онытты. Бик тиз генə паспортны бирде. "Боерын, боерын!"—дип төркчəчə күчте. —Юлыгыз мөбарəк булсын, фалəн",—диде. Минем берлə бергə килгəн юлчылар да бердəн минем корылтайга килүче икəнемне аңлап алдылар. Мин пароходта килгəндə "ни булыр, ни булмас",—дип үземне Мисырга баручы мөхəррир дип кенə таныткан идем. Һəм, алар берлə сионизм Кодес *(Г.Исхакый бу атаманы Коддес рəвешендə яза. Иерусалим.)* мəсьəлаləре турында бик күп сөйлəшкəн, дөресрəге аларны сөйлəткəн идем. Шуның өчен минем, бердəн, мөхəррирлегемнəн вəкил булып чыгуым алар өчен көтелмичəрək килеп чыкты, аптырады. Ləкин минем үземнең моны үйлап торырга вакытым да, телəгем дə юк иде. Мине гүмрүктəн (таможнядан), жил кебек, чанталарымны да ачтырмыйча алып чыгып, безне көтеп торган автомобильгə утырттып шəһəргə алып киттеləр.

Мин каршы алучыларга: "Мин Яффада берəр көн калып, Кодеска барам. Мине бер үтəлгə (отельгə) индерегез",—дисəм дə, тыңлаучы булмады. Бер мөселманның өенə китерделəр. Анда бик күп көтүчелəр мине "əһлəн вə сəһлəн" (хуш килдегез, рəхим итегез!) дип каршы алдылар. Бу Яффаның мəшһүр бер ишаннарының балаларыннан Əл-Лачанинның өе икəн. Анда пароходның беренче сыйныфында күргəн бер азəрине таптым. Ул Зыяэддин Табатаи исемендə, Иранның иске назираləреннəн (түрələреннəн) һəм Качар фамилиясе берлə тартышучылардан, соныннан, Низажан Пəһləви шаһ булгач, мəмləкəтеннəн куылган бер Иран олугларыннан икəн. Сөйлəштек, таныштык. Чəйдən соң: "Боерын!"—диделəр. "Кая барабыз, миңа бер отельгə төшəргə кирəк. Мин монда бер көн калам", — дидем. Мофти Хажи Əмин Əл-Хөсəйниның хəзерге хезмəт ипташləреннəн булган, элеккеге Ярдын *(Ордун, Иордан.)* көчмəтенең назире, Төркия гаскəрендə орду (хəрби) мофтисе булган əш-шəйх Мозаффар: "Хəзер Кодеска барыйк, автомобильлəр хəзер. Аннан соң монда килеп булыр, ара якын",—диде. Мин дə, бəлки, шулай дорестер,—дип разый булдым. Автомобильлəр берлə Кодеска юнəлдек.

Яффа—алтмыш меңле мөселман шəһəре. Сəүдəле, бай шəһəр. Аның күршесендə яһүдиләр үзləренə Тел-Абиб исемендə бер шəһəр салганнар һəм анда үз ел эчендə кырык меңле бер шəһəргə житкəрəннəр. Безнең юлыбыз бу ике шəһəрнең арасыннан китə иде. Гарəп шəһəре искедəн салынган—иске ысул биналар, яһүдиләр шəһəре соңгы ысулда салынган Аурупа шəһəрləре төсен бирə иде. Юлыбыз ялт иткəн асфальт. Тирə-юньне əфлисүн бакчалары тоткан. Бер-ике атнадан əфлисүн өлгерə торган чак булганга, бөтен агачлар яшеллe, сарылы əфлисүннəр берлə бизəнгəннəр. Һава бездəге августа ахыры һавалары. Табигать таулы, ташлы. Бу таулык, ташлык арасындагы бакчалар адəм баласының бик күп тырышуы аркасында гына үсə алганнар. Юлның яхшылыгын күрəп: "Моны инглизлəр эшлəдеме?"—дидем. "Юк, төрəклəрдəн калма (калган). Элек тə бар иде. Сугыш вакытында төрəклəр шул хəлгə күйдылар",—диделəр. Юлда автомобильлəр, ослəрəнə капчыклар йөкləнгəн ишəклəр, дояларне, арбаларга жигелгəн үгезлəрне очратырга, куып житеп үтеп китəргə тугры килə иде. Боларны алып баручы юлчыларның күбесе башларына безнең кəлəпүш күк бер нəрсə, йə бер иске фəс кигəн, ослəрене тубыкларына кадəр төшереп кигəн бер ситса күлмəк кигəн янаяклы гарəплəр иде. Хатыннарның күпчелеге һич нəрсə берлə йөзлəрен капламаган, башларын, савларен яулык берлə бəйлəп, ослəренə бер кара капут (кием; жилəн) кигəннəр иде. Аларның муеннарына бик күп зиннəтлар тагылган кебек, яланаяклларына да, тубыктан аз гына югары, белəзеклəр киелгəн иде. Йөзлəре-битлəре матурлыктан шактый озак, өс-башлары шактый керле иде.

Без сәгать ярымнар чамасы юлда калып, тауларны бер меңеп-бер төшеп, алтмыш километрлык араны үтеп, Кодес Шәрифкә килеп життек. Монда мине бер отельгә төшерделәр. Фәлəстин мөселманнарның баш мөфтисе корылтай жыюда зур хезмәт күрсәткән Хажи Әмин Хөсәйни отельгә килеп зиярәт итте. Мин дә жыенып, киненең мондагы мөселманнарның милли идарәсенә булган хәмгыятел-исламда мефтине зиярәт иттем. Анда корылтайны хәзерлəү һәйəтенең бик күп əгъзалары берлə таныштым. Аларның бик күбесе төркчə сөйлəшə һəм төрек вакытында зур-зур мəмүриятлəрдə (рəсми урыннарда) булган кешеләр иде. Шунда ук Нəкышбəнди *(XIV йөздə Урта Азиядə яшəгəн атаклы суфый.)* ханəкасенең (йортының) шəехе Ягъкуб əфəндe берлə дə таныштым. Ул гарəпləшкəн бер төркестанлы булса да, симасын (төс-кыяфəтен) һəм телен югалтмаган, мосафирчылыгын да саклаган иде. Аның берлə бергəлəп Мəсжедe Аксаны *(Иерусалимдагы бик борынгы, атаклы мəчет.)*, Хəрəмне Шəрифнe карарга киттек. Хəрəмe Шəриф—мөселманнар өчен бер мөкəддəс жир. Ул дурт почмаклы бер биек бер таш койма берлə əйлəндереп алынган. Аның эче—мөселманнар өчен мөкəддəс булган 17 дисəтинə зурлыгында бер мəйдан. Мəйдан уртасында сигез почмаклы иттереп салынган "Жəмигъ ас-Сахра" *("Коббəт əс-сахра")* исемендə бер жамигъ *("мəчет")* бар. Бу жамигъ бу көндə дə Мəлик бине Мəрван *(VIII гасыр.)* тарафыннан салынган рəвешендə саклана. Жамигънен исеме аның эчендəге зур коббə (гарəпчəсе: Əс-сахра.) ташыннан килə икəн. Ул таш Ибраһим галəйһиссəлам заманында өстендə корбан чала торган бер таш булган. Вакыт үтə-үтə ул таш тарихлашып, бик күп дин əһеленə мөкəддəслəшкəн. Исламның беренче вакытларында мөселманнарның кыйблалары да менə шул Хəрəмe Шəрифкə, шул ташка таба булган. Мигъраж кичəсендə Мөхəммəд галəйһиссəлам Мəсжед əл-Хəрəмдан Мəсжед əл-Аксага килеп намаз укып, мигъражга ашканда, шул таш өстеннән ашкан. Менə шуңа күрə бу таш ислам дөньясында зур мөкəддəс ташлардан санала.

Христианнарда бу тарихи таш өстендə Хəзрəтe Гайсə утырганмы, Хəзрəтe Мəрьям ятканмы дигəн бер хикəя сөйлиләр. Алар өчен дə бу жир мөкəддəс. Яһудиләр өчен дə ул бер изге таш əһле салиб *(төрe йөртүчеләр.)* Кодесны алган чакта, алар бу ташны бер тимер рəшəткə берлə əйләндереп алганнар да, аның өстен бер пəрдə берлə каплаганнар. Солтан Салахеддин əһле салибнe куып чыгарып, Кодес шəһəрен мөселманнар кулына кайтаргач да, рəшəткəнe сүттермəгəн. Ул хəзер дə шул хəлендə тора. Бүген олуг бəйрəмнəрдə аның эчендə хатыннар намаз укыйлар. Мəсжед бик матур иттереп эшлəтелгəн. Аның бизəкləре бик күп. Тəрəзəләре искиткеч матур. Зиннəтләрнен соңгырак дəвердəгеләре төрек солтаннары тарафыннан ясалган. Диварларга бик күп аяте хəдисләр язылган. Боларны солтан Габделхəмид алтынлатkан. Монда төрекләрнен бу мөкəддəс жирлəргə иткəн хезмəтлəрен алым саен очратып торасын. Жамигънен төрле төстəге пыялалардан эшлəнгəн бик матур тəрəзләренең бик тарихилары Мəлик бине Мəрван һəм солтан Салахеддиннан калган булса да, аларның да күбесе төрек солтаннары тарафыннан төзəттерелгəннəр. Бу жамигъ Истанбулдагы Айа-Суфия һəм Солтан Əхмəд *(мəчетлəре.)* кебек зур жамигълардан түгел. Ләкин ул тарихи, мөкəддəс һəм бик иске бина булганга, бик кыйммəтле бер жамигъ. Соңгы елларда мөфти Əмин əл-Хөсəйни мөселманнардан, бигрəк тə Һиндстаннан бик күп акча жыеп, аның соңгы жир тетрəүлəрдə какшаган баганаларын алыштырган. Жимерелергə торган жирлəрен төзəттергəн. Бозылган зиннəтләрен тутырган. Бу эштə Кодес мөселманнарына төрек мигъмарларыннан (архитекторларыннан) Кəмал бəкнен зур хезмəте тигән. Кутаһия *(Төркиядəге шəһəр.)* һəм Барсадан *(Кечe Азиядəге кала.)* китерелгəн төрек осталары бу эшлəрне эшлəү берлə калмаганнар, алар шундый ташларны ясарга, шуларны эшлəргə Кодес мөселманнарын да өйрəтеп киткəннəр.

Кодестагы икенче изге жамигъ—Мəсжед Əл-Акса дип атала торган зур бер жамигъ. Ул Хəрəмнен бер почмагында тора. Аны хəзрəтe Гомəр килеп салган. Ул жамигъ кечерəк булганга, хəзер аның янына күшып бер зур мəсжед салганнар. Хəзрəтe Гомəрнен мəсжедe анда бер кечкенə бүлмə генə булып калган. Монда зур бəйрəм намазлары укыла. Анда ун-уныбишлəп мен кеше сыярлык урын бар. Бу жамигъны да төзəтеп яталар. Бу мəсжедлəрнe карап йөрегəндə, аны күрсəтеп йөрүчеләр: "Бу жирдə Ибраһим галəйһиссəлам намаз укыган, бу жирдə Исмəгыйль, бу жирдə Муса, бу жирдə фəлəн пəйгамбəр намаз укыган",—дип

аерым-аерым урыннарны күрсәтәләр. Бу сүзләр караучыларда "әллә бер вакытларны бу пәйгамбәрләр шунда җыелып, бер корылтай ясаганнармы икән?" дигән бер фикер калдыра.

Хәрәмe Шәрифнең бер борылышында ике дивар арасында, яһүдиләрнең дә бер бер мөкаддәс жирләре бар. Аңа мөселманнар "Бораккә-шәриф" диләр. Аурупада ул "Еглау дивары" дип мәгъруф. Дивалрларынын берсендә яһүди язуы берлә язылган берничә ташлар бар. Бу ташлар Сөләйман сараенын, яһүди дәүләтенең иң күәтле чагыннан калган ташлар имеш. Ул дивар мөселман вакыфлары уртасында. Ләкин бик иске дәверләрдән бирле монда яһүдиләрнең килеп гыйбадәт итүләренә, бигрәк тә аларнын иске тарихларын сагынып, "Тәурат" укып еглауларына мөселман падишаһлары һәр вакыт рөхсәт итә торган булганнар, дөнья суғышыннан соң инглизләр Фәләстинда яһудиләрә бер "милли йорт" ясарга сүз биреп, монда меңнәрчә сионистлар күчеп килеп, бу жирләрне яһудиләштерергә башлагач та, бу хәл шул рәвештә барган. Ләкин яһүдиләр акрын-акрын аны үз кулларына кертергә, башта пәрдәләр берлә, бара-бара такта коймалар берлә аерырга, ахырдан аңа бер синагог *(гыйбадәтханә.)* төсе берергә тели башлаганнар. Ләкин мона каршы бер Кодес мөселманнары гына түгел, бөтен дөнья мөселманнары каршы төшкәннәр. 1930 елда бу мәсьәлә, бик зур тавышлардан соң, мөселманнар файдасына хәл ителәде. Андагы пәрдәләр, коймалар сүтелде. Бу жирләрнең мөселманнарныкы булуы мәхкәмә (хөкем; суд) тарафыннан тәсдыйк ителде (расланды). Ләкин моннан соң да мөселманнар яһудиләрнең бу жиргә килеп гыйбадәт итүләренә каршылык кылмаганнар. Без карап йөргәндә дә берничә яһүди "Тәурат" укып торалар һәм берничә яһүди хатыны йөзләрен ташка сөртеп, үкереп-үкереп еглыйлар иде. Бу жирдән ерак түгел икe инглиз полисе, ул-бу чыкмасын өчен, карап торалар *(Бу юллардан соң "Жамигыл-сахра" мәчетенең рәсеме бирелгән.)*. Моннан башка мөкаддәс жирләрнең иң зурысы христиан дөньясынын изге саналган "Къийамә" *(Воскрecение.—Г.И.)* чиркәве. Ул бер тарихи бина. Ул Византс *(Византия.)* падишаһларынnан Константин дәверендә Елена тарафыннан салынган, эчендә бик күп баганалы, бераз Айа-Суфия жамигъына охшаган бер чиркәү. Монда христианнарнын ышануынча, Гайсә галәйиссалам күмелгән. Шундагы бер жирне аның кабере дип күрсәтәләр. Ул жир чиркәү эчендә, ләкин бер төрбә рәвешендә. Өстенә бик күп кандилләр (люстралар; яктыртқычлар) асылган. Анда һәрбер мәзһәбнен аеры-аеры кандилләре бар икән. Бу кандилләр мәзһәб еенә түгел, милләт аермасы берлә дә аерылганга охшый. Бу төрбәнe саклау эше христиан гарәпләре кулында икән. Чиркәүнең эче берничә бүленгән. Бер зур гына жире—католикларныкы, берсе—румларныкы, берсеи—әрмәннәрнеке, берсе—гарәпләрнеке. Һәм алар аерым-аерым гыйбадәт кылалар, бу жирләрне аерым-аерым саклыйлар. Аның кынгыяуларары да бүленгән. Монда бер нәрсә күзгә ташлана: саннары ул чаклы күп булмаган румнар берлә әрмәннәрнен чиркәүдге урыннары башкаларныкына караганда бик күп зур. Моның сәбәбе шул икән: элек заманнарда мондагы урын өчен бик зур низаглар, канлы суғышлар булган. Шул эшләрдә хәкем (хөкем чыгаручы) булып төрек хөкүмәте эшкә катыша торган булган. Румлар, әрмәнләр һәм христиан гарәпләр Төркия тәбәгасе *("буйсынуында".)* булганга, ул аларны яклый төшә торган булган икән. Шунар күрә аларнын урыннары да зуррак икән. Чиркәү бик искергән, дивар ташлары күпкалаган. Бер жир тетрәүдә аның бер зур гөмбәзе жимерелеп тә төшкән. Тагын бер шундый тетрәү булса, аның бөтенлөй жимерелүе дә бик якын. Без шундагы папаслардан (поплардан) аның ни өчен төзәтелмәвен сорадык. Алар "төзәтү өчен бөтен мәзһәбләр бер фикергә килергә кирәк. Ә һәрбер мәзһәб үзенә зур эшне алырга тели. Шунар күрә шулай кала бира: төрекләр заманында яхшырак иде. Алар мөселман булганга, солтаннар безнен бер фикергә итә алалар иде, төзәтергә кирәк булганда, солтаннар безнен бер фикергә килүебезне көтмичәрәк төзәттерә иделәр. Бүгенге хәкәм булырга тиешле инглизләр үзләре дә христиан булганга, аларны бер мәзһәб тә кабул итми",—диделәр. Ләкин озын моназараләрдән (бәхәсләрдән) соң инглизләр дә төрек солтаннарынын юлын тотканнар. Жир тетрәүдән соң жимерелгән гөмбәзнe төзәттерергә керешкәннәр. Бу чиркәүдә христианнар өчен бик күп мөкаддәс булган әйберләр бар. Ләкин минем исемне жибәргән нәрсә мәрмәрдән ясалган Хәзрәти Мәрьямнен бер һәйкәле булды. Христиан падишаһлары аңа шул чаклы

күп энже, гәүһәр һәм алтын зиннәтләр бүләк иткәннәр, аларны тагарга түгел, янына куярга да урын калмаган.

Бу чиркәү янында "Гомәр җамигы" дигән бер кечкенә мәсҗед бар. Бу бик тирән мәгънәле бер тарихи мәсҗед икән. Ислам гаскәре Кодесны алгач, Гомәр (585—644 елларда яши. Икенче хәлиф) шәһәрне зиярәткә (каварга) килгән. Ул "Кәйамә" чиркәвен караган һәм аны христианнар малты булып калыргә тиеш дип кулыннан кәгазь биргән. Папаслар берлә сөйләшкәндә, намаз вакыты житкән. Гомәр намаз укырга теләгәч, папаслар бер палас китереп: "Йә, мөселманнарның хәлифәсе, шунда намаз укы. Бу Алла йорты!"—дигәннәр. Гомәр: "Мин монда намаз укысам, киләчәктә мөселманнар, монда хәлифә намаз укыды дип, чиркәүне сезнең кулыгыздан алу ихтималлары бар. Андый, минем сүземне боза торган бер эш киләчәктә булмасын өчен, монда намаз укуым муафикъ түгел",—дип чиркәү янындагы бер бүш җиргә намаз укыган. Соңра мөселманнар бу җиргә бер мәсҗед салганнар. Ул Хәзрәте Гомәрнең аяклылыгын һәм түтрылыгын күрсәтә торган һаман бер җанлы дәлил булып тора. "Кәйамә" чиркәвенең ачкычы әле дә Гомәр тапшырган бер мөселман гаиләсендә тора икән. Бүгенге көндә дә шул гаилә чиркәүне ачып яба икән. Инглизләр Кодесны алгач, бу ачкыч мәсьәләсе тагы күтәрелгән. Христиан дөньясының бер мөкаддәс чиркәвенең ачкычы бер мөселман кулында тору монасиб түгел, дигәннәр. Алырга теләгәннәр. Ләкин ачкычның кем кулында булуы турында тагын бик зур низаг чыккан. Һәр мәзһәб ачкычны үзенә алырга теләгән. Шуна күрә ул мәсьәлә тагын искечә калдырылган. Чиркәү эчендә, чиркәүнең вакыфларына тимәү турында Гомәрнең кулы берлә язылган кәгазь дә саклана икән.

Кодесда болардан бака да бик күп изге жирләр бар. Тик болары шуларның ин зурлары гына. Монда урысларның чиркәүләре, үтәлләре *(кунак йортлары.)* һәм вакыфлары да бар. Ялгыз вакыфларының гына бүтенге кыймәте ике йөз мең алтын сум икән. Монда хәзерге көндә дүрт йөзләп монах һәм кайта алмыйча калган бераз урыс шуны ашап яталар. Элек монда һәр ел егерме мең урыс зиярәтчесе (паломнигы) килә торган. Алар монда миллионарча акча калдыра торган булганнар. Русия мөселманнарыннан монда, югарыда сөйләнгән, Нәкъшбәнди завыяседе (почмагы; тәкъяседе) генә бар. Аның да вакыфы (фонды) күп түгел. Ул Русиядән килгән мөселманнарга мосафирханәлек хезмәтен итә килә. Анда унбиш-егермегә якын хажга килеп кайта алмыйча калган һәм Русиядән качып чыккан төркестанлылар яшәп торалар. Аларның кечкенә кәсепләре дә бар. Аларның күбесе пычак кайраучылыкны үзләренә һөнәр итеп алганнар. Алар мине туганнары кебек каршы алдылар. Корылтайдагы эшебезне зур дикъкать берлә тәгъкыйбь итәләр (күзәтәләр).

Корылтай ябылуның икенче көненда без мондагы мөстәкыйль вәр мәләкәт саналган Шәркый Эрдүнгә *(Шәркул-Ордун—Трансиорданиа.)* барыргә йөрибез. Анда берничә мең мөһажирләр яшиләр. Аларның кайберләрен без корылтайда күрдек, кайберләре үзләре килеп күрештеләр. Бу мәмләкәт христиан тарихында бик мәшһүр Эрдүн *(Йордан.—Г.И.)* елгасының көнчыгышында кечкенә бер жир. Ул төрекләр вакытында бер мөтәсаррифлык (вилаят; төбәк) кенә булган. Хәзер ярым мөстәкыйль бер мәмләкәт булып, Мәккәи Мөкәррәмә шәрифе әмир Хөсәеннен зур баласы әмир Габдуллага бирелгән. Дүрт йөз мең чамасы халкы булып, күпчелеге гарәп. Аның ярты миллион инглиз лирасы килере бар. Зур шәһәре Гамман. Бу мәмләкәтнең ин зур байлыгы Лут күле *(Жансыз дингез—Г.И.)*. Бу күлдә бик күп төрле, һөнәр сәнәгатендә кирәкле булган тозлар, мәгъдәннәр чыга. Төрекләр заманында бу күл шулай бush яткан. Хәзер бер инглиз компаниясе аны эшләтә башлаган. Күл буена кечкенә-кечкенә фабрикалар, лабораторияләр салдырган. Мәгъдәннәрне, тозларны чыгарырга тотынган. Шундук (шунда ук) коену жирләре эшләнгән. Без барган чакта декабрьнең яртылары булса да, әле читтән килгән бик күп кешеләр коену киемнәрендә су буенда чабышып, уйнап йөриләр иде. Суы да жылы иде. Ләкин суның тәкъдир бер төсе һәм һичбер су тавышына охшамаган бер тавышы бар. Яр буена дулкыннын бәрелүеннән бик күп ак күбекләр жыелган. Күлнең өстендә һичбер кош-корт юк. Эчендә дә балык, бака кебек һичбер жан иясе да яшәми. Ләкин үзенең суы коену өчен бик файдалы, имеш. Коену киемнәребез булмаганга, без коена алмадык. Йөзебезне кулыбызны юдык. Авызыбызны чайкадык. Ләкин төмсез тәме авыздан сәгатьләр буе китмәде. Күл бик бай

булса да, әле инглизләр дә аның бөтен байлыгын файдалана башламаганнар икән.

Вакытында автомобильчебез (шоферыбыз) килмәгәнгә, вакыт та тар булганга, без Гамманга кадәр бара алмадык. Көнебезне Кодес тирәсендәге тарихи һәм изге саналган жирләрне карарга сарыф иттек. Беренче иттереп Хәлил әр-Рахман дигән бер шәһәргә киттек. Ул Кодестан утыз чакрымнар ераклыкта бер авыл. Халкы мәселман. Бу шәһәрне Ибраһим галәйһиссәлам, халыкны Сараны күмәр өчен, сатып алган һәм соңыннан Ибраһим пәйгамбәрнең якын нәселеннән зыяраты булган урын янына корылган. Тарихта да, "Корьән"дә дә Ибраһим галәйһиссәламнең күшымта аты "Хәлил әр-Рахман" булганга, бу шәһәргә дә шул исем бирелгән. Бу зыяратлыкта Ибраһим галәйһиссәлам үзе, хатыны Сара, улы Исхак, аның углы Ягькуб, аның углы Йосыф торган кебек, бер хикәялегенда тына түгел, чынлап та зыяратлар. Аларның өстенә бер зур мәҗәд салынган, зыяратлар, тимер бармаклар берлә әйләндерелгән көенчә, мәҗәд эчендә калганнар. Зыяратлар зур бер таш өстенә эшләнгән булганнар. Ташларның астын тарих эзләүче җәмгыятьләр казып яталар икән. Безне аларның эченә кертмәделәр. Мәҗәд зур. Төрле жирдә карилар (укучылар) "Корьән" укып утыралар. Мәҗәдне күрсәтеп йөртүчеләр аның тарихи якларын сөйләп аңлаталар. Ләкин бу мәҗәднең яныңда әллә никадәр телэнчеләр жыелган. Һичбер ирек бирмичә телэнәләр. Күрсәтеп йөрүче дә тарихи яклардан күбрәк, әкият тарафынарак сүзне бора, яныңдагы кешенең кем булганын тикшермәстән, үзе белгән бөтен әүлияләрне шунда жыелган итеп күрсәтергә тырыша. Тарихны белгән кешегә бу бик начар тәэсир калдыра. Мәҗәд эчендәге төрле хәерчеләр: "Укыган вирдемне (догамны) синең хисапка, Хәзрәтe Ибраһимга багышладым. Аның кебек бала-чаган күп булсын. Укыган ясин шәрифне Хәзрәтe Йосыфка багышлыйм. Бала-чаган аның кебек матур булсын, падишаһ булсын",—кебек вак сату-алулар бик эчне пошыра, һичбер бер төрле иттереп дикъкатьне теләгән нәрсәгә борырга ирек бирмиләр. Бигрәк тә Муса афәнде (Муса Биги) берлә безнең икебезнең башларыбыздагы бүрекләр бөтен хәерченең күз алдына, сугыштан элек сирәк кенә килеп жиярәт итә торган татар байларын хәтерләттe һәм безне Әхмәд бай *(Хөсәенов.—1837—1906.—Аталкы татар сәүдәгәре.)* берлә Хәсән Акчурин *(1855-1916.—Татарның эре фабриканты.)* дип хисапланды булырга кирәк. Алар безнең бөтен ягыбызны сырып алып әллә ниләр сөйләнүдән туктамадылар. Шуның өчен мәҗәд һәм зыяратларны туйганчы карап булмады. Тиздән чыгып качтык. Бу урын мәселманнарга изге бер жир булган кебек, ул яһудиләр өчен дә мөкаддәс һәм зиярәт итә торган урыннары. Ләкин алар үзләреннең олугларына хөрмәтсезлек булмасын өчен, мәҗәдкә чыга торган баскычларның берничәсеннән югары үтмиләр, пәйгамбәрҗенең туфрагы яткан җирдән аякларны берлә басудан сакланалар икән. Шунарга баскычка менә торган жирдән яһудилэрнең йөзләрен сөрудән *(сөртүдән.)* ялтырап беткәннәр. Соңгы гарәп-яһуди кычкырышы вакытында мондагы яһудиләргә ярдәм килмәгәнгә, бик күп яһуди өйләре жимерелгән, үзләре качканнар. Синагоглары буш калган. Бүген анда бер яһуди утырмый икән.

Хәлил әр-Рахманнан соң без Бәйтелләхмгә *(Вифлеемгә.)* киттек. Бу жир—Хәзрәтe Гайсәнең туган урыны. Хәзрәтe Мәрьям корсаклы булгач, монастырьдан куганнар. Аны хөрмәтсез итәргә теләгәннәр. Шул яшь хатынны саклау өчен, Йосыф исемендә бер яхшы кеше Хәзрәтe Мәрьямгә өйләнгән. Үзе хөрмәтле карт булганга, үзенең исеме берлә Хәзрәтe Мәрьямне сакланган. Бала туар вакыт җиткәч, андый-мондый тавыш чыкмасын дип, Мәрьямне ишәккә атландырып, аулак бер жир эзләргә дип чыгып киткән. Уйлаган жиргә барып житә алмаган. Юлда юлаучы туктый торган бер жирдә Хәзрәтe Гайсә дөньяга килгән. Менә бу жир—шул урын. Ул жирдә Константиннның *(Византия императорының.)* хатыны Елена тарафыннан зур бер чиркәү салынган. Ул бик матур иттереп эшләнгән һәм мозаик берлә бизалган. Мина инде мен ярым ел вакыт үткән булса да, әле мозаик эшләренең бик күбесе сакланган. Болары күргәнгә Византс *(Византия.)* мәдәнияте нең никадәр тирән булганын күз алдына китерәсен. Хәзрәтe Гайсә туганнын соңында, аны юганнар. Ул жир бер чокырлы таш. Ул да чиркәү эчендә калдырылган. Аннан соң бала йоклатырга бишек булмаганга, аны печән-салам ашый торган тагараккa салганнар. Ул жир дә хәзер изгеләнгән һәм аерым итеп тотып алынган. Гайсә туган вакытта күк йөзендә бик зур галәмәтләр булган.

Йолдызлар ана сәҗдә иткәннәр һәм жиргә ингәннәр, имеш. Йолдыз төшкән жир дип тагын бер жирне әерпи куйганнар. Анда алтыннан бер йолдыз сурәте да ясаганнар. Уртасындагы тишектән йолдыз жиргә сенеп киткән, имеш. Әлбәттә, боларның бик күбесе арттырылган. Ләкин Гайсәнең шунда тууы мәгълүм бер нәрсә. Шунар күрә бу жир—христиан дөньясы өчен бик зур хөрмәтле урын. Аның бөтен тирәсенә бик күп монастырьлар салынган. Чиркәүнең эче, Кодестагы күк, төрле мәзһәбләргә бүлеп бирелгән. Бу мәзһәбләр дә бер-берсенә кашы дошман бер вазгыятъ алганнар.

Безгә чиркәүне бер әрмән побы күрсәтеп йөрде. Сөйли, тарихны да яхшы белә. Ул безгә әллә нинди кирәкмәгән тәрелөрне күрсәтеп, башыбызны әйләндермәде. Тарихи якларына дикъкать итте. Шунарга без бу попдан бик рази калдык. Чиркәүнең тирә-юнен карап йөргәндә, монастырьларының беренең ишегенә язылган бер кәгазь безне гажәпкә калдырды. Анда "Хатыннарга керергә мәмнүгъ (тыелган)",—дип язылган. Моның сәбәбен белер өчен ишекне кагып, сорамакчы булдык. Ләкин ишектән берәү дә чыкмады. Әрмән побы сәясәт исәдә булырга кирәк, моның мәгъһәсен безгә аңлатмады. Аннан чиркәүнең башына чыгарга булдык. Безгә кечкенәрәк монаклар юлбашчылык иттеләр. Уңайсыз гына баскычтан үрли башладык. Бераз меңгәч тә, бер зур чиркәү кыңгыравы юлыбызны каплады. Ни күзебез берлә күрик: кыңгыраура урысчалап фаланфалан тарафыннан, фалан елда Тула шәһәрендә эшләнгән, дип язылган. Юл күрсәтүче: "Бу баш үзе дә урыслар тарафыннан эшләнгән. Мондагы рум монастыры бөтенләй урыс акчасына яши иде. Хәзер Русиядән килүче киселгән, акча да бетте. Румлар *(грекләр.)* бик ярлыланды",—диде. Юлда очраган кыңгыравуларның барысының да Русиядә эшләнгән булганы күренә иде. Башына менеп житеп, шәһәрне карадык. Урыс акчасына эшләнгән зур-зур биналарны югарыдан сәер иттек *(күзәттек.)*. Аларда безнең халкыбызның да мангай тирләре берлә эшләнгән миллионнарның әрәм булып ятуына ачындык.

Акрын гына төшә башладык. Кыңгырау яныңа килгәч, Муса әфәнде: "Кагып карыйкмы әллә? Бу бит безнең халыкның акчасына эшләнгән",—диде. Мин дә шул әрәм акчаның жылаганын ишетәсем килеп китте. Монахка сөйләдек. Ул: "Юк, ярамый. Аны зур бәйрәмнәрдә генә кагалар",— диде. Карыйсы жирләрен карап бетердек. Чиркәү бик искергән, сәләмәләнгән булганга, "ник төзәтмисез?"—дип тагын сорадык. Чиркәү төрле мәзһәб арасында бүленгән. Төзәтү өчен бер фикергә килергә кирәк. Шуны булдыра алмыйбыз, диделәр. Бу ислам дөньясына каршы эшләрдә берләшә белгән христиан дөньясының үзенең бик зур изге урыннарын саклауда берләшә алмавына гажәпкә калып, чиркәүдән чыктык та, бу шәһәрдәге мәсҗедне карарга киттек. Мәселманнар аз булганга булырга кирәк, монда мәсҗедләре зур да, бай да түгел; тарихи кыйммәте дә юк иде.

Урамга чыксак, бер төркестан түбәтәйле әфәнденең бер кибәттә сату-алу иткәнен күрдек. Чыннан да бу кеше фирганәле Габделкәрим исемендә бер үзбәк булып чыкты. Большевикладан качып чыгып, элек Эфганстанга, аннан акрын-акрын Кодеска кадәр килеп чыккан. Хәзер Бәйтелөхмәдә кечкенә генә бер кибет ачып, христианнарның шәмнәрен, вак-тәяк изге китапларын, хәтта төрелөрен сатып сөудә итә икән. Безне, туганнарын күргән кебек, каршы алды. Хәзер *(бик тиз.)* кибетне ябып, өенә чәй эчәргә алып керде. Бу әфәнде инде монда бер гарәп хатынына өйләнеп, үзенең гаилә нигезен дә корган һәм икс баласы да булган икән. Икс-өч яшлек зур кызы үзбәкнең бөтен төсләрен алып чыккан. Ләкин теле, "баба"дан *(әтидән.)* башкасы, гарәпчә. Үз иленнән хат-хәбәр булмауга бик зарланды. Без дә белгән мәгълүматны биреп аерылдык.

Кодеска кайтып, анда күрергә өлгермәгән жирләрне караштык. Монда безнең өчен иң кызыгы Кодес каласын урап алган коймa иде. Бу коймa шул кадәр ныk, шул кадәр биек итеп салынган, инде дүрт йөз ел үткән булса да, әле бер кирпечe дә төшмәгән иде. Коймаңы Сөләйман Ечуне *(XVI йөздә идарә иткән госманлы солтаны.)* эшләткән. Бу жирләр аның атасы Явыз Сәлим вакытында Төркиягә кушылган булган. Сөләйман Кануни Кодесны зиярәт иткәннең сонында, халыктан: "Сезгә бүләк бирергә телим. Сез нәрсәгә мохтажсыз?"—дип сораган. Ул вакытларда шәһәрне бәдәвиләр *(күчмә гарәпләр.)* килеп басып, талап торганга, халык шулардан котылыр өчен: "Безгә бер коймa кор. Бәдәвиләр үтәрлек булмасын",—дигәннәр. Сөләйман Кануни шул коймаңы кордырган.

Шуннан соң Кодес халкы тынычланган. Без кайманы әйләнеп чыгарга теләдек. Ләкин монын өчен ин аздан дүрт сәгать вакыт күбрәк кирәк икән. Без кайманын төрле капкаларын карап, каравыл ясалган жирләренә чыгып, тирә-юньне күздән кичердек. Кайманын тарихы, максаты һәм шуна сарыф ителгән көч хакында төшендек. Анын салынуына, көн исәбе белән, миллионнарча эшче көне киткән. Анын өчен, шөбһәсез, миллионнар-миллионнар акча түгелгән. Аны елдар буе ун-егермешәр мең кеше эшләгән. Хәзерге көндәге биш Акараны корылык материал киткән. Төрекнең ул вакыттагы ин зур мөһәндисләре (инженерлары) монын өчен башваткан. Ни өчен төрекнең ин зур падишаһы—мөселманлыкның көчле хәлифәсе—моны эшләткән? Ул вакытта бу көчне, бу материалны, бу акчаны төрек халкының үз файдасына куя алачак бер урын юк идеме? Бар иде. Ул төреклек өчен дә, мөселманлык өчен дә Кодестан кырык мәртәбә әһәмиятле бер урын—Идел буенда урыска каршы төрк-татар милләтенең корган Казан каласы, мөселман өммәтенең христианлыкка каршы корган Казан ханлыгы иде. Ул шул көннәрдә Иван Грозный берлә үзенең барлыгын, иреген саклар өчен канлы сугышта иде. Ул шул илнең ислам мәдәнияте астында яшәве өчен мең төрле корбан берлә үзен сакларга тырыша иде. Ул үзенең көче берлә генә урыс агымын, христианлык ташкынын туктата алмаганын күргач, үзенең мәсъәләрендә иселенә хотбә укыла торган хәлифәсенә—Сөләйман Канунига дин исеменнән ислам байрагын сакларга ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән иде. Ул урыслыкка каршы гасырлар буе чик саклаучы булып килгән, төрк илләреннең сакчысы булган Казанны бергәләшеп саклашырга үзенең олуг агасы итеп яна ялварган иде, ялынган иде. Аз гына көч бирә күр, урысларга каршы ике генә сүз сойли күр, дип күз яшен түккән иде. Сөләйман: "Мин, бөтен мөселманнарым хәлифәсе, жир йөзенең солтаны, дингезләрнең падишасы, әмирләрнең әмире. Мин андый вак, Казан кебек эшләр берлә вакланыйммы? Минем алдымда зур эшләр тора: Кодесны зур койма берлә әйләндерәсе, Крит атасын *(атавын.)* камасы, Венаны мохасарә итәсе *(камап аласы.)* бар. Китегез, башны әйләндереп йөрмәгез, мине ваксытмагыз",—дип, Казаннын күз яше эчендә булган илчеләрен кире борып жибәргән иде.

Ана инде дүрт йөз елга якын вакыт үтте. Сөләйман Канунинын менләрчә-меңләрчә төрекләрнең канын түгеп, елдар буе сугыштан соң алган Крит атасы бүген Юнанстаннын *(Грециянен.)* яхшы зәйтүн үстерә торган бер губернасы булды. Кодесның әйләнәсенә миллионнарга төшереп эшләткән кальга арган каргалларның күнып каркылдый торган жиргә әйләнде. Вена шәһәре... бар да билгеле. Казан нишләде?.. Ул урыс агымына үзе генә карыш тора алмады, төрк илләренең сакчысы түгеллеге. Урыс ташкыны Казанны гына түгел, бөтен Идел буен басты. Себерне алды, Кырымны таптады, Төркияне Кара дингезнең бу ягыннан куды. Төркестанны басты, Балканны аякландырып, Төркиянең берлеген парчаландырды *(жимерде.)*, Төркиянең бөтен барлыгын бер сорау тамгасы астына алды...

Сөләйман Кануни Иван Грозный кадәр булмыйча, аның бер командиры чаклы гына бер милләтче булган булса иде һәм Казанга кечкенә генә бер ярдәм күлын сузган булса иде, Төркия башына бәла булган бер урыс империясе кайдан чыгар, кайдан күәт алыр иде дә, Сөләйман Кануни корган Госманлы империясен кем жимерер иде? Нинди юл берлә ул төрк мәдәниятенең бишегe булган Төркестанны таптар иде? Бу сорауларның жаваплары төрк деньясы өчен бигүк ямьле хатирәләрне ачмаганга һәм төрк *(бу сүзнен бу рәвешле язылышы "төрки" мәгънәсен белдерә.)* кабиләләре арасындагы мөнәсәбәтнең табигый булмаганын күрсәткәнгә күрә, алар турында сүзне бу урында озайтмыйча, Кодес сәфәрен тәмамлыйк.

Ахыры киләсе санда.

Адлер Тимергалин

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

БӘДӘВАМ *г.* — "Дәвамлы рәвештә, кабатлана торган" мәгънәсендә. *"Бәдәвам китабы"* — татарлар арасында киң таралган дини әчтәлекле тезмә әсәр. Дүрт юллы строфалар тезмәсеннән торган һәм көйләп укыла торган бу әсәрнең һәр строфасы *"Аллаһ дигел бәдәвам"*, ягъни "Берөзлексез Аллаһ дип кабатла" сүзләре белән тәмамлана. Авторы һәм кайчан иҗат ителүе билгесез. Кайберәүләр аны Утыз Имәнигә нисбәт итәләр, ләкин Ш.Мәржани бу китапны бик борынгы әсәр дип саный. Иҗат ителү вакытын монгол чорына кадәрге дип тә санаучылар бар. Китап Ислам нигезләрен пропагандалый, анда мәҗүси гореф-гадәтләр тәнкыйть ителә. Беренче тапкыр бу китап 1846 елда Казанда нәшер ителә, аннары тагы кат-кат дөнья күрә.

БӘЙТ ӘЛ-ИБРӘ *г.* — "Инә йорты" мәгънәсендә. Магнитлы энәсе булган һәм дөнья якларын күрсәтә торган әсбап — компас, буссоль. Бу әсбапны аталары гарәп дингезчесе *Әхмәд ибн Мәҗид* уйлап чыгарган.

БӘРӘҢГЕ ФЕТНӘСЕ *тар.* — 1840 — 1844 елларда безнең якларда (Казан губернасы Лаеш өязендә) хакимиятләрнең бәрәңге утырту сәясәтенә каршы халык кузгалышы. Гомумән, "бәрәңге" сүзе татарда бәрәңге утырта башлаганчы да булган (*"урман бәрәңгесе"*). 1807 елда Оры авылының агъшп китүен сурәтләгән бәетта "Бәрәңге урманы агачы" телгә алына. Бер уңайдан, "бәрәңге" сүзенең килеп чыгышына карата Каюм Насыйрида очрый торган фаразны да әйтеп китәргә мөмкин. Ул "бәрәңге" сүзе фарсыча "фәрәңги" ("франкларныкы", "Европаныкы") сүзенә барып тоташа дип күрсәтә. Шулай да бәрәңге игү Рәсәйтә Германиядән кергән булырга тиеш. Шунысы кызык, Америкадан кайткан талымсыз бәрәңге культурасы Германиядә дә тиз генә кереп китә алмаган, моның өчен хакимиятләргә халыкны ирексезләү һәм мәҗбүр итү чаралары да кулланырга туры килгән (мәс., Пруссиядә Фридрих тарафыннан). Тора-бара бәрәңге халыкның төп ризыкларыннан берсенә әйләнгән диярга мөмкин. 1941 — 45 елларгы Ватан сугышы вакытында СССР да нәкъ менә бәрәңге миллионлаган кешене ач үлемнән йолып калды. Шагыйрь Мәхмүт Хөсәен бәрәңгегә: "Йодрык кадәрле, Йомры гәүдәле, Ак тәнле, Ах, тәмле, Бигрәк тәмле бәрәңге!" — дип мәдхия укый. Немецларда да бәрәңге турында күңелле җыр бар.

БӘРДЕ ГАҖҮЗ *г.* — Март ае ахырларында була торган салкыннар. *"Карт-карчыклар суыгы"* дигән сүз. *"Әбиләр чуагы"*на капма-каршы. Татар диалектларында, башкортларда һәм казакъларда аны *акман-токман, акпан-токпан* дип атыйлар.

БЕР ТУКСАН *тар.* — Туксан көн мәгънәсендә. Электә елның һәр кварталын бер туксан дип йөрткәннәр. *// Туксансыз тургай чырламас* — ел башыннан туксан көн үтмичә тургай сайрамас.

БЕРЕНЧЕ КУЛ ЧЫГАНАКЛАР — Беренчел чыганаклар. Русча — *первоисточники*. *// Аның, үз хисабына сәяхәт итеп, беренче кул чыганакларга нигезләп язган хезмәтләре фактик материалга байлыгы белән әле булса фәнни әһәмиятләреп югалтмаганнар (Исмәгыйль Рәми).*

БИГЕМ — Төрки сүз, "минем бигем" (бөгем, бикәм) мәгънәсендә. Шуны искә төшерик, урта гасырларда Франциядә кардиналларга "монсеньор" ("әфәндем") дип эндәшкәннәр.

Дәвамы. Башы журналыбызның 1 нче санында.

"Бигем" исә электә төркиләрдә аксөяк хатын-кызга эндәшү сүзе булган (ханым кебек).

XVI гасырда Төньяк Һиндстанны Тимерләр яулап алгач, буйсындырылган өлкә һәм шәһәрләрне идарә итү эшен алар үзләренең бикләренә тапшырганнар. Шул рәвешле биредә *бикләр* һәм *бигемнәр* пәйда булган. Һиндстанда "бигем" сүзе "бегум" һәм "бегүма"га әйләнгән. Мәс., Жюль Верн "Бегуманың биш йөз миллионы" дигән романында Һиндстандагы бер идарәче ханымны "бегума" дип атый.

Әзәрбайжаннарда *Бигемага, Бигемжан, Бигемханум* кебек хатын-кыз исемнәре теркәлгән.

Тагын кара: ***ХАНЫМ.***

БИДГАТЬ *г.*—Башка гадәт; эләккесенә каршы килә торган эш, кырыш эш мәгънәсендә. Коръән һәм Сөннә өйрәтүләре белән сыешмый торган фикерләр, гамәлләр, гадәтләр һәм йолалар; ересь. Ләкин Исламда "бидгать хәсәнә" төшенчәсе дә бар, мәсәлән, заманында Мәүлид бәйрәме ижмаг тарафыннан шундый хуп күрелә торган гамәл дип игълан ителә (*бидгать хәсәнә*—хуплана торган яңалык, күркәм яңалык). Бидгать сүзе (*бида* рәвешендә) "Древнетюркский словарь"га теркәлгән.

Бидгать гамәлләрне кылучыларның тәүбәсен һәм кылган гамәлләрен кабул итүдән Аллаһ баш тартты. Мөселманнар арасында бер бидгатьче кеше заһир булса, аны бидгать гамәлләрдән туктатыгыз, туктамаса, аңа һичберегез иярмәгез, чөнки ул динне бозучы һәм мөселманнарны аздыручы (Хәдис.).

Бидгать гамәлләр турында Галимҗан Баруди түбәндәгеләрне яза.

"Бидгатьләр арабызда бик күп таралган, алар идә тартышу күп кешеләр илә тартышу була. Шунлыктан бу читен мәсьәлә турында мәкаләләр язу безнең кеби көчсез затларга бигрәк тә зур инде...

Һич динһән булмаган нәрсәләрдә дә дин исеменнән зур тәгъсиблар кылабыз (азапланабыз).

Безнең бу ялгыш сәясәтебез эшне сүтә генә бара. Урынсыз тискәреңүләргә яшьләрнең сарулары кайнап, бездән бизүләргә сәбәп була. Бу һич тә динһән булмаган мәсьәләләр өчен кешене фасыйк, вәһһаби, кәфир вә әлла ниләр ясап бетерсәк, хәтта бидгатьләрне үтерү вә сөннәтләрне тергезү өчен тырышып йөрүчеләргә дә шул ук исемнәрне тагып, телебезгә килгән бар начар сүзне әйтеп, күлымыздан килгән бар зарарны кылып йөрсәк, яшьләрнең безне бер жирәнгеч мәхлук санап, бездән бизәчәкләре табигыйдыр. Безгә асыл дин илә аңа соңыннан тагылган бидгать вә хорафатларны аера алмый йөрергә оят инде. Китабымыз Коръән Кәрим һич үзгәрми заманыбызга кадәр сакланып килгән һәм Пәйгамбәребезнең хәдисләре дә язылган. Рәсүл Әкрәмнең тәрҗемәи хәле дә камил рәвештә язылган. Шулар мәйданда була торып та, диннең рухын вә мәгънәсен ялгыш аңлап йөрергә, дин өстенә ташланган чүпләрне диннең жәүһәрләре дип сатаашырга нинди гозер бар?"

/ / Бидгать мәзһәб.

БИДГАТЬ АТАСЫ *гг.* — Ересиарх.

БИДГАТЬЧЕ *г.*—Бидгать гамәлләр тарафдары, еретик.

БИЗМӘН *тар.*—"Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"ндә бизмән—"Бер башы чукмарлы, икенче башы үлчәнә торган әйбер әлеп куярлык итеп эшләнгән шкалалы күчәрдән гыйбарәт үлчәү". Бу иң гади үлчәү коралы һәм аны белдергән сүз борынгы Иранннан сәүдәгәрләр белән килгән дип уйларга нигез бар. "Бизмән сүзе төрки телләрдән (бик ихтимал, болгар теленнән) башта Скандинавия илләренә, аннары Русь илено һәм Германиягә тарала" (Р.Әхмәтьянов). Ул швед, дания, немец, чех, поляк һ.б. телләргә дә кергән.

Кайчагында Үлчәү (Мизан) йолдызлыгын *Бизмән йолдызлыгы* дип атау очрый.

Тагын кара: ***БАТМАН.***

БИИСМИЬИ *г.*—(Аллаһ) исеме белән (ягъни: *бисмиллаһ*). Ризаэддин Фәхреддиннең хатлары гадәттә шушы сүз белән башлана. */ / Бииспиһи сөбханаллаһи*—

мактаулы Аллаһ исеме белән (шулай ук хат башында очрый).

БИМАРСТАН *ф.* — Шифаханә, хастаханә. Ислам дәверендә беренче бимар- стан әл-Вәлид ибн Габделмәлик хәлифәлек иткән заманда ачылган. 259 / 873 елда Әхмәд ибн Тулун Мисырда беренче зур шифаханәне төзи. Фәкать яһүд халык өчен генә ачылган бу шифаханәдә бер генә солдат та, бер генә сарай хезмәткәре дә дәвалана алмаган. Анда ирләр һәм хатын-кызлар өчен аерым мунчалар булган. Идарәче бу бимарстанны тотуга елына 60 мең динар акча биреп бара. Шифаханәдән дәваланып чыкканда пациентларга бер тавык һәм бер ипи биреп жибәрә торган булганнар.

БИРҮНИ—Әбү Рәйхан Мөхәммәд ибне Әхмәд әл-Бирүни (973, Кита, хәзерге Каракалпакстанның район үзәге Шаббаз (Бирүни) – 1048, Газна). Урта Азия галиме, энциклопедист. Гарәп телендә язган, ләкин туган теле фарсидан башка, тагын төрки, санскрит, йәһүд һәм Сүрия телләрен дә белгән. Тарих, математика һәм астрономия, география, топография, физика, медицина, геология һәм минерология буенча хезмәтләре күп. Шәрыкта беренче буларак, Жирнең Кояш тирәли әйләнүе турында фикер кузгата, ләкин тикшеренүләрендә геоцентризм системасына таянып эш итә. Тарихи процесслардың барышында кабатлану цикллары булуы турында фикерләр әйтеп чыккан. Тарихта оҳшаш чорларның, оҳшаш вакыйгаларның, хәтта оҳшаш шәхесләрнең ниндидер бер эзлеклелек белән кабатлануы турындагы фикер рус галиме, Шлиссельбург торкыны мәшһүр Н.А.Морозов тарафыннан күтәрелеп, соңгы елларда бу мәсьәлә математик исуллар белән дә тикшерелде һәм чынлап да тарихи күренешләрнең аерым блоклар рәвешендә кабатлануына игътибар ителде. Жир табигатендәге аерым цикларның Кояш активлыгына бәйлелеге дә исбат ителгән факт *(А.Л. Чижевский)*.

Бирүни календарьлар тарихы белән дә кызыксынган.

Әбү-р-Рәйхан әл-Бирүнинең "Кичкән буыннар ядкярләре"ндә Мохәммәд Пәйгамбәрнең тормыш юлындагы вакыйгалар һәм фактларның жентекле хронологиясе китерелә.

Гомумән алганда, Бирүнинең ислами карашлары табигый-фәнни карашлар белән бергә үрелгән.

Астрология белән дә кызыксынган. Аның "Йолдызлар турындагы фән башлангычларына төшендерү китабы" билгеле (еш кына аны "Астрономия" яки "Астрология" дип тә йөртәләр).

Бирүниның "Китаб әс-сайдана фит-тыйббә" китабында 1000 нән артык агач һәм төрле үсемлекләрнең, дару үләннәренең үзлекләре турында мәгълүмат бирелгән. "Сайдана"нең төп нөсхәсе 1927 елда Төркиянең Бурса шәһәре китапханәсеннән Әхмәд Зәки Вәлиди Тоган тарафыннан табылган. 1941 елда галим аны рус теленә тәрҗемә иткән.

Бирүни Идел буе болгарларының теле турында да язып калдырган.

БИТЕК—Татар һәм башкорт телләрендә шифалы тылсым көченә ия булган язулы догалык кәгазе, талисман, амулет. *Бәти* сүзендә сакланган. Әбиләр аны, өчпочмаклап күн белән тышлап, яннарына тагып йөргәннәр. Борынгы чорда кытай теленнән кергән сүз дип исәпләүчеләр бар. Борынгылыкта *китап, төргәкнамә* (свиток) мәгънәсенә дә ия булган шикелле. */ / Битмәк* – язмак, язу. *Бителмеш* – язылмыш.

БИТЕКЧЕ, БИТКҮЧЕ *бор.* — Язучы, кятиб, секретарь, писер. */ / Диван битекчесе* – суд секретаре. *Олы битекче (битикче)* — баш секретарь, беренче секретарь.

БИХӘБЛИЛЛАһ *г.* — Би+хәбл+аллаһ. Туры мәгънәсе: Аллаһ бавына. Ягъни: *аллаһ бавына ябышып, Аллаһының ярдәме белән. / / Ябышырлар бихәблилла җәмига* — ябышырлар барысы да Аллаһ бавына *(Г.Тукай)*.

БОЕРЧЫ *тар.* — Хан диванханәсендә теге яки бу эш тармагын идарә итүче канцелярия хезмәткәре, мәэмүр, приказный. "Древнетюркский словарь"да шушы ук мәгънәдәге *буйрук, буйрук, бырук* сүзе теркәлгән.

БОЕРЫК БӘКЛӘР *тар.* — *Приказные* (казакларда ефрейтор дәрәҗәсенә туры

килә). Чыганакларда *"буйруг бәгләр"*, *"буйрукта ултурган кешеләр"* рәвешендә дә очрый.

Тагын кара: ***БОЕРЧЫ.***

БОКТЫРМА *тар.*— Яшеренгән гаскәр, поскак, бөгәвел, засада. Мондый сугыш алымын монгол гаскәрләре еш кулланганганнар булса кирәк. Соңра ул русларга да күчкән (мәс., Куликово сугышындагы "засадный полк").

БОЛА— Чуалыш, фетнә, гыйсьян. // *Болачылар*— фетнәчеләр.

БОЛГАРИ, БОЛГАРЫЙ *тар.*— XIV гасырда монгол, тибет, румын, венгр һ.б. телләрендә яхшы сыйфатлы йомшак күннең исеме. Мондый күнне болгарлар чит илләргә дә сатканнар. Татар телендә "болгар олтан" дигән сүз дә сакланган. Нәкыл Исәнбәт *болгар олтан*— "сыер-үгез күненнән борынгы болгарлар ысулы белән махсус рәвештә эсалган нык олтанлык" дип яза. // *Унган хатын билгесе: игә кертер тирене, Болгарый кылыр күнене, түнлы кылыр ирене.* Чынлап да дала яғында тире илләү белән хатын-кызлар шөгыльләнгән.

"БОРТАС ТУНЫ"— Бортас илендә яшәгән кызыл төлке тиресеннән эшләнгән тун гәрәпләрдә "бортас туны" исеме белән билгеле булган (Әбү Габдулла әл-Гарнатый буенча).

БОЯР *тар.*— "Татар телеңең аңлатмалы сүзлегендә" "бояр" сүзенең ике мәгънәсе күрсәтелгән: **1**.Мәскәү Русендә бүләк итеп бирелә торган югары дәрәҗә; шул дәрәҗәгә ия кеше. **2**.Борынгы Руськта һәм Мәскәү дәүләтендә хаким сыйныфның югары катлау вәкиле, әре жирбиләүче.

Р.Әхмәтьянов бер нигездән чыккан "баяр" һәм "бояр" сүзләрен аерып карый. "Баяр" сүзе "алпавыт" мәгънәсендә һәм ул XVI—XVII гасырларда рус телендә кулланылган *боярове дети* "бояр хезмәтчеләре" сүзеннән килә. Соңгысы "Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"ндә "Бояр балалары" рәвешендә бирелгән һәм "Борынгы Руськта (XIII гасырдан) һәм Мәскәү дәүләтендә хәрби яки гражданлык хезмәтен үтәгән вак алпавытлар" дип аңлатылган. Р.Әхмәтьянов үзенең "Этимологик күзәтүләр" исемле мәкаләсендә "*Бояр, боярин* (шуннан үк *барин, бар, барыня, барышня, барич* сүзләре ясалган), яки *боярын* асылда "патшаның вассалы" дигән сүз. Баярлардан үзәгә буларак, боярлар тик XVIII гасырда гына булганнар. Бояр патшага карата үзен шактый мостәкыйль тоткан—аның үзенең армияе (әлеге *боярове дети*) булган һәм ул, боярлар думасының члены буларак, патша сәйлауда катнашкан (татар дәүләтләрендә бу функцияне карачылар үтәгәннәр)",—дип яза.

Рус телендәге *бояр, боляр* сүзе Дунай бие славян болгарлары теленнән кергән дип исәпләнә. Ә алар аны төрки болгарлардан алганнар. Охшаш сүзләр хорват, словен, чех һәм словак телләрендә дә бар икән. Борынгы төрки телләрдә *бойла яр*—хакан хозурында аерым кабилә(ләр)нең вәкиле. Борынгы чыганакларда төркиләрдәге *уң кул бойла ир, сул кул бойла ир* һәм *бойла бага тархан* (илче бага) дәрәҗәләре билгеле. Рус авторлары "байар" сүзен *бай+ир* мәгънәсендә итеп карыйлар. Соңрак Мәскәү кулы астына кергән төркиләрдә бу сүз "дворян", "рус алпавыты", "рус офицеры" мәгънәсен дә алган.

БӨГӘВЕЛ *тар.*— Шпион; засада (поскак, боктырма).

БӨЗӨРГЕЛӘР (бозорглар) *ф.*— Үткән заманнарда булган зыялылар, гыйлем-хикмәт ияләре, бөеклә р. Урта Азиядә бөзөргелә рнең каберен зиярәт кылу, анда барып дога уку, садака өләшү кебек гамәлләр нык тәмләр жәйгән була. *Бөзәрге*— тәсаувыфта суфылыкның бер югары баскычы, дәрәҗә. Бу дәрәҗәне алган хатын-кыз да ир (ирән) дип аталырга хокуклы. // *Пәләри бозорг*—дәү әти, бабай. *Бозорги кадер*—кадерле зур кеше. *Бозорги рузгар*—замана олысы. *Багъ бозорган*—изгеләр бакчасы.

Мәратибләр бозорг иләи имәс— "Мәртәбәләр зурлык (олысымаклык) белән түгел" (*Габделжәббар Кандалый*).

Утыз яшьтә утын кыйлып, көйдерделәр, Җәмлә бәзәрг йыглып, донья куйдырдылар (Хужа Әхмәт Ясәви).

Бозорг ибн Шәһрияр– һиндия могҗизалары турында әкиятләр җыентыгы төзегән диңгез капитаны.

Г.Ф.Саттаровның "Татар исемнәре" сүзлегендә "Бүзәргән" исеме теркәлгән. Төзүче аның мәгънәсен борынгы төрки *боз – буз – буз* сүзеннән чыгара (*буй* мәгънәсендә; ягъни балага "Буйга җиткән" исеме куешлган булып чыга). Чынлыкта исә, ихтимал, Казан шәһәренең 1565 / 68 – 1646 елларга караган теркәү кенәгәсендә телгә алынган *Безергән* исеме һәм *Безергенев* фамилияе фарсыча *бәзәрге* (зыялы, хикмәт иясе, олы) сүзенә барып тоташа торгандыр.

БӨРЕҖ *г.*—В.М.Беркутова: "Татарларда Кояш системасы Бөреж дип аталган," – дигән фикер очрый. Ләкин асылда гарәпчә *бөреж – бүрүж* сүзе зодиак йолдызлыкларын белдерә һәм ул грек телендәге *манара, каланча, башня* мәгънәсендәге сүздән алынган. Урта гасырлардагы гарәп астрономиясендә 14 зодиакаль йолдызлык: Кучкар, Үгезбозау, Орион, Игезәкләр, Кысла, Арыслан, Кыз, Үлчәү, Чаян, Укчы (Жәя), Кәкәмөгез, Сукояр, Тулпар әкә Дөлдөл (Пегас) һәм Андромеда. Моннан күренгәнчә, бу исемлектәге Орион, Тулпар-Дөлдөл һәм Андромеда йолдызлыклары бүгенге зодиакаль йолдызлыклар исемлегенә кертелми, аның каравы анарда Балыклар йолдызлыгы юк (өстәвенә хәзерге карталарда зодиакта 13 нче йолдызлык – Еланлы йолдызлыгы да күрсәтелә).

Бүрүж һәм *Бурж* язылышлары очрый.

БӨТИ-ТУМАР *тар.*—Шифалы һәм тылсымлы сүзләр язылган талисман, амулет. Гадәттә аны муенга такканнар. Ләкин "Мәхәббәт язуы дип, ялган бөтиләр тагып йөрү" шәригатькә хилафлык кылу була. *Бөти-томыр* язылышы да очрый, тик дөресе шулай ук *бөти – битек* мәгънәсендәге *тумар* булырга тиеш. Үзбәк телендә дә "тумар" – талисман мәгънәсенә ия. Аларда *муен томар* һәм *култык томар* атамалары бар. Беренчесе күлмәк өстеннән хатын-кызлар тагып йөри торган өчпочмаклы бизәнгеч, ә икенчесе портсигарга охшашлы металл савыттан гыйбарәт булып, аны да күлмәк өстеннән тагып йөрткәннәр. Безнең керәшенәрдәге *мыйтумар* (бутумар) – шул ук муен тумары. Керәшенәрнең мыйтумары берничә рәт көмеш акчалар тезгән күкрәк бизәнгеченнән гыйбарәт булган.

БУРАЛГЫ– Сукбай, зимагур, әварә. Русча – *бродяга*. Ихтимал, *бурлак* сүзе дә шушы буралгы сүзенә барып тоташа торгандыр. Р.Әхмәтьянов бу сүзне "бор-у"(әйләнү, әйләнеп йөрү) тамырыннан чыгара һәм "брамат" сүзен дә шуңа бәйләп аңлата. "Буралгы" сүзе Сәгыйть Хәлфиннең куҗязма сүзлегенә теркәлгән. "Идегәй" дастанында *буралгы* – "брамат йөргән, иясез ат". Безгә билгеле булган мәкаль-әйтемнәргә караганда, бурлаклык татар юксыллары арасында да тамыр жибәргән: мәс., "Бурлакка башын кояштан яшерергә зурат бар", "Бурлак киткән Шәмәрдән, кайтып килә Самардан, аяк-кулы кабарган", "Бурлакның ботыннан тотып селкесәң, бете коела, ди" кебек мәкальләр шул турыда сөйли. Татарстанда Идел буена урнашкан "Кабачище" авылы (хәзерге Яшел Үзән) бурлак-буралгыларның "мәркәзе" булып исәпләнгән.

БУРДА *тар.* – Үзенә багышлап мәдхия язганы өчен, Мөхәммәд Пәйгамбәрнең шагыйрь *Кәгаб бин Зәһирга* бүләк иткән ябычасы. Исламның кадерле ядкәре булып хисаплана торган бу ябычаны кат-кат юк иткәннәр, ләкин ул яңадан пәйда булган. Кәгаб бин Зәһирның һәм гарәп шагыйре Мөхәммәд ибн Сәед әл-Бусириның касыйдәләре дә бурда дип аталган. Соңгысының "Касыйдәт әл-Бурда" дигән поэмасыннан алынган юлларны җәмәгать биналары дивар ларына эләләр, аларны, Коръән аятьләре белән беррәттән, мәет озату йолаларында укыйлар.

БУРИЙӘ, БУРИЯ *ф.* – Чыпта, камыш палас. Камыштан үргән көрзин һәм биштәр кебек нәрсәләрне дә бурия дигәннәр. // *Суда үскән камышларның Аслы бер дә, нәсле бер. Бәгъзесеннән канд алырлар, Бәгъзесеннән – бурия (Гали Чокрый).*

"БУРИЙӘ КУБЕ" *ф.* – "Чыпта хакы" мәгънәсендәге үткен сүз. Мәдрәсәләргә вәкыф ителгән хәҗрәләрне сатарга ярамагач, кайбер Бохара дамеллалары, хәйлә юлына басып, вәкыфлы хәҗрәнең, имеш, үзен түтел, бәлки хәҗрә ишеген ача торган ачкычны, хәҗрә эчендәге иске чыптаны яки камыш паласны (бурийәне) яисә ишек чаршавын, – шуларга хәҗрәне өстәп, – сата торган булганнар.

БҮЗ БАЛА, БҮЗ ЕГЕТ *тар.* – 10 – 20 яшь арасындагы ир бала. Үсмерлектән үткән яшь егетләрне *бүз егет* диләр. Р.Әхмәтьянов "бүзьегет – егермегә җитмәгән сугышчы" дип яза. Татар халык иҗатында мәхәббәт темасына чыгарылган дастан жанры да "Бүз егет" дип аталган.

Егерме белән утыз арасындагы сугышчыны *азамат* дип атаганнар. Аннары алар *күш агасы* һәм *ут агасы* дип йөртелгән. Аннан соң кеше тормышында *карасакал* һәм *аксакал* дәверләре килә.

БҮЛӘК тар. – XIV гасыр урталарыннан мордва жирендә татар морзаларына *бүлеп* бирелгән биләмә. Бүләк территориясенә караган авыл халкы теге яки бу морзага ясак түләп торган һәм мондый түләүләр XVII гасырда, инде мордва рус кулына тошкәннән соң да дәвам иткән, фәкать татар морзаларын рус алпавытлары алмаштырган. Охшаш сүз мари һәм удмурт телләрендә дә кергән, димәк, "бүләкләү" дигән нәрсә бу территорияләрдә дә таралыш алган. Рус документларында мондый биләмәләр "бәляк" дип йөртелә. Ихтимал, рус дәүләтендә гадәткә кергән *"дача"*ларның да мәгънәсе өлешчә шушы "бүләк" терминына туры килә торгандыр.

Татар теле диалектларында "бүләк" сүзенең "вак урман, әрәмәлек" мәгънәсе дә булган ("Татар теленең диалектологик сүзлеге", 1969). "Таллыбүләк", "Бишбүләк" – авыл исемнәре.

БҮРӘК—Бөккән, кайбер сөйләшләрдә – "тәкә". "Бүрәк" сүзе русча "пирожок, пирог" мәгънәсендә, яғыни асылда русның "пирог"ы борынгы болгар телендәге *бүрәк, пүрәк* сүзенә барып тоташа (Р.Әхмәтьянов.) "Бөрек" сүзе төрек телендә дә актив (пирог, пирожок). Ф.С.Баязитова "Томернең өч туе" дигән китабында Әстерхан татарларында туй вакытында пешерелә торган бүрәкнең түбәндәге төрләрен күрсәтә: *ак бүрәк* – ит эчле бөккән, *кабак бүрәк* – кабак эчле бөккән, *казан бүрәк* – казанда майда пешергән бөккән, *касык бүрәк* – пилмән, *куз бүрәк* – эченә чикләвек салып пешерелә торган бөккән. Болардан башка, *шешбүрәк* – "шешпә пешерелгән бүрәк, бүрәк шешлек" тә бар (Р.Әхмәтьянов). *"Чебуреки"* дигән ризык атамасы да рус теленә төркиләрдән (Кырым татарларыннан?) кергән.

ВАКТЕЛГЫЙША *г.* – **1**.Кояш баеп шәфәкъ батканнан соңгы вакыт. **2**.Аулак җыелыш, кичке аш (христианнарда: *Тайная вечеря*).

ВАКЫТЛЫ БЕРКЕТЕЛМЕШЛӘР *тар.* – Русчасы – *временнообязанные.* "Вакытлы беркетелмеш" терминын Мәхмүт Максуд рус шагыйре Некрасовның "Русь илендә кем рәхәт яши" поэмасының татарчага тәрҗемәсендә тәкъдим итә.

ВӘ *г.*— Һәм, янә, да/дә. Кайчагында "белән"/"ила" теркәгече ярдәмендә бирелә. Шунысы кызык, керешеннәр очен нәшер ителгән татарча дини текстларда "вә", "һәм" (бусы фарсы теленнән) теркәгечләре очрамый. Хәлбуки бу текстларда шәрык сүзләре (терминнар) шактый мул кулланыла.

ВӘ ИЛХ. – Һәм башкалар. "Ила ахири" сүзеннән кыскартып *илх.* сүзе ясалган. Мәҗит Гафурида *алех* язылышы очрады.

ВӘКАЛӘТНАМӘ *гф.* – Бу сүз XVI – XVII гасырларда ук татар язма телендә *верительная грамота* мәгънәсендә кулланылган.

ИҖАТ ОФЫКЛАРЫ

Танылган әдәбият галиме А. Әхмәдуллинның драма жанры үзенчәлекләрен һәм бүгенге татар театрын өйрәнүне, бәяләүне максат итеп куйган "Офыклар кинәйгәндә" исемле тәнкыйть мәкаләләре җыентыгын зур кызыксыну белән кулга алдым.

А. Әхмәдуллин дистә еллар дәвамында татар сәхнә әдәбиятын нәтиҗәле өйрәнеп килә. Аның "Ничек сурәтләргә сине, замандаш" (1976), "Сәхнә әдәбияты һәм тормыш" (1980), "Татарская драматургия" (1983), "Фәтхи Бурнаш" (1988), "Дөреслеккә ирешү юлында" (1993) кебек китапларында, "Татар әдәбияты тарихы"ның 3-6 томнарының драматургиягә бәйле бүлекләрендә, шулай ук дистәләгән җыентыкларда, газета-журналлардагы мәкаләләрендә әлеге төрнең мәйданга килгәннән алып бүгенге көнгә кадәрге үсеш-үзгәреш тенденцияләре, традиция-яңалыклар, классик һәм бүгенге көн авторларының сәнгатьчә фикерләүдәге табышлары һ. б. җентекле рәвештә һәм фәнни нигезгә салынып тикшерелә. Галимнең яңа китабы да әлеге эзләнүләрнең дәвамы булып тора.

Хезмәтнең беренче бүлеге "Драматургия һәм театр сәнгате" дип атала. Биредәге мәкаләләр циклында А. Әхмәдуллин заман үзгәрешләрен оста тоемлаучы, нечкә эстетик зәвыкка ия тәнкыйтче булып ачыла. XX гасырның сиксәненче еллары уртасыннан җәмгыятьтә башланып киткән үзгәрешләр дөньяга карашыбызга зур йогынты ясап, әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә дә башкача караргa этәрде. Моңа кадәр татар әдәбиятының, шул исәптән драматургиянең шактый өлеше социалистик реализм кысаларында язылу белән бергә, аларны сәнгати яктан өйрәнү дә еш кына идеологик принциплардан чыгып башкарылды. Ә янарыш чоры килгәч, бик күпләр икеләнеп торган вакытта, тәнкыйтче сәхнә әдәбиятын яңача өйрәнүнең юлларын, төп юнәлеш-нигезләрен билгеләгән мәкалә белән чыга. Шунысы игътибарга лаек, әлеге мәкалә академик М. Хәсәновның алдарак язылган, гомумән татар әдәбиятын яңача өйрәнү проблемаларына багышланган хезмәте белән аваздаш. Таныклан икс әдәбият галимененә татар сүз сәнгате үткәненә һәм бүгенгесенә караган мәсьәләләрдә концептуаль яктан фикердәшләр булуы ачык чагыла. А. Әхмәдуллин драматургия тарихына бәйле тема-жанр өлкәсендәге, сәнгатьчә сурәтләү алымнарындагы казанышларны күрсәтү белән бергә, алдагы тикшеренүләр өчен җитди сораулар да куя. Менә аларның кайберләре: үзәбездәге сәхнә әдәбияты белән чит илләрдә иҗат ителгән пьесаларның *(Г. Исхакый, Х. Хәмидуллин)* әдәби-эстетик бәйләнешен ачу; совет чорында трагедия жанрының уңышларга ирешмәү һәм сатирик комедиянең тәссезләнү сәбәпләре; психологик драманың XX йөз башы югарылыгыннан әллә ни күтәрелә алмавы; аерым тема-проблемаларның артык күпертелүе; Шәрык традицияләре дәвамчанлыгы; шәхес концепциясен аңлауда һәм сәнгати чагылдыруда беръяклылык һ.б.

Шунысы шатландыра, тәнкыйтче сорау-мәсьәләләрне куеп кына калмый *(анысы да бик мөһим)*, үзенең күпсанлы язмаларында аларга җавап эзли, аерым мәсьәләләр буенча шактый җитди

Азат Әхмәдуллин. Офыклар кинәйгәндә. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2002 ел.

тикшеренүләр дә алып бара. XX гасырның туксанынчы еллары татар драматургиясенә күзәтү төсендә язылган мәкаләсендә ул әлеге чорның үсеш тенденцияләрен билгели, табышларны һәм кимчелекләрне аерып күрсәтә. Авторга аналитик фикерләү, нәтиҗәләр ясау хас. Ул кыска, әмма мәгънәви тирән штрихлар белән драматургларның соңгы еллар ижатында чагылган сәнгати үзенчәлекләрен ача. Бу урында үз стиле күренеп торган талантлы драматург Р. Хәмид турындагы өзекне китерми мөмкин түгел: "Р. Хәмиднең саф драма вә трагедияләре дә гаять үзенчәлекле, аның кырыс вә гажәеп тормышчан геройларга, символикага, метафораларга ия пьесалары сәхнәләштерү өчен шактый ук авыр. Автор тади-гадәти чынбарлыкта тетрәндергеч ситуацияләр таба белә".

Тәнкыйтьченең принципиаль күзәтүләреннең тагын берсенә тукталып үтәсем килә. Безнең сәхнә әдәбиятында комедия жанры аерым урын алып тора. Драматургия үсешенең аерым чорларында ул әйдәүче жанр буларак алга чыга. Шул ук вакытта, аерым хезмәтләрдә комедиянең театрлар репертуарында күбәеп китүе, аларның бер өлешенең көры тамашага нигезләнүе, автор һәм режиссерларның зәвыксыз тамашачыга йөз тотуы турында борчулы фикерләр дә яңгырый. А. Әхмәдуллин хәзерге драматургиядә әлеге жанрның алга чыгуын билгеләп кенә калмый, аның түбәндәге сәбәпләрен дә күрсәтә: 1) күпчелек комедияләрнең ижтимагый эчтәлекле булуы; 2) тамашачыны рухи хәрлеккә чыгару, күңелен күтәрү ягыннан бер мәгънәдә дә комедия белән ярыша алмавы; 3) көлүнең төрле төсмерләреннән файдаланып, бүгенге идеалсыз тормышны күпмедер бизәве; 4) заман үзенчәлекләрен чагылдыруы белән халыкның эстетик зәвыгына туры килү. Бу инде авторның житди эзләнү-уйланулары, комедия жанрының урынын билгеләүдә табылган нәтиҗәләре дигән сүз.

Классик драматургларыбыздан Ф. Халиди, Г. Исхакый, Һ. Такташ, Т. Гыйззәт ижатларына бирелгән бәя, аларның һәрберсенең бай мирасыбыздагы урынын билгеләү омтылышы заманчалыгы, фикер ачыклыгы һәм төгәллеге белән аерылып тора. Ә инде авторның Г. Исхакый драматургиясенә бәйле эзләнүләре, аның ижат яңалыкын билгеләве, гомумән, яңа сүз булып яңгырый. Әйе, татар халкының бөек улы Г. Исхакый XX гасыр татар әдәбиятына һәм ижтимагый-фәлсәфи фикер үсешенә гаять зур өлеш керткән шәхес булараК туксанынчы еллар башыннан өйрәнелеп килә. Аның тормыш һәм ижат юлы турында байтак хезмәтләр дөньяк күрсә дә, бу адипнең бай мирасын, әсәрләренең идея-эстетик үзенчәлеген әле безгә өйрәнәсе дә өйрәнәсе. Әдип ижатын тикшерүнең төп юнәлеш-ориентирлары галимә Р. Ганиева тарафыннан билгеләнгән булса *(Мирас.—1998.—№5)*, А. Әхмәдуллин XX гасыр башы Яңарышының нигез ташларын салучыларның берсе булган Г. Исхакыйның сәхнә әдәбияты өлкәсендәге эшчәнлеген, татар драматургия тарихы белән тыгыз бәйләнешен тикшерә. "Татар халкы яшәшенең төрле якларын гомумкешелек кыйммәтләре ноктасыннан" бәяләгән олпат зат пьесаларының яңалыгын автор түбәндәгеләрдә күрә: милли жанны образ-характерлар ижат итү; чорның гаять катлаулы тема-проблемаларына нигезләнгән яңа эчтәлек алып килү; кеше күңеленең тирән катламларын ачып, аның ныклыгына һәм, киң мәгънәдә, милләтебез рухына мәдхия юк, аның "авыртканын нокталарын" билгеләү аша киләчәккә үсеш юлын, юнәлешен күрсәтү; ислам фәлсәфәсе белән бергә Гарәбнең эстетик фикеренә дә иркен таяну; сурәтләүнең алым-чараларын тагы да үстерү, бастау аша сәнгатьчә дәрәслеккә ирешү һ. б.

Г. Исхакый ижаты турында бүген дә төрле фикерләр очрый. Берәүләр, Октябрь инкыйлабыннан соң татар әдәбияты Исхакый ижаты йогынтысыннан башка үсте дисә, икенчеләр, гомумән, милләттәпәрвар шәхес әсәрләре үз вакыты өчен генә әһәмиятле булып, бүген инде кыйммәтләрен югалтты дип саный. Мондый фикерләр, кызганыч ки, А. Гыйләҗев белән А. Яхин кебек танылган әдип һәм галим тарафыннан да әйтелде. Шуларга бәйле рәвештә Г. Исхакыйның татар драматургиясенә алып килгән яңалыклары һәм ана йогынтысы турында А. Әхмәдуллин фикерләренең кыйммәте тагы да үсә. Җыентыктагы Г. Исхакый турындагы язмалар белән танышкач, күпләрдә әдип пьесаларына тагын бер мәртәбә мөрәҗәгать итү теләге туар, мөгаен.

Тәнкыйтьче өчен объективлык хас, ул фикерләрен теоретик яссылыкта аңлатып кына калмый, аларны тере яки бу авторның ижатын экентекле тикшерү аша дәлилли дә. Ф. Бурнаш, Һ. Такташ, Т. Гыйззәт ижатлары турындагы язмалар әнә шундый. Ул әлеге авторларның әсәрләрен мактау яисә каралту юлыннан китми, ә алар ижатында дөреслек һәм рәсми идеология тартышын ачык-

ларга тыршша. Китап авторы моңа кадәр игътибардан читтә калган фактларны таба, аларны әдипнең сәнгатьчә фикерләү үзенчәлеге аша бәяли, үз чоры һәм бүгенгәчә өчен яңалыгын ача. А. Әхмәдуллин татар драматургиясен тар кысаларда гына тикшерми, үзенең мәкалә-язмаларында аталы рус әдибе Ф. Достоевскийның "Шайтаннар"ына да, Европаның фәлсәфи-эстетик фикеренә көчле иогынты ясаган Ницше тәгълиматына да шактый иркен мөрәҗәгать итә. Бу исә аның эзләнүләр колачын бермә-бер киңәйтә.

Чорыбызның күренекле драматургы Т. Миннуллин ижатына битараф кеше юктыр, мөгаен. Гаять актив, нәтиҗәле эшләүче әдипнең спектакль премьераларына бәйләмәләр дә вакытында чыгып килә. Шулай да Т. Миннуллин ижатын эзлекле өйрәнеп килгән, һәр әсәренә карата дип әйтерлек фикер-мөнәсәбәтен белдергән, ижат серләрен укучытамашачыга таныткан тәнкыйтьче— А. Әхмәдуллин. "Туфан Миңнуллин театры" төшенчәсен нигезләүче, аның төп хасиятләрен ачучы кеше үл. Әлеге җыентыкта драматургның соңгы еллар ижатына әтрафле күзәтү ясала, бәя бирелә, форма һәм эчтәлек елкәсендәге табышлары билгеләнә. "Әниләр һәм бәбиләр", "Хушыгыз", "Илгизәр плюс Вера", "Шәжәрә", "Сәяркә" кебек пьесаларга һәм алар нигезендә куелган спектакльләргә бәяләмәләре яшь тәнкыйтьчеләр, театр белгечләре өчен менә дигән өйрәнү мәктәбе була ала. Әйнде З. Хәким өчтомлыгы турындагы мәкаләсе фикер тирәнлеге белән аерылып тора. Тәнкыйтьче кабатланмас үзенчәлекле прозаик һәм драматургны ача, аның ижат йөзен, стилен билгели.

А. Әхмәдуллин үз язмаларын төрле рәвешләрдә тәкъдим итә. Әйтик, "Шәжәрә"гә бәяләмә диалог формасында булса, Әлмәт театры спектакльләрен ул репертуар сайланышы, режиссер табышлары һәм артистлар уены ягыннан өчкә бүлеп тикшерә. Автор кирәк урында шактый усал тәнкыйтьли, уңышсызлыкның сәбәпләрен ача, киңәш-фикерләре белән бик телән урталаша. К. Тинчуринның "Соңгы салам"е буенча куелган спектакль турындагы мәкаләсендә үл пьесаның фикер ачыклыгына, герой үлеме сәбәпләрен билгеләүгә зыян китерә торган кыскартуларның акланмавын әйтә. Ә менә З. Хәкимнең "Күрәзәче" спектаклен моңсу комедия дип тәкъдим ителсә дә, А. Әхмәдуллин аның трагикомедия жанрына тартым бүлуын нигезли.

Тарихы мен елдан артып киткән әдәбиятыбызның үсеш-үзгәреш этапларын, ана йогынты ясаган фәлсәфи-эстетик карашларны, халык тормышы белән тыгыз бәйләнешен, традиция һәм яңалыкларның үзара мөнәсәбәтен, әдәби әсәрне анализлау критерийларын бары тик ныклы теоретик һәм методологик принципларга таянып кына объектив ачыклап була. А. Әхмәдуллин хезмәтенең "Әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйть" дип аталган икенче бүлегендә әлеге катлаулы мәсьәләләргә бәйле теоретик сораулар тикшерелә һәм аерым әсәрләрдәге табыш-югалтулар ачыклана.

Татар әдәбият белеме совет чорында марксистик-ленинчыл методологиягә нигезләнде. Аның төп принциплары белән килешмәгән хәлдә, алмашка нәрсә тәкъдим итәргә? Ф. Мусин, Ф. Хатипов, Т. Галиуллин кебек галимнәрнең бу мәсьәләгә мөнәсәбәтләре газета-журналларда басылып чыкты. А. Әхмәдуллин әдәбият тарихын, шул исәптән совет чорын бәяләгәндә, бер чиктән икенчесенә ташлану тарафдары түгел. Аның фикеренчә, Октябрь инкыйлабына кадәрге әдәбиятыбызның ислам фәлсәфәсе нокталсыннан карап кына аңлап була. Гомумән, әдәбият үсешенең төп тенденцияләрен билгеләгәндә, аерым әдипләр ижатына бая биргәндә, милли мәнфәгать чагылышы һәм гомумкешелек кыйммәтләре нигез булырга тиеш дип саныйм үл.

Бу урында тагын бер мәсьәләгә тукталмый мөмкин түгел. Автор Ф. Мусинның кайбер фикерләре белән бәхәскә керә. Аерым алганда, аның Г. Ибраһимов 1917 елга кадәр гомуммилли позициядә торып, совет чорында гына "тар сыйныфый кысалар"га эләгүе турындагы карашын кире кага. "Мәсьәләне болай итеп кую безнең язучылар, әйтерсен дә, бары совет жәмгыять шартларында гына сыйныфый көрәш тәгълиматына килделәр, дигән тарлыкка этәрә", ди. Соңгы фикер белән килешеп бетмәс идем. Мәсьәлә, күрәсең, "сыйныфый көрәш" төшенчәсен ничек аңлау һәм аңлатуга кайтып кала. Дөрес, Октябрьгә кадәр Г. Ибраһимовта гына түгел, Г. Исхакый, Г. Тукай, Ф. Әмирхан һ. б. күп кенә әдипләрнең әсәрләрендә дә социаль тигезсезлек мәсьәләсе кискен итеп күтәрелә. Әмма аларның берсе дә бай һәм ярлы, капиталист һәм пролетариат каршылыгын бер-берсенең бугазына ябышу, кан түгү, юк итү рәвешендә сурәтләми. Ә бит төрле сыйныфларның үзара килешә алмавы, алай гына да түгел, дошманлыкның һаман арта баруы һәм

бер-берсен юк итү белән генә тәмамланыы бары тик совет чорында тына төп идея буларак яши башлады.

Икенче урында Ф. Мусинның "совет чорындагы әдәбиятыбызны, беренче чиратта, зур югалтулар дәвере дип каарга тиешбез" дип бәяләве белән А. Әхмәдуллин принципиаль төстә килешми. Мондый караш әдәбият үсешендәге тулы бер дәвереле, дисталәгән әдип иҗатын юкка чыгаруга китерә, ди ул. Алай үк түгел инде. Мәсәлән, А. Әхмәдуллин үзе китергән Г. Исхакый иҗатына мәрәҗәгать итик. Бәхәссез, XX гасыр башы татар әдәбиятының үсеш юнәлешен билгеләүчеләрнең берсе булган әлеге олы әдипнең мирасы совет чорында атнын иҗат иткән К. Тинчурин, Һ. Такташ, Гали Рәхим, Н. Исәнбәт, Ә. Еники кебек дистәләгән язучыга таныш булган, алар аның шифалы йогынтысын тойганнар, билгеле бер дәрәҗәдә традицияләрен үстергәннәр. Ләкин шул ук вакытта, XX гасыр уртасында иҗат мәйданына килгән әдипләр Г. Исхакый әсәрләрен белми үстеләр бит. Әгәр дә аның "Ике йөз елдан соң инкыйраз", "Зөләйха", "Көз" һ. б. шедеврлары халык арасында таралган булса, милли үзаңыбыз шулкадәр үтбәнәер идеме икән? Мондый мисалларны күплән китерә алабыз. Социалистик реализм кысаларында булмасак, Г. Ибраһимовның "Адәмнәр"еннән соң — натурализм, Г. Ибраһимовның "Яшь йөрәкләре"еннән, Ф. Бурнаш, Һ. Такташ, Г. Рәхим кебек әдипләрнең уңышлы әсәрләреннән соң романтизм юнәлешләре киң мәйдан алып үсеп китмәс идеме? "Югалтулар дәвере" дигәндә Ф. Мусин әнә шуларны күздә тота бит.

Г. Исхакыйның "Көз", Ф. Әмирханның "Шәфигулла агай", Р. Мөхәммәдиевнең "Ак кыялар турында хыял" әсәрләрен анализлаган мәкаләләр һәм Н. Исәнбәт, Н. Фәттах, Г. Ахунов, Т. Галиуллиннарның ижат портретына штрихлар буларак бирелгән язмалар матур тел белән язылып, әдәби әсәр кебек жинел укыла. Автор кыска, жыйнак бәяләмәләрендә житди гомумиләштерүләр ясый һәм һәр әдипнең үзенә генә хас табыш-үзенчәлекләрен билгели.

А. Әхмәдуллинның күпкырлы эшчәнлегенә сокланмый мөмкин түгел. Университетта лекцияләр уку һәм әдәбият белеме, әдәби тәнкыйть, драматургия тарихы, театр сәнгате буенча дистәгә якын китаплар чыгарудан тыш, ул дистә елларга дәвамында мәктәпләр өчен программалар, дәреслек һәм хрестоматияләр эшләүдә актив катнаша, дәресләре, бу эшне житәкләп бара. Без сүз алып барган хезмәтнең "Матур әдәбият һәм мәктәп" дип аталган өченче бүлегендә дә программа-дәреслекләр төзүнең нәзарый-методологик принциплары, әдәбиятны укыту методикасы, аның үсеш-үзгәреш перспективалары үзәктә тора. Әйе, мәктәп елларында укучының шәхесе формалаша, дөньяга карашы билгеләнә һәм әнә шул процесста ин үтемле чараларның берсе булган әдәбиятның әүтәлеге, аны укыту юллары гаять мөһим урын алып тора. Фикер төрлелеген инкарь итмәстән, укыту эшендә билгеле бер принципларга, методологик нигезләмәләргә таяныла. Аларның аеруча мөһимнәрен А. Әхмәдуллин аерып та чыгара: динисуфыйчыл һәм романтик фикерләү өстенлек иткән Урта гасыр әдәбиятын нинди нигездә өйрәнергә? Әдәбияттагы Шәрык һәм Гареб йогынтысының, үзара бәйләнешенең нигезе кайда, нәрсәдә? Әдәбият программаларында Г. Исхакыйның урынын ничек билгеләргә? Хәзергә ижат методларын, әдәбияттагы шәхес концепциясен ничек аңлатырга? Әнә шундый сораулар буенча үз карашларыбызны үртаклашып, автор мәктәп дәреслекләренең нигезен тәшкил иткән фикерне ассызыклап күрсәтә: "Кешегә кешелекле, миһербанлы мөнәсәбәт, кешене югары көч вәкиле яки табигать баласы буларак карау һәм сурәтләү беренче урында торырга тиеш".

Мәктәптә әдәбият укытуны камилләштерү һаман житди мәсьәләләрнең берсе булып кала бирә. Профессор А. Әхмәдуллин житәкчелегендә һәм доцент А. Яхин тарафыннан төзелгән программа-дәреслекләрдә, алар буенча укытуга бәйле фикер-карашлар татар вакытлы матбугатында инде байтак булды. Авторлар үзләре дә шактый кискен мәкаләләр белән чыктылар. Әлеге хезмәттә дә А. Әхмәдуллинның бу мәсьәләгә карган икс язмасы урын алган. Автор оппоненты А. Яхин төзегән программа-дәреслекләргә, үл тәкъдим иткән укыту ысулларына тирән анализ ясый. Алардагы яңалык һәм табышларны жентекләп барлау белән бергә, аерым мәсьәләләрдә бәхәскә керә, үз карашын белдерә, урыны белән тәнкыйть тә итә.

"Офыклар киңәйгәндә" жыентыгы А. Әхмәдуллинның күпкырлы ижат эшчәнлегендә билгеле бер этапны тәмамлау, нәтиҗәләр ясау булып тора. Аның фикер һәм карашларын белгечләрне генә түгел, ә киң катлам укучыларны да битараф калдырмас дип уйлыйм.

Әлфәт ЗАКИРЖАНОВ

КЕШЕ, ИДЕЯ ҺӘМ ӘДӘБИЯТ

Соңгы елларда әдәби тәнкыйтьнең сүлпәнләнүе күзәтелә дип нәгъләләр орабыз. Бәлки, аның житди сәбәпләре бардыр, шул сәбәпләрнең бәлки ин өскә калкып торганы—заманга ярашлы нык-лы нәзари-теоретик нигезнең булмавыдыр? Иске багаж белән ерак китеп булмый бит, тәнкыйтьчеләрнең зиһене чуалды, тәнкыйть таякка калды. Уңай үзгәрешләргә зар-интизар булган "торгынлык" хөкемендә без. Әдәби барышны югары кимәлдә күзәтә алмаган абруйлы тәнкыйтьчеләре, объектив тәнкыйди фикере булмаган әдәбиятның киләчәк үсеше шик астында.

Әгәр дә бу яктан килеп карасак, хәл бөтенләй үк өметсез дә түгел, тәнкыйтьнең озаклаусыз жанланып китүенә жирлек туып килә кебек. Шуның бер мисалы—әдәбиятны яңача өйрәнүдә матур башлангычларның барлыкка килүе. Филология фәннәре докторы, Казан дәүләт университеты профессоры Дания Заһидуллинаның соңгы елларда эзләнүләре, әдәби-нәзари фикер үсеше, татар әдәбиятындагы төрлелек һәм яңа әдәби-эстетик концепцияләрне жентекләп өйрәнүләре шундый фикерга этәрә. Берничә ел элек галимәнең "Әдәбият кануннары һәм заман" дигән саллы хезмәте дә дөнья күреп, һәм галимнәр, һәм укытучылар, әдәбиятны өйрәнүчеләр тарафыннан уңай бәя алган иде инде. 2003 елда Татарстан китап нәшриятында басылган "Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы" дигән китапта инде алдагы хезмәтләр тагын да конкретлаштырып, XX йөз башы татар прозасындагы яңа күренешләрнең фәлсәфи нигезләре барлана, әдәби барышның үзенчәлекләре өйрәнелә.

Модернизм сүзе үзе үк заманча дигәнне аңлата. Бездә традицион дип йөртелә торган әдәбият, яғъни тормышны бар булганча, вакыйга-күренешләрне персонажларның эш-гамәлләре һәм аратирә әсәргә алганын киткән диалог һәм монологлар ярдәмендә тасвир кылу кинаралса да, минемчә, әдәбиятның төбендә, бишек башында ул башкачарак шәкелдә—Күк, Тәнре, Жир, Су һәм башка галәми Ияләр белән сөйләшү, серләшү, аларның жир кешеләре кылган гамәлләргә мөнәсәбәтләрен белдертү формасының чагылдырышы буларак яралгандыр дип айтәсе килә. Соңрак фәлсәфи нигез арткарак күчеп, реальлеккә омтылыш, бәндәчелек, жир акылы, яшәеш мотивларын өстенлек алгандыр кебек. "Татар модернизм әдәбияты дөньяны бербөтен төре организм, теләк-омтылышлар үены итеп карый. Кеше гомере кояш чыгу һәм бату хәрәкәтенә бер мизгеле, аралыгы кебек аңлатыла. Өмет һәм аның өзелүе—әлеге мизгелнең баскычлары, өмет үзе исә шәхси, милли тормышны һәм гомумән Яшәешне хәрәкәткә китерү механизмы, этәргеч көч буларак күрсәтелә"—дип яза галимә.

Монда бер әһәмиятле момент бар, ул да булса, модернизмны миллиятләргә тәэсир итү дәрәҗәсендәге көчләрнең берсе итеп тану. Соңгы вакытта һәр төрле яңалыкны, үзебезчәрәк әйтсәк, "жәдитизм"не кире кагу, бу күренешләрне дини яки милли позицияләрдән чыгып, рухият үсешендә (бу очракта уң мина аңның кадимгеген, аның катып калган шәкелдә сакланышын тәэмин итү кебегрәк аңлашыла) кире фактор буларак хөкем итү тенденциясе дә терелеп килүен искә алганда, Дания Заһидуллинаның әлеге хезмәте нәкъ вакытында әйтелән сүз дип кабул ителергә хаклы. Модерн стиле, галимә өйрәнгән категорияләр, фәлсәфи агымнар нисбәтеннән чыгып фикер

Дания Заһидуллина. Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2003 ел.

йөртсәк, борынгы чорда ук яралса да, хезмәттә дөрес искәртелгәнчә, XX йөз башында калыплашу, яңалыкка китерүче тарихи сәбәпләр, алшартлар да читләтеп үтелми. Болар барысы да татарның милләт булып оешуына бәйле рәвештә киралана, фәлсәфәнең "Европа форматын" тудырган Кант, Гегель, Ницше, Шопенгауэр һәм башка классиклар өйрәтүләре белән чагыштырыла, татарның модернистик юнәлешне хуплаган яки өнәп бетермәгән язучы, әдипләрнең фикерләрен барлый, фикерне ныгыту өчен—иллюстрация, ижат үрнәкләрен мул китерә. Модернга үз өлешләрен керткән әдипләр байтак икән ласа! Мәҗит Гафури, Нәҗип Думави, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Гали Рәхим кебек татар әдәбиятының корифейлары яңашәсендә әдәби эшчәнлекләре аз яки бөтенләй өйрәнелмәгән Шәһит Әхмәдиев, Гали Рәфикый, Борһан Мансур, Абруй Сәйфи (Нәкыя), Хөсни Кәрим, Нәҗип Гасрый, Әхмәтгәрәй Хәсәни, Нәҗип Хәлфин, М. Хәнәфи һәм башка авторларның карашларын яки ижат үрнәкләре, үй-фикерләре, биографик материаллар белән танышу бик тә кызыклы булды.

Фикер дигәннән, хезмәттә фикер агымының күәтле булуына хәйран калсың. Соңгы чорда төпле, акыллы били торган хезмәтләрнең аз язылуына эч тә пошып куя иде. Китап шушы бушлыкны тутыруда да әһәмиятле урын биләр диясе килә—анда төп фикерләр ассызыклап, аңга үтеп керерлек итеп бирелгәнең барыла. Бу үз чиратында авторның гыйлемле, язерлекле һәм үз-үзеңә нык ышанган булуын күрсәтә. Шулай ук әдәби барышка яңача йогынты ясаган "Ан" журналы эшчәнлеге белән танышу шәхсән үзем өчен кызыклы булды. "Модернчылар"ның нигезләе шушы журнал тирәсенә туплануы, Европа фәлсәфәсе тибындагы яңа өйрәтүләре, Яшәеш хакындагы милли концепция табарга омтылышлары, "сәнгатьлелек өчен көрәш"тә тоткан мәсләге аның редакторы Әхмәтгәрәй Хәсәни исеме белән тыгыз бәйләнгән. Димәк, әдәби барышка йогынты ясау дәрәҗәсе теге яки бу басманың кем тарафыннан житәкләнүенә дә бәйле икән.

Шушы урында бүгенге көннәргә кайтасы килә. Дания Заһидуллина—эзләнүчән шәхес. Галим буларак гыйльми кысаларга, дәвер чикләренә кереп бикләнүне өнәми. Бүгенге әдәби барышны да жентекләп өйрәнүче буларак, хәзерге авторларның әсәрләрен бәяләгәндә дә модерн сыйфатларын жентекләп күзәтә килә. Ә андыйлар әдәбиятыбызда, шөкер, барлар. Нәбирә Гыйматдинова, Рафаэль Сибат, Флүс Латыйфи, Фоат Садриев, Зиннур Хөсниәр, Галимҗан Гыйльман, Зөлфәт Хәким, Марат Кәбиров, Рәшит Бәшәр, Заһидә Мәхмүди, Ркаил Зәйдулла әсәрләрен инде иске калыпка тына салып һич бәяләп булмаячак. Укучыга житкәрәсе килгән идея-уй кадәресен ни рәвешле тасвир кылырга? Гомумән, стиль мәсьәләсе автор өчен гади нәрсә түгел. Тормышны хиссият аша суәртләп, укучының күзаллавы—анасты фикерена таяныргамы, натурализмга авышыргамы, әллә романтизм белән өреталган реалистик баскычка күтәрелергәме, яки әле һаман кайбер авторларның жилкендергән ясалма хыялый стиль—соцреализмга ябышып ятаргамы? Әсәр матурлыкны күрсәтеп, шуның аша яшәүнең идиллиясен ачып салырга тиешме, тәрбия-әхлак ягын калку чагылдырып, һәр чор ашкынган "яна кеше" тәрбияләү белән мәшгуль булырга тиешме, әллә хәямчәлән әйтсәк, "мәй эч тә, кызлар коч, ике көнлек дөньяны үкенечкә калдырма" фәлсәфәсен сендерергә омтылсынмы, әллә инде укучыны фәкать фикерләргә өйрәтүне максат итеп куйсынмы?.. Шул ук вакытта тормыш бер үйласаң шундый да катлаулы, икенче караганда пүчтәк нәмәстә кебек тоела, аны аерым әсәрдә бөтен тулылыгы белән күрсәтерлек универсаль алым, яки калыплашкан идея-кыса да була алмаганын яхшы чамалыйбыз. Китапны укыганда егерменче йөз башыннан үзебез яшәгән заманга кабат-кабат кайтасың, модернистик алымның үзенчәлекләрен хәзерге чор призмасы аша карарга омтылыш ясау да табигый, авторның үз алдына куйган бер максаты да балки шулдыр—үткәнне бүтенгегә ялгау, бүтенгене ачыграк тоемлау өчен үткәнгә мөрәҗәгать итү, шул рәвешле әдәби барышның дәвамлылыгын: үткән—бүтенге—киләчәк формулаларын әдәбият, димәк, яшәеш өчен әһәмияттен искәртү.

Һәр яңалык кешедә кызыксыну уята, "модерн" сүзе дә уйны кузгата. Шул сәбәпледер, бераз чигенеш ясап аласы килә". Түбән Кама каласында гажәп бер

шәхес яши. Әхсән Фәтхетдинов ул. Бөек сәнгатқәр, Татарстанның халык рәссамы. Әдәбиятны искиткеч аңлаучы, тирәнәән тоючы сирәк затларның берсе. "Мәйдан" журналында аның бөек шагыйребез Равил Фәйзуллинга атап язылган хатлары басыла. Ара-тирә, эче пошкан чакларда тып итеп редакциягә дә килеп керә ул. Мең яшәр Локман Хәким инде менә! Ак чәчләре ак болыт кебек, аз гына җил иссә кабарып, таралып китәр сыман, якты йөзендә ниндидер илаһи серлелек. Кешеләр каршына нәкъ киреәкле чакта пәйда булып, иң кирәкле сүз әйтеп өлгергән әкияти Локман Хәкимне нәкъ менә шушы гамь вә үй иясенә охшатам. Ниндидер фикерләр җилкетә бу тынгысыз жанны, шулар белән уртаклашасы килә, күрәсең, Түбән Камада ишүйдашларын таба алмаган да, яшьләр янына, "Мәйдан"га ашыккан. Монда яшьләр, монда аны тыңлаучылар (!) бар. Ана шул гына кирәк тә. Берсендә үл хәзерге прозадагы катып калганлыкны тәнкыйть итеп ташлады. "Татар прозасы болай барыргә тиеш түгел!— диде Әхсән ага үзенә хас кайнарлык белән. — Нәрсә язалар инде хәзер? Юк белән вакыт үткәрә язучылар. Икс кешене кара-каршы бастыралар да, и сөйләштерәләр, и азапльләр бичараларны. Имеш диалог коралар. Кемгә кирәк аларның арзан сафсатасы. Күкләр белән сөйләшергә өйрәнсен кеше, Жир белән, Кояш, Ай белән! Шул чагында гына әсәр акылга ни дә булса бирә алачак. Андый язучы бар иде— Рафаэль Сибат. Югалттык без аны, үкенәм, янына барып, үзе белән сөйләшеп, гәпләшеп кала алмаганга жаным әрни... Рухыма якын кеше жир читендә булса да, эзләп табасым, сөйләшәсем килә аның белән. Андый олпат зат тагын бар иде—Бәхтияр Табиев. Сез аның Кояшка карап ятучы картны сурәтләгән картинасын белә дә торгансыздыр. Менә кайда ачыла үл талант дигән хикмәт!"— дип, безгә сабак биреп ала Әхсән ага. Бу әсәрне күргәнем бар. Тетрәндерә. Дала. Чиксезлек үзәгендә дөнья белән янарак кына хуллашкан кеше жәсәде.

Кеше гомере бус дөнья куган, башын күтәреп Күккә караш ташларга вакыт таба алмаган. Һәм менә финал—соңгы сулышын алгач, иркенләп кояшка бага. Барлык кысаларны ватып, хәрлек, чиксезлекне татый-тоя алган кеше Рухы бу очракта хәтта Үлемгә рәхмәт әйтәдер шикелле. Кояштан исә мәңгелек йокыга талган (бәлки, жисми күчеш кенә кичергән?..) Кешегә табан ниндидер серле моң-симфония агыла...

Дәрдмәнд иске төшә: "Тегәп моңлы күзем күкнен йөзенә, Хикәя сөйләдем айның үзенә." Ниндирәк субстанциядә Айга, Кояшка хикәят сөйләргә талпыныш ясый адәм баласы?.. Менә Рафаэль Сибатның үй очышы: "Нигә Ходай безгә биш гомер һәм биш жан бирмәгән икән? Бәлки безнең өчен бер жан да бик зур нәрсәдер. Ул бит тән-төрмәне тарсынып яши бугай. Ул үзен читлектәге кош итеп сизәдер. Йөрәк туктауга, жан шул оясыннан очып чыгып Күккә ашмас иде..." Инде Әхсән ага белән "Хатлары"ндагы бер нәсәрдәге фикер чигешенә игътибар итик: "Гармун моңы турында еш уйланыла, үз-үзеңә сөйләнеп тә йөрим, ләкин һәрчак башкача, төрлечә чыга. Кайсы кылларның чиртелүенә карыйдыр инде үл. Кайчак төнлә урамда татарча гармун уйнап үтәләр, тыңлап, уйнаванның туктамаса гына ярар иде дип ятасын, озаграк уйнасын диеп тәрәзәгә торып карыйсын, тавышы югалганчы озатып каласын, күкләргә төбәләсең, ә анда һаман Күк яна, бу юлы гармун моңына күшылып яна, өзелеп-өзелеп, телгәләнеп яна—гармун моны диярсең. Күкләр яныы, гармун моны бергә тоташа да, йокылар бүленә, уянып китәсең. Бүленсең, бүленсең төнге йокыларын гармун тавышларыннан, моңнарыннан, кабат-кабат бүленсең. Күнел каршы килми. Бары тик башка тавышлардан гына бүленмәсен, күнелгә ятмаганнардан, фажигалеләрдән. Яңгыра, яңгыра, гармун моңы, уят кешеләрне, уйлат, кеше ит! Синең көчең житә аңарга." Бу юлларга күпме сылзану, күпме мәхәббәт, күпме мәгънә, күпме фәлсәфә, күпме хис сыйган! Кайбер язучыларыбызның "яна әдәбият тудырам" дип көчәнүләрен, лыгырдык тасвирларын, "мин"нәви шапырынуларын күздән кичерәсең дә, иректсездән ирентә әрнешле елмаю куна... Ходай кемгә ниндирәк талант бирәсен белә шул үл. Рафаэль Сибат искәртүе: "Сәләт Күктән бирелә... Аны исраф итмә!"

Инде Дания Заһидуллинаның яна китабына кайтыйк. Эмма укучы сизентәндер, мин китаптан ярты адым да читкә китмәдем сыман. "Татар прозасында символлар", "Әдәбиятта сылзану (экзис-

тенциализм) фәлсәфәсе", "Мәхәббәт фәлсәфәсе" бүлекләре аеруча жентекләп эшләгәннәр шикелле тоела. Аерым авторларның үзләре яшәгән дәвер мөмкинлегенә биргәнчә, кеше жанын, кеше рухын аңларга һәм аңлатырга омтылулары, шул юлда сынволлар белән эш итү үзенчәлекләре әтрафлы яктыртыла. Фатих Әмирханның "Ай өстендә Зөһрә кыз" хикәясендәге төп мотивка ингътибар итик. Галимә әсәргә анализ ясагач мондый фикергә килә: "Бер милләтнең мөстәкыйбәлеген жуюы Яшәешнең гармониясен боза, кешелеккә кайгы-моңсулык булып әйләнеп кайта." Безнең күзлектән караганда бик аңлаешлы булса да, Фатих Әмирханча итеп.

Сылтану фәлсәфәсе дигәндә, бигрәк тә тормышның мәгънәсе хакында уйланулар, әрнүләр гомер бакый кешене калдырмагандыр. Гали Рәхим "Жәйге нәсер" әсәрендә болай өзгәләнә: "Тормыш, син ник бу кадәр әшәке дә, ник синдә мин теләгән матурлык юк? Тормыш, ник син буш?" М. Хәнәфи "Милләтем" әсәрендә болай сыктый: "Сине жәһәләт йокысына китергән агулы кан минем дә тәнемне әрнетән, тамырларымнан ага!... Синең уй вә кыялларыны елаткан чылбырларның эзләре минем аяк вә кулларымда кызарып янып торалар. Ачы хәсрәтләреп, төнсез кайгыларын мине тәрбия кылдылар, йөрәгемне көйдереп, бетмәс хәсрәт утлары яктылар. Ничек каныма сенгән кайгыларымны сөям, шулай ук алар хәрмәтенә сине дә сөям—аяксыз-кулсыз, өметсез милләтем!"

Мондый төшенкелек мотивларына карата китап авторы мондый аңлатма бирә: "Яшәешнең асылына сызлану салынган, сызланучы кеше генә шушы Яшәешне чагылдыру, аңлау һәм аңлату, хәтта үзгәртү сәләтенә ия. Хакыйкатькә төшенмичә торып, күләчәккә юлны билгеләү мөмкин түгел." Сызлану һәркемгә хас. Әдәби стиль буларак сызлану мотивы кергән әсәрләрдә буялар артык куе салына, авторлар шул рәвешле укучыны сискәндерергә, уйланырга мәжбүр итмәкче, яшәешкә битараф булмаска өндиләр. Билгеле, шушы ук фикерләрә, фатализмнан качып, башка әдәби чаралар ярдәмендә дә ирешеп булыр иде, андый әсәрләр кирәкме, юкмы дигән сорау да куярга мөмкин. Әмма Дания Заһидуллина инде бу денъядан кичкән авторларның әсәрләреп күренеш буларак өйрәнә, һич кенә дә безнең әдәбиятка төшенкелек мотивларының тулып яткан яслама әдәби чаралар агылып керсен дими. Автор хезмәтнең беренче бүлегендә үк Гаяз Исхакыйның сүзләрен китереп, проблемага үз мөнәсәбәтен өлешчә белгертә дә сыман: "Әдәбиятның бөтен кагылдәләре аша сикереп әдәбият баетуны, тормышка аз гына да муафыйк булмаган хыяллар тасвир кылу" "әдәби жинаять" дигән каршта торган бөек әдип.

Мондый әсәрләр һич кенә дә чордашларымның эстетик эзләнүләренә тулы жавап бирә алмасалар да, Яшәү—Үлем категориясен бер генә талант яисе дә читләп үтми, үз мөнәсәбәтен белдерергә тырыша. Дәвер таләбе белән шулдыр, кулына каләм алган затлы шәхесләр кешедә тормышка өмет уятырга омтылалар. Әхсән Фәтхетдинов бу хакта болай яза: "Яшәү—авырлык та, кайгы да, шатлык та. Үлү—кайгы гына. Ә үлгәнһәп соң яшәү—киләчәк тарих, аның күбесе ачык түгел, серле дә ул. Шатланырга кирәк жир өстендә жәйне, кышны, язны, көзне күреп яшәгәндә, сөйгәндә-сөелгәндә, күп авырлыклар булганда да. Тормыш башка килмәс. Өлгерергә тырыш мәнгелек тормышның бер өзегендә! Кадерен бел, бәясен бел үлүең булмый торган жирдәге тормышның!" Рафаэль Сибат исә тагын да кыскарак. "Тудынмы—Яшә! Үлем—синең эш түгел..." Бәс, шулай булгач, кирәкме соң аларны өйрәнү? Киресенчә, чөнки, автор искәрткәнчә, үткән гасыр башындагы әдәби эзләнүләр татар әдәбиятына йогынты ясап киләе, аңдый әсәрләрнең дә милләтнең рухият үсешенә тегә яки бу дәрәжәдә катнашы бар һәм алар ижтимагый фикернең, димәк татар фәлсәфәсенең аерым чагылышлары, сәнгатьлелеккә ирешүнең игътибарга лаек формалары дип тә каралырга хаклы. Кыскасы, татар әдәбият тыйлеме тагын бер салты хезмәт белән баеды. Монын өчен без профессор Дания Заһидуллинага рәхмәт әйтергә, ана яңадан-яңа иҗат уңышлары теләргә тиешбез.

Факил ӘМӘК



75—КЫЯМӘТ (КЫЯМӘТ) СҮРӘСЕ

(Кыямәт сүрәсе 40 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән.)

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

1. Кыямәт исеме белән әйтәмен, **(2)** *(кылган яманлыкларына үкенгән, вәҗдан газабы кичергән)* жаннар исеме белән әйтәмен *(яңадан терелү һәм жавапка тарту, ничшиксез, булачак).* **(3)** Кешеләр: үлгән череп таркалган сөякләребезне бергә җыеп, безне яңадан терелтә алмаячак, дип уйлый. **(4)** Ничшиксез, аларның бармак очларына чаклы, ничек булган, шулай мөкәммәл итеп, яңадан җыярга кодрәтебездән килә. **(5)** Ләкин кеше дигән жан иясе алда күрәчәгенә ышанмый, *(азгынлыкка омтыла).* **(6)**—Кыямәт көне кайчан киләчәк соң?–дип көлгән була. **(7)** Күзләр камашып. **(8)** Ай тотылып. **(9)** Кояш белән Ай бергә укмашып. Менә шул булыр Кыямәт көне. **(10)** Ул көн килгәч, кеше әйтер:

–Бу дәһшәттән кая качып котылыйм?–дияр.

11. Юк шул, качар урын табылмас. **(12)** Ул Көнне качып котылу урыны бер генә–Аллаһның хозуры. **(13)** Ул Көнне һәр кешегә элеккеге дөньяда калдырган яхшы-яман гамәлләре турында хәбәр бирелер. **(14)** Ин дөресе–кеше үзенә каршы үзе шаһит булыр *(кылган гөнаһлары белән).* **(15)** Хәтта ул ярлыкау сорап ялварса да.

16. *(Ий, Мөхәммәд)* ашыгып, *(Корʾән аятьләренең барысы да вәхий ителгән бетмәс борын)* ятларга тырышма. **(17)** Шик юк ки, аны *(Корʾәнне Китап итеп)* туплау, синең күнеленә индерү, укыту эшләре безнең хәтыярыбызда. **(18)** Шулай булгач, Без аны *(Жәбраил теле белән сиңа)* укыган вакытта кабатлап бар. **(19)** Соңыннан аны аңлатып бирү дә, хакгыр ки, безнең ихтыярда. **(20)** Аяныч ки, сез ашыгасыз, сезгә тиз кирәк. **(21)** *(Тормыш мәшәкатьләрендә ашыга-кабалана)* сез Кыямәт турында да онытасыз.

22. Ул көнне берәүләренең йөзе якты булыр. **(23)** Алар Аллаһка багып торыр. **(24)** Икенчеләренең сытык чырае кара көйгән булыр. **(25)** Алар умыртка сөякләрен сындырачак җәза киләчәген сизенеп, шулай кайгылы күренер. **(26)** Күзгезенә ачып карагыз, жанығыз бугаз төбенә менеп җиткәч: **(27)**

–Кем безне дәвалар, кем коткарыр!–дип кычкырырсыз. **(28)** Шунда гына кеше жаннан аерылыр вакыт житкәнен белер. **(29)** Бер тез икенчесенә берегер *(кылган гөнаһлары аркасында йөри алмас хәлгә килер).* **(30)** Ул көнне кайтарылыш бары тик Аллаһ хозурына булыр. **(31)** Бу кеше иман китермәде һәм намаз укымады. **(32)** Шулар өстенә, ул *(Корʾәнне)* ялганга чыгарды, иманга арка куеп китте. (33) Кардәшләре алдында үзен аллә кемгә күрә, масаеп йөри башлады. (34) Син жәһәннәм кисәге булырга лаек, бик тә лаек. **(35)** Сиңа газаплар булсын, син аңа лаек. Бик тә лаек. **(36)** Кеше үзен: ничүкләүләрсез, авызлыксыз, күзәтүчесез яшәргә хаклы, дип саныймы алла? **(37)** Ул ана карынына атылган бер мәнидән хасил икәнен онытамы? **(38)** Соңра шул мәни бер өешкан кан кебек *(яралгы)* булды, аннан соң аны кеше кыяфәтенә кертеп, дөньяга яралттык. **(39)** Ирлә-хатынлы итеп тудырттык. **(40)** Шушыларны бар итә алган Аллаһ мәетләрне генә терелтә ала торгандыр, шәт?

76—ИНСАН (КЕШЕ) СҮРӘСЕ

(Инсан сүрәсе 31 аятьтән тора. Мәккәдә, Мәдинәдә иңгән.)

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

1. Адәми затның исеме дә, жисеме дә булмаган чактан алып, *(адәми зат барлыкка килгәч)* озак заманалар узып китмәдеме?

2. Хакыйкать шулдыр ки, Без кешене *(ир кешенең мәние белән хатын кешенең орлыгы кушылган)* катнашмадан яралгыдан ясадык. Аны сынап карар өчен, ишетү,

күрү сәләте бирдек. **(3)** Хактыр ки, Без аңа тугры юл күрсәттек. Теләсә, шөкер кылучы булыр, теләмәсә көферлекне сайлар. **(4)** Хактыр ки, без кяферләр өчен чылбырлар, тимер богау-кыршаулар һәм ялкынлы ут хәзерләп куйдык.

5. Игелекле кешеләр исә кяфүр мае *(камфора)* кушылган эчемлекләр эчәр. **(6)** Аллаһның игътибарына лаек бәндәләр эчә торган ул ширбәт чишмәсе өзлексез агып торыр. **(7)** Ул бәндәләр, дөньәдә һәр жирдә мәгълүм булган шул көннән *(Кыямәт жавабынан)* куркып, антларына тугры калыр, вазифаларын төгәл үтәрләр. **(8)** Үзләре дә фәкыйрь булуга карамастан, соңгы ризыкларын мохтажларга, ятимгә, әсир кешегә бирер. **(9)** Алар хәерчеләргә:

—Без сезне Аллаһ ризалыгын алыр өчен ашатабыз, сездән бер түләү дә, рәхмәт әйтүегезне дә көтмибез. **(10)** Без читен һәм хәтәр бер көннең газабыннан куркабыз,— дип әйтерләр. **(11)** Менә шуның аркасында Аллаһ ул көнне аларны афәттән коткарыр, чырайларына нур өстәр, күңелләренә куаныч бирер.

12. Түзем *(сабыр)* булганнарына күрә, Аллаһ аларга жәннәтне ефәк киемнәре белән бүләк итәр. **(13)** Канәфиләрдә кырын ятып, эссе дә, салкын да булмаган мохиттә, **(14)** жәннәт агачларының күләгәсендә, үрелеп көнә ала торган жимешләр ашап, истирахәт кылырлар. **(15)** Аларга көмеш кувшиннардан бәллүр касаләрдә, **(16)** көмешсу ташаяк савытларда, жәннары теләгәнчә *(жәннәт ширбәте)* әләшеп йөрерләр. **(17)** Зәнжәфил суты катыштырылган эчемлек салынган касә бирерләр. **(18)** *(Зәнжәфил)*—жәннәттә ага торган бер чишмәнең суыдыр. Чишмәнең исеме исә Сәлсәбил дип атала. **(19)** Мәңге яшь, саф егетләр тирә-юнькә хезмәт күрсәтеп йөрер. Ул егетләрнең сафлыгы, әйтерсез дә, чәчелгән энҗе бөртекләре. **(20)** Ул жәннәтне күрер булсаң, шаккатарсың. Ул—нигъмәт, байлык, гүзәллек солтанаты. **(21)** Аларның өстендә калын-юка яшел ефәк киемнәр булыр, алар көмеш бәләзекләр кигән булыр. Аллаһ аларга саф, татлы эчемлек кенә эчерер. **(22)** Хактыр ки, Аллаһ юлында күрсәткән хезмәтләрегез өчен, вәгъдә ителгән әжер шушы булыр.

23. *(Ий, Мөхәммәд)*—Корьәнне сина Без индердек. *(Аны башка зат индерә алмый.)* **(24)** Аллаһның хөкемен сабыр гына көт; һичбер имансызга һәм гөнаһкярга иярмә. **(25)** Иртә-кич Аллаһ исемен зикер ит. **(26)** Төннең бер өлешен Ана сәждә итеп уздыр, төннең озын вакытында да тәсбих тарт.

27. Кешеләр күз ачып йомганчы узып китә торган фани дөньяга мөкиббән һәм килечәктә башларына төшәчәк *(Ахирәт)* көнне онытылар. **(28)** Аларны Без юктан бар иттек һәм аларның тез буыннарын нык иттек. Әгәр ихтыяр итсәк, *(аларны юк итеп)* алар урынына бүтәннәрне бар кылып идек. **(29)** Шик юктыр ки, бу—бер үгет-нәсихәт. Теләгә булган кеше Рәббыга юнәлер.

30. Сез теләгәннәр фәкать Аллаһ әмере белән генә тормышка ашар. Шик юк, Аллаһ бар нәрсәне дә белеп тора. Ул—хикмәт ияселәр. **(31)** Ихтыяр иткән кешесен Ул рәхмәтенә багышлар. Кяферләр өчен хәтәр газап бирер.

77—МҮРСӘЛӘТ (ЙОМЫШ БЕЛӘН ҖИБӘРЕЛГӘН) СҮРӘСЕ

(Мүрсәләт сүрәсе 50 аятьтан тора. Мәккәдә иңгән. Мүрсәләт—жибәрелгәннәр, күндерелгәннәр.)

Бисмиллаһир-рахмәнир-рахим.

1. Игелек тарату өчен берсе артыннан берсе күндерелгән *(фәрештәләр, пәйгамбәрләр исеме белән)* **(2)** дөньәгә белән исә торган жилләр, **(3)** *(дөреслек һәм игелек)* таратучылар, **(4)** *(кайда хакыйкать, кайда ялганны)* аңлаганнар, **(5)** Аллаһның кисәтүләрен иреште рүчеләрнең исеме белән ант итәмен ки: **(6)** ярлыкаучы ул яки күркытып кисәтүче, **(7)** белеп торыгыз, вәгъдә ителгән Көн, һичшиксез, киләчәк. **(8)** Йолдызлар сүнгәч, **(9)** Күк йөзе ярылгач, **(10)** таулар күбарылып, тузанга әверелгәч, **(11)** пәйгамбәрләргә Кыямәтнең кайчан булуны әйтелер, **(12)** Хөкемнең кайсы көнгәчә кичектерелүчеге хәбәр ителер. **(13)** Хак белән ялганны аеру көненә чаклы кичектерелячәк. **(14)** Аеру көненең ни икәнен *(Без әйтмәсәк)* син каян белерсең? **(15)** Ул көндә *(Корьән аятьләрен)* ялганга чыгаручан кешеләргә, ай-һай, авыр булыр. **(16)** Әүвәл яшәгән кавемнәрне без шулай һәлак итмәдекме? **(17)** Алардан соң килгән кяферләрне дә Без дөмектерәчәкбез. (18) Гөнаһлыларны Без әнә шулай жәзапка

тартачакбыз. **(19)** *(Аллаһның аятьләре һәм пәйгамбәрләрнең үгетләрен)* ялганга чыгарганнарның Ахирәт көнендәге хәле коточкыч яман булыр.

20. Без сезне юк дәрәҗәсендәге сыеклык тамчысыннан (орлыктан) яраттыкмыкмы? **(21)** Аны ышанычлы урынга *(ана карынына)* урнаштырдык. **(22)** Мәгълүм бер вакытка чаклы. **(23)** Без моны кодрәтебез илә тәкъдир иттек. Без шундый кодрәткә ия.

24. *(Кодрәтебезне)* ялганга чыгарганнарның Ахирәт көнендәге хәле коточкыч яман булыр. **(25)** Без Җирне барчагызны бергә җыяр өчен мәйдан итеп яраттыкмыкмы?

(«Разве не сделали Мы так, что притягивает к себе земля.
Мәүланә Али тәфсиреннән.)

(26) Тереләрне дә, мәетләрне дә *(җирдә бар иттек)*. **(27)** Анда биек нык тауларны бар иттек. Сезгә татлы сулар эчертмәдекме? **(28)** *(Шушы нигъмәтләрне)* ялганга чыгарганнарның Ахирәт көнендәге хәле коточкыч яман булыр. **(29)** *(Ул көнне кяферләргә әйтелер ки):*

–Әйдәгез, сез ялганга санаганга *(җәһәннәмгә)* керегез! (30) Барыгыз, *(җәһәннәмнең)* өчкә аерыла торган күләгәсенә керегез. **(31)** Ул күзгә рәхәтлек бирмәс. Ул ялкынныннан да сакламас. **(32)** Ул ут шундый ялкыннар атадыр ки, һәр ялкыны зур сарай кебек булыр. **(33)** Һәрбер очкыны сап-сары дөя кебек зур булыр. **(34)** Ул көнне *(җәһәннәмне)* ялганга чыгарганнарның хәлләре коточкыч яман булыр. **(35)** Бу көн тәлгәрнең тотлыгачак көне булыр. **(36)** Гафу сорарга телиләләр дә, аларга рөхсәт бирелмәячәк. **(37)** Ялганга чыгарганнарның ул көнне хәлләре коточкыч яман булыр. **(38)** Бу көн *(яманнан яхшыны)* аеру һәм хөкем көне булыр. Ул көнне Без сезне дә, әүвәлгеләрнең барысын да бергә туплаячакбыз. **(39)** Хәйлә корырга уйласагыз, сез аны Миңа каршы корып карагыз. **(40)** *(Кыямәтне)* ялганга чыгарганнарның ул көнне хәле коточкыч яман булыр.

41. Саф мөселманнар чишмә буендагы күләгәләр астында рәхәт чигәр. **(42)** Алар күңелләре теләгән жимешләр арасында булыр. **(43)** Мөэминнәргә әйтелер ки:

–Кылган игелекләрегезгә күрә, рәхәтләнеп ашагыз, эчегез! **(44)** Хактыр ки, игелек кылганнарны Без әнә шулай бүләклибез.

45. Ялганга чыгарганнарның ул көндәге хәле бик яман булыр. **(46)** *(Әй, кяферләр, фани дөньяда)* ашагыз-эчегез, рәхәтләнеп *(типтереп)* калыгыз. Шик юктыр ки, сез гөнаһкярларсыз. **(47)** Ялганга чыгарганнарның хәле коточкыч яман булыр. **(48)** Аллаһка буйсыныгыз, дигәч, алар буйсынмады. **(49)** *(Кыямәтне)* инкарь иткәннәрнең хәле коточкыч яман булыр. **(50)** Алар иман китерсен өчен тагын нинди китап индерергә кирәктер?

78—НӘБА (ХӘБӘР) СҮРӘСЕ

(Нәба сүрәсе 40 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Нәба–хәбар дигән сүз.)

Бисмиллаһир-рахмәнир-рахим.

1. Бер-берләреннән алар ни турында сораштыра? **(2)** Олуг хәбәр *(Корьән белән Кыямәт)* турындамы? **(3)** *(Корьән турында да, Кыямәт хакында да алар)* уртак фикергә килә алмыймы? **(4)** Хәер, озаклямый аңларлар. **(5)** Шыннан да, алар аңлаячак. **(6)** Без Җирне сезнең өчен ястык кебек итеп ясамадыкмыни? **(7)** Тауларны да казык кебек итеп утыртмадыкмыни? **(8)** Сезне пар-пар яраттык. **(9)** Хәл алыр өчен йоклы бирдек. **(10)** Төн пәрдәсен хасил иттек. **(11)** Эшләр өчен көне бирдек. **(12)** Өстегезгә жиде кат Күкне кордык. *(М. Али «жиде кат күк»не Кояш системасының жиде җисеме, ди.)* **(13)** Анда балкып янучы бер кандил *(Кояшны)* куйдык. **(14)** Куе болытлардан шаулатып яңгыр койдырабыз. **(15)** Ул бөртекләр *(бодай, арпа, арыш)*, үсемлекләр (үлән, агачлар) үстерә. **(16)** Бер-берсенә уралып үскән жимеш бакчаларын сугара. **(17)** Шик юктыр ки, *(Хактан ялганны)* аера торган хөкем көне инде билгеләнгән. **(18)** Ул көнне Сур быргысына өреләчәк һәм сез *(каберләрегездән кубып)* төркем-төркем булып *(хозурыма)* килачәксез. **(19)** Ул көнне Күк капусы ачылыр. **(20)** Таулар *(урыннарыннан күбарылып)* тузан бөртегә кебек очып йөрер, монар кебек уйнар. **(21)** Хактыр ки, җәһәннәм ул–бер капкын. **(22)** Азгын халыкларның торачак урынлары. **(23)** Бетмәс-төкәнмәс вакытлар буена алар анда калачак. *(Җәһәннәмдә мәңге калу мәсьәләсенә карашлар төрлечә, Муса Биги хәрәмтәләре дә кяферләрнең дә, озак вакытлар тәмугта янганнан соң аннан чыгарылачагы турында язган, башка тәфсирчеләр дә бу*

хосуста үз фикерләрен әйтә килә. Мәүланә Али нәсхәсендәге 1201 һәм 2643 нче аңлатмаларда шул хакта тәфсилән языла.)

(24) Анда бер генә күләгә дә, эчәр өчен салкынча сыеклык та булмас. **(25)** Эрен катыштырылган кап-кайнар судан башка. **(26)** Кылган гамәлләренә таман җәза алачаклар. **(27)** Чөнки алар Хисап көненең киләчәгенә ышанмый иде. (28) Коръәнебезнең аятьләрен ялганга чыгардылар. **(29)** Без исә барысын да язып, хисапка ала бардык. **(30)** *(Аларга шулай диярбез ки):*

–Менә хәзер инде *(җәзагызны)* татыгыз! Газабыгызны арттырудан башка бернидә эшләмибез.

31. Һичшик юктыр ки, сафлыкта мөэминнәр *(Аллаһның җәзасыннан курыкканнар)* өчен Сәгадәттә кавышу булыр. **(32)** Бакчалар, йөзем бөкләннары. **(33)** Күкрәкләре тыңтыгыз яшь кызлар, **(34)** мәлдерәмә тулы касәләр янда булыр. **(35)** Анда бушсүзләр сөйләнмәс, ялган-гайбәт булмас. **(36)** *(Бу Сәгадәт)* Раббыдан бөек әҗер һәм ярлыкау буларак бирелер. **(37)** Күкләрнең, Җирнең һәм икесе арасында булганнарның хуҗасы Раббыбыз–Аллаһ. Ул–рәхимле. Ул көнне инсаннар Аңа каршы сүз әйтергә *(акланырга яки рөхсәтлек бәлдерергә)* ирекле түгел. **(38)** Изге рух *(Җәбрәил)* һәм фәрештәләр сафсафга булып торган үл көндә, Аллаһның рөхсәтеннән башка сүз әйтелмәс. Рөхсәт булганда, Хакыйкать турында сөйләнер. **(39)** Менә, катгый киләчәк котылгысыз көн шул булыр. Шулай булгач, теләгән кеше Аллаһ юлына юнәлсен. **(40)** Озакламый сезнең өскә килачәк җәза белән сезне кисәтеп куйдык. Ул көнне *(инкарьчы)* кеше *(фани дөньяда)* кылганнарына карап:

–Их, ни аяныч, туфрак булып кына калган булсам иде,–дип үкенер.

79—НӘЗИГАТЬ (ЙОЛКЫП АЛУ) СҮРӘСЕ

(Нәзигать сүрәсе 46 аятьтан тора. Мәккәдә иңгән. Нәзигать–суырып, йолкып чыгаручылар, дигән сүз.)

Бисмиллаһир-рахмәнир–рахим.

1. *(Кяферләрнең төннәрендәге җаннарын)* суырып алучыларның исеме белән, **(2)** (мөэминнәрнең җаннарын) жиңеллек белән алганнарның исеме белән әйтәмен ки, **(3)** *(Җир белән Күк арасында Аллаһ йомышы белән)* очып йөрүчеләрнең исеме белән әйтәмен ки, **(4)** *(кяферләрнең җаннарын–җәһәннәмгә, мөэминнәрнекен җәннәткә урнаштыру эшендә)* ярыша-ярыша алда барганнарның исеме белән, **(5)** *(Аллаһ әмерен ила)* тәдбирләр корып *(алдан уйлап)* эш йөрәткәннәрнең исеме белән әйтәмен ки *(һәр барчагыз ул көнне җәвап бирер өчен терелачәк).* **(6)** Ул көнне *(Сур бырсысының)* хәтәр аваз яңгырар *(Җирдә тереклек бетәр).* **(7)** Шуның артыннан ук *(икенче тапкыр Сур бырсысына өреләр һәм барча кеше терелеп, каберләреннән чыгар).* **(8)** Ул көнне барысы да йөрәкләре ярылырдай булып *(мөэминнәр кылчык бәхет белән кавышу шатлыгыннан, кяферләр алачак җәзаларын сизенеп)* тетрәнер. **(9)** *(Гөнаһлыларның күрку һәм ояттан, саваплыларның тыйнаклыктан)* күзләре аска текәлгән булыр. **(10)** *(Гөнаһкярлар дөньядагы чакта)* әйтә:

–Без, үлгәч, яңадан элеккеге хәлебезгә кайтачакбызмы? **(11)** Череп, сөякләребез тараелып беткәч тәме? *(Без моңа ышанмыйбыз),*–дип *(көлкегә алалар иде).*–**(12)** Алай булса, бу *(безнең өчен)* зыян булачак.

13. Шик юк ки, бу эш *(яңадан терелу!)* бер аваздан *(Сурдан)* соң булыр. **(14)** Шул чакта ук алар терелеп, мәхшәрдә булачак.

15. *(Ий, Мөхәммәд)* Муса турындагы риваять сиңа килеп ирештеме? **(16)** Ничек итеп Аллаһ изге Тува үзәнендә аңа эндәште:

(17)–Бар син Фиргавен янына,–диде.–Ул бик тә азды, хәттин ашты. **(18)** Әйт син аңа: *(кяферлегеңнән, азгынлык гөнаһларыңнан)* арынырга теләмисеңме?–диген. **(19)** Мин сине Аллаһны танырга чакырамын. Аллаһны танысаң, Аллаһтан куркырсың, гөнаһ кылмассың. **(20)** *(Муса китте, Фиргавенга)* ин олы мөгҗизә күрсәтте *(таягын елангач әверелдерде, кесәсеннән нур чәчүче күлен чыгарды).* **(21)** Ләкин Фиргавен Мусаның кылмышларына ышанмады, аны ялганчыга чыгарды. *(Аллаһка каршы)* көфер сөйләде. **(22)** Ахырда ул йөз чөреп, китеп барды. **(23)** Аннан соң ул халык җыеп **(24)**:

–Сезнең ин бөек аллагыз ул–мин!–дип кычкырды. **(25)** Шуның аркасында Аллаһ аны Ахирәт көнендә дә, дөньялыкта да җәзасы белән тотты. **(26)** Шик юктыр ки, *(гөнаһ кылудан)* курыкканнар өчен бу *(хикмәтләрдә)* гыйбрәтләр бар. **(27)** Сезне яңадан терелтү ансатракмы, әллә Күкне бина кылуны? Күкне Аллаһ яралтты. *(Сезне яңадан*

терелтү Күкне барлыкка китерүдән дә ансатрак.) **(28)** Күкнең биеклеген Аллаһ билгеләде. Аннан соң ул аны камил бер тәртипкә куйды. **(29)** Төнен караңгы ясады, көнен якты итте. **(30)** Аннан соң Аллаһ Җирне ястык кебек итте. **(31)** Туфрактан су һәм үсемлекләр чыгарды. **(32)** Тауларны беркетте. **(33)** Мал-туарларыгыз утлап йөрсен өчен.

34. Бөтен куркынычлардан да куркыныч көн килгәч, **(35)** кеше ни өчен шулай дөнья артыннан *(мал-байлык артыннан)* чапканын аңлар. **(36)** Ул ялкыны *(җәһәннәм)* барысына да күрсәтелгәч, **(37)** хәттин ашып азганнар, **(38)** дөнья тормышына табынганнар **(39)** бара торган урын–Төмыт икәнен аңлар. **(40)** Әмма раббының *(кисәтүләреннән)* курыккан һәм нәфес һәвәслегенә юл куймаган кешенең **(41)** барачак урыны–җәннәт булыр.

42. Кыямәт көненең кайчан килеп басачагы турында *(Мөхәммәд)* сиңнән сорарлар. **(43)** Аңа кагылышлы мәгълүмат синдә юк. **(44)** Кыямәт көне килгәчәк ахыр көн бары тик Аллаһ хозурында гына. **(45)** Син *(Аллаһ җәзасыннан)* куркучы кешеләрне кисәтүче, хәбәр бирүче генә. **(46)** Кыямәт көнен күргәч, аларга дөньяда *(кабердә)* өйләрә чаклы–ярты көн, өйләдән соң ярты көн генә торган кебек тоелыр.

80—ГАБӘСӘ (ЧЫТЫК ИЮЗ) СҮРӘСЕ

(Габәсә сүрәсе 42 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Габәсә–чытык чырайлы, дигән сүз.)

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

1, 2. Бер сукыр адәм килеп, сүзен бүлдергәч, *(Пәйгамбәр)* йөзен чытты һәм читкә борылды. **(3)**

–Син каян белдең, балкы, ул *(синең вәгазеңне тыңлап)* пакълөнергә дип килгәндер? **(4)** Яки ул синең үгетеңне тыңлап, үзенә файда алырга теләгәндер. **(5)** Әмма *(бай һәм йөз төергән бирәр төкәббер кеше очратсаң), (6)* син аңа игътибар итәсең. **(7)** Гәрчә, аның иманга килмәвеннән сиңа ни файда, ни зыян? **(8)** Ләкин синең янга йөгереп килгән кеше **(9)** *(Аллаһ каршында гөнаһ кылудан)* курка торган кеше булса да, **(10)** син аны игътибарсыз калдырасың. **(11)** Аң бул! Коръән ул вәгазьләрдән торса. *(Вәгазьне барча теләгәннәрә аермаенча сөйлә.)* **(12)** Тыңлаган кеше аннан сабак алыр. **(13, 14).** Ул *(Коръән)* бик тә абруйлы, кадере бөек, сафлыкъ сәхифәләрдән хасил. **(15, 16)** Бик тә куймәтле, сөеклә, сафлыкъ *(фәрештәләр тарафыннан күчерелен)* язылган Китап.

17. Әче кәһәр төшсен *(инкарьчы)* кешегә! Ул никадәр дә көфер зат. *(18)* Юкса, аны *(Аллаһ)* нәрсәдән бар кылды соң? **(19)** Бер тамчы сыеклыктан, *(мәни бөртегеннән)* бар кылды һәм аңа рәвеш бирде, чиклəр куйды. **(20)** Соңыннан аның юлын җайлы итте. **(21)** Аннан соң аны җансыз итеп, гүргә индерде. **(22)** Шуннан соң Үзе теләгән вакытта аны яңадан терелтәчәк. **(23)** Хактыр ки, кеше *(Аллаһның)* әмерләрен җиренә җиткезеп үтәми. **(24)** Ашаган ризыгына баксын инде, ичмасам. **(25)** Хактыр ки, Без мул-мул яңгырлар ядырдык. **(26)** Аннан соң Без туфракны яхшылап ярдык *(сөрдек).* **(27)** Шулай итеп, без анда орлык үстердек. **(28)** Йөземнәр, ашый торган төрле *(яшелчә)* үләннәр. **(29)** Зәйтүн агачлары, хөрмә бағларын. **(30)** Күп-куе булып үскән җимеш бакчалары. **(31)** Җиләк-җимеш һәм печән үстердек. **(32)** *(Боларның һәммәсен дә Без)* сезгә һәм мал-туарларыгызга файда булсын, дип бар иттек.

33. Менә кайчан колак тондыргыч аваз яңгырагач, **(34)** кеше качачак агаэнесеннән, **(35)** анасыннан, атасыннан, **(36)** хатынынан һәм балаларыннан. **(37)** Ул көнне барысының да үз мәшәкате булыр *(ничек тә булса Аллаһның хәтәр җәзасыннан котылу).* **(38)** Ул көнне йөзләре балкып тора торганнар да булыр. **(39)** Көлеп, сөенеп йөрүчеләр. **(40)** Ул көнне тузан каплаган *(кара йөзлелəр дә)* булыр. **(41)** Кап-кара көйгән йөзләр. **(42)** Менә шулар инде кяферләр һәм аныңаять челәр.

81—ТӘКЪВИР (ТӨРЕП КУЮ) СҮРӘСЕ

(Тәкъвир сүрәсе 29 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Тәкъвир–чорналу, уралу, бөрешү, бөктерләнү.)

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

1. Кояш бөрешеп, сүнгән заманда, **(2)** йолдызлар сүнеп, егылган чакта, **(3)** таулар кубарылып, *(монар кебек)* хәрәкәтkә килгәндә, **(4)** буаз дөялəр караучысыз калгач,

(5) кыргый хайваннар бер урынга тупланган чакта *(гомумәфәт килгәндә әртәкчылар белән бичара киеклөр бер урынга җыела, бер-берсенә кагылмый)*, **(6)** диңгезләр дөрләп яна-яна ташып,бер урынга коя башласа, **(7)** рухлар *(җаннар)* үз тәнҺәре белән кушылган заманда; **(8)** тереләй җиргә күмелгән сабый кыз баладан: **(9)** ни сәбәпле сине шулай кылдылар, дип сорар вакыт җиткәч; **(10)** *(гамәл)* дәфтәрләре ачылып, *(жинаятьләр)* фаш ителгәндә; **(11)** Күк урынныннан күпкан мәлдә, **(12)** хәтәр ялкынлы җәһәннәм артыгы белән кыздырганда; **(13)** җәннәт мәэминнәрә якынайганда, **(14)** менә шул чакта һәрбер кеше үзенең кылмышларын белән үзенә ни хәсрәтләнен бик яхшы аңлар.

15, 16. Килеп китүче *(Күк җисемнәре)*нең исемнәре белән әйтәмен ки, **(17)** караңгыга батырган төн, **(18)** яктылык ата башлаган таң исеме белән әйтәмен ки; **(19)** шик юк, *(Корьән)* бик тә шәрәфле бер илченең *(Жәбраилнең)* алып килгән изге сүзләредер. **(20)** Бу илче *(Аллаһның)* хөрмәтенә лаек, көчле һәм Гарешнең Раббысы янында урын алган, **(21)** анда *(фәрештәләр арасында)* абруй казанган, Аллаһның ышанычын аклаган илче.

22. Сезнең кардәшегез *(Мөхәммәд тә)* дивана түгел. **(23)** Хактыр ки, ул *(Мөхәммәд)* аны *(Жәбраилне)* офыкның биеклегендә ап-ачык итеп күрде. **(24)** Ул саран түгел *(Мөхәммәд кешеләргә мәгълүм булмаган яшерен нәрсәләр мәсьәләсендә гаепләнмәс)*.

25. Ул *(Корьән)* лөгъәтләренеп, ташлар атып *(оҗмахтан)* күылган шайтанның авызыннан чыккан сүз түгел. **(26)** Шулай булгач, *(Корьәнне танымыйча)* кая китеп барасыз? **(27, 28)** Ул галәмдәге халыклар өчен, тугры юлдан барырга теләгәннәр өчен вәгазьдән башкасы түгел.

29. Ләкин шунысы да хактыр ки, галәмнәрнең Раббысы теләмәсә, сез теләгегезгә ирешә алмассыз. *(Аллаһның әмереннән башка сез теләй дә алмассыз.)*

82—ИНФИТАР (ЯРЫЛУ) СҮРӘСЕ

(Инфитар сүрәсе 19 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Инфитар–ярылу, жимерелү мәгънәсендәге сүз.)

Бисмиллаһир-рахмәнир-рахим.

1. Күк ярылган чакта, **(2)** йолдызлар чәчелеп коелган вакытта, **(3)** диңгез-океаннар бергә кушылган хәлдә, **(4)** каберләр актарылып, асты өске килгәндә *(ягыны, үлеләр терелеп, кабердән чыкканда)*, **(5)** һәркем кыләчәге өчен ни хәзерләнгәнен, *(фани дөньяда)* нинди гамәлләр калдыргаиын беләчәк.

6. *(Әй, адәм баласы)* нәрсәгә кызыгып *(алданып)*, син чиксез юмарт Аллаһның нигъмәтләреннән *(сәваптан, яралыкандан, жәннәттән)* коры калдың? **(7)** Аллаһ сине юктан бар итте, саламәт әгъзалар биреп, *(бөтен гөүдәңне)* тигез, төгәл итте, *(аларны бер-берләренә яраклаштырып)* бөтен ягыңны үлчәм белән камилләштерде. **(8)** Ничек теләсә, сезне шундый кыяфәттә яралтты. **(9)** Юк бит! Шушы ап-ачык дәлилләрдән соң да, сез динне *(Кыямәт көнен, Корьәнне)* ялганга чыгарасыз. Гәрчә, **(10)** сезнең өстегездә Хакыйкать сакчылары *(фәрештәләр)* тора. **(11)** *(Аллаһ хозурында)* бик тә ышаныкъ казанган, намуслы рәвештә язып баручылар бар. **(12)** Алар сез ни кылсагыз, шуны белеп тора. **(13)** Игелек кылганнар, һичшиксез, Нәгъйм җәннәтләренә керер. **(14)** Гөнаһкярлар исә тәмугта яначак. **(15)** Ул көнне аларның барысын да шунда алып килерләр. **(16)** Һәм алар аннан *(тәмугтан)* беркайчан да чыкмас. *(Бөгъзеләре «жәһәннәмдә вакытлыча калырлар», «жәһәннәмнән һич аерылмаслар», «жәһәннәмнән котыла алмаслар» дип яза, боларның барысын берләштергәндә аятьне менә болайрак тәкъдим итәргә була: Һәм алар Аллаһ Тәгалә билгеләгән вакытка чаклы жәһәннәмдә калачак.)*

(17) Син үл көннең ни икәнен белисеңме? Ул турыда сиңа *(Аллаһтан башка)* кем сөйләсен? **(18)** Кыямәт көненең ни икәнне син белмисең. *(Аллаһтан башка)* сиңа үл турыда тагын кем сөйләсен? **(19)** Ул шундый бер көндер ки, һичбер кеше икенчесенә, һичбер нәрсәгә ярдәм итә алмас. Ул көнне хөкем бары тик бер Аллаһ тарафында гына булыр.

Самат Шакирның тууына 80 ел

БОЗ КИЧҮ

Ижат кешесенең гомере, матур бизәкләргә таркалып, замандашлары күңелендә жете хатирәләр булып саклана. Ул бизәкләр айлар, көннәр, сәгатьләр һәм хәтта аерым мизгелләрдән тора.

Заманында, Самат Шакирга ияреп, Татарстан авылларында йөргән идек. Ижади сәяхәтләрдән буш кайтмыйсың—күрешәсең, өйрәнәсең, илһам аласың, таныласың...

Жае чыкканда, салпы ягына салам кыстырырмын дип, Самат абыйның биографиясен алдан ук өйрәнеп куйдым. Кызыклы шәхес... Ул НЭП елларында туган, Ватан сугышының соңгы елларында Совет Армиясе сафларында хезмәт иткән. Арча педагогия училищесын тәмамлагач, аның хезмәт юлы әле мәктәптә, әле район газеталары редакциясендә алышынып тора. Холкы белән—укытучы, чынбарлыкта әдәби хезмәткәр, эчке дөньясы белән—шагыйрь, максаты белән—бар гомерен хәрби-патриотик темага багышлаган публицист.

Элек, яшь буынны батырлык үрнәкләре рухында тәрбияләү дигән мактаулы традицияләр бар иде. Хәбәрсез югалган, исемнәре ялган тарих белән күмелгән, онытылган, сугышчан бүләкләрдән мәхрүм калган фронтовикларның батырлыгын исбат итеп документаль әсәрләр языла, яңа һәйкәлләр күтәрелә, митинглар, тантаналы кичәләр үткәрелә, урам исемнәре яңара. Рафаэль Мостафин, Шамил Рәкыйпов, Самат Шакир, Зөки Әхмәтжанов, Шаһинур Мостафин кебек язучыларыбыз үз-үзләреп аямыйча сугыш батырлары эзеннән йөрде.

Самат Шакирны язучы буларак күтәргән беренче әсәр—"Легенда егетләре", дип әйтсәк, ялгышмабыз. Сталинград сугышларында һәлак булган өч егет: испан, рус һәм татар егетенең язмышына нигезләнеп язылган әлегә документаль повесть житмешенче еллар уртасында төрле телләргә тәрҗемә ителеп дөнья күрде.

Аның Советлар Союзы геройларына багышланган "Һәйкәлләр итәгендә чәчәкләр" дигән повесте 1976 елда "Казан утлары" журналында да басылып чыккан иде. Ул батырларны бер-бер артлы эзләп таба тора. Гел юлда, гел эзләнүдә. Фашист тоткынлыгында көрәшеп, батырларча һәлак булган Хәйретдин Мәҗәйнең фронт көндәлекләрен һәм шигырьләрен эзләп табып, аерым китап итеп чыгаруны да Самат Шакир; егерме тугыз татар язучысының биографик белешмәсе тупланган "Алар сафта" җыентыгының автор-төзүчесе дә; Куйбышев, Братск, Красноярск, БАМ төзелешләренә, Чирәм жирләргә барып якташларыбызны зурлаучы да ул—язучы-документалист Самат Шакир...

Киксәнечче елларда, СССРның Илбашы Л. И. Брежнев исеменнән истәлек-трилогия басылып таралгач, татар дөньясын бер исем скскәндерде—"Кече жир" китабында телгә алынган батыр Вәлиуллин кем ул һәм кайдан?!

Төрки фамилиясеннән чамалап, мөгаен безнең милләт кешеседер дип, дүрт республика аякка басты.

Самат Шакир үзе бу турыда тәфсилләп сөйли белә иде:

"Әйтергә кирәк, минем партиянең өлкә комитетына чакырып алдылар. Кичекмәстән юлга чыгарга куштылар. Хәкүмәт мөһерe сугылган командировка таныклыгын тоттырып, шуның белән берлектә, кара "Волга" ярты сәгать эчендә аэропортка илтеп куйды..."

Самат абый, ияләнгән гадәтенчә, нәзәкатле итеп кенә борынын пыршылдатып

куя, обком кушкан эшләрнең җитдилегенә инандыру өчен сирле паузалар ясый. Чөнки партия бу җаваплы эшне нәкъ менә аңарга—язучы Самат Шакирга ышанып тапшырган.

Ватан сугышының баталияләре тарихына "Кече җир" дип кереп калган Новороссийск шәһәренә дүрт милләтнең дүрт эзтабары килеп төшә.

"Әйтергә кирәк, "Кече җир"дәге Сәләхетдин Вәлиуллин Тәтеш районында туып-үскән татар егете булып чыкты, шуның белән берлектә, мин аның туганнарын эзләп таптым..."

Әлки районы хезмәтчәннәре белән бергә уңнан сулга: Самат Шакир, Фәннур Сафин, Риф Гатауллин. 1982 ел.

Самат Шакир бүгенгеләр күз алдына китерә алмастай самими, беркатлы һәм чиста күңелле юаш кеше иде. "Кече җир" турындагы сөяхәтнәмәсен ул Әлки якларында егермә дүрт җирдә сөйләде. Һәм сөйләгән саен, Сәләхетдин Вәлиуллин исемен әйткәндә, шул сөенечне үз күңеле аша үткәреп, дулкынлана, каен яфрагы чаклы гына яшел кульяулыгын дүрткә бөкләп, күз төпләреп корытып ала...

Ул хәтта банкетлардан соң рәхмәт әйткән чакларда да үзенчә эчкерсез булып кала иде:

"Искиткеч зур рәхмәт Сезгә! Әйтергә кирәк, безне әле беркайчан да бу хәтле сыйлаганнары югые..."

Галимҗан Латыйпка рәхмәтнең бу рәвешчә әйтелүе охшап бетми. Урамга чыккач Самат Шакирны битәрли башлый:

"Нәрсә дип җебеп төштең?! Беркайчан да бу хәтлек сыйламаганнарые, имеш... Язучы халкын бөтен җирдә дә гел шулай хөрмәтлиләр икән дип уйласыннар өчен, рәхмәтне сабыр гына әйтергә кирәк."

"Ник, әйбәт сыйладылар ич инде, шуның белән берлектә..."—дип, Самат Шакир тагын нидер өстәп акланмакчы була, ләкин Галимҗан Латыйп кырт бүлдерә:

"Нормально! Нормально..."

Кышкы сәфәрләрдә Әлкидән кайтыр өчен Чулман аша боз кичәсе бар. Хәлбуки, ул елларда әле бүгенге күпер хыялда да юк. Декабрь ахыры булуга карамастан боз юка, төрәзәдәй үтә күренмәле. Шомландырып торган кара-кучкыл агым өстеннән барасың. Бу төрәзәнең берәр өлгесе чатнап китсә—котылу юк дигән шөбһәдән гәүдәләр тагын да авырая.

Фәннур Сафин белән Риф Гатауллин, бер-берсеннән үн метрлап ара калдырып, алдан баралар...

Син алдан атла, дип, ара калдырып барган Самат абый, үзе үк "эһ!" дигәнче мине куып житте дә белөгемә килеп ябышты—котылам димә... Икәүләшеп барырга рөхсәт итмиләр, боз ярылса батабыз, дип, аңлатып карыйм. Әнә нисе дә китми:

"Кире борылмам. Без дуслар ич инде, батсак бергә батарбыз!"

Чулман бозын без бик озак кичтек. Хәтәрне оныттырып өчен ул гел сөйләнеп барды.

"Мин Брежневка багышлап шигырь язган идем, әйтергә кирәк, Сара апаң Садыйкова аны көйгә салды. Кассетага күчереп жибәргән идек Үзенә... Сиңа гына әйтәм инде: Брежневтан Рәхмәт хаты килде. Шуның белән берлектә, бу рәхмәтнең

пенсиягә чыкканда ярдәме тияргә мөмкин диделәр...”

Боз кичүеннән соң күп тә үтмәде Л. И. Брежнев гүр иясе булды. Ил халкы бер кайгырса—Самат абый биш кайгырды:

“Мин пенсиягә чыкканчы гына яшәмәде ичмасам”.

Әлкидән кайткач, Самат абый Язучылар йортына ешрак килә башлады. Килгәч тә: вакыт уздырып өчен генә бүлмәдән бүлмәгә сугылып йөрмәде; утыздан артык китап авторы булса да ижат йортларына путевкалар белешеп кермәде; акчага кинәнмәсә дә матди ярдәм сорап әдәби фонд директорын йөдәтмәде... Кульязмаларын калдырып, хәл-әхвәлләрне белешер дә оялып кына китеп барып. Авырган чакларында аның шигырьләрен кызы Зөбәржәт китерә иде.

Инеңә төшкән калын толымлы, зифа буйлы, хан кызыдай нурлы йөзле, ягымлы тавышлы кызы белән Самат абый һәрчак горурланды. Чынлап та, чибәрлеге, сөйкемлелеге һәм тәрбиялелеге белән Зөбәржәт шагыйрьләрнең күз явын ала иде. Аны күргәч, Самат Шакир ижатына карата игътирамның тагын да ныграк арта иде.

Арабыздан киткән шәхесләрне зар елап сагынасы урында мин аларның берәр күңелле якларын истә калдырырга тырышам...

Л. Брежневны Ю. Андропов алыштырды.

Самат Шакирның пенсиягә чыгар вакытлары бөтенләй якынайды. Бауман урамыннан икәүләшеп атлыйбыз.

“Сиңа гына әйтәм инде, бер көнне санап утырдым, әйтергә кирәк, миндә йөз дә кырык ике мактау грамотасы җыелган. Пенсиягә бераз файдасы тимәс микән?”

“Ул кадәресен белмим шул, Самат абый.”

“Әллә, миңәйтәм, Андроповка багышлап та җыр язып карыйк микән?”

“Син нәрсә, Самат абый, Андропов КГБдан килгән кеше бит ул. Дәрес аңламас, татарлар куштан икән, диярлә!”

“Шулай дисеңме?! Алайса Сара апаңа тизрәк шалтыратыйм әле. Ул аның көен чыгара башлаган иде бит инде...”

Әдәбият юлы бозлы идел кичү кебек. Тайгак, шомлы, хәвефле, алдавыч, әмма мәртәбәле кичүне бик сирәкләр генә исән чыга ала. Кемдер егылып кала, кемнеңдер аяк астында боз чатный, кемнәребез Самат абый кебек сәер үлемгә дучар була да үзеннән соң җавапсыз сораулар гына өеп калдыра...

Самат Шакирның архивында язучылар, генераллар, сугыш һәм хезмәт батырлары, житәкчеләр белән төшкән фотолары бик күп. Ләкин мин журнал укучыларыбызга үз кулларым белән төшергән гап-гади бер фотоны тәкъдим итәргә телим...

Камил КӘРИМОВ

Нәниләр дөньясы

Вәсимә Хәйруллина

Без балалар

Җир-анабыз!
Без балалар —
Синең алтын бөртекләрең.
Әй, һавабыз!
Без балалар —
Синең нәни бөркетләрең.

Кояшыбыз!
Без балалар —
Синең вак-вак чаткыларың.

Чишмә суы!
Без балалар —
Синең көмеш тамчыларың.

Газиз Ватан!
Без балалар —
Аяк бастык синдә туып.
Сине яклаячак буын,
Сине саклаячак буын
Без ул, без ул — балаларың!

Татар иле

Татар иле, татар жире,
Исә синдә саба жиле.
Алтын кебек синең кырлар,
Ялкын кебек дәртле җырлар.

Җәен-кышын, язын-көзен
Кунакчыл син, ачык йөзең.
Оста мәргән, үткен күзең,
Жордыр телең, тапкыр сүзең.

Йөзең чибәр, гүя чәчәк,
Табының мул: бәлеш, чәкчәк.
Чал тарихлы, тирән уйлы,
Ничә гасыр сабантуйлы.

Мәйданында яшь батырлар
Сөлге белән бил тотарлар.
Йоклаганны уятырлар,
Татар жирен яңартырлар.

Илбашы булсаммы...

Иелеп партага,
Язалар балалар.
Башлары төрледән:
Ак, сары, каралар.
Тып-тыныч сыйныфта,
Йөгерек күллары.
Кулдан да елдамнар
Аларның уйлары.
Олгаеп киткәннәр,
Язалар иншалар.
Аларны әгәр дә
Илбашы булсалар,
Мәктәпләр, бакчалар,
Юл, күпер салалар.

Әзсенеп язганны,
Уйланып калалар.
Аннан зур хәрефтән
Яазалар: "Тынычлык!
Илбашы булсам мин.
Куярмын тыршлык
Сау булсын, дип, дөнья,
Сау булсын ир башы.
Сугышлар башламам,
Булсам мин илбашы".

Шәп ил

Ул илме?
Шәп ил ул:
Зәп-зәңгәр, ямь-яшел, кып-кызыл.
Яп-якты, бик рәхәт,
Син анда йә "улым", йә "кызым".
Сап-сары комлыклар.
Агач ат, кылычлар, курчаклар.
Прәннек, кәнфитләр,
Кәнфиттәй һай, тәмле ул чаклар.
Ул илдә
Әнкәңнең
Җып-җылы кочагы,
Иркәлек.
Тик аннан без никтер
Ашыгып китәбез иртәрәк...
Бер киткәч ул илдән,
Юл ана ябылып
Калачак.
Салават күпере
Шикелле
Бер мизгел балачак.

Икмәк

Түгәрәк ипи, кара,
Бик тәмле, кабып кара.

Майдай йөрәккә ята,
Аны һәркем ярата.

Янында алсу йөзле
Калачлар төрле-төрле.

Булса да нинди төстә,
Ия ул олы кочкә.

Икмәк жирдән кеч алган,
Орлык эченә салган.

Кояш өстәгән дәрман,
Су, үс, дип биргән фәрман.

Үскән шулай, чыныккан,
Мичтә көчен ныгыткан.

Кара һәм ак түгәрәк
Чыккан мичтән тәгәрәп.

Җыйган көчләрен хәзер
Безгә бирергә әзер.

Син бик кирәкле кеше

Белеп үс кечкенәдән,
Син бик кирәкле кеше.
Ә кирәкле кешенең
Була яраткан эше.

Яратсаң авыл эшен —
Көтә җәйрәгән кырлар.
Синең өчен таң атар,
Тургайлар сиңа җырлар.

Урманнар көтә сине,
Анда җәнлекләр көтә.
Кош-корты һәм бөҗәге
Барсы сине үз итә.

Таулар, диңгезләр көтә.
Космодромнар, вокзаллар.

Барысы да киң итеп
Ишекләрен ачканнар.

Теләсәң, яз китаплар,
Йә артист бул, көй чыгар.
Бәлки, синнән бер дигән
Милиционер чыгар.

Күп укы да галим бул,
Ясарсың яңа ачыш.
Табиб бул, укытучы —
Дәрт-дәрман тора ташып.

Син бик кирәкле кеше,
Тик тот шуны исеңдә:
Алтын куллы, йомры башлы
Бул сайлаган эшеңдә.

Юмор-сатира

Тәлгать Нәҗмиев

САБА ХИКМӘТЛӘРЕ

Йә Сәйдәш, йә Тукай...

Нинди генә кушамат такмылар адәм баласына. "Кушамат" үзе дә кушма сүз—ат кушу, димәк. Саба кешеләренә бик борынгыдан кушылганнар алар. Мәсәлән: Кәләм Каш Сабиры, Төлке Гарифы, Акыллы Йосыфы һ.б.

Кушаматлар бүген дә тагылып тора.

Тукай чатында көне буе узган-барган транспортны күзәткәне өчен юл хәрәкәте иминлегге инспекторы Рушанга "Тукай" кушаматы чәпәгәнһәр... Бик килешеп тора аңа бөек шагыйребез исеме. Аннары Рушан үзе дә шигъри жанлы Мулланур Әхмәтсафин (псевдонимы Нурсаф) малае бит әле. Мулланур абыйга минем үземнең дә гомерлек эчке бер ихтирамым бар. Илленче еллардан бирле, ягъни яртысы гасыр буе яза ул шигъри сәйләнһәрне. Ижатка фатиханы Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Газиз Нәбиуллин кебек шәхесләрдән (алар Сабага килгәч, билгеле) алган.

Шулай итеп, Рушанга "Тукай" кушаматы бирелүдә бернинди хилафлык юктыр, дип уйлыйм.

Шушы Тукай белән бәйле бер вакыйганы "Истә тотарга кирәк" дип, күңелгә салып куйган идем. Әлеге дә баягы, КВН вакытында район эчке эшләр бүлеге белән "Сабагазстрой" филиалы командалары ярыша.

—Мин ГАИга эшкә керәм әле,—дигән була бәйгедә катнашучы берәү.

—Исемең ничек?—дип сорый "Сабагазстрой" филиалы командасы капитаны.

—Әлфәрит...

—Сине эшкә алмаячаклар. ГАИда эшләү өчен йә Сәйдәш (ЮХИДИ хезмәткәре Сәйдәш Латыйпов күздә тотыла), йә Тукай булырга кирәк...

Якут туй

Сабаның кемнәре генә юк. Академиклары, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреатлары, язучылары, композиторлары, артистлары, режиссерлары, хәтта зәңгәр экран йолдызлары, курчак уйнатучылары да бар...

Наилә Ногманова егерме елга якын "Татарстан" телевидениесе экраны аша җылылык, сафлык, гүзәллек бөркеде. Хәзер ул Казан дәүләт университетының журналистика һәм социология факультетында телевидение теле дәресләре алып бара. Мөлаем, чибәр дикторны бөтен Татарстан халкы әле дә хәтерли. Мин, шәхсән үзем, аларны кырык елга якын беләм. Төп чыгышы Ядегәр авылыннан булган Ренат Ногманов белән алтмышынчы елларда комсомол туйлары ясап, бөтен бистәне шаулатканнар иде. Аңарчы, Ренат белән Наилә, курчак театрында эшләп кайткан булганнар. Кыскасы, Ренат Миңнулла улы күренекле артист та, режиссер да, житәкче дә, эшмәкәр дә.

Алар мине олы вакыйгага—Наилә ханым белән бергә гомер итә башлауларына кырык ел тулу тантанасына чакырдылар. Саба сандугачы Рисәнә Мостафина, редакциянең мөңгелек шоферы Фиргать—өчебез район делегациясе ясап бардык.

Искиткеч шәп үттө якташларымның Якут туйлары (кырык ел бергә яшәү шулай

дип атала бит). Чакыру билетлары да бик матур эшләнгән иде. Район хакимияте аппараты җитәкчесе Расих Сабиров кечкенәдән үк рус мәктәбендә укыганлыктан, кайбер татар сүзләренең нечкәлекләрен сизмәләп бетерми иде. Ул өстәлдәге чакыру билетына күзен нәбәкәйләндереп бик озак карап торды да:

—Болар башта Якутиядә яшәгәннәрмени?—дип сорап куйды.

Рәхмәт яугыры

Нинди генә жыелышларга йөрмәдек инде без. СССР таркалды, җәмгыять үзгәрде, әмма ул семинар-киңәшмәләр, утырышлар кимемәде. 2003 елда, ай саен диярлек, кайсы да булса җирле үзидарә Советы утырышына барып, һәр учреждениедә сарыф ителгән газныц, электр энергиясенең күпме тотылганын анализлап, житәкчесенең хисабын тыңладык. Экономия булса—сөендек, артык ягылса—көендек...

Шундый утырышка—Иштуган бистәсенә дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеге үзәге хуҗасы, Татарстан Республикасының атказанган табибы Мәгъсүм Гаффаровны жибәргәннәр.

Югарыда язылган төп көн тәртипләре төгәлләнгәннән соң, утырыштагылар чираттагы мәсьәләгә—газета-журналларга язылу проблемаларына күчәләр. Шул минутларда баш вәкил Мәгъсүм Мансур улы район газетасының исемен онытып жибәрә бит.

—"Колхоз байрагы"на, юк ла инде "Җиңү байрагы"на, алай да түгел, карале, тел очында гына тора, әйтеп булмый, үләме әллә кайәре! Бар бит инде, ни, редакторы, ни, ишәккә арты белән атланып йөри торган. Үзегез дә беләсез бит инде... Язылыгыз инде шуның гәжитенә,—дип, бурыч куйган, рәхмәт яугыры.

Пижамалы тараканн

Мәгъсүм Гаффаров белән бәйле тагын бер хәл.

Сабалылар аны якын итеп "Максим" диләр. 2002 елның чәчәкле җәендә аның язмышы иллене сукты. Ярты гасырлык юбилей—ир-егетнең тормышта 5:0 белән жиңүе бит ул.

Мин дә иң изге теләкләремне житкергәнгә соң: "Мәгъсүм—летун түгел, бер көнәфидә иң озак утыручы житәкчеләр арасында икенче урынны тота",—дигән булдым.

—Беренчесе үзеңме?—диешеләр төрле яктан, мине бик шәп белгән якташларым.

Аннары сүз үзеннән-үзе икенче темага—җәй көне халыкны туңкайта торган колорадо коңгызына күчте.

—Ул пижамалы тараканнан окончательно котылдым мин,—дидем горур кыяфәт белән.

—Ничек итеп?—ди, Мәгъсүм, гаҗәпләнүен яшермичә.

—Бөрәнге утыртмадым.

Тишегенең эченә...

Кайбер вакытта миннән: "Ижат кешесе башкалардан нәрсәсе белән аерыла ул?"—дип сорыйлар.

—Әгәр дә каләм тибрәтүче "Лифт ватылды" дигән ия белән хәбәрдән генә торган жөмләне "Лифтны паралич сукты" дип язса, бу ижат әһеле була инде, димен. Аңлашылып житмәсә, тагын бер жөмлә белән ныгытам фикеремне. Мәсәлән, гади кеше: "Сандугачлар алмагачка оя ясый",—дип жөмләне тәмамлый. Ә безнең халыкныкы бер чиреккә арта инде: "Сандугачлар оя ясый алма агачы ботагының тишегенең эченә",—дип тасвирлый.

Җиңү яулау җиңел түгел

Саба ягы үзенең көмешчеләре, итек басу, кап сугу, хәтта аш-су осталары белән дә дан тоткан. Олы Кибәхҗә авылында туып-үскән Юныс Әхмәтҗанов исә дистәләгән мактаулы исемгә, хәтта Ленин орденына лаек булган кеше. Бөек аш-су остасы, повар иде Юныс ага. Ул Мәскәүдәге Олимпиадада спортчыларны да сыйлады, Германиядәге Лейпциг ярминкәсендә, милли ашларыбызны тәкъдим итте. Якташыбызның "Татар ашлары" китабы халык кулыннан төшмәде. Остазның әшен мөнгелөштерел, ризык төмен белүче чын гурманның төрле елларда чыккан унөч китабы берләштерелеп, фотосүрәтләр белән нәшер ителде.

Гаилә хәле турында да берничә җөмлә.

1948 елда Юныс абый, мехкомбинат клубында, тегүче кыз Зәйтүнә белән таныша. Дурт елдан соң гаилә корып, утыз ике ел буе пар күгәрченнәрдәй яшәп калалар. Уллары Фоат Казан технология университеты спортзал директоры, тренер. Кызлары Фәридә әтиләре юлыннан китә, "Бәхетле" ширкәтенең кондитер цехы начальнигы, кулинарларның төбәкара ассоциациясе (МАК) әгъзасы, Мәскәүдә узган кондитерларның Россия бәйгесе лауреаты, Франция кулинарлар академиясе дипломанты.

Юныс ага районда үткәрелгән зур чараларга кайтып, ярдәм кулын суза иде. Гомумән, ул туган ягының ватанпәрвәре булды. Шуны раслау өчен бер хәлне искә төшерик әле.

Элек Казан телевидениесе районнар арасында телеконкурслар оештыра иде. Безгә 1974 елның ноябрендә арчалылар белән көрәшергә насыйп булды.

Көрәш киренке булды, әлбәттә. Ике районнан колхоз рәисләре, агрономнар, икътисадчылар, инженерлар, механизаторлар, шоферлар, милли көрәш осталары, сыер савучылар ярышты. Алдан урыннарга барып төшерелгән сюжетлар күрсәтелеп бәялөнде. Ике терлекче токмач кисәргә дә тиеш иде. Токмач сыйфатлы да, күләмле дә булырга тиеш иде. Жюрида Юныс ага Әхмәтҗанов бар. Аның: "Саба кызы үң яктагы пычакны алсын",—дигән серле вә яшерен сүзе чыбыксыз телефон аша килеп иреште. Безнең пычак артык үткен булган, токмачны гына түгел, кызыбызның бармагын да шәп кисте ул.

Телевизор экранында токмач өстенә кып-кызыл кан сузылганын күреп, тамашачы "ah" итте. Кыскасы, без, сабалылар, байтак конкурста өстенлек яуладык һәм 52:49 исәбе белән җиңдек. Кан коеп алган җиңү иде ул.

Үзе юк

Кышкы айларда тавыкларыбыз ялкаулыкка чыкты. Казанга киткәндә хәләлем өч-дүрт дистә йомырка сатып алырга кушкан иде.

Ул көнне, ничектер, иртәрәк кайтылды. Шофер Фиргатькә әйберләрне өйгә илтергә кушып, үзем редакциягә кереп калдым.

Фиргать китеп озак вакыт үтмәгән, Мәскәүдән Кадим дус шылтыратып, мине сораган.

—Йомыркалары кайтты, үзе күренми әле,—дигән хәләлем, аны-моны уйламыйча.

Сыер хәле

Апрель аенда "Бәкер"дә Фәйзерахмановлар гаиләсе белән бергә туры килдек. Хажи Ибраһим улын күреп беләдериек инде. Саба лесхозының баш инженеры, Лубән урман техникумын төмамлап, яшь белгеч өчен барлык баскычларны үткән шәхес. Тумышы белән Арча районының Носы авылыннан. Хажи әфәнде ишле балалы Фәйзерахмановлар гаиләсенең төпчеге (олы абыйсы Җәүдәт Казан авыл хуҗалыгы академиясе ректоры). Әтисе вафат булганда карында калган була Хажиебыз.

Хажиның хәләле Сабабаш авылы кызы Әлфия икән. Укытучы. Кыскасы, югары культуралы гаилә.

—Өйгә кайтсак, чәйне сөтләп эчәр идек,—дип куйды гаилә башлыгы.

—Белмим шул,—диде Әлфиясе,—сыерыбыз бит ни, декрет ялына чыга...

"Галстуклы" кунаклар

Ут күршеләр. Элек, шырпы юкта, учагын сүнсә бер-беренә ут алырга, яки кич утырырга керә торган күршене шулай атаганнар. Хәзер андый күршеләр юк диярлек. Ә менә ахирәт дуслар бар әле.

Югары Утар балалар йорты интернаты директоры, Россия Федерациясенең атказанган социаль-тәэминат хезмәткәре, районыбызның "Алтын йөрәкле кеше" исеменә лаек булган подполковник Имаметдин Гәрәев, озак еллар район эчке эшләр бүлеге начальнигы булып эшләде. Отставкага киткәннән соң ул салым инспекциясен җитәкләүче Раушан Әхмәтуллин, Пенсия фондының район идарәсе начальнигы Рәстәм Хисмәтуллов, "Саба ремонт-төзелеш участогы" җитәкчесе Ринат Сөнгатов белән күптәнге сыналган, аерылмас чын дуслар иде. Бәхәскә кергән очракта, бер-беренә юл куялар, җыен юк-барны "чәйнәп" утырмыйлар, "замана шайганы" белән мавыкмыйлар. Һәм әлбәттә, иркенләп мунча чабынырга да каршы килмиләр. Берсендә, дөрестән дә бик озак торалар болар мунчада.

—Гөлнара, бар хәлләрен белеп кайт әле, кунаклар һушларыннан язып егылмадылар микән?—ди өстәл әзерләп йөргән иманлы Гәрәевич.

Тәрәзәгә пленка да кадакланган була ахры. Эчтәге хәлләрне бик ачык күреп бетерә алмаган Гөлнара кайткач болай ди:

—Кунаклар исән-сау. Ләүкәгә тезелешеп утыргганнар. Нигәдер "галстукларын" гына салмаганнар...

Сырттан йөрү

Биналар, бүлмәләр генә түгел машиналар да туза, яңа маркалары чыга тора. Элек җитәкчеләр нигездә "ГАЗ-69"ларда йөрделәр. Алар сәнәүлы гына булганлыктан, һәр машинаның дәүләт номерын яттан белә идек.

Өр-яңа "УАЗ"икка утырып 1972 елда Татарстан Югары Советы Рәисе Салих Гыйлемхан улы Батыев килде. Ул "Искра" колхозына СССРның 50 еллыгы уңаеннан Истәлек Билгесе ордены тапшырды. Һәркем исе китеп карады яңа "люфковой"ны. Тиздән колхоз рәисе Миннехан Нигъмәтҗановка да нәкъ шундый машина кайтты. Әмма утырып йөрергә насыйп булмады рәискә, аны район авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы итеп күчергәннәр иде инде. Яңа машина башта "Авангард" колхозында баш агроном, аннары КПСС райкомының өештыру бүлеге инструкторы булып эшләп, соңыннан шушы хуҗалыкка рәис итеп тәкъдим ителгән Габдәлмәннәф Әхтәмовка бик кулай килде. Батыевка рәхмәт укый-укый шактый еллар йөрделәр ул машинада.

Ә менә тәүге ике генә ишекле "Нива" райбашкарма рәисе Габделхак Мәүлә улына кайтты. Озак тотмады, Иске Җәри авыл Советы рәисенә күчерелгәч куйды ул аны. Арткы ишеге булмагач, ошатмаган:

—Сырттан йөриләр,—дип әйткән ди.

Үзенә көкре

Кайчагында мин бик уңай булам,
Ачу кылган чакта—бик күрә.
Бармакларым минем—үземә таба,
Гәүдәм—җиргә таба көкере.

Илдар Юзи.

Хәзер "Саба дулкыннары" телерадиокомпаниясен җитәкләүче Фоат Әхмәтшин заманында ВЛКСМ райкомының беренче секретаре итеп сайланган кеше. Аннары байтак еллар буе район эчке эшләр бүлеге начальнигының урынбасары булып та эшләде. Спортта актив катнаша. Татарча көрәш буенча хөкемдарлык та итә.

Ризык өзерләргә кулы ятып тора. Армиядә аш-су остасы булган. Бигрәк тә шашлама пешерергә ярата. Бала чакта тормышның әчесен-төчесен күп күрә ул. Тугыз айлык вакытта кайнап торган самовыр суына пешеп, үлем газаплары кичерә. Ике кулының да чәнти бармаклары учына таба бөгелеп, гомергә катып кала. Ул үзе шаяртырга бик ярата. Шуна күрә мин дә күрешкәндә шаяртып алам:

—Район җитәкчеләре арасында бармаклары үзенә көкре бердәнбер кеше син,—дигән булам.

Берлекнең яңа әгъзалары

Галиәхмәт Шаһи

Шаһиәхмәтов Галиәхмәт Шаһиәхмәт улы 1949 елны Татарстанның Арча районы Шура авылында туган. Үз авылында сигезьеллык мәктәпне тәмамлагач, аңа туган якларын озак елларга калдырып китәргә туры килә. Башта Йошкар-Олада урта белем ала һәм технология техникумына укырга керә. Диплом алгач сәүдә системасында эшли. Яшьлек романтикасы Галиәхмәтне Уфа, Оренбург, Ташкент, Алма-Ата шәһәрләренә, аннан комсомол путевкасы белән Оренбург өлкәсендәге Ирикла ГРЭСы төзелешенә алып килә. Анда дүрт ел эшләргәннән соң, Галиәхмәт туган якларына әйләнеп кайта, Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә читтән торып укырга керә. Университетта укыган елларда Арча районы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли. Шул елларда аның вакыйты матбугатта беренче шигырьләре басыла. 1982 елда Г. Шаһи Чаллы якларына юл тота. Башта Мөслим районы Баек авылында әдәбият укыта. 1984 елда Чаллы шәһәренә килеп урнаша һәм биш еллап мәктәптә эшли. Ләкин, сәламәтлегә кагшау сәбәпле, яраткан һөнәрен ташларга туры килә. Хәзерге вакытта ул Чаллы шәһәрендә фокатъ ижат эше белән генә шөгыльләнә. 1997 елны Чаллы шәһәре нәшриятында "Кояшлы юл" исемле беренче шигырьләр җыентыгы басылып чыга. Хәзерге көндә ул берничә китап авторы. Татарстан Язучылар бирлегe идарәсенең 28 январьда узган утырышында Галиәхмәт Шаһи Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителде.

Ринат Баттал

Батталов Ринат Гыймазетдин улы 1948 елны Татарстанның Әгерҗе районы Ырыс авылында колхозчы гаиләсендә туа. Урта мәктәпне тәмамлагач армия сафларында була. Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлый, соңрак Ижевск университетында югары белем ала. Хезмәт шөгыльләре — трактурист, почтальон, авыл советы секретаре, район газетасы хезмәткәре, инженер, профсоюз әһеле...

Ринат Баттал шигырьләрне мәктәп елларында ук язса да, җитди ижат белән шөгыльләнүе соңгы ун елга туры килә. Түбән Кама су саклагычы төзелеп, туган авылы су астында калу да аның күңелендә җәрәхәтле тәэсир ясаган, күрәсен. Ярсу һәм тыелгысыз хис шигырь юлларын булып ташыган. Бу хакта Р. Батталга тәкъдимнамә биргән якташы Мансур Вәлиев болай яза: "Ринат белән без туып-үскән Иж буйлары, Әгерҗе якларын табигате белән генә түгел, кешеләре белән дә бик кызыклы, ә авыллар күченү белән бәйле хәллəр ижат кешесе өчен бик күп фаҗигалә вакыйгалар да китереп чыгарды. Ринат Батталның "Агымсуда — акчарлак" исемле китабында ул хис-тойгылар бик ачык чагыла".

2004 елның январенда Кабул итү Коллегиясе карары нигезендә (рекомендация бирүчеләр: Р. Шәфи, М. Вәлиев, Г. Гомәр) Язучылар берлеге Идарәсе Ринат Гыймазетдин улы Батталовны Татарстан Язучылар оешмасына әгъза итеп кабул итте.

«Казан утлары» архивыннан

Әдәби ел йомгакларына багышланган җыелыштан соң төшерелгән рәсем. Беренче рәттә, сулдан уңга — Сибгат Хәким, Нәкый Исәнбәт, Хәй Хисмәтуллин, Афзал Шамов, Сәйфи Кудаш, Хәсән Туфан, Гомәр Бәширов, Исмәгыйль Рәми, Идрис Туктар.
Икенче рәттә — Нури Арсланов, Фатих Хөсни, Әхмәт Исхак, Габдрахман Әпсәләмов, Мирсәй Әмир, Габдрахман Минский, Газиз Иделле, Гариф Галиев, Гариф Гобәй, Нәби Дәүли, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники. Казан. Язучыларның Тукай клубы (Бауман, 19), март, 1964 ел.

Казан университетында укыткан каләмдәшләр, галимнәр. Сулдан уңга — Азат Әхмәдуллин, Мөхәммәт Мәһдиев, Вахит Хаков. 1983 ел.

Фронтовик язучы Мәгъсүм Насыйбуллин. 2000 ел.

Шагыйрә Газизә Сәмитова (1862 — 1929) кабере янында Әстерхан өлкәсе. Ташлыяр авылы. Чәчәк салучысы — җырчы Рәхилә Мифтахова. 1992 ел.

Мәшһүр сәүдәгәрләр — бертуган Хөсәеневләр иганәсенә салынган "Хөсәения" мәдрәсәсе бинасы. XX гасыр башында төшерелгән рәсем.

Хатлардан юллар

* * *

Хөрмәтле редакция!

Мин "Казан утлары" журналын гомерем буе укып килүчеләрдән. Әле кечкенә чагымда бабам Рәхимҗан мәҗбүр итеп укыта, шуны укып бетермичә урамгә уйнарга да чыгармый торган иде. Тора-бара күнектем, журнал аерылгысыз юлдашыма, дустыма, киңәшчемә әверелде. Хәзер мина шул бабамны сагынып искә алам. Шулай итеп ул миндә туган телебезгә, әдәбиятка, татар мәдәниятенә һәм сәнгатенә әрату уяткан икән.

Без монда, Оренбург өлкәсендә, акрын гына урыслашып барабыз бугай. Тел югала бара, йолаларны, гореф-гадәтләребезне оныта башладык. Хәтта картлар да урамда сөйләшкәнде әртылаш урысча гына "себәрәләр". Дөрес, хәзер "ТНВ–Татарстан яңа гасыр" телевидение таптыруларын карыйбыз каравын. Жиде ел буе шуның өчен тырыштык, миллионнарча сум акчалар түктек. Ин сәере шунда, ул "ТНВ"да чыгыш ясаучылар татарча безгә караганда да начаррак сөйләшәләр. Татарның башкаласында яшәп тә шундый дәрәҗәгә төшеп була микәнни?! Сезнең журнал да андый хаталардан хали түгел. Әле менә "Казан утлары"ның 2003 елгы 6 нчы санын укып утырам. Розалина ханым Нуруллинаның "Томаннарга еллар күмелде" дигән язмасында телгә алынган кешеләр юк-юк та урыс сүзләре кушып сөйләшәләр. Тормышта, бәлки, шулайдыр да бит… Ә безнең саф, чиста татар сөйләмен ишетәсе килә. Без, ераткагы укучыларыгыз, сезнең аркада гына аз булса да татар булып яшибез лобаса. Жибәрмәгез әле андый тел-стиль хаталарын. Телебезнең саф чишмәсен Сез сакламасагыз, кем саклар.

Ихтирам белән **Госман САФИН.**
Оренбург өлкәсе, Богырыслан шәһәре.

***

Кадерле "Казан утлары"!

Мин бик күп татар балалары кебек үк озак еллар читтә йөргән кеше. Кайларда гына яшәргә туры килмәде. Өч ел Владивостокта, өч ел Калининградта, ике ел Архангельскида һәм егерме жиде ел Магадан шәһәрендә гомер кичердем. Кайда гына булсам да, үземнән татар жырларын, бигрәк тә Илһам Шакиров жырларын язылган пластинкаларны калдырмадым, "Казан утлары" журналын алдырырга тырыштым. Алар минем өчен изге ядкарьләр, туган жир жылысы кебек иде.

Без татарлардан диңгезчеләр аз түгел. Менә безнең гаиләдән генә дә дүрт туганның өчесе диңгезчеләр. Мин Кубада да булдым, экваторны берничә тапкыр кичеп үтәргә туры килде, Канадада, Данияда, башка бик күп илләрдә булдым. Охотск диңгезендә сигезәр ай бер дә яргә чыкмый ятарга туры килгән чаклар булды. Әйтәсе килгәнем шул, туган илләрне, туган телне, күнелгә якын газиз моңнарны сагынганда Илһам Шакиров, Габдулла Рәхимкулов пластинкалары жанымны, рухымны сихәтли иде. Журнал сәхифәләре аша туганнарым белән аралашам иде кебек. Кызганыч, Габдулла абый юк инде. Аллага шөкер, әле Илһам Шакиров бар. Мин бүгенге заман эстрадасының шырдый-бырдый жырларын бик үк кабул итеп бетерә алмыйм. Татар моңы дигәндә ин әүвәл колагымда Илһам Шакировның тылсымлы аһәңнәре яңгырый башлый. Аңа журналыгыз аша минем иксез-чиксез рәхмәтләремне, ихтирамымны житкерсәгез иде. Халкыбызның шундый олы талантларын исән чакларында үк кадерләргә, хөрмәтләргә кирәк. Журнал битләрендә андый якты шәхесләр турында очерк-язмалар ешрак күренсә начар булмас иде.

Сезгә исәнлек-саулык теләп **Равиль.**
Ульяновск өлкәсе, Парау авылы.

* * *

"Казан утлары"ның 2003 елгы 3 нче санындагы "Әткәй белән сөйләшү"не укып чыккач, кулыма каләм алмый булдыра алмадым. Шундый шәп, хисле вә тәэсирле язма өчен рәхмәтемне авторына да житкерәсем килде.

Хөрмәтле Наис Гамбәр туган! Сезнең ул язмагызны укыганда кире балачагыма әйләнеп кайткандай булдым. Үземнең дә шулай нарат үсентеләре утыртып йөргән, посадка арасында печән чапкан вакытлар бар иде. Шулхәтле жанлы итеп язгансыз, күз алдымнан кино кадрлары сыман яшьлегем еллары гына түгел, бөтен гомер юлым узгандай булды. Аталарны искә алырга, олылый белергә өйрәтә торган язма килеп чыккан. Ата кадерен белү бик үк житеп бетми кебек хәзер. Ихлас рәхмәт Сезгә. Минем бер юанычым бар, күңелемә якын шигырьләргә көйләр чыгарам. Язмагыз аязгындагы әткәгез турындагы шигырьне дә "көйле" итәсем килде. Минем ноталарым артык катлаулы түгел, әз генә өйрәнә башлаган теләсә кем аңларлык. Рәхмәт йөзеннән истәлегем булсын! Туганнарыгызга да күрсәтерсез, бәлки.

Изге теләкләрдә калучы **Мәсгут ИСХАКОВ**.
Әгерҗе районы.

* * *

Мин "Казан утлары"н инде 55 нче еллардан бирле алдырып киләм. Әле тагын "Ватаным Татарстан", "Татарстан яшьләре", "Мәдәни җомга" газитларенә, "Идел" журналына да язылам. Башка кешеләр ничектер, ә мин бу басмаларның бер саны 100 сум булса да алдырачакмын. Үземчә һәр укыган әсәргә 6-7 билге куям. Башта шигырьләргә күз төшерәм, аннан төнкыйть мәкаләләренә. Аннан соң гына күләмле чәчмә әсәрләргә күчәм. Дөресен әйтим, күңел төшенке чакта шигырь укысаң жанга рәхәт булып китә. Күңел чистарынып, сафланып кала. Әлләни кур инә инде. Үземчә шулай дип уйлыйм. Бер куплет өйбәт шигырь үзе бер поэмага тора ул. Миңа хәзер 64 яшь. Үз яшемнән миңа һәрчак үн яшькә кимрәк биреләр. Андыйларга мин "Картаясыгыз килмәсә, шигырь укыгыз" дип, җавап бирәм. Шигырьләрдән генә торган журнал чыгарып булмыймы икән? Юкса, монда шигырь китапларын, гомумән, татар китапларын табуы кыенрак.

Тагын... Татар язучыларының зураттыларын рәсемнәрен кайдан алдырып була икән? Аларны китапханә диварына тезеп куйсаң, үзе бер әдәби галерея булыр иде. Аларны мин үзем түләп алырга да риза. Ялгышмасам, андый рәсемнәрне соңгы елларда чыгарганнары юк кебек. Ә безгә, Татарстаннан читтә яшәүчеләргә андый рәсемнәр бик тә, бик тә кирәк.

Бохетле булыгыз! Эшләрегездә уңышлар телән –

Рафикъ ХӘЛИЛОВ.
Пермь өлкәсе, Түбән Сөн авылы.

* * *

Бу юлларны күз яшьләрем аша язам. Үзем мин Башкортстанга караган Дүртөйле районындагы Биектау авылыннан. Армиядән кайткач, 1953 елда вербовка буенча Новокузнецк шәһәренә киттем. 1993 елга хәтле күтәрү кранында эшләдем, аннан соң ун ел дворник булдым, ягъни урам себердем. Металлургия комбинатында кырык ел эшләп, хезмәт ветераны дигән исем дә бирмәделәр. Чөнки тел шома булмады, шулай булгач, кирәкле "агъм"га эләкмәдем. Хәер, анысы чукынып китсен, кирәге дә юк. Иң аянычы, гомер үтеп бара. Ә үкенечләремнең чиге-чамасы юк. Бүгенге көндә мин япа-ялгызым. 1954 елда язмышымны урыс хатыны белән бәйләгән идем. Ике кыз бала булды, татарча белмиләр. Милләтләре урыс. Оныклар да, аларның балалары да урыс халкына күшылдылар. Мин берүзем татар булып калдым. Хатын үлде. Ике кызымның икесе дә ирләре белән аерылып, урыс фамилиясендә калдылар. Оныклар Нәбиева булырга. Үл гынамы, Светлана Геннадьевна булып йөриләр. Әнгамовна түгел. Мина шундый эшләр... Мин бүген үземне милләтебезне саткан хаин итеп саныйм. Совет чорында бөтен татар халкы шулай таралып бетте шул. Заманы шундый иде. Безнең Новокузнецкида гына да минем язмышны кабатлаган кешеләр буа буарлык. Гомерем азагында милләтләшләремә үкенечле васыятемне житкерәсем килә: милләтегезгә хыянәт итмәгез, өйләнмәгез чит кавем кызларына, кияүгә чыкмагыз. Сатмагыз халкыбызны. Гомер азагында үкенерсез, соң булыр...

Бу хатны язгач, күңелгә бераз жиңел булып китте.

Әнгам НӘБИЕВ.
Кемерово өлкәсе, Новокузнецк шәһәре.

ИҖАТ ЙОРТЫ АЧЫЛДЫ

"Васильево" шифаханәсе территориясенда әдәбият-сәнгать әһелләре өчен күптән көтелгән иҗат йортын ачу тантанасы булды.

"Бу—әһәмиятле вакыйга,—диде Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев тантанада катнашучылар алдында ясаган чыгышында.—Иҗат кешесенә игътибар бик кирәк. Мин алдан ук белеп торам, бу бинаның һәр карышы байтак иҗат мизгелләрен үзенә сендереп калыр әле. Еллар узу белән мондагы һәр нәрсә зарым бер кыйммәткә ия булыр.

Иҗат йортын ачу тантанасында Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, Композиторлар берлеге рәисе Рәшит Кәлимуллин, В. Качалов исемендәге рус драма театрының баш режиссеры Александр Славутский һ. б. лар иҗат әһелләренә карата шундый кайгыртучанлык күрсәтүләре өчен Президентка һәм Татарстан хөкүмәтенә ихлас рәхмәтләрен белдерделәр.

Ике катлы мәһабәт бинада иҗат берлекләре әгъзаларына өеннән барлык уңайлы шартларны булган уникә бүлмә бар. Аларның дүрттесе язучылар өчен тәгаенләнә. Юллама хакының зур өлешен хөкүмәт күтәрәчәк.

Иҗат йортын ачу тантанасында Татарстан Премьер-министры урынбасары Зилә Вәлиева, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Роберт Миңнуллин, мәдәният министры Илдус Тарханов, иҗат берлекләре рәисләре, әдәбият-сәнгать әһелләре катнашты.

ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛЛӘР КИҢӘШТЕ

17 февральдә Казан Кремлендә Татарстан Республикасының Россия төбәкләрендә, якын һәм ерак чит илләрдәге вәкаләтле вәкилләренең киңәшмәсе узды.

Киңәшмәдә Татарстан Президентының халыкара мәсьәләләр буенча дәүләт киңәшчесе, ТР Президентының Тышкы багланышлар департаменты директоры Т. Акулов, ТР Президентының сәяси мәсьәләләр буенча киңәшчесе Р. Хәкимов, ТР Президентының хуҗалык эшләре белән идарә итүчесе Ж. Салихов, ТР Премьер-министры урынбасары—ТР икътисад һәм сәнәгать министры А. Пахомов, Россия Федерациясенең Тышкы эшләр министрлыгының Татарстандагы белән эшләү идарәсе начальнигы урынбасары С. Николаев, Мәскәү хөкүмәтенең халыкара элемтәләр департаментының чит илдәге ватандашларыбыз белән эшләү бүлеге начальнигы Ю. Каплун, шулай ук ТР Дәүләт Советы, ТР Мәдәният, Мәгариф министрлыклары вәкилләре, төрле ведомство, оешма җитәкчеләре катнашты. Вәкилләрнең 2003 елда башкарган эшчәнлеге, нигездә, унай бәяләнде. Әһәмиятле вакыйгалардан үткән елда Казанга ЮНЕСКОның генераль директоры Коитиро Мацуура, 30 илнең дипломатик вәкилләр җитәкчеләренең килүе, Казан оешуына 1000 ел тулуны ЮНЕСКОның юбилей даталары исемлегенә кертүе булды, Татарстанда Россия Федерациясенең кайбер субъектлары һәм кунәрне үтте. Шулай ук мөһим вакыйга—Татарстан Республикасы һәм Россиянең Тышкы эшләр министрлыгы 2003-2005 елларда халыкара һәм тышкы икътисади багланышларны тормышка ашыру буенча протоколга кул куйды. Федерация субъекты һәм Россиянең тышкы-сәяси ведомство арасында мондый документ беренче тапкыр төзелде, диде Ж. Салихов.

Т. Акулов билгеләп үткәнчә, РФ Президенты Владимир Путин Татарстан башкаласы Казанның 1000 еллыгын билгеләп үтүне Россиядә генә түгел, ә бөтендөнья күләм бәйрәм икәнен әйтте. Бүген Татарстан Республикасының Россия төбәкләрендә, якын һәм ерак чит илләрдәге вәкаләтле вәкилләре алдында торган мөһим бурычларның берсе—төбәкләрдә Казанның 1000 еллыгын пропагандалау, ана багышланган төрле чаралар үткәрү.

Утырышта деньянын төрле почмакында яшәүче татарларны дәрәҗәләр белән тәэмин итү, татар теле укытучыларының белемен күтәрү һәм аңадан әзерләү, туган телдәге басмаларга, вакытлы матбугатка язылу мәсьәләсе турында да сүз барды.

УФАДАГЫ МӨҺИМ ҖЫЕН

25 февраль көнне Уфада Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының күчмә утырышы булып үтте. Татар конгрессы оешканнан бирле бу аның Башкортстан башкаласындагы тәүге күчмә утырышы иде. Шуңа да аны Татарстан ягыннан ярдәмгә һәм теләктәшлеккә мохтаҗ булган Башкортстан татарларын зарыгып көткән иде.

Уфадагы бу мөһим чарага Казаннан Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров, БТК башкарма комитеты рәисе урынбасары, күренекле галим

Дамир Исхаков, БТК әгъзасы, Россиядәге милли-мәдәни мохтәриятләр эшчәнлеге координаторы Римзил Вәлиев, БТК башкарма комитеты әгъзасы Фәрит Уразаев, Татарстанның Башкортстандагы сәүдә-икътисадый вәкиллеге житәкчесе, БТК башкарма комитеты әгъзасы, Башкортстан татар конгрессы башкарма комитеты рәисе урынбасары Рамил Бигнов, Татарстан Сәүдә һәм икътисади хезмәттәшлек министрлыгы вәкиле Айдар Абдрахманов һәм БТК башкарма комитеты рәисенең матбугат секретаре Гөлназ Шәйхи килде.

Чиләбе, Пермь һәм Төмән өлкәләрендәге татар милли оешмалары вәкилләренең дә ерак аралардан якын итеп килүе бу җыенның географиясен тагын да киңәйтте.

Башкортстан ягыннан күчмә утырышка республиканың барлык татар милли оешмалары житәкчеләре һәм милли хәрәкәтнең актив әгъзалары, шулай ук дәүләт оешмаларының дәрәҗәле вәкилләре чакырылган иде. Мәһим сөйләшүнең кон тәртибена бер генә тема—"Башкортстан татарларының милли-мәдәни үсеше проблемалары турында" мәсьәлә кертелгән. Әмма кин колачлы бу тема, фикер алышулар барышында күптармаклыга өйләнде һәм ул Башкортстан татарларын борчыган күпсанлы мәсьәләләрне үз эченә алды.

Күчмә утырышны БТК башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров ачты һәм алып барды. Зур доклад белән дә ул чыгыш ясады. Р. Закиров бер ел ярым элек эшли башларан Бөтендөнья татар конгрессының яна башкарма комитеты башкарган эшләрә һәм төрле төбәкләрдә яшәүче татарларны борчыган проблемаларга тәфсилләп тукталды.

Аннан соң утырышта Татарстаннын Башкортстандагы сәүдә-икътисади вәкиллеге житәкчесе Рамил Бигнов чыгыш ясады. Ул үз чыгышында, нигезлә, Башкортстанда татар теленә дәүләт тел статусы бирү мәсьәләсенә, аны хәл итү юлларына тукталды. Рамил әфәнденен фикерләре ачык һәм төпле иде. "Башкортстанда яшәүче татарлар үз теленә дәүләт тел статусы алмыйча тынычлана алмаячак,— дип белдерде ул. —Президент Мортаза Рәхимов сайлаулар алдыннан бирган вәгъләсен сүзлә генә калдырмыйча, аны чынга ашыру өчен үзенен хакимият мөмкинлекләрен эшкә кушарга бурычлы".

Сөйләшүдә катнашучылар бигрәк тә Башкортстан татар конгрессы башкарма комитеты рәисе урынбасары, күренекле профессор Радик Сибәгатовның чыгышын зур хөрмәт белән кабул итте.

Аның ни очен Башкортстандагы татар теленә дә, башкорт һәм урыс телләре белән бергә, дәүләт тел статусы бирелергә тиешлеген тәгаен саннар һәм далилләр белән ныгытып сөйләве һәркемне ышандырырлык иде.

Утырышта алга таба чыгыш ясаучылар да Башкортстанда һәм башка төбәкләрдә татар милли-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү тәнгәлендәге көнүзәк проблемаларга тукталды һәм аларны хәл итү юлларын тәкъдим итте. Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының күчмә утырышында катнашучылар ил Президенты Владимир Путинга Башкортстанда татар теленә статус бирү мәсьәләсенәдә хәт әзерләдә һәм кабул итте. Бирелдә шулай ук, күчмә утырышта янгыраган бәхисап файдалы тәкъдимнәрне исәпкә алып, аерым резолюция кабул итү турында да кишәлеңде.

ЯЗУЧЫЛАР РАЙОННАРДА

Быел Татарстан Язучылар берлеге төзелүгә 70 ел тула. Юбилей мөнәсәбәте белән республикабызда күптөрле чаралар үткәрү күздә тотыла. Шул уңайдан Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Фоат Галимуллин житәкчелегендә бертөркем язучылар һәм сәнгать әһелләре Кукмара, Балтач, Арча, Бөектау, Яшел Үзән, Кайбыч, Тәтеш, Буа районнарында булып, мәдәният йортларында, мәктәпләрдә, хезмәт коллективларында күпсанлы очрашулар үткәрдә. Республикабыза Татар әдәбиятә хәзмәт күрсәткән язучы-шагыйрьләр Әхсән Баян, Мөсәгыйть Хәбибуллин, Мәдинә Мәликова, Резеда Вәлиева, Эльмира Шәрифуллина, Шаһинур Мостафин, Хәбир Ибраһим, Галимҗан Гыйльманов, Рифә Рахман, Зиннур Хөсниәр, Рафис Корбан, Газинур Морат, шулай ук Татарстанның атказанган артистлары Рәбига Сибгатуллина, Рамил Миңдияр, Татарстаннын атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор һәм музыкант Фәрит Хатипов катнаштылы.

ШАГЫЙРЬНЕ ИЛ ОНЫТМЫЙ

15 февральдә Мәскәудә Муса Жәлилне иске алу кичәсе үткәрелде. Ул һәр елны 15 февральдә Татар мәдәнияте үзәгендә—"Асадуллаев йорты"нда уздырыла. Әлеге үзәктә сугышка кадәр Муса Жәлил, башка татар язучылары, жырчы, композиторлар ещ булган.

Кичәдә жырчылар, герой-шагыйрьнен тормышын һәм иҗатын, моннан 60 ел элек немец төрмәсе Плетцензеезда жәзалап үтерелгән көрәштәшләренең язмышын нечкәлән белгән профессор Габделхак Әхтәмжан һәм шагыйрь-тәрҗемәче Вил Ганиев чыгыш ясадылар. Шулай ук язучы Әхмәт Саттар, профессор Әгъдәс Борһанов, Рифат Әбдиев, журналист Әхмәт Галимов һәм башкалар да Муса Жәлил турында сөйләделәр.

Әдәби-музыкаль кичәдә шагыйрьнен шигырьләре, аның сүзләренә язылган жырлар яңгырады.

Иске алу кичәсендә М. Жәлилнен кызы Чулпан да катнашты.

Кичәдә катнашучылар Татар мәдәният үзәгенә Муса Жәлил исеме бирүне сорап тиешле оешмаларга мөрәҗәгать итәргә кирәк булганлыгын белдерделәр.

ФАКИЛ САФИН КИЧӘСЕ

Чаллыда "Майдан" журналы баш мөхәррире Факил Сафинның 50 яшьлек юбилее узды. Аны тәбрикләргә Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Роберт Миннуллин, Язучылар берлегe рәисе Фоат Галимуллин, "Казан утлары" журналының баш мөхәррире, Татарстанның халык шагыйрә Равил Фәйзуллин, Татарстан язучыларының әдәбият фонды идарәсе рәисе Гәрәй Рәхим, депутат-язучылар Туфан Миңнуллин, Разил Вәлиев, мәдәният министры урынбасары Илфак Ибраһимов, Башкортстанның халык шагыйрә Марат Кәримов, шагыйрь һәм прозаик Марат Кәбиров һәм башка төбәкләрдән әдипләр килде.

Мөхәррирне шәһәр хакимияте исеменнән Чаллы мэры Илдар Халиков котлады.

Роберт Миннуллин Татарстан Президенты Указы белән хәзерге татар әдәбияты өлкәсендә һәм матбугатны үстерүдәге казанышлары өчен Сафин Факил Миннемөхәммәт улына "Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре" дигән мактаулы исем бирелүе хакында хәбәр итте. Дәүләт Советының Фәрит Мөхәммәтшин кул куйган котлавын тапшырды.

Тамаша залында юбилярның якташлары да күп җыелган иде. Туган як кешеләреннең уй-теләкләрен Мәслим районы хакимияте башлыгы Р. Хәбипов иреште рде.

Кичәдә Чаллы шәһәр театры артистлары башкарулында Факил Сафинның әсәрләре буенча әдәби-музыкаль композиция яңгыралды.

ЖЫРЧЫ ИСЕМЕНДӘГЕ ФЕСТИВАЛЬ

Бөтенденьа татар конгрессы башкарма комитеты, Түбән Новгород татарларының Казан шәһәрендәге "Якташтлар" җәмгыяте, "Казан" милли мәдәният үзәге һәм "Татарстан" журналы редакцияе быелның апрель-декабрь айларында Рәшит Баһапов исемендәге татар жыры фестивален гамәлгә кую турында карар кабул итте.

Фестиваль мәшһүр жырчы Рәшит Баһаповның халкыбызның рухи-мәдәни тормышында тоткан урынын, милләт булып сакланыш калуыбызда аның бәялеп бетергесез ролен истә тотып, моң иясенең мирасын барлау, пропагандалау, исемен мәңгеләштерү жәһәтеннән һәм татар халкының милли бердәмлеген нығыту, милли жыр сәнгатен камилләштерү максатыннан оештырыла.

Фестиваль чаралары Татарстанда гына түгел, ә татарлар яшәгән башка төбәкләрдә дә узачак. Фестиваль кысаларында жырчының якташы, "Татарстан" журналының баш мөхәррире Рифат Фәттаховның "Рәшит Баһапов" дигән китабын тәкъдир итү, жырчының язмаларыннан төзелгән аудио һәм компакт-диск чыгару, "Рәшит Баһапов һәм татар жыры сәнгате" дигән темага фәнни-гамәли конференция үткәрү күздә тотыла. Фестивальнең гала-концерты декабрь аенда Казан шәһәрендә узачак.

ОНЫТЫЛМАС КӨЙЛӘР ИЯСЕ

Мәшһүр композитор Фәрит Яруллинның 90 еллыгы республикабызда кин билгеләп үтелде. Башкортстандагы татар жәмәгатьчелеге дә бу датаны игътибарсызы калдырмады. Яруллиннар уфалылар өчен үз, якын исем. Үткән гасырның егерменче елларында, Фәритнең әтисе, күренекле музыкант Заһидулла Яруллин гаиләсе белән Уфада яшәгән булган.

Уфада Әхмәтзәки Вәлиди исемендәге республика милли китапханәсенең музыка залында Фәрит Яруллинның юбилее уңаенан икe чара булып үтте. Бу көнне бирелә журналистлар өчен матбугат очрашуы да оештырылды. Анда Фәрит Яруллинны якыннан белгән кешеләр дә катнашты. Күренекле балетмейстер, милләттәшебез Һашим Мостафевның композиторыбыз турындагы истәлекләре аеруча кызыклы иде. Әнде Уфадагы чараларга Фәрит Яруллинның бертуган энесе, күренекле композитор һәм мәгаллим Мирсәет Яруллинның да килүе уфалылар өчен сөенечле вакыйга булды.

ШӘРИФ КАМАЛ МУЗЕЕНДА

25 февральдә Ш. Камал музеенда әдипнең 120 еллыгына багышланган кичә үтте. Анда Шәриф Камалның "Акчарлаклар" спектакленнән өзекләрне Россиянең һәм Татарстанның халык артисткасы Нәжибә Ихсанова һәм Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Наил Әюпов башкарды. "Хажи әфәнде өйләнә" спектакленнән өзекләрне К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрыннан Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Наил Шәйхетдинов, Татарстанның халык артисты Ренат Мифтахов уйнады, Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Айрат Арсланов язучының новеллаларын укыды. Татарстанның халык артисткасы Нажия Терҗулова заманында Ш. Камал яраткан жырларны хәтердә яңартты.

Кичәне музей житәкчесе, шагыйрь Рәмис Аймәт алып барды. Бирелә катнашучылар "Матурлык туганда" дигән кургәзмәне карадылар. Анда Татарстан Милли музее фондында сакланган архив материаллар, кулъязмалар күелган иде. 26 февральдә музейда Ш. Камал һәм Г. Кутуй дуслыгына багышланган "Ерлар һәм язмышлар" дигән кичә узды.

ЯШЬ АВТОРЛАР ИГЪТИБАРЫНА

Татарстан Язучылар берлеге һәм "Идел" яшьләр үзәге инде биш ел яшь каләм тибрәтүчеләр арасында "Иделем акчарлагы" дигән конкурс оештырып килә.

Конкурста катнашу өчен проза, поэзия, драма жанрларында язылган әсәрләр 2004 елның 1 августына кадәр кабул ителә. Анда 14-30 яшьләрдәге авторлар катнаша ала. Авторларның әсәрләре компьютерда яисә машин-

када басылган хәлдә булырга тиеш.

Иҗатлары унай бәя алган сәләтле яшьләр шушы елның октябрь аенда Казанга чакырылып, "Чишмәкәй" лагеренда таныл-ган язучылар үткәрәчәк остаханәләрдә катнашу хокукы ала.

Әсәрләрне хат белән "Идел" яшьләр үзәгенә юлларга кирәк.

Адресы: 420107, Казан, Свердлов урамы, 12 нче йорт. Телефон 64-32-77.

ИҖАТ КИЧӘСЕ

Чаллы шәһәренең "Шатлык" яшьләр үзәгендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, галим Әнвәр Шәриповның иҗат кичәсе булып узды. Кичәдә аның хезмәттәшләре, студентлар, укытучылар, галимнәр, язучылар, шагыйрьләр катнашты. Әдәби җәмәгатьчелек Әнвәр Шәриповны Г. Утыз Имәни, Кол Шәриф иҗатларын, гомумән, урта гасырлар татар поэзиясен өйрәнүче галим буларак белә.

Кичә Чаллы педагогия институтының "Асылъяр" җыр ансамбле тарафыннан М. Имашевның Э. Шәрипов сүзләренә иҗат иткән "Сабантуйлы Татарстаным" җырын башкару белән башланып китте. Чаллы Язучылар оешмасы житәкчесе В. Имамов, "Мәйдан" журналы баш мөхәррире Ф. Сафин, Чаллы пединститутының фәнни эшләр буенча проректоры И. Сафуанов, шагыйрьләр Р. Бәшәр, Ф. Җәмәлетдинова, Р. Мөхияр һ. б. Әнвәр Шәриповның фәнни хезмәтләре, әдәби иҗаты турында сөйләделәр. Кичәдә композитор Р. Зарипов һәм Э. Шәрипов сүзләренә иҗат иткән "Әнкәй хатлары", "Соңлап килгән мәхәббәтем", "Аксыл томан", "Өтазы", "Сабантуй батыры", И. Закировның "Ага сулар" һәм башка җырлар яңгырады.

МИЛЛӘТТӘШЛӘРЕБЕЗ КҮРГӘЗМӘСЕ

"Казан" милли мәдәният үзәгенең сәнгать галереясында танылган Уфа рәссамы Рәсим Насыйбуллинның шәхси күргәзмәсе эшли.

Р. Насыйбуллин Уфа дәүләт сәнгать институтының сәнгать бүлеген тәмамлый, 1985 елдан Уфа дәүләт нефть һәм техника университетының архитектура кафедрасында рәсем дәресен укыта. Башкортстан һәм Россия Рәссамнар берлекләре әгъзасы Р. Насыйбуллин республика, зона, төбәк һәм Бөтенроссия күргәзмәләрендә актив катнашып килә. Авторның әсәрләре М. Нестеров исемендәге сәнгать, Башкорт дәүләт археология музейларында, Уфа сәнгать галереясында, кайберләре Англия, Израиль һәм Төркия дәүләтләре шәхси галереяларында урын алган.

Р. Насыйбуллин—күпкырлы рәссам, аның иҗатында реализм һәм авангардлык традицияләре үзара бәйләнгән.

"ТАТАР КИТАБЫ" КИБЕТЕ

Башкалабызда "Татар китабы" дигән яна кибет ачылды.

Ул Татарстан китап нәшрияте, "Мәгариф", "Яңалиф", "Хәтер", "Раннур", "Мәскәүнең "Инсан" һәм башка нәшриятләрдә басылып чыккан татар китапларын сату белән шогыльләнәчәк. Биредә әдәби әсәрләр, балалар әдәбияты, сүзлекләр, дәреслекләр, методик әсбаплар, Казанның 1000 еллыгына багышланган китаплар, Корьәннең төрле басмалары, шулай ук жыр сөючеләргә аудиокасеталар сатып алу мөмкинлеге дә бар.

Кибетнең адресы: Бауман урамы, 29/П нче йорт, "Нур-маркет" (жыр асты галереясе).

Тышлыктагы сурәтләр

Тышлыкның беренче битендә: Беренче чәчәкләр. ***Н. Исмәгыйлев фотосы.***

Тышлыкның дүртенче битендә: шагыйрә **Энҗе Мөэминова.**

Нурихан Фәттах

Татар әдәбияты авыр югалту кичерә: озакка сузылган каты авырудан соң, 18 февральдә 76 нчы яшендә Татарстанның халык язучысы, тарихчы-галим Нурихан Фәттахның тынгысыз йөрәге тибүдән туктады.

Нурихан Фәттах (Нурихан Садрилмән улы Фәттахов) 1928 елның 25 октябрендә Башкортстан Республикасының Яңавыл районындагы Күчтавыл дигән татар авылында игенче гаиләсендә туа. 1946 елда Яңавылдагы татар урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Диплом алгач, 1951 елдан 1952 елга кадәр Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты редакциясендә мөхәррир, ә 1952—1953 елларда Чистай шәһәрендә "Сталин байрагы" газетасы редакциясендә төрәмәче булып эшли. 1953 елның маеннан, яңадан Казанга кайтып, калган бөтен гомерен профессиональ язучылык эшенә багышлый.

Нурихан Фәттах, әдәбият белән балачактан кызыксынып, мәктәптә укыганда ук шигырьләр, хикәяләр яза башлый. Студент елларында фольклор экспедицияләрендә катнаша, халык ижаты әсәрләрен жыя, халыкның сөйләм теле үзенчәлекләрен, аның йолаларын, гореф-гадәтләрен һәм борынгы тарихи риваятьләрен мавыгып өйрәнә. 1944 елда "Совет әдәбияты" (хәзерге "Казан утлары") журналында аның беренче шигырьләре, ә 1948 елда "Безнең хикәяләр" исемле күмәк җыентыкта беренче проза әсәре дөнья күрә. 1955 елда ул "Сезиенчә ничек?" исемле беренче романын тәмамлый.

Илленче еллар урталарында, Казахстан далаларында чиләм жирләрне үзләштерү башлангач, Нурихан Фәттах ике ел рәттән берничә ай буе Павлодар өлкәсендә "Казан" совхозында эшли. 1962 елда аның "Бала күңеле далада" исемле зур романы языла. Бу әсәрне һәм аннан соң медицина хезмәткәрләре тормышыннан алып ижат ителгән "Мәдир Сажидә" повесте белән Нурихан Фәттах үзен татар прозасына үзенчәлекле шигъри бер төс, аһәң алып килгән каләм остасы итеп таныта.

Алтмышынчы еллардан башлап язучы төп игътибарын татар әдәбиятында күтәрелмәгән чиләм хәлендәге тарихи жанрга юнәлтә. Әдипнең "Ителсуы ака торур", "Сызгыра торган уклар" роман-трилогиясе, "Кол Гали" һәм "Сарматкызы Сәринә" исемле трагедияләре, "Ерак гасырлар авазы", "Шәжәрә", "Язык боги ов фараонов" исемле фәнни хезмәтләре — күпьеллык эзләнүләре нәтиҗәсе.

Нурихан Фәттах балалар әдәбиятында һәм әдәби төржемә өлкәсендә дә актив эшләде. Балалар өчен ул "Тегермәндә", "Өч туган", "Ирек, Алмас һәм Җалил", "Безнең бабай" исемле хикәя жыентыклары чыгарды, "Энжеле үрдәк" исемле өкият-пьеса язды.

Әдип татар телендә рус язучылары — Б. Житковның хикәя жыентыкларын, И. Васильевның "Звезда" повестен, француз классик язучылары — В. Гюгоның "Отверженные" романын, О. Бальзакның "Отец Горио" романы белән сайланма хикәяләрен төрәмәмә итте.

Әдәбиятыбызны үстерүдәге зур хезмәтләре өчен Нурихан Фәттахка 1976 елда "РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре" дигән мактаулы исем бирелде. 1994 елда "Сызгыра торган уклар" роман-трилогиясе өчен Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә, 1998 елда "Татарстан Республикасының халык язучысы" дигән абруйлы исемгә лаек булды.

Тарихны халыкка кайтару өлкәсендәге күп санлы хезмәтләре өчен Нурихан Фәттахка халыкара биографик үзәк (Кембридж, Англия) тарафыннан "1992 ел кешесе" исеме бирелде.

Нурихан Фәттах 1965 елдан СССР һәм Татарстан Язучылар берлекләре әгъзасы иде.

Барлык гомерен, көчен һәм ижатын халкыбызга багышлаган искиткеч талантлы һәм олы жанлы әдипне югалту безнең күңелләргә тирән сагыш салды. Үзеннән һәрвакыт нуряктылык сирпеп торган зыялы бу олуг шәхесенең кабатланмас образы безнең күңелләрдә мәңге сакланыр.

М.Ш. Шәймиев, Р.Н. Миңнеханов, Ф.Х. Мөхәммәтшин, Э.С. Гобәйдуллин, З.Р. Вәлиева, Р.М. Миңнуллин, И.Г. Тарханов, К.Ш. Исхаков, А.А. Камалиев, Ф.Г. Галимуллин, Р.Г. Тажетдинов, Т.А. Миңнуллин, Р.А. Фәйзуллин, Ш.Г. Галиев, И.Г. Юзеев, В.В. Корчагин, Г.А. Паушкин, М.М. Хәбибуллин, Р.М. Заһидуллин.

ЯҢА КИТАПЛАР

Татар шигърияте: 1980—2000 еллар.—Казан: "Мәгариф" нәшр., 2003.—352 бит.
Тиражы—3000 данә.

"Милли әдәбият китапханәсе" сериясендә нәшер ителгән бу җыентыкта олы һәм яшьрәк буын шагыйрьләреннең 1980—2000 елларда язылган әсәрләреннән иң камил үрнәкләр урын алган. Шигырьләр хәзерге татар поэзиясенең үсеш үзенчәлекләрен, тематик төрлелеген, сурәтләү байлыгын күздә тотып сайланган. Китап урта мәктәпнең өлкән сыйныф укучыларына, студентларга, укытучыларга, гомумән, шигърият сөючеләргә тәкъдим ителә.

Төзүчеләре—Тәлгат Галиуллин, Нурфия Гафиятуллина. Рәссамы—Л. Золондинова.

Имамов Вахит. Тозлы яра: роман.—
Казан: Татар кит. нәшр., 2004—384 бит.
Тиражы—5000 данә.

Язучының 50 яшьлегенә атап чыгарылган бу китапка кереш сүзне Марсель Галиев язган. "Бүгенге заманда язучы булып, фәкать каләмең белән шәхесеңне раслый алу—үзе бер фидакарьлек. Бу көч сирәкләргә бирелгән. Вахит Имамов әнә шундый сирәкләрнең берсе",—ди ул.

Романда сурәтләнгән вакыйгалар Башкортстан төбәгендә үткән гасырда булып узган хәлләргә нигезләнгән. Әсәр язучының октябрь инкыйлабына, колхозлашу хәрәкәтенә, япон сугышына һәм башка вакыйгаларга яңа күзлектән бәя бирүе белән дә кызыклы.

Китапның мөхәррире—И. Ногманов, рәссамы—И. Әжемов.

Индекс 73210

Энже Мөэминова

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)